Академия наук Республики Татарстан
Институт языка, литературы и искусства
имени Г.Ибрагимова

# Галиасгар Камал

## Сочинения
В трех томах

Том 2

Пьесы, произведения эстрады, стихи

*Издание второе, исправленное и дополненное*

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2010

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г.Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

# Галиәсгар Камал

## Әсәрләр

Өч томда

2 том

Пьесалар, эстрада әсәрләре, шигырьләр

*Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП
НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 821.512.145-2 : 1
ББК 84(2Рос=Тат)-6 : 5
К22

Редколлегия:
*З.Р.Вәлиева, К.М.Миңнуллин, Д.С.Шакиров,
А.Г.Әхмәдуллин (баш мөхәррир), З.З.Рәмиев*

Текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны
әзерләүчеләр:
*Бәян Гыйззәт, Зөфәр Рәмиев,
Фатыйма Ибраһимова, Әнисә Алиева, Мәгъсүм Хәбибуллин,
Малик Хәйруллин*

**Камал, Г.Г.**

К22 Әсәрләр : 3 томда / Галиәсгар Камал. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010.
ISBN 978-5-298-01900-2
2 т. : пьесалар, эстрада әсәрләре, шигырьләр / текст., иск. һәм аңл. әзерл. Б.Гыйззәт, З.Рәмиев, Ф.Ибраһимова, Ә.Алиева, М.Хәбибуллин, М.Хәйруллин. – Төз. һәм тулыл. 2 нче басма. – 2010. – 479 б.
ISBN 978-5-298-01902-6

Татар халкының классик язучысы, драматург Галиәсгар Камал әсәрләренең бу томында әдипнең совет чорында язылган пьесалары, эстрада әсәрләре, шигырьләре урын алды.

УДК 821.512.145-2 : 1
ББК 84(2Рос=Тат)-6 : 5

ISBN 978-5-298-01902-6(2 т.)
ISBN 978-5-298-01900-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2010



# Пьесалар

## ХАФИЗӘЛӘМ ИРКӘМ

*Комедия дүрт пәрдәдә*

УЕНГА КАТНАШУЧЫЛАР:

Хафизә – авылның данлыклы матур кызларыннан.
Хафиз – авылның егетләреннән, ярлы кеше баласы.
Вахит – Хафизәнең атасы.
Хөбби – Хафизәнең анасы.
Кәрим – авыл кулагының улы.
Сираҗи – кулак, комитет председателе, Кәримнең атасы.
Сиби, Нигъмәт, Әхми, Фатыйх, Давыт, Баһави, Фазылҗан – авыл егетләре.
Карт – авыл карты.
Мәрфуга, Сәгадәт, Кәримә, Хәмидә – авыл кызлары.
Комиссар.
Старший – отряд башлыгы.
Әби – авылда двор тотучы карчык.
Егетләр, кызлар, кызылармеецлар һәм башкалар

Вакыйга авылда.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авылда ындыр арты, яр буе. Суның аргы ягында урманлыклар күренә. Пәрдә ачылганда, сәхнә буш. Бераздан, як-ягына каранып, Кәрим керә.

#### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кәрим (*үзалдына сөйләнә*). Беркем дә юк. Һичбер кем дә минем шикелле ашыкмый. Хафизәләрне киндер тукмаклар өчен монда җыелачаклар, дигәннәр иде, мин, ахры,

ашыгыбрак килгәнмендер. (*Бер агач төбенә утыра.*) Кем белә, бәлки, башкалар шикелле булсам, мин дә ашыкмас идем. Ләкин шул мине сөю, көнләшү ашыктыра. Ие, Хафиз Хафизәне сөя, шулай ук Хафизә дә аны сөя. Мин дә Хафизәне сөям, чын күңелдән сөям, ә Хафизә мине сөйми, Хафизны сөя. Хафизә сөймәслек кыз түгел, аны һәркем дә яратыр, һәм ул шулай сөелергә тиеш тә. Чөнки ул матур, андый матурлар тирә-якларда бик сирәк табылалар. Бәлки, бөтенләй табылмаслар да. Шулай булгач, бер Хафиз гына аны нишләп яратмасын, аның Хафизәне яратуы бер дә гаҗәп түгел. Тик менә Хафизәнең миңа күз төшермичә, шул шыр ялангач ярлы Хафизны сөюенә генә бер дә акылым җитми. Ничә тапкыр яучы җибәртеп карадым, берсен дә кабул итми. Миңа, Хафизәне кулга төшерү өчен, Хафизны юлдан алып ташлаудан башка бер чара да юк. Ни булса да булсын. Миңа аны юл өстеннән алып ташларга кирәк, аннан соң, бәлки, мин Хафизәне үземә карата алырмын. (*Бер якка карап.*) Сиби килә, минем бердәнбер дусым. Аңар сер сыя, башка егетләрнең берсенә дә ышаныр хәл юк. Барысы да аума халыклар. Эчертеп, исертеп сыйлаганда, һәммәсе дә сиңа дус булып әллә ниләр эшләргә вәгъдәләр кылалар, айныгач, макмыр башларыннан бар вәгъдәләре дә очып беткән була.

С и б и керә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

С и б и. Нихәл, иптәш, монда берьялгызың гына, әвене янган кеше шикелле борыныңны салындырып ни эшләп утырасың? Без сине тегендә чишмә янында килер әле дип көтеп утырабыз. Анда безнең иптәшләр гармуннар белән әйттереп, ду килеп утыралар, мин әле монда ни хәлләр бар икән дип белергә генә килгән идем. Әле берәү дә юк икән, кызлар да килмәгәннәр. Әллә бүген киндерне башка җирдә тукмакларга булганнар микән?

К ә р и м. Килерләр әле. Синең белән мин генә бит ул бик борчылабыз. Башка һичбер кемнең дә җаннарын борча ашамый.

С и б и. Ашамыймы соң, бик нык ашый, бары тик син генә аны шулай дип уйлыйсың. Йә, сөйлә әле, иптәш, ни хәлләр бар, ниләр бар? Бу арада синең белән күрешеп сөйләшә дә алган юк. Яңарак хәбәрләр юкмы?

К ә р и м. Ни булсын, берни дә юк.

С и б и. Теге беркөн түбән очта булган җыелыштан бирле Хафизәне күргәнең юкмы?

К э р и м. Юк, күргәнем юк. Нигә? Әллә берәр төрле яңарак эшләр булганмы?

С и б и. Юк, алай артык яңа эшләр булганы юк. Тик болай гына, үзем генә әйтәм, берәр төрле ятрак, яңарак эшләр юкмы, дим. Хафизны үз тирәсенә шактый гына күп ишләр җыйган дип сөйлиләр. Җыен ярлы-ябагайлар аның тирәсенә җыелганнар, ди. Аннан соң тагын, алар Хафиз белән Хафизәне мактап бер яңа көй, бәетләр дә чыгарганнар, ди. Бүген монда киндер тукмаклаган җирдә шуны җырламакчы* булалар икән. Түбән очның Исми Хәйрие көйләрен дә отып кайткан. Безнекеләр дә анда, чишмә янына җыелып, шул көйгә салып, Хафизны яманлап бәет чыгара калдылар. Бик күңелле такмаклар тезәләр. Мин сине эзләп монда килдем. Әйдә, кызлар җыелганчы, шунда, алар янына барыйк та аннан соң егетләр белән бергәләп җыелып монда киләбез.

К э р и м. Анда ничек, безнең яклы егетләр күпме?

С и б и. Байтак бар. Мин киткәч, бәлки, тагын да җыелганнардыр әле. Безнең як күп булыр. Бөя бөяргә дә җитәр. Әйдә киттек.

К э р и м. Әйдә алайса киттек.

Китәләр. Пауза. Х ә м и д ә белән М ә р ф у г а керәләр.

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Х ә м и д ә. Әбәү! Монда бер кеше дә юк ич! Мин бая ук инде Шәмкиләргә кергән идем, Хөбби абыстай: «Безнең Әсма инде бая ук, әллә кайчан ук киндер тукмалаган җиргә китте», – дигән иде. Әллә ул туп-туры Сәрбиләргә китте микән? Бәлки әле, кызлар шунда җыелганнардыр?

М ә р ф у г а. Юк, ул Гайниҗамалларга кергәндер. Гайниҗамал аның «дусым»ы бит. Шуның белән бергә килә торганнардыр. Һи, бу кызларны да әйтер идем шул, үзләре киндер тукмаклыйбыз дип йөргән булалар, ничә көннән бирле сөйләнеп йөриләр, ә үзләре таганнарын да асып әзерләп куймаганнар. Болар соң таганны кайда гына асмакчы булдылар икән? Бер дә әзерләгән нәрсәләре күренми. (*Агачтагы бауларын күреп.*) Ә, менә икән, менә, элгәкләре дә бар. Монда әзерләгәннәр икән. Асарга бүрәнәсе генә кирәк.

Х ә м и д ә. Менә монда бер бүрәнә кисәге дә бар, шулдыр инде, шуны асмакчы булганнардыр. Бу бик кыска бит, монда ничә генә буй тукмакларлар икән?

---

* «Җыр», «җылы» сүзләре авторда һәр урында «ер», «елы» дип язылган.

Мәрфуга *(карап)*. Шул бик җиткән инде, алты тукмак белән тукмакларлык булгач, ярый. Бүген көннең актыгы түгел әле. Озаккарак сузылса, тагы да күңеллерәк булыр. Хәзер инде авыр эш вакыты да, урак өсте дә түгел. Ашлык коела дип куркасы юк. Әнә кызлар да җыела башладылар, Кәримә белән Сәгадәт тә килә.

Кәримә белән Сәгадәт керәләр.

Хәмидә (*Сәгадәткә*). Гармуныгызны ничек алып килмәдегез?

Сәгадәт. Минем гармун туганымнарда иде. Беркөн абыз эти ачулангач, ватып якмасын дип куркып, аларга илтеп куйган идем. Әле тукмаклый башламаган икәнсез.

Хәмидә. Без нәрсә тукмаклыйк? Безнең киндер дә, тукмак та юк. Без бүген бит Сәрбинең бирнәгә дип әзерләгән нечкә киндерләрен тукмакларга гына килдек.

Сәгадәт. Кара әле, сез ишеттегезме әле, Хафиз белән аның иптәшләре Хафизәне мактап яңа көй чыгарганнар. Көйләре дә, җырлары да бик матур. Хафизәне бөтенләй күккә күтәргәннәр. Бүген монда, кызлар җыелгач, шуны җырламакчы булалар, ди. Җырларын тыңларга түбән оч кызлары белән егетләре дә менмәкче булалар икән. Җырларының берничәсен мин дә отып алдым. Мин инде ул көйне гармунда да уйный белә башладым.

Хәмидә. Син юкка гына гармуныңны алып килмәгәнсең, уйнап күрсәткән булыр идең.

Сәгадәт. Егетләр килгәч уйнарлар әле, ишетербез. Мин алар шикелле үк матур итеп уйный белмим әле. Хафизның Хафизә белән йөргәненә Сираҗи Кәрименең бик ачуы килә икән, ди. «Мин, – дип әйтә икән, ди, – ни эшләсәм дә эшләрмен, шул Хафизәне Хафиз кулыннан тартып алмасам, дөньяда исемем Кәрим дә булмасын, дөньясында йөрмим дә», – дип әйтә икән, ди.

Мәрфуга. Аның шул булыр инде, фитнәнең. Байлыгына масайган була да, әллә кем булган булып, борынын чөеп йөри. Прсидәтел улы булгач та, үзен әллә кем дип исәпли, Сираҗиның байлыгы аның бер айлык. Йә, әйдәгез инде, кызлар да килеп җитәрләр, без бүрәнәне рәтләп, күтәреп асып куя торыйк. Ә, әнә Сәрбиләр дә киләләр, туганым да килә, әйдәгез, элик.

Кызлар. Әйдәгез.

Нечкәрәк бер бүрәнәне бергәләшеп күтәреп, җирдән ярты аршын биеклектә итеп бауга эләләр. Сәрби һәм берничә кыз бер төргәк киндер һәм тукмаклар күтәреп керәләр.

---

Абыз эти – этисе белән бертуган абыйсы.

С ә р б и. Әле кызлар шулай гынамыни?

С ә г а д ә т. Тукмак тавышлары ишетелә башлагач җыелырлар әле. Кояш баер вакыт та җитеп килә. Тизрәк кызларга хәбәр бирә башларга кирәк. Аларның кайсыберләре әле, бәлки, безнең монда җыелачагыбызны да белми торганнардыр.

Х ә м и д ә. Әйдәгез алайса, эшкә башлыйк.

С ә р б и. Әйдәгез.

Киндерләрне җәеп тукмакларга керешәләр.

С ә г а д ә т (*бераз тукмаклагач, туктаган арада*). Безнең монда киндерне гел бер генә төрле көй белән тукмаклыйлар. Аны әллә ничә төрле көй белән тукмаклый торган җирләр дә бар икән. Мин былтыр әниләр белән кодагыйларга кунакка барган идем, шунда ишетеп кайттым. Ничә тукмак белән тукмаклаганнардыр, ул кадәресен белә алмадым. Авылның икенче башында тукмаклыйлар иде. Барып карый алмадым. Әмма соң инде тавышлары шулкадәр матур булып ишетеләдер иде! Һич сөйләп тә бетергесез менә. Шулкадәр моң, шулкадәр күңелле!

Яңадан тукмаклый башлыйлар.

Х ә м и д ә. Кара әле, туганым, кайбер якларда бөтенләй киндер сукмый торган җирләр дә бар икән. Абый сөйләде. Абый әйтә: «Без салдатта хезмәт иткән җирдә, – ди, – киндер бер дә юк, – ди. – Һәммә кеше дә ситсы белән йоннан гына киенәләр, – ди. – Анда сөлге-эскәтер сугучылар да юк, – ди. – Ыштыр чорнап, чабата-оек киеп йөрүчеләр дә юк, – ди. – Сала кешеләре дә суканы күн итеге киеп сукалыйлар, – ди. – Анда бездәге шикелле агач сукалар да юк, – ди. – Торганы сабан гына. Ашлыкны да машина белән уралар, печәнне дә ат җигеп, машина белән чабалар», – ди. Менә рәхәт, ә? Дөньяда шундый җирләр дә бар икән.

С ә г а д ә т. Булмый ни, бардыр шул. Ул гына түгел әле, җитен киндерен чуарлап суга торган җирләр дә бар икән. Аларның суккан киндерләрен минем дә күргәнем бар. Нәкъ менә сәрфинкә шикелле вак шакмаклы була икән.

С ә р б и. Базарда минем дә күргәнем бар. Бер марҗа кигән иде. Аларны әллә кайсы яктан шунда, читтән килгәннәр, диделәр. Яңа җиргә күчеп баручылар, диделәр. Яңа җиргә дигәннәре кайдадыр инде, ул кадәресен мин белмим. Нәкъ менә чуар ак яулык шикелле шакмаклы иде.

---

С ә р ф и н к ә (*сарпинка*) – шакмаклап яки буй-буй итеп эшләнгән юка тукыма.

Яңадан тукмаклый башлыйлар. Бераздан еракτан «Хафизәләм» көен уйнап, җырлап килгән тавышлар ишетелә, ләкин сүзләре аңланмый.

Сәгадәт. Киләләр, киләләр, теге яңа көйне, Хафизә көен җырлыйлар бугай, бик матур көй икән. Әгәр дә Хафизә бу көйне үзе ишетсә, бер дә урынында басып тора алмас иде. Үрле-кырлы сикерер иде. Хәер лә, ишеткәндер инде. Бер генә түгел, әллә ничә тапкыр ишеткәндер. Кичә егетләр җыелышып өй түрләреннән җырлап узганнар, ди. Анда әле Хафизәдән дә бигрәк Кәрим үрле-кырлы сикерә, ди. Бөтенләй кая барып бәреләсен дә белми, ди. Кәрим инде берничә көннән бирле кемне күрсә, шуны сыйлап, үзенә ишләр дә җыя башлаган, ди...

Хәмидә. Йә, әйдәгез, тукмаклыйк әле, тавыш бирик.

Тукмаклыйлар. Еракτан түбәндәге җыр тавышлары ишетелә.

Олы юлдан атлар чаба, ком буранын туздырып,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, ком буранын туздырып.
Матур егет пар кыз таба, йөрми гомер уздырып,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, йөрми гомер уздырып.

Хафизәнең матурлыгы тирә-юньгә дан булган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, тирә-юньгә дан булган.
Хафизә кулга эләкмәгәч, Кәрим күзе кан булган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Кәрим күзе кан булган.

Хафиз егет Хафизәне тулган айга охшата,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, тулган айга ошата.
Кәрим йөрәк кайгыларын яшен түгеп бушата,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, яшен түгеп бушата.

Хафизә озын чәчләренә чәч тәңкәләр тезә икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, чәч тәңкәләр тезә икән.
Хафизәнең кайгысына Кәрим ничек түзә икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Кәрим ничек түзә икән?

Җырлап керәләр.

Хафизәнең ак яулыгын чайкаганда су алган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, чайкаганда су алган.
Хафизә күзен салмагачтын, Кәрим башы чуалган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Кәрим башы чуалган.

Нигъмәт (*керер*). Ягез, кызларның асыллары, без килгәч кенә нишләп туктадыгыз? Бик матур итеп тыкырдатадыр идегез бит әле. Каравылчы Төхфи бабай шакылдавыгыннан бер дә ким түгел иде.

Хәмидә. Без түгел әле, сез үзегез туктадыгыз. Кәрим-

нең борынына бер-икене чиерткәч тә шуның белән эш беттемени?

Нигъмәт. Инештә су бетмәсә, бездә җыр бетмәс. (*Бер озын кәгазь күрсәтеп.*) Менә ул бездә никадәр әле. Ятлап та бетерерлек түгел.

Хәмидә. Яле, Нигъми абый, бик күңелле икән, тагын бер җырлагыз әле.

Нигъмәт. Сез дә безгә кушылып бергәләп җырлыйсызмы? Безгә кушылып җырласагыз, җырларбыз.

Кызлар. Җырлагыз, җырла, кушылабыз, кушылабыз.

Нигъмәт. Әйдәгез, егетләр, матур кызларның сүзләре җирдә калмасын. Калганын җырлыйбызмы?

Егетләр. Җырлыйбыз, җырлыйбыз, актыгына кадәр җырлыйбыз.

Җырлыйлар.

Хафизәнең баш яулыгы аллы-гөлле буйлы икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, аллы-гөлле буйлы икән.
Хафизә кулдан ычкынгачтын, Кәрим ниләр уйлый икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Кәрим ниләр уйлый икән?

Кәрим ниләр уйлый икән? – Утрып, үкреп җылый икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, утрып, үкреп җылый икән.
Хафизә – Хафиз кочагында, Хафиз куены җылы икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Хафиз куены җылы икән.

Нигъмәт. Йә инде, кызлар, күңелегез булдымы?

Хәмидә. Рәхмәт сезгә.

Нигъмәт. Без сезнең сүзне тыңладык. Инде сез дә безнең сүзне тыңлагыз. Йә, инде бер матур гына итеп киндер тукмаклап алыгыз.

Сәгадәт. Ярый, тыңлыйбыз. Әйдәгез, кызлар.

Тукмаклый башлыйлар. Егетләрнең кайсы чүгәләп, кайсы агачларга сөялеп карап торалар.

Әхми (*бераздан, уң якны күрсәтеп*). Егетләр, егетләр, әнә Хафиз үзе дә килә. Әйдәгез, егетләр, җырлап каршы алабыз.

Нигъмәт (*як-якка каранып*). Кая? Ә, менә бу яктан Хафизә дә килә. Әйдә башлагыз!

Кумәк җыр.

Югары очтан берәү килә, Хафизәнең атлавы,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Хафизәнең атлавы.
Батыр егет, матур кызны бик күңелле мактавы,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бик күңелле мактавы.

Хафизә – кызлар янына, Хафиз егетләр янына килеп туктый. Хафиз белән Хафизә ымлашып исәнләшәләр.

Хафиз. Исәнмесез, иптәшләр! Сез нишләп бездән көләсез?

Әхми. Безме? Һич юк, без нишләп синнән көлик? Бер дә көлмибез. Ә әнә анда, тегендә, Кәрим ялчылары бездән көләргә дип җыенып йөриләр, ди. Чишмә буенда, безне мыскыл итеп, бәет чыгарып яталар, ди. Сиби дә шунда, ди. Кәрим кичә төн буена аларны эчертеп, сыйлап чыккан, ди. Без шуны ишеттек тә монда җыелып килдек. Киндер тукмаклаган җиргә алар да килми калмаслар. Әгәр дә андыймондый мыскыл итә калсалар, без дә аларга бирешмәбез.

Хафиз. Рәхмәт.

Нигъмәт. Ягез инде, кызлар, нишләп сез, без килгәч кенә, тукмаклаудан туктадыгыз? Әйдә тыкырдатыгыз. Мин дә сезнең тукмак көенә басып биеп алырмын.

Кызлар җыелып киндер тукмаклый, егетләрнең берсе гармун уйный. Нигъмәт бии башлый.

Тыкыр-тыкыр, тыкыр-тыкыр, кызлар киндер тукмаклый,
Кызлар киндер тукмаганны безнең китап бик мактый.

Биюендә дәвам итеп.

Әйдә, кызлар, булышыгыз, бергә салыйк сукмакны,
Дус шатлыктан кулын чаба, дошман көя, ух-ах, ди.
Бие, бие син, егет, такырайт ындыр табагын,
Бии белмәгән җырласын, кызганмасын тамагын.

Сиби кереп, яшеренеп тора. Егетләр белән кызлар кара-каршы бии башлыйлар. Хафиз Хафизә янына килеп, башы белән ымлап, Хафизәне бер читкә алып китә.

Хафиз. Хафизә, сиңа сөйлисе бик күп сүзләр бар. Бүген кич күрешеп сөйләшергә вакыт таба алырсыңмы?

Сиби, яшеренгән җиреннән күренмичә генә чыгып, Хафизәләр артына яшеренеп, сүзләрен тыңлап тора.

Хафизә. Хафиз, син бүгенгә генә сабыр ит инде. Бүген моннан да бик соң кайтылыр. Аның өстенә тагы бүген әни минем монда килүемә дә бик борчылып калды. Кичә кемнәрдер урамнан безнең турыда чыгарылган көйне уйнап, җырлап уздылар. Ахрысы, әниләр шуны ишеткәннәрдер. Әни бүген көн буена миңа ачуланып, караңгыланып йөрде. Син иртәгә кич, мәзин ясигыга[1] азан әйткәч тә, безнең келәт артына кил. Шул вакытта мин дә чыгармын, ирkenләп сөйләшербез. Ләкин, кара аны, зинһар, дип әйтәм,

бик сак була күр, Кәримнәр сине күрмәсеннәр. Болай да әле ул ачуыннан тиресенә сыя алмыйча йөри. Йә, ярый, бар инде, читкәрәк кит, һәммәсе дә безгә күз салып карап торалар.

Хафиз. Ярый алайса, мин иртәгә шул син әйткән вакытта килермен, син, зинһар, чыкмыйча кала күрмә, сөйлисе сүзләр бик күп.

Хафизә. Ярар.

Хафиз. Хәзергә хуш.

Хафизә. Хуш.

Хафиз егетләр арасына китә.

Нигъмәт. Бии торгач, корсактагы ашаган ипиләр дә коелып бетте. Тукмак көенә басу бик күңелле икән. Моннан соң инде бу көйне «тукмак көе» дип әйтербез.

Фазылҗан. Ягез, әйдә, кызган юлы кызсын инде.

Ерактан җыр һәм гармун тавышы килә.

Әхми. Әһә, егетләр, иптәшләр, теге оч егетләре, ак чабата-ак оеклар менеп киләләр. Әгәр дә безне тешләп җырласалар, яхшы карагыз, бер дә бирешмәгез, бер урынына ун җавап кайтарырга тырышыгыз.

Нигъмәт. Хафаланма, бирешмәбез, тырышырбыз, әгәр дә бик ачуны китерсәләр, мәми авызларының салма савытларына менеп төшәргә дә бик кыйбат алмабыз.

Җыр тавышы якыная бара.

Әхми. Әһә, егетләр, араларында Кәрим дә бар. Ахры, үзләрен сыйларга да өлгергәндер, бик болагайланып киләләр.

Нигъмәт. Болагайлансыннар! Алар болагайлансалар, без аларга уңагайлап та җибәрә белербез.

Хафиз. Анысы шулаен шулай да, ләкин эш зурга китеп бармасын. Исерекләр белән сугышып йөрү яхшы түгел. Әгәр дә бәйләнә башласалар, китүебез яхшы булыр.

Нигъмәт. Бер дә курыкмагыз. Кара-каршы әйтешмичә китте-митте юк, кирәк булса, бәргәләшеп тә алырбыз.

Кәрим партиясе (*җырлый*).

Хафиз киткән ил буена, илдән хәер сорарга,
Хафиз бүкән, апара корсак, илдән хәер сорарга.
Хафизә балчык эзләп йөри
ватык чүлмәк сыларга,
Хафизә бүкән, апара корсак,
ватык чүлмәк сыларга.

Х ә м и д ә (*Хафизәгә*). Әйдә, Хафизә, без тизрәк яхшы чагында моннан китик, күрәсең, алар нинди исерекләр.

Х а ф и з ә. Сугыш-фәлән чыгарып, Хафизларны харап итмәсләр микән?

Х ә м и д ә. Син алар өчен кайгырма, Хафизның иптәшләре әле җитәрлек. Алар ул исерекләргә генә бирешмәсләр. (*Китә башлаган кызларны күрсәтеп.*) Әнә күрәсең, бар кызлар да китеп бетәләр.

Х а ф и з ә. Әйдә алайса.

Китә башлыйлар.

С и б и (*качып торган җиреннән чыгып, Кәрим партиясенә кушылып*). Туктагыз, кызлар, кайда качасыз? Без бит аю түгел, ашамабыз.

Х ә м и д ә. Күзле бүкәннәр! Кыйланышлары! Җирәнгечләр! Бер тиенлек эчеп, егерме тиенлек исергәннәр.

Китәләр.

К ә р и м. Кызлар, туктагыз әле, ник китәсез?

К ә р и м п а р т и я с е (*җырлый*).

Хафизәләрнең капкасын
Калмаган, ди, ачасы,
Хафизә лә бүкән, ачыгавыз,
Калмаган, ди, ачасы.
Ачык капкаларны күргәч,
Килә ташлап качасы.
Хафизә лә бүкән, ачыгавыз,
Килә ташлап качасы.

Көләләр.

Х а ф и з п а р т и я с е (*җырлый*).

Аргы яктан болыт килә.
Яшен яшьнәп, камчылап.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Яшен яшьнәп, камчылап.
Бай баласы Кәрим елый,
Яше ага тамчылап.
Хафизә матур әләкмәгәч,
Яше ага тамчылап.

К ә р и м п а р т и я с е (*җырлый*).

Аргы якның егетләре,
Авызлары селәгәй;
Хафизә, сөрт авызларын –
Авызлары селәгәй.

Хафиз малай ач бетләре
Йөри булып көләгәй.
Хафизә, кара, күрмисеңме?
Йөри булып көләгәй.

Хафиз партиясе (*җырлый*).

Кәрим, Кәрим-кәрләләргә
Әлләниләр кирәкми.
Хәфизәләм иркәм, аппагым ла,
Әллә ниләр кирәкми.
Айдай матур Хафизәләр
Кәримнәргә әләкми.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Кәримнәргә әләкми.

Барысы бердән. Ха-ха-ха!

Кәрим. Авызыгызны җыя төшегез, малайлар! Юк исә тешләрегезне җирдән җыеп алырсыз!

Хафиз. Чамалабрак сөйлә, малай! Кем белән сөйләшкәнеңне белеп сөйләш. Әгәр дә без сезнекен җыйдырсак, үзегез дә хәйран калырсыз.

Кәрим. Кем белән сөйләшкәнебезне бик яхшы беләбез, ач бет! Хәерче! (*Иярченнәренә.*) Әйдәгез, урыгыз үзләрен!

Бәргәләшүләр башлана. Дисәтникләр белән Сотский керә.

Сотский. Һи, йөзегез каралар! Караңгы төн эчендә бу нинди тавыш?! Тотыгыз үзләрен!

Аеклар кача, исерекләр егылып кала. Сотский белән дисәтникләр куа китәләр.

Сиби (*кире кайтып*). Кәрим, Кәрим!

Кәрим (*кереп*). Нәрсә? Ни бар?

Сиби. Бая мин Хафиз белән Хафизәнең сөйләшкәннәрен тыңлап тордым. Хафизә, Хафизга иртәгә кич ясигыга азан әйткәндә, келәтләре артына килергә кушты. Үзләрен шунда эләктерербез.

Кәрим. Ярый. Иртәгә тагы сөйләшербез. Сый миннән, тырышыгыз!

Тиз генә китәләр.

Сотский, Дисәтник (*яңадан кереп*). Әнә тегендә тагы икесе! Һи, йөзе каралар!

Куа китәләр.
Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Йорт артында түтәл бакчасы. Түрдә бер якта такта түбәле бер каралты. Икенче якта тәрәзәсе бакчага караган бер келәт. Келәт белән каралты арасында кечкенә капка. Вакыт кич. Ай калыккан. Яшькелт яктылыкта якындагырак кешеләрнең йөзләрен танырлык. Пәрдә күтәрелгәч, Кәрим белән Сиби шыпаеп кына керәләр. Тирә-якны тикшереп карыйлар. Кеше юклыкка ышангач, Сиби Кәримне сәхнә алдына алып килә.

Сиби. Кичә мин сиңа яхшылап сөйли алмадым. Дисәтникләр кугач, өйгә кайттым да яттым. Бүген иртә белән сиңа сөйләргә дип барган идем, син атаң белән базарга киткән икәнсең.

Кәрим. Ие шул, вулыс эше белән этине чакырткан нар иде. Базардан әйберләр дә алып кайтасы бар иде. Базардан әле күптән түгел, яңарак кына кайттык. Мин атны туаргач та монда йөгердем. Йә, сөйлә, ниләр бар?

Сиби. Шул менә, мин монда бигрәк шул бар булганнарны сиңа сөйләп бирер өчен дип килдем. Кичә сез тегендә чишмә буенда бәетләр чыгарып маташкан арада, мин качып-посып кына ындыр артына тегеләр янына бардым да аларның ниләр сөйләгәнен, ниләр эшләгәннәрен яшеренеп кенә карап тордым.

Кәрим. Йә, йә, сөйлә, тизрәк сөйлә, нәрсәләр сөйләделәр?

Сиби. Күп артык сүз сөйләмәделәр. Хафизә безнең урам буеннан уйнап, җырлап узганыбызны, синең Хафизга ачуланып йөргәнеңне, безнең Хафизны сагалап йөрү ихтималыбыз булганын сөйләде дә бүген кич Хафизны шушында килергә чакырды, мәзин ястүгә[2] азан әйткәндә келәт артына, түтәл бакчасына килергә кушты. Шушында иркенләп сөйләшергә булдылар.

Кәрим. Йә?

Сиби. Бары шунда инде. Мин дә шул вакытта синең белән монда килеп, безнең яклы булган егетләр белән бергәләшеп, аларның күрешеп яткан вакытларында гына кинәттән килеп чыгып, Хафизны тотып әверергә булдык.

Кәрим. Анысын бик шәп иткәнсез, ә соң әле безнекеләр кайда?

Сиби. Мин аларга алдан ук хәбәр биреп, аларны алдан ук әзерләп кисәтеп куйдым. Алар мунча янына, су буена килеп, шыпырт кына җыелып торырга булдылар, шунда алар тавышсыз-тынсыз гына сагалап торып, мин хәбәр биргәч тә, килеп, Хафизны эләктерәчәкләр.

Кәрим. Юк, алай гына эләктерү ярамый. Бер кыйнау белән генә эш бетми. Аның яклы булган егетләр дә әз түгел. Бүген без аны кыйнасак, икенче бер вакытны, ва-

кытын туры китереп, аларның да безне кыйнау ихтималлары бар. Һәм шулай булачак та. Кичә дә без дуамалга тавыш чыгарып бәйләнүебез белән зур ялгышлык иттек.

Сиби. Соң алай булгач, синеңчә нишләргә кирәк? Синеңчә, тик шулай гына, үзе теләгәнчә генә рәхәтләнеп йөри бирсенмени? Минемчә, аны тотып бик нык итеп әпәләүдән башка бер юл да юк. Аны шулай итеп кенә бу тирәдән биздермәсәң, башкача һичбер төрле итеп тә биздерергә мөмкин түгел.

Кәрим. Була, башка юл белән дә бик шәп итеп эшләргә була.

Сиби. Ничек итеп?

Кәрим. Башкачарак итеп. Менә ничек: ул монда килсен дә, бик иркенләп кенә, бернидән дә шикләнмичә генә... (*Як-ягына каранып.*) Юк, безгә монда якын урында сөйләшеп торырга ярамый. Кичә син анда агач артында аларны яшеренеп тыңлап торган шикелле, безне дә кемнең булса да берсенең берәр җирдә яшеренеп тыңлап тору ихтималы бар. Без хәзергә бу якын-тирәдән читкәрәк таеп торыйк әле. Безгә нишләргә кирәк икәнен мин сиңа шунда сөйләрмен.

Сиби. Белмим, нәрсә генә эшли алырсың икән, мин бер дә төшенә алмыйм. Бер дә ышана алмыйм, берәр эш чыгара алырсың микән?

Кәрим. Чыгару гына түгел, чыгарганда да менә дигән шәп итеп чыгарырбыз. Эш чыгару да, теш чыгару да алар безнең өчен берни дә тормыйлар. Әйдә, без хәзер моннан китик тә, тегендә, су буенда, мунча янында иптәшләрнең җыелганын көтеп торыйк. Шуннан торып Хафизның килгәнен сагалап карап торырга да уңайлырак булыр. Шунда ук киңәш-табышларын да итәрбез.

Сиби. Әйдә алайса киттек.

Чыгып китәләр. Сәхнәдә тынлык.
Бераздан качып-посып кына Хафиз керә.

Хафиз. Ялгышмасам, тирә-яклар тыныч, беркем дә юк шикелле. (*Як-ягына карангалап, шыпаеп кына келәт янына килеп тыңлый да келәт тәрәзәсен чиертә.*)

Эчтән җавап юк.

Җавап юк. Ахрысы,мин ашыгыбрак, иртәрәк килгәнмендер. Билгеле,иртә килгән. Мин бит аңар мәзин ястүгә азан әйткән вакытта килермен дип вәгдә биргән идем. Ул да шул вакытта чыгарга булган иде. Әле азан әйткәне юк. Азан әйтү түгел, әле мин килгәндә, мәчеткә ут та кермәгән иде. Йөрәк түзми шул. Тасырдап тора. Нишлисең бит,

тизрәк күрергә дип ашкынасың. Шул тирәдә бераз шыкланыбрак көтеп торырга кирәк. (*Пауза.*) Бүген әллә нишләп, эчләр пошып, күңелләр тынычсызланыбрак тора. Әллә инде кичәге тынычсызлыклар шунда баштан чыгып бетмәгәннәр. Әле ярый минем иптәшләр күп иде. Аның өстенә тагы, бәхеткә каршы, сотскилар да килеп чыктылар. Юк исә, ихтимал, әллә нинди күңелсез хәлләр булган булыр иде. Ярый әле үчсез котылдык, бездән дә, алардан да зарарланган кешеләр булмады. Ни җитмәгән инде шул Кәримгә! Кеше өлешенә күз төшермәсә, аңар авылда башка кызлар беткәнмени?

Келәт тәрәзәсеннән ут яктысы күренә.

Әһә, Хафизә келәткә чыкты. (*Тәрәзәгә чиертмәкче була.*) Юк. Ярамый. Кем белә, бәлки, Хафизә түгелдер? (*Тәрәзәдән үрелеп карый.*) Берни дә күренми. Тәрәзәнең пәрдәсен төшереп куйганнар. Азан әйткәнне көтеп тормыйча хәл юк. Күпкә түзгәнне, азга гына түзәрмен. (*Бераз читкәрәк китә.*) Тирә-якта сагалап торучылар була күрмәсен. Нигәдер күңел бик курка, тез буыннары да калтырый башладылар.

Бер яктан азан тавышы ишетелә.

Азан әйтә, ут та сүнми, чыгып та китмиләр, мөгаен, Хафизәдер. Тукта, сынап карыйм әле. (*Акрын гына тавыш белән җырлый.*)

Тәрәзәнең бусагасы бик киң микән, тар микән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бик киң микән, тар микән?
Хафизә күк матур ярлар бу дөньяда бар микән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бу дөньяда бар микән?

(*Тәрәзәдә ут сүнә дә яңадан яктыра.*) Әһә, булды, Хафизә икән. (*Барып тәрәзәне чиертә.*)

Хафизә (*эчтән*). Хәзер чыгам. (*Утны кыса.*)

Тынлык. Сакланып кына кечкенә капкадан чыга.

Хафиз. Хафизә!

Хафизә. Чү, акрын, кеше-кара күренмиме?

Хафиз (*тиз генә тирә-якны барып карап*). Юк, юк, беркем дә күренми, бик тыныч. (*Килә, Хафизәне коча.*)

Хафизә. Чү, тимә әле, тукта әле. Кичәге көннән бирле җаным бер дә урынында түгел әле. Нәрсәгәдер җаным тынычсызланып, борчылып тора.

Хафиз. Минем дә.

Хафизә. Кичә без киткәч ниләр булганын бер дә белә алмадым. Кешедән сорашырга да яхшысынмадым. Без китеп, Гобәйләр чатын борылгач та, аннан, сезнең яктан, ын-

дыр артыннан әллә нинди тавыш-гаугалар ишетелде, әллә нинди сугыш-фәләннәр булмагандыр бит?

Хафиз. Юк, бик ул кадәр зур эшләр булмады. Бары тик бераз гына өстебездәге тузаннарны кагышкалап кына алдык. Шулай да әгәр дә сотскилар килеп чыкмаган булса, шактый гына зур бәрелешүләр дә булып алган булыр иде. Үзең дә күргәнсеңдер, Кәримнең иярченнәре барысы да бик исерекләр иде. Тавыш чыгартыр өчен Кәрим аларны юри сыйлаган. Моннан соң инде алар безне бер дә тыныч тотмаслар, безгә ничек тә бераз саграк булырга туры килер.

Хафизә. Ие шул, мин дә шулайрак дип әйтмәкче идем. Бераз тавыш-тыннар басылганчыга кадәр күрешмичәрәк, сакланыбрак торсак, ничегрәк булыр иде икән дип әйтмәкче идем.

Хафиз. Анысы шулай, мин дә шулайрак уйлыйм. Ләкин без алай торудан гына тынычлык таба алырбыз микән? Әгәр дә без һаман да шушы көйгә генә торсак, Кәрим безгә бер дә тынычлык бирмәс бит. Ул безне һаман да борчып кына торыр.

Хафизә. Соң син нишләмәкче буласың?

Хафиз. Әгәр дә мин яучы җибәреп этиләреңнән сине соратып карасам, ничегрәк булыр иде икән? Этиләрең сине бирергә риза булмаслар иде микән, дим?

Хафизә. Сынап кара, «ятып калганчы атып кал» дигәннәр бит, кем белә, бәлки, риза да булырлар. Ә соң әгәр дә этиләр риза булмасалар, ул вакытта нишләрбез?

Хафиз. Риза булмыйлар икән, әгәр дә син үзең риза булсаң, ул вакытта да җае табылыр. Моннан качып китәрбез дә икенче бер авылга барып никах укытырбыз. Аннан соң, калага барып, бераз вакытка кадәр калада торып торырбыз да, соңыннан, тавыш-тыннар басылгач, этиләрең белән килешеп, яңадан авылга кайтып тора башларбыз. Аңарчы, бәлки, күз алдыннан югалып торгач, Кәримнең дә өмидләре өзелер.

Хафизә. Мин алай гына китәргә куркам шул. Әгәр дә эти-әниләр рәнҗесәләр, нишләрбез? Йә булмаса «качып киттеләр» дип тоттырсалар, ни итәрбез?

Хафиз. Юк, Хафизә, син бер дә алай хафаланма, этиләрең алар акылсыз кешеләр түгел, бер дә алай иттермәсләр. Без бит никах укытырбыз. Никах укыткан булгач, алай «качып киттеләр» дип әйтә дә, тоттыра да алмаслар. Хәзер инде андый заманнар узган. (*Як-ягына каранып.*) Минем күземә тегендә, читән буйларында кемнәрдер йөргән шикелле тоелды. Әллә нинди кеше күләгәләре күргән шикелле булдым. Безне сагалап йөрүчеләр-фәләннәр була

күрмәсеннәр тагы. (*Акрын гына, шыпаеп кына карый.*) Юктыр, ахры, болай гынадыр. «Курыккынга куш күренә» диләр.

Хафизә. Шулай да бит, бу бит бик читен бер эш. Баштарак, берәр төрле эшкә урнашканчы, көн күрүләре дә бик авыр булыр бит. Без бит бер дә шәһәр тормышына ияләнгән кешеләр дә түгел. Анда барып бернисез генә ничек итеп урнашып тора башларбыз?

Хафиз. Анысы шулаен шулай да, ләкин бит шәһәр җирендә бер кешенең дә ачтан үлгәнен әйтмиләр. Шөкер әле, минем көчем дә, тазалыгым да бар. Кулымнан эш килмәслек егет тә түгел. Мин бит, бик оста булмасам да, балта эшләрен дә яхшы гына беләм. Анда берәр балта остасына ялланып эшләрмен, һич булмый икән, көнлекче булып, утын ярып йөреп булса да тамагыбызны туйдыра алырбыз әле. Шәһәр җирендә эшләгән кешегә эш табылыр. Бары тик...

Хафизә. Кара әле, тегендә минем күземә читән артыннан кешеләр үрмәләп йөргән шикелле күренә башлады.

Хафиз. Юк, берни дә юктыр. Бая миңа да шулай тоелган иде дә, ахрысы, кеше булмагандыр. Читәннең артында кемнең булса да бозаулары йөри torгандыр.

Хафизә. Юк, мин әллә нигә бик шикләнәм. Сагалап йөрүче кешеләр-фәләннәр була күрмәсен. Яхшы вакытта мин кереп китим. Йә мине югалтып, артымнан эзли чыга башларлар. Әни әле болай да бик борчылып йөри. Озак торырга туры килмәс. Хәзергә хуш. Иртәгә тагы шушы вакытларда монда килерсең. Шунда иркенләбрәк сөйләшербез. Ничек тә саграк бул.

Хафиз. Ярый алай булса, хәзергә хуш, җаным! (*Җырлый.*)

Бакча ишегеңне ачып куй,
кояш төшсен түтәлгәй,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
кояш төшсен түтәлгәй.
Күңелең, күзеңне төшермә
Хафизыңнан бүтәнгәй,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Хафизыңнан бүтәнгәй.

Хафизә. Хуш! (*Җырлый.*)

Кызу кояш кыздырса да бакчадагы түтәлне,
Хафизым иркәм, аппагым ла,
бакчадагы түтәлне.
Хафизәң тик сине сөя,
сөйми синнән бүтәнне,
Хафизым иркәм, аппагым ла,
сөйми синнән бүтәнне.

Хафизәңнең бар уе син, уйнаса да, көлсә дә,
Хафизым иркәм, аппагым ла, уйнаса да,
көлсә дә.
Хафизәң сине һич онытмас, үлсә,
гүргә керсә дә,
Хафизым иркәм, аппагым ла, үлсә,
гүргә керсә дә.
Хуш!

Х а ф и з. Хуш, җаным!

Кочаклашып үбешәләр. Хафизә кереп китә.

(*Ялгыз, үзалдына.*) Үзем дә белмим, ни өчендер шул Хафизә миңа авылдагы бөтен кызларның һәммәсеннән дә матуррак күренә. Үзен күргән саен күрәсе генә килеп тора. Ә күргәннән соң йөрәкләрем тибә башлый да каушавымнан сөйлисе сүзләремне дә онытып бетерәм. Берни дә сөйли алмый калам. Ах, тагын бер бик кирәкле бер сүз әйтәсем калган икән. Тукта әле, үзенә әйтим әле. (*Тәрәзәдән үреләп.*) Хафизә, Хафизә! Ишетми. Әллә өйгә кереп китте микән? Хафизә, Хафизә!

К ә р и м, С и б и һәм башка б е р н и ч ә е г е т төрлесе төрле яктан йөгерешеп керәләр.

К ә р и м. Тотыгыз, тот!

С и б и. Келәт басалар!

Е г е т л ә р (*бердән*). Тотыгыз, тот! Сибегез! Кайда сез? Келәтегезне басалар! Карак бар! Карак!

Хафиз качмакчы була. Аны тотып алалар.

К ә р и м һ ә м и п т ә ш л ә р е (*капканы ачып*). Чыгыгыз! Чыгыгыз! Келәтегезне басалар!

В а х и т, Х ө б б и кечкенә капкадан чыгалар.
Тирә-яктан берән-сәрән кешеләр җыела башлый.

В а х и т. Нәрсә, ни бар?

С и б и. Келәтегезне бастылар.

Х ө б б и. Ярабби Ходаем! Җыеп, саклап килгән бодай оным бар иде, харап булдык!

В а х и т. Кайда? Кем? Кая таба китте?

Е г е т л ә р. Менә тоттык. Кем икәнен белеп булмый. Башын яшерә.

В а х и т. Кая дисәтник? Кая староста? Егетләр, зинһар, җибәрә күрмәгез, ычкындырмагыз! Кәмититкә алып барыйк.

Ф а з ы л җ а н. Кабыргаларын яхшылап санагыз!

Егетләр йодрыкларын йомарлап киләләр. Суккалыйлар.

Кәрим. Юк. Егетләр, монда тимәгез. Без кыйнап гаепле булмыйк. Суд үзе тикшерер.

Вахит. Ие, ие, егетләр, сез, зинһар, булышыгыз инде. Әйдә, кәмититкә алып барыйк үзен. Чү! Чү! Бу Хафиз түгелме соң?

Сиби. Ие, ие, шул икән, шул!

Вахит. Һи, яхшыдан яман туган нәрсә, оятсыз!

Хафиз. Валлаһи, Вахит абзый, минем һичбер гаебем юк. Алар бары тик дошманлык белән генә...

Кәрим. Әйдәгез, әйдә, егетләр, күп сөйләтмәгез үзен. Анда баргач тикшерерләр.

Хафиз. Кара аны, Кәрим! Онытма! Бу эш сиңа бик кыйбатка төшәр.

Кәрим. Күрербез!

Егетләр Хафизны алып китәләр.

Сиби (*Кәримне читкә тартып*). Шаулама, иптәш, эш пеште! Кыз синеке. Сыеңны гына кызганма.

Кәрим. Аннан эш калмас!

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Тәбәнәк кенә, начар гына, иске генә өй. Түрдә киң сәке, зур мич, ике якта тар гына ян сәкеләр. Сәке белән ян сәке алдында өстәл. Өстәл өстендә чынаяклар. Әби самавыр әзерли. Старший белән иптәш солдатлары капчыкларыннан икмәкләрен чыгарып, ашарга әзерләнәләр.

Старший. Нихәл, әби, тормышларың ничек? Көн күрүләр бик авыр түгелме? Бала-чагаларың бик күп түгелме?

Әби. Шөкер әле, бер көе генә, авыш-кыеш китергәләп гомер итеп килгән булам шунда. Минем бит бер башым да бер үзем генә. Булышырга бер кешем дә юк.

Старший. Беркемең дә юкмыни?

Әби. Балаларым булуын булган иде дә, барысы да яшьләтә үлеп беттеләр. Берүзем, берьялгызым гына калдым. Соңгы елларга кадәр карт белән икәү генә менә шулай, сезнең шикелле калага баручылар, каладан кайтучыларга аш пешереп, самавырлар куеп, двор төшергәләп көн итеп килгән идек килүен дә, узган ел картым да үлеп киткәч, бөтенләй япа-ялгыз, ятим калдым. Шулай да, шөкер әле, яхшы кешеләр бөтенләйгә үк ташлап бетермиләр. Искедән бирле аш-су күреп килгән дус-ишләр бөтенләй үк хәтерләреннән чыгарып бетермиләр әле. Узган-барганда һаман да миңа төшеп, аз-маз булса да ризыкланырлык биреп китә-

ләр. Әллә ни артык эшләр булмаса да, тамагың тук булып, көннәрне әвеш-кыеш китерерлек булса, риза инде шунда, безнең дөньяда күп торасы калмаган инде, үлгәнче ач булып, кешедән сәдака-хәер сорарырга чыгарлык булмаса, бик риза инде. Шуңа риза инде. (*Пауза.*) Карагыз әле, улларым, самавыр кайнап чыгып өлгергән инде. Үземнең бер дә көчем калмаган. Билләрем дә бик авырта. Карчык кешенең карчыкларча булыр инде аның. Картайгач, карт эт шикелле буласың, диләр иде, бик дөрес икән, бер дә карт эттән артык җирем калмаган, самавырны өстәл өстенә үзегез генә алып куймассыз микән? Бик авыр шул. Яшь чагында моннан да зур самавырларны да дыңгырдатып китереп куя торган идем.

Старший. Ярар, ярар, әби, бер дә үзегез күтәреп азапланмагыз. Безнең егетләрдә көч күп әле, алар алып куярлар. Ягез әле, иптәшләр, кайсыгыз булса да берегез самавырны алып килеп китереп куегыз әле.

Кызылармеецлардан берсе самавырны өстәлгә куя.
Чәй салып эчәргә керешәләр.

Әби, әйдә, сез дә чәй эчәргә рәхим итегез. Утырыгыз.

Әби. Юк, рәхмәт, үзегез генә тынычлап, иркенләп кенә эчегез әле. Мин шунда, әгәр дә сездән артып калса, сездән калганны, берәрне генә эчеп алырмын. Безнең шикелле карчык кешегә чәйне күп эчү бик файдалы түгел. Тышка күп йөретә. Сез соң нинди чәй эчәсез? Яфрак чәеме? Яфрак чәй ул әллә нишләп минем йөрәгемә ярамый, йөрәгемне кисә.

Старший. Юк, әби, яфрак чәй түгел, төрле җиләкләрдән киптереп ясаган чәй.

Әби. Алай булса, берәрне генә эчеп карыйм алайса.

Старший. Әйдә кил, рәхим ит, утыр.

Әби. Тукта инде, алай булгач, мин дә сезне сөт белән сыйлыйм. Бераз сөтем калган иде шикелле, сөтләп эчегез. (*Барып бер савыт белән сөт китерә.*)

Старший. Алай булса, сез безне сөт белән сыйлагыз, без дә сезне шикәр белән сыйлыйк. (*Бер шакмак шикәр бирә.*)

Әби. Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт. Без инде шикәрне бик күптән үк онытып бетергән идек. (*Шикәрне ала. Ян сәкегә барып утыра, чәй эчә башлый.*) Улларым, сез соң ничек, салдат хезмәтен бетереп кайтып киләсезме? Әллә, булмаса, сезне өйгә кунакка гына җибәрделәрме?

Старший. Юк, әби, без эш белән йөрибез!

Әби. Нинди эш? Әллә сезне иген-фәлән җыярга дип чыгардыларммы?

Кызылармеецлар көлешәләр.

С т а р ш и й. Юк, әби, бер дә курыкма, иген җыярга түгел, башка төрле бер эш белән.

Ә б и. Юк, алай-болай куркып әйтүем түгел, куркырга, мин бит иген игә торган, йә булмаса ашлык җыеп, ашлык-тару белән сату итә торган кеше дә түгел. Әле тик болай гына, исемә төшкәнлектән генә әйткән сүзем. Халык бит әллә ниләр сөйли.

С т а р ш и й. Алай икән. Соң, нихәл, авылыгызда нинди хәлләр бар? Авыл халкы нинди эшләр бетереп ята? Авылыгызда тынычлыкмы?

Ә б и. Ни эш бетерсен, безнең сала кешесенең эше билгеле инде аның. Иген игә, булса – урагын ура, көлтә кертә...

Урамда гармун тавышы һәм «Хафизәләм иркәм» көен җырлаган тавышлар ишетелә.

С т а р ш и й. Алар кемнәр? Болай җырлап йөриләр? Әллә солдатка каралачак яшьләрме?

Ә б и. Юк, тегеләй генә, яшьләр үзара гына җырлап йөриләр. Билгеле инде, араларында салдатка каралучылары да бардыр.

С т а р ш и й. Ахры, бу көй яңарак чыккан бер көйдер, минем моңарчы мондый көйне бер дә ишеткәнем юк иде.

Ә б и. Ие, яңа көй ул. Монда, безнең авылда, Хафизә атлы матур бер кыз бар. Егетләрнең, яшь-җилбәзәкләрнең, беләсең инде, аларның бар белгәннәре кыз гына. «Кыз» дигәч тә кызып китәләр, аларның авызларыннан сулар килә. Яшьләрнең аларның дөньяның авырлыкларына бер дә исләре китми. Шул Хафизә дигән кызны безнең авылның ике егет сөеп йөриләр. Яшьләр шуларга төбәп бәет чыгарганнар. Әле менә бер-ике генә көн элек шул Хафиз дигән егетне келәт баскан өчен тотып яптылар. Иртәгә суд булачак.

С т а р ш и й. Нинди Хафиз дигән егетне?

Ә б и. Шул инде, кызны сөеп йөргән егетне.

С т а р ш и й. Ничек соң ул, ул шулай начар куллы егет идемени?

Ә б и. Юк, моңарчы алай бер дә начар исеме ишетелгәне юк иде. Болай үзе бик акыллы, бик инсафлы егет шикелле күренәдер иде. Кеше инде карбыз түгел, эчен ярып карап булмый. Тышыннан гына карап, кешенең яхшымы, начармы икәнен кайдан беләсең? Кем белә, бәлки, ярлылыгыннан аптырагач, шайтан җилкеткәндер инде.

С т а р ш и й. Ничек соң ул, он-фәлән, ашлык-фәлән урлаганмыни?

Эби. Юк, алай аның янында оны-фәләне булган дип әйтмиләр. Оны-фәләне булмаган, бары тик келәт тәрәзәсеннән керергә теләгән вакытта гына егетләр килеп тотканнар.

Старший. Нинди келәт тәрәзәсеннән?

Эби. Бая әйттем бит әле, Хафизә дигән бер матур кыз бар, дип. Шуларның келәт тәрәзәсеннән.

Старший. Кем белә, бәлки, ул анда урлар өчен кермәгәндер, кыз янына килгәндер.

Эби. Ул кадәресе инде безгә караңгы. Бәлки, шулайдыр. Иртәгә судлары булачак. Шунда беленер әле. Ләкин тоткан егетләр, келәт басарга кергән иде, дип әйтәләр икән.

Старший. Аны соң кемнәр тоткан?

Эби. Шулар инде, бая әйткән идем бит әле, кызның икенче бер сөйгән егете бар, дип, шул егетләр тоттырган. Әле ул бүген кич монда безгә килеп, иптәш егетләрен җыеп сыйламакчы булып киткән иде. Бәлки, озакламыйча килеп тә җитәрләр инде. Миңа ашарга да әзерләп куярга кушып киткән иде. Ике каз да пешертте. Кайдандыр ике чиләк бал да алып килделәр. Базга төшереп куйдым, озакламаслар, бәлки, килеп тә җитәрләр инде.

Старший. Алай икән! Эби, син «каз» дигәч искә төште. Синдә бераз ашарлык берәр нәрсә юкмы? Без сиңа бәясен түләрбез. Үзеңдә булмаса, башка берәр кешедән булса да табып китерә алмассыңмы? Маймы, йомыркамы, кайсы булса да ярый. Ит булса, бигрәк тә яхшы. Мә, менә акчасын да ала кит, камисар кайткач, аңарга да ашарга нәрсә кирәк булыр.

Эби. Үземдә сезгә җитәрлек нәрсә табылмас шул. Ярый, күрше-коланнарга барып карыйм. Табарга тырышып карармын. Бәлки, табылыр әле. Ә соң үзегез генә чыгып эзләп керә алмассыз микән? Мин бит ялгыз кеше.

Старший. Эби, курыкма, без синең әйберләреңә тия торган кешеләр түгел, әгәр дә син үзең генә барырга курыксаң (*бер кызылармеецны күрсәтеп*), менә бу иптәш тә синең белән барсын. Без бит солдат кешеләр. Солдат кеше авыл халкының күзенә күренеп, әйбер сорый башласа, бушлай алмагайлары дип куркып, сатарга теләмиләр, бары тик шуның өчен генә сезгә кушам.

Эби. Әйдә, ярый алай булса, күршеләрдән берәрсенә барып карыйк. Бәлки, бирерләр.

Старший (*иптәшләреннән берсенә*). Бар, Шакир иптәш, эби белән син барып кил әле. Менә сиңа бераз акча, барыгыз, тизрәк кайтыгыз!

Шакир. Слушаюсь!

Эби. Ярый, барып карыйк, әйдә алайса, улым, барып

карыйк. Һи, язмыш! Әгәр дә исән булсалар, минем дә сезнең шикелле балаларым булыр иде.

Шакир. Әйдә, әби, киттек.

Әби. Әйдә, бәбкәем, әйдә.

Чыгалар.

Старший. Кызык эшләр! Бу әбинең сөйләгән әкиятләре мине бик гаҗәпләндерә башладылар әле. Бу эштә нинди булса да берәр төрле сер булырга кирәк, минем шул серне аңлыйсым килә. Мин монда мич башына менеп, яшеренеп ятам. Ә сез, әби кайткач, нинди булса берәр төрле сылтау табып, чыгып китегез. Соңыннан, егетләр киткәч, кайтып ятарсыз. Йә булмаса туп-туры ишегалдында арбага ятарсыз, бүген көн җылы, туңарлык түгел. Әби кайткач мине сораса, «йөреп керәм» дип чыгып китте диярсез. Аның ул егетләрне сыйлауның нинди дә булса да берәр төрле мәгънәсе булырга кирәк, ул аларны бушка гына сыйламый торгандыр, аңладыгызмы, иптәшләр? Әгәр дә андыймондый зуррак эш чыкса, камисар кайткач, аңар да белдербез. Аңладыгызмы?

Кызылармеецлар. Аңладык.

Старший. Ярый, әйдәгез эшкә. (*Мич башына менеп ята.*)

Бер кызылармеец. Чыннан да, моннан берәр төрле эш чыгу ихтималы бар бит, ә? Кем белә, бәлки, алар арасында дезертирлар да бардыр әле.

Икенче кызылармеец. Билгеле, бардыр.

Әби белән кызылармеец керәләр.

Әби. Ну, егетләр, бәхетегез бар икән. Мин бер дә табылыр дип уйламаган идем, сез сораганнарның барысы да табылды.

Бер кызылармеец. Рәхмәт сиңа, әби, ярый, бик яхшы булган алайса. Әби, хәзергә син ул нәрсәләрне беразга җыеп куеп тор. Старший кайткач, үзебез сорап алырбыз. Бәлки, ул тиз кайтмас.

Әби. Ул, старшина дисезме, кайда китте соң әле?

Бер кызылармеец. Ул «бераз йөреп керәм» дип чыгып китте. Камисар эш белән киткән иде, алар, бәлки, бүген бөтенләй дә кайтмаслар. Тиз кайтмасалар, без йоклап-нитеп калсак, кайткач сорасалар, алып бирерсең. Шакир иптәш, синең йокың киләме, минем йокым бик килә, мин тышка арбага чыгып старшийлар кайтканчы бераз йоклап алмакчы булам, синең йоклыйсың килмиме?

Шакир. Килмәгән кая ул, бик килә, бик арылган.

Бер кызылармеец. Әйдә алай булса, арбага чыгып

бераз йоклап алыйк. Әйберләрне дә үзебез белән алыйк. Кәзүнни нәрсәләрне калдырып йөрү ярамас. (*Шыпыртлап.*) Теге егетләр килгәч, күреп шикләнмәсеннәр.

Барысы да чыгалар.

Әби. Барыгыз, бар, балаларым, ял итегез, аргансыздыр. Ерак җирдән килгәч армый ни. (*Үзалдына.*) Юньле генә егетләргә охшыйлар. Шулай да алар сораган нәрсәләрнең барысы да үземдә бар икәнен әйтергә курыктым. Кем белә бит, бәлки, әллә нинди кешеләрдер. Очраган бер кешегә ышанып бетереп булмый.

Урамда җыр, гармун тавышлары ишетелә.

Киләләр бугай, ярый, бик яхшы, бик вакытлы киләләр. Салдатлар бар вакытта килүләрен бер дә күңелем тартмаган иде. Ярый әле чыгып киттеләр. Башка кешеләр булса, мин аларны фатирга да төшермәгән булыр идем дә шул, салдат кешегә сүз әйтеп булмый. Әллә нинди бәлагә эләгү ихтималың бар.

Кәрим керә.

Кәрим (*сузып, сыер мөгрәгән аваз белән болагайланып*). Әби өйдәмү?

Әби. Өйдә, өйдә, балакайларым, әйдәгез, рәхим итегез, хуш киләсез.

Кәрим (*ишекне ачып*). Әйдәгез, егетләр!

Алты-җиде егет керә, кайсы исерек, кайсы кызмача.

Әүхәди. Ха-ха-ха! Шәп эш, ә?! Сыйланабыз диген, ә? Кәрим шәп егет ул, ярый ул, аның өчен, ичмасам, нишләсәң дә стует. Ә ул Хафиз нәрсә? Ул бит ач бет! Аның үзенә дә юк, кешегә дә.

Кәрим (*кызмача*). Ну, егетләр, әйдәгез, сәке түреннән.

Утыралар.

Әйдә, тарт гармуныңны!

Гармунчы. Була ул. «Хафизә» көенме?

Кәрим. Ярый, тарттыр. Әй, юк, кирәкми, бүгенгә аны тарттырма, башканы әйттер.

Фазылҗан. «Хафизә» көен аны Кәрим Хафизәне алган вакытта туйда әйттерербез.

Кәрим. Әби, кая, баягы казлар белән балларны китер әле.

Әби. Ярый, хәзер китерәм. Мин аларны, бик әчеп, тәмсезләнеп, кыркуланып бетмәсен дип, базга төшереп куйган идем. Хәзер алып менәм.

К ә р и м. Ярый, бар алайса, тизрәк алып мен.

Ә б и. Ярый, хәзер. (*Чыга.*)

К ә р и м. Ягез, әйдәгез, әйттерә башлагыз. Тарт гармуныңның колагын!

Гармун уйный, егетләр җырлыйлар. Бу урында нинди булса да берәр төрле авыл көе җырлана.

Ф а з ы л җ а н. Шуны беләсе иде: тегендә Хафиз нишләп ята икән, Хафиз? Кандалалар белән борчалар үзен үрле-кырлы сикертәләр бугай.

Ф а т ы й х. Әле аның сикерәсе көннәре алда. Аны судта тагы да яхшырак сикертерләр әле. Ну, малай, Кәрим, үзеңдә баш та бар икән соң! Кайдан табып уйлап чыгарган бит! Келәт басарга кергән, имеш! Ха-ха-ха! Келәт басарга диген, ә? Ие, келәт басарга кергән. Тычкан кимерерлек бер сынык каткан икмәге дә булмаган буш келәтне басарга! Ха-ха-ха!

К ә р и м. Йә, җитәр инде. Авызыңны бик артык җырма. Беләсең икән – бик яхшы, эчеңнән генә тын. Йә әби килеп керер.

Ф а т ы й х. Мин бит болай гына, үземнең исем киткәннән генә әйтәм. Келәт баскан диген, ә? Ну соң үзеңдә баш та бар икән! Һаман әле көләсем килә. Ха-ха-ха! Хафиз келәт баскан!

Ф а з ы л җ а н. Йә, сиңа әйтәләр бит инде, тик утыр, дип. Бу кадәр тотнаксыз бортак авыз булырсың икән!

Ф а т ы й х. Юк, юк, мин бит болай гына. Әйдә уйна гармуныңны, мин биим.

Гармунчы озын көй уйный. Фатыйх алпан-тилпән биеп маташа. Әби бер култык астына каз кыстырып, ике кулына ике чиләк белән бал күтәреп керә.

Д а в ы т. Менә, ичмасам, әбине мактасаң да ярый. Әби дисәң дә әби. Әбинең дә менә дигәне! Җан теләгән нәрсәне алып килгән бит.

Ә б и. Караңгыда базга чүт-чүт кенә егылып төшмәдем. Егетләре яхшы, егетләре! Егетләр хөрмәтенә генә төштем. Юк исә караңгы төн уртасында җен оясы базга һич аягымны да атлап төшмәс идем. Төнлә белән базга күп төшеп йөрергә ярамый. Җен сирпелүе бар.

К ә р и м. Рәхмәт сиңа, әби, рәхмәт. Синең яхшылыгыңны һичбер вакытта да онытмабыз. Менә эшләр генә бетсен, әби, аннан соң мин сине буш итмәм, әби. Үзең дә беләсең бит әле, безнең эшләр бар. Менә кайчан Хафизә минеке булыр, шул вакытта мин сине түр башына менгереп утыртып, баш кодача итеп сыйлармын.

Ә б и. Бик яхшы, улым, бик рәхмәт. Алла морадларыңа ирештерсен. Чибәр егетләргә чибәр кызлар килешә. (*Читкә.*) Атаң үлсә ни миңа, анаң үлсә ни миңа. Биш сум акчаң бир миңа.

Ф а т ы й х. Торам, торам да, һаман да минем исем китә, Хафиз тегендә ябылган җирендәниләр генә уйлап ята икән? Чыннан да әллә мин келәт басарга керәдер идемме икән, ди микән? Ха-ха-ха!

Д а в ы т. Фу, валлаһи! Тәмам туйдырып бетердең инде син дә. Әйдә, тот кулыңа да эч. Эчеп исерерсең дә кайтып йокларсың.

Ф а т ы й х. Юк әле, тора тор әле, мин бер дә исерек түгел! Ха-ха-ха! Минем бары тик көләсем генә килә. Хафиз егет келәт баскан. Аның дала-кыр шикелле такыр идәненә сөртенеп егылып башын ярган! Ха-ха-ха!

Д а в ы т. Булса соң, сиңа нәрсәгә? Син тик эчүеңне генә бел. Сез дә шул, сезгә нигә кирәк иде шул бортак авызны ияртеп йөрергә!

Ф а т ы й х. Исерек! Итәрсең мине тиз генә исерек! Әйдә менә уйнап кара бию көен, мин сиңа биеп күрсәтим. (*Торып биемәкче була да абынып егыла.*)

Д а в ы т. Йә, тор инде, нәрсә ауныйсың?

К ә р и м. Йә, тимәгез аңар, ятсын шунда. Аның булуы җиткән инде. Әйдәгез, егетләр, ашагыз, эчегез, уйнагыз, көлегез, биегез, бүген минем туй!

Ф а т ы й х (*яткан җиреннән*). Юк әле... Туй түгел... Туй алда... Кәрим, мине туйдан калдырма... (*Йокыга китә.*)

Д а в ы т. Ягез әле, тагы бераз җиңел көйләрдән әйттереп җибәрегез әле.

Эчәләр, җиңел көй уйнала. Җырлыйлар, бииләр, исерәләр.

К ә р и м. Ягез, иптәшләр, күңелегез булдымы инде?

Е г е т л ә р. Шәп, шәп, бик шәп! Маладис, Кәрим, маладис! Кәрим маладис! Кәрим барысын да булдыра ул!

К ә р и м. Туктагыз әле, егетләр, монда бал бик күп бит әле. Әйдәгез эчәбез.

Ә б и. Егетләр, бераз саграк булыгыз. Бик тавышланмагыз. Монда каладан килгән, фатир төшкән салдатлар бар. Араларыннан берсе зуррак башлыклары булырга кирәк, ансы йөрергә чыгып китте. Шулар ишетә күрмәсеннәр, яхшы түгел...

Е г е т л ә р. Нәрсә? Салдатлар? Кайда? Нинди салдатлар?

Ә б и. Ниндиләр икәнен белмим, башлыклары «йөреп кайтам» дип чыгып китте. Аннан да зуррагы, камисар дигәне, вулыска кантурга киткән бугай. Башкалары ишегалдында, арбада йоклыйлар.

Е г е т л ә р (*аерым-аерым*). Ват тибә на! Менә сиңа кирәк булса!

Ф а з ы л җ а н. Менә сиңа пәрәмәч!

Д а в ы т. Бетте баш алай булса! Әйдә, укчәң күтәр, сыз тизрәк!

К ә р и м. Син нишләп соң аны элегрәк әйтмәдең?

Ә б и. Әйтәм бит, тышта, арбада йоклыйлар, дип, бик тавышланмасагыз, алай бик күп зарарлары булмас.

К ә р и м. Юк инде, алай булгач, барып чыкмады. Әйдәгез, егетләр, киттек моннан!

Д а в ы т. Туктагыз әле, эчеп бетермәгән бит.

К ә р и м. Юк, ярамый, монда ярамый. Әйдәгез, балның бер чиләген үзегез белән алыгыз. Калганын иртәгә яңадан килеп эчәрбез.

Д а в ы т. Ну, ярый алайса, әйдәгез!

Кузгалалар, алпан-тилпән килеп чыгалар. Фатыйхны уятып, җитәкләп алып чыгалар. Урамда җыр, гармун тавышлары ишетелә. Әби өстәлне җыештыра.

Ә б и. Ахры, башка җирдә күбрәк эчкәннәрдер. Бер чиләкне дә эчеп бетерә алмадылар.

К ы з ы л а р м е е ц л а р керәләр.

Ш а к и р. Тышта шактый гына салкынча икән, өрә башлады. Инде кунаклар киткәч керергә дә ярый торгандыр.

Ә б и. Ярый, ярый, бик ярый. Әйдә, сез дә бераз кунак булыгыз. Менә каз итләреннән, балдан да рәхим итегез. (*Алларына каз ите куя. Берәр җамыяк бал салып бирә.*) Монысын базга төшереп куйыйм әле. Монда торып кыркуланып бетмәсен. Иртәгә тагын килеп баш төзәтергә дип сорарлар әле. (*Чыга.*)

С т а р ш и й (*мич башыннан төшеп*). Иптәшләр, безгә монда эшләргә шактый гына зур эшләр бар икән әле. Камисар кайткач, мин эшне аңар далажит итәрмен. Ул аларның күрмәгәннәрен күрсәтсен, арт сабакларын укытсын әле.

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Нигъмәтләрнең өе. Авылча чибәр генә җыештырылган. Х а т и р ә өстәлгә аш урыннары әзерләп йөри. Өстәл янына тыштан урындыклар кертә.

Х а т и р ә (*әзерләп бетереп*). Инде шәп булгандыр. Ашсулар гына булып җитсә, килсәләр дә ярый. Менә кызык, Кәрим, Хафизәне алам, Хафизның башын чыкмас тишеккә

тыгам, дип йөргәндә генә, үзе эләккән дә куйган. И абый шатланган! Шатлыгыннан бөтенләй эченә дә сыя алмый. Кәрим-кәрләләргә аларга хәзер инде кришке диме, книшке диме шунда, ансы ни дигән сүздер инде. Ярый инде, бәхетләре бар икән. Мин бер дә болай булыр дип уйламаган идем. Түбән очлар Хафизның башын чыкмас тишеккә тыга алмаганнар шул. Ярый, бик яхшы, шулай кирәк аларга, борыннарын бик югары чөеп йөриләр иде, менә хәзер чөеп карасыннар инде, хәзер сыйларга Кәримнәре юк. Тукта, җиңги янына чыгып керим әле, ул әзерләнеп җитә микән? (*Чыга.*)

Пауза.
Ишектән Әхми белән Нигъмәт керә.

Нигъмәт. Ну, Әхми иптәш, әйдә рәхим ит, моннан элек Хафизга яла яккан чакларда Кәримнәр бәйрәм иткән булсалар, хәзер инде без бәйрәм итәбез. Безнең шикелле ярлыларның сыйлары зур булмаса да, дошманнарны җиңүнең шатлыклары зур булыр.

Әхми. Мин судка бара алмадым бит, суд ничек булды соң?

Нигъмәт. Анда, туган, эшләр башкачарак йөри икән. Анда син Кәмитит Сираҗи малае дип исләре китеп тормыйлар икән. Монда беренче җавапны алган чагында гайрәт орган малайларың, анда баргач, бөтенләй песи булдылар да калдылар.

Әхми. Йә, йә, сөйлә әле, эшләр ничек булды?

Нигъмәт. Тукта әле, мин кат-кат сөйләргә катыннар түгел, менә иптәшләр килсеннәр, аннан соң барыгызга бердән аермачык итеп сөйләп бирермен. Мин сөйләп бирә алмаганнарын Хафиз белән Хафизәдән сөйләтерсез. (*Ишекне ачып.*) Хатирә!

Хатирә (*ишектән кереп*). Нәрсә, абый?

Нигъмәт. Йә, сез ничек, әзерләнеп җитәсезме инде? Хафизәләр тиздән кайтып та җитәрләр инде.

Хатирә. Без хәзер, җиңги әйтә: «Муллалар белән кодалар килеп җитсә дә ярый инде, – ди. – Безнең барысы да әзер инде»,– ди.

Нигъмәт. Нинди кодалар? Нинди муллалар?

Хатирә. Ник, никах укырга! Туй итәргә!

Нигъмәт. Аларның никахлары укылгандыр инде. Без бит монда кызыл туй итәбез.

Хатирә. Әбәү! Ул нинди туй була соң тагы? Абый, туйның кызыллары, яшелләре дә буламыни?

Нигъмәт, Әхми көләләр.

Нигъмәт. Була шул, сеңлем, була. Бик кызык, бик күңелле була. Менә килгәч күрерсең әле.

Хатирә. Әкәмәт икән алайса.

Нигъмәт. Әкәмәт шул. Менә синең үзеңне дә шундый кызыл туйлар ясап кияүгә бирербез әле.

Хатирә (*оялып*). Әй, китсәнә, мәхәббәтсез! (*Чыга.*)

Әхми. Яшь әле ул, йә, шуннан соң?

Нигъмәт. Нәрсә «шуннан соң»?

Әхми. Судта эшләр ничек булды, дим.

Нигъмәт. Андагы әкәмәтләрне сөйли-сөйли арып бетәрсең, әйттем бит инде, егетләр, кызлар килсеннәр дә аннан соң барыгызга да берьюлы сөйләрмен дип.

Тышта, еракта җыр, гармун.

Әнә егетләр дә киләләр бугай, әйдә, үзләрен каршы алыйк.

Әхми. Әйдә.

Чыгалар. Пауза.

Хатирә (*кереп*). Әбәү, абыйлар чыгып та киткәннәр икән әле. Урамда әллә кемнәр җырлап киләләр. Әллә кызыл туй дигәннәре шул микән. Мөгаен әле, кызыл әләмнәр дә күтәреп килә торганнардыр. Шуңа күрә кызыл туй ди торганнардыр.

Җыр тавышы якынлаша.

Көн авыша, төн авыша,
Безнең яшьләр кавыша;
Сөйгәненә каушалмаган
Авыруга сабыша.

Матур егет, матур кызлар
Бер-берсен табыша;
Бездә хаклык, бөтен яшьләр
Безнең якка авыша.

Хатирә (*тәрәзәдән карап*). Шул шул, әйттем бит, кызыл әләмнәр күтәреп килә торганнардыр әле, дип. Менә хәзер белдем инде кызыл туйның нәрсә икәнен! (*Йөгереп чыга.*)

Кәрим туе карчыкта,
Үче ята капчыкта;
Иптәшләрең күп бит синең,
Әйдә сыйлан, бар, чык та.
Кәрим эше шәп ие,
Бар иде аның әбие;
Тәбегә төшкән тычкан кебек,
Капчык эчендә бие!

Шәп, ди, Кәримнең өе,
Сау торамсың бер көе;
Бу кем көе дип сорасаң,
Кәрлә Кәримнең көе!

Х а т и р ә (*йөгереп кереп*). Җиңги, җиңги, киләләр, киләләр! Әй күңелле дә соң!

Н и г ъ м ә т. Әйдәгез, әйдә, кодалар, хуш киләсез!

Ә х м и. Әйдәгез, егетләр, әйдә, түрдән узыгыз!

К ә л и (*кереп*). Кызыл туйлар мөбарәк булсын, яшьләр башына бәхет кунсын, өйләре бала белән тулсын!

Көлешәләр.

Ә х м и. Һи, тозсыз! Теләк тә тели белмисең, алар мәчемени өйне бала белән тутырырга?

К ә л и. Башка нинди теләк телим соң? Шуннан артыгы безнең кулдан килми инде. Бай булсыннар дип әйтә алмыйм, буржуйлардан болай да бик күп җык күргән инде.

Н и г ъ м ә т. Ягез, әйдә утырышыгыз, гәпләшегез! Тиздән кияү белән кыз да кайтып җитәрләр инде.

Б е р е г е т. Алар соң нигә кайтмый калдылар?

Н и г ъ м ә т. Никах укытырга калдылар, мин туйга әзерләнә торырга дип алданрак кайттым.

К ә л и. Анда нинди никах ул тагы?

Н и г ъ м ә т. Нинди никах булсын, кызыл никах. Берсе – алганлык, икенчесе барганлык хакында язылырга калдылар.

К ә л и. Ә, алай икән, бөтенләй аңлый яздым.

Ә х м и. Йә, Нигъмәт, бая әйткәнеңне сөйлә инде!

Е г е т л ә р. Нәрсәне, нәрсәне?

Н и г ъ м ә т. Судның ничек булганын. Әхми бая миннән судтаниләр булганын сораган иде дә, мин, кат-кат сөйләмәс өчен, сез килгәч сөйләргә дип калдырган идем.

Е г е т л ә р. Чынлап, сөйлә әле, без дә ишетик.

Н и г ъ м ә т. Суд бөтенләй бер кәмиткә әйләнеп китте. Кәримнең иярченнәре, берсе өстенә берсе сөйләп, бутап бетереп, адәм көлкесе булып беттеләр. Берсе әйтә: «Хафиз келәткә керде», – ди. Икенчесе әйтә: «Кермәде, бары керергә генә маташадыр иде»,– ди. Берсе: «Хафизны кыйнадылар», – ди. Икенчесе: «Кыйнамадылар»,– ди. Сез мунча янына ни өчен килгән идегез дигәч, берсе: «Кәҗә эзләргә килдем», – ди. Икенчесе: «Кәрим килергә кушты», – ди. Шулай да әгәр дә судта Хафизә белән старше дигән салдат булмаган булса, Хафизның эше начар булган булыр иде. Ну соң Хафизә белән старше дигән салдат бөтен сер-

не ачтылар да салдылар. Салдат Кәримнәрнең әби йортында ниләр кыланганнарын, ниләр сөйләгәннәрен – һәммәсен дә бәйнә-бәйнә ачты да салды да бирде. Ул старше, алар әбигә килер алдыннан Кәримнәрнең әбигә киләчәкләрен ишеткәч, мич башына менеп ятып, кемнең нәрсә сөйләгәнен тыңлап яткан икән. Ә тегеләр, исерек баштан мактанышып, үзләренең нәрсәләр эшләгәннәрен һәммәсен дә сөйләгәннәр. Салдат шуларның һәммәсен ап-ачык сөйләде дә бирде. Судтагы бөтен халык түзә алмыйча яңгыратып кул чаптылар. Ә аннан соң инде Хафизә дә эшне ап-ачык итеп сөйләп биргәч, Кәрим иярченнәренең корган төрле пәрәвез ояларын себерелеп төгелде. Кәрим яклы булып ялган шаһитлык биргән иярченнәрнең йөзләре күп-күмгәк булып, торатәш булып каттылар.

Нигъмәт сөйләгәндә, к ы з л а р, берәм-берәм кереп, аш өенә таба узалар.

Е г е т л ә р. Ә соң Хафизә нәрсә дип сөйләде?

Н и г ъ м ә т. Хафизә ул бөтенләй халыкның исен китәрде. Мин, диде, авылда җавап алган вакытта, диде, авыл хатыннарының миңа төрле яла ягуларыннан куркып, диде, дөресен сөйләргә курыккан идем, диде, соңыннан Хафизны караклыкта гаепләп япканнарын күргәч, җавап алган вакытта Кәрим иярченнәренең Хафизга ялган яла ягуларын ишеткәч, минем аркамда аның хурлыкка калачагын белгәч, һич чыдый алмадым, бөтен куркуларымны, оятларымны бер якка ташладым да, дөресен сөйләр өчен батыраеп, монда судка килдем. Хафизны келәт янына мин чакырдым, аны анда мин китердем, Хафизның һичбер келәт басканы да юк, һичбер нәрсә урларга уйлаганы да юк, болар бары Кәрим иярченнәренең уйлап чыгарган ялганнары гына, диде.

Бөтен егетләр яңгыратып кул чабалар.

Е г е т л ә р. Маладис, Хафизә, маладис! Ну соң кыз да икән! Йә, йә, шуннан соң?

Н и г ъ м ә т. Шуннан соң Кәрим иярченнәре күп-күмгәк булдылар да калдылар, телләре тотлыкты.

Е г е т л ә р. Шуннан соң, шуннан соң?

Н и г ъ м ә т. Шуннан соң судьяләр киңәшкә кереп киттеләр дә, бераздан чыгып, Хафизның акланганлыгын, Кәрим иярченнәренең ялган таныклык биргәнлекләре өчен судка биреләчәкләрен әйтеп, ябарга алып киттеләр.

Егетләр кул чабалар.

Е г е т л ә р. Йә, йә?

Н и г ъ м ә т. Ә аннан соң тагы шул да бар икән әле, судка килүчеләрнең дакументларын тикшергән вакытта, Кәримнең дизиртир икәнлеге беленгәнлектән, аны дизиртирләрне яба торган төрмәгә алып киттеләр. Аннан соң Хафизны коткарып чыгарып җибәрделәр.

Е г е т л ә р. Шуннан соң?

Н и г ъ м ә т. Аннан соң судка җыелган яшьләр Хафиз белән Хафизәне тәбрикләп, Хафизны чөеп, аларны сыйларга алып китмәкче булдылар. Без моннан баручылар аңа ирек бирмәдек. Егетләр: «Без авылга алып кайтып, аларның туйларын итәбез», – ди башладылар. Шуннан ук үзара акча салышып, авылга алып кайтырга сыйлар алырга булдылар. Авылга кайткач, йә яңадан берәр төрле комачаулык чыгар да яңадан аркылы төшүчеләр булыр дип, Хафиз белән Хафизәне күндереп, язылышырга алып киттеләр, мине туйга әзерләнә торыр өчен монда кайтарып җибәрделәр.

Тышта кыңгырау тавышлары.

Инде тиздән кайтып та җитәрләр, яңлышмасам, бу кыңгырау тавышы шуларныкы булырга кирәк.

Е г е т л ә р (*ду кубып*). Шулар, шулар! Әйдә каршы алырга! (*Чыга башлыйлар.*)

А р а д а н б е р ә ү. Җырлап каршы алабыз, җырлап!

Т а в ы ш. Әйдәгез, егетләр, җырлап!

Чыгалар. Икенче яктан кызлар да йөгерешеп чыгалар. Тышта җыр. Җиңел көйгә җырлана.

Хуш, хуш килегез, бакча булсын илегез, (*2 тапкыр*)
Ике матур килгән юлга гөлчәчәкләр сибегез. (*2 тапкыр*)
Сип, сип, сибегез юлларына гөлчәчәк, (*2 тапкыр*)
Чәчәк күк үк матур булып яшьләр гомер итәчәк.
(*2 тапкыр*)

Атлар килеп туктаган тавыш, күтәренке рухлы тавышлар.

Килде, килде яшь бикәч, әйдә тизрәк ишек ач,
Өйләргә дә ямьнәр керсен, яшь бикәчләрне күргәч.

Н и г ъ м ә т (*ишектән кереп, юл биреп*). Хуш килдегез, рәхим итегез, яшь кияү, яшь бикәч!

Җ и ң г и (*эчтән йөгереп чыгып каршы алып*). Хуш киләсең, килен, төкле аякларың белән, бәхетең белән.

Ишектән тупырдашып керәләр.

Әйдә, килен, әйдә, кияү, түрдән узыгыз. (*Мендәрләр салган ике урындыкны күрсәтә.*)

Х а ф и з ә. }
Х а ф и з. } Рәхмәт, җиңги, илтифатыгызга.

Егетләр, кызлар тирә-яктагы эскәмияләргә тезелеп утыралар.

Җ и ң г и. Әткәгез белән әнкәгезгә дә хәбәр иттем. Алар да хәзер киләләр. Хафизның котылганын ишетеп алар да бик шатландылар.

Х а ф и з ә. Рәхмәт.

Җ и ң г и. Картайганнар шул инде. Аларның да ахыр гомерләрендә дөньяда тынычлап торасылары килә. Ярый инде. Шатлык, тигезлек белән гомер итегез.

Н и г ъ м ә т (*поднос белән өч стакан бал китереп өстәлгә куеп, икесен Хафиз белән Хафизәгә биреп*). Мәгез, юлда озак кайтып тамакларыгыз кипкәндер, балдан рәхим итегез, менә сезгә май. Майдан да авыз итегез. Дөньяда балдай татлы, майдай тук булып гомер итегез. (*Өченче стаканны кулына алып.*) Иптәшләр, мин сезгә бер-ике генә сүз сөйләп, үземнең шатлыгымны белдермәкче булам. Иң элек якын күргән иптәшем Хафиз белән аны тиң күреп, аңа иптәш булган Хафизәне никадәр зур авырлыклар күреп, никадәр зур хурлыкларга чыдап, ахры бер көн җиңеп, кавышулары белән тәбрик итәм. Бу җиңү бер Хафиз белән Хафизәнең җиңүе генә түгел, бәлки, бик күп ярлыларның байгураларны җиңүе, төрле пәрдәләр астында тоткынлыкта яткан туташларыбызның, авыр пәрдәләрне ертып ташлап, якты дөньяга чыгу җиңүе. Яшәсен меңнәрчә Хафизәләр! Яшәсен меңнәрчә Хафизлар, ура!

Е г е т л ә р. Ура! Яшәсен Хафизә! Яшәсен Хафиз!

Х а ф и з (*торып*). Нигъмәт иптәш бик дәрес сүз әйтте. Чыннан да без моңарчы тоткынлыкта идек. Әгәр дә без үзебез тоткынлыгыбызны аңлап, бергәләшеп баш күтәреп чыкмасак, бәлки, без тагын да ничә елларга кадәр шул тоткынлыкта яшәгән булыр идек. Ривәлүтсия килеп, безнең аякларыбыздагы богауларны өзде. Без богаудан котылдык. Безнең богаудан котылуыбыз ачуыннан байлар безгә каршы тешләрен шыкырдаталар. Шыкырдатыгыз, иреннәрегезне чәйнәгез, без барыбер сезне җиңәрбез! Мин бу стакандагы ширбәтне үзебезнең җиңүебез, минем һәм минем кадерле иптәшем Хафизә һәм сез иптәшләрем хөрмәтенә эчәм. Барыбызның да киләчәк тормышларыбыз татлы булсын! (*Стаканын Хафизә стаканына чүки.*)

Икесе бергә эчәләр.

Һ ә м м ә с е. Яшәсен Хафиз, яшәсен Хафизә!

К а р т керә.

К а р т. Әссәламегаләйкем!

Е г е т л ә р. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, бабай, хуш киләсең!

К а р т. Киләм, балаларым, киләм, бик шатланып киләм. Хафизның котылганын, Хафизә белән кушылганнарын ишетеп, аларны котларга дип киләм. Туйларыгыз котлы булсын. Хафиз улым, Хафизә, син дә, бик исәнсау, шатлык белән йөреп кайттыгызмы?

Х а ф и з. Хәйри бабай, сезнең яхшы теләкләрегез аркасында бик исән-сау кайттык. Әйдә, бабай, түрдән узыгыз, безнең сөекле кодаларыбыздан булырсыз.

К а р т. Узам, балаларым, бик шатланып узам. Үзем дә шул сезнең шатлыкларыгызны күреп, карт көнемдә бер яшәреп калыйм дип килдем. Сезнең хәбәрләрне ишетеп, бөтен авыл шау килә. Әле монда килгәндә, мәчет яныннан узганда, мәзингә очрадым, миңа әйтә: «Болай ашыгып-ашыгып кая барасың?» – ди. Мин әйтәм: «Хафиз белән Хафизәнең туйларын күрергә барам», – дим. Миңа әйтә: «Һи син, карт җүләр, – ди, – картайган көнеңдә син дә шул җүләрләр белән бергә җүләрләнеп йөрисеңме инде, – ди. – Үзеңнең бер аягың җирдә, икенче аягың гүрдә, картайган көнеңдә сиңа мәчет түрендә генә утырырга кирәк иде, – ди. – Андый шайтан бала очырган җиргә баручыларга, андый шайтаннарга ияручеләргә хәзрәтнең дә бер дә ризалыгы юк», – ди. Мин әйттем: «Хәерле булсын, – мин әйтәм, – ризалыгы булмаса булмас инде, – мин әйттем. – Моңарчы да аларның ризалыкларын алабыз дип кара җәяүгә калып беттек инде», – дидем. Шуннан соң мәзин ачуланып кулын селтәде дә китте.

Х а ф и з. Бик яхшы иткәнсең, бабай.

Н и г ъ м ә т. Рәхмәт, бик яхшы иткәнсең, бабай.

К а р т. Шулай булмый ни, моңарчы нинди-нинди генә туйлар булмады, ярлы булгач, берсе дә, син карт кеше, әйдә туйга рәхим ит дип, безнең шикелле ярлыларны чакыручылар булмады. Муллалары да, мәзиннәре дә – барысы да байлар белән генә булып килделәр. Ә менә сез, чакырмыйча гына килсәм дә, ике куллап каршы алдыгыз! Рәхмәт сезгә, балаларым, шатлык белән тигез гомер итегез!

Х а ф и з. Рәхмәт, бабай, безне тиң күрүегезгә. Нигъмәт иптәш, бал-майдан Хәйри бабайга да авыз иттер әле.

Н и г ъ м ә т. Була ул. (*Бал салып бирә.*)

К а р т (*балны алып*). Без яшь чакта балны аны җырлап бирә торганнар иде, хәзер сезнең яшьләрдә андый йолалар юкмыни?

Н и г ъ м ә т. Нишләп булмасын. Бик бар. Әйдәгез, иптәшләр, Хәйри бабайга җырлап та бирегез инде.

Ә х м и. Әйдәгез, егетләр, җырлыйбыз.

Е г е т л ә р. Әйдәгез. (*Җырлыйлар.*)

Әйдә, дуслар, җырлап бирик,
Китерик туйның йоласын;
Безнең дуслар шат булсыннар,
Дошманнар тик еласын.

Көн-төн баю, ярлы талау –
Дошманнарның уйлары;
Дуслар белән бергә булсын
Без ярлының туйлары.

Безнең авыл зур авыл,
Уртасыннан су ага;
Элек байлар рәхәт чиккән,
Хәзер безнең шобага.

Совет үзебезнеке,
Ил үзе дә безнеке.
Безне һичкем җиңә алмас,
Бөтен дөнья безнеке.

Бөтен җир-сулар безнеке,
Ис китми вак-төяккә;
Дөньяда тормыш калмасын
Буржуйга, аксөяккә.

Олы-кече, бергәләшеп,
Илгә хезмәт итәрбез,
Бергәләшеп хезмәт итсәк,
Рәхәт гомер итәрбез.

В а х и т белән Х ө б б и керел артта карап торалар.

Без үстердек буйларны,
Ашлык, сарык, куйларны;
Җиң сызганып, уйнап-көлеп,
Без итәбез туйларны.

Без килмәдек китәргә,
Килдек туйлар итәргә;
Насыйп булсын ике яшькә
Рәхәт гомер итәргә.

Карт (*Вахит белән Хөббине күреп*). Яшьләр, балалар, юл бирегез, карт белән карчык килә. Хафиз, атаң белән анаңны каршы ал. Кайда син, Нигъмәт, китер үзләренә бал!

Хөбби. Ярабби Ходаем, картайган көнемдә бар икән күрәселәрем! Аh-hа-hай! (*Кычкырып елый башлый.*)

Карт. Тукта әле, Хөбби! Нәрсә булды тагын сиңа? Кеше шатланып туй иткәндә, син авыз күтәреп елап торасың. Әйдәгез менә монда, кода-кодагый булып түрдән утырыгыз.

Икесенә дә урын бирәләр, Вахит белән Хөбби утыралар.

Карт. Менә шулай, менә шулай. Кеше шатланып туй иткәндә, син тагы авыз күтәреп елап торасың.

Вахит. Анысына синең исең китмәсен. Хатыннарның, карчыкларның аларның шулай булыр инде. Алар, шатлансалар да, кайгырсалар да, шулай авыз күтәреп елаудан башканы белмиләр.

Хөбби. Ник, менә тагы, шулай шул, дөрес түгелмени? Шулай шул, безнең кайгыбыз да, хәсрәтебез дә шул инде. Бала... бит... ул... Аhа-hа-hа...

Карт. Кайда, Нигъмәт, тизрәк китер балыңны, йөрәге басылсын.

Нигъмәт бал китерә. Карт, алып, Вахит белән Хөббигә бирә.

Хөбби, Вахит (*балны алып*). Рәхмәт. Ярый, исән булыгыз.

Эчәләр.

Карт (*Хөбби эчкәндә*). Хөппи, Хөппи, Хөппи, хуп! Менә шулай, менә шулай! (*Пауза.*) Йә инде, кызлар, егетләр, туйның җитешмәгән җире калмасын, бер җырлап та бирегез.

Егетләр. Әйдәгез, әйдә, җырлыйбыз.

Давыт (*тәрәзәне ачып*). Хафизә апа! Хафиз абый! Мин дә керим инде! Мин бит сезне бик яратам.

Хафиз., Егетләр. Әйдә, кер, кер!

Давыт (*атылып кереп*). Менә рәхмәт, Хафизә апа! Хафиз абый! Валлаhи менә, мин сезнең икегезне дә бик яратам. (*Бер җиргә чүгәли.*)

Гармунчы уйный башлый, кызлар белән егетләр күмәк җыр белән «Хафизәләм» көенә җырлыйлар.

Хафиз белән Хафизәнең сөрмәле икән күзләре,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, сөрмәле икән күзләре.
Сөешеп барган матурларның айдай нурлы йөзләре,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, айдай нурлы йөзләре.

Кызарып чыккан кояшлар төшлекләргә авыша,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, төшлекләргә авыша;
Яшьтән сөйгән яшь матурлар бер-берсенә кавыша,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бер-берсенә кавыша.

Хафиз белән Хафизәләр шат яшәсеннәр бергә,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, шат яшәсеннәр бергә.
Мондый шатлыклар китсеннәр яшьләр өчен гомергә,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, яшьләр өчен гомергә.

Карт. Йә, булган икән, берәгәйле булсын, туй икән, чын туй булсын, кара-каршы биеп тә җибәрегез!

Кызлар. } Ярый, бабай, сүз юк.
Егетләр. }

Кызлар белән егетләр кара-каршы бииләр.
Берничә пар биегәч.

Карт *(алга чыгып.)* Һи, сез, яшьләр, минем карт йөрәкне дә җилкетеп җибәрдегез. Мин дә биим әле. (*Бии.*)

Давыт (*карт биегәндә йөгереп чыгып*). Тукта, бабай, Хафизә апаның туенда мин дә биеп калыйм.

Икесе бергә комически рәвештә биегәндә, пәрдә төшә.
Пәрдә.

## ӨЧ ТОРМЫШ

*Өч күренештә*
*Клуб сәхнәләре өчен пьеса*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Алып баручы.
Әхмәди – эшче.
Хәерниса – аның хатыны.
Өч бала – Әхмәдинең балалары.
Хәйри – күрше хатыны.
Городовой.
Миңнебай – дворник.
Бай.
Ишан.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Уен башланыр алдыннан сәхнә алдына – пәрдәнең тышкы ягына уенны Алып баручы чыга.

Алып баручы. Исәнмесез, саумысыз, иптәшләр, эшчеләр, хезмәтчеләр, ханымнар, туташлар, олылар, кечеләр, картлар, яшьләр һәм безнең белән тиңдәшләр! (*Пауза.*) Ирекле илне алга җибәрүдә берексен безнең киңәшләр! (*Пауза.*) Бүген сезне бөек революциянең ... еллыгы белән тәбрик итәм!

Оркестр интернационал уйный.

Революциядән элекке хәлләр белән таныштыру өчен, сезне революциядән электәге тормыш хәлләренә тартып алып китәм. Ул хәлләр турысында сөйләп торуларны бер якка ташлап, тормыш ничек булганын уйнап күрсәтәбез, ул заманның эшче тормышыннан башлап. (*Кереп китә.*)

Пәрдә ачыла.

Эшченең кечкенә бер бүлмәдән гыйбарәт квартиры, йорт нәрсәләре бик ярлы. Караңгырак. Зурлы-кечеле, яланаяклы, яланбаш, иске-ертык күлмәктән өч бала туңып, бөрешеп утырганнар. Хәерниса ниндидер бер иске нәрсә ямап утыра.

1 нче бала. Әни, ашыйсым килә...

Хәерниса ишетмәмешкә салына.

2 нче бала. Әни, дим, минем дә ашыйсым килә.

Хәерниса. Тамагыгызга пычак! Ашатырмын менә кисәү агачы белән! Ашарга булмагач, мин сезгә аны пычагымнан алып бириммени? Акча ала алган булса, менә атагыз кайткан чагында алып кайтыр.

3 нче бала. Акча аламы соң?

Хәерниса. Бирсәләр, алыр.

2 нче бала. Әни, аны кем бирә соң?

Хәерниса. Кем бирсен, эшләгән бае бирергә тиеш.

3 нче бала. Нишләп бирми соң?

Хәерниса. Акча юк, диләр ич.

3 нче бала. Әни, бай кешенең дә акчасы булмыймы икәнни?

Хәерниса. Юк, диләр ич. Бүген кәләпүш типчеп төшергәч, миңа да «Бүген акча юк, иртәгә килерсең» диделәр.

3 нче бала. Әни, ул бай кешеләрнең дә шулай, безнеке шикелле, акчалары булмыймы икәнни?

Хәерниса. Аларныкын каян беләсең, юк, диләр ич.

2 нче бала. Әни, ашыйсым килә!

Хәерниса. Әйткәнне ишетмисеңмени? Юк, диләр бит инде сиңа!

3 нче бала. Кайчагында Хәйри апалардан ипи алып тора торган идек бит әле?

Хәерниса. Дөмекмәдегез дә ичмаса! Нигә дип мине бу кадәр йөдәтәсез? Сораган, аннан да сораган, кырык кат сораган инде. Алар үзләре дә безнең шикелле ач утыралар әле.

Хәйри керә.

Әйдә, Хәйри абыстай!

Хәйри. Әхмәдиең кайтмадымыни әле?

Хәерниса. Юк әле. Кайтып, аңарга да нәрсә бар соң, ашарыңа да булмагач!

Хәйри. Шулай шул, туганым, безнең Сабир да әле генә кайтты. Ярый тагын, кайдандыр акча табып, үзе белән бер бөтен икмәк алып кайткан. Синең Әхмәдиеңнең дә акча ала алмыйча аптырап йөргәнен, сезнең дә ач утырганыгызны әйткәч, әҗәткә дип бераз икмәк кертеп бирергә кушты. Шуны сезгә кертеп бирим әле дип кердем.

Хәерниса. Һай, рәхмәт, Хәйри абыстай, бик зур рәхмәт. Үзем ничек булса да түзәр идем әле шунда, менә бу балаларны бер дә түздерер хәл юк, ашарга сорап, теңкәбәгырьләремне корытып бетерәләр.

Х ә й р и. Шулайдыр шул, туганым, шулайдыр.

Х ә е р н и с а. Читен инде, Хәйри абыстай, бик читен. Һичбер каян да алырга урын юк. Бүген, төн йокыларымны калдырып, Гайнетдин байга кәләпүш типчеп төшергән идем, кибетчеләре: «Кәләпүшләреңне калдыр, без байның үзеннән башка бер тиен дә бирә алмыйбыз, акчага үзе бар чагында килерсең», – дип җибәрделәр. Ары әйләндем, бире әйләндем, байның төшкәнен берничә сәгать сагалап тордым. Бай, төшкәч тә, безгә күзен дә салмыйча, әле берәү белән, әле икенчесе белән сөйләшкән булып, әллә никадәр гомер уздырып маташты. Аннан соң да эшләребезне көчкә генә карап, һичбер юк гаепләр тапкан булып маташты. Начар эшләгәнсез дип, эттән алып, эткә салып, тетеп сүкте дә: «Барыгыз, бар, күземә дә күренмәгез, бүген бер тиен дә акча юк, иртәгә килерсез», – дип куып чыгарды.

3 н ч е  б а л а. Әни, ашарга бир инде!

Х ә й р и. Ай Алла, Хәерниса туганым! Сүзгә мавыгып, мин тагы алып кергән икмәгемне дә онытып утырам икән. Мә, туганым, кисеп бир үзләренә, ашасыннар. (*Бирә.*) Аларның да шул, мескеннәрнең, ашыйсылары килә торгандыр.

Х ә е р н и с а. Шулай, шулай, Хәйри абыстай, үзеңнән дә бигрәк алар өчен йөрәкләр өзелә. Үзеңә булмаса да, аларны бер дә ач тотасы килми шул. (*Икмәкне алып, кисеп.*) Мәгез, ашагыз! (*Кечкенә генә, юка гына кисеп алып, үзе дә ашый башлый.*) Җәй көне, җылы вакытлар булса тагы бер хәл иде, үзләрен урамга куып чыгарыр идең дә, бераз колакларың тынып торыр иде. Бу суык вакытта аларны кая куып чыгарасың, өс-башларына да юк.

Х ә й р и. Шулай инде, туганым, шулай, ни дисәң дә аптыраш. Үзебездә дә нәкъ шундый ук хәлләр. Ичмаса, ягарыңа утыны булса тагы бер хәл булыр иде. Утын алырга да көч юк бит. Әле менә үзем дә, тиреслек башыннан аннан-моннан йомычкалар җыеп кереп, бераз гына җылыткан шикелле булдым шунда.

Х ә е р н и с а. Анысы инде, Хәйри астай, йомычкасын табып булса, бик рәхәтләнеп ягасың инде аны. Әле бит аның йомычкасын да табар хәл юк. Бүген менә иртә белән Габдерахман байларның теге, амбарлар эшләтә торган җирләренә барып, бер кочак йомычка җыйган идем, чыгып барганда, дворниклары күрде дә: «Байның рөхсәте юк», – дип, җыйган йомычкаларымны да кире ташлаттырды.

Х ә й р и. Шулай, шулай, туганым, дөрес әйтәсең, байларда аларда шәфкать дигән нәрсә һич юк. Алар үзеңнекен талап алырга гына әзер торалар.

Х ә е р н и с а. Бай үзе дә түгел бит әле. Үзе булса тагы бер хәер иде. Дворнигы бит әле. Үзе дә безнең шикелле

бер хәерче иде бит. Аңар безнең шикелле ярлы кешеләрнең хәлләрен бераз гына булса да белергә кирәк иде. Без соң, бераз гына хәлебез булса, йөзебезне ертып, әрсезләнеп, алар каршысына барып йөрер идекмени?

Хәйри. Чынлабрак исәпләгәндә, туганым, дворникка да берни дә әйтеп булмый. Үзең беләсең бит, алар да, безнең шикелле үк, бай кулында кол булып торалар. Аларның да шул, байлары ни кушса, шуны эшләми хәлләре юк. Ярлылар яклы булсалар, байлары аларны бер минут та тотмыйча, хәзер куып чыгаралар. Юк инде, юк, туганым, байларда шәфкать-мәрхәмәт дигән нәрсәнең булганы да юк һәм булачак та түгел. Алар шул безнең шикелле ярлыларны талаганга, ярлылар хакын ашаганга күрә дә шулай баеп, симереп беткәннәр.

Хәерниса. Дөрес, Хәйри астай, сүзең бик дөрес. Менә айдан да артып китте инде, бай һаман да, ачу тотып, безнекенең хезмәт иткән акчасын бирми йөртә. Эшчеләрнең байларга ничек ачулы булганын үзең дә беләсең инде. Безнеке дә бит бер көннәрне эшчеләр арасында булган бер җыелышта байларның эшчеләрне, ярлыларны кысулары, аларның җәберләүләре турысында бик кызып, бик каты итеп сөйләгән. Шуның сөйләгәнен нindидер бер эте байга ирештергән. Бай шуңар ачуланып, менә аның хезмәт иткән акчасын бирми йөртә.

Тыштан тавыш. Сәдакадан рәхим итсәгез лә, бәбкәйләрем!

Хәерниса. Үзебезгә булмагач, без аны җәһәннәмнән алып бирикмени?! (*Ишеттереп.*) Гаеп итмә әле. Бер нәрсәм дә юк.

Хәйри. Шул инде, туганым, шул, һәркайсыбызда да бер хәл. Алар да шул, безнең янга килмичә, кая барсыннар? Байлар бит алар, хәерчегә бер телем икмәкләрен бирергә кызгансалар да, хәерчегә өрә торган этләренә ашатырга кызганмыйлар. Әле бер көннәрдә генә күрдем, байларның теге, исемен дә әйтә белмим, аты җиткере, нәрсә соң әле, теге сыгылмалы, резинке көпчәкле бер нәрсәләре бар бит әле, Гали байның хатыны шундый нәрсәгә атын җиктереп, алдына күчерен утыртып, әллә кем булып, илаһи, түшләрен киереп, тәкәбберләнеп кайтып килә ләбаса, күрсәң, бөтенләй косарсың килешләренә! Карасам, ни күзем белән күрим: алдына, аяк астына, ике пот булыр, һәйбәт, симез үпкә-бавырлар салып кайтып килә. Кара, мин әйтәм, байлар да, мин әйтәм, шулкадәр байлыклары була торып, үпкә-бавыр ашыйлар икән дим, мин әйтәм, тәгаен ул, корсакка узгандыр да, нәфесе үпкә-бавыр тели торгандыр, мин әйтәм... Шулай дивана кеше шикелле үзалдыма кычкы-

рып сөйләшеп барам икән. Янымнан бара торган бер ир кеше: «Алар аны үзләре ашар өчен алалар дип беләсеңмени? Алар бит аны этләре белән хезмәтчеләренә алып кайталар», – дигәч, үзалдыма сөйләнеп килүемә оялып киттем.

Хәерниса. Шулай инде, шулай, Хәйри астай. Алар каршында этләр безгә караганда кадерлерәк.

Хәйри. Һи, мин, сүзгә керешеп, мавыгып, бөтен дөньямны да онытып җибәргәнмен. Сабир икмәк алып кайткач, самавыр куеп җибәргән булган идем, самавырым кайнап ташып беткәндер инде. Сабир буран очырыр. Ярый, хуш! Үзең ипи алып кайткач та кертерсең, җәме! Шулай да бик озаклама. Безнең үзебезнең эшләребез дә бик шәптән түгел.

Хәерниса. Ярый, ярый, Хәйри астай, озаклатмам. Бик зур рәхмәт инде сиңа. Үзе акча алып кайткач та, алып кайтып түләрмен.

Хәйри. Ярый, хуш.

Хәерниса. Хуш, Хәйри астай, хуш.

Хәйри чыга.

*(Икмәкне кисеп алып, йотыга-йотыга ашый башлый.)* Һи, җаныем. Чикләвек төше тәмнәре килә.

3 нче бала. Әни, әллә аңарга чикләвек төше салып пешергәннәрме?

Хәерниса. Әйе, балам, әйе, чикләвек төшләре кушып, сары майлар салып пешергәннәр.

3 нче бала. Әйтәм бик тәмле!

2 нче бала. Әни, бервакытны эти безгә перәннек алып кайткан ие, имә? Ул да шулай бик тәмне ие бит, имә?

Хәерниса. Әйе, әйе, балам, шулай. Ашыйсың килсә, карның бик ачса, ипи дә шулай перәннек шикелле тәмле була ул.

3 нче бала. Әни, бая теге Хәйри апа әйткән баш хатыннары гел шулай перәннек кенә ашап тора торганнардыр, имә?

Хәерниса. Алар ашыйлар, балам, ашыйлар. Алар перәннеген дә, кәндитерен дә ашыйлар.

3 нче бала. Ул да шулай тәмнеме, ә?

Хәерниса. Тәмнедер, балам, тәмнедер.

Әхмәди керә дә, хәлсезләнеп, ишек янындагы табуреткага утыра.

Тагы булмагандыр, ахры. (*Ишеттереп.*) Нихәл, әллә бүген дә бирмәделәрме?

Ә х м ә д и. Биру түгел, бай бүген бөтенләй кибетенә дә төшмәде. Кибетчеләр: «Юкка вакытыңны әрәм итеп йөрмә, төшмәс, бай бүген кунак уздыра, Бигәнәй ишан хәзрәт килгән», – диделәр. (*Балаларының ашаганын күреп.*) Ипи кайдан алдыгыз?

Х ә е р н и с а. Балалар ашарга дип бик йөдәткәч, син кайткач кертеп бирербез дип, Хәйри ападан алып тордым.

Ә х м ә д и. Мин алып кайткач! Алырсың эт авызыннан сөяк!

Х ә е р н и с а. Соң бүген нишләрбез икән инде? Мичкә ягарга утын да юк.

Ә х м ә д и. Нишләргә дә белгән юк. Бөтенләй башларым катты инде. Әллә, булмаса, байның өенә барып карыйм микән дигән идем дә, җә ачуымнан каты сүзләр әйтеп ташлармын диеп бармадым.

Х ә е р н и с а. Анысы шулай да, монда да хәлләр бик авыр шул. Бүген соң көнне ничек итеп кенә авыштырырбыз икән?

Ә х м ә д и. Нишләргә дә белмим. Бөтенләй башым эшләми. Муеннан бурыч, һичкемнән дә сорап торыр хәл юк. Әллә, булмаса, байга барып, син генә сорап карыйсыңмы, хатын кеше баргач, биреп җибәрмәс микән?

Х ә е р н и с а. Барсаң да, барыбер бирмәс, бары тик теләнүең генә калыр. Шулай да ачтан үләр хәл юк, хәерле булсын, бармыйча булмас. Син беркая да чыкмый торгансыңдыр бит? Мин кайтканчы, балалар янында торып торырсың.

Ә х м ә д и. Ярар, торырмын, торырмын, тик син бар гына.

Х ә е р н и с а. Хәерлегә булсын, барып карыйм инде алайса. (*Өстенә сәләмә киемнәр киеп, чыга башлый.*)

Ә х м ә д и. Кара әле, сиңа әйтәм, бик ашыйсы килә бит, шул Хәйридән алган икмәктән миңа да бераз өлеш калмадымы?

Х ә е р н и с а. Әнә шунда бераз калдырган идем, ал, балаларга да бераз калдыр. Барып карыйм инде, ни булыр, ләкин ни өчендер бер дә күңелем ышанмый. (*Чыга.*)

Ә х м ә д и (*барып, икмәк сындырып алып, балалар өстенә бераз карап тора да үзалдына сөйли башлый*). Их, тормыш, тормыш! Бу бала дигән нәрсәләр дә безнең шикелле ярлыларда гына шулай күп булалар. Минем сөйләгән сүзләрне байга тарелка ялаучы урам көчекләре ирештергәннәр булырга кирәк. Аларның ишләре дә күп бит.

Г о р о д о в о й* керә.

Бу эте нишләп йөри тагын?

Г о р о д о в о й. Әхмәди Мөхетдинов син буласыңмы?

Ә х м ә д и. Әйе, мин булам, ни эшкә кирәк?

Г о р о д о в о й. Ни эшкә булсын, билгеле инде, кунакка түгел. Үзеңнең ни эшләгәнеңне үзең белә торгансыңдыр.

Ә х м ә д и. Минем гаепле булырлык бернәрсә дә эшләгәнем юк.

Г о р о д о в о й. Мин дә эшләгәнсеңдер дип әйтмим бит. Эшләгәнең юктыр шул. Шул, эшләгәнең булмаганга күрә дә чакыра торганнардыр. Соңгы вакытларда сүзгә бик остарып киттегез, авызыгызга телегез сыймый башлады. Бигрәк артык белемле, акыллы баш булып киттегез, акылыгыз башыгызда гына тора алмый. Кешегә эш югында эш чыгарып йөрисез.

Ә х м ә д и. Сезгә чурт кушканмыни! Йөрмәгез. Йөрсәгез, бушка йөрмисез бит, жалуния аласыз.

Г о р о д о в о й. Урыс рабочиларына ияреп йөрү безнең шикелле мөселман агай-энеләренә бер дә килешә торган эш түгел инде. Безнең мөселман агай-энегә мәчеткә күбрәк йөрергә кирәк, мәчеткә!

Ә х м ә д и (*көлеп*). Мөселман булгач, үзең син мәчеткә күбрәк йөр, ә син анда учаскыдагы түрәләреңә тарелка тотып йөрисең.

Г о р о д о в о й. Безнеке ул – хезмәт ул, хезмәт, патша хезмәте. Хәзрәтләр дә патшага хезмәт итәргә кушалар.

Ә х м ә д и. Синең ул хәзрәтләрең дә шул – барысы да түрәләрең төсле үк бер чыбыктан сөрелгән халыклар!

Г о р о д о в о й. Ну, әйдә, күп телеңә салынып торма. Әйдә тизрәк өстеңә киен. Әле дә сине эзләп йөреп ашарга кайтырга да соңга калдым.

Ә х м ә д и. Өскә киенергә минем сезнеке шикелле казенный киемнәрем юк.

Г о р о д о в о й. Киемнәрең булмаса, анда сиңа да казенный киемнәр табылыр. Арестант чикмәннәре белән чахавызлар тулы.

Ә х м ә д и. Ярар, барырбыз, хатын кайтсын, мин бу балачагаларны кемгә калдырыйм? Карарга кеше юк.

Г о р о д о в о й. Синнән башка да торырлар әле. Аларга чорт та тимәс. Эт балаларын көтәр өчен көтүче ялламыйлар.

---

* Авторда: градовой.

Ч а х а в ы з (*цейхһауз*) – кием-салым складлы.

Ә х м ә д и. Кабахәт! (*Балаларын барып кочаклап.*) Ну, балалар! Сезне ятим калдырырга туры килә бит!

2 н ч е  б а л а. Әти, бу усал бутишнек белән кая барасыз?

Ә х м ә д и. Җәһәннәмгә, балалар, җәһәннәмгә!

3 н ч е  б а л а. Әти, ул нинди җир? Анда ипи бирәләрме?

Ә х м ә д и. Бирәләр, балам, бирәләр. Монда бирмәсәләр дә, анда бирәләр.

3 н ч е  б а л а. Әти, безгә дә ипи алып кайтырсың, җәме!

Ә х м ә д и (*сөеп*). Ярар, балам, ярар!

Г о р о д о в о й. Җә, әйдә тизрәк!

Чыгалар.

2 н ч е  б а л а. Абый, алар кая киттеләр?

3 н ч е  б а л а. Ипи алырга, ди ич.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылыр алдыннан А л ы п  б а р у ч ы сәхнә алдына чыга.

А л ы п  б а р у ч ы. Менә шулай, иптәшләр, революциягә кадәр, самодержавие һәм капиталистлар заманында, эшчеләр тормышында шул рәвештә бардылар эшләр. Инде хәзер карап торыгыз, эшченең шул замандагы хуҗасы – юан бай, буржуй нишләр? (*Кереп китә.)*

Пәрдә ачыла.

Байның ишегалды күренә. Ишегалды караңгы, аңарга байның өе тәрәзәләреннән төшкән электр яктылары яктылык бирәләр.

Х ә е р н и с а (*куркып кына, як-ягына каранып кына ишегалдына керә*).

Читтән эт өргән тавыш ишетелә.

Ярабби, этләре дә өрә. Ачуланмасалар гына ярар иде. Ах! Читен дә соң шул этләр каршысына бару! Әҗәл белән бер! Ачуланып, сүгеп кенә кайтармасалар ярар иде.

Дворник М и ң н е б а й керә.

М и ң н е б а й. Әй! Кем бар анда? Эт өрдереп, кеше көлдереп караңгыда кем йөри? (*Хәернисаны күреп.*) Әй, син кем? Нәрсә монда караңгыда сораусыз-нисез ишегалдына ке-

---

Б у т и ш н е к (будочник) – постында будкасы булган полицейский.

реп йөрисең? Әйберләр чәлдерергә кердеңме? Бар, чык, югал күземнән! Сезнең аркада монда байдан орыш алырга туры килә.

Х ә е р н и с а. Мин ул, мин, Миңнебай абзый. Байга йомыш белән килгән идем.

М и ң н е б а й. Ә, Хәерниса, син икәнсең әле. Мин хәерче кергәнме әллә дип торадыр идем. Йомыш белән килгән булгач, нигә дип кич, караңгыда йөрисең соң? Байның гадәтен белә торгансыңдыр бит. Йомыш белән килгән кешеләрне байның өйдә кабул итмәгәнен бер дә белмисеңмени?

Х ә е р н и с а. Һи, Миңнебай абзый, үз ихтыярымда булса, мохтаҗлыгыбыз булмаса, байның капкасыннан аягымны да атлап кермәс идем. Мохтаҗлык китерә, Миңнебай абзый, мохтаҗлык! Ашарга бер телем икмәк, ягарга бер агач утын да юк, балаларның өсләренә кияргә киемнәре юк. Ялангач утыралар. Чыдарлык түгел. Балалар суыктан бөрешеп утыралар.

М и ң н е б а й. Начар хәл, алай булгач, Хәерниса, бик начар. Әхмәди дә эшли алмый торгандыр шул.

Х ә е р н и с а. Эш дисең син, Миңнебай абзый! Бай бит әле эшләгән өчен тиешле акчаларын да ни гомерләрдән бирле һаман бирмичә йөртә. Бүген дә әле үзе көн буе байның кибет ишеге төбен саклап кайтты. Бүген ул, Бигәнәй ишанын чакырып, аш уздыра икән, кибеткә бөтенләй төшмәс дигәч, аз булса да биреп җибәрмәсме диеп, менә үзем килдем.

М и ң н е б а й. Ай-һай, Хәерниса, белмим шул, бай бирер микән?! Байның аңарга бик нык кәефе киткән. Бөтенләй каны каткан. Аны мин шуннан әйтәм, ул мине дә: «Әле син дә, Әхмәди шикелле, байларга каршы өрә башладыңмыни, хәерче эт?» – дип тетеп сүкте. Әхмәдигә дә нигә кирәк иде инде шулай телләнеп йөрергә! Байларны җиңәргә соң безнең генә кулдан киләмени! Аларның бит патшасыннан башлап бутишнекләренә чаклы барысы берегеп эшлиләр.

Х ә е р н и с а. Дөрес, Миңнебай абзый, дөрес. Бик белеп әйтәсең. Көчленеке замана. Тешләреңне кыса-кыса булса да чыдыйсың. Әхмәдигә дә телләнмәгән булса бик яхшы булган булыр иде дә бит, нишләтәсең инде аны. Аңарга сүз тыңлатып буламыни! Әйтсәң: «Мин ялганлый белмим», – ди.

М и ң н е б а й. Шулай да, Хәерниса, хәерле булсын инде. Әхмәди кулыннан эш килми торган егет түгел, ничек тә рәтен табар әле.

Х ә е р н и с а. Анысы шулай, тик әле менә бүгенгесе генә читенрәк. Шулай итеп, мин бүген байны күрә алмам микәнни?

М и ң н е б а й. Бер дә әйтә алмыйм шул. Бераз гына көтеп тор инде, ашап бетерделәр, хәзер чәй генә эчәләр. Кунаклары тиз таралыр инде. Ишанны икенче җирдән алырга да килделәр. Атлары көтеп тора.

Парадный ишегендә электр яна.

Әнә утны да яндырдылар, чыга торганнардыр. Син читкәрәк китеп тор.

Б а й белән И ш а н парадныйдан чыгалар.

Б а й. Миңнебай! Бар, әйт, ишан хәзрәткә ат бирсеннәр!

М и ң н е б а й. Хәзер! (*Чыгып китә.*)

Тышта тавыш.

М и ң н е б а й т а в ы ш ы. Әүхәди!

Т ы ш т а н т а в ы ш. Әү!

М и ң н е б а й т а в ы ш ы. Тизрәк, ишан хәзрәткә ат китер!

Т ы ш т а н т а в ы ш. На! Тррр!

Б а й. Тәкъсир, зинһар, гаеп итә күрмәгез инде, бу юлга сезне яхшы сыйлап та, сезнең белән иркенләп сохбәт кылып утырып та булмады. Бик ашыктырдылар. Алла боерса, насыйп булса, сәфәрегез бик тиз булмаса, икенче бервакыт, форсатыгыз булганда иркенләп сохбәт кылып утырырга рәхим итегез. Алдан берәр кеше җибәреп әйттерсәгез, без фәкыйрь бәндәгез әзерләнеп торырбыз.

И ш а н. Җәнабе Хак Тәгалә хәзрәтләре хәерле гомерләр биреп, сәламәтлегебезне дә алмаса, сезнең белән иркенләп сохбәт кылып утырырга үзебезнең дә теләгебез бик зур иде.

Б а й. Рәхим итегез, тәкъсир, рәхим итегез. Хаҗ шәриф сәфәрләрендә, мөбарәк җирләрдә күргәннәребезне дә искә төшерербез. Анда йөргәндә сәфәр мәшәкъкатьләрен дә бергәләп күрдек бит. Әйе, сәфәрегез тиз түгелдер бит?

И ш а н. Үзебезнең ниятебез тиз китүдә иде дә, Хак Тәгалә хәзрәтләре ничек тәкъдир иткәндер, анысын һич белеп булмый. Үзебез ватаны аслыебызны да бик сагына идек тә, сезнең шикелле әһле хайрат яраннар авыз ачып сөйләргә дә ирек бирмиләр: «Китмәгез әле, хаҗи, анабыз абыстайны да ат җибәреп алдырабыз»,– дип, абыстагызны алдырырга махсус атлар да җибәрделәр.

Б а й. Шулай, шулай, тәкъсир, хәзрәт, китмәгез әле, һич

---

С о х б ә т  к ы л у – утырышу, берәү белән сөйләшеп утыру.

Х а җ  ш ә р и ф  с ә ф ә р л ә р е – изге урын Мәккәгә бару сәфәрләре.

В а т а н ы  а с л ы е б ы з – төп ватаныбыз.

Ә һ л е  х ә й р а т  я р а н н а р – изге эшкә гашыйк кешеләр.

китәргә ярамый. Сез булганда, шәһәребезгә нурлар керәп, бәрәкәтләр иңә. Әле, тәкъсир, сезне утыртып йөрергә дип теге ахтәм абил дигән нәрсәне алырга да ният бик зур иде дә, җитешә генә алмыйм. Бәлки, сез сәфәр кылганчы шуңа утыртып йөрүләр дә насыйб булыр.

И ш а н. Фәкыйрегез өчен дип андый зур мосарифләргә кермәвегез мәгъкульрәк булыр. Фәкыйрегез андый рәсүли әкрәм сәлләллаһе галәйһиссәләм заманында, гасрый сәгадәттә булмаган һәртөрле бидгать нәрсәләрдән саклануны важиб дип санаучылардандмын. Хәтта, мөмкин булганда, тимер юл, вапур шикеллеләргә утырып йөрүдән дә саклану фазыйләтлерәк. Бинаән галәйһи, кадим-кадимнән килгән ат белән, хәтта мөмкин булганда, мөбарәк тәвә белән йөрү мәгъкульрәк булыр.

Б а й. Ләббәйкә, тәкъсир, ләббәйкә! Алай булса, тәкъсир, бетте, әстәгъфирулла тәүбә! Алмыйм!

Чыгалар.

Б а й т а в ы ш ы: «Хуш, тәкъсир, хуш!»

Ат аягы тавышы. Б а й керә.

Х ә е р н и с а (*качып торган җиреннән чыгып, байның алдынарак чыгып*). Бай!

Б а й (*Хәернисаны танымаганга салынып*). Миңнебай! Мин сиңа ничә тапкыр әйттем, актык мәртәбә әйтәм: хәерчеләр түгел, йомыш белән килгән кешеләрне дә кич белән миннән рөхсәтсез капкадан кертәсе булма. Йомышлары булган кешеләр, кирәк булса, көндез кибеткә төшәрләр.

М и ң н е б а й. Хаҗи абзый, хәерче түгел бит ул, үзебезнең Хәернисa бит ул, Әхмәди хатыны. Сезне күрергә дип килгән.

Б а й. Төннә белән монда ни калган аңар?

Х ә е р н и с а. Зинһар, хаҗи абзый, мәрхәмәтегездән ташлый күрмәгез инде, өебез суык, ягарга бер агач утыныбыз юк. Балаларым ач-ялангач утыралар.

---

А х т ә м а б и л – автомобиль.
М о с а р и ф – әрәм-шәрәм итү.
М ә г ъ к у л ь – урынлы.
Г а с р ы й с ә г а д ә т – бәхет гасыры.
Б и д г а т ь – элеккегә каршы ят бер эш.
В а җ и б – тиешле.
В а п у р – пароход.
Ф а з ы й л ә т – яхшы эш.
Б и н а ә н г а л ә й һ и – шуның өчен.
К а д и м - к а д и м н ә н – борын-борыннан.
Л ә б б ә й к ә – тыңлыйм.

Б а й (*үзалдына*). Мин аны тагы, әллә Әхмәдине чыгарту турысында ялынырга килгән микән дип уйлаган идем. Әле һаман алып китмәгәннәр, күрәсең. (*Ишеттереп.*) Ач булсагыз, эшләрсез. Тырышыбрак эшләсәгез, ашарыгызга да, киярегезгә дә, ягарыгызга да булыр. Тамагыгызга булмаганга мин винават түгел. Сезне бушка туйдырып яткырырга миндә әндри казнасы юк. Теленә салынып, рабучилар арасында митингы ясап йөрергә белгән бит. Шул рабучилары туйдыра алмаганнармыни?

Х ә е р н и с а. Үзенең күрәсенә каршы булгандыр инде, хаҗи абзый. Мин дә әллә ничә тапкыр әйттем инде үзенә.

Б а й. Ярый, үзең иртәгә кибеткә төшәрсең, тиешле акчагызны биреп җибәрермен. Кара аны, үзең төш. Үзең өчен генә бирәм. Әхмәди өчен җик тиен бирәсем юк. Миңнебай, бар, әнә теге, этләргә дип алып кайткан үпкә-бавырдан бер ашлык итеп кисеп ит бирсеннәр, хатынына әйт. Аннан соң үзең шунда ишегалдындагы йомычкалардан бер кочак йомычка биреп җибәр. Аннан соң аң бул, моннан болай, миннән рөхсәтсез, ишегалдына, бигрәк тә кич белән, кеше кертәсе булма.

М и ң н е б а й. Ярый, хаҗи абзый, барысы да сез дигәнчә булыр.

Х ә е р н и с а. Рәхмәт инде, хаҗи абзый, балаларны сөендергән өчен сиңа бик зур рәхмәт!

Б а й (*як-ягына тәкәбберлек белән карап, үзалдына*). Пристефенең дә һаман ужуы җитмәгән икән әле. Һаман да япмаганнар, күрәсең... Алары да шул бушлайга гына тыгынырга яраталар. (*Кереп китә, утны сүндерә.*)

М и ң н е б а й. Ишеттеңме ниләр сөйләгәнен? Тавышлары бөйрәктән чыга. Хәерниса, син шунда гына торып тор, мин үзем алып чыгармын. Үзем алып чыккач мулрак та булыр. Син карый тор, капкадан кеше-фәлән кермәсен. Кеше керсә, хуҗаның рөхсәте юк диген, капка төбеннән узмасын. (*Почмактан китеп күздән югала.*)

Х ә е р н и с а (*үзалдына*). Бу хурлыкларны да күрәсе көннәребез бар икән. Әхмәдигә дә ачуланырга урын юк. Мескен, ул да шул, бичара, хурлыкларга төшкәч, йөрәгенә чыдый алмыйча сөйләгәндер. Әхмәдинең урынсыз калуы җиңел эш түгел, шулай да кайгырырга ярамый, тик баш белән кул гына сау булсын, эшләгән кешегә эш табылыр. Әллә никадәр бала-чагалы, ирсез тол хатыннар да башларына төшкәч чыдап торалар әле.

М и ң н е б а й керә.

---

Җ и к (*цек*) – ярык, тишек.

Миңнебай. Менә, мә, ал. Тач май гына. Бай сиңа эткә дигәнне бирергә кушса да, мин менә аның үзенә дигәнен күтәреп чыктым. (*Бер кулек нәрсә бирә.*) Сиңа бер түгел, биш көн пешерергә җитәрлек булды. (*Зур бер кәгазьгә төргән нәрсә биреп.*) Мә, менә монысы җиңгәңнең күчтәнәче, балаларга ашатырсың дип бирде, майлы бөккән, гөбәдия кисәкләре. Җиңгәң сине бик ярата икән, Хәернисага дигәч, барысыннан да мул иттереп бирде. Бер дә кайгырма, Хәерниса. Баш исән булса, мал табылыр. Әйдә, мин сине арт капкадан озатыйм, шуннан күтәрә алган кадәрле йомычкаларыңны да ала китәрсең.

Хәерниса. Рәхмәт, Миңнебай абзый, бик рәхмәт. Синең бу яхшылыкларыңны гомеремдә дә онытмам.

Миңнебай. Ярый, үзегезне карагыз. Балалар сау булсыннар! Хуш! Әхмәдигә сәлам әйт! (*Озата.*)

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Эшче Әхмәди Мөхетдиневнең яңа стильдә эшләнгән зур-зур тәрәзәле, якты ике бүлмәле, электрик һәм радиолар кертелгән, киң, якты, җыйнак квартиры.

Пәрдә ачылыр алдыннан Алып баручы пәрдәнең тышкы ягына чыга.

Алып баручы. Менә шулай, иптәшләр, элекке ике пәрдәдә күргәнчә, революциягә кадәрге иске заманда полицияләр, жандармнар, байлар, хуҗалар, алпавытлар, муллалар, ишаннар – барысы бер компания ясап, булдылар көчлеләр. Шартлаганчы ашадылар, эчтеләр, типтерделәр. Эшче-крәстиән һәм бөтен хезмәт халкының канын булдыра алган кадәр эчтеләр. (*Пауза.*) Бөек Октябрь революциясе булгач, хезмәт ияләре азат булдылар; яңа, ирекле, матур тормыш кордылар. (*Пауза.*) Без хәзер, тоташ күмәкләшү нигезендә, капитализмның соңгы терәге булган кулак сыйныфын сыйныф булу ягыннан, нигездә, бетердек. Без хәзер сыйныфсыз социализм җәмгыяте төзибез. Ләкин әле сыйнфый көрәш кискен бара, капитализмның калдыклары пролетариатка каршы үзенең соңгы көчләрен туплап көрәшә. (*Пауза.*) Сез хәзер яңа тормышны, эшченең революциядән алган казанышларын күрерсез. (*Кереп китә.*)

Пәрдә ачыла.

Хәерниса ишектән ике кулына кәрзин һәм чемодан күтәреп керә, икенче бүлмәгә үтә, өстен чишенеп чыга. Баштагы ике картинада күренгәнгә караганда олыгайган һәм тазарган, өс-башлары ул вакыттагыга караганда һич чагыштырмаслык дәрәҗәдә яхшырган.

Х ә е р н и с а. Ярый, бетте. Шушы ял көне җитсә, берәр төрле эш туа да тора. Көннең узганын сизми дә каласың. Кооперативта һичбер баш тыгарлык та түгел. Фабриктан палучка алган көнне бераз сыйланып та каласы килә. Заем кәгазьләрен тикшереп кайтырмын дигән идем, бүген өлгерә алмадым инде. Зарар юк, отыш чыккан булса, әллә кая качмас әле. Балалар мәктәптән кайтып җиткәнче ашны булдырып куярга кирәк. Аннан соң кичен кинога барып кайтырмын. Тукта, бүген ни көн соң әле? Бу алты көнлек эш атнасына күчкәннән бирле көн исемнәрен дә онытып бетердем инде. Бүген театрга барырга билет биргәннәр иде, числасын да карамадым, кайчанга икән (*кесәсеннән билетны алып*), ә, бүгенгә түгел икән әле. Бу яңалиф[1] чыкмаган булса, берни белми каладыр идем. Абыстайдан биш ел укып белмәгәнне өч айда өйрәттеләр дә куйдылар.

Х ә й р и керә.

Һу! Әйдүк, Хәйри апа, исән-сау йөрисеңме? Бер дә килүеңкитүең юк.

Х ә й р и. Дөнья мәшәкъкате, туганым, дөнья мәшәкъкате. Һич бушар хәл юк. Үзегез бик исән-сау гына торасызмы соң? Әхмәди бик исән йөриме?

Х ә е р н и с а. Шөкер әле, бик исән-сау йөри. Яхшы эшләгән өчен әле үзен күптән түгел генә бүләкләделәр. Башка фабрикта эшләсәм дә, минем дә аннан каласым килми. Үзе дә хәзер эш башыннан эшләгәнгә күрә, тырышып эшләп, акчаны да яхшы таба. Мин дә булышкалыйм. Олы улым, ФЗУны бетереп, яхшы гына урынга урнашты, жалуниясе дә яхшы. Уртанчысы рабфакта укый, икенчесен күн техникумына бирдек, ул да яхшы гына укып бара. Ала торган стипендияләре үзләренә җитеп бара. Безгә һичбер мәшәкъкатьләре юк.

Х ә й р и. Бик яхшы, бик яхшы, туганым, син дә бик ачылып киттең, бер дә теге элекке вакыттагы кәләпүш типчеп утырган Хәерниса бу дип әйтмәссең.

Х ә е р н и с а. Дөнья шулай өйрәтә икән ул, Хәйри апа.

Х ә й р и. Шулай инде, туганым, дөнья нужасын сезнең кадәр татыган кеше бик аз табылыр. Әхмәди төрмәдә утырганда, шул балаларны туйдырыр өчен, төннәр буе утырып эшләдең бит. Ну үзеңдә дә йөрәк бар икән, бара торгач шул балаларны да кеше иттең.

Х ә е р н и с а. Сөйләмә дә инде, Хәйри апа. Ул вакытлар исемә төшкәч, әле дә булса йөрәкләрем жу итеп китә. Әйтергә генә асат, Әхмәдине ике ел ярым төрмәдә черттеләр бит. Ичмасам, революциядән соң яхшы иттеләр, үзләренең төкләрен өттеләр.

Х ә й р и. Бер көннәрне мин урамда сезнең элеккеге байны күрдем. Әмма корсаклары шиңгән. Электәге киереп йөргән корсагының капчыгы гына калган.

Х ә е р н и с а. Ишаннарның фатихалары файда бирә алмаган икән алайса.

Х ә й р и. Йөргәннәр шунда безнең шикелле беркатлы надан халыкларны, хәер-дога да бәддога дигән булып алдалап. Пычагым! Барысы да безнең шикелле халыкларны кулларына эләктерер өчен тозак кына булган. Ярый, туганым, кайтыйм инде, үзең дә безнең якларга барып чык.

Х ә е р н и с а. Куй юк сүзләреңне, авызыңны да ачма, чәй эчертми җибәрәмме соң! Әллә нигә бер килеп чәй дә эчми китәргә! Менә хәзер аш салып җибәрәм, аш та ашап китәрсең. Бүген ял көне булганга, сталавайга бармадым, өйдә үзем пешерим әле, дидем. Утыр әле, утыр.

Х ә й р и. Алай оят булыр ич.

Х ә е р н и с а. Юк, юк, ояты-фәләне юк. Үз кеше бит син.

М и ң н е б а й керә.

М и ң н е б а й. Мөмкинме? Бәлки, хаҗи әфәндедән рөхсәт алмыйча капкадан керергә дә ярамый торгандыр. Хи-хи!

Х ә е р н и с а. Ай, Миңнебай абзый! Бу синме?

М и ң н е б а й. Исәнме, Хәерниса, бик исән-сау торасызмы? Әхмәди, балалар исәнме?

Х ә е р н и с а. Бары да исәннәр, бик таза-сау йөриләр. Үзегез ничек соң, бик исән-сау торасызмы, җиңги исәнме?

М и ң н е б а й. Бик исән, барыгызга да бик күп итеп сәлам әйтте. Җимертеп йөри әле. Аш-су тирәсен яхшы булдырганга, үзен колхоз ашханәсенә повар итеп куйдылар, минем дәрәҗә дә күтәрелде, син байның юрга атларын карап остарып беткән кеше, дип, атлар карарга конюшниләр башлыгы итеп куйдылар.

Х ә е р н и с а. Яхшы булган.

М и ң н е б а й. Кергәннән бирле карап-карап торам да, төсмерләгән шикелле дә булам, Хәйри бикә түгелме соң син?

Х ә й р и. Шул үзе.

М и ң н е б а й. Исәнме! Нигә исәнләшмичә утырасың соң? Сабир исәнме?

Х ә й р и. Бик исән, бик таза-сау йөри.

М и ң н е б а й. Шулай да бик картаеп киткәнсең. Ә менә Хәернисаны танымасаң да, гаеп итә алмассың, күз тимәсен тагы, җүләр кеше әйтмешли, бер дә колхоз биясеннән

ким түгел. (*Төргән казын бирә.*) Менә сиңа җиңгәң күчтәнәч итеп бер каз җибәрде.

Хәернисa (*алып*). Бик рәхмәт инде исенә төшереп җибәрүенә. Алырга да оят инде, үзебез бернәрсә дә җибәрә алганыбыз юк.

Миңнебай. Синең җибәрүең кирәк түгел, Әхмәдидән күргән яхшылыкны минем гомердә дә онытасым юк. Әгәр дә ул безнең күзебезне ачмаган булса, без бу дәүләтләргә ирешә алмаган булыр идек. Әгәр дә алар үз-үзләрен кызганмыйча, төрмәләргә кадәр кереп, туры юлны безгә аңлаткан булмасалар, без гомер буена шул юан корсак хаҗиларга кол булып торган булыр идек.

Хәйри. Андый юан корсак хаҗиларны өттек инде хәзер.

Миңнебай. Шулай кирәк аларга. Үзләре дә безнең җилкәләребезне җитәрлек кимерделәр.

Әхмәди керә.

Әхмәди. Һу, кадерле кунаклар! Исәнме, Хәйри абыстай! Миңнебай абзый, бу синме?

Миңнебай. Урыс әйтмешли, я за него!

Әхмәди. Бик шәп, бик шәп! Һич көтмәгәндә очрашу! Сезнең белән күрешмәгәнгә бик күп еллар булды бит инде.

Миңнебай. Шактый булды инде. Ул вакытларда туган тайлар ат булып, аларның да тайлары өлгереп җиттеләр инде.

Әхмәди. Җә, Миңнебай абзый, бик исән-сау, сәламәт торасызмы? Җиңги исәнме? Балалар исәнме?

Миңнебай. Хәзергесен бик исән-сау, сәламәт. Җиңгәгез дә бик исән-сау, совхоз биясе кебек симерә бара. Күптән түгел генә тагы бер кызыбыз булды әле.

Әхмәди. Бик шәп, бик шәп, үсәме соң кызый?

Миңнебай. Үсмәгән кая ул, анасына охшаган, яхшы атлар шикелле тыпырдап ята. Нәселле буласы әллә каян билгеле.

Әхмәди. Үзегез ни эшләп ятасыз, колхоздамы?

Миңнебай. Колхозда булмыйча ярыймы соң, билгеле, колхозда.

Хәернисa. Әле соң син бүген ничек иртә кайттың? Минем аш та салынмаган. Хәзергә чәй генә эчеп торырсыз инде. (*Чәй әзерли.*)

Әхмәди. Чәй булгач, бик ярый. Кайда, чәйне генә китер дә, эчеп китәргә кирәк. Ашны кайткач ашармын.

Миңнебай. Узып барышлый юлда ат сугарырга гына дип кердеңмени?

Әхмәди. Шундыйрак бер хәл. Конференциягә барасы бар, делегат итеп сайладылар.

Миңнебай. Тпр-р. Алай булгач, син дә минем шикелле икәнсең алайса. Мине дә шул, синең шикелле, Октябрь бәйрәмен уздырып кайтырга авылдан делегат итеп җибәрделәр. Син шәһәр күргән кеше, шәһәргә барып безнең исемнән Октябрь бәйрәмен котлап кайт, диделәр. Шулай дигәч тә, чап әйдә шәһәргә!

Хәерниса. Җә, әйдә, чәйдән рәхим итегез. (*Чәй ясый.*)

Хәйри. Рәхмәт, җитешербез.

Әхмәди. Авылда шул колхоз эшендә генәме?

Миңнебай. Билгеле, шулай. Җиңгәгез колхоз булып аш пешерә, мин тагы колхоз булып ат карыйм. Колхозның бөтен конюшниләре бары да минем кулда. Быел менә яхшы нәселле атлар алабыз. Барысына да үзебез хуҗа, ду китереп торабыз.

Әхмәди. Алайса, бик шәп.

Хәерниса. Җә, менә бүген алып кайткан удар паекларыннан җитешегез.

Миңнебай. Җитешәбез, бик җитешәбез. Сезне бик сыйлыйлар икән. Бу атланмайны колхоз сыерларыгызның сөтеннән атлыйлармыни?

Хәерниса. Безнең фабрикның үзенең сөт фермасы бар.

Миңнебай. Сипарат мае булырга кирәк, бик тәмле. Безнең капиративта да бу арада теге ширпатрип дигән товарлары күбәеп тора әле. Киләчәктә тагы да күбәер дип торабыз инде, насыйп булса.

Әхмәди. Җә, Хәйри абыстай, сездә ни хәлләр бар?

Хәйри. Бертөрле генә йөреп торам әле. Нөркинеке бер көй дигәндәй, һаман да бер көе инде.

Әхмәди. Сезнең тирәгә бер дә барып булмый, Сабир ни эшләр бетереп йөри?

Хәйри. Безнеке инде шул, бер көй дигән шикелле, йөреп торабыз шунда.

Әхмәди. Ярый. Менә хәзер безнең яңа фабрик өлгерде. Бәйрәмдә ходка җибәреләчәк. Әгәр дә керергә теләсә, аңарга да урын табылыр. Хәзерге көндә эшче куллар кадерле.

Хәйри. Булса, ярар иде кана. Бик яхшы булыр иде, югыйсә, һаман да шул бер көе дигән шикелле, бер дә рәтле эш чыгара алмый.

Бай (*ишек кагып, тыштан*). Әхмәди Мөхетдинев шушында торамы?

Әхмәди. Кем бар анда? Ишек ачык, керегез!

Бай керә.

Миңнебай (*үзалдына*). Сөбханалла, өрәкме дип торам.

Әхмәди. Нихәл, бабай, ни йомыш?

Бай. Сез танымыйсыз бугай мине. Мин хаҗи абзагыз булам.

Әхмәди. Чыннан да, таный алмаслык булгансыз.

Бай. Минем күзләрем дә начарланды, Әхмәди сез була торгансыздыр бит, тавышыгыздан шуңар охшатам.

Әхмәди. Әйе, мин булам.

Бай. Исәнме, энем, киленбикә, ялгышмасам, Хәерниса исемле иде бугай, ул да исәнме? Мин сиңа бик зур бер йомыш белән килгән идем.

Әхмәди. Нинди йомыш?

Бай. Үзеңә мәгълүм, безнең инде йорт-җир, мал-мөлкәт калмады. Шайтаннан да ярлы булып калдык.

Әхмәди. Гаҗәбрәк икән. Ишаныгыз да, охранкагыз да булышлык итә алмадымыни?

Бай. Ул иске эшләрне искә төшермәгез инде, Әхмәди.

Әхмәди. Ике ел ярым төрмә бик тиз генә онытылырлык түгел ул. Революция булмаса, һаман да утырган булыр идек яки күптән төрмәдә череп үлгән булыр идек.

Бай. Шулай инде, аның каравы менә безгә соңыннан бик ансат булмады.

Әхмәди. Эш нәрсәдә соң? Минем эшем ашыгыч, йомышыгызны сөйләгез.

Бай. Сату итәргә җае юк, дус-ишләр дә барысы да ташлап бетерделәр, берәр урынга керермен дигән идем. Шул иске эшләрне онытып, син миңа берәр язу бирә алмассыңмы икән дигән идем. Синең һәр җирдә сүзең үтә, диделәр.

Әхмәди. Бик мөмкин. «Охранкага өстемнән донос ясап, ике ел ярым төрмәдә утырттыручы кеше шушы булган иде» дип язып бирсәм, ярый торгандыр бит?

Бай. Юк инде, Әхмәди, алай итмә инде син. Шайтан вәсвәсәсе белән булган эшне алай йөзгә бәрмә инде.

Миңнебай. Әллә, булмаса, хаҗи абзый, минем янга, авылга колхоз атларын карашырга гына барасыңмы? Синең инде тешләрең дә төшеп беткән, минем шикелле, атка дигән солыларны ашый алмассың, миңа атлар карашып йөрерсең шунда.

Бай. Мин авыл эшенә өйрәнмәгән шул. Анда кыенрак булыр. Мин таный да алмыйм, син кем буласың соң?

Миңнебай. Нишләп таный алмаска! Көн саен: «Әллә солыны үзең ашап бетерәсеңме?» – дип, һәр көн бәйләнгән Миңнебаең мин ич инде ул.

Бай. Булгандыр инде, Миңнебай, булгандыр. Тик менә хәзергесе уңайсызрак. Безнең кебек кәсеп-хәрәкәткә өй-

рәнгән кешегә дөньясы уңайсызрак килде. Сез инде, агай-эне, борынгы нәрсәләрне куеп торып, хаҗи абзагызның эшен азрак рәтләп җибәрсәгез иде. Дакумент җаен әйтәм, дакумент җаен.

Ә х м ә д и. Ярый, хаҗи, бигайбә. Син, эш кирәк булса, учреждениеләрнең үзенә туры бар. Үзеңнең әүвәлге байлыгыңны, сәүдәңне, охранкаларыңны – барысын да яшерми әйтеп бир. Шулай булса, сиңа бер документ та кирәк булмас, һәр учреждениенең башлыгы үзе карар. Хезмәт итә алырлык булсаң, алар сине кая куярга икәнен үзләре белерләр. Ләкин бел: советны алдарга йөрмә, барыбер эшең чыкмас.

Б а й. Бетте, Әхмәди, бетте. Безнең бөтен дөньябыз өчен эш чыкмаганны, минем өчен генә чыкмас инде. Ярый, гаеп итмәгез. (*Чыга.*)

Ә х м ә д и. Бик месекенләнеп йөргән була, ә эчендә зәһәр ятканы әллә кайдан күренеп тора. Күрмим, ди, ә күзләре шар кебек.

М и ң н е б а й. Кара син күсене, һаман кимерергә чамасы бар, тотмыйсыңмы капчыгыңны! Атлар карарга чакыргач, «булдыра алмам» дигән була. Белә торып, синең кебек элекке ерткычны, хәзерге корткычны колхоз эшенә алырга без дә дурак түгел. Ни әйтер икән, мин әйтәм.

Ә х м ә д и. Ярый, Миңнебай абзый, хәзергә! Мин китәм әле.

М и ң н е б а й. Ярый, сау булып тор!

Ә х м ә д и. Октябрь бәйрәме көнне кичен миндә кунак булырсың.

М и ң н е б а й. Ярый, килермен.

Ә х м ә д и. Иске вакытларны хәтерләп, бүгенге шатлыкларны бүлешеп, менә дигән итеп бәйрәмләрбез. (*Чыга.*)

Озаталар.
П ә р д ә.

## ЫСУЛЫ КАДИМЧЕ

Трактирда бер кабинет. Ысулы кадимче киерелеп утырган. Алдында берничә шешә, сыра, авызда – папирос. Сәхнә алдында утырган Тәфсирче вакыйганың мәгънәсен Тукаев шигыре буенча[1] тәфсир итә бара.

Тәфсирче

Мәнәр көннәрдә бер көн, әмре трахтир[2],
Утырмыштым ки бер пивнойда сирра.
Кулымны селтәдем фани җиһаннан,
Авызда – папирос, алдымда – сырра[3].

Пәрдә ачыла.

Кадимче

Төкерәм дөньясына,
Диңгез тубыктан миңа.
Ничә мичкә пирәш булса –
Бар да эчемә сыя.

Без акчаны тапмыйбыз,
Акча ул безне таба.
Һәр көн учлап файда итәм,
Эш бара алга таба.

Малны мин үзем табам,
Тапкан акчамны кабам;
Ишаннарга мөрид булып,
Бөтен гөнаһны ябам.

Мин эчсәм – бит үз малым,
Мин чамадан узмадым.
Көн буена сату итәм,
Кич монда итәм җалым.

---

Тәфсирче – аңлатучы.
Сирра – яшерен генә.
Пирәш – сыра.

Нигә ул мал, эчмәгәч,
Теләгәнчә күпмәгәч?
Мин эчмичә ничек чыдыйм,
Тәкъдир шулай көчләгәч.

Өстәл шакылдата.

Әй, син, Иван, бире кил!

Иван керә.

Мә, эчеп җибәр шуны.
Мине сораучылар булса,
Монда җибәр туп-туры.

Иван

Слушаюсь, хорошо,
Тегендә утыра Маша.
Маня да көтеп утыра,
То есть симпатия ваша.

Кадимче

Ә соң безнең кампания?
Кайда алар? Керсеннәр!
Минем бүген юмартлыкны
Керсеннәр дә күрсеннәр!

Иван

Сейчас барсын позову,
Всем я знак даю.
Если еще хотите,
Пол дюжинә подаю*.

Кадимче

Бик буш әле карын да,
Бар, тиз китер барын да.
Сталавайны китер,
Тегесе кирәкми дарм да.

Иван

Слушаюсь!

Чыга.

---

* Хәзер барсын чакырам –
Һәммәсенә ым кагам.
Әгәр тагын теләсәгез,
Алты шешә чыгарам.

Сталавай (*столовой*) – аш алдыннан эчә торган (*аракы*).

Кадимче

Миңа нинди пачут шәп!
Нинди генә орам гәп!
Пол дужинә заказ бирәм,
Санап тормыйм берәмләп.

Әйдә килсен, керсеннәр!
Кем икәнне белсеннәр!
Дошманнарым җыласын,
Тик дустларым көлсеннәр.

Берәү керә.

Берәү

Һә, нихәл, бай, саулыкмы?
Тапкансың син аулакны...
Пирәштән икән эшләр,
Яратмыйсыңмы әллә акны?

Кадимче

Кирәк булса агы да,
Соратырбыз тагы да.
Кәеф өчен пирәш шәп,
Акның юк һичбер ягы да.

Ул бик тиз башка китә,
Изеп ташлый, эт итә.
Кәеф корып, гәпләшеп
Утыруга ни җитә!

Берәү

Дөрест әйттең, агай-эне,
Беләсең үзең җайны.
Күбекле пирәш шәп ул,
Корсакка була җайлы.

Дөрест сүзең, ни әйтим,
Сал әле берне, чөйкәлтим.
Ялгыз эчү күңелсез,
Әйтерсең лә син ятим.

Салып эчә. Икенче берәү керә.

---

Пол дужинә (*дюжина*) – «алты шешә сыра» мәгънәсендә.

Икенче

Һа! Монда шәп икән:
Өстәл, көзгеләр, диван!
Утырырга рөхсәтме?
Стакан китер, Иван!

Иван

*(ишектән башын тыгып)*

Сию минуту!*

Стакан китерә.

Кадимче

Җәгез, әйдәгез, җитеш.
Булмасын гаеп итеш.
Шуны әйтәм, дөньяда
Начарга бара бит эш.

Берәү

Дөрест, дөрест, бик көйсез,
Палужим, сез ничек дисез?
Минемчә, җәдит муллалар –
Барсы да надан, динсез.

Кадимче

Җәдитләрдә нинди дин?!
Мин аларны кяфир, дим.
Без гөнаһлы булсак та,
Алла гафур рәхим, дим.

Тәфсирче

Керештек тикшерергә муллаларны,
Ки, ягъни кайсы азгын, кайсы тәкъва!

Кадимче

Беләмсез, алар тансаны
Бик зур һөнәрдән саный.
Аерма юк: андый кызны
Яки мәткә алсаңный!

---

* Бер минутта, хәзер!
Алла гафур рәхим – Алла гафу итүче, рәхимле.
Тәкъва – дини тотнаклы.
Мәткә – бозык хатын-кыз.

Тәфсирче

Сүгеп теттек җәдитләрне дә, ягъни
Алар – динсез! Шулай язган китапта.

Икенче

Шулай, шулай, алар да
Куфта, сарафан кия.
Кияү – ак якалы булсын,
Шундый динсезне сөя.

Тәфсирче

Күңелләр калды саф ширке залялдән,
Минутта пот вә пот динлелек арта.

Берәү

Сез караңыз бер уйлап:
Алар, театр уйнап,
Динне мыскыл итәләр бит,
Азып киттеләр буйлап.

Тәфсирче

Хәрам, диләр, театр, тансаларны,
Тегендә типтерү – әүля вә әгъля!

Кадимче

Уйлаңыз, бу бит зур эш.
Ачарга кирәк сугыш!
Җә, тагы берне җибәрик,
Әйдә, син, кода, булыш!

Эчәләр.

Берәү

Торганы гел каймак икән,
Эчәргә стуит пирәшен;
Түлке ачуны китерде
Җәдит дигән керәшен.

---

Ширке залял – бозык уйлар.
Буйлап – «дин юлыннан чыгып» мәгънәсендә.
Әүля вә әгъля – яхшырак, уңайрак.

Кадимче

Дин ачуым кузгалды,
Йөрәк тә китте ярсып;
Яртыны җибәрми булмас,
Сорыйк званук басып.

Тәфсирче

Бер оҗмах кошлары булдык бу җирдә,
Бөтен бүлмә тулып китте тәвабка[4].

Икенче

Әле вакыт бик иртә,
Эчик әле, китерт тә.

Кикерә.

Сырасы бик шәп икән,
Борынны ярып кикертә.

Маруся керә.

Беренче

Ә, менә Марусә!
Матурлана ул, үсә.
Ялгыз гына килдеңмени?
Кая калды соң Дусә?

Маруся

Алар да хәзер керә,
Таня да безнең белә.
Сыраңыз да беткән икән,
Минем эчәсем килә.

Кадимче

Сыра бетсә – сорарбыз,
Исерткәнче сыйларбыз!
Бик иркенләп утырыңыз,
Без бит прастуйларбыз.

Без түгел бит франтлар,
Кимибез шиблит, фраклар,
Без барыбыз прастуй,
Барыбыз бериш – братлар.

---

Тәваб (*тәваф*) – изге урын.

Әй, Иван, Стипан!
Китер бире стакан!
Бик шәп итеп утырыйк әле,
Җәдит сөйләп кызды кан.

Марусә, утыр бире,
Юк бит килмәгән җире;
Әгәр мөселман да булса,
Булыр идем мин ире.

Ишектән **Иван** керә.

Иван, китер яртыны,
Өстә тагы алтыны!
Күрмисеңме, кунак килгән,
Кызларның да алтыны.
Закускалар шәп булсын –
Кәбестә, кыяр, балыктан.
Чәйлекне дә шәп бирербез,
Калышмабыз халыктан.

Дуңгыз ите булмасын,
Анысын яхшы кара.

**Иван**

Слушаюсь!

Чыга.

**Кадимче**

Ә бит җәдит дигән халык
Бөтенләй бозлып бара.

**Маруся**

Нигә компанияңез әз?
Нигә син ялгыз, князь?
Ник бу бүлмәгә утырдыңыз?
Фу! Какая гадость, грязь!*

**Икенче**

Не бризгай, ничава,
Зату бит чиста душа**.

---

* Фу! Нинди шакшы, әшәке!
** Җирәнмә, ярар инде,
Ансы булмаса, күңел саф.

Күп көязләнеп тормаска
Наш шәригать куша.

Шулай бүлне хараша,
Кил, Марусинкә, душа.
Җәдитләр көяз булса да,
Карманда ни гроша*.

Ә ми, казанские купса,
Сам торгуем лафкуй:
Сирный спичка биркунса,
Псәкуй лускуд, трәпкуй!**

Кәеф корып утырырга
Наш динге ни жалит,
Ә ват киәргә жилит
Наш шәригать ни вилит***.

Кадимче

Смилыйрак сөйләшергә
Җитми әле градыс.
Әйдә, тагы чөйкәлт берне,
Ник болай тик торабыз.

Иван аракы китерә.

Ә, вәт килде Иван да,
Бетеп китте пиваң да;
Тагы пол дужинә китер,
Җылына торсын тик анда.

Итне күрсәтеп.

---

* Шулай бигрәк әйбәт,
Кил, Маруся, җанкаем.
Җәдитләр көяз булса да,
Кесәдә булмас тиен.

** Ә без, Казан сәүдәгәрләре,
Үзебез кибет тотабыз:
Күкерт шырпысы – унар пот,
Төрле кисәк тукыма – чүпрәк сатабыз.

*** Кәеф корып утырырга
Без акча кызганмыйбыз.
Ә менә жилет кияргә
Безнең шәригать кушмый.

Биркунса (*берковец*) – ун пот (*үлчәү берәмлеге*).

Эта чава, закуска?
Әй, мясо ыштули дуңгуз?
Дуңгуз мясо нам – грих!*
Тукта, ашамый торыңыз!

Беренче

Ни булган дуңгыз булса,
Ашар әле Марусә.

Дуся керә.

Әйдә, кайда йөрисең?
Кил әйдә, утыр, Дусә.

Дуся

Галя, милая, извини,
Чакырмагач сез мине,
Килеп керергә не смела**,
Әйдә, сыйла тиз мине.

Утыра.

Маруся

Ну, әйдәңез, князья,
Эчик әле бераз, йә!
Ник алай тик утырасыз?
Просто безобразие!

Кадимче

Дөрест әйтәсең, верны,
Әйдә, тор әле ычмирны!
Кая, килсен уенчылар,
Яңгырат трактирны!

Икенче

Чыннан да бит бик моңлы.
Кайда, китерт гармунны!
Ә сез шәп кенә җырлаңыз,
Таратыңыз бар моңны!

---

* Монысы нәрсә, кабымлыкмы,
Әй, дуңгыз ите түгелме?
Дуңгыз ите безгә – гөнаһ!
** Галя, җаныем, гафу ит,
Чакырмагач сез мине,
Килеп керергә базмадым.

Маруся

Әй, Ваня, бар, чакыр
Петя белән Митяне.

Икенче аңар кулын сала.

Постой, тик кенә утыр,
Безобразничать итмәле.

Кулын алып ташлый.

Икенче

Мин сине вид яратам!
Люблю, бүлше ничава.

Маруся

Смотри, син тик утыр.
Ато, знаешь, того!*

Бармак яный.

Икенче

Слушаюсь пакурны**.
Нинди матур бит борны,
Рәхәтләнеп утырырга
Туры килмәде урны.

Тәфсирче

Трактирларның ул гашыйкларыннан
Тезелделәр килеп катына торра.
Диделәр: «Кем, ничек тик ултырасың?
Давай гармун китерт, безнеңлә җырла».

Скрипкәче һәм Гармунчы керә.

Китерттек скрипкә берлә гармун;
Кызыклы барча нәрсә килде монда.
Фәкать бер бүлмәдә, һич кемсә күрмәс,
Китерттек берничә акшарлы кыз да!

---

* Кара әле, син тик утыр.
Юкса, беләсеңме, аң бул!
** Буйсынып тыңлыйм.
Торра – барысы.

К а д и м ч е

Килеңез, әйдә, кереңез!
Кайда тагы береңез?!
Уйнаңыз да көлеңез,
Бер җырлап та биреңез!
Мә, чәйлеген ал пируд!*

Акча бирә.

Г а р м у н ч ы

Хәзер уйнап бирербез,
Бераз тамак чылатыйк.
Марусә бик оста җырлый,
Әйдә шуны җырлатыйк.

Бу урында бер рус көе яки русчадан бозып ясалган бер татар көе җырлана.

К а д и м ч е

(*исерек*)

Әйдә, дустлар, эчеңез,
Тот кулыңа стакан,
Эчәргә бетсә – китер,
Әй, Иван, Стәпан!

Эчемлек сала. Эчәләр.

Әйдә, дустлар, утырыйк,
Өстәлләрне тутырыйк;
Мондый дустлар тиз җыелмас,
Уйнап, көлеп утырыйк.

Тагы берне салып эчә. Дусяны кочаклап.

Кара син нинди, Дусә!
Караган саен үсә.
Берәү үлә, берәү туа,
Ә дөнья бит – калүсә.

Д у с я

Ну, будет, князь, оставь!
Кеше бар, не хорошо**.

Залдагы халыкны күрсәтә.

---

К а л ү с ә (колесо) – тәгәрмәч, көпчәк.
* Мә, чәйлеген алдан ал!
** Йә, тукта инде, князь!
Кеше бар, яхшы түгел.

Күрәсең бит: халык көлеп
Бер-берсенә караша.

Кадимче

Әйдә карый бирсеннәр,
Әнә бездән көлсеннәр;
Берсенә дә исем китми –
Мин кемлекне белсеннәр!

Мин үз акчамны эчәм,
Теләсәм – хурлар кочам,
Теләсәм – җирдә йөрим,
Теләсәм – күктә очам!

Уйнаңыз, әйдә, гармун,
Акырт, кызганма телен.
Типтереп кал дөньясында –
Миңа бик рәхәт бүген!

Эч, эч, әйдә эчеңез,
Кабарганчы эчеңез!
Типтереңез дөньясында
Булганынча көчеңез!

Мәлҗеп төшә. Табындагылар эчәләр.

Дуся

Әй, князь, вставай*,
Безнең белән эч давай!

Икенче

Әйдә, өеңә озатыйк,
Тагы берне эч тә, бай!

Кадимче

(*йокы арасыннан*)

Я бүлше не хачу!**
Җәдитләргә килде ачу!
Алар динсез! Бетте аларның
Хатыннарында качу![5]

Йокыга китә.

---

* Әй, князь, тор.
** Мин бүтән теләмим.

Маруся

Вставай, князь, будет!
Надо же его будить*.

Завод кычкырта.

Дуся

Черт с ним, домой пора,
Слышишь, завод гудит**.

Маруся

Ну айда, пойдем, пойдем!
Завтра другой раз зайдем.
Может завтра другого –
Получше его найдем***.

Чыгалар.

Беренче

Әйдә, күтәр стакан,
Хәзер дөнья безнеке!
Бик шәп булыр, көн саен
Эләксә шундый бер-ике.

Стакан һәм шешәдәге калдыкларны эчәләр.
Закускаларны да ашыгып-ашыгып ашыйлар.

Икенче

Тагы да яхшырак булыр,
Кесәсен дә бушатсак.
Борынын, аягын кыркып,
Матур кошка охшатсак.

Беренче

Бар алайса, син кара,
Кеше-кара күрмәсен.
Мин бире җаен карыйм,
Арчыйк әле бүлмәсен.

---

* Тор, князь, җитәр!
Аны уятырга кирәк бит.
** Чәнчелсен лә, кайтырга вакыт,
Ишетәсеңме, завод кычкырта.
*** Йә әйдә, киттек, киттек!
Иртәгә тагын керербез.
Бәлки, иртәгә бүтәнне –
Аннан яхшыракны табарбыз.

Икенче ишектән карана. Беренче Кадимченең кесәсен арчый.

И к е н ч е

Җә, әйдә, тиз, булдымы?
Бербөтенгә тулдымы?

Б е р е н ч е

Бөтенлек тә, артык та!

Көлеп.

Бәхет башка кундымы?!

Чыгалар.

Т ә ф с и р ч е

Хисапсыз күп эчте, мәлҗеде ул.
Утырган җирдә шунда кагылды ул.
Шул ук хәлдә аңар бер төш күренде.
Төшендә бик гаҗәп бер эш күренде.
Сөйлимме мин төшендә ул ни күрде?
Үзен ул гүяки оҗмахта күрде.

Сәхнә караңгылана. Артта пәрдә ачыла. К а д и м ч е «оҗмах»та өстәл янында утырган. Тирә-ягында матур киенгән к ы з л а р, г ы й л ь м а н н а р, алдында төрле эчемлекләр, закускалар; ул анда бер кулы белән эчә, икенче кулы белән х у р л а р коча.

Т ә ф с и р ч е

Тезелгәннәрдер әтрафында хурлар,
Ки айдан якты йөзләр, балкый нурлар.
Пичәтләнгән шәраблар алга килгән,
Афисиантлар – бары вилдан вә гыйльман.
Эчемлекләр – бөтенләй бесплатный,
Берәү дә бер тиен акча түләтми.
Кызык соң, бер кулы белән эчә ул,
Икенче кул белән хурлар коча ул.
Кетердәп тәмле пешкән кәтлите бар,
Закускага дәхи кошлар ите бар.

Бер яктан Р и з в а н чыга.

---

Г ы й л ь м а н н а р – җәннәт хезмәтчеләре.
Х у р л а р – җәннәт кызлары.
Ә т р а ф – тирә-як.
В и л д а н в ә г ы й л ь м а н – оҗмахтагы хезмәтче егетләр.
Р и з в а н – җәннәт бакчалары сакчысы.

Бераздан бер тарафтан чыкты ризван, –
Тәмам алтын-көмешкә, нурга чумган.

Кадимче

Сөйлә әле, и хәзрәт, бәүвабы җәннәт,
Нидән ләкте миңа бу назы нигъмәт?

Ризван

Шулай, оҗмахлысың, син чөнки динле,–
Химаять әйләдең пивнойда динне!

Сәхнә караңгылана. Картина күздән югала. Сәхнә яктырганда,
Кадимче электәгечә йоклап утыра. Бераздан уяна.

Кадимче

(*як-ягына карап*)

Ә мин соң әле кая?
Җәннәттә идем бая.
Мине ялгыз калдырып,
Иптәшләр нишләп тая?

Тәфсирче

Төше шул төшкә җиткәндә уянды.
«Мин әле кайда?» – як-якка каранды.
Утырган дустларыннан җилләр искән,

Кадимче кесәсен капшана.

Кесәгә кулны салса – тайды истән.

Кадимче

Ходай орган караклар, уңмаганнар,
Кесәмнән пыртманитны урлаганнар.

Иван керә.

Тәфсирче

Шул ук хәлдә килеп керде афисиант,
Рәхимсез йөртәдер күзләрне ялт-ялт.

---

Бәүвабы җәннәт – оҗмах ишеге сакчысы.
Назы нигъмәт – сый-хөрмәт.
Химаять әйләдең – сакладың.

Афисиант

Позволь, барин, двадцать рублей с вас!
Давайте скорей, – скоро уж час!*

Кадимче**

(*ике кесәсен чыгарып*)

Шту делат?
Май динги бит иптәшләр украл!
Сабакылар они, украл да удрал!

Афисиант

Вон как! Неужели так!
Знаем мы вашего брата.
Давайте скорей, мне итти пора,
Минеке дә домой йоклайт пора.

Кадимче

Җәйбүге, дим, динге сапчим карапчил.
Күрмисеңме, кесәмдә исә бит җил?

Афисиант

Знаем мы вашего прекрасно,
Айда, не валяй дурака понапрасно.
Бесплатно хотел «кызым» угостить?
В награду будешь в участке гостить.

Афисиант чыга, тышта свисток тавышы. Кадимче аптыраштa кала, кесәләрен ашыгып-ашыгып капшый.

Тәфсирче

Афисиант күп талашмый китте моннан,
Ике данә кылычлы хәзер булган.

Ике городовой керә.

Афисиант

Пожальте, вон он, барин.

---

* Рәхим итегез, барин, сездән егерме сум!
Бирегез тизрәк – инде сәгать бер тула!

** Кулъязма бу урында өзелә. Дәвамы 1935 елгы басмадан бирелде.

Кадимче

Харап булдым, инде мин кайда барыйм?

Городовойлар

Это что ли?

Афисиант

Да.

Городовойлар килеп култыклыйлар.

Городовой

Айда!

Кадимче

Җәйбүге минә карапчил!

Афисиант

Что? Карапчил?

Городовойлар

Айда, не разговаривай!

Типкәләп алып чыгалар.

Тәфсирче

Чыгып барганда дөп-дөп типкәлиләр,
Яман сүзләр белән дә сипкәлиләр.

Ишеккә бармагы белән төртеп күрсәтеп.

Озак та үтмичә ул часка керде,
Төшенең раслыгын шул чакта күрде.

Пәрдә.

# ТӘКЫЙ ГАҖӘБ, ЯКИ АХЫРЫ ЗАМАН

*Өч пәрдә, биш картинада*

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘДӘГЕ КЕШЕЛӘР:

Мулла – җуан гәүдәле, сирәк сакаллы, җәпчек борынлы, табак битле, ямьсез генә, урта яшьләрдә.

Мөрит – чандыр гына, кәҗә сакаллы.

Мужик – талчукчы бер татар, мулланың йомышларын башкаручылардан.

Мәзин – җуантык кына, алпан-тилпәнрәк йөри торган урта яшьләрдәге бер кеше.

Карый – мәчетләрдә Мисыр мәкаме белән Коръән укып, байларга тәрилкә тотып йөрүче, урта яшьләрдәге бер сукыр.

Гармунчы – утыз яшьләрендә, кырма сакаллы. Башына кәнител белән чиккән кәләпүш кигән, күлмәк итәген тышка чыгарып калдырып, аның өстеннән жилет кигән кара мыеклы кеше.

Җуан бай – Казанның Печән базары «әкабир»ләреннән, сәүдәгәр бер бай.

Нәгыймә – яшереп фәхешханә тотучы, эчеп шешенеп беткән, карылган тавышлы, битләрен җете кызылга буяган бер хатын.

Хәдичә – шулай ук битен кан кызыл төскә буяган башрак бер фахишә.

Татарлар, фахишәләр, бай белән килгән татарлар.

Вакыйга татарлар күп тора торган зур шәһәрдә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Пәрдә ачылыр алдыннан пәрдәгә түбәндәгечә язу төшә:

Замана ахыры булса, ниләр булгай?
Дөньяга төрле-төрле бәла тулгай.
Галимнәр чагыр эчеп, зина кылгай,
Мондыйн артык тәкый гаҗәб дыңнары бар.

Сәхнәдә уртачарак кына бер бүлмә. Бер почмагын ширма белән бүлгән, уртада өстәл, урындыклар. Өстәл әйләнәсендә Мулла, Мәзин,

---

Мәкам – көй.
Әкабир – зур кешеләр.

Мөрит, Карый, Мужик, фахишәләр белән аралашып утырганнар. Фахишәләрне кочалар һәм эчәләр.

Мөрит. Әйдә, мәзин, нишләп утырасың, бул инде.

Мәзин. Мин мәҗлесләрдә дә аш бүлә-бүлә арып беткән инде. Менә яшь бикәчләр бүлеп бирсеннәр әле. Алар кулыннан эчкәч, тәмлерәк тә булыр.

«Кыз»лардан берсе. Әйдә, адаш, бүл.

«Адаш» сала, һәммәсе дә рюмкаларны күтәрәләр, эчә башлыйлар, муллага рюмка җитми.

Мулла. Көлле кем кад әхәз әл-җамә,
Вә ля җамә ләна,
Мәлләзи зарра мөдир әл-җами
Ләү җамә ләна*.

Мөрит. Нәрсә укыдың, хәзрәт? Син инде безгә ул сүзләреңнең мәгънәсен дә әйтеп бир, ул ни дигән сүз була соң?

Мулла. Аның мәгънәсе менә шул: «сезнең һәркайсыгыз да рюмкаларыгызны алдыгыз, ә без фәкыйрегезгә рюмка юк». (*Янындагы «кыз»ны кочаклап.*) Ни булган булыр иде бу чибәр кызга, әгәр дә безгә дә рюмка китерсә?!

Нәгыймә. Кая, хәзрәткә бер рюмка китерегез.

Мужик. Ярый, ярый, хәзрәткә мин үзем табып китерермен. (*Чыга башлый.*)

Хәдичә. Бар алайса, энә, бар, теге якта лакан янында бер рюмка бардыр, кичә мин теш чистартырга дип тоз белән көл салган ием, шуны җуып алып кил.

Мужик. Ярый. (*Чыга, рюмка алып керә.*)

Мулла (*янындагы «кыз»ны кочаклап*).
Ватә нәдимән ли хәттәссабах,
Әгъядө мәҗдүли мәканил вишах!**

Мужик. Хәзрәт, син инде аның мәгънәсен дә әйтеп бир.

Мулла. Аның мәгънәсе – безнең капка баганасы. Ә син, мужик, утын агачы. Шуның да мәгънәсен белмисең.

Мужик. Үзегез өйрәтмәгәч, хәзрәт, без аны каян белик? Үзегез өйрәтмәдегез ич.

Мулла. Өйрәтмәдек шул. Сезгә нигә өйрәтергә? Мужик өчен гарәпчә белүнең һичбер нәрсәгә дә кирәге юк,

---

* Сез үзегезгә кирәк кадәр рюмкалар тутырып алдыгыз, ә без фәкыйрегезгә рюмка бөтенләй юк.

** «Бу арусыз урында таң атканчы кочаклашып утырыйк әле» дигән мәгънәдә.

мужиклар күпне белә башласалар, гыйлемнең кадере бетә. Сез, мужиклар, без сезгә нәрсә сөйләсәк, сез шуның буенча гамәл итәргә генә тиеш.

Мәзин (*янында утырган «кыз»ны кочаклап*). Хәзрәт, Гомәр Хәйям хәзрәтләре әйткән: «Без дөньяда шәраб эчәбез һәм җир кызларын кочабыз, чөнки безгә «Дөньяда нишләсәң, ахирәттә дә шуның белән кубарылырсың» диделәр. Без бу дөньяда кәҗүнке шәрабын эчәбез, ахирәттә кәүсәр шәрабын эчәр өчен. Без дөньяда менә шушындый җир кызларын кочабыз, ахирәттә, җәннәттә хур кызларын кочар өчен.

Мулла (*шаркылдап көлеп*). Һи сафсата, сафсата! Сиңамы соң шундый кәҗә сакалларың белән хур кызлары кочарга! (*Янындагы «кыз»ны кочаклап.*) Ватә нәдимән ли хәттәссабах, әгъядө мәҗдүли мәканил вишах!

Мужик. Хәзрәт, бая да мәгънәсен әйтеп бирмәдең шуның, мәгънәсен дә әйтеп бир инде?

Мулла. Аның мәгънәсеме? Аның мәгънәсе менә шул: «кичтән таңга кадәр безнең белән табындаш булып утыра торган җирләре йомшак-симез бер кыз утырды» дигән сүз. Әй, мәзин, күптән бирле инде синең биегәнеңне күргән юк. Әйдә, булмаса, бер бик шәп итеп кенә басып җибәр әле.

Мәзин. Бик була ул. (*Торып бии башлый.*) Хурын мәкъсуратын фил хиям. Хурын мәкъсуратын, тын, тын, фил хиям! Хурын мәкъсуратын, тын, тын, фил хиям!* (*Шул сүзләрне кат-кат әйтә-әйтә бии.*)

Мулла. Афәрин, мәзин, җегет икәнсең, мәдрәсәдә икмәк чертеп кенә ятмаган икәнсең. Моталәгаң чыккан икән. Әгәр дә «Сөлләм казыен»[1] да шулай шәп моталәга кыла ала торган булсаң, тәмам кеше булачак икәнсең.

Мәзин. Бер дә уйнама, хәзрәт, без моназарәләрдә Кышкарларга[2] да бирешмидер идек.

Мулла. Җә, әйдә, күңеллерәк булып китсен әле, кызлар, сез дә нечкә тамакларыгыз белән берәр мәкърәне ычкындырып җибәрегез әле.

Нәгыймә. Әнә Хәдичәгә әйт.

Мулла. Җә, әйдә, Хәдичәи көбра хәзрәтләре, берәр мәкърәне әйтеп җибәр инде.

Хәдичә. Әй, мин сезнең ул гарәпчәләрегезне белмим лә!

---

Кәүсәр шәрабы – җәннәттәге баллы ширбәт.
* «Мәхәббәт минем акылымны алды» дигән мәгънәдә.
Моталәга – уку, аңлау.
Моназарә – сүз көрәштерү, дискуссия.
Мәкърә – Коръәннән өзек.
Көбра – иң зур, иң бөек.

М у л л а. Белерсең әле, белерсең. Җә, булмаса, карый, әйдә, син берәр мәкъранe әйттереп җибәр. Әйдә, гармун тәсбихләреңне тезә башла.

Н ә г ы й м ә. Әйдә, Әптери, тарт гармуныңны.

Ә п т е р и. Була ул. (*Гармун уйный.*)

К а р ы й. Каләшшәех фишшифа дип укыганың

мантыйкмы,

Каләшшәех фишшифа дип

укыганың мантыйкмы?*

М у л л а. Юк, юк, тукта әле, мантыйк кирәкми, җырласаң башканы җырла.

К а р ы й. Ярый, башкасы да була. (*Яңагына кулын куеп, Коръән укырга җыенгандагы шикелле тамакларын кырып.*)

Җырла, җырла, дип әйтәсез,
Җыручы җегет мин түгел...

Тукта әле, тамак кибеп китте әле, бераз тамак чылатырга бирегез.

М ә з и н. Әй, сукыр тәре, бик күп эчәсең, исерерсең. Монда инде сиңа салырлык маи саффә дә калмаган.

К а р ы й. Кая әле, шешәңне монда бир әле, карап карыйк – күпме генә калган икән?

М ә з и н (*шешәне биреп*). Мә! Син соң, сукыр тәре, нәрсә беләсең, би гайн!

К а р ы й (*шешәне алып*). Күзсез кеше сукыр түгел, гайннең ун төрле мәгънәсе бар икәнен белмәгән кеше – үзе сукыр. (*Шешәне колак төбендә селкеп.*) Әле монда нәкъ җиде рюмка чыгарлык аракы бар.

М ә з и н. Ярый, карап карыйк. (*Аракыны алып, рюмкаларга сала, аракы нәкъ җиде рюмка була.*) Афәрин, сукыр шайтан, зирәклегеңә! Җә, берне әйттереп тә җибәр инде.

Мулла янындагы «кыз» белән култыклашып, бүлмәгә кереп китәләр.

Мулла абзаң остабикәсе белән хилвәти сәхихәгә очтылар. (*Көйли.*)

Замана ахыры булсаниләр булган?
Дөньяга төрле-төрле бәла тулгай,
Галимнәр чагыр эчеп, зина кылгай,
Андыйн артык тәкый гаҗәб дыңнари бар.

---

М а н т ы й к – логика, тәртипле.

* Шәех яктыга илтә дип укыганың дөресме (логикамы)?

М а и  с а ф ф ә – кәеф суы.

Б и  г а й н – күзсез.

Х и л в ә т и  с ә х и х ә – серле аулак.

К а р ы й (*көлеп*). Әшратый сәгатьмени[3]?

М у ж и к. Нинди алтышар гына сәгать булсын, биш мәртәбә алтышар сәгать булгандыр инде. Тегендә дә әллә ничә сәгать утырдык. Мулла үзе бер дә үзенең кесәсен капшамый, гел минем кесә генә бушый.

М ә з и н. Син, мулла кем, син инде алай миннәт итеп, үзеңнең нигъмәтеңнең әҗерен җуйма. «Мулла ашаса, юллап ашар» дигәннәр, ул сине ким-хур итмәс.

М у ж и к. Ким-хур итмәс, ким-хур итмәс, әгәр дә болай күпкә китсә, минем кесәдәге акчалар да күпкә җитмәс.

К а р ы й. Менә мин дә әле баядан бирле шуңар гаҗәпләнеп утырам. Һәркем: «Замана ахыры да, замана ахыры», – диләр. Китапларның әйтүенчә, әгәр дә ахыры заман җитсә, Җир үзенең эчендәге бөтен хәзинәләрен җир өстенә чыгарып ташлар, ахыры заманда малның һич кадере булмас, алтын-көмеш, җәүһәр-якутлар җир өстендә чәчелеп ятарлар, һичбер кеше дә аларга илтифат итмәс, дигән. Пәйгамбәрнең хәдисләре[4] буенча күптән инде ахыры заман булырга тиеш ие, ә хәзергә кадәр әле алтын-көмешләрне бер дә түгеп-чәчеп йөрткән кешеләр күренми. Алтын-көмешләрне түгел, кәгазьне дә бик тиз генә ычкындырмыйлар. Җиде ясин[5] чыккан өчен дә бары кырык-илле тиен генә тамызалар.

М у ж и к. Анысы инде, карый, «Биргәнгә биш тә күп, алганга алты да аз» дигәннәр. Менә әле үзем дә шушы көннәрдә, ун шыр чәй саттырыр өчен, бер атнадан артыграк йөрдем, ә мае, мае дисәң, бары биш кенә тәңкә булды әле, карый, сезнең эш ничек тә ярый, ничек тә безнеке шикелле түгел, ансат. Сез бит акчаны бит сыпырып кына аласыз, ә менә без бер тиен өчен дә маңгай тире түгәбез.

Г а р м у н ч ы (*үзалдына*). Бу мыжымнан да күп рәт чыкмас, ахры. (*Ишеттереп.*) Мин баядан бирле карап-карап торам да, сез бары тик үзегезне генә кайгыртасыз. Сез бераз минем якка таба да рәхим капчыгыгызны салындырыгыз.

М ә з и н. Ие шул, аның да авызы кипкәндер, мә, бераз авызыңны җебет! (*Аракы салып бирә.*)

Г а р м у н ч ы. Җебетсәк, зарар итмәс шул. (*Алып эчә.*) Иң элек авызны җебет, аннан соң уч төбен җылыт, аннан соң булырсың җегет.

М ә з и н. Ха-ха-ха! Менә, менә монысы ярый! Ә син бу сүзгә ни дисең, карый?

К а р ы й. Карый, карый, карыйга аңар ничек тә ярый. Ә менә минем әле тагын мәзиннең мәкамен бераз ишетеп

---

М и н н ә т – битәрләү.

аласым килә. Мәзин әфәнде, кичә сезнең хосуллар чибәр генә булды шикелле? Фидиягә[6] яхшы гына бер тамак толып[7] эләккән, диделәр бугай?

Мужик. Шул, бугай гына ла ул. Аннан бик күп мәгънә чыгарлык түгел. Якасына көя төшеп беткән.

Мәзин. Алучы кеше һәрвакытта да шулай ди инде ул. Әй, чынлап та, синең ул толыпка күпме бирерлек чамаң бар? Бер «әби»не[8] бирерсең бит инде?

Мужик. Ничәсенә? Акылың алтын икән, мәзин. Сыена алтыны әйләсәң, ярты йөзне бирергә ярый, анда да бары тик үз кеше итеп кенә. Юк исә аның тышы тәвәккәл бүректән башкага ярарлык түгел, бик кырылган.

Карый. Әйдә, булмаса, берәр сәүдә дә итеп алыгыз. Безгә дә мөгәриҗе булыр.

Мужик. Юк, карый, шуннан артык булырлык булганда, эш күтәрми. (*Үзалдына.*) Ярты йөз дә мае чыгарлык булмагач, мин аны нигә дип алыйм? Ул бит аңар «Аллаһы әкбәр»гә генә килгән.

Мәзин. Чынлап, Гайнетдин абзый, әгәр дә алырга ниятең булса, ят кешегә китмәсен, син дә игелеген күр, мин дә бераз ташлармын. Әнә барсын, алты миннән булыр, берәр дужинә синнән. Бәя сиксән сум булыр. Син мине дә кысма. Андый фидияләрне без кайвакытларда икешәр ел көтеп алабыз.

Мужик. Ярый алайса, сыйның* барысы да синнән, бәя алтмыш булыр.

Мәзин. Гайнетдин абзый, син юкка гына изәсең, әле мин... әле мин баш бераз кыза төшкәнгә генә ычкындырып җибәрдем инде.

Мужик. Йә, ярый, мәзин, син дә кысма, мин дә кысмыйм, унике синнән, бәя – җитмеш.

Мәзин. Җә, ярар, Гайнетдин абзый, төгәл өч чирек булыр.

Мужик. Ярар алайса инде, пружбең калмасын. Миңа файдасы калмас калмавын, ярар инде, тагы башка вакытта берәр уступке ясарсың. Түлке кара аны: әгәр дә эченә көя тигән булса, алмам.

Мәзин. Юк, юк, юк. Андый-мондый булса, мин соң

---

* Авторда: сыйнының.

Мәкам – көй.

Хосул – керем.

Алтыны әйләсәң – «алты шешә эчемлек алсаң» мәгънәсендә.

Мөгәриҗ (*мөһәрриҗ*) – күңел табу, исертү.

Дужинә (*дюжина*) – «унике шешә эчемлек» мәгънәсендә.

Пружбең (*просьба*) – теләгәнең.

Уступке (*уступка*) ясарсың – «бәяне киметерсең» мәгънәсендә.

аны үз кешегә бирәмме? Шәп, шәп, бик шәп, бик нәгыз нәрсә, менә дигән, нәкъ кызлар шикелле. Бай бит аны бик зур мәҗлесләр булганда гына киядер иде, башка вакытларда кладаваеннан да чыгармыйдыр иде. Хәзер аның шикелле янып торган кызыл тамак толыпны бик сирәк табарсың. Хәсис, бит ул аны үзе кияргә дә кызганадыр иде. Сиңа насыйп мал икән.

Мужик. Йә, ярый инде алайса, әйдә, иң элек синең шутка бер дуржинаны китерсеннәр, аннан соң... Әйдә, Нәгыймә, бар, уникене китер.

Нәгыймә. Акча пирут! Югыйсә сез исергәч тана башлыйсыз.

Мужик. Юк инде, кызый, бездә андый эшләр булмас! Без, әлхәмделиллаһи, чисный кеше, кешенең бер тиененә дә тигәнебез юк.

Нәгыймә. Ә мин чисный түгелме? Мин ышанычлы, чисный булмаган кешене бусагамнан да атлатмыйм. Миңа сез генә түгел, шәһәрнең менә дигән атаклы байлары да киләләр. Минем һичбер вакыт һичбер тиеннәренә дә тигәнем юк. Аллам сакласын, кеше хакына хыянәт кылырга. Син алай, үзең генә чисный булган булып, кәпрәеп утырма. Без дә бик яхшы беләбез сезнең нинди кеше икәнегезне.

Мужик. Йә, ярар ла инде, Нәгыймә, нигә ул кадәр чәпчисең? Мин бит син чисный түгел дип әйтмим ич.

Нәгыймә. Әйтмәсәң, менә шул: телеңне бераз тыя төшебрәк сөйләш. Без дә сезнең кем икәнегезне бик яхшы беләбез. (*Чыгып китә.*)

Мәзин. Менә кәсафәт, хәзер кызарга гына тора, ялкынмыни?

Битләрен яулык белән сөртә-сөртә, Мулла керә.

Нихәл, тәкъсир, эшләр максудчамы? Яшь остабикәдән уңдыңмы? Аның, кәсафәтнең, сәдәйләре эт башы кадәр бар. Синең белән минем остабикәләр шикелле генә түгел.

Мулла. Ля тәкәлләм кәсир, май кап*.

---

* Күп сөйләмә, май кап.
Нәгыз – яхшы, шәп.
Хәсис – эшәке, саран.
Шут (*счет*) – исәп.
Дуржина (*дюжина*) – унике.
Пирут (*вперед*) – алдан.
Кәсафәт – йөзе кара, бит ертучы.
Тәкъсир – олылау сүзе.
Максуд – теләк.
Сәдәй (*сәди*) – имчәк.

Мәзин. Өскөту, рәхимәкемуллаһ моный!* Кая соң әле бу бәдчәһар Нәгыймә, кая югалды? Хәмамнан соң «салкын чәй» бик шифалы була торган ие.

Мулла (*көлеп*). Һи сафсата!

Нәгыймә шешәләр кертә.

Нәгыймә. Җә, кашынып җибәрегез әле, кайсыгыз кашына?

Мулла. Ә, менә монысы ярый! Болар ничек, кайдан болай көтмәгәндә генә килеп чыкты? Әллә һәүне кәүсәрдәнме?

Мужик. Син югында без монда «Мөхтасар»дагыча[9] бераз бәйгы фасид кылып алдык әле, мәзиннең теге фидиягә килгән толыбын сатып алдым, бу шуның сые.

Мулла. Шәп булган, бик шәп, файдасын күр.

Нәгыймә. Җә, әйдә, фасид-масидләрегезне соңыннан сөйләрсез, тизрәк кашыныгыз, кибетләр ябылганчы, алдырып калдырасы нәрсәләрем бар.

Мужик (*мәзингә акча биреп*). Мә, мәзин, тот, ал акчаңны! Сәдакаларыңны үз кулың белән бирерсең.

Мәзин (*акчаны алып*). Нинди сәдака? Мулла-мәзиннең сәдака бирмәгәнен бер дә белмисеңмени? Сәдака булмаганда да әле, кулга кергән акчаны кире чыгару бик читен. (*Акчаны санап.*) Дөреслеккә дөрес икән дә инде, әллә, булмаса, Гайнетдин, яртысын син бирәсеңме?

Мужик. Юк инде, мәзин, анысы булмас. «Мәгәр ирмен дигәннең вәгъдәсе төз. Әгәр төз булмаса, андыйн өмид өз» дигән ди бит китапта.

Мәзин. Анысы шулаен ул шулай да, ләкин кесәгә кереп җылынып та җитмәгән акчаны кире чыгарып бирү бик читен шул, мулла Гайнетдин!

Нәгыймә. Җә, нишләттердегез инде?! Нәрсә тагы телегезгә салынасыз? Әйтәм ич, кибетне ябалар, дип!

Мәзин. Мә, мә, мә, зинһар, ачуланма гына, кәсафәт! (*Акчаны яңадан бер мәртәбә астын-өстен әйләндереп карап бирә.*)

Нәгыймә чыга.

Фу! Чыннан да, бик читен булды. (*Шешәдән салып.*) Кайгысын бераз бастырыйм ичмаса! (*Эчә.*) Каушавымнан кәгазьләрнең башларын чеметеп алып, кесәгә салырга да

---

* Тукта әле, рәхимле мулла!

Бәдчәһар – битсез, оятсыз.

Хәмам – мунча.

Һәүне кәүсәр – тәнгә җиңеллек бирүче җәннәт күле.

Бәйгы фасид кылу – бозыклык эшләү, сатулашу.

оныткanмын, яңадан тиздән акча керергә сәбәп була торган иде. (*Яңадан салып эчә.*) Уф!

Мөрит. «Пае мари, чәшме мури, нано мөлла кәс надид»* диләр иде, дөрес түгел икән.

Мәзин. Мин мулла түгел шул, мәзин генә.

Мулла. Һи сафсата! Фарсыча сөйләп яткан буласың тагы.

Мөрит. Син алай димә, хәзрәт, мин бит Бохараи шәриф күргән кеше[10].

Мужик. Син инде аның мәгънәсен дә әйтеп бир. Без дә аңлыйк. Без бит галим-голәма мәҗлесендә шул китап сүзләрен ишетер өчен күбрәк булабыз.

Мөрит. Аның мәгънәсеме? Аның мәгънәсе: җыланның аягын, кырмысканың...

Мулла. Мәхзүм, тукта. (*Кулын селтәп.*) Мәхзүм, тукта, мин истибрага бик кысталдым. Сөйләсәң, мин чыккач сөйләрсең. (*Тора, кесәсеннән бер шешә белән «вак» чыгарып, тел астына сала.*)

Мәзин (*торып*). Тукта, хәзрәт, мин дә бик кысталдым. (*Мулла янына бара.*) Тораби шифадан миңа да бераз тәнәззел иттер әле. (*Сала.*)

Икәүләп чыгалар.

Мужик. Җә, сөйлә инде, чыгып киттеләр.

Мөрит. «Җыланның аягын, кырмысканың күзен, мулланың ашын дөньяда һичкем күрмәде» дигән сүз.

Мәзин (*ишектән башын тыгып*). Һи, кәсафәт, артта гайбәт сатып утырасың. Эчә торган сыраларың минеке бит әле! (*Югала.*)

Мужик. Кызык икән!

Карый. Сез алай голәманы тәхкыйрь кыйлмагыз. Син бит үзең дә ишан нәселеннән.

Мөрит. Була бирсен, мин туган чакларда әти ишан түгел иде әле. Ул тик соңыннан гына, болай гына, Бохарага барып җөреп кайткачтын гына, җиңел кәсепкә өйрәнеп китте.

Гармунчы, гармунын кыстырып, чыга башлый.

Тукта, син кая барасың?

---

* Еланның – аягын, кырмысканың – күзен, мулланың ашын һичкем күрмәс (*фарсыча мәкаль*).

Мәхзүм (*мәхдүм*) – дин башлыклары улларына эндәшү сүзе.

Истибра – бәвел итү, бәвелдән соң юыну.

Тораби шифа – туфрак шифасы.

Тәнәззел иттерү – авыз иттерү.

Тәхкыйрь кыйлу – хурлау, мыскыл итү.

Г а р м у н ч ы. Кая барыйм, чыгам. Монда сезгә төн буена бушка гына уйнап утырмам.

М ө р и т. Сабыр ит, сабыр, сиңа да хәзер булыр. (*Мужикка.*) Әйдә, аңар син кашын инде. Толыпның маен бераз чыгар.

К а р ы й. Бераз гына зәкяте[11] кирәк шул.

М у ж и к. Миннән зәкяте генә түгел, гошере[12] дә булды инде. Маен да, каймагын да җыеп алдылар. Җә, ярар инде, синең дә пруҗбең калмасын. Мә, менә! (*Акча бирә.*)

Г а р м у н ч ы. Менә монысы ярый. Шулай дөрес бит, карый? Шулай яхшы гадәтле булырга кирәк.

М у ж и к (*сыра салып*). Мә, менә тамагыңны да чылат!

Г а р м у н ч ы. Анысы тагы да шәп. (*Эчә.*)

М у ж и к. Җә, бераз әйттереп тә җибәр инде. Аларның сүзләрен тавык чүпләп тә бетерә алмас.

Гармунчы уйный башлый. М ә з и н керә.

М ә з и н. Менә, менә, монысы шәп! Бик шәп! (*Килеп утыра.*) Ә сез, кызлар, нишләп тик кенә утырасыз? Әйдәгез, сез дә сайрап җибәрегез.

М у ж и к. Чынлап, сез дә гел авызыгызга уймак кына кауп утырасыз.

Б е р «к ы з». Тукта, җырларбыз әле, «Туганым» керсен! Без генә монда нәрсәгә авыз күтәреп утырыйк? Бар, дусым, чакыр үзен, мулла хатыны булдым дигәч тә, остабикә булып ятмасын әле.

«Кыз»ларның берсе чыга.

М ө р и т. Әллә яңадан зөфаф кичәсеме[13]?

М у л л а, и к е к ы з керәләр.

Әле сезне генә сөйләп торадыр иек, әллә кая югалдыгыз.

М ә з и н. Сәдәй шәрифләрен бераз угалап алды бугай.

М у л л а. Һи сафсата!

Утыралар.

М у ж и к (*стаканнарга сыра салып, гармунчыга бирә*). Җә, әйдә, әйттереп тә җибәр.

Барысы да эчәләр.

Ә сез, кызлар, сезнең дә тамакларыгыз тутыгып бетмәсен, сез дә бераз сайрап алыгыз.

Б е р «к ы з». Әнә остабикә җырласын, остабикә генә булып ятмасын әле.

«Т у г а н ы м». Җырлармын шул, синнән сорап тормам. Бик җырлыйсың килә икән, үзең җырла. Хәрап икән, җырларга бик оста булган, имеш, һи, әҗәткана!

М у ж и к. Җә, җә, жә, зинһар, кычкырышмагыз!

Гармунчы гармунның басын акырта.
Н ә г ы й м ә ишектән ашыгып керә.

Н ә г ы й м ә. Нәрсә бар, ни булды?

Г а р м у н ч ы (*күзе белән «кыз»ларны күрсәтеп*). Юк, берни дә юк.

Н ә г ы й м ә (*«Туганым»га*). Ни булды?

«Т у г а н ы м ». Менә, бу ич!

Б е р «к ы з ». Мин сиңа нәрсә әйттем соң? Чебен тимәс чер итәр!

М у ж и к. Җә, ярар, талашмагыз! Әйдә, тарт гармуныңны!

Гармунчы кыска көй уйный, «кыз»лар такмак әйтәләр.
Бу урында нинди булса да берәр төрле мәгънәсез такмак әйтелер.
Такмак туктагач.

Әйдә, булган икән булсын, бер басып та алыгыз инде.

Гармун бию көе уйный, «кыз»лар бииләр. Бию тәмам кызып җиткәндә генә тыштан ишекне бик каты дөбердәтәләр. Уен туктый.

Н ә г ы й м ә. Тик кенә утырыгыз, курыкмагыз, салмыкыйлардыр әле. (*Чыга. «Кыз»лар тиз генә шешәләр, стаканнарны җыялар. Нәгыймә ишектән бик ашыгып керәп.*) Хәзрәт, хәзрәт, һәрап булдык, нишлибез, сезнең мәхәллә байлары килгән, яннарында мин танымаган берике кеше дә бар, сезне сорыйлар.

М ә з и н. Хәрап булдык, инде нишлибез?

Карый тиз генә торып, кармаланып, качарга урын эзли, нәрсәләрне аудара, мәзин почмактагы караваат астына кача башлый.

М у л л а. Туктагыз, алай булмый. Ничек тә башкача юлын табарга кирәк. Һәммәгез дә тизрәк уйлагыз.

Барысы да тыналар, күзләрен муллага тегәләр.

(*Бераз уйлап торгач, шатланып.*) Таптым! Тизрәк өстәлне җыегыз да идәнгә табын әзерләгез.

Тыштан дөбердәтәләр.

К а р ы й. Рисвай булдык, хур булдык! Ураза җиткәндә генә хәрап булдык, хәтемсез калдырдылар!

Дөбер-шатыр өстәлләрне җыялар.

М у л л а. Бер дә каушамагыз, әйдә, тизрәк табын! Син, мәхзүм, кияү булырсың, ә син, Нәгыймә, килен булырсың, ә мин никях укырмын.

---

Х ә т е м с е з к а л д ы р у – тәмамлатмыйча калдыру.

Дөбердәтәләр.

Б а р ы с ы  д а. Ярый, ярый!

М у л л а. Әйдә, кызлар, сез тизрәк табын әзерләгез.

«Кыз»лар чыгалар, идәнгә эскәтер ябып, көрпәләр салып, тәрилкә-кашыклар кертәләр. Мулла, мәзиннәр дә – барысы да булышалар. Мулла биленнән чалмасын алып, башына урый. Түргә менеп утыра. Һәммәсе дә утырышалар.

Бар, ач инде, керсеннәр.

Нәгыймә чыга, ишек ача, д у р т - б и ш  т а т а р дөбердәшеп, шаулашып килеп керәләр. Табын янында Мулла, Мәзин, Карый, Мөрит һәм Мәхдүм утырганны күреп, аптырап калалар.

Җ у а н  б а й (*ирексез*). Әссәламегаләйкем!

Б а ш к а л а р (*ирексез*). Әссәламегаләйкем!

М у л л а (*һичбер нәрсә булмаган шикелле, салкын кан белән генә*). Вәгаләйкемәссәлам! Әйдәгез, хуш килдегез, утырыгыз, югарыданрак рәхим итегез.

Җ у а н  б а й (*аптырап*). Юк, хәзрәт, рәхмәт, борчылмагыз, безгә шушында да ярар.

Мужиклар, аптырашып, ирексез табынның түбән буена утыралар.

М у л л а. Җәгез, фатиха[14].

Барысы да дога кылалар.

Хуш килдегез, кодалар, хуш килдегез, сез кияү ягыннан буласызмы, әллә кыз ягыннанмы?

Җ у а н  б а й. Ничек, хәзрәт?

М у л л а. Ничек дип, кыз ягыннанмы, әллә кияү ягыннан чакырылган кодалармы, дим?

Җ у а н  б а й. Ни, хәзрәт, без... без... болай гына... ие, болай гына...

М у л л а. Ярый, ярый, ничек тә ярый. Кияү дә инде сезгә таныш кеше, килен булачак кеше дә инде, әлбәттә, сезгә күптән таныштыр. Баштарак, килен булачак кешенең исеме-чабы чыкканрак кеше булганга күрә, мин бигүк риза булып җитмәгән идем җитүен дә, мәхзүм үзенең өйләнүе яхшы нният белән булганын белдергәч, шәһәребездә, бәлки, фисык-фәсадның кимүенә дә сәбәп булыр дип, риза булдым. Иншалла, ахыры яман булмас әле. Сез килгәч, мәҗлесләр дә күркәм булып китте. Мин шулай мөгътәбәраннар катышкан мәҗлесләрне бик яратам.

Җ у а н  б а й. Хәзрәт, без болай гына ие, без болай гына...

---

Ф и с ы к - ф ә с а д – бозыклык.

М ө г ъ т ә б ә р а н – ихтирамга лаек.

Мулла. Яхшы, яхшы, мин сезне гаепләп әйтмим, ният яхшылыкта булгач, ничек тә ярый. (*Уенчыга.*) Кара әле, җегет, сез бу йорттагы кеше шикелле, барыгыз әле, теге яктан чыгып сорагыз әле, әгәр дә киләсе кешеләре артык күп булмаса, никяхны көттермәү яхшырак булыр.

Гармунчы. Ярый, хәзрәт, хәзер. (*Чыга.*)

Мулла. Әле сез килер алдыннан гына мәхзүмгә шуны әйтеп торадыр идем әле, мондый фисык-фәсад заманында мондый зур эшкә җөрьәт итүегезгә бик зур...

Гармунчы керә.

Гармунчы. Хәзрәт, башка киләсе кешеләребез юк, диләр.

Мулла. Ә, шулай диләрме? Ярый алай булса, никяхны укысак та ярар. Мәхзүм, синең шаһитларың бармы?

Мөрит. Юк, хәзрәт, минем алдан әзерләп куярга һичбер хәтеремә дә килмәгән.

Мулла. Зарар юк, үзең мәҗлестә хазир булгач, гакыдта да үзең хазир булгач, мәҗлес халкының шаһит булулары кифая инде. Ләкин кыздан вәкиллек һәм ризалык алу кирәк булыр. Аның ягыннан вәкил кем? (*Җуан байга.*) Аның ягыннан вәкил кем, сез түгелме?

Җуан бай. Юк, юк, хәзрәт, юк.

Мулла. Ә кем соң?

Җавап юк.

Мәҗлестә үзе хазир булмаганда, бер вәкил кирәк булыр. (*Җуанга.*) Әллә, булмаса, сез вәкил булып, ата булып утырасызмы?

Җуан бай. Юк, хәзрәт, мин була алмыйм, башка берәр кеше булсын.

Мулла. Ярый алайса, сез шаһит кенә булырсыз. Мәҗлес урыс арасында, еракта булганга күрә, мин митрикене үзем белән йөртергә курка төшәм. Ул бит безнең өчен бик кадерле, бик кыйммәтле нәрсә. Сез бүген моннан кайтышлыймы яки иртәгәме миңа кереп, митрикегә кул куеп чыгарсыз. (*Мужикларның берсенә.*) Икенче шаһит син булырсың. (*Мәзин белән карыйга.*) Мөәззин әфәнде, карый әфәнде, җегет ягыннан сез шаһит булырсыз. (*Җуан байга.*) Сез инде, алайса, ата булып утырырга теләмисез икән? (*Гармунчыга.*) Җегет, син инде, алайса,

---

Хазир булу – күз алдында булу.
Гакыд – сүз беркетү.
Кифая – җитәрлек.

бар әйт, әгәр дә оялмаса, шунда ишек янына гына чыгып торсын.

Гармунчы чыга да Н ә г ы й м ә белән бергә әйләнеп керә.

*(Нәгыймәгә.)* Йа Рабби, үзең гафу ит. Кызым, йөзеңне капла, безнең шәригатьтә хиҗаб, ягъни ирләрдән йөзне каплау важиб.

Нәгыймә җиңе белән йөзен каплаган була.

Кызым, синең исемең ничек?

Н ә г ы й м ә. Нигә, белә торгансыздыр ич инде. Мине шәһәрдә белмәгән кеше юк. Бу байларның һәммәсен дә мин таныйм ич!

Бай һәм мужиклар сискәнеп китәләр.

М у л л а. Шулай да исемең ничек, ни атлы?

Н ә г ы й м ә. Нәгыймә ич!

М у л л а. Атаң ни атлы?

Н ә г ы й м ә. «Атаң ни атлы» дисеңме? Кит аннан, минем әтинең ни атлы икәнен дә белмәскә сез тагы! Аны нигә миннән сорыйсыз? Минем әти бит бу байларга кәвеш тегә иде, күкрәге череп, кибеп үлде.

М у л л а *(Җуан байга)*. Атасы ни атлы соң аның?

Җ у а н б а й *(кызарынып)*. Син Гайнетдин кызы түгелме соң?

Н ә г ы й м ә. Алла! Белмәгәнгә салына тагын. Мин кыз чагында, кибетегезгә кәләпүш төшергән чакларда, бик яхшы беләдер иең әле! Бер вакытны, «чибәр кыз икәнсең» дип, кантурга керергә чакыручы...

Җ у а н б а й. Эһем, эһем... ие, ие, Гайнетдин кызы... читекче...

Н ә г ы й м ә. Нинди читекче булсын! Бутамасана әле!

Җ у а н б а й. Юк, ялгыш әйттем, ие, ие, кәвешче...

М у л л а *(чыдый алмыйча, мыек астыннан көлеп)*. Ярый инде, алайса, никях укыйбыз. Син бу җегеткә хәләл җефетлеккә барырга ризамы?

Н ә г ы й м ә. Әй, мин сезнең җефет-мөфетләрегезне белмим лә! Миңа үзебезчә генә итеп әйт! Юкка башымны катырма.

К а р ы й *(көлеп)*. Килен бик батыр икән!

Н ә г ы й м ә. Батыр булмасаң монда, сезнең белән ишәрсең ишәк чумарын! *(Килүчеләрдән берсен күрсәтеп.)* Әнә

---

Х и җ а б – йөзне каплау, качу.

В а җ и б – тиешле.

Х ә л ә л җ е ф е т – никахлы хатын яки ир.

тегесе узган елгы бирәчәген дә түләми әле. Алтыга аласы калган ие...

Барысы да башларын бөгәләр.

Мулла. Алай булса, син мәхзүмгә хатынлыкка барырга риза?

Нәгыймә. Риза ла инде. Нәрсә җөдәтәсез инде, бая шулай дип әйттек ич инде.

Мулла. Мәхзүм, син дә ризамы?

Мөрит. Риза.

Җуан бай. Җә, хәзрәт, укы инде, укы. Җә тагын әллә ниләр лыкылдый башлар. Күп сөйләтеп торуда мәгънә булмас.

Мулла. Мәһәре[15] күпме?

Мөрит. Мәһәре мисел, хәзрәт.

Мулла. Кызым, шулаймы?

Нәгыймә. Нәрсәгә миннән сорап торасыз, шулайдыр инде. Сезнең жен телегезне чурт белсенмени! Кешедән артык алмабыз әле.

Мулла. Алай булса, укыйбыз инде. Әлхәмделиллаһ! Әлхәмделиллаһилләзи...

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ[16]

### ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Пәрдә ачылыр алдыннан пәрдәгә түбәндәгечә язу төшә:

Дәҗҗал[17] мәлгунь чыгу белән Румга баргай,
Мәһди[18] чыкты дәюбән Дәҗҗалга хәбәр булгай,
Сиксән мең җөһүд пәри җәмгъ булгай.
Андин артык тәкый гаҗәб дыңнарый бар[19].

Ерактан музыка тавышы ишетелә. Пәрдә ачылу белән, һәртөрле хәл һәм кыяфәттәге төрле нәсел мөселманнар, христианнар, гомумән, дин тотучы халыклар, хатыннарын, яшь балачагаларын ияртеп, берсен-берсе куып, кагыла-сугыла, шау-шулар кубарып, тузаннар туздырып, һәммәсе дә бер якка таба агылалар.

Чалмалылар (*зарланган тавыш белән*). Йа Аллаһ! Йа Аллаһ! Рәхмәтеңнән ташлама! Ахырзаман! Кыямәт! Дөньяга фитнә тулды! Дине Мөхәммәдкә игътибар калмадый! Мәчетләр клуб булды...

Кәшиш. Чиркәүләр музей булды, монастырьлар мәктәп булды.

---

Мисел – «риза булырлык, ошарлык» мәгънәсендә.
Рум – Византия.
Җөһүд пәри җәмгъ булгай – сугыш пәриләре җыелыр.
Кәшиш – христиан рухание.

Р а в в и н. Синагогларны алдылар, раввиннар кара җәяү калдылар.

М у л л а. Мәчетләр бушады, ташлап чыккан байгыш оясына охшады. Итагатьле мөселманнар дөньядан югалды, муллаларның куллары буш калды, һиммәтле мөселманнар, байларның байлыгын хөкүмәт җыеп алды, безгә ышанучы, безгә сәдака бирүче бары җыен җарлы-җабага калды. Хөкүмәт мулла-мәзиннәргә налог салды, зур пулатлы, зәкят, гошерле байлар кара җәяү калды. Никях юк, балага исем куштыру юк, бар эшне загес дигәннәре үз кулына алды. Ураза юк, ифтар[20] юк, фитра[21] юк, корбан[22] юк, зәкят юк, фидия юк! Болардан башка безгә дөнья юк. Болар барысы да әшраты сәгать, кыямәт галәмәтләре!

А к с а к а л  к а р т. Бу афәтләрнең барысы да безнең үзебездән, китәрбез дөньяны ташлап тиздән. Бу эшләргә булырмы түзгән, мин дә инде күптән өметне өзгән, ташлап китәм дөньясын тиздән, калмамын көздән. Олыларга ихтирам юк, картларга игътибар юк. Хатын-кызда хиҗаб юк, муллаларында оят юк, муллалары указларын ташлады, мәзиннәре сука сукалый башлады. Ишаннары хатын-кыз, асраулары артыннан чаба башлады. Күп галимнәр залим булды, күп суфилар шайтан булды, дөнья большевиклар белән тулды.

И ш а н. Алла, дидем, Алла, дидем, Алла дигән саен бер яңа кием кидем. Башымны аска идем, никадәр халыкның газиз хакларына тидем. Төрле ялганнар белән халыкның башларын исерттем, дару диеп әфиюн, мәгъҗүннәр эчерттем, зикер, тәсбигъ дигән булып, таза миләрен череттем. Корсак өчен төрле хәйләләр кордым, бөтен аңгыраларны үземә таба бордым. Әллә никадәр тозаклар кордым, ләкин булмады, нәфсем һаман да туймады. Булмады, ач күзем һаман да туймады. Туяр да иде, ләкин большевиклар юл куймады. Без хәзер инде бетәбез, үзебезгә ияргәннәр белән бергә ерак илләргә китәбез.

Халык төркеме агыла башлый, Ишан да шул тулкынга иярә.

Р а д и о я ң г ы р а т к ы ч. Әй, сез, пәйгамбәр өммәтләре, кая качасыз! Качып кая барасыз? Бара торган юллары-

---

Р а в в и н – яһүдиләр рухание.
С и н а г о г (*синагога*) – яһүдиләрнең гыйбадәтханәсе.
И т а г а т ь л е – буйсынучан.
Һ и м м ә т л е – тырыш, энергияле.
М ә г ъ җ ү н – наркотик әйбер.
З и к е р – искә алу, зикер әйтү.
Т ә с б и г ъ – җидегә җиткерү.
П ә й г а м б ә р  ө м м ә т л ә р е – пәйгамбәргә ияручеләр.

гызның алды караңгы, астыгызда төпсез упкыннар! Башларыгызны наданлык томаннары каплаган! Тирә-якларыгызга күз төшереп, бер әйләнеп карагыз! Дөньяданиләр барлыгын күрегез! Анда бөтен халык дөньясын яхшы, якты, рәхәт, тыныч тормышка алып чыга торган, юл күрсәткеч, якты кызыл йолдыз ялтырый. Ул йолдызның мәһабәтлеге алдында бөтен кара йөзлеләрнең тез буыннары калтырый! Халык өчен анда – наданлыктан котылу юллары! Анда рәхәт, анда бәхет, анда тигезлек белән тормыш юллары ялтырый!

Х а л ы к (*күмәк хор белән*). Йа Рабби! Йа Рабби! Кәрамәт! Могҗиза! Бу нинди мәһабәт тавыш? Безгә күктән, һатифтән тавыш килә. Ул тавышлар безгә өметләр бирә.

М у л л а. И мөэминнәр, мөселманнар, зинһар, ул тавышларга алданмагыз! Аларның барысы да шайтан тавышлары. Иблис[23] мәлгунь тавышы!

И ш а н. Йа Рабби Ходаем, әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ! Тәүбә, тәүбә! И мөэмин-мөселманнар, алданмагыз, һичберегез дә сәләфләр юлыннан аерылмагыз, ул тавышларга колак салмагыз, безнең юл – байлар юлы, Алла юлы, хак юл икәнне аңлагыз! Ул тавыш – азгын тавыш, әшратый сәгать! Ул – әшратый сәгать тавышы! Ул тавыш – Дәҗҗал мәлгунь тавышы! Дәҗҗал мәлгунь безне туры юлдан яздырырга, динебездән аерырга, сәләфләр юлыннан читкә тайдырырга тырыша. Барыгыз да, һәммәгез дә бары тик голәмалар, әүлиялар, пәйгамбәрләр сүзләренә генә колак салыгыз. Мөэмин-мөселманнар, аңлагыз: аларның сүзләренә колак салмагыз; ишетегез, мөселманнар, кыямәт җитте. Малларның, байлыкларның кирәкләре бетте. Тәүбә капкалары[24] ябылмас борын, мал-мөлкәтләрегезне Ходай юлына сарыф кылып калыгыз, үзегезне тәмуг утларыннан йолып алыгыз! Тәүбә-истигъфар итегез, күңел сабакларыгызны яңартыгыз!

М у л л а. Ишеттегезме, җәмәгать, ишан хәзрәтнең сүзләрен? Аның сүзләре барысы да Алланың аять[25], пәйгамбәрнең хәдис сүзләре. Күрәсезме, күккә терәлгән бит аның күзләре. Тизрәк тәүбә-истигъфар итегез, салаватларыгызны әйтегез, нәзер-ниязларыгыз[26], сәдакаларыгыз булса, тизрәк биреп калыгыз!

К а р т л а р. Йа Аллаһ! Йа Рабби! Йа Рабби! Рәхмәтеңнән

---

К ә р а м ә т – могҗиза.
Һ а т и ф – күктән, гаибтән килгән аваз.
С ә л ә ф л ә р  ю л ы – борынгы изгеләр, пәйгамбәрләр юлы.
И с т и г ъ ф а р – гафу итүне сорау.
С а л а в а т – мактулы догалар.

ташлама! Изге җаннар, ишаннар, әүлияларыбызның догалары бәрәкәтендә безне ташлама! Тәмуг утыннан азат ит! Биргән сәдакаларыбызны кабул ит!

Сәдака бирәләр.

Мулла (*сәдакаларны ала-ала*). Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр!

Ишан. Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр! Лә илаһә иллаллаһе валлаһе әкбәр! Валлаһе әкбәр вә лиллаһил хәмде!* Биргән сәдакаларыгыз кабул булсын, гөнаһларыгызны юсын, үзегезне тәмуг утларыннан йолсын. Бу сәдакаларны бирүчеләр оҗмахта хур кызлары куйнында кунсын!

Радиоянгыраткыч. Иптәшләр, гражданнар, тыңлагыз! Иске тормыш калдыгы – муллалар, ишаннар, үзләре һичбер төрле эш эшләмичә генә, кеше көченнән файдаланып, баеп ятучы халыклар, бер төркем надан динчеләрне үзләренең ялганнарына ышандырып, артларына ияртеп, үзләренең уйдашлары булган буржуйлар, кулаклар, алпавытлар, җуан корсаклы байлар белән бергәләп, безнең рәхәтлек, тигезлек дөньясын ташлап, илебездән китәр өчен надан халыкларны ияртеп, качып киткәнлекләре хакында хәбәрләр алынды. Шул сәбәптән, болар хакында нинди кискен чаралар күрергә тиеш икәнлеге турысында җыелыш ясалып, карар чыгарылды. (*Пауза.*) Китүчеләр арасында үзләренең аңсызлыкларыннан гына муллалар, ишаннар, мөритләр, байларга ияреп киткән ярлылар булса, ул бичаралар аларның тырнакларына эләгеп хәрап булмасыннар өчен, ярлыларның һәммәсен дә коткарырга!

Ишан. Җәмәгать! Мөселманнар! Ишеттегезме шайтаннарның әгъвасын? Зинһар, җәмәгать, ышанмагыз ул тавышка! Ул тавыш ул – Дәҗҗал мәлгунь тавышы. Дәҗҗал! Дәҗҗал тавышы! Беләсезме, без барыбыз да бергә хәрап булабыз бит!

Халык. Дәҗҗал?! Дәҗҗал?!

Ишан. Әйе, әйе, Дәҗҗал! Дәҗҗалның да нинди генә! Һәммәгез дә тәүбә-истигъфарга! Дәҗҗал мәлгунь чыгып җиткәнче, Коръән күтәрелгәнче, тәүбә капугълары бикләнгәнче, барыгыз да тәүбә-истигъфарга! Зинһар, дип әйтәм, мөселманнар, Дәҗҗал мәлгуньгә, Иблис-шайтаннарга иярә күрмәгез, тәүбә-истигъфарларыгызны кылып, кардәш-ыру, хатын-кыз, бала-чагаларыгыз белән бәхилләшеп калыгыз!

---

* Алла бөек, Алла бөек! Бер Алладан башка Алла юк! Аллабызга хөрмәт, дан!

Әгъва (*игъва*) – аздыру, котырту.

Музыка тавышы ишетелә.
Музыка революция көйләреннән берәресен уйный.

Ишетәсезме, мөэмин-мөселманнар, бу шайтан уеннарын? Кем дә кем шул шайтаннарга иярсә, кыяматтә мүгезле булып, хайван сурәтенә әверелеп кубарылыр дигән китапта. Бу – Дәҗҗал мәлгунь музыкасы! Ул, Дәҗҗал мәлгунь, бу музыкалары белән без мөэмин-мөселманнарны алдарга килә. Зинһар, дип әйтәм, алданмагыз! Әйдәгез, мөселманнар, һәммәгез дә догага! Гафил булмагыз, җәмәгать, һәммәгез дә динсезләргә каршы мөкаддәс сугышка! Мөкаддәс җиһадка! Хәзерге көндә җиһад һәрбер мөэмин вә мөселманга фарыз!

Муллалар.
Байлар.
Алпавытлар.
Зыялылар.
} Әйе, әйе, җиһадка! Динсез, дәһриләргә, Дәҗҗалга каршы җиһадка!

Халык (*кумәк*). Бездә юк мылтык, бездә юк туплар, бездә юк танки, бездә юк газлар, бездә аз саннар, без ничек җиһад кылыйк?!

Муллалар. Бездә бар Алла!

Ишан. Бездә бар иман!

Мөритләр. Бездә бар дога!

Мулла. Коръәндә әйткән, йөз сабырлы кеше – ике йөзгә, мең сабырлы кеше ике меңгә каршы тора алыр, дигән.

Ишан. Курыкмагыз, мөселманнар, сез белмисезмени бездә хәер-дога һәм бәддогалар барлыгын? Без хәер-дога белән дә, бәддога белән дә аларны җиңәрбез. Безнең бәддогалар аларны тотар. Әйдәгез, барыгыз да тезләнегез, әйдәгез, һәммәгез дә догага! Мин дога кылам, сез һәммәгез дә «амин» дип торыгыз.

Мулла. Ие, ие, җәмәгать, ишан хәзрәт дөрес әйтә, һәммәгез дә догага!

Халык тезләнә.

Ишан хәзрәт дога кылсын, без «амин» дип торыйк. Амин! Амин!

Ишан. Аллаһеммә онсор мән насараддин!*

Халык. Амин!

Ишан. Аллаһеммә онсор мән насараддин! Аллаһеммә

---

Җиһад – изге сугыш.
Фарыз – үтәлүе тиешле булган бурыч.
Дәһри – алласыз.
Хәер-дога – яхшы теләк, яхшылык теләү догасы.
Бәддога – каргыш, явызлык теләү догасы.
* Сезнең Аллагызның дине барысын да җиңүчән!

онсор мән насараддин! Вәхзел мән хәзәләддин!* Вәхзел мән хәзәләддин! Амин! Амин!

Халык. Амин! Амин!

Радиоянгыраткыч. Сезгә актык мәртәбә әйтелә: алдакчы муллалар, караңгылыкта калдыручы ишаннар, аларга ияргән сорыкорт, әрәмтамак мөритләрнең сүзләренә ышанмагыз, үзегезнең туганнарыгыз, кардәшләрегез, иптәшләрегез сафына кайтыгыз! Ул алдакчыларның көннәре санаулы! Бара торган юллары аяулы! Алар актык көннәрен күрәләр, алар үзләренә үзләре кое казыйлар, алар үз аякларына үзләре балта чабалар, алар тиздән бетәләр, бетәләр, бетәләр, аларга иярмәгез!

Ишан.<br>Муллалар.<br>Мөритләр. } Җәмәгать, барысы да шайтан мәлгунь тавышлары! Барысы да Дәҗҗал мәлгунь тавышы! Мөэмин-мөселманнар, зинһар, алданмагыз! Аларга бирешмәгез!

**Кинәттән шалтыраган, каты дөбердәгән, шартлаган тавышлар ишетелә, сәхнә караңгылана, картина алмаша. Сәхнә яктырганда, иске, ямьсез, төрмәгә охшаган, подвал сыман бер нәрсәнең эче күренә. Яндырып куелган берничә шәм яктысында Ишан, Мулла, Мәзин, мөритләр, поплар, алпавытлар, дворяннар, берничә инженер, генераллар, офицерлар, адвокатлар, буржуйлар, кулаклар һәм шуларга охшашлыларның, искелек тарафдары интеллигентларның яшерен җыелышлары күренә.**

## ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

Милләтче инженер. Җәмәгать, безнең бу яшерен җыелышны җыюдан максудыбызның нәрсә икәнлеге сезнең һәркайсыгызга да мәгълүмдер. Соңгы заманнарда дөньяның барышлары бөтенләй хәзергенең киресенчә иде. Элекке заманнарда мондый сасы подвалларда безнең упший дошманнарыбыз булган суциалислар, каммунислар, тагы шуларга охшаган халыклар гына яталар ие. Хәзер бу көндә бу сасы падвалга без үз иркебез белән җыелдык. Юк исә башка җиргә җыелырга безгә мөмкинлек калмады. Мәҗлесебезне мондый урында ясау безнең өчен бик үк күңелле булмаса да, шуңарга күнмәү мөмкин түгел, чөнки башка урында безгә иркенләп сөйләшеп, фикер алышырга мөмкин булмаячак. Хәзер безгә эшкә башлау өчен бу җыелышка бер придсидәтел сайларга кирәк.

Ишан. Юк, алай ярамый, эшкә башламас борын ук безгә кяфир мәлгуньнәргә охшарга ярамый, безгә андый

* Таратыгыз бу динне!

тәһарәтсез кешеләр кирәкми. Безгә өммәти Мөхәммәд, мөэмин-мөселман кеше садри мәҗлес булсын.

М у л л а л а р. } Мө р и т л ә р. } Ие, ие, ишан хәзрәт дөрес әйтә, безгә андый кеше кирәк түгел, безгә мөэмин-мөселман кирәк.

М у л л а (*мәзингә әйләнеп*). Шәп әйттемме?

И н ж е н е р*. Хәзрәтләр, сез алай эшкә башламас борын ук, алай эшне таратырга тормагыз, безнең бу урынга нинди авырлык, нинди читенлекләр белән генә җыела алганыбыз үзегезгә мәгълүм. Әгәр дә без эшебез башланмас борын ук таралырга торсак, аннан соң ни булыр?

М у л л а л а р. } Мө р и т л ә р. } Ни булса да булсын, безгә кара йөрәкләр кирәкми.

И н ж е н е р. Ярар, йәмагәт, сез әйткәнчә дә булсын, соң кемне сайлыйбыз?

М у л л а л а р. } Мө р и т л ә р. } Ишан хәзрәтне, ишан хәзрәт!

И н ж е н е р. Ярый, сез дигәнчә булсын. Хәзрәт, сез ризамы?

И ш а н. Риза, риза, мин мөэмин-мөселманнарның һәркайсыннан да риза. Аллаһы тәбарәкә вә тәгалә** хәзрәтләре сезнең дә һәркайсыгыздан риза булсын. Бәндәгез һәрвакытта догада. (*Догага кул күтәрә башлый.*)

И н ж е н е р. Мин сезгә бу киңәш мәҗлесенә придсидәтел булып, сабранианың тәртипләрен карап алып барырга ризамы, дим.

И ш а н. Кайсы субраниәне әйтәсез, теге Өфедәге духавный субраниәнеме? Ул бит инде күптән бетте. Җәлил, мөртәт муллалар аның башына җитте.

И н ж е н е р. Юк, хәзрәт, мин шушы сабранианы, шушы җыелышны тәртипләп алып барырга, дим.

И ш а н. Ә, алай икән, җә, ярар, алай җәмәгать үтенгәч, сүзләрен тыңлап, мәшәкъкать булса да, ияртеп алып барырбыз шул инде. Аны соң еракка алып барырга туры килерме? Әллә, булмаса, мин карт кеше монда гына калып торыйммы, үзегез генә барып кайта алмыйсызмы соң? Дөньялар да бик бозык вакыт, мин шушында гына калып торыйм.

И н ж е н е р (*кәефсезләнеп*). Фу! Наконец, это... прямо-таки... хәзрәт, без сиңа бер җиргә дә барырга әйтмибез, менә шушында гына придсидәтел булып утырып торырга гына дибез.

---

* Авторда: милләтче.

** Ризалык бирүче бөек Алла.

С а д р и  м ә җ л е с – җыелыш рәисе, председатель.

М ө р т ә т – динен ташлаган, башка дингә күчкән.

И ш а н. Ә, ярый, утырып торырга гына булса була, бераз ял итеп тә алырмын, әгәр дә шунда берәр йомшаграк урын булса, бераз ятып истирахәт кылып алсам, тагы да яхшырак булыр. Әгәр дә мин вә нәгаһ йоклап китсәм, зинһар, мине үзегездән калдырып, ташлап китә күрмәгез. Кяфир бәдбәхетләрдән качып бара торгач, бөтенләй сөяксанакларым да ватылып беткән. Сез эшегездә булыгыз, мин ял итеп алыйм инде. (*Ята, ятуы белән йокыга китә.*)

И н ж е н е р. Йәмагәт! Булай бу эш булмады инде. Безгә бит куркынычлар якынайганнан-якыная бара, безгә тизрәк эшкә тотынырга кирәк, вакытның каждый минуты ничаклы кимәт торганын үзегез беләсез. Каммунислар безне монда озакка кадәр тыныч тотмаслар, җә, тизрәк булыгыз, икенче придсидәтел сайлагыз!

Һ ә м м ә с е. Ярый, ярый, әйдә үзегез генә булыгыз да куегыз!

И н ж е н е р. Шулаймы? Алай булса, вакытны уздырырга ярамый, мин сабранианы ачык дип игълан итәм! (*Звонок шалтырата.*)

И ш а н (*йокы арасыннан*). Бар, остабикә, чыгып карасыннар, ашка алмага килгәннәр бугай, көттермәгез!

И н ж е н е р. Канично, сезнең барыгызга да билгеле, безнең пративникларыбызда силы бик күп, җыен ярлы-ябага, җыен брадәгеләр алар ягына җыелган. Вуйска да алар ягында. Вуйска...

Г е н е р а л (*сикереп торып*). Анда нинди вуйска?! Аларда никакуй регуләрный вуйска юк! Миндә, минем кул астымда бер дивизия генә регуләрный вуйска булса, мин белер идем аларны нишләтергә!

И н ж е н е р. Бөтен вапрус та шул шунда. Регуләрние түгел, талпа да безнең якта юк. Безнең арттан ияргән халыкларның үзләренә өләшенгән кораллардан файдаланырга да кулларыннан килми.

Г е н е р а л. Өйрәтергә кирәк суккин сыйннарны, өйрәтергә!

А д в о к а т. Аларны, каммунислар үз якларына караткан шикелле, агитацияләр белән үз ягыбызга каратырга кирәк. Бездә бит алардагыга караганда әллә ничә өлеш матур итеп язучы әдипләр, шагыйрьләр, мөхәррирләр бар.

П о э т (*йокыдан уянгандай сикереп торып*). Була ул, язабыз, нинди темыда язарга кушсагыз, һәммәсен дә бул-

---

И с т и р а х ә т к ы л у – ял итү.

В ә – «шунда» мәгънәсендә.

Н ә г а һ (*нагяһ*) – көтелмәгәндә, вакытсыз.

дырырбыз! Кемнәрне мактарга, нинди прирудыларны тасвир итәргә кушсагыз, һәммәсен дә булдырабыз, бары тик илһам китерү өчен бераз фин-шампан гына төшереп аласы иде. Эх, әрәм калды бит шампанскиләр тулган подваллар! Кем белә, бәлки, берәр вакытта бу подвалда да минә дигән шампанскиләр чымырдап яткандыр, ә хәзер аларның монда каберләре генә калган, сөякләренең дә көлләрен күккә очырып бетергәннәр! Бервакытны без...

И н ж е н е р. Туктагыз! Шагыйрь! (*Шалтырата.*) Безнең монда сезнең андый хиалларыгызны тыңлап торырга вакытыбыз юк. Хәзерге карала торган мәсьәлә турында нәрсә әйтәсең?

Ш а г ы й р ь. Ни әйтим, берни дә әйтә алмыйм, язарга дисез бит, кушыгыз, мин язам. Бары тик бераз гына илһам кирәк, илһам! (*Бугазына чиертеп.*) Менә шул юк, шул юкка илһам да юк. (*Бугазын кашып.*) Бу да юк. (*Маңгаена төртеп.*) Шуңар күрә һәм бу да юк. (*Читкә барып, башын бер якка салып, таянып утыра.*)

И н ж е н е р. Ягез, әфәнделәр, тизрәк булыгыз, кем, кайсыгыз эшлеклерәк бер фикер әйтә?

М у л л а. Без әйтәсе сүзләребезне бик күп әйттек, тәмуг белән куркыттык, оҗмах белән җумаладык, вәгазьләр белән алдадык, җәннәт нигъмәтләре белән кызыктырдык, булмады.

И ш а н (*йокыда*). Ни дисең, мулла? Нигъмәтләр әзер дисеңме?

И н ж е н е р. Аны күп ишеттек. Сез нинди булса да берәр төрле эшлеклерәк фикер әйтегез, эшлеклерәк!

П о п. Без башка нәрсә әйтә алыйк? Безнең дә, муллаларның да, башка дин руханиларының да – һәммәсенең дә халыкны куркытып, баш идереп, куркытып торган коралыбыз шул дин генә. Без ике мең елга якын, бу муллалар мең ярым елга якын, ә раввиннар, рәһбаннар, шаманнар, буддалар аннан да артык еллардан бирле һаман да шул дин белән, һаман да шул ахирәт, кыямәт белән, ут белән куркытып, баш идереп саклап килгәннәр, хәзердә дә безнең кулдан шуннан артык нәрсә килми.

М у л л а л а р.<br>М ө р и т л ә р. } Ахирәт! Кыямәт, Дәҗҗал, Иблис, шайтан, яәҗүҗ-мәәҗүҗ![27]

И н ж е н е р. Тагын кем нәрсә әйтә?

А д в о к а т. Эш шулай булса, әгәр дә надан халыкта әле хәзердә дә халыкның күңеленнән шундый дингә ышану чыгып беткән булмаса, нигә безгә аларның шул надан-

Ф и н - ш а м п а н – шәрабның бер төре (исеме).
Р ә һ б а н – монах.

лыкларыннан файдаланмаска, нигә безгә үзебезнең белемнәребездән файдаланмаска?

Инженер. Анысын мин дә аңлыйм, ләкин ничек итеп файдаланырга икәнлегенең юлларын гына төшенеп җитә алмыйм.

Адвокат. Монда бер дә төшенмәслек нәрсә юк. Халык Алла бар дип ышана икән, алар күзенә Алланы гәүдәләндереп ясап күрсәтергә, кыяматкә ышана икән, кыяматне аларга тудырырга, моның өчен байлар – малларының бер өлешен, адвакатлар, руханилар – телләрен, сезнең шикелле инженерлар – белемнәрен, генераллар – җаннарын, аннан калган безгә ияргәннәр* башларын кызганмаска кирәк.

Инженер. Әфәнделәр, сез бу фикергә ни дисез?

Барысы да. Шәп, шәп фикер!

Буржуй. Шәплеккә шәп тә, ләкин сез бу камбинацияләр ничә працинт файда бирер дип уйлыйсыз?

Интеллигент. Син күп шаулама инде, синең белән без бергә булганда, булды гына диген, капиталың йөз працинтын ияртеп үзеңә кайтыр.

Буржуй. Алай булганда, капитал миннән.

Мулла. Хәер-дога миннән.

Мөритләр. Булышлык бездән.

Интеллигент. Мин дә тырышырмын.

Генерал. План төзү миннән.

Офицерлар. Башкару бездән!

Инженер. Бөтен хәйлә коралларын уйлап чыгару миннән! Әйдәгез алга!

Башкалар. Чү! Чү! Чү!

Буржуй. Андый кызыл сүзне авызыңнан җил алсын!

Мулла.<br>
Поп. } Амин!<br>
Мөритләр.

Генерал. Направо! Марш!

Чыгалар.

Ишан (*йокысыннан уяныр-уянмас*). Амин! Сәдакалар кайда? Ашлар кайда? (*Уяныл, кармаланып.*) Бу кай җир?

Тышта шартлаган тавыш.

Ла хәүлә... Әллә чыннан да кыямәт... Аһ, беттем!..

Пәрдә.

---

* «Акларга ияргәннәр» дигән мәгънәдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КАРТИНА

Зур бер гараж. Урталыкта биек урын әзерләнгән, аның өстенә урындыклар куйган. Урындыкларга руханилар, ишаннар, муллалар, мөритләр, карт генераллар, офицерлар, аксөяк интеллигентлар һәм башка шуңар охшашлы контрлар утырганнар. Сәхнәнең икенче бер почмагында, хайван дисәң, хайван түгел, машина дисәң, машина түгел, әллә нинди бер «гигант чудовище» басып тора. Зур күзләре уттай янып тора. Пәрдә ачылганда, трибунада Интеллигент.

Интеллигент. Шулай итеп, мөхтәрәм әфәнделәр, безнең күптәннән бирле килгән зур мичталарыбыздан берсе бүгенге көндә дөньяга килде яхуд килер алдында тора. Моңарчыга кадәр булып узган бик күп яшерен мәҗлесләрдә милләтебезнең зурларының, икенче төрле итеп әйткәндә, саннарыбыз аз булган булса да, «Бөек милләт мәҗлесебезнең» зур карарларының иң зур икесе безнең тарафыбыздан җиренә җиткерелде. Безнең гыйлем һәм фәннәребезнең зур җимеше булган бу зур әсәрләребезнең җимешләрен якын киләчәктә күрәчәгебезгә без иман китерәбез!

Һәммәсе. Афәрин! Тәхсин! Бәрәкалла!

Интеллигент. Бу хакта, ягъни кәрамәт, могҗиза аппараты булган бу харикыльгадә аппарат, машина хакында сүз сөйләргә карт, тәҗрибәле, галим инженерыбыз – милли инженер Шаһбазгәрәетдин бәк әфәндегә сүз бирелә.

Һәммәсе. Рәхмәт, рәхмәт! Яшәсен Шаһбазгәрәетдин әфәнде!

Инженер (*трибунага чыгып*). Менә инде, йәмагәт, без – абразованный, интеллигент, то есть укымышлы халыклар, сез, кажетсе, андыйларга алимнәр, дисез, илем кеше, дисез; вот менә инде без, сез әйткәнчә инде, илем кешеләр, үзебезнең тайный сабраниаларыбыз, то-есть, сез әйткәнчә, милләт мәҗлесенең пастанавлиниесе буенча, банә сез күрә торган шул гигант свирх машиныны уйлап чыгардык. Безгә әйттеләр, сез шундый бер машины уйлап чыгарыгыз, ул машины үзе бик таза да булсын, көчле дә булсын. В добавок үзе бер чудовище, Коранда әйтелгән, да-да-да, аты ничек иде әле шуның?..

Муллалар. Даббәтел арыз[28]...

---

Яхуд – яки.
Тәхсин – мактап яхшы дип әйтү.
Харикыльгадә – гадәттән тыш.

И н ж е н е р. Ва, ва, ва, шул, даплатыйл арыз, шундый бер сында да булсын, диделәр. Вот менә без, инжинирләр, думали, думали, наконец, вот шушы чудовищены, муллаларча әйткәндә, даплатный арызны уйлап чыгардык. Бу – без, инжинирләр, уйлап чыгарган чудовище, самый последни словы тихники. Безнең сез кушкан буенча уйлап чыгарган коралыбыз шушы. Мондый хитрый арудиәне сам дьявол үзе дә уйлап чыгара алмас. Точь-в-точь, муллалар әйткән даплатный арыз.

М у л л а. Дөрес, дөрес, нәкъ Коръәндә әйткән даббәтел арыз.

И н ж е н е р. Полужым, мин, мижда пручим, мин үзем динне бик яхшы итеп, как слидует белмим; мин Коранны укымаган, ул ягын как слидует халыкка сөйләп бирү сез хәзрәтләр өстенә төшә. Без, инженерлар, түлке наукы әм тихнике ягын гына карыйбыз. Ну вот, менә бу даплател арыз үзе, төбендә бу көнгә кадәр бик күп миравай вайналарда упатриблэт итеп киленгән танкилар систимендә падвижнуй крипыс фурмасында эшләнгән булса да, моның икенче бер маральний яктан приимуществасы бар: бу чудовище ризина шикелле гипки, ә шуның белән бергә иң крипки матириалдан эшләнгән, ә үзе йөргәндә как бер гигант слон, татарча әйткәндә, как фил шикелле йөри. Вот, испыйтания вахтында үзегез дә күрерсез, ул, үзенең эчендә грамадный каличествада взрыйвчатый әйберләр булуга да карамастан, бик зур скурыс белән йөри, одним словым, Коран әйткән даплатный арызтан ким түгел. Безгә хазер инде бер Мәһди белән аның кулына тота торган, уттан булган зур бер кылыч кына кирәк, ә ул кылыч та бередә хәзер. Вот ул кылыч биредә. (*Зур бер кылыч күрсәтә.)*

Кылыч бер ялкынлана, бер сүнә.

М у л л а л а р. Сөбханалла, кәрамәт!

И н ж е н е р. Менә күрдегез, без үзебезнең теләкләргә якынлаша барабыз. Буларны булдырганны, башкаларын бик тиз булдырырбыз. Мәһди булырга кеше табылыр.

И н т е л л и г е н т. Ә соң Дәҗҗал?

М ө р и т. Ә соң Дәҗҗални каян алырбыз?

И н ж е н е р. Кайгырмагыз, бары да булыр, бары тик акча гына булсын да, халык безгә генә ышансын. Вот хәзер инде яңадан килик даплатыл арызка. Безнең өчен иң важный булганы шунысы. Чөнки безгә иң важный булганы бөтен мөселманнарны, бөтен динле халыкларны үз ягыбызга аударырга, аларны үзебезгә иярһергә кирәк. Ансыз безнең эшләр барып чыкмый.

И н т е л л и г е н т. Миңа бер генә сүз әйтергә рөхсәт итегез, бик важный бер мәсьәлә: мин сезгә ул турыда белдерергә соңга кала яздым, безнең булачак, яңа оештырылачак Туран[29] илләреннән бик яхшы хәбәрләр алдым. Әле бөтенләй яхшылап карап чыга алмадым, шулай да безнең анда җибәрелгән илчеләребезнең яхшы эш күргәнлекләре аңлашыла, мин...

И н ж е н е р. Ярый, бик шатлыклы хәбәр, ул турыда аерым сөйләшербез. Инде килик без үзебезнең даплатыл арызка. Ул менә сезнең каршыгызда. Безнең башка коралларыбыз рәткә салынып барган шикелле, ул да рәтләнде. Бөтен дөньяның пралитариат ривалюциясен җимереп ташлау өчен безгә шундый корал җитә. Бөтен дөнья сациализмын җимерү өчен безгә шушы гигантның мин аңар «дин» дип исем биргән бер кнупкесен басу җитә. Шул кнупкене басу белән ул гигант машины хәрәкәткә килә.

Һ ә м м ә с е. Ничек итеп?

И н ж е н е р. Учен прусты. Муллалар миңа әйткәннәр ие, безнең ислам диненең дүрт тармагы бар, алар дүртесе дә бергә килеп тоташалар, дигәннәр ие. Минем бу гигантның да шундый дүрт тармагы булган дүрт аягы бар. Ул дүрт аяк бер цинтрга, менә шушы кнупкегә килеп тоташалар. Аның аяклары бик зур хасиятле: нәкъ диннең дүрт тармагы шикелле, теләсәң кайсы якка сыгылалар һәм кнупкене басу белән хәрәкәткә киләләр. Шуның өчен дә мин ул кнупкене «дин» дип атыйм. Бу гигантның бөтен сикрите дә шул дүрт аягы белән йөрүендә. Шул гигантны хутка салып җибәрү белән, бөтен гигант кузгала. Әле хәзергә бөтенләй сынап җиткергәнебез юк, шулай да булса, бу гигантның бөтен гәүдәсе утта янмый, суга батмый, туп, бумбы, снәрәтләр алмый торган састафлардан эшләнгән булганлыктан, бөтен халыкларның аңар иман китерәчәгенә мин бик яхшы ышанам. Сациализм дигән дошманыбызны бетерү өчен, безгә аның бары шулкадәресе генә кирәк тә. Аннан калган бөтен эшләрне безнең бик көчле булган, һәртөрле яшерен серле машиналарыбыз эшләячәкләр. Җәгез, әйдә, һәммәгез дә гигантның эченә! Хәзер тәҗрибә башлана, хәзер тәҗрибә башлана, җәгез, әйдә, һәммәгез дә керегез эченә! Мин хәзер «дин» кнупкесен басам! Без шушы гигантның гигант адымнары белән барып, шушы дин кнупкесен басып, бөтен дөнья сациализмын күккә очырырбыз!

Б а р ы с ы  д а. Афәрин! Тәхсин! Браво!

И ш а н. Җәгез, мөэмин-мөселманнар, бер фатиха! Аллаһеммә онсор мән насараддин!

Б а р ы с ы  д а. Амин! (*Барысы да «гигант» эченә керәләр.*)

И н ж е н е р. Җәгез, яхшы карагыз, мин «дин» кнупкесен басам! Бер! Ике! Өч!

Машина кузгала башлый, бик каты шартлау, караңгылык. Стеналар җимерелгән тавышлар.

Р а д и о  я ң г ы р а т к ы ч. «Дин» кнопкасы басылды, динчеләрнең бөтен дөнья социализмына каршы корылган «гигантлары» шартлады!

## БИШЕНЧЕ КАРТИНА

Интернационал уйный, артта пәрдә ачыла, артта – ялтыраган якты кызыл йолдыз, бөтен тирә-якта – индустрия төзелеше, уртада төрле милләт пролетариатының кардәшлеге картинасы күренә. Аяк астында бөтен дин халыклары ята.

П ә р д ә.

# МОГҖИЗА

*Бер пәрдәдә*

УЕНГА КАТНАШУЧЫЛАР:

Нәфисә – 60 яшендә, тол карчык.
Рокыя – улының кызы. Комсомолка, 20дә.
Мәгъри – күрше карчыгы, 50дә.
Мәрьям – күрше хатыны, 35–40 яшендә.
Терехин – авыл милиционеры, 30–40 яшендә.

Вакыйга авылда. Киемнәр авылча, бары милиционер гына формада.

Авыл өенең эче. Стена буенда стенага беркетеп эшләгән эскәмияләр, түрдә сәке. Сәке алдында өстәл. Өстәл янында тәрәзәләр. Стена буендагы ян сәке янында тәрәзәләр. Сул яктагы арт кулиста ишек. Стенада шәмаилләр[1]. Арттагы сул якта мич. Мич янында савытлар тезелгән шүрлек. Уң як стенада тәрәзә.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә күтәрелгәндә, Нәфисә җеп җерләп утыра.

Нәфисә (*ачуланып, җеп җерләвен ташлап*). Барысы да дин тотмаганлыктан, Аллаһы тәбарәкә вә тәгалә хәзрәтләренең ачуына грифтар булдылар. Менә шуңар күрә дә барысының да асты өскә килде! Ул рәхимле Алланы бер дә белми, бер дә күрми дип белә торганнардыр. Ул барысын да белә, барысын да күрә! Алланың мәчет астын шайтан арбасы, әллә нинди җен машинасы абзары ясаганны кем күргән дә кем ишеткән. Гараҗиа дип йөргән булалар. Әстәгъфирулла тәүбә! Ярабби Ходаем, үзең кичер. Әстәгъфирулла, тфү, тфү! Гараҗиа! Кара җәяү калганыгызны сизми дә калырсыз әле! Картайган көнемә чаклы гомер итеп, гомеремдә дә андый сүз ишеткәнем юк иде. Трахтыр! Трактирлар борынгы заманда калада да, базарлы авылларда гына буладыр иде. Кайдан чыгардылар?! (*Пауза.*) Каян чыксын? Бөтен шул каһәрләр барысы да шул халхоздан чыкты. Халхоз булганчы бар кеше дә Алладан куркып, мулла, мәзин, хәзрәтләрдән оялып торалар иде. Изгеләр

---

Грифтар булу – дучар булу.
Гараҗиа – «гараж» сүзен бозып әйтү.

бәддогасы тотар әле үзләрен! Әнә анда әле, калада, зур бер мәчетне шайтан бала очыра торган клубка әйләндергәннәр икән дә, шуннан мәчеттә һәр көнне төннәр буена изге газизләрнең җаннары әрнеп-әрнеп, ачыргаланып-ачыргаланып җылый башлаганнар, ди. Элекке заманнарда һәркем олыны олы, кечене кече дип беләләр иде, олылар алдында әдәп саклап йөриләр иде. Ә хәзер? Хәзер нәрсә? «Син, убырлы карчык, нәрсә беләсең соң? Анда синең ни эшең бар? Сиңа мәчет нәрсәгә? Хатыннар барыбер мәчеткә йөрмиләр, анда, мәчет астында, безнең трахтырлар, орлык ашлыклары торудан сиңа ни зарар?» – диләр. Хатыннар йөрмәсә, мулла-мунтагайлар, мәзин-абызагайлар, карт-корылар башларына чалмалар киеп мәчеткә йөриләр иде, карарга ук ямьле иде.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Р о к ы я керә.

Р о к ы я (*кулындагы мандолинасын ян сәкегә куеп, чишенеп утырып, мандолинасын кулына алып, үзалдына*). Баштарак мин, музыка түгәрәгенә йөри башлаган вакытларда, бер дә өйрәнә алырмын дип уйламаган идем, йөри торгач, төшендем тагы. Тиздән 8 Март – хатыннар бәйрәме җитә. Аңарчыга кадәр Уразага каршы, аннан Корбанга каршы кичәдә, аннан 8 Март көнендә уйнарсың, диделәр. Уразага каршы кичәдә җырлыйсы җырларымны өйрәнеп җиткердем шикелле инде, репетициядә бик ярattылар. Шулай да тагы бер кат җырлап карыйм әле. (*Уйнап җырлый.*)

Ураза, Корбан бәйрәмендә
Агайлар бал куялар;
Аракы, сыра, балларны
Чиләк-чиләк коялар.
Мунчалар да ягалар,
Пешерәләр коймаклар;
Кунакларга йөрешәләр
Җыен кәкре сыйраклар.
Җигеп чаба туры атлар
Җыен динче дураклар.
Тыгыналар, сыйланалар
Кода-кодагый, картлар!

Н ә ф и с ә. Тфү! Ходай орган нәрсәләр! Телегезгә тилчә төшкән нәрсәләр! Телләрегез коргыры! Үзебезгә генә тел тиерүегез җитмәгән иде, инде динебезгә дә тел тиерә башладыгызмыни? Каһәр төшкән нәрсәләр! Бигрәк артык

узындыгыз инде. Атаң мәрхүм, исән булса, күрсәтер иде сиңа «дураклар»ыңны!

Р о к ы я. Бик исебез китеп торыр иде ди инде, чуртым куркып торыр иде ди алардан! Исәннәре әле дә бик күп бит, нигә бер дә куркыта алмыйлар?

Н ә ф и с ә. Куркытырлар әле, боерган булса, куркытырлар. Ходайдан вәгъдә җитсә, шундый итеп куркытырлар, тыныгызны да чыгара алмассыз!

Р о к ы я. Куркып тора ди чуртым алардан. Моңарчы да бик күп куркыттыгыз инде Алладан.

Н ә ф и с ә. Булыр әле, көне җитәр, кыямәт көнендә сез күрмичә, без күрмәбез. Күрер көннәрегез алда әле.

Р о к ы я. Менә молодис, монсын дөрес әйттең! Безнең алда рәхәт күрәчәк көннәребез бар әле.

Н ә ф и с ә. Масаймагыз, күрерсез, Алла боерса, күрерсез!

Р о к ы я. Күрсәк күрербез инде. Ярар, мишәйт итмәгез әле. Төкерәбез без аларга. (*Җырлый.*)

Эчәрләр дә тилерерләр,
Сугышырлар исереп;
Кодасы да кодагые –
Бар да булыр исерек.

Тиздән бетәр, туганнар,
Уразалар, корбаннар;
Китәр баштан томаннар,
Ачы бал, «үзе куганнар».

Бәйрәмнәре, ләвәшләре,
Күркә, каз бәлешләре –
Тыгынучы «абыстай»ларның
Аз калды инде ишләре.

Н ә ф и с ә. Тукта, дим, нәгъләт яуган бала, имансыз! Уразалы авызым белән әллә ниләр әйттереп, мине дә гөнаһыга батырасың!

Ярабби Хак, үзең сакла!
Гасый бәндәләрә катма!
Җәһәннәм утына атма!
Әйя хәннан, вәйя мәннан!

Нигә дип шундый көфер җырлар җырлыйсың?

Р о к ы я. Нигә җырламаска? Әнә үзең дә җырлыйсың ич!

---

Л ә в ә ш – катлама, гөбәдия.

Г а с ы й б ә н д ә л ә р ә к а т м а – гөнаһлы кешеләргә санама.

Ә й я х ә н н а н, в ә й я м ә н н а н – и игелекле, юмарт Алла!

Н э ф и с э. Әстәгъфирулла диген! Изгеләрдән калган робагыйларны җыр дигән өчен җир йотар!

Р о к ы я. Мин майлы калҗа түгел, тамагына торыр. (*Җырлый.*)

Уразасы, сәхәре,
Бәйрәме дә кирәкми.
Кирәк булса, без табабыз
Үзебезгә кирәкне.

Н э ф и с э. Бик кирәк булыр иде дә, әле ансы сезгә эләкми.

Р о к ы я (*җырлый*).

Бәйрәмгә дигән акчага
Без алырбыз китаплар.
Китап укып күзне ачсак,
Безне һәркем дә мактар!

Н э ф и с э (*урыныннан сикереп торып*). Туктыйсыңмы син, юкмы? Менә ачармын мин күзеңне, табагач белән башыңа берне алып бәрсәм! Ярабби Ходаем, бу нинди бәла бу?! Үз өеңдә үзеңә газиз рамазан шәриф айларында тәсбихләр тартып, зекерләр әйтеп утырырга да тынычлык юк!

Р о к ы я (*көлеп*). Мин сине тынычсызларлык итеп начар җырламыйм бит, ышанмасаң, әнә безнең укытучы Зәйнәп ападан сора. Ул миңа: «Син бик яхшы җырлыйсың»,– ди.

Н э ф и с э. Сорармын ди, сорамый ни, шул динсез марҗагыздан сорап торырмын ди! Сорау түгел, балаларның газиз башларын әйләндереп бетергән өчен, мин аның күзләрен чукып чыгарыр идем әле. Син әнә яхшы кыз булсаң, андый марҗаларыгызның сүзләрен тыңлаганчы, ак сакаллы карт – Сәйфетдин абзагыздан сора: сезнең халхозларыгыз турысында ул синә ни дияр икән.

Р о к ы я. Сәйфи кулактанмы? Бик хәҗәте бар!

Н э ф и с э. Бер дә кулак түгел. Авылыбызда менә дигән, беренче, акыллы, яхшы кеше ул. Авылыбызда ничә еллар двор тотты. Узган-барган, менә дигән зур, атаклы кешеләрнең берсе дә аңар төшмиче, анда кунак булмыйчы китмиләр иде.

Р о к ы я. Аңарга төшкән кунак үзе дә булган кулак.

Н э ф и с э. Сәйфетдин абзагыз әйтә: «Бу, – ди, – халхоз дигән нәрсәләр, – ди, – барысы да шайтан мәлгунь уйлап чыгарган нәрсәләр, – ди. – Ул трахтыр дигәнен дә шул шайтан уйлап чыгарган», – ди.

Р о к ы я. Ул шулай димиче ни дисен! Колхоз булгач,

---

Р о б а г ы й – дини бәет, мөнәҗәт.
З е к е р (*зикер*) – мактау догасы.

аларга көн бетте инде. Ярлы-ябагайларның берсе дә аңарга юк бәягә чәчәргә җирләрен бирмиләр. Машина, тракторлар булгач, атсыз кешеләрнең берсе дә өч-дүрт хакы белән ат сорарга аңар бармыйлар. Аннан берәү дә бурычка чәчәргә орлык ашлыгы сорамый. Аның шуңар ачуы килә, ә сез аны аңламыйсыз, һаман да аның көенә биисез.

Н ә ф и с ә (*ачу белән*). Тик тор ичмасам, җүләр! Алла сезнең акылыгызны ук алып бетергән икән инде. Оятсыз, динсезләр! Менә мин җүләр әйткән иде диярсең: ахры бер көн, кайчан булса да бер көн, бу сүзләреңнең кийәлеген күрерсең! Телегез корыр, явызлар, телегез корыр! Ходай Тәгалә ул барысын да белә, барысын да күрә. Бигрәк акыллы булып киттегез, картлардан да уздырып җибәрмәкче буласыз. Ярабби Ходаем, газиз рамазан шәрифтә тоткан уразаларым хөрмәтенә һәртөрле начарлыклардан үзең сакла!

Р о к ы я. Җә, җитәр инде, барыбер тынычлап җырлап булмый. Өйрәнермен әле. Кояш баер вакыт та җитеп килә. (*Мандолинасын элә.*) Иптәш кызлар янына барып килергә кирәк.

Н ә ф и с ә. И Ходаем! Сезнең шикелле динсезләр белән күп сөйләшеп утырсаң, гөнаһлы буласың, билгеле. Икендем[2] дә укылмаган, авыз ачарга самавырым да куелмаган.

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Т е р е х и н керә.

Т е р е х и н. Исәнме, әби! Исәнмесез, Рокыя! Вот, сиңа, әби, авыл советыннан повестка. (*Өстәлгә куя.*)

Н ә ф и с ә (*шикләнеп*). Аларга тагы нәрсә кирәк икән?

Т е р е х и н. Анда баргач үзен белерсен, мин сорамаган. (*Сул яктагы тәрәзәгә бара да тәрәзәдән карый.*)

Н ә ф и с ә. Ярабем, газиз рамазан шәриф хөрмәтенә үзең сакла.

Т е р е х и н (*үзалдына сөйләгән шикелле, уйга калып*). Бу нинди кирәмәт? Гараж бикле, ә югары катта, мечеть эчендә яктылык бар шикелле. Карарга кирәк.

Н ә ф и с ә. Йа Алла, бәгъщрем, нәрсә, нәрсә, нәрсә дидең? (*Тәрәзәгә йөгереп килә.*) Кайда, нинди кирәмәт?!

Т е р е х и н. Ә, юк, берни дә юк икән. Мечеть тирәсенә байый торган кояш яктысы гына төшкән булырга кирәк. Йә, мин киттем, вахтым юк. (*Чыга.*)

---

К и й ә л е г е н к ү р ү – бәласен күрү.

К и р ә м ә т (*кирамәт*) – могҗиза.

Н э ф и с э (*тәрәзәдән карый, эченнән эгузе бисмиллалар әйтеп мыгырдый*). Ярабби Ходаем! Чыннан да нур! Җәннәт нурлары! Бикле мәчет эчендә җәннәт нурлары! Газиз акшам[3] вакытында, бикле мәчет эчендә җәннәт нурлары! Әүлиялар йөри торганнардыр, җаннарым! Әүлияларның җаннары авыз ачарга килгәннәрдер! Бары да кыямәт галәмәте. Ярабби Ходаем, үзең кичер безне!

Р о к ы я. Әби, син нәрсә сөйлисең? Анда нинди нур булсын? Берни дә юк бит.

Н э ф и с э. Тик тор, азгын халхоз! Терехин динсез, урыс, кафир, мәлгунь, ул булып ул да нур барлыгын үз күзе белән күрде. Ни дигәнен ишеткәнсеңдер бит? «Мәчет бикле була торып, бу якты каян килә икән», – диде.

Р о к ы я. Ул бит яктылык кына, диде, нур димәде. Күзенә ни булса да берәр нәрсә күренгән шикелле булгандыр.

Н э ф и с э. Тик тор ичмасам, азгын! Сез Алланың үзен күрсәгез дә ышанмассыз! (*Авыз эченнән укына.*) Үз күзләрем белән күрдем бит инде, ялык-ялык яна! Әллә, Ходаем, бүген Кадер кичәсе[4] булды микән? Фәрештәләр күктән иңде микән? Коръәндә: «Кадер кичәсе уразада булыр, күк капуглары ачылыр, күктән фәрештәләр иңәр, таң атканчы мөселманнарга сәлам биреп йөрерләр», – дигән. Күк капугсы ачылган вакытта син дә тәүбәңне кылып, догаларыңны укып кал. Кем белә, бәлки, сиңа да Алла инсаф бирер, мөселманлыкка кайтып, иман белән дөньядан үтәрсең. (*Авыз эченнән укына.*) Җаным, бәгърем, әнкәем, тәрәзәгә күзем төшкәч тә эсселе-суыклы булып киттем, аркаларымнан тирләр чыкты. Әллә нинди тәсбих әйткән тавышлар ишеткән шикелле булдым. Йа газиз Аллам! Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла!

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М э г ъ р и керә.

М э г ъ р и. Уф, ардым. Көне буе йөреп, билләрем калмады. Авыз ачарга коймак изгән идем, мичем өлгермәде. Табамны мичкә тыгыйм дигәндә генә, табагачымның тимере төште. Табагачыңны гына биреп торсана, бушагач та кертермен.

Н э ф и с э. Ал, ал, газиз күршем, ал. Үлеп-нитеп китсәм, догаларыңнан ташлама! Монда күземә таба агачлары күренми әле. Ярабби Ходаем, ниләр генә булыр да, ниләр генә күрербез?

М э г ъ р и. Нәрсә бар, әллә берәр хәл булдымы? Төсләрең дә киткән, әллә авырыйсыңмы? (*Өстәл янына утыра.*)

Р о к ы я. Башың авырып киткәндер, барыйм әле, бәлки, мин дә могҗизаларны күрермен. (*Чыга.*)

М ә г ъ р и. Нәрсә булды соң, туганым? Ул нинди могҗиза турысында сөйли?

Н ә ф и с ә (*сер итеп*). Могҗиза, туганым, чыннан да могҗиза! Үз күзем белән күрдем, күк капугсы ачылганны күрдем.

М ә г ъ р и (*якынрак килеп, шыпыртрак тавыш белән*). Могҗиза? Күк капусы дисеңме? Кайда? Кайчан?

Н ә ф и с ә (*шыпыртлап кына*). Менә әле генә, теге кафир Терехин милиционерны беләсең бит, шул кергән иде. Шул тәрәзәгә карады да бөтенләй агарып китте, тораташ булып катты. «Могҗиза», – ди. «Чыннан да могҗиза», – ди. «Мәчет йозак белән бикләнгән, ә эченнән якты нур күренә», – ди. Шуннан, мин сиңа әйтим, сикереп торып, тәрәзәдән барып карасам, ни күзем белән күрим: мәчетнең эче нур белән тулган. Колагыма фәрештәләр тәсбих әйткән авазлар ишетелә, бөтен өй эченә хуш исләр аңкыды.

М ә г ъ р и. Ярабби Ходаем, изге рамазан шәриф айларында тоткан уразаларымны кабул ит, гөнаһларымны кичер. Хәерлегә түгел бу, туганым, хәерлегә булмас! Заманалар бозылды, мәчетләрне мыскыл иттеләр. Әйтәм аны, бүген сәхәр ашап яткач, миңа да гаҗәп бер төш күренде: мин шулай ямь-яшел котырынып үскән арыш басуы арасыннан мижа буйлап барам икән дим, барсам, кинәттән генә әллә нинди гаҗәп бер эт хап итте дә каршыма сикереп килде дә чыкты. Үзе болай бер дә эткә охшамый: койрыгы бөтенләй бозау койрыгы шикелле, ә башына кош канаты шикелле канатлар үскән – әнә теге коймак майлый торган канатлар шикелле. Шуннан шул эт минем өстемә сикереп килде дә, мәсихле читегемнең өстен ялады да, җир астына төшеп киткән шикелле булып, күздән югалды.

Н ә ф и с ә. Булыр, булыр, туганым, мин дә шуны әйтәм әле, үзеңә мәгълүм бит инде, теге каһәр яуган нәрсәләр мәчетне алып, теге тәмуг машинасы абзары ясап, мәчетне бикләп мыскыл иттеләр бит. Шуның өчен, мин әйтәм, изге урын буш ятмасын дип, Аллаһы Тәгалә, мин әйтәм, газиз Кадер кичләрендә, бүген, мөгаен, Кадер кичедер, мәчеттә намаз укырга күктән фәрештәләрне иңдергәндер, дим.

М ә г ъ р и. Шулайдыр, шулайдыр, туганым, бер дә башкача булмас! Һи Раббем, һи Раббем, ахырзаман алдына күрә шулайдыр, туганым, ахырзаман алдына күрә.

Н ә ф и с ә. Кара әле, туганым, син бераз гына утырып тор, мин хәзрәткә генә кереп чыгыйм, аннан сорашыйм, бу эшләр ахырзаман галәмәтләре түгел микән?! Булмаса, кайткач та табагачны табып бирермен.

М ә г ъ р и. Бар, бар, туганым, бар, уен эш түгел бит ул, нигә утырмаска, утырам, утырам. Әгәр дә ахырзаман булса, табагачлар белән әллә ни эшли алмассың.

Н ә ф и с ә. Утыр, утыр, туганым, мин хәзер. (*Шәлен бөркәнә-бөркәнә чыга.*)

М ә г ъ р и (*үзалдына*). Менә күрдегезме, бу калхозчылар калхозлары белән эшне кайда китереп җиткерделәр! (*Эченнән догалар укый.*)

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М ә р ь я м керә.

М ә р ь я м. Исәнме, Мәгъри абыстай? Бу Нәфисә абыстай, ут кабынган шикелле ашыгып, эндәшми-тынмый кая китте?

М ә г ъ р и (*пышылдап*). Чү, акрын, монда бик зур хәлләр булды әле!

М ә р ь я м (*пышылдап*). Нәрсә, әллә кемне булса да берәр кешене суйганнармы?

М ә г ъ р и. Могҗизалар бар әле монда, могҗизалар! Трахтыр ачкан мәчеттә могҗизалар!

М ә р ь я м (*тәрәзәдән күрсәтеп*). Мондамы?

М ә г ъ р и. Ие, шунда. Нәфисә үзе күргән, үз күзе белән күргән, күк капугсы ачылган, күктән җиргә нурлар яуган. Җәбраил галәйһиссәлам[5] фәрештәләр белән ак пыракларга[6] атланып мәчеткә иңгәннәр, мәчетнең мыскыл ителүе өчен кайгырып бик җылаганнар.

М ә р ь я м. Ярабби Ходаем, җиде газизләр[7] хөрмәтенә...

М ә г ъ р и. Җәбраил пәйгамбәрнең бер канатында бер фәрештә, икенче канатында икенче фәрештә, ди, канатын җәйгән, ди. Әнә теге «Сөбател-гаҗизин»[8] китабында әйткән бит әле, шуның нәкъ үзе, ди, канатлары бөтен җир йөзен каплаган, ди.

М ә р ь я м. Ишеткәнем бар иде, анда ничек дигән соң әле, «балык диңгез өстендә, диңгез җир өстендә, җир үгез мүгезендә, үгез балык мыегында» дигән бугай.

М ә г ъ р и. Ул башка да, бу башка. Монда Җәбраил пәйгамбәр нәкъ үзе. Җәбраил пәйгамбәр канатын җәйсә, бөтен җир йөзен каплап алыр, дигән. Әгәр дә ул канатын бер тибрәтеп җибәрсә, барлык савитларың әллә кайларга очар.

М ә р ь я м. Бик зур эш бу, Мәгъри абыстай, бу бер дә тикмәгә түгел. Никадәр динсез кеше бит әле, теге Терехин дә үз күзе белән күргән; күргән дә бер сүз дә эндәшә алмаган, багана шикелле тораташ булган да каткан. Әле булса да һаман сын шикелле катып тора, ди. (*Авыз эченнән догалар мыгырдый.*)

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Н ә ф и с ә ашыгып йөгереп керә.

Н ә ф и с ә. Һи, туганнарым, һи, алтыннарым!

М ә г ъ р и. Җә, нәрсә ди, хәзрәт нәрсә ди?

Н ә ф и с ә. Барысын да хәзрәткә сөйләдем. Хәзрәт тыңлап торды да: «Бу бик зур эш бу,– ди,– мәчеткә кертмәсләр инде кертүен, шулай да булса, кайда булса да акрын гына мәчет картлары белән җыелып намаз укырга, дога кылырга, Коръән укып, нәфел корбаннар чалырга[9], сәдака-хәерләр бирергә кирәк булыр», – ди.

М ә г ъ р и. Шулай, шулай, изгеләр зияраты өстенә барып корбаннар да чалырга кирәк. Барлык авыл картларын, бөтен карчык-корыларны җыеп алып барырга кирәк.

Н ә ф и с ә. И Ходаем, Сәйфетдин абзыйга әйтеп чыгарга оныткан икәнмен! Теге трахтырларга баш булып тора торган Гарәфинең бөтенләй теле корган, ди, һичбер нәрсә дә сөйли алмый, ди, телдән калган, ди.

М ә г ъ р и (*кычкырып җибәрә*). Актык көннәребез җитте! Башыбызга бәлаләр яуды! Алла каршында без гөнаһлы бәндәләр! Безгә үлем якын килде!

Н ә ф и с ә. Ах, үлем, үлем! Йөгерим әле, Сәйфетдин абзыйга хәбәр итим!

Кызулап чыгып барганда, Р о к ы я г ә очрый.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Р о к ы я. Болай кайда ашыгып чыгып барасың, кичке ашны ашарга вакыт, өстәлне әзерләргә кирәк.

Нәфисә ачу белән карап, эндәшми генә чыгып китә.

М ә р ь я м. Ашау кайгысы юк әле биредә. Беребез дә авыз ачмаган. Ниләр булганын күрәсең ич.

Р о к ы я. Ниләр булган?

М ә г ъ р и. Эндәшмә ичмасам, тик тор, калхозчы! Сезнең аркагызда халык монда җәфалар чигә. Сезнең гөнаһ шомлыгыгыздан Алла безне дә җәзалый. Сез трахтыр китереп куйгач та, Алла сезнең пычрак трахтырларыгызга чыдап торыр дип белдегезмени?

Р о к ы я. Нишләп пычрак булсын ул? Бик шәп итеп тазарткан, юган. Күзге шикелле ялт итеп тора.

М ә г ъ р и. Нишләп пычрак булмасын, берсендә-берсендә егермешәр көч утыра, ди ич.

Р о к ы я. Нинди көч?

М ә г ъ р и. Нинди көч булсын, билгеле инде, шайтан көче, явыз көч. Борып җибәргәч тә, пыр-пыр-пыр килеп, барлык пычрак көчләрен пырхылдатып ыргыта башлый.

Шуңарга күрә дә ул атсыз-нисез дулый да. Сәйфетдин абзый үзе әйтте. Шайтан булмыйчы ни булсын тагы, атсыз сука сукалаганны кемнең күргәне бар?

Р о к ы я (*шаркылдап көлеп*). Мәгъри астай, ул бит шайтан көче түгел, ат көче.

М ә г ъ р и (*мыскыл белән көлеп*). Синеңчә шул егерме ат трахтыр эченә кереп утырган димени?

Р о к ы я. Һи, синең белән сүз әрәм итеп сөйләшеп торуы да не стует. Картлар бөтенләй акылларын да югалтып бетергәннәр.

М ә р ь я м. Бәладән башаяк! (*Кулын селтәп.*) Син, Рокыя, бераз җүнләбрәк сөйләш. Алла аяз көнне өегезгә яшен суктырмасын.

Р о к ы я. Бер дә сукмас, хафаланма!

М ә р ь я м. Тыңлап торырга да куркыныч. Узган ел берәү шулай синең шикелле сөйләгән дә шундук аяксыз-кулсыз булган, паралич суккан.

М ә г ъ р и. Сугар һәм сугар да! (*Тәрәзәгә барып карый да кинәттән идәнгә егыла.*) Ай, ай, ай! Ярабби, изгеләр хөрмәтенә... (*Идәндә тәгәри.*) Раббем, Ходаем, Хуҗа Баһаветдин[10]!

Р о к ы я (*Мәрьям белән икәүләп аның өстенә атылып*). Нәрсә, ни бар, сиңа ни булды?

М ә р ь я м. Яраббем Ходаем! Мәгъри абыстай, җаным, ни булды?

### СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Н ә ф и с ә керә.

Н ә ф и с ә (*аптырап карап тора*). Әткәем, җиде газизләрем, ни бар, нәрсә булды?

М ә г ъ р и (*идәндә тәгәрәвендә дәвам итеп*). Һай, газизләрем, ай Аллам! Без гөнаһлыларны кичер!

Мәрьям һәм Рокыя Мәгъри тирәсендә чуалалар.
Мәрьям аңар чүмеч белән су китерә.

Н ә ф и с ә. } Сиңа ни булды?
М ә р ь я м. } Нәрсә бар?
Р о к ы я. } Бу ни бу?

М ә г ъ р и (*калтыранып суны эчә һәм идәнгә утыра*). Һай, җаннарым, бәгырькәйләрем! Миңа да могҗиза күрергә насыйп булды! Үз күзем белән, үз күзем белән! Һай, бераз гына хәл җыйыйм әле. Уф!

Н ә ф и с ә. } Ярабби Ходаем, нәрсә булды?
Р о к ы я. } Нәрсә юк сүз сөйли?
М ә р ь я м. } Ух, эчләрем авыртып китте. Балам гына төшмәсә ярар иде.

Мәгъри. Җаннарым, бәгырьләрем, тәрәзәгә каравым гына булды, каттым да калдым! Карыйм, карасам: трахтыр мәчете алдында уттан бер багана тора. Ялкыннары күккә чыккан.

Нәфисә (*куркып*). Нәрсә? Уттан багана дисеңме?

Мәгъри. Уттан, туганнарым, уттан! Ярабби Ходаем, кичер. Без гөнаһлыларны яндырып бетермәсә генә ярар иде. Ходайны ачуландырганбыздыр шул, Ходайны!

Рокыя. Һаман саен акылдан шаша баралар. (*Тәрәзәгә йөгереп бара.*) Нәрсә бар соң анда? (*Шаркылдап көлә.*) Шулай икәне билгеле, шулай булмыйчы ни булсын. Син бераз күзләреңне ачыбрак кара, Мәгъри абыстай. Тракторчылар койма артына ут якканнар, ә ул синең күәскә ут баганасы булып күренә.

Нәфисә. Син үзең лыгырдама! Юлдан язган нәрсә! Синең акылың җитә торган нәрсәмени ул!

Рокыя. Син үзең күзеңне яхшылабрак ачып кара.

Мәрьям (*тәрәзәдән карап*). Чынлап та ут якканнар икән шул. Уй! Бөтенләй котымны алдыгыз! Бераз хәл җыеп керим әле. (*Чыга.*)

Нәфисә. Дөньядагы кирәмәтләргә искитәрлек. Ул җүләрнең сүзенә ышанмагыз. Аның күңел күзе күрми. (*Сер итеп.*) Сез минем ниләр эшләгәнемне белмисез әле.

Мәгъри (*сикереп торып, Нәфисә янына утырып*). Нәрсә, нәрсә, ниләр булды?

Нәфисә. Сәет хатыны Мәрфуга әйтте, мәзин хатыны абыстай да шунда иде, ул да шулай ди...

Мәгъри. Абыстаймы? Җә, җә, ул нәрсә ди?

Нәфисә. Бик изге, бик борынгы бер язу тапканнар. (*Эченнән догалар мыгырдый.*)

Мәгъри (*эченнән догалар укып*). Изге язу диме? Нинди язулар ди? Кайдан тапканнар ди?

Нәфисә. Күзгә күренми торган серле язулар, ди, алтын белән язылган, ди.

Мәгъри. Алтын белән... Алтын хәрефләр белән дисеңме?

Рокыя. Әби, алай күзгә күренми торган булгач, аны ничек күргәннәр соң?

Нәфисә (*ачу белән*). Син тик кенә тор, динсез! Алла сезнең күкләргә аларны аңларлык акыл бирмәгән. (*Мәгърига.*) Шул язуда язылган, ди, безнең түбән оч чишмәсенең астында изгеләр зияраты бар, аның суы шул изгеләр күз яшеннән агып чыга дип әйтелгән, ди. Язулар иске булса да, өр-яңа, ди. Үзе иске булса да, бер дә чермәгән, ди.

Рокыя. Ничек инде ул алай, үзе чермәгән дә, үзе күренми дә?

Мәгъри. Син аңламаган башың белән тыгылма әле. Алар соң синең белән безнең күк гөнаһлы пычрак күзләргә күренәләрмени? Шунда яталар да яталар, ә үзләре күренмиләр. Әнә Әбүгалисина хәким дә үзе исән, үзе күренми бит! Хозыр галәйһиссәлам дә кеше күзенә күренми йөри бит әле. Мәңге суын эчкәнгә күрә үлми дә, кеше күзенә дә күренми. Күренгәндә дә ап-пак сакаллы дәрвиш, сәдакачы кыяфәтендә генә күренә. Сез пычагымны беләсезмени соң?

Нәфисә. Шулай шул, нишкә дип ул пычрак күзләргә күренеп үзен хур итсен!

Рокыя. Тфү! Бөтен карчыклар акылдан шашканнар!

Нәфисә. Менә кыямәт кенә җитсен, шаштырырлар әле үзегезне. Күзләрегез шар булыр.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Мәрьям керә.

Мәрьям. Һи! Белсәгез иде, бөтен авылның асты өскә килә!

Нәфисә.
Мәгъри. } Тагы ни булган?

Мәрьям. Бөтен авыл куркуларыннан кая барырга да белмиләр. Сафа абзыйның хатыны балалары белән базга төшеп бикләнгәннәр. Шәрип абзый хатыны, балалары белән печәнлеккә менеп, печән астына күмелгәннәр, ди. Мөкиләр белән Таһирлар өйләренә кереп бикләнгәннәр. Унлап йорт күрше авылларга таралганнар, җир йотмасын дип куркалар, ди. Кайберәүләр урманга китеп, салашларга качканнар.

Нәфисә. Ахырзаман җитте! Тәүбә капугълары ябылмас борын, гөнаһларымны кичер!

Мәгъри. Йа хуҗа Баһаветдин, мәдәт!

Тавыш (*тыштан*). Кара әле, Вәли, бар әле, колхоз абзарына барып Миңлебайларга әйт әле: мин аңар әйтергә оныткан, сары алашага эссе көенә солы бирә күрмәсен! Аннан бригадирларга йөреп әйтеп чык: хәзер үк канторга җыелсыннар, эш бар!

Нәфисә. Әстәгъфирулла тәүбә, тәүбә, тәүбә. Бу, ни, теге кем, Гарәфи тавышы түгелме соң? Теле корган, сөйләшә алмый дигәннәр иде бит?

Мәгъри. Шайтан алмаштыргандыр, туганым, шайтан! Аның урынына шайтан Гарәфи булып акыра торгандыр!

---

Мәдәт – ярдәм.

Р о к ы я. Нәрсә тилерәсез, Гарәфи абый үзе бит!

М ә г ъ р и. Өрәге килә, өрәге!

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Т е р е х и н керә.
Терехинны күргәч, Н ә ф и с ә акырып идәнгә йөзтүбән егыла. М ә г ъ р и өстәл астына керә. М ә р ь я м почмакка, эскәмиягә менә.

Н ә ф и с ә (*кат-кат*). Лә хәүлә вәла куәтә!

М ә г ъ р и. Әгузе билләһи минәш шәйтан ирраҗим!

М ә р ь я м. Каравыл! Хәрап булдым, беттем!

Барысы да бервакытта кычкыралар.

Р о к ы я (*барлык тавышы белән кычкырып көлә*). Уф! Чыдар хәлем калмады, эчләрем катып бетә инде!

Н ә ф и с ә.
М ә г ъ р и. } Бисмиллаһи! Тфү! Тфү! Тфү!
М ә р ь я м.

Т е р е х и н. Берни дә аннамыйм, өянәкләре килгәнме буларнын? Нишләгәннәр?

Р о к ы я (*һаман көлә-көлә*). Уф, хәлләрем бетте. Барысы да синнән булгач, син аларны ничек итеп аңларга?

Т е р е х и н. Миннән?

Р о к ы я. Билгеле, синнән! Син тәрәзәдән карадың да гаражда әллә нинди яктылык уйлап чыгардың. Ә карчыклар синең яктылыгыңнан әллә нинди нурлар, фәрештәләр уйлап чыгардылар. Сине, тораташ булып каткан, баганага әйләнгән, диделәр. Гарәфинең телләре корган, диделәр.

Т е р е х и н. Йә, йә, йә!

Р о к ы я. Тегендә ягылган утны ут баганасы дип белделәр. Ә хәзер инде ниндидер алтын белән язылган язу турында сөйлиләр.

Шул вакытта Нәфисә, Мәгъри, Мәрьям әллә нинди аңланмый торган сүзләр мыгырдыйлар.

Т е р е х и н. Ха-ха-ха! Аннадым, аннадым! Ягез әле, түтиләр, чыгыгыз әле, күрәсез вот, берни дә булмаган, исән-сау, багана да булмаган. Ә ул нурларыгыз, яктыларыгыз турында да кайгырмагыз!

Н ә ф и с ә. Ничек? Изге җәннәт нурымы?

М ә г ъ р и (*өстәл астыннан чыгып*). Әгузе билләһи... Син дә өрәк түгелме, җаным?

Ике карчык икесе дә Мәрьям янына сырышып Терехинга куркып карыйлар.

Т е р е х и н. Курыкмагыз, фәрештәгез дә хәзер милициядә утыра.

Мәгъри. Ничек, фәрештәне дә тоттыгызмыни? Йа Хуҗа Баһаветдин, мәдәт! Коточкыч эшләр!

Рокыя. Инде мин дә хәзер берни дә аңлый алмыйм.

Нәфисә (*артка чигенә-чигенә*). Өрәк, өрәк!

Мәрьям. Ярабби Ходаем, фәрештәләрне милиция тотып япканны кем күргән дә кем ишеткән!

Терехин. Кафаланмагыз, изге күз яшьләрегез дә, җәннәт нурларыгыз да минем кесәдә.

Мәгъри. Юк сүз, ышанмагыз, булмас! Нур кесәгә керәмени? Фәрештәләр үзләрен тоттырып торалармыни?

Терехин (*Рокыяга*). Барысы да көлке генә, башка берни дә юк! Мин тәрәзәдән яктылык күрдем дә, бу, мин әйтәм, нәрсә булырга кирәк, дим. Гараж бикле, мин әйтәм, ә тәрәзәдә ут бар, дим. Юк, мин әйтәм, бу бушка гына түгел, дим. Авыл советы председателен, анын янына ячәйкедән ике кеше алдым да кинәттән генә килдек тә бастык! Гаражга барып керсәк, ни күзебез белән күрик, анда сәндерәдә теге фәрештә утыра, ә аның янында – нур.

Нәфисә (*ботларына чабып*). Әнкәем, бәгырькәем, утыра диген, ә?

Терехин. Ә күз яшьләре тама да тама!

Нәфисә.<br>
Мәрьям. } Тама?<br>
Мәгъри.

Терехин (*кесәсеннән шәм кисәге чыгарып күрсәтеп*). Менә шул изге нурны кесәмә тыктым, ә фәрештә дигән мәзин хатынын самогон аппараты белән бергә – әле теге изгеләр күз яше тама торган апараты белән – милициягә озаттым.

Барысы да. Һай, эткәем! Ай-яй-яй!

Мәрьям. Ә мин, җүләр, шуңар ышанып йөрим.

Нәфисә. Ә теге күренми торган алтын язулар?

Рокыя. Ул соң мәзин хатыны анда кайдан барып кергән?

Терехин. Мәзин мәчетнең ачкычын биргән вакытта ян ишекнең ачкычын үзендә калдырган. Мәзин хатыны кич белән гаражда кеше булмаганын белгән дә шуннан файдаланып кергән.

Барысы да (*башларын селкеп*). Ай-яй-яй!

Терехин (*Нәфисәгә*). Ә теге алтын язу турысында әйтсән, ул турыда Сәйфетдин кулак белән сөйләшергә туры килер әле. Язудагы кул аныкы, ләкин ул подлец путаллы

---

Путаллы алтын кара – язулар өчен кулланыла торган алтын.

Шельма – алдакчы, мошенник.

алтын караны каян алган? Ул, шельма, трактор колоннасын таратырга теләгән булырга кирәк. Ә хәзер инде эләкте.

Барысы да ахылдыйлар, ухылдыйлар. Рокыя шаркылдап көлә. Нәфисә белән Мәгъри авызларын ачып, башларын селкеп утыралар.

Р о к ы я (*мандолинада уйнап җырлый*).

Безнең авыл алдаулары
Оста итеп эшләнгән;
Нишләп оста эшләнмәсен,
Мулла, мәзин эшләгән.
Халык керде колхозга,
Тракторлар китердек.
Мулла, мәзин, кулакларны
Себреп түгеп бетердек.

Н ә ф и с ә. Тик тор, оятсыз! Газиз рамазан ае, ә ул өйнең бәрәкәтен очырып җырлап утыра.

Р о к ы я (*аны тыңламыйча җырлый*).

Яңа тормыш китерә
Яңа төрле уйларны!
Бөтенләйгә себреп ташлый
Бай, кулак, буржуйларны!

М ә г ъ р и. Алладан курку юк, бәндәдән оялу юк. Тизрәк баш алып качарга гына! (*Кызулап чыга.*)

Р о к ы я (*җырлый*).

Җыярбыз киртәләрне,
Ташларбыз* сиртмәләрне.
Биреп баланы яслегә,
Эшләрбез иртәләрне.
Ялынмабыз башкага,
Без йөрербез ашка да.
Казан асу да кирәкми –
Йөрербез ашханәгә.

Нәфисә бертуктаусыз дога укып, башын селкеп утыра.

Т е р е х и н. Их, шәп! (*Бии башлый.*)

Мәрьям дә биергә тотына.

Р о к ы я (*җырлый*).

Кабыклардан козау ясап,
Бәрәңгеләр җыярмын.
Клубларда кино карап,
Кич концертта җырлармын.

П ә р д ә.

---

* Кулъязмада: җыярмын, ташлармын.
К о з а у – тубал, тырыска охшаган савыт.

## КҮЗСЕЗ МАСТЕРЛАР

*Сукырлар тормышыннан инсценировка*

Сәхнә – сукырлар тулай торагындагы мастерской.

КАТНАШУЧЫЛАР:

Гариф – щетка эшләүче.
Гайнетдин – матрац эшләүче.
Сабит – мех фабригында сортировкада эшләүче.
Әхмәди – гармунчы.
Галия, Сәкинә, Әхмәт – рабфакта укучы студентлар.

Уенга катнашучылар барысы да сукырлар.

Пәрдә ачылыр алдыннан сәхнәнең тышкы ягына уенны Алып баручы чыга.

Алып баручы. Исәнмесез, саумысыз, белгән һәм күргәннәр, олылар, кечеләр, картлар һәм яшьләр, һәм безнең белән тиңдәшләр! Фабрик-заводларда эшләүче ударниклар, шулай ук кеше тапканны гына ашарга көтеп ятучы ялкау бездарниклар! Без килдек сезнең каршыга кечкенә генә бер театр уены белән. Сукырлар тормышы белән таныштыру уе белән. Күзсезләр өчен күз урынына тора таяк. Ленин васыятьләре – безнең тормыш юлы буенча тезелгән маяк. Күзлеләр карамасыннар безгә аяп. Без эшлибез тормыш юлында сызганып. Телибез кеше күк яшәргә төрле фән, һөнәрләр өйрәнеп. Җитәр инде, патша заманында да чат башларында бик күп йөрдек сөйрәлеп. Эш эшлибез, тормыш төзибез, йөрмибез тик кенә сөйләнеп. Менә сез безнең тормышның да бер почмагын күрегез. (*Кереп китә.*)

Пәрдә ачыла.

Гариф (*эшләп бетергән бер пар щеткасын көйләп шакылдатып*). Менә, Гайнетдин, бу щеткаларны үзләрен күзле дип йөри торган халтурщик кустарларның борын асларына китереп төртеп күрсәтәсе иде, һәрбер тишегенә

ничә бөртек щетина, ничә бөртек кыл кергәнен белә алырлар идеме икән?

Гайнетдин. Берәмләп санап карасалар, белә алырлар. Шулай да син дә артыграк мактанып җибәрәсең. Безгәме соң күзлеләр белән тиңләшергә!

Гариф. Нигә тиңләшмәскә! Кулдан эш килгәч, мактанырсың да шул, күзле мастерларны ярышка чакырырга да ният бар әле.

Сабит. Безнең мех фабригында сортировкада эшләүче әллә никадәр күзлеләр бар. Шуларның күбесе безнең шикелле яхшы итеп сортларга аера белмиләр. Без сортларга аерган тиреләрнең өне өнгә, җоны җонга килә дә тора. Мастерлар без аерган нәрсәләрне бик яраталар, күзлеләр аерган нәрсәләрне дә кайвакытларда, бракка чыгарып, кире кайтаралар.

Гайнетдин. Менә мин матрацны капшап карау белән үк аны кем эшләгән икәнен беләм. Сукырлар эшләгән матрацлар мамык шикелле, ә күзлеләрнең ялкаулары эшләгән матрацлар Гариф эшләгән щеткалар шикелле тырпаеп торалар.

Гариф. Минем щетка шикелле түгел. Әндринең кырма сакалы шикелле диген, шадра! Минем белән тиңләштереп маташкан буласың тагы. Үзеңнең борчакка егылган шикелле шадра битләреңне бел.

Гайнетдин. Шадра, шадра, шадра йөрәк яндыра, ди. Дарым шадра булсын, шадра булса да, Гайнетдинеңне аны кызлар ярата, артыннан калмыйчы ияреп йөриләр, аны култыклап кына йөртәләр.

Сабит. Син дә мактанган буласың тагы шунда. Сиңа кем иярә соң! Әллә шул көйгән тире шикелле җыерчык битле Җәмиләң белән мактанган буласыңмы?

Гайнетдин. Һи, кабак баш! Син дә кеше булган булып сөйләп утырасың шунда, Җәмиләнең бите җыерчыклы икәнен кайдан белдең? Әллә аны капшап карадыңмы?

Сабит. Карадым шул. Беркөн коридорда үзе килеп бәрелде дә, минем Зөбәйдәмме икән дип, битен сыйпап караган идем, шунда белдем.

Гайнетдин. Миңа килгәндә ул тутырган тавык шикелле иде, бала тапканга күрә генә шулай йөнчелеп китте. Мин электә, Герман сугышына кадәр, типсәм тимер өзәрлек, кып-кызыл, нарат яркасы шикелле бер егет идем. Герман сугышында газ белән агуланып кына шулай сукыраеп, ябыгып калдым.

Сабит. Да! Ул патшаларның бүләкләре безгә бик кыйбатка төште!

Гайнетдин. Кыйбатка төшсә төште, аның каравы

безнең эшләр дә яхшы пеште. Революция аркасында патшалары, буржуйлары чәнчелеп китеп, җәһәннәменә дә барып төште. Совет хөкүмәте төзелмәгән булса, без әле һаман да күпер төпләрендә теләнеп утырган булыр идек. Хәзер бөтен дөньяда бары тик бездә генә сукырларны кешегә саныйлар. Капиталистлар илләрендә этләргә сан бар, ә сукырларга һичбер сан юк.

Сабит. Сукырларга! Сукырларга түгел, аларда күзле, таза эшчеләргә дә сан юк. Хәзер барлык капиталистлар илләрендә илле миллион кадәр эшчеләр эшсез калып ачыгалар, ә безнең Советлар илендә эшче көчләр җитми.

Гариф. Үз гомереңдә син дә бер дөрес сүз сөйли белерсең икән!

Гайнетдин. Кайсы илдә мондый нәрсә булганы бар?! Бездә барлык инвалидларны да, сукырларны да эшкә тарталар, һөнәрләре булмаганнарны төрле һөнәргә өйрәтәләр, укыталар.

Сабит. Дөрес әйтә Гайнетдин!

Гайнетдин. Икенче бишьеллык тулганда, Совет илен танымаслык та булыр әле. Ул вакытта сукырларны таный да алмассың. Әле хәзерге көндә дә Мәскәүдә магнит катушкалары чорнау эшендә безнең сукырлар иң беренче мастерлардан саналалар.

Гариф. Тиздән совет медицинасы аркасында сукырларны көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмаслык булыр әле.

Гайнетдин. Матрац тәмам булды. Их, йомшаклыгы да йомшаклыгы! Мамык түшәк шикелле. Әллә Җәмилә апагыз белән йокларга үземә алып каласы инде.

Гариф. Бик йомшак, җылы булгач, Җәмиләңнең мае эреп агар.

Гайнетдин. Бер дә акмас.

Тышта гармун тавышы.

Әһә! Минем эш бетүгә, Әхмәди дә килеп җитте, бик шәпләп әйттереп утырабыз икән.

Әхмәди керә.

Әхмәди. Исәнмесез, егетләрнең асыллары! Сәлам бирдем бит, нигә алмадыгыз?

Гариф. Кайчан?

Әхмәди. Нигә, гармунны кычкырттым бит, ишетмәдегезмени?

Гайнетдин. Әйдә, бик вакытлы килдең. Син килүгә, ударник Гайнетдин абзаң эшен дә бетереп куйды. Күңелләр боегып торадыр иде, бераз ачылып китәр.

Ә х м ә д и. Минем күзләр шикеллеме, хи-хи!

Г а р и ф. Ник, синең күзләр ачыкмыни?

Ә х м ә д и. Ачык булмый ни, ачык шул. Безнең шикелле профессор кешегә ачык күзле кеше диләр бит.

С а б и т. Нәрсә профессоры?

Г а р и ф. Нәрсә профессоры булсын, икмәк черту профессоры!

Ә х м ә д и. Бер дә түгел, чын-чын гармун профессоры. Абзаң бүген бирегә килгәнче шул гармуны белән бер червонсы эшләп алды әле ул. Ул кадәр акчаны бит аны профессорлар гына төшерә ала.

Г а й н е т д и н. Әйдә, бирегә, минем янга кил. Профессор кешегә урын бирмәү килешмәс. Червонсыны алгач, үзең кәефләнеп тә өлгергәнсең күренә...

Ә х м ә д и. Ансыз буламы соң!

Г а р и ф. Гармун уйнауларыгыз, җырларыгыз бик күңелле эш, тик шул агуны эчүегез белән генә эшне изәсез.

Г а й н е т д и н. Суфи суган сөймәс, күрсә кабыгын да куймас, ди. Үзеңнең ташлаганыңа күптәнме соң әле?

Г а р и ф. Шулай дип әйтерләр дигән идем аны! Гомереңдә бер генә тапкыр ялгышсаң да, хәзер йөзеңә бәрергә генә торалар.

Г а й н е т д и н. Җә, ярый, Әхмәди, ул ишанның сүзенә карама. Саулыгың барында сала бир.

Г а р и ф. Ташларга кирәк, дуслар, ташларга! Ансыз күңелле тормыш корып булмыймыни!

Г а й н е т д и н. Ярый, ташларбыз, ташларбыз, курыкма! Әйдә, Әхмәди, гармуныңны тартып җибәр.

Ә х м ә д и. Аннан эш калмас. Син үзең дә мәгънәсен әйтә бар.

Г а й н е т д и н. Була ул.

Әхмәди бер кат уйнап чыга, Гайнетдин җырлый.

Без, күзсезләр, килеп чыктык
Бүген сезнең каршыга.
Мин сиңа җыр җырлап бирәм,
Син кул чабып каршыла.

Өйрәнмәсәк без һөнәр,
Тавык-чебешләр көләр.
Дөньябызны төзәтмәсәк,
Калырбыз булып җүләр.

Г а л и я, С ә к и н ә, Ә х м ә т керер тыңлап торалар.

Йә, нихәл, шулай ярыймы! Чиерттерәме Гайнетдинегез борыныгызга!

Г а л и я.
С ә к и н ә. } Браво, браво! Молодец!
Ә х м ә т.

Ә х м ә т. Молодец, Гайнетдин абзый, бик шәп, искиткеч шәп!

Г а й н е т д и н. Шәп диген, ә! Шәп булмаска, Гайнетдин абзаң үзе чыгарган җыр ла ул.

Г а л и я. Шулаймыни? Син шулай шигырьләр дә чыгара беләсеңмени?

Г а й н е т д и н. Мин, сезнең шикелле шигырь-мигырьләр чыгара белмәсәм дә, бераз шулай бәетләр язгалый идем. Яшь чагында, сезнең шикелле кызларга хат язган чакларда, хатка бәетләрне үземнән язадыр идем. Соңыннан, күз күрми башлагач кына, тукталып калган идем, хәзерендә, татарлар өчен сукырлар әлифбасы чыгарылгач, тагы яза башладым.

С ә к и н ә. Молодец, Гайнетдин абзый, молодец! Йә, тагын җырлагыз әле, без дә ишетик.

Г а й н е т д и н. Ярар, җырларбыз. Нәрсә анда ишек төбендә басып торасыз, утырышыгыз!

Студентлар утыралар.

Туташлар сорагач, җырламый булмас инде, Әхмәди, уйнап җибәрәсең шул инде, җырламый ярамас. Тик бер шартым бар: мин җырлаганнан соң, сез дә җырларсыз. Мин кызлар җырлаганны бик яратам, яшь вакытлар искә төшә.

Г а л и я. Җырларбыз, җырларбыз, Сәкинәнең дә үзе чыгарган җырлары бар, ул да җырлап күрсәтер.

С ә к и н ә. Әй, минеке җыр түгел лә ул, әллә нинди әбиләр мөнәҗәте шикелле булып чыкты.

С а б и т. Зарар юк, башта шулай булса да, яза-яза матурлана бара ул.

Г а й н е т д и н. Җә, әйдә алайса, Әхмәди, уйнап җибәр, тик карагыз аны, соңыннан үзегез дә җырларлык булсагыз гына җырлыйм.

Г а л и я.
С ә к и н ә. } Җырлыйбыз, җырлыйбыз!

Г а й н е т д и н. Әйдә, Әхмәди, уйна алайса.

Ә х м ә д и. Була ул. (*Уйный.*)

Г а й н е т д и н (*җырлый*).

Эшлә, туган, һөнәр өйрән,
Язу танымый калма.
Надан калсаң, менә шунда
Читен булачак алда.

Әхмәт Гайнетдин янында шешә күреп, иснәп карый.

Ә х м ә т. Менә монысы бер дә ярамый инде, Гайнетдин абзый. (*Иснәп.*) Монда сезнең аракы исе килә.

Г а й н е т д и н. Юк, ул болай гына, аз гына, эшләп аргач бераз сөяк-санакны йомшатып җибәрер өчен генә.

Г а р и ф. Мин дә әйттем аларга, һаман ташламыйлар.

Ә х м ә т. Әхмәди абзый, ул эшең бер дә ярамый инде. Үзең картайган, бала-чагаларың да бар.

Ә х м ә д и. Дөрес әйтәсең, Әхмәт, сүзең дөрес, тик менә йөрәк яна. Иптәшләрнең барысы да эштә, рәхәтләнеп көн күрәләр, кулларыннан эш килә, барысы да укый-яза беләләр, һөнәрләре бар, ә минем нәрсә рәхәтем бар да, нәрсә куанычым бар? Элекке заманда, патшалар вакытында, безне укытмадылар. Безгә күпер төпләрендә сорашып утырудан башка эш калмады. Көн буена йөзеңне җыртып теләнеп утырасың да сагышыңнан эчәсең... Күрәсең, әле дә менә ташлап булмый...

Ә х м ә т. Ярамый, Әхмәди агай! Без бит барыбыз да синең шикелле үк күзсезләр, шулай булса да, без шат тормыш алып барабыз. Сиңа да бүгенге көн кешесе булырга кирәк.

Ә х м ә д и. Сез – яшьләр, сезнең эшләрегез алга бара, киләчәктә сезне бәхет көтә. Ә минеке нәрсә? Мин укый-яза белмим, иптәшләрнеке шикелле һөнәрем дә юк.

Ә х м ә т. Юк сүз сөйлисең, Әхмәди абзый. Син чыннап торып безнең арага кил. Без сиңа яраклы эш табарбыз. Эшкә тотынгач, күңелләрең күтәрелер. Менә бездә матрац эшләнә. Гайнетдин абзыйлар матрац өчен мунчаланы үзләре йомшартып утырып, әллә никадәр вакытларын әрәм итәләр. Ә мунчала тетәргә генә синең кулдан килә, ул эшне син булдыра аласың. Син мунчала тетеп аларга булышсаң, эш тизрәк барып, мастерскойның эш чыгаруы да артыр, шуның аркасында синең дә тамагың тук, өстең бөтен булыр. Шуның аркасында эчүләрең дә ташланыр. Үзеңне укырга, язарга да өйрәтербез. Китаплар укый башлагач, күңелләрең дә ачылыр.

Ә х м ә д и. Анысы мунчала тетү генә кулдан килер! Тик менә укырга өйрәнүе генә кулдан килерме икән?

Ә х м ә т. Һич тә хафаланма, килер. Ике-өч ай эчендә сине укый-яза белә торган кеше итәргә үзем өстемә алам. Менә, бәлки, Сәкинә иптәш белән Галия иптәшләр дә булышырга сүз бирерләр. Галия, Сәкинә, сүз бирәсез бит? Шулай бит, туташлар?

Г а л и я. Бик шатланып!

С ә к и н ә. Кулдан килгәнчә – һәммәсен!

Ә х м ә д и. Рәхмәт алайса, энекәшләрем, сеңелләрем! Алай булса, мин дә сүз бирәм. Моннан соң эчү юк! Күңелне күтәреп җибәрдегез, кайтам да хатыннан сөенче алам, ул да шатланып җибәрсен. Шатлыктан уйнап та җибәрим, булмаса.

Ә х м ә т. Билгеле, шулай кирәк. Әйдә, Сәкинә, син дә үзеңнең чыгарган җырларыңны җырлап җибәр. Сезнең ишеткәнегез юктыр әле, Сәкинә бик шәп итеп үз тормышыбыздан җырлар язган.

Г а р и ф. Минем дә күңелне җилкетеп җибәрдегез, башлагыз әйдә!

С а б и т. Ярый, булган-булган бутка булсын дигәндәй, әйдәгез, барыбыз бергә кушылып җырлап җибәрик.

Г а й н е т д и н. Булды гына, әйдә, башла, Сәкинә! Әхмәди, тарт гармуныңны!

Ә х м ә д и. Була ул. (*Тон биреп уйнап чыга.*)

С ә к и н ә (*башлый*).

Ике суның уртасында
Безнең Казан каласы.
Уку белән кеше була
Безнең эшче баласы.

Х о р. Әйе шул, шулай шул,
Безнең эшче баласы. (*2 тапкыр*)

С ә к и н ә. Без эшләрне эшлибез
Инә белән, без белән;
Удар эшләр алып барыйк
Ленин сызган эз белән.

Х о р. Әйе шул, шулай шул,
Ленин сызган эз белән! (*2 тапкыр*)

Ә х м ә т. Менә молодец, менә молодец! Бу эшләр кәефкә килә.

Г а й н е т д и н. Әйдә, булган-булган берәгәйле булсын. Инде оркестрда да уйнап җибәрик.

Г а л и я. Ничек итеп?

Г а й н е т д и н. Даешь, тавышлы оркестр!

Б а р ы с ы  д а. Әйдә!

**Гармун, тарак, чыбыклар белән шумовой оркестр уйныйлар.**
**П ә р д ә.**

# БОЗАУ

*Комедия бер пәрдәдә*

ӘШХАС:

Мәрьям.
Кәримә – аның кайнигәче.
Маһруй – асрау.
Рәшит – Мәрьямнең ире, картаеп өйләнгән кеше.
Хәким – Рәшитнең энесе.

Яхшы, матур гына бүлмә. Яхшы мебельләр, рәсемнәр, идәндә паласлар, түрдә сул яктарак китап шкафы, уң якта беренче планда язу өстәле, өстәл өстендә китаплар, сулда икенче планда камин.

## БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Маһруй, Рәшит.

Маһруй. Башка йомышыгыз юкмы?

Рәшит. Юк, бер эшем дә юк.

Маһруй чыга башлый.

Ә, кара әле, абыстаңа бернәрсә дә сөйләмә.

Маһруй. Яхшы, ярый.

Рәшит. Берни дә юк... Үзең дә беләсең бит... (*Борчылып.*) Абыстаң Кәримә белән күрешкәнлекне, аның белән сөйләшкәнне тоймасын. (*Үзен мөдафәгә кылган шикелле.*) Аннан курыкканлыктан түгел дә... Шулай да күңелсезлек булмасын, дим, шуннан гына... (*Үзалдына.*) Һи бу хатыннарның җөдәтүләре, борчулары!..

Хәким керә.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм Хәким.

Рәшит. Һа, Хәким! Бу кадәр бик иртәләгәнсез,ниләр бар?

---

Әшхас – катнашучылар.
Мөдафәгә – үзен саклау.

Хәким (*күңелсез генә*). Берни дә юк...

Рәшит. Юк, юк, синдә нинди булса да берәр төрле эш бар. Мин синдә ниндидер бер эч пошу барлыгын күрәм.

Хәким (*креслога утырып*). Ихтимал.

Рәшит. Маһруй, бар син безгә сөтләп чәй китер. (*Хәкимгә.*) Әллә кофи телисезме?

Хәким. Ни булса да ярый.

Маһруй чыга.

Рәшит. Җә, сөйлә, зинһар, ни бар?

Хәким. Синең көчсезлегең, синең җиңелүең, синең җүләр... (*Сүзен алмаштырып.*) Ә, синең кирелегең...

Рәшит (*тәмам беркатлылык белән генә*). Бик яхшы аңладым... Җә, ни булган соң?

Хәким. Ни булсын, туйның, өйләнүнең, яшь хатын белән гомер итә башлауның аннан һич аерылмый торган итәге: рәхәтсезлек, ул-бу... җиңелү, буйсыну... Аңладыңмы?

Рәшит. Берни дә аңламадым.

Хәким. Аңламассың шул. Кәефеңә килми дә, шуның өчен аңларга да теләмисең.

Маһруй чәй китерә. Бераз тынлык. Маһруй чыга.

Рәшит. Ни бар?

Хәким. Хатыныгызның вак, мәгънәсез, акылсыз теләкләреннән башка тагы ни булырга мөмкин?

Рәшит (*бик йомшак, елмаеп*). Ә, ул бала гына әле, аңар карамагыз...

Хәким. «Ул бала гына әле, аңар карамагыз», имеш... Һәр көн бер сүз... Беркөн хатының иң нечкә, иң кадерле булган бер хисеңә кагыла. Аңар үзенең дәрәҗәсен белдерер өчен дип абзаңа киләсең... Сиңа җиңелү, көчсезлек, картлык, күңел кую була торган эшләр дип әйтәләр... Һич оялмыйлар да.

Рәшит (*ачу беләнрәк тә, ялыныбрак та шикелле*). Тукта әле, ни булган соң? Җә, аңлат әле!

Хәким (*истиһза белән*). Иң зур бер тәрбиясезлегендә матур бер балалык, күзләрендә бөтен дөньядан да югары бер сәмавилек, сүзләрендә шигырьләрдән дә артык тәмлелек күрә торган хатыныгыз...

Рәшит (*кинәт кенә, ачу беләнрәк*). Җә, җитәр, ахырын сөйлә!

Хәким. Хатыныгыз безнең Кәримәне өйдән куа...

---

Истиһза – көлү, мыскыл итү.
Сәмави – күкнеке, илаһи.

Р э ш и т (*көлеп*). Һи, әрсез!.. Болай гына ул, кечкенә бер балалык кына... Илтифат итмәгез!..

Х ә к и м. Хәер, инде хәзер аны әйтеп торырга да хаҗәт калмады... Тутабыз бүген өйдән китә...

Р ә ш и т (*ачулы*). Юк! Монысына минем ачуым да килә... Шундый олыгайган бер хатын, шундый юк эшләргә илтифат итеп, биренеп, шундый бер диваналык кылсын, имеш! Бу һич була торган эшмени? Ул бит әле бер бала гына. Сөйләр, сандугачланыр. Аның сөйләгән сүзләренә бер сайрау дип кенә карарга кирәк, илтифат итмәскә, ачуланмаска кирәк. Аңар бары тик кәефләнергә генә кирәк. Ул шулай инде...

Х ә к и м (*чырайларын сытып*). Зинһар, дип әйтәм, шагыйрьләнүләрне, фәлсәфәләрне ташлагыз әле. Бераз гына үзебезнең хәлебезне дә уйлап карыйк! Абыстай аерым ашый... Чөнки хатыныгыз шулай тиеш дип тапкан. Абыстайның сезнең белән күреп сөйләшергә хакы юк, чөнки сезгә әмерләр биреп тора торган сөйгәнегез, сезнең тормышыгызның кояшы, сезнең хатыныгыз шулай тели. Сез абыстайның бүлмәсенә, аның янына да аена бер мәртәбә генә, анда да карак шикелле качып-посып кына, асрауларга ялынып, анда кергәнеңне әйтмәүләрен үтенеп кенә керәсез. Чыккан вакытта да күңелегездә курку, каушау була. Хатыныгызның күзендә ачу бармы-юкмы икәнен белер өчен, ничә көннәргә кадәр хатыныгызның күзенә курка-курка гына карыйсыз. Аннан безгә дә, үзегезгә дә ялган сөйләгән бер тавыш белән: «Ул бит әле бер иркә бала гына», – дип куясыз. Шуның белән бөтен эшләрне җайладым дип беләсез. (*Аяк өстенә торып.*) Җитәр инде... (*Ишеккә таба барып.*) Ул иркә балагыз белән сез үзегез генә калыгыз! Сезгә кәефләнер өчен ишекләр ачылыр.

Р ә ш и т (*аяк өстенә торып, бераз алга атлап, аптырап*). Тукта, Хәким. Хәким, монда кил, монда кил! Хәким! (*Кире борылып, сәхнә алдына килеп, халыкка.*) Һи, балалык, балалык!..

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

М ә р ь я м, Р ә ш и т.

М ә р ь я м (*кереп җитәр-җитмәс, хәлсезләнгән шикелле, креслога утырып*). Ах, моңар чыдарга мөмкин түгел, моңар чыдарга мөмкин түгел!..

Р ә ш и т (*янына килеп, кулын кул эченә алып*). Ни булды, ни булды сиңа, кечкенәм?

М ә р ь я м. Уф! Зинһар, син дә җөдәтмә әле. Кит әле...

Р ә ш и т (*тагын да мөлаемрак, тагын да якынрак килә*

*төшеп*). Юк, юк, сөйлә, сөйлә, матурым, сөйлә! Синең кәефеңне кырган нәрсәнең ни икәнен, нигә борчылганыңны, сине кем борчыганын миңа сөйлә. Сөйлисең бит? Син минеке, мин синеке!

Мәрьям. Эчем поша, эчем поша, эчем поша...

Рәшит (*ялынып*). Нилектән алай? Кемгә? Кемнән туйдың?

Мәрьям. Синнән дә, алардан да, барысыннан да, барыгыздан да!

Рәшит (*кәефсезләнеп*). Миннән дәме? (*Ялынып.*) Җә, сөйлә, тагы мин ниләр эшлим? Мин бит синең колың, бөтен гомерем, бөтен тормышым синеке... Син ни теләсәң – һәммәсе дә булып тора. Атларың, алтын-көмеш, бриллиантларың, асрауларың, хезмәтчеләрең...

Мәрьям (*гасаби һәм хурлап*). Шулар булгач җиткәнмени? Юк, түгелме? Юк... (*Тагы да артыграк ачуланып.*) Карт бер ир... Каһәр төшкән кайниш, үз-үзенә исе киткән бер каене урынына...

Рәшит. Аңлыйм, аңладым. Син ачуланган. Мин бер сүз дә әйтмим, син бит үзең дә мине сөясең... Кичә син үзең дә шулай дип әйттең түгелме?

Мәрьям (*каты гына*). Кайчан?

Рәшит. Кичә, мин сиңа брошка алып кайткач.

Мәрьям (*ирексез генә*). Әйе, әйе.

Рәшит (*янына утырып, ялманып*). Аны алган вакытта мине шулай (*муеныннан үбеп*) үптең дә...

Мәрьям. Бүген син бик эчпошыргыч!..

Рәшит (*рияланып көлеп*). Мин эчпошыргычмы? Булсын, минем шаян бала!

Мәрьям (*ирексез, гасаби көлү белән көлеп*). Мин шаянмы?

Рәшит (*йомшак кына, беркатлылык белән*). Алай дип әйткәнне яратмасаң, алайса, нервный хатыным... (*Салкын, ясалма көлү белән.*) Минем үзсүзле матурым...

Мәрьям. Минме? Минме? Җә, әйт!.. (*Рәшитнең кулын чеметеп.*) Мин үзсүзлеме?

Рәшит. Ай!..

Мәрьям. Үзсүзле икән!..

Рәшит. Юк, җаным, юк... Син түгел, шаярып сөйләдем...

Мәрьям (*аяк өстенә торып, ачуланып*). Үзсүзле мин түгел, аңлыйсыңмы, үзсүзле синең тутаң... Кәримәгез... Хатыннарның да иң актыгы...

Рәшит. Җә, җитәр, хатын!

---

Гасаби – борчулы.

М ә р ь я м (*тагы да артык ачуланып*). Мин аны кудым да инде, ул бүген китәчәк!

Р ә ш и т. Кудым дисеңме? Юк ла, андый эшне син эшләмәссең!

М ә р ь я м. Әйе, кудым. Бар да бетте. Ул шуны телидер иде, шулай эшләдем дә...

Р ә ш и т. Аның ни гаебе бар иде?

М ә р ь я м. Гаебеме? Анда да, монда да күршеләргә мине холыксыз дип сөйләп йөрүе... Өй эчендә мине күргәндә, миңа исе китмәгән булып, тәкәбберләнеп узып киткән булуы... Менә сиңа ике гаеп!.. Яшь, матур хатын андый эшләргә чыдый алмый...

Р ә ш и т. Бик яхшы иткәнсең, хатын, бик яхшы, ярый, син дигәнчә дә булсын, ләкин син бер генә мәртәбә булса да ул турыда миннән сорап уздырырга кирәк иде.

М ә р ь я м. Синнәнме? Ни өчен? Өй синеке түгелмени? Әйе, әйе шул, синеке. Син шул мине сөймисең, һич сөймисең... Ах! Без хатыннар нинди тиз ышанучаннар. Сез ирләрнең ялган сүзләренә никадәр җиңел ышанабыз... Никадәр җиңел!

Р ә ш и т (*аптырап*). Мин нәрсә ялган сөйләдем?

М ә р ь я м. Нәрсә дисеңме? Һәр көн, һәр сәгать, һәр минут саен сөйләгән, кат-кат әйткән шул ялганнарыңны оныттыңмыни?

Р ә ш и т. Онытырга әле минем белгәнем дә юк.

М ә р ь я м. Белү синең кәефеңә ошамый да, син шуның өчен аңламыйсың. Һәр сәгать саен, һәр минут саен «Сине сөям, бик, бик сөям» дигән сүзләреңне онытасыңмыни?

Р ә ш и т (*кызып*). Әйе, сине бик сөям, бик, бик...

М ә р ь я м (*үпкәләп*). Мине сөйсәң, өйнең синеке булганын сөйләп тормаган булыр идең.

Р ә ш и т (*ашыгып*). Мин һич андый бер сүз сөйләмәдем дип уйлыйм.

М ә р ь я м. Сөйләмәдең, сөйләмәсәң дә, шуны аңлаттың! «Миннән сорап узарга кирәк иде», – дидең. Синең ул сүзеңнән «Миннән сорамыйчы шундый эш эшләдеңме, бу һич була торган эш түгел, булмас» дип куркытуың аңланадыр иде.

Р ә ш и т. Юк, хатын, мин ул сүзне ул уй белән әйтмәдем. Өй, бөтен нәрсәләр, бөтен бар булган нәрсәләр, бөтен тормыш синеке... Ул синеке булырга тиеш. Әгәр дә кулымнан килә торган булса иде, бөтен шул дөньялардан сиңа бер уенчык ясап бирер идем.

М ә р ь я м (*елмаеп, назланып көлеп*). Рәхмәт сиңа, карт бала... Алай булгач, өй минеке булгач, бөтен тормыш та минеке булгач, тутаң да бүген бу өйдән китәргә тиеш!

Р ә ш и т. Юк, юк, бүген үк булмый!

Мәрьям (*вакытлы бер ачу белән*). Бүген булмый? Ни өчен? Бүген үк булырга тиеш, мин шулай телим! Ялганчы, бер минут элек кенә ни сөйлидер идең? Җә мин, җә ул!

Рәшит. Бер-ике көн соңрак булса ярамыймыни?

Мәрьям (*тагын да артыграк ачуланып*). Менә сиңа актык сүзем: җә мин, җә ул!

Рәшит (*нишләргә белмичә*). Син уйлап кара, бер-ике көннән генә ни булган...

Мәрьям. Булмый, булмый, тыңламыйм да, уйламыйм да...

Рәшит. Бер өй табыйк, бер фатир тапсыннар... Болай кинәттән генә... Кардәш бит, җаным, үтенәм!..

Мәрьям. Уф, уф, уф... Син мине сөйсәң, болай сөйләмәс идең...

Рәшит. Ярый, ярый, ләкин...

Мәрьям. Ләкин-мәкин юк! Мин китәм. Күп сөйләп торырга да теләмим. Ул бүген китәр. Син аның белән сөйләшеп тә торма. (*Чыга.*)

Рәшит аптырап карап кала.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Рәшит, Маһруй.

Маһруй (*кинәт*). Абзый!

Рәшит. Ни бар?

Маһруй. Ни, абзый, ни китә...

Рәшит (*ачуланып*). Нәрсә, кем?

Маһруй. Кәримә апа.

Рәшит. Әйт үзенә, балалыкны ташласын.

Маһруй. Сезнең белән сөйләшергә тели.

Рәшит (*аңлый алмый*). Минем белән күрешергә? Кайда күрешергә?

Маһруй. Монда...

Рәшит. Юк, булмый. (*Икеләнеп торып.*) Бар әйт, килсен.

Маһруй. Ярый. (*Чыга башлый.*)

Рәшит (*шыпыртлап кына*). Саклан, хатын тоймасын, саклан, хатын сизә күрмәсен.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Рәшит ялгыз, соңыннан Кәримә.

Рәшит (*өстәлдән бер гәзитә ала, бераз укый, карый, аны ташлый, икенчене ала, янә ташлый*). Һичнәрсә аңлый алмыйм. (*Бер китап ала.*)

Кәримә керә. Өстенә киенгән. Бер-берсенә карашалар. Сүз эндәшмиләр. Бераздан.

Утыр!

Кәримә, ят кеше шикелле, урындыкның кырыена гына утыра. Яулыгы белән күзен сөртә.

Тагы ни булды, ни бар?

Кәримә (*эченнән ачу белән*). Белмисеңмени? Хәким сиңа сөйләгәндер дип беләм.

Рәшит. Әйе, әйе, сөйләгән иде, мин ул эшкә балалык дип кенә карадым да илтифат итмәдем.

Кәримә. Балалык ул алай булмый, бу балалык түгел, явызлык, тилелек...

Рәшит. Бик дөрес әйттең. Шулай булгач, тиле кеше сүзе буенча йөриләрмени?

Кәримә. Минем кәефем киткән кеше – тиле түгел, тиленең ире.

Рәшит. Минме? Мин соң нишләдем?..

Кәримә. Синме? Син куркасың. Бер тиледән, бер хатыннан куркасың. Ул хатын өчен кадерле тутаңны, сөекле энеңне онытасың. Үзеңнән дә имин түгел.

Рәшит (*ачуланып*). Юк, апа, юк, мин алай мыскыл итүгә, хурлауга чыдый алмам, синең тиле дигәнең – ул минем хатыным... Икенчедән, мин хатынымнан курыкмыйм. Сине яраткан шикелле аны да яратам. Бөтен тавыш сездән чыга.

Кәримә. Ярый, зыяны юк. Без бу сүзләрне хатыныгыз белән сездән ишеттек. Без хәзер китәбез... (*Мәгънәле итеп.*) Моннан соң шәп итеп, тавышсыз, тыныч кына торырсыз.

Рәшит. Сез дә инде бигрәк, һичбер нәрсәгә дә чыдый алмыйсыз. Кечкенә генә бер сүз, кечкенә генә бер эш сезнең кәефегезне җибәрә.

Кәримә. Юк, туганым, бу кечкенә эш түгел. Бу – ачу, бу – мыскыл итү! Мин китәм, дидем, китәм. Шул җитәр инде. Бәхетле булыгыз, бәхетле! Сезнең тормышка без уңайсызлык итәдер идек.

Рәшит. Кәримә, мин синнән үтенәм. Син бераз үлчәбрәк уйлап кара. Мин өйләндем... Яшь, матур хатын алдым. Ни өчен андый хатын сайладым? Әгәр коры бер кирәклек өчен генә булса, аннан картрак хатын да яраган булыр иде.

Кәримә. Һаман да шул буш сүзләр...

Рәшит. Син минем сүземне дә тыңларга теләмисең.

Кәримә. Ни өчен тыңлап маташыйм? Синең сөйлисе сүзләрең безне гаепле итеп күрсәтер өчен булган сүзләр

икәнен мин белмиммени? Бик күп тыңладым. (*Яулык белән күзен сөртә.*)

Р ә ш и т. Юк, алай түгел. Сез дә гаепле түгел, ул да... Бары тик минем фикерем турысында бер-ике сүз генә. Нәрсә дип башлаган идем соң әле? Ә, әйе, әгәр шулай булса, миңа берәр картрак хатын булса да яраган булыр иде, шулай түгелме? Мин алай теләмәдем. Мин үз тирәмдә бераз кызулык, бераз җылылык, бераз яшьлек, бераз матурлык, бераз шигырь дә булуын теләдем һәм шуны теләдем. Миңа тынлык җан бирмидер иде. Әгәр тынлык минем күңелне тынычландырса иде, мин өйләнмәгән булыр идем. Өйне карап торырга син бар әле дияр идем дә тик торыр идем.

К ә р и м ә. Алай булгач, мин сине бәхетле итә алмаган икәнмен. Алай булгач, син миннән риза булмаган?

Р ә ш и т. Зинһар, холыксызланма әле. Мин сиңа үземә нәрсә кирәк булганлыгы турысында сөйлим. Миңа тын тормыш түгел, җанлы тормыш кирәк иде, дим. Сез минем хакым өчен шундый бераз тынычсызлыкларга булса да түзегез димәкче булам.

К ә р и м ә. Түзәргә, куылганнан соң да түзәргә...

Р ә ш и т. Тавышыгызны чыгармагыз, аны ачуландырмагыз...

К ә р и м ә. Туган, өч ай инде авызымны да ачканым юк... Шулай да хатыныгыз һич юктан, тик торганда туфаннар кубара, акыра, бакыра, хурлый, куа... (*Күзләрен сөртә.*)

Р ә ш и т. Анысыннан да көләргә генә кирәк. (*Беркатлыланып.*) Ул бит шул ачулы вакытларында бигрәк тә матурланып китә. (*Көлә.*)

К ә р и м ә. Сезнеңчә шулай, сезнеңчә аның һәрбер кыланышлары да матур. Сез аны акылдан шашып, тилереп сөясез. Һичбер гаепләре күзегезгә күренми. Туганыгыз куыла, елый, сез аңар сафсаталар белән җавап бирәсез, сез җиңелгән, сез шул гыйшык упкыннарында тыпырчынырга, тыпырчынган саен шуннан бер ләззәт табарга калгансыз. Ә без аңар түзә алмыйбыз, безгә тыныч тормыш, йоклаган тормыш кирәк. Без китәбез.

Р ә ш и т. Әгәр дә сез теләгән тормышны мин сезгә монда табып бирсәм дә китәсезме?

К ә р и м ә. Табып бирү!.. Һич ышана алмыйм...

Р ә ш и т. Аннан сиңа ни булган? Ул эшләрне булдыручы мин булачак. Менә шуннан соң мин җиңә аламмы, юкмы икәнне күрерсең.

К ә р и м ә. Ярый, бүгенге куылудан соң нишләргә?

Р ә ш и т. Бар эшне дә миңа гына калдырыгыз! Катышмагыз. Бүлмәгезгә китегез дә тынычланыгыз.

К ә р и м ә. Һаман без баш иик тә, һаман без җиңеликме?

Р ә ш и т. Алай дип уйламагыз. Нигә җиңелергә? Сез җиңәрсез. Сезнең монда торуыгыз аңар «Син кем соң ул кадәр, бу минем кардәшемнең йорты, рәхәтләнеп тора бирәм» дигән сүз булыр.

К ә р и м ә. Алай уйланса, билгеле, без җиңәрбез. Ләкин, әрсезләнеп, килмешәк шикелле тору, аның хурлауларына эндәшмәү – ул бит «Мин мохтаҗ, мине теләгәнчә изегез» дигән сүз! Син шуны аңламыйсыңмы? (*Күзләрен сөртә.*)

Р ә ш и т. Әйе, ләкин...

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Ә ү в ә л г е л ә р һәм М ә р ь я м.

Р ә ш и т Мәрьямне күрү белән куркып карый. Кәримә, усал күз белән карап алганнан соң, Рәшитнең кыйланышларына карап, илтифатсыз утырган шикелле утыра.

М ә р ь я м (*иренә, каты гына*). Мин сиңа ни дидем...

Р ә ш и т (*куркып, аптырап*). Ә... ни... хатын...

К ә р и м ә (*батыраеп*). Алай ул кадәр җикеренергә нинди хакың бар?

М ә р ь я м (*ачу белән*). Әле һаман телләнәсезмени? (*Мәгънәле иттереп.*) Өйдә торырга да хәтта...

К ә р и м ә. Сез ул кадәр кем булдыгыз соң, сүз дә сөйләмәскә?!

Р ә ш и т. Карагыз әле... Бу – балалык...

М ә р ь я м. Син тик кенә торсана, мескен!

К ә р и м ә. Дөресен генә әйткәндә, киленнең тәрбиялелегенә искитәрлек...

М ә р ь я м. Син дә күп сөйләнмә, үзеңнең кем икәнеңне генә бел... Асраулыкка да яраксыз...

Р ә ш и т. Бераз акрынрак...

К ә р и м ә. Минме, сезме?..

М ә р ь я м. Сез, билгеле, сез...

К ә р и м ә. Моннан да артык оятсызлык булмас...

Р ә ш и т. Җә инде, син дә... Туган...

М ә р ь я м. Һаман да әле шуңар тагы «туган» дип торган була, карт җанвар...

Р ә ш и т. Мәрьям, дим, акрын, акрын...

К ә р и м ә (*Рәшиткә мыскыл белән карап*). Чыдап торуыгызга һич сүз дә әйтерлек түгел...

М ә р ь я м. Нинди оятсыз хатын! Куылгач та минем өемдә утырырга батырчылык итә.

К ә р и м ә. Кайдан килеп сезнең өегез булды икән? Сөйләп күрсәтсәгез лә!

Р ә ш и т. Һич килешкән эш түгел, зинһар, туктагыз.

М ә р ь я м. Иремнең өе булгач, минеке була. Аңладыгызмы?

К ә р и м ә. Туганымның өе булгач, минеке була. Сез дә аңладыгызмы?

М ә р ь я м (*Рәшиткә*). Җә, сөйлә, сөйлә, өй кемнеке?

Р ә ш и т. Туктагыз, иң элек тынычланыгыз да...

М ә р ь я м (*ачу белән Рәшитнең кулыннан тартып*). Җә, сөйлә, сөйлә, әйт, әйт!

Р ә ш и т (*тотлыгып*). Әй, өй, әйе, өй...

К ә р и м ә. Тизрәк сөйлә!..

Р ә ш и т (*ялынып*). Ләкин син инде, Кәримә...

М ә р ь я м. Карт җүләр. Минем колак төбемдә шул җир кортының исемен әйтергә оялмыйсыңмы?

Р ә ш и т. Минме?

М ә р ь я м. Син...

К ә р и м ә (*тәкәбберләнеп, илтифатсыз шикелле*). Сөйләгән сүзләрегезне үзегезгә кайтарам.

М ә р ь я м (*тагы да артыграк ачу белән*). Һаман да тора әле... Намуссыз. (*Акырып елый башлый.*) Ах, мин нинди бәхетсез, мин нинди бәхетсез!.. (*Рәшит аны диванга алып килеп утырта. Мәрьям бөтенләй һушыннан киткән шикелле утыра.*) Мин никадәр бәхетсез!.. Аһ!.. Аһ! (*Елый.*)

Рәшит, кесәсеннән яулык чыгарып, Мәрьямнең күзләрен сөртә.
Пауза.

Р ә ш и т (*Кәримәгә, шелтәлерәк рәвештә*). Күрдеңме инде? Хәзер...

К ә р и м ә. Кызганыч, бичара, мәхлук! Ышанды да тагы...

Р ә ш и т. Син бигрәк чиктән узып китәсең!..

## ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш у л а р  у к, Х ә к и м, соңыннан М а һ р у й.

Х ә к и м (*кереп җитәр-җитмәс*). Ни бар? Ни булды?

К ә р и м ә (*Хәким янына йөгереп килеп*). Үләм, үләм, беттем...

Р ә ш и т (*Мәрьямне күрсәтеп. Хәкимгә*). Менә кара, моның хәленә кара...

Х ә к и м. Син дә бигрәк артык бозауландың.

Р ә ш и т (*һаман да Мәрьям янында чуалып, беркатлылык белән*). Җә инде, туган, шулкадәр бу хәлне күрә торып та чыдарга мөмкинмени?

Мәрьям (*кысынкы, назлы тавыш белән*). Китсеннәр! Китсеннәр!

Рәшит. Ни диден, җаным?

Мәрьям (*тагы да артыграк назланып*). Китсеннәр, теләмим...

Хәким. Аңладык, ханым әфәнде, аңладык.

Кәримә. Китмим һәм китмәм!..

Рәшит (*ялынып*). Туганым!..

Хәким. Апа, тик тор... Эндәшмә!..

Кәримә. Ни өчен?

Мәрьям (*иркәләнеп*). Китсеннәр, теләмим, китсеннәр.

Рәшит. Мәрьям, чү, өзлегерсең.

Кәримә (*Хәкимгә*). Кардәшмени соң ул...

Хәким. Аптыраган, мескенчәк... эш ит.

Рәшит. Шундый эшкә сәбәп булудан ни файда бар?

Хәким. Без нәрсәгә дә сәбәп булмадык, бары тик хатыныгыз... Җә, куй инде, сөйләмик...

Мәрьям (*кинәт сикереп торып*). Нәрсәне, нәрсәне сөйләмисез, ни әйтер идегез? Ул кадәр сөйләрлек нәрсә беләсез?

Хәким. Җә, куй инде, күп сөйләнмә...

Кәримә. Без бик күп нәрсәләр беләбез... Бары тик тәрбиябез генә ирек бирми...

Рәшит. Куегыз, зинһар! Балалыкны ташлагыз!

Мәрьям. Ифтирачылар! Яла ябучы хатын! (*Исәпләмичә.*) Мин нишләсәм дә ирекле, мин бер намуслы хатын булганга...

Хәким. Ул сүзне авызың белән пычратма!.. Син, әйтсәм әйтим инде, шундый бозау, мисез бер ир белән теләсәң ничек уйнар өчен, безнең монда булуыбызны теләмисең. Без китәбез.

Рәшит (*ачуланып*). Китәбез... Китегез, китегез, ишекләр ачык.

Кәримә (*нәфрәт белән*). Кардәш, имеш...

Рәшит. Моны мин теләмим, сез телисез.

Хәким. Шулай, шулай.

Мәрьям. Ах, хәлем начарлана... Үләм, үләм... Уф, уф!..

Рәшит Мәрьямгә йөгереп бара.

Кәримә (*Мәрьям белән Рәшиткә ишеттерерлек итеп*). Бикә нинди иркәләнә!..

Рәшит. Әйтсәм әйтим, син – акылсыз!

Мәрьям. Китсеннәр, буылам!

Хәким. Хәзер китәрбез, хафаланма, бикә!

---

Ифтирачы – яла ягучы.

К ә р и м ә. Китәрбез!

Р ә ш и т. Китегез, миннән сезгә дога...

Х ә к и м. Мохтаҗлыгыбыз юк.

К ә р и м ә. Намуслы хатыныгыз белән калыгыз.

М ә р ь я м. Уф, беттем, беттем... (*Һушы китә, егыла.*)

Р ә ш и т. Ни, кайда, кеше юкмы?! Һушы китте. Звонок бирегез! (*Звонокка бара.*) Сез никадәр мәрхәмәтсез кешеләр... (*Ишеккә бара.*) Кайда, кем бар? Килегез! Килегез! (*Яңадан звонокка килә, бик каты шалтырата.)*

Рәшит бу эшләрне эшләгәндә, Хәким белән Кәримә, ышанмаганлыкларын аңлатып, шыпыртлап сөйләшәләр.

Кәримә, сез никадәр илтифатсыз!

К ә р и м ә (*Хәкимгә*). Нинди тиле!

Х ә к и м. Бозау, тиле!

Р ә ш и т (*Мәрьям янына йөгереп*). Начар, начар, хәле бик начар! (*Җүләрләнгән шикелле, Кәримәгә йөгереп килеп.*) Мәрхәмәтсез, нәрсә карап торасың? Шалтырат!

Кәримә ирексез звонок янына йөгереп барып баса, Хәким кызгану катыш ачу белән карап тора. М а һ р у й керә.

Р ә ш и т. Кызый, син кайда югалдың? Йөгер, бар, тизрәк!

М а һ р у й (*аптырап*). Ни бар?

Р ә ш и т. Сорап тора торган вакыт түгел. Әйдә, кил, күтәреш, бүлмәсенә илтик.

Маһруй җилкәсеннән тота.

Алай түгел, алай түгел, аркама атландырыгыз.

Маһруй атландырырга тырыша, булдыра алмый.

*(Рәшит сәхнәгә арты белән әйләнә.)* Хәким, зинһар. Хәким!

Х ә к и м килә. Маһруй белән бергә Рәшитнең аркасына күтәрәләр, шул рәвешчә күтәреп, Рәшит, аның артыннан Маһруй чыга.

## СИГЕЗЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Х ә к и м, К ә р и м ә.

К ә р и м ә (*диванга утырып*). Уф Алла! Тәмам беттем. Нинди фетнәче хатын!..

Х ә к и м. Нинди хәйләкәр тагы!

К ә р и м ә. Бичара Рәшит шуларны чын дип белә.

Х ә к и м. Ул аны, Рәшитне, сәгать борган шикелле бора. Ирләр ничек борыла, күрдеңме?

К ә р и м ә. Безгә монда инде артык торырга мөмкин түгел.

Х ә к и м. Һич ихтималы да юк.

К ә р и м ә. Шулай да Рәшиткә бер-ике сүз әйтик әле.

Х ә к и м. Әйе, бөтен гаеп анда, аңар бер-ике сүз сөйләргә кирәк.

К ә р и м ә. Әйе, әйе, шулкадәр ачуым килә, шулкадәр дошманлыгым бар, хәтта кардәшлегемнән кул селтәсем килә! Хәер лә, сез, ирләр, барыгыз да шулай, өйләнгәч.

Х ә к и м. Юк, мин алай түгел...

К ә р и м ә. Күрербез.

Х ә к и м. Бердән, мин өйләнмим, икенчедән, һичбер вакыт алай җиңелмәм!

## ТУГЫЗЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Ә у в ә л г е л ә р, Р ә ш и т, соңыннан М а һ р у й.

Р ә ш и т (*керү белән*). Сез дә шул, балалар! (*Битен яулык белән сөртеп, язу өстәле янына утыра.*) Нинди начар минутлар. Доктор чакырттым, хәле начар... Бик начар... Монда бар гаеп сездә...

К ә р и м ә. Бәхетле булыгыз, без сезне сөекле хатыныгыз белән генә калдырып китәбез.

Р ә ш и т. Мине, шушы хәлдәме? Мәрьям шул хәлдә көенчәме?

Х ә к и м. Һаман да Мәрьям шул хәлдә вакыттамы, дисез, кардәшләрем шундый хәлдә вакытта, димисез. Әйдә, апа, тор! Бу җүләрнең өеннән, яныннан тизрәк китик.

Кәримә елый башлый.

Р ә ш и т. Кәримә, үтенәм, Кәримә, елама, кал!

К ә р и м ә. Сезнең кызгануыгызга мин мохтаҗ түгел. Аңлыйсызмы? Сөекле еланыгыз белән бәхетле булыгыз!

Р ә ш и т (*ачулырак йомшаклык белән*). Ләкин... үтенәм, болай артыкка китмәгез. Күрәсез бит, авыру бит... Карагыз!..

Х ә к и м (*Кәримәнең кулыннан тартып*). Ташла шул бозауны... Ташла шул авыру җүләрне...

Чыгалар.

Р ә ш и т (*сәхнәнең алдына килеп, аптыраган төстә, беркатлылыгын күрсәтә торган бер рәвештә авызын туарып*). Уф! (*Китә. Звонок бирә, нервныйланып шалтырата.)*

М а һ р у й керә.

М а һ р у й. Нихәл, бикәнең кәефе ничек?

П ә р д ә.

## ҖАНТАҺИР БЕЛӘН ҖАНЗӨҺРӘ

*Бер пәрдәдә*

УЕНГА КАТНАШУЧЫЛАР:

Зөһрә – авыл мулласының кызы.
Таһир – авылның мәзин улы.
Кара малай – мулланың ялчысы.
Остазбикә – мулла хатыны, Зөһрәнең анасы.
Мулла – Зөһрәнең атасы, авыл мулласы.
Староста – авыл старостасы.
Көтүче – авылның көтүчесе.
Куштаннар – авыл куштаннары.
Мәзин – Таһирның атасы.

Вакыйга авылда.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мулланың кара өе. Зөһрә, сәкегә утырып, белер-белмәс, лыгырт-лагырт гармун уйный. Таһир, ишек төбендәге ян сәкегә утырып, аның уйнаганын тыңлап утыра.

#### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Таһир, Зөһрә.

Таһир

Һи, ташласана шул гармуныңны,
Һич иштәсе дә килми моңыңны.
Лыгырт-лагырт чыккан гармун тавышлары
Искә төшерәләр сыер көтүен, болынны.

Зөһрә

Ул көйне мин, Таһир, һаман уйныйм,
Аның катык-сөтләрен мин яратам.
Янында әгәр икмәге дә булса,
Җанга азык табам шуңардан.
Әллә синең һич исең китмиме
Зур-зур кабып икмәк убарга?

Кайчан йомшак кабартмалар пешә,
Кайчан орлык төяләр килеләр,
Шул вакытта һәркем:
«Менә ул, Зөһрә, бәхет ни!» – диләр.
Синең ишеткәнең юкмыни?
Бөтен халык шулай сөйлиләр.
Ашаган саен, чәйнәгән саен,
Йоткан саен арта шатлык;
Тарткан гармуныңның моңы саен
Бары шул сүзләрне ятлыйлар.
Таһир белән Зөһрә «абыстайдан
Сабак ала» диеп сөйлиләр.
Ә мин сөям, син бәрәңгемне
Шашып сөям – алар белмиләр,
Җә, син нишләттерденң инде,
Анда сөялеп катып торасың,
Нигә тизрәк яучы җибәрмисең,
Оныттыңмы әллә мине сорасын?
Таһир, беләсеңме, һәрвакытта
Сакланырга кирәк дошманнан;
Һәркемгә дә дошман күбрәк була
Дуслардан.

Таһир

Курыкма, Зөһрә. Әйдә, кул көчләрен
Сынап карасыннар кирәксә,
Авызларын җимреп, тешләрен сындырып
Бетерермен, әгәр кулыма эләксә.
Кояш эсселәре кызган чакта,
Җәһәннәмдәй кызу басу буенда
Сука тотканда армаган
Бу беләкләр,
Курыкма, талмас синең туеңда.
Каты басуларны сукалап, ертып
Йөргән ак юргам
Таптап, тузан итәр дошманнарны
Без барасы керсез ак юлдан.

Зөһрә

Мин шат, Таһир. Ышанам мин,
Бәхетле без мәңге-мәңгегә.
Алла безгә – шатлык, рәхәт;
Иген уңса, туярбыз без бәрәңгегә.

Т а һ и р

Дөрес, Зөһрә, бергә ашарбыз,
Мин бәрәңге урлармын,
Сикереп чыгып киртәләр.
Әгәр күп дулый башласаң,
(*Йодрыгын күрсәтеп.*)
Менә бу йодрык сине иркәләр.
Тора алмасаң атаң аш өендә,
Аның барлык өен ташларбыз.
Бу өй тормышыннан күңлең бизсә,
Абзарларда яши башларбыз.
Күп җирләр йөрдем, күп авыллар күрдем,
Нинди өйләргә генә кермәдем.
Бары да матур, ләкин һичкайда да
Безнең абзардан матурын күрмәдем.
Анда таулар, өем-өем тирес
Таулары, абзар артында – әрем,
Тигәнәк...

З ө һ р ә

Ах!..

Т а һ и р

Төрле-төрле бәрәңге, кишерләр үсә,
Рәхәтләнеп йөрерсең биегәләп.
Әгәр кирәк булса, бу өйне ташлап, анда
Китәрбез.
Су буендагы теге өянке төбендәге
Кара мунчаны өй итәрбез.

Курнос К а р а  м а л а й кереп тыңлап тора.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш у л а р ук һәм К а р а  м а л а й.

З ө һ р ә

Ах, ул чакта нинди шат булырмын,
Үкенмәс идем гомер-гомергә.
Мунча да чабынырбыз, аш та пешерербез,
Самавыр куярбыз төшкән күмергә.

Т а һ и р

Шатлан, Зөһрә, без бит мәңге бергә,
Аптырамабыз утын, күмергә.

Кара малай

Ах, җимрек авыз, Зөһрә аның
Кочагында! Таһир рәхәтләнә
Бүген дә.
Ничек түзим! Шартлыйммы,
Әллә башлыйммы эт күк өрергә?
Тукта, озакламас, вакыт җитәр,
Табар малай юлын ничек тә.
Абыстайга барып әйтим дә
Үзем сагалап торыйм ишектә.

Таһир

(*тәрәзәдән күрсәтеп*)

Әнә абзар. Әнә мунча,
Әнә бакча, нинди матур.

Зөһрә

Ие, бакчалар да күңелле!

Таһир

Әйдә, Зөһрә, монда бушка үткәрмә
Ходай биргән матур көнеңне.
(*Кара малайны күреп.*)
Ә! Кара малай!

Кара малай

Нигә бик шүрләдегез алай?
Әгәр тавыш чыгармаска булса,
Махуркалык, чәйлек давай.

Таһир

Нәрсә йөрисең монда мишәйт итеп,
Кара аны, тешең җимерермен.

Кара малай

(*үзалдына*)

Ярар, карарбыз,
Мин сезне абзакай белән
Абыстайга әйтеп, кирәгегезне
Бирдерермен.
(*Таһирга.*)
Нәрсә миңа җиксенәсең?

Миңа мулла абзый «кеше юкмы»
Дип карарга кушты.
Чит авылның мөритләре килгән, ди бит,
Нигә аңар эчегез пошты?

Таһир

Әйдә алайса китик, Зөһрә,
Сабак укыйсың бардыр синең дә.

Зөһрә

Әйдә, миңа сабак өйрәтерсең.

Чыгалар.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Кара малай.

Кара малай

(*ялгыз*)

Телдә сабак, ләкин
Күңелдә әллә нинди серләр,
Миннән яшермәкче, мескен кыз!
Чәйлек бирмәде. Билләһи, абыстайга
Әйтәм.
Әйдә тизрәк моннан сыз!

Чыга башлый. Ишектә Остазбикә очрый.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Кара малай, Остазбикә.

Остазбикә

Син мондамыни?
Мин сине эзлим тагы тегеннән.
Йә соң, эшләр ничек?
Тыңлап торыйм чын күңелдән.

Кара малай

Бары да була, абыстай,
Күп шаулама, тыныч булсын
Күңлегез.

Остазбикә

Шулаймыни? Алай булса,
Тиздән җаен күрербез.

Кара малай

Чү, мулла абзыйлар килә
Бугай... Артларыннан сагалап
Йөрербез.
(*Чыга.*)

Остазбикә

Хода ярдәм бирсен,
Бер ышана, бер ышанмый күңлем
Моңарга.
Тизрәк, кайчан гына, кайчан гына
Котылырмын шуның оятыннан.
Азап күреп тапкан, дөньясында
Шуның белән күңлен юаткан,
Бөтен гомер аңар теләк теләп,
Уяу торган төннәр буенча.
Байга бирермен дип, чәчәк итеп
Асрап килгән идем уемча.
Имеш, шушы балаң Таһир кук
Ялангач галахны сайласын!
Нинди авыр! Ичмаса, Кара
малай
Бар эшне тиз уңайласын.
(*Чыга.*)

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Мулла, Мәзин, Староста, Көтүче һәм куштаннар керәләр.

Мулла

(*Старостага*)

Җә, сөйлә, Хәйбулла,
Нинди бәхетсезлек, нәрсә булган
Ди безнең көтүгә?
Баярның сыеры югалган диме?
Килеп катышкан диме безнең көтүгә?
Баяр пүнәтәйләр белән килмәкче
Була диме безгә тентүгә?

Староста

Безнең көтүләр, йөри торгач,
Баяр җиренә барып чыкканнар.
Анда чыгып җитәр-җитмәс,
Хезмәтчеләре аларны тотканнар.

Мулла

Хурлык! Ничек алар җөрьәт иткән?
Кемнәр анда эшнең башында?
Тотылган маллар өчен алар
Мәсьүл булыр урәтник каршында!

Староста

Әгәр маллар гына харап булса,
Берни булмас иде аңардан.
Ахры, баяр бераз «төрткәндер»,
Станавайның да күзләре аларган.

Мулла

Юк, юк, хәзер миннән башка,
Сүз юк, алар барсы бергә – юлбашчы.
Кемнең шунда барып көтүне алып
Кайтырга көче җитә?
Үзем барам, сездән булмаса.
Кем батыр, шул барсын, куркаклар
Калсын...

Староста

Хәзрәт, без барыбыз да ризабыз...

Мулла

Кем баручы – бары да
Балта, сәнәк белән коралллансын!

Куштаннар

(*бергәләп*)

Сугышабыз, хәзрәт, барабыз!

Мулла

Бармы арагызда? Нинди
Егет, җанын кызганмыйча,
Алдан бара дошман каршына?

---

Мәсьүл – җаваплы.

Староста

Бездә байтак әле тимер
Куллы егетләр.
Алар куркак түгел, һәммәсен дә
Тик шатландырыр гына бу эшләр.
Менә бит мәзин малае Таһир бар,
Аны баш итеп җибәрсәк, нишләр?
Ул бит шактый гына батыр егет,
Җир давында да шөһрәт тапты бит.
Шуны җибәрик, юк исә баяр безне
Аяк астында таптый бит.
Мәзин риза булса, Таһир риза,
Аңар зур гына күсәк бирелсен.

Мәзин

Мин риза. Алла ярдәм бирсен
Һәммәсенә туган ил өчен.
Ләкин күршеләргә җәбер салмыйк,
Турылыктан читкә таймагыз.
Җәбер-золым итеп, киләчәктә
Вулыс каршында гаепкә калмагыз.

Мулла

Таһир, кил әле бире, күрәсеңме,
Безнең көтүне тотып япканнар.
Безнең авылны санга санамыйча,
Нинди эшләр эшләп ятканнар!
Җимерергә кирәк авызларын,
Шуңар синең көчең җитәрме?

Таһир

Хәзрәт! Җитәрме көч, җитмәсме көч,
Тик минем күкрәгемдә иман бар.
Һичнәрсәдән курыкмый сугышырга
Башы чукмарлы күсәк имән бар.

Мулла

(*аркасыннан сөеп*)

Рәхмәт, балакай, рәхмәт!
Җиңеп кайтсаң, сиңа илдән бүләк бар.
Бирешмә бер дә, каршы торучыларның
Башын күсәк белән яр!

Т а һ и р

Әйдә киттек, дуслар, баяр иленә!
Әхми, син кыстыр балта-пычак биленә.
Дер селкетеп кайтыйк үзләрен
Бергә-бергә!
Ат калдырыйк туган илгә,
Сагнып сөйләргә гомергә.

М у л л а

Ярый, Алла сезгә ярдәм бирсен,
Курку салсын явыз дошманга!

М ә з и н

Түземлек бирсен Тәңре җанга!

Б а р с ы  д а

Без барырбыз да хәзрәт кушканга!

Чыгалар.

М у л л а

(*торып тәрәзәгә килә*)

Ярый, мужиклардан тынычландым.
Бәлки, алып та кайтырлар, кем белә?
Чү! Абзар артында Зөһрә
Пыш-пыш сөйләшә кем белән?
Таһир – яшь бала, ләкин гайрәт,
Илгә куаныч.
Ходай никтер аны мәзингә
Биргән,
Тик шунысы бераз кызганыч!
Мәзин малае мулла булыр,
Ә минеке бит кыз бала.
Шул якларын уйлагач,
(*Күкрәген күрсәтеп.*)
Шунда әллә ниләр кузгала.

Урынына утыра. О с т а з б и к ә, аның артыннан К а р а  м а л а й керәләр.

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

М у л л а, О с т а з б и к ә, К а р а  м а л а й.

О с т а з б и к ә

Ишетәсеңме, ишет, колагың
Булса тишек!

Мулла

Җә, соң, ни булган? Ни бар?
Сөйләп бир, ничек?

Кара малай

Әнәтерәк, Таһир абый белән
Зөһрә апа
Абзар артында сөйләшеп ята...

Остазбикә

Ә син шуны да карамыйсың,
Син бит ата!

Мулла

Сөйләшсә ни булган ди?
Кияү булыр, яхшы булыр бигрәк,
Вота!

Остазбикә

Ах, бәхетсезлек, бәхетсезлек,
Рисвай булдык!

Мулла

Нинди рисвайлык, ни булган соң?
Юкка гына кайгыру – хата.

Кара малай

Хәзрәт, харап булдык,
Зөһрә апа белән Таһир абый тотылды,
Күрше егетләре кыйнамакчылар иде,
Бәхте әле, качып кына котылды.

Мулла

Булмас, булмас, мин моңарга
Ышанмыйм!

Остазбикә

Менә бит, Кара малай күргән!

Кара малай

Дөрес, хәзрәт, дөрес, ышан, дим.

Мулла

Тукта, мин берни дә белмим,
Кайда алар?
Таһирны да, Зөһрәне дә
Табып китерегез монда, бар!
(*Үзалдына.*)
Эшләр җайланганда гына
Кайнаталар бит канны!

Кара малай

(*чыгып барганда*)

Эш уңайлана,
Абыстай, тынычландыр җанны.

## ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Мулла, Остазбикә.

Мулла

Ниләр эшләнәләр бит яшертен,
Ә мин аны бүген бөтен яшьләргә
Баш иттем.

Остазбикә

Аңар син үзең ирек
Бирдең,
Бары да, бары да болар үзеңнән!
Әйтмәдемме Таһир турында мин,
Ерак ит дип шуны күзеңнән?
Тыңламасаң мине – менә хәзер
Сәбәп булдың үзең барсына!
Һичкемдә дә түгел, синдә
Гаеп...

Мулла

Тукта әле, син дә мине борчыма,
Барсана!
Уйла ләкин азрак, бәлки, монда
Без белмәгән серләр булгандыр,
Кем соң белә, бәлки, Зөһрә монда
Тәкатеннән читтә булгандыр.

Остазбикә

Әллә, тәкъдир шулай булгандыр дип,
Ризалыкка күңлең тартамы?
Әллә Зөһрәбезгә тапмабызмы
Мәзин улларыннан башканы?
Уйлап кара дәрвиш мәзинеңне,
Элек көтү көткән түгелме?
Нәсле нинди аның, каны кайдан?
Каткан мужик нәсленнән түгелме?
Бүген таңда миңа пар ат җигеп
Данлы байлар тора килергә.
Ә бу кем соң, мәзин улы?
Сорыкорт булып калыр гомергә.
Нәрсә? Әллә шулай мәчетләрең
Үзеңнән соң вәйран ятармы?
Бабайлардан калган мөнбәреңне
Кара мужик – Таһир таптармы?
Кызыңны әллә шуңар бирерсеңме?
Акылыңдамы син, түгелме?
Әгәр бүген тотып кыйнатмасаң,
Әзерләгез миңа гүремне!

Мулла

Ие, шулай, шулай, кичмәм* аны,
Ул бит мине мәңге каралый.
Ах, бәдбәхет! Үтерә, җаным чыга,
Гомерлеккә мине яралый.

## СИГЕЗЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Таһир, Зөһрә, Староста, Кара малай, мужиклар, куштаннар керә.

Таһир

Хозурыгызга килдек, хәзрәт,
Әмрегезгә әзер торабыз.

Мулла

Кабахәтләр, гөнаһ җыючылар!

---

* Кичмәм – кичермәм.
Вәйран яту – җимерелеп яту.
Мөнбәр – мәчеттәге кафедра, алга чыгып уку урыны.

З ө һ р ә

(*артка чигә*)

Ах, нинди сүз!
(*Күзен каплый.*)

М у л л а

Җыла, җылагыз!

К а р а  м а л а й

Җә, җылагыз инде, мулла абзый куша ич!

М у л л а

Җылагыз кан-яшь белән, оятсызлар!

Т а һ и р

Тукта әле, хәзрәт, сез ни сөйлисез?
Нигә мондый әллә нинди көйләр көйлисез?
Кемгә ул андый сүзләр?

Зөһрәне күрсәтеп.

Җылый, әнә күрәмсез?

М у л л а

Нәрсә сөйлиләр бит, хәясызлар!
Әйтерсең лә бары да сөттән ак!
Барсын да беләм, барсын беләм.
(*Зөһрәгә.*)
Качма миннән, әйдә мондарак!

Зөһрә җылый.

Ник дәшмисең? Әллә рисвайлыктан
Йөзең кызара?
Нинди хурлык!
Синнән бары да болар, явыз кыз бала!

З ө һ р ә

Әткәй бәгърем, сезгә ни булды?
Миңа нинди яла ягалар?
Ант итәм мин, әткәй, бер гаебем юк,
Шаһитым бар – кәҗә, сарык, атлар, арбалар!

---

Х ә я с ы з – оятсыз.

М у л л а

Чү! Намуссыз, пычрак телең белән
Мине тәхкыйрь кыласың!

К а р а   м а л а й

Әй, җылатма инде, мулла абзый,
Зөһрә апа җылый.

М у л л а

Җыласын!

З ө һ р ә

Әткәй бәгърем, әнкәй, әйт,
Нәрсә бар?

О с т а з б и к ә

(*төртеп җибәрә*)

Кит! Бездән сиңа
Дога юк!
Мәңге сине кызым диясем юк!

З ө һ р ә

Бары да беттемени шулай ук?

М у л л а

Җә, әйт, Таһир, танма,
Зөһрә белән йөримсең?

Т а һ и р

Ие, сөйдем, хәзрәт, сөйдем мин,
Ләкин сезнең күк аны хәясызлык
дия алмыйм.
(*Зөһрәне тота.*)

М у л л а

Җитәр, җитәр, кая кулың суздың?
Кемнең кулын тоттың, күрәмсең?
Син ул кызның мулла кызы икәнен
Беләмсең?

---

Т ә х к ы й р ь   к ы л у – хурлау.

Т а һ и р

Беләм, хәзрәт, беләм, монда гаеп
Юк бит әллә ни,
Зөһрә мине сөя, мин – Зөһрәне,
Аермагыз без бәндәне.

К а р а  м а л а й

Мин бик риза, Таһир абый
Чәйлек бирсә җәлләми.

М у л л а

(*Зөһрәгә*)

Сөйлә, син дә шуңар
Алдандыңмы? Ник дәшмисең?
(*Көлеп.*)
Бәлки, ялгандыр?

З ө һ р ә

Ие, әткәй, сөйдем, ул да мине.
Нишлик, тәкъдир шулай язгандыр.

Т а һ и р

Җылатмагыз, аның авазыннан
Бишектәге бала уяныр.
Күзләреннән аккан яшьләр белән
Француз яулыклары буялыр.
Мактанмагыз алай байлык белән,
Бездә дә бит байлык җитәрлек.
Кичә генә әле базардан унике аршын
Ситсы алдым,
Күрсәгез, бөтенләй искитәрлек.
Муллалыкка указым бар,
Белмәсәм дә язу язарга.
Урын чыкмаса, сату итәм,
Спикүлянт булам базарда.

М у л л а

Җитәр, җитәр, ялынмагыз,
Тиз югалыгыз минем каршымнан!
Җүләр, соң шундый кытлык елда
Күлмәк тегәләрмени унике аршыннан!

Староста

Әллә, әллә риза буласызмы, хәзрәт?
Аның атасы бит – изге карт.
Монсы – кызың, монсы улың булсын,
Хөкмеңне бераз йомшарт.
Бергә-бергә гомер иткән,
Бозылышырга бер дә кирәкми.
Менә үзем тамга җыярга өстемә
Алам.
Күрше авылга мулла кирәк, ди.

Остазбикә

Сезгә нәрсә кирәк? Тыгылмагыз
Мулла эшенә.

Староста

Җә, риза булыгыз инде,
Яманатыгыз чыкмасын кешегә.

Мулла

Юк, юк, ялынмагыз, алыгыз
Шуны каршымнан!
Бар, чакыртыгыз дисәтник!

Остазбикә

Мулла буласы булгач,
Бирикме әллә?
Алдын-артын да исәплик.

Мәзин йөгереп керә.

Мәзин

Әссәламегаләйкем,
Хәзрәт!
Сабыр итсәгез булмасмы әзрәк?
Мин улыма дип акча җыйган идем,
Фидияләрне сатып әзерләп.

Мулла

Алай ничек булыр икән соң?
Ил картлары, сез ни дисез?
Әгәр мин кызымны Таһирга бирсәм,
Минем указыма тимәмсез?

Староста

Юк, юк, хәзрәт, тимәбез,
Һичбер сүз дә димәбез.
Башка авылга мулла итеп куярга
Сезнең өчен үзебез димләрбез.
Ә менә, шаять, риза булыр мәзин
Абзый үзе дә?

Мәзин

Ярый, ярый, мин риза,
Чыкмыйм халык сүзеннән.
Минем бар курыккан нәрсәм –
Төшү халык күзеннән.

Мулла

Ярый инде алайса, фатиха,
Без дә, ахры, күнәрбез,
Картлар туй итешеп бирешсә,
Ахырдан бер түләрбез.

Мәзин

Шыр тилемә кыз алдым –
Сөендем дә куандым.

Мулла

Синекеннән биш битәр –
Бирдем исә котылдым.

Пәрдә.

## КОНТРОЛЬ БУДКАСЫ

БЕР ПӘРДӘДӘ

Кич. Завком алды. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә дежурный Эшче.

Эшче. Их! Иң көчле, нык, тырыш, иң эшлекле, яхшы сыналган, чыныккан егетләрне генә сайлап җыеп, бер удар бригадасы төзесәң иде дә, эшләп чыгаруны йөз илле процентка күтәреп, бракны бер генә процентка калдырып эшләсәң иде. Аннан соң фабкомга барып керсәң дә, бюрога барып керсәң дә исемеңнең кызыл тактага язылганын күрсәң иде. Шуннан соң гәзитләрдә «Батыр Гәрәй бригадасыннан үрнәк алыгыз!» дип язып та чыгарсыннар иде. Их! Барлык ялкаулар, эчкечеләр, прогулчыларның барысының да борыннары салынсын иде. (*Койма ягына таба карап.*) Кемдер койма аркылы керергә азаплана бугай. Әй! Тукта! Кем бар анда? Нигә койма аркылы йөрисез? (*Кычкыра төшеп.*) Һәй! Нигә койма аркылы йөрисез, дим?! Тукта! Кем бар анда? Пропускың бармы? Юк исә хәзер карга шикелле итеп атып төшерермен бит! (*Мылтыгын төзи, затворын корып чыгып китә.*)

Техрукны өстерәп алып керә.

Мин койма аркылы йөрүче кеше булырсыз дип һич тә уйламаган идем. Сез ни өчен техрук була торып, алай, мәче шикелле, койма аркылы йөрисез? Сезнең өчен капка бар бит, фабрикка, бигрәк тә кич белән контрольгә күренмичә керергә ярамаганны үзегез дә бик яхшы беләсез бит?

Техрук. Зинһар, шул контроль турысында сөйләмәгез әле. Шул контроль дигән сүзне ишеткәч тә, контроль комиссиясе исемә төшә дә, күз алларым караңгыланып китә.

Эшче. Нигә ул кадәр курыктыгыз? Бөтенләй төсегез качкан бит.

Техрук. Ничек, төсем качкан дисезме?

Эшче. Ие. Төсегездә бөтенләй кан әсәре дә калмаган.

Техрук. Ә, алай гына булса бик күп зарар юк. Әле анда контроль комиссиясендә аннан да куркынычра-

гын әйттеләр: «Синдә партиецлыкның һичбер исе дә калмаган», – диделәр. Менә шунысы бигрәк начар. Мин шулай ук булдыммы икәнни?

Э ш ч е. Икенче бишьеллык белән ант итеп әйтәм, бик дөрес әйткәннәр.

Т е х н о р у к. Син «бишьеллык белән» дисең әле. Мин контроль комиссиясендә Карл Маркс белән дә ант итеп караган идем, алай да ышанмадылар. «Синдә бөтенләй партиецлыкның исе дә калмаган», – диләр, шулай ук булдыммы икәнни?

Э ш ч е. Сез миңа гына ышаныгыз: әгәр дә ялган сөйләсәм, күзләрем маңлаемда да булмасын. Сез бөтенләй эштән чыгып беткәнсез!

Т е х н о р у к. Син миңа аттың бугай? Бөтенләй котымны алдың. Бер дә юкка кешене үтерерсең бит.

Э ш ч е. Мин атмадым. Бюродагы үзара тәнкыйть шикелле шартлаттым гына. Безнең бюрода да бит кайвакытларда шулай борчак аткалыйлар, ләкин нәтиҗәсе чыкмый кала. (*Пауза.*) Туктагыз әле, сезне шулай койма аркылы йөрергә нәрсә көчләде соң әле?

Т е х н о р у к. Тс-с-с! Акрын! Мин «промфинпланны тутырып, икенче бишьеллыкның промфинпланын каршылау» дигәннән куркам. Менә мине шулар саташтырып йөртәләр.

Р а д и о. Алло!.. Алло!.. Алло!.. Каршылау планы... фабригына да килеп җитте!

Т е х н о р у к (*куркып*). Нәрсә ди?.. Нәрсә ди? Килеп җитте, диме? Әйттем бит мин сезгә! Мин... мин... тизрәк бюрога!

Р а д и о (*Хасбулат көенә*).
Яңгырат, дулкын,
Шаулат син илне!

Э ш ч е (*кушыла*).
Үзәк Комитет
Промфинпланны
Тутырырга дип
Директив бирде!

Т е х н о р у к. Промфинплан?
Җитмәсә тагы, каршылау планы
Безнең фабрикка мине эзләп килде!
Куркам, шикләнәм, кабинетка барып
Тизрәк бикләнәм, тизрәк бикләнәм!

(*Ашыгып чыгып барганда күзлеген төшереп калдыра. Ишектән кереп барганда Г а л и я г ә бәреләә.*) Күзлексез бернәрсә дә күрә алмыйм. (*Галиянең кулындагы себеркегә күзе төшеп.*) Моның белән ни эшлисез?

Бию кѳе уйнала.

Г а л и я. Себерәм, тазартам.

Т е х н о р у к. Кемнәрне? Нәрсәне? (*Чыга.*)

Г а л и я. Чытык йөзләрне, сукыр күзләрне
Тимер себерке себерер, эштә өмитсезләрне, –
Кемнәр ышанмый промфинпланга,
Ударчылыкка, сыйнфый коралга.
Техноруклар да себерелер,
эшкә ялкау булганда.
Прогулчыларны, барлык ялкауны,
Ырвач, летунны җуяр, юк итәр.
Кемнәр куркаклар, кемнәр ясыйлар
Эштә өзеклек, чыгарып* браклар, –
Тимер себерке себерер барысын,
Себерә-себерә дә шактый арырсың.

Тукта әле, болай сөйләнеп торып кына эш чыкмас, тизрәк җыештырырга кирәк.

Э ш ч е. Җыештырырга дисеңме? Сиңа соң әле болай ни өчен алай җыештырырга кирәк булды?

Г а л и я. Чүп-чарлар бик күбәйгән.

Э ш ч е. Дөрес! Фабрикта эшкә яраксыз чүпләр бик күбәйгәннәр. Менә атаклы прогулчы ...ләргә** әллә кайчан инде фабриктан себерелеп түгелергә вакыт иде дә бит, әле һаман да себерелеп түгелмиче йөриләр.

Г а л и я. Түгелерләр, берсе дә калмас! Их... их... их! Мондагы чүпләр! Бер дә юк нәрсә юк! Әллә нинди хәшәрәтләр... Күзлекләргә кадәр бар.

Э ш ч е. Нинди күзлек?

Г а л и я. Аның нинди икәнен кем белә? Болай үзе карап торырга алсу күзлек.

Э ш ч е. Ә! Аны чыгып барганда технорук югалткан иде...

Г а л и я. Әй, кара әле, әйт әле, зинһар, ни өчен ул безнең технорук алсу күзлектән йөри икән, ә?

Э ш ч е. Бар нәрсә дә күзенә алсу булып күренсен өчендер.

Г а л и я. Әгәр дә бу күзлекне мин кисәм?

Э ш ч е. Синең күзеңә дә барлык нәрсәләр алсу булып күренерләр, шулай ук мин дә алсу булып күренермен.

Г а л и я (*күзлекне киеп*). Ай-яй-яй-яй! Син нинди матур! Бөтенләй гашыйк булырсың! Ә менә бу – (*Халык ара-*

---

* Авторда: чыгуга.

** Бу урында фабриктагы атаклы прогулчы исеме әйтелә. – *Г.Камал искәр.*

*сыннан бер картны күрсәтеп.*) кап-кара кашлы, кара күзле, сызылып киткән кара мыеклы япь-яшь бер егет.

Эшче. Анысын инде оптический обман, диләр.

Галия. Ничек ул алай? Күзлек оптым иләйһи алдалыймыни? Нәрсә генә сорарга теләгән идем соң әле? Ә... исемә төште. Сез белмисезме, миңа кайдан бераз корт табарга мөмкин булыр икән? Бик кирәк иде.

Эшче. Корт дисеңме? Син бигрәк юк нәрсәгә аптырыйсың икән. Аны безнең фабриктан теләгәнең кадәр табып була. Әнә теге ялкау Галимнең ике айдан бирле инде станогын тазартканы юк, бөтенләй кортлап беткән.

Галия. Юк ла, мин аны әйтмим, миңа бит сөттән ясаган корт кирәк.

Эшче. Хәер, анысын мин белә алмыйм.

Галия. Аннан соң тагы бераз гына булса да мариновать ителгән нәрсәләр булса да зарар итмәс иде.

Эшче. Мариновать ителгән нәрсәләр кирәк булса, аларның байтагын безнең фабкомнан табып булыр. Әгәр дә ул гына җитмәсә, производство киңәшмәсеннән сорап карарсың. Аннан табарга мөмкин булыр дип беләм. Анда эшчеләрнең шактый гына кыйммәтле тәкъдимнәре мариновать ителәләр. Эшкә ашырылмыйча сөрсиләр.

Радио. Тыңлагыз, тыңлагыз, тыңлагыз! Бюроның производствога салкын каравы аркасында, ... фабригында ...лык план ... процент кына тутырылды. (*Нинди урында куелса, шул урындагы саннар күрсәтелер.*) Партия ячейкасы һәм ударниклар тревога бирәләр, тревога! (*Сигнал гаскәри тревога уйный.*) Производствога массаның игътибарын туплап, берничә өлеш көчәйтелгән энергия белән хәзергә кадәр булган өзеклекләрне бетерергә, товарның сыйфатын яхшыртырга! (*Тревога.*) Әй, батыр егетләр! Ударниклар! Каршылау планын бөтен цехларга, барлык бригадаларга, һәрбер эшчегә җиткерү безнең бурыч булсын! (*Тревога.*)

Каршылау промфинпланы керә.

Каршылау промфинпланы. Мин килдем сезгә эшләр тикшерергә, юкмы икән дип өзеклекләр сезнең цехларда!

Эшче. Әй, иптәш, тукта, кая барасың? Пропускың бармы?

Каршылау. Нигә булмаска, бар. Ләкин озаклап, сөйләшеп торырга вакытларым тар. Син, иптәш, соңга калдың миннән сорарга. Мин киләм пропускысыз бөтен фабрик буйлап удар ялкыннан туганга. Бөек елдай эре саннар

белән летуннарга каршы ут ачам. (*Пауза.*) Кемнәр ялкау, кемнәр ышанычсыз карый безнең планга? Хәйлә чире белән авыручылар, ялкаулар, прогулчыларны эшче буксирына, тәнкыйть утына! Төзәлмичә аша барса, яңа төзелеш аңар ошамаса, китә бирсен ата-бабасыннан калган иске йортка. Тәҗрибәгә тәҗрибәне кушып, эшче тәкъдимнәренә тапкырлап, промфинпланны тутырып, каршылап, барлык цехларны чакырырга кирәк бердәмләшеп, удар темпны бәйләп ярышка!

Эшче. Нигә соң син аны башта ук әйтмәдең шулай дип? Әйдә, иптәш, бик вакытлы килдең, барысын тикшер, барысын карап чык. Исерекләр, ялкаулар, летуннар, ялган авыру белән авыручыларны барлап, санап чык.

Галия. Юк, иптәш, син бүген генә аларны тикшереп бетерә алмассың, аларны исәпләп. Аларның, прогулчыларның, ишләре безнең фабрикаларда дистәләп. (*Прогулчылар белән летуннарны саный.*) Калган летуннарны санап та тормыйм, алар барыбер бүген килмәсләр. Чөнки алар кайда төшем күбрәк булса, шунда чабалар. Алар өчен бары тик спецкием, икмәк-забор карточкасы, тагы башка шундыйларны алырга гына булсын. Ә менә болар – (*исемлек укый*) ялган авыру белән авыручы симулянтлар. Аннан башкаларын үзең санарсың.

Эшче. Бүген без аларның барысын да бирегә җыярбыз.

Галия. Син аларны ничек итеп җыярсың икән?

Эшче. Мин аларны ничек итеп җыярга икәнен үзем беләм. Алар үзләре дә үзләренең ничек җыелганнарын да сизми калырлар.

Каршылау. Ярый алайса, анысын үзең кара, кулыңнан килгәнне эшлә. Сыйнфый сызыктан чыкма. Мин тагы алга!

Марш уйнала.

Эшче. Кемнәрдән генә башларга?

Галия. Летуннардан башла. Алар бит канатланып очалар. Барысыннан да тизрәк очып килеп җитәрләр.

Эшче. Сынап карыйк. (*«Эшче көчләр җитми» дигән язу элеп куя.*) Менә әгәр дә шушы язуга да килмәсәләр, башымны кисәргә бирәм! Тс-с! Әйттем бит, әнә килеп тә җитте.

Канатына «подъемный» дип язылган.
Яшеренеп кенә Летун керә, як-ягына карана. Музыка ... уйный

Летун. Минем өчен кайда да бер, –
Бүген – монда, иртәгә – анда.

Тик акчасы булсын бераз,
Калганы миңа ерунда!
Трррам, траррам,
Калганы миңа ерунда! } (*2 тапкыр*)

Бу фабрикка эшче көче җитми дип язылып куелган икән, бик шәп, бик шәп! (*Эшчегә.*) Иптәш, рәхим итеп, мине эшкә алып җибәрегез әле. Мин – менә дигән мездрильщик[1].

Э ш ч е. Безгә бит мездрильщик кирәкми, сортировщик кирәк.

Л е т у н. Анысы минем өчен ерунда! Мин ул эштә 16 ел, то есть 16 ай, то есть 16 атна эшләдем, ... нче категория белән жалованье алып килдем. Кара әле, иптәш, сездә ничек, спецкием бирәләрме? Жалованье хисабына алдан аванс бирәләрме?

Э ш ч е. Сезгә ничек дип аңлатырга кирәк, мин сезгә сортировщик кирәк дип ялгышрак әйткәнмен икән. Безгә сортировщик кирәкми икән, җуеш скабачы[2] кирәк икән.

Л е т у н. Анысы нечего! Җуеш[3] булгач, эссе табасында эшләргә мөмкин! Аяк-кулларны пешерми торгандыр бит? Билгеле, юк. Мин ул эштә бик күп еллар эшләдем. Кара әле, сездә 1 л. икмәк карточкасын эшкә керүдән берничә көн алдан ук алып куеп була торгандыр бит?

Э ш ч е. Аны алдан алып куюның нигә кирәге бар?

Л е т у н. Юк, болай гына әйтәм, алданрак алып куйсаң, задатка шикелле булыр иде, дим. Хәзер бит һәр җирдә промтоварга да, киемнәргә дә, утынга да, яшелчәләргә дә авансларны алдан ук алып куялар бит.

Э ш ч е. Ярый. Мәсьәлә аңлашылды. (*Халыкка карап.*) Күрдегезме, шәп кош бит? Кайда симезрәк ит күрсә, шунда кунып йөри торган песнәктән бер дә ким түгел. Иптәшләр! Яхшы карагыз, илләреннән сөрелгән спекулянтлар, кулаклар, буржуй малайлары, эшче киеменә төренеп, кайда күбрәк чиертсә, шунда кунып йөриләр. Алар өчен эшче көчләр җитмәү дә, бюролар да, кооперацияләр дә – барысы да савым сыерлар гына. Летуннар – алар фабриклар өчен әрәмтамаклар гына! Аларга бары тик спецкием булсын да, 1 нче категория икмәк-забор карточкасы алып сатсыннар гына. Летуннар – алар чын күңелдән эшләүче эшчеләрнең хакларын ашаучы караклар гына. (*Летунны якасыннан тотып, төртеп чыгара.*)

Г а л и я (*биеп, себерке белән себереп, җырлый*).
Себер, себер, себерке!
Фабрикта чүп калмасын.
Урын сайлап йөрүчене
Һичкем эшкә алмасын.

Себер, тимер сeберке!
Себер, барсын тазала.
Очып йөргән летуннарны
Эш бирмиче җәзала!

Эшче. Ярый, Галия туган, хәзер инде кармакны эчүчеләргә салып карыйк әле.

Галия. Карап карыйк әле, син аларны ничек итеп тотарсың икән?

Эшче. Эчүчеләрнеме? Мин аларны градусник белән тотам. Иң яхшы юл шул. (*Градусникны элеп куя.*)

Галия. Ни өчен градусник белән?

Эшче. Бар белгәне: ни өчен дә ни өчен! Мин синең өчен анкетамы әллә? Һаман сорыйсың да сорыйсың. Менә хәзер ни өчен икәнен үз күзең белән күрерсең. Аннан соң ни өчен икәненә үзең дә төшенерсең.

Исерек керә.

Әнә килеп тә җитте.

Исерек (*градусникны күреп*). Кырык градус, ә... Их, минем сорокоочкам! Тик син ни өчен бутылкада түгел, ә? Ни өчен син кызыл башлы бутылкада түгел?

Эшче. Кулыңа эләккәнне төшерә бир!

Исерек. Бу нәрсә соң? Тилегән маемы?

Эшче. Юк, терекөмеш, ртуть.

Исерек. Аны эчәләрме?

Эшче. Эчәләр.

Исерек. Нәрсә белән?

Эшче. Теләсәң нәрсә белән.

Исерек. Мин стакан белән эчәргә яратам.

Музыка уйный, Исерек җырлый.

Без эчәбез тилгән маен,
Эш кала дип тормыйбыз.
Бүтән эшкә исебез китми,
Ду кучереп җырлыйбыз!

Галия (*йодрык күрсәтеп.*) Ә менә моны яратасыңмы?

Исерек. Аны эчәләрме соң?

Галия. Юк, эчмиләр, салалар гына.

Исерек (*авызын күрсәтеп*). Мондамы? Менә монда салалармы? Җә әле, якынрак китер әле!

Галия. Үзең якынрак кил.

Эшче (*йодрыгын йомарлап*). Әгәр дә менә мин салсам, кабыргаларыңны да җыеп ала алмассың!

Исерек. Нәрсә, әллә сез сугышырга уйлыйсызмы? Нигә сугышырга кирәк? Әгәр дә сугышырга теләсәгез, менә

сезгә күкрәк, эшче күкрәге! Җә, кайда, кем белән, нәрсә өчен сугышырга?

Э ш ч е. Промфинплан өчен.

И с е р е к. Ә? Промфинплан? Аны эчәләрме?

Э ш ч е. Юк, эчмиләр, тутыралар гына.

И с е р е к. Эчмәгәч, аның өчен нигә көрәшергә! (*Җырлый.*)

Көрәшмибез юк өчен,
Баш ватмыйбыз план дип.
Тилгән мае эчеп алсак,
Хәтерлибез «апаң» дип.
Кем сугыша план өчен,
Кем әйтә: «Аны тутыр», – ди?
Безнең өчен барсы пустәк,
Эчсәк ярты литрны.
Нигә кирәк соцдоговор?
Договорсыз да эчәбез.
Бер стакан эчеп алсак,
Җәяү диңгез кичәбез.

Г а л и я (*шешәнең авызына бер кәгазь тыгып, исереккә бирә*). Мә, эч!

И с е р е к (*шешә эченнән кәгазьне алып*). Моны эчәләрмени?

Г а л и я. Юк, аны эчмиләр, укыйлар.

И с е р е к. Менә инде анысы булмый! Мин укырга бик шәпләрдән түгел. Электә укыганнарымнан да бары тик градус кына хәтеремдә калган.

Г а л и я. Китер алайса, үзем укыйм. (*Кәгазьне алып укый.*) «Кайбер эшчеләрнең эчүләре аркасында, безнең цехта товарның сыйфаты начарлана, эш чыгару проценты кими, брак күбәя. Үзләрен үз эшләрендә җаваплы дип санамаулары аркасында, фабрик зарар итә». (*Мөмкин булганда, боларның барысын да цифрлар белән күрсәтергә кирәк.*)

Тыңлагыз! Тилегән мие эчеп, диңгезне җәяү кичүче батырлар менә шулар. (*Эчеп, прогул ясаучыларның исемлекләре укылыр.*) Безнең цехтагы (безнең фабриктагы) промфинпланын тутырырга комачаулаучы прогульщиклар менә шулар.

Э ш ч е. Син аны нәрсә өчен укыйсың?

Г а л и я. Ничек «нәрсә өчен»? Эшчеләр үз араларында булган корткычларны белеп торырга тиешлеләр.

Э ш ч е. Дөрес, Галия. (*Исерекне күрсәтеп.*)

Менә мондый матурларга,
Аяк өстән йоклаучы батырларга

Каршы каты, нык көрәш кирәк,
Күмәкләшеп, бергәләшеп көрәш кирәк!
Аларны – эшче буксирына, тәнкыйть утына!
Эштә өзеклек ясап, исерек халык
Тап төшерә безгә, зарар итә совет портына.
Эчә дә ул, исереп «баеп» ала,
Прогул ясый атна-ун көннәр;
Эш планы тулмый, артка кала,
Йөз урынына сиксән каплана.
Гәзит-журналлар аша
Эшне барлау безгә бурыч булсын.
Барлык исерек бүген – кара тактага!

Г а л и я. Дөрес, иптәш, гәзит-журналлар аша эшләрне барлап тору эшкә зур булышлык итә. (*Исерекне күрсәтеп.*) Менә мондый халыкларны да рәткә кертә. Аларның төзәлүләренә ярдәм итә.

Э ш ч е. Ярый, инде хәзер иң соңгы хәбәрләр белән иптәшләрне таныштырырга кирәк.

Г а л и я. Нинди хәбәрләр белән?

Э ш ч е. Менә гәзиттә бик кызык хәбәрләр бар. (*Гәзитне карап.*) Профессор Бизе[4] Төньяк боз диңгезендә яңа бер атау эзләп тапкан – утрау ачкан.

Г а л и я. Исең киткән икән. Утрау ачкан, имеш. Менә ул, әгәр дә бик шәп кеше булса, безнең комбинатка яки фабкомга килеп, бер генә тапкыр булса да вакытында җыелыш ачып карасын иде.

Х а л ы к  а р а с ы н н а н  б е р ә ү. Карагыз әле, иптәш, ни өчен исерек кеше турысында сөйләгәндә, «бер тиенлек эчеп, ун тиенлек исергән» диләр?

Э ш ч е. Юк, иптәш, сез ялгыш әйтәсез, ул ун тиенлек кенә исерми.

Х а л ы к  а р а с ы н н а н  б е р ә ү. Мин аның производствога китергән зарарын әйтәм.

Э ш ч е. Мин дә зарарын әйтәм шул. Аның зарары ун тиенлек кенә дә, бер тәңкәлек кенә дә булмый. Аның аркасында булган прогулларны, эшләп чыгаруларның кимүләрен, аның өстенә товарның начар булып чыгуларын да кушсак, зарар берничә мең сумнарга җыела. Эчүченең бала-чагалары ач кала. Завод-фабрикларның вакытында ягу нәрсәләре, чималлар җитештерүләренә киртә була. Аңлашылдымы?

Х а л ы к  а р а с ы н н а н  б е р ә ү. Аңлашылды.

Э ш ч е (*исерекне күрсәтеп*). Ә менә моңар аңланмады. (*Исерек янына барып.*) Моны кая куярга инде? Будка эченә кертеп ташларгамы? (*Күтәрмәкче була да, борынын тотып.*) Фу! Бигрәк хуш исле чәчәк икән. Моның исен иснә-

сәң дә исерерсең. (*Күтәрә алмый.*) Моны җәмәгать буксирына алмыйча булмас, ахры. (*Будкага өстери башлый.*)

Исерек (*авыз эченнән*). Мин, мин... үзем... дүрт аяклап булса да барам...

Эшче. Юк инде, туганкай, алдыйсың! Социализмга болай синең шикелле дүрт аякланып барып булмый. (*Исерекне төрткәләп чыгарып җибәрә.*)

Галия. Миңа тагы җыештырырга, тагы себерергә эш чыкты.

Музыка.

Себер, себер, себерке, фабрикларны чистала,
Кемнәр эчеп прогул ясый жалованье алган числода, –
Тимер себерке белән себерик – барысын тазалыйк,
Эштә өзеклек ясаучының барысын да җәзалыйк.

Телефон шалтырый.

Эшче (*телефонда*). Ие. Нәрсә? Туктатырга? Кемне, нәрсәне туктатырга? Темпны? Нинди темпны? Бишьеллыкны? Соңга калдыгыз инде. Без инде күптән икенче бишьеллыкны башладык. Кем сөйли моны? Троцкийчымы[5] әллә? Юк. Алай булгач, кем соң? Уң оппортунистмы? Кем? Кулаклыгы бетерелгән кулакмы? Түгел? Чорт белсенме сезне? Сез барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән халыклар! Ахмак син! Темпны акрынайтырга ярамый. Аңар һичбер ударник та, һичбер эшче дә, һичкем дә риза булачак түгел!

Радио. Тыңлагыз! Тыңлагыз! Тыңлагыз! Каршылау планы бишьеллыкның ахырыннан 150 процентка күтәрүне сорый. (*Пауза.*) Тыңлагыз, тыңлагыз... Безнең ... фабригы белән ... фабригы арасындагы ярышларда ... иптәш бригадасы иң беренче санала. Чөнки бу бригада бирелгән заданиене үтәүне 276 процентка җиткерде. Ударниклар! Барыгыз да социализм ярышын җәеп, киңәйтеп җибәрүне хәтерегездән чыгармагыз! Удар бригадалары оештыру көндәлек бурыч булсын. (*Саннарны урыннардагы бригадалардан алырга кирәк.*)

Эшче. Җә, Галия, инде кайсыларын кармакка эләктерәбез? Әйдә, булмаса, симулянт – ялган авыручыларга кармак салып карыйк. Хәзер яз! «Амбулатория. Барлык яшерен авыруларны, хәзергә кадәр һичбер докторлар да эзләп таба алмаган авыруларны таба торган амбулатория. Бюллетень дә шунда ук бирелә» дип яз.

Галия. Аңладым. (*Яза.*) «Амбулатория. Барлык авыруларны карый. Әлегә кадәр бер доктор да таба алмаган авыруларны таба торган амбулатория. Бюллетень дә шундук бирелә».

Э ш ч е. Булдымы?

Г а л и я. Булды. Хәзер бетте.

Эшче тиз генә вывесканы әлә дә ак халат кия.
С и м у л я н т керә. Яңагын бәйләгән. Ике култык таягына таянган.
Кесәсеннән рецептлар ала.

С и м у л я н т. Гражданин доктор, ярдәм итегез. 1905 елдан бирле авырыйм. Ышанмасаң, табан астыннан сора.

Э ш ч е. Нәрсә? «Сора» дисезме? (*Таяк белән табанына сугып карап.*) Ни өчен сез култык таягыннан йөрисез? Сезнең аягыгыз нишләгән?

С и м у л я н т. Һай, сорамагыз, доктор, минем үкчәләрем артка әйләнгән. Никадәр генә дарулап карасам да, һаман артка әйләнгән көенә тора. Һичбер төзәлергә исәбе юк.

Э ш ч е. Ә борыныгыз җилкәгезгә әйләнмәгәнме тагын? Гаҗәп, бик гаҗәп, мондый авыруны гомеремдә беренче тапкыр күрәм.

С и м у л я н т (*тавышын үзгәртеп*). Нәрсә инде, куегыз әле, зинһар, шул кыйланууыгызны! «Беренче тапкыр күрәм», имеш. Һәр көнне больницага йөрим ич! Хәмидә Алдарованы белмисезмени? Мине монда гына түгел, родильныйда да беләләр инде. Ышанмасагыз, андагы акушеркалардан да сорагыз.

Э ш ч е (*корсагына сугып*). Соң, хәзер авыруыгыз юкмы?

С и м у л я н т. Карагыз әле, доктор, сез мәсьәләгә якынрак килегез әле. Менә шушы бюллетеньгә генә пичәт басып җибәрсәгез, ихтимал, бераз җиңелрәк булыр иде. (*Җырлый.*)

Больнис саен һәр көн чабам,
Докторың – ахмагың һич белмәс.
Айлар, еллар отпускы алам,
Ялганым – алдавым ул белмәс.
Ха-ха-ха-ха! Тагын алдыйм ла!
Докторың – ахмагың һич белмәс.
Пивной саен чапсаң иде,
Дусларым-ишләрем, бер эшсез.
Меңнәр акча тапсаң иде,
Дусларым-ишләрем, кул көчсез!
Бирсәң бюллетень, мә, ал илле тиен,
Докторым – дускаем, кеше сизмәс.

Э ш ч е (*кәгазь биреп*). Мә, ал!

С и м у л я н т (*кәефсезләнеп*). Нәрсә, рецептмы? Хөрмәтле доктор, сез минем һәрбер кесәмдә берәр йөз рецепт бар икәнен белмисез, ахры? (*Кесәсеннән бик күп рецепт алып, кулын югары күтәреп идәнгә сибә.*) Миңа нәрсәгә

сезнең латинча язылган кәгазьләрегез кирәк соң? Миңа аларның сукыр бер тиенгә дә кирәге юк. Әгәр дә хәзерге көнгә кадәр миңа бирелгән төрле тамчыларның, төрле даруларның барысын бер җиргә түгә барсаң, көймә белән йөзәрлек бер күл булыр иде. Мин аларны кайсы аптиктән алсам, шуның янында түгеп калдырам. Ә син тагы миңа рецепт бирәсең.

Эшче. Мә, син иң элек укып кара әле.

Симулянт. Әйтәм бит, нигә кирәк миңа синең латин белән язылган язуларың! Миңа урысча язылган бюллетень кирәк.

Галия. Китер, үзем укыйм. (*Укый.*) «Хәмидә Алдаровага һәр көн самокритика дигән компресс ясап, «Кызыл Татарстан» һәм фабрик гәзитләре аркылы кимендә ун укол кадарга. (*Башка урыннарда шундагы исемен әйтергә.*) Аннан соң да төзәлмәсә... төзәлмәсә... фабриктан чыгарып, саф һавада бераз җилләтергә!»

Эшче. Э... хәзергә без сине озак вакытлар онытмаслык итеп дарулыйк. (*Будканы күрсәтеп.*) Менә монда рәхим ит!

Симулянт (*тарткалашып*). Гражданин, товарищ, иптәш, нәрсә бу? Ни өчен сез авыру кешене болай газаплыйсыз? (*Читкә.*) Әгәр дә мин чыннан тотынсам, сезнең шикелләләрнең дистәсен бер сугуда бәреп егачакмын! (*Халыкка карап.*) Кайда соң безнең дуслар? Сабир, Шәйхи, Кадыйр, карагыз әле, сез нигә минем хәлемә кермисез? Сез дә минем күгүк симулянтлар лабаса! (*Култык таякларын ташлый.*)

Эшче. Мәсьәлә аңлашылды. Әйдә, рәхим ит! (*Төрткәләп будкага кертә.*)

Галия. Башкаларга ни булса ул, миңа тагы җыештырырга туры килә. Их! Тормыш дисәң тормыш! (*Җырлый.*)

Себер, себер, себерке, фабрикта чүп калмасын.
Әрәмтамак симулянтлар эшкә киртә салмасын.
Себер, себер симулянтны, ялтыратсын табанын,
Симулянтлар аптырасын туйдыра алмый тамагын.

Эшче. Җә, ничек, шәп тотаммы боларны?

Галия. Әйтерең бармы?! Безнең балык әзерләүче оешмалар да болай шәп тота алмыйлар. Кара әле, иптәш, кемнәрне әйтәләр әле һәрвакыт ком коеп йөриләр дип?

Эшче. Билгеле, корткычларны. Алар һәрвакыт безнең подшипникка ком салырга тырышалар. Ләкин без аларны да кармакка эләктерербез. Без дә аларга беренче числода ком сибәрбез. (*Җиргә ком сибә.*) Күр дә тор, хәзер килеп җитәр. Әнә килә дә.

Икесе дә яшеренәләр. К о р т к ы ч качып кына керә.

К о р т к ы ч. Беркем дә юктыр, ахры. (*Як-якка карана.*)

Сөйләгәндә көчле ялкын чәчәм,
Сәясәткә миннән бае юк.
Уңга, сулга куллар чайкыймын мин,
Эшләргә, дим, удар темп белән!

Ләкин болар бар да тыштан гына,
Ник барсы да утка очмый шунда.
Хәзер белдем барлык эч серләрен,
Үз халкыма хәбәр бирер, җимерермен!

Барлык фабрикларның көле күккә очар,
Шулай миңа әмер бирелгән,
Килер бер көн – җир тетрәтеп.
Туй, тантана ясап йөрермен.
Аннан соң эшчеләр өстеннән
Ничек хөкем йөртәсен белермен.

(*Комга күзе төшеп.*) Их, их, их! Нинди һәйбәт ком! Ни өчен сиптеләр икән моны?

Г а л и я (*яшеренгән җиреннән чыгып*). Ни өчен булсын, төзү эшләренә кирәк булган өчен.

К о р т к ы ч. Мин бер кызык нәрсә уйлап чыгардым әле. Ха-ха...

Г а л и я. Җәгез әле, миңа да әйтегез әле, нинди кызык уйладыгыз? Минем дә көләсем, минем дә күңел ачасым килә.

К о р т к ы ч. Менә шулай, бераз гына комны аласың да подшипникка илтеп саласың. Машиналар «шып!» туктый да кала.

Г а л и я (*җирәнеп карап*). Шәп кызык икән! (*Ачу белән.*) Бездә бу кызык саналмый. Хыянәт, производствога зарар, социализм төзү эшенә аяк чалу дип санала.

К о р т к ы ч. Нинди хыянәт булсын? Машиналар беразга туктыйлар да шау-шу бетә, ә без рәхәтләнеп ял итәбез. Аннан безгә ни зарар? Эш хакыбызны барыбер түлиләр бит.

Эшче читтән тыңлап тора.

Э ш ч е (*чыгып*). Син, Галия, кемгә сүз әрәм итәсең? Мондый кабахәтләр белән сөйләшеп торырга да ярамый. (*Корткычка якын килеп.*) Вон!!! Марш бире дән! (*Корткычны будкага җилтерәтеп кертеп җибәрә.*)

Р а д и о. Тыңлагыз... тыңлагыз... тыңлагыз! Донбасс

шахталарында корткычлар, контрреволюционерлар оешмасы ачылды. Алар, эшкә өзеклек ясау өчен, Донбасс шахталарында катастрофа ясаганнар. Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты партия оешмаларына, хуҗалык һәм профсоюз оешмаларына мөрәҗәгать итә. Производство заданиесен тутыруда кайбер җитешсезлекләр булуга да карамастан, барлык корткычларның, оппортунистларның, контрреволюционерларның каршылыкларын һәм алар тарафыннан салынган киртәләрне җимереп, социализм төзү эшендә искиткеч зур адымнар белән алга барабыз. Безнең промышленностьның соңгы көндәге үсеше [...] корткычларның актык көннәре якынлашканлыкны күрсәтә. Шуның өчен һәр җирдә производство программалары удар темплар белән үтәлергә тиеш. Партия эшчеләре, комсомоллар һәм барлык эшче сыйныфы! Сез үзегезгә бирелгән производство заданиеләрен тутырырга, икенче бишьеллыкның промфинпланнарын каршыларга әзерме? Әй сез, ударниклар! Сез үзегезнең партиягә биргән вәгъдәгезне, өстегезгә алган производство заданиегезне тутырасызмы?

Эшче. }
Галия. } Тутырабыз!

Радио. Тутырабыз һәм арттырабыз!

Галия. Хәзерге көннән башлап производстводагы барлык чүпләрне тазартырга!

Эшче. Корткычларга җавап итеп, барлык эшчеләр үзләрен ударник итеп билгеләргә тиешлеләр!

Галия. Ударниклар санын арттырабыз, чүпләрне юк итәрбез!

Эшче. Партиянең директиваларын үтәрбез, капитал илләрен куып җитеп узып китәрбез! (*Пауза.*) Бу картина тагы да тулырак чыксын өчен, безнең атаклы йокы чүлмәге – фабкомны гына китерәсе калды.

Галия. Минем аның өчен атап әзерләгән бишек көем дә бар.

Эшче. Ничек?

Галия. Менә шулай.

Йокла, иркәм, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым.
Эштә синең ни кайгың бар,
Йокла әйдә көнозын.

Безнең план тулмады,
Тикшерүче булмады.
Вакытында карамады
Завком – йокы чүлмәге.

Бездә үсә гигантлар,
Ун атлыйсын бер атлап.
Эшкә салкын караучылар
Тазартылыр чиратлап.

Р а д и о. Алло, алло, алло! Промфинпланны арттырып тутырырга вәгъдә бирү белән бергә, партия тарафыннан безнең өскә йөкләтелгән барлык бурычларны йөз проценты белән эшкә ашырырга тиешбез. Безнең Советлар илендә бишьеллыкның ахырында 518 яңа гигант фабрик, заводлар, 1040 яңа машина, трактор станцияләре эшкә башладылар. Без социализм төзелешенең нигезен корып бетереп, хәзер аларны тәмамлау юлында тырышабыз. Бу гигантларның аякка басуы, промышленностьның көчәюе, авыл хуҗалыгының күмәкләшүе бездән темпны тагын да көчәйтүне, удар санын күбәйтүне сорый.

Э ш ч е. Эшчеләр, батыр ирләр!

Г а л и я. Юк, ирләр генә түгел, хатыннар да!

Э ш ч е. Эшче хатын-кызлар, барыгыз да ударчылар сафына! (*Халыкка.*) Иптәшләр! Без, эш мәйданында көчебезне туплау белән бергә, әнә шул әйтелгән гигантларны вакытында эшкә башлату һәм өзлексез эшләтеп тору өчен сума, средствоны бергә туплауны да хәтеребездән чыгармаска тиешбез. Ирекле илдә социализм төзүче ирләр һәм хатын-кызлар! Сез барыгыз да яңа заемга язылырга, ул заемны таратырга тиешлесез!

Г а л и я. Язылабыз!

Э ш ч е. Таратабыз!

Б е р г ә. Гигантларның өзлексез эшләүләрен тәэмин итәбез!

Г а л и я. Эш белән!

Э ш ч е. Көч белән!

Г а л и я. Бир кулны!

Э ш ч е. Мә бишне!

Г а л и я. Ал унны!

Интернационал.
П ә р д ә.

## ҖАНЛЫ КИНО

Алып баручы. Иптәшләр, бүген без сезгә яңа формада кинокартиналар күрсәтергә булдык. Гадәттә, кино картиналарын караңгыда, экранга электр яктылары төшереп күрсәтәләр. Ә без бүген сезгә яктыда беренче мех фабригындагы караңгы картиналарны күрсәтәбез.

*Ике кеше сәхнә аркылы әрле-бирле йөри башлыйлар.*

Менә бу кая барырга да белми йөри торган ике кешене күрә торгансыздыр. Алар икесе дә беренче мех фабригындагы «Меховщик» гәзитенең 60 (157) нчы номерындагы эшчеләр хатында язылган приемчы ике кешене күрсәтәләр. Аларның икесе дә аена өчәр йөз сум жалованье алалар. Алып, жалованьены аккуратно рәвештә кесәләренә салалар. Принимать итү өчен һичбер нәрсә дә юк. Шунлыктан алар, үзләренә өчәр йөз сум жалованьены ни өчен түләгәнлекләрен уйлап, хәйран калалар. Фабзавком үзенең сумаларына, әлбәттә, учет ясый торгандыр. Учет ясамаса, тик йөрүчеләргә өчәр йөз сум түли-түли кесә төбе коргандыр.

*Юан кеше кыяфәтен күрсәтеп, корсакларын киереп, ике кеше чыга.*

Менә бу корсакларын киергән ике кеше картинасын күрәсезме? Алар шул ук номер «Меховщик» гәзитендә язылган, аерым привилегия белән файдалана торган беренче фабрик администрациясе. 20 сентябрьдә 5 эшче, беренче фабрик столовоена килеп, беренче чиратта ук талоннарын биреп обед сораганнар. Повариха, озак вакыт көтеп, обедны биргән. Беренче блюда булган бик яхшы чырайлы һәм майлы. Шундый блюданы ашасаң, эшләр булачак уңайлы. Икенче блюда итле, бәрәңгеле – гуляш. Ите дә, бәрәңгесе дә шактый гына гләш! Алар уйлаган повариха аларга да шундыйны бирә дип. Һич уйламаганнар аларга булыр калдык сыек өйрә дип.

Яхшы өлешне алган директор иде, Афанасьев,

Яхшы ашап чыгып китте, бичара, тиресенә көчкә сыеп.

бишенче фабриктагы тәртипләрне шул ук номер гәзит

буенча иптәшләр бирер сөйләп. Болай гына сөйләү җитмәсә, алар әйтерләр көйләп.

Җ ы р ч ы. Казан дигән таш кала бар,
Күп калага баш кала.
Эшчеләргә ашлар пешә
Зур гына ашханәдә.

Х о р. Ашханәдәге тәртипләр
Үрнәк булсын башкага. } (*2 тапкыр.*)

Җ ы р ч ы. Бишенче мех фабригында
Бар икән зур ашханә;
Ике өстәлгә аш бирүне
Тик бер кеше башкара.

Х о р. Башкарырга уйлыйлар, ди,
Шул икедән башка да. } (*2 тапкыр.*)

Җ ы р ч ы. Эшче халык аш биргәнче
Ярты сәгать көтәләр.
«Нигә озак ашыйсыз?» – дип,
Эшчеләрне тетәләр.

Х о р. Көтә бирсеннәр эшчеләр,
Алар бит тик мехчылар. } (*2 тапкыр.*)

Җ ы р ч ы. Эшче халык көтә-көтә
Эшкә дә соңга кала,
Йә прогул дип язалар,
Йә ул шелтәләр ала.

Х о р. Эшче халык, тиресе таза,
Күтәрә, мескен, җәза. } (*2 тапкыр.*)

Җ ы р ч ы. Официантны тарталар
Төрлесе төрле якка.
Кайсы ашый икешәр кат,
Кайсылар кала артка...

Х о р. Кайберәүләр кат-кат ашый,
Кайсылар кала артка. } (*2 тапкыр.*)

Җ ы р ч ы. Күптән түгел күп эшчеләр
Ашамый да калдылар;
«Икенче кат сорыйсың», – дип,
Талоннарын алдылар.

Х о р. Берәү ашый тыгына-тыгына,
Ач калучы сүгенә.

Җ ы р ч ы. Повар йөри ак халаттан,
Аклыгы – нәкъ трубочист.
Ашханәгә духи сипкән,
Борынга тула бик хуш ис.

Х о р. Ислемайлар магазины:
Одеколон, йә, душись! } (*2 тапкыр.*)

А л ы п  б а р у ч ы. Хәзер киноның икенче бүлеге күрсәтелә.

Ике егет кулларына стаканнар тотып чыгалар, бии-бии стаканнарыннан бер-берсенә сибәләр.

Менә болар беренче фабрик эшчеләре. Аларга әчегән сөт биргәннәр. Эшчеләр әчегән сөтне әчмичә, бер-берсенә сибеп, уйнап йөргәннәр. Бу эшне бик күп кешеләр күргәннәр.

Ике кыз «1=9» дигән цифр күтәреп чыгалар.

Менә болар беренче фабриктан икенче фабрикка җибәрелгән комсомолка Хөснетдинова, Миңнуллина, Бәширова дигән комсомолкалар. Нормаларын тутырмыйча ырвачлык ясаганнар. Бер көнгә бирелгән норманы кичкә генә 9 көндә тутырганнар.

Шул ук кызлар ике лакан сурәте күтәреп чыгалар.

Алып баручы. Менә болары беренче фабриктан икенче фабрикка килгән комсомолка Трифина, Семенова, Нистратова дигән кызлар. «Безгә бирәдә помой ашаталар» дип, лакан күтәреп, беренче фабрикка барырга пропуск сорап йөриләр. (*Пауза.*) Шундый ук хәлләр сирийный цех җуыш скабасында[1] да бара, Треугольник җыелышына калыр өчен бушлай обед сорыйлар. «Обед булмаса, калмыйбыз» дип, кулларын селтәп китәләр. (*Пауза.*) Хәзер сырьелар базасына күчәбез. Аның картинасы килеп җитмәгәнгә, сөйләп кенә китәбез.

Бер егет, бер кыз җырлыйлар.

Сырьелар базасында бик булдыклы куштаннар,
Тик нигәдер удар обед сөтенә су кушканнар.

Чернова бик яхшы ударник, эшне яхшы йөретә,
Тик нигәдер прогулчыга язып акча бирдертә.

Фабкоммыдыр, парткоммыдыр, бик күп китаплар ала,
Шул бичара китаплар идәндә тик аунала.

Ионова-комсомолка прогуллар ясаган,
Ялган талоннар ясап, обедлар да ашаган.

Кеше шкафына кереп, сабыннар да суыта,
Тиздән суды булачак, ди, җавабын бирер судта.

Грузчик Вәлиуллин да артка калмый, «тырыша»,
Ялган талоннары белән ашханәгә сырыша.

Ә грузчик Галиуллин, ашавын ул ашамый,
Эшкә исереп килүне һичбер вакыт ташламый.

Кладовщик Карпова һәм хисапчы Чернова –
Икесенең 15–30 минут соңгару чире була.

Сортировщик Моканай, карарга юньле малай,
Жалованье алгач, икенче көн исереп килмә алай.

Чегорковның бригадасы примерный санала,
Күп булмаса энә шундый Моканайлар арада.

Бишенче фабрик картинасы бик дөрес, түгел ялган,
Охрана труда законы әллә кайда югалган.

Алып баручы. Картина хәзер алтынчы фабрикка күчә. Анысын да әйтеп күрсәтик шулай ук әүвәлгечә.

Егет. } Столовойның поварын директорлар ошата.
Кыз. } Ник ошатмасыннар аны,
ул бит бик шәп ашата.
Күп сөйләнә торгачыннан, артып киттек үтәгә,
Башкалары калып торсын киләсенә – иртәгә.

## КАЗАННАН ХАТЛАР

### БЕРЕНЧЕ ХАТ

Ә җ а к уң яктан ашыгып чыгып, урталыкка туктап.

Ә җ а к. Кайда гына китте икән соң бу Кужәк? Шушында клубка китте дигәннәр иде. Казаннан хат килде, мех фабрикларыннан язганнар булырга кирәк. Иске әлиф белән, гарәпчә язганнар. Яңалифчә танымый торган кешеләр хәзерге вакытта анда гына калды дип әйтерлек. Мин үзем яңалиф белән генә укыган. Кужәктан укытырмын дигән идем. Ул иске әлифне укый белә бугай. (*Сул якка кереп китә.*)

Пауза. Сул яктан К у җ а к чыга. Урталыкка туктый.

К у җ а к. Казаннан хат килде. Мех фабрикларыннан язганнар булырга кирәк, яңалиф белән язганнар. Ә мин, Рәхим хәлфәдән иске әлиф белән генә укыганга күрә, яңалифне әле бик яхшылап танып җиткерә алмыйм. Әҗактан укытырмын дип килгән идем. Ул бүген клубта булыр дигәннәр иде. Кайда гына китте икән соң бу Әҗак? (*Уңга кереп китә.*)

Пауза. Ә җ а к – сулдан, К у җ а к уңнан чыгалар.

Ә җ а к. Һа! Кужәк! Мин сине тегеннән эзләп йөрим.

К у җ а к. Ә мин сине – моннан.

Ә җ а к. Нигә?

К у җ а к. Меховой фабриклардан булырга кирәк, миңа хат килгән.

Ә җ а к. Шуннан булырга кирәк, миңа да килгән.

К у җ а к. Мә, укы. (*Хат бирә.*)

Ә җ а к. Мә, син дә укы. (*Хат бирә.*)

К у җ а к. Нигә үзең укымыйсың?

Ә җ а к. Мин иске әлифчә белмим. Ә син нигә укымыйсың?

К у җ а к. Яңалифчә белмим. Синнән укытырмын дигән идем.

Ә җ а к. Алай булса, минекен син укы, ә синекен – мин.

К у җ а к. Ярый. Җә, элек син укы.

А җ а к. Юк, иң элек – син.

К у җ а к. Юк, син!

А җ а к. Юк, син!

К у җ а к. Син!

А җ а к. Син!

К у җ а к. Алайса, бер дә укымыйм.

А җ а к. Мин дә укымыйм.

К у җ а к. Укыма!

А җ а к. Укыма!

К у җ а к. Җә, укыйк инде.

А җ а к. Ну, укыйк.

Икесе дә эчтән генә укый башлыйлар да көлешәләр.

Нигә көләсең?

К у җ а к. Ә син нигә?

А җ а к. Көлке ич.

К у җ а к. Ә минеке көлке түгелме?

А җ а к. Алай булса, әйдә, берәр-берәр, бүлеп-бүлеп укыйбыз.

К у җ а к. Әйдә. Ну, башла!

А җ а к (*укый*). «Кадерле туган! Син киткәннән бирле Казанда көн саен яңадан-яңа кызык эшләр була да тора. Мин сиңа шуларны тәртибе белән язып белдерәм».

К у җ а к (*укый*). «Сөекле иптәш, син киткәннән бирле кызыклы эшләр белән дөньялар тулды. Шуларны язып сине көлдерәм». [...]

А җ а к (*укый*). «Беренче фабрикның кызыл почмагы бөтенләй эштән чыгып бетте. Гәзит-журналлар идәндә аунап яталар. Аларны җыйдырыр өчен зиярат өстендә йөри торган кәҗәләрне җыеп китереп, өмә ясатырга кирәк булыр, ахры».

К у җ а к. Кара, миңа да нәкъ шуның турында язалар. (*Укый.*) «Беренче фабрик кызыл почмагын һич караучы юк, балалар шкафлар эченә кереп кача-кача уйныйлар. Кызыл почмакны бөтенләй кадаклатып куярга туры килер, ахры».

А җ а к (*укый*). «Син киткәннән бирле Казанда яңа бер төрле авыру башланды. Докторлар ул авыруны яңа бер төрле авыру дип табалар һәм аңарга «дезертирлык авыруы» дип исем биргәннәр. Шул авыру белән авырып, производство политехника мәктәбенә язылган 50 кешенең август аенда берсе дә мәктәпкә килә алмаган. Сентябрь аенда бары биш-алты кеше генә ул авырудан исән калганнар. Хәтта электә премия алучылардан Максудова, Фазылҗанова, Мөхетдинова, Гатауллина, Закировалар да

шул авыруны эләктергәннәр булырга кирәк, алар да килмәс булдылар».

К у җ а к. Кызык икән. Ул авыру турысында минем хатта да язганнар, ләкин минеке башкачарак.

А җ а к. Җә, укы, нәрсә язалар?

К у җ а к (*укый*). «Син киткәч, Казанда Яшьләр көне демонстрациясе булды, 5 нче фабрикның Гайнуллиннар төркеме шул демонстрациядә булмады. Мәмәшова белән Мөхәммәтовалар демонстрантлар колоннасыннан качып тротуарда подручком йөрделәр. [...] Бу авыру үзе тагы, бер генә дә төрле булмыйча, әллә ничә төрле була икән. Ул авыру эләгүчеләрдән, мәсәлән, ОМКУЗның[1] сырье базасыннан Лазарева, Карпова, Ионова, Мингалиев – өчәр айлык взнос түләтүдән, Кукелев, Салатков, Журавлева һәм 6 нчы фабриктагы Әхмәдуллина, Ногманова, Әхмәтҗанова, Хаҗиевалар эштән качып прогул ясыйлар. Бу яңа авыруның хәзергә кадәр докторлар да белмәгән яңа галәмәтләре дә бар икән. Ул эләккән кешеләр йоклаучан булалар икән. Әнә дүртенче фабрикның заем комиссиясенә авыруның шундые эләккән булырга кирәк, ул йоклап калган да подписка җыя алмаган, диләр. Әнә тагы 5 нче фабриктагы конвейерный цехтагы Төхфәтуллинага бөтенләй башка бер төрдәгесе эләккән, диләр. Ул үзе яңалифчә белмәсә дә: «Мин урысчаны яхшы беләм, авыл кызлары арасында укып йөрмим», – дип качып йөри. Тагы шундыйлары да бар: шул ук фабриктагы Васильев дигән токарь, шул ук яман авыру аркасында, систематически эчәргә сабышып, акылыннан шашып, кайда барса, шунда «Расчет! Расчет!» дип йөри башлаган».

А җ а к. Андыйлар миндә дә бар ул. Мин тик, син ышанмассың дип, ул җирләрен укымый калдырган идем.

К у җ а к. Һи, жүләр, укымаска ярыймы соң, әйдә укы. Иң кызыгы да шул бит аның.

А җ а к (*укый*). «Яңа чыккан авыру аркасында күп кенә кешеләр акылларыннан шаша башладылар. Мәсәлән, 5 нче фабриктагы фабком члены Загибина: «Кая, миңа тизрәк расчет бирегез, минем тапкан урыным кача!» – дип пыр туздырып, яңа тапкан урыны артыннан чабып йөри, заявлениеләр бирә».

К у җ а к. Әйттем бит кызыктыр дип. Мин дә, син ышанмассың дип, бер кызыгын яшереп калдырган идем әле.

А җ а к. Нәрсә?

К у җ а к (*укый*). «6 нчы фабриктагы столовойда эшләүчеләр яңа төрле бер ярыш уйлап чыгардылар. Үзләре аңар «социализм ярышы» дип исем дә биргәннәр...»

А җ а к. Ул нинди ярыш икән? Әллә аз гына нәрсәдән туклыклы күп аш пешереп чыгаралармы икән?

К у җ а к. Тукта, сабыр ит, хәзер укыйм. (*Укый.*) «Столовойда эшләүчеләр, тәмам корсаклары ярылганчы ашап, бүген мин күпме арттым икән» дип, һәр көн үлчәүгә барып үлчәнәләр».

А җ а к. Яхшы юл тапканнар. Аларның үлчәүләренең ахырында ничек булып чыгуы турында миңа хәбәр итәрсең әле. Әгәр дә күп артсалар, моннан соң эшчеләрне курортларга җибәрмичә, шул столовойга җибәрә башларбыз. Мин дә бая тагы, син ышанмассың дип, тагы берникадәр нәрсәләрне укымый калдырган идем. Тыңлап тор, инде укыйм.

К у җ а к. Җә?

А җ а к. «Бу яңа чыккан авыру белән авыручылар арасында качу гына түгел, качырулар да көчәйде».

К у җ а к. Анысы нинди авыру тагын?

А җ а к. Анысы – качыру авыруы.

К у җ а к. Ул нинди тагы?

А җ а к. Менә тыңлап тор, укыйм. (*Укый.*) «6 нчы фабриктагы охранница Андреяша фабриктан чыкканда комендатурада эшчеләрнең кесәсеннән чыккан алмаларны үзенә качырып алып кала. Завхоз Сәйдәшев пожарный начальнигына сөйләгәндә авызыннан тәмле-тәмле сүзләр качыра икән. 4 нче фабрикның раскройный цехындагы цех комитеты члены инструкторның систематически рәвештә нәрсә качыру авыруы белән авырганын сөйлиләр».

Куҗак китә башлый.

Тукта, кая барасың?

К у җ а к. Качыру, качу авырулары көчәйгән дисең ич!

А җ а к. Дисәм соң?

К у җ а к. Тизрәк качарга кирәк, миңа да йокмасын, дим.

А җ а к. Тукта, бераз гына көт. Начарларын сөйләгән шикелле, бераз яхшыларын да әйтеп алыйк та, аннары бергәләп качарбыз.

К у җ а к. Ярый алайса.

А җ а к. «Август аенда 2 нче фабрикта Транзалов бригадасында эшләр 123 процент эшләнгән. Шулар арасыннан Насыйрова – 141 процент, Галиев 140 процент үтәп, премия алганнар. Гыймадиева – 99 процент, Сурдичева 96 процент эшләп, артта калганнар».

К у җ а к. Беттеме?

А җ а к. Бетте.

К у җ а к. Ә мине ник әйтмәгән?

А җ а к. Син ни эшләдең?

К у җ а к. 100 процент хат укыдым, ә 100 процент син укыганны тыңлап тордым. Шулай булгач, мин 200 процент башкарган булам...

## АҖАК БЕЛӘН КУҖАК (1)

Аҗак. Безнең бүгенге програмның ... нче номеры мин һәм... то есть Аҗак белән Куҗак сөйләр өчен дип төзелгән иде, ләкин Куҗак, саботаж ясап, килми калды. Шуңар күрә миңа ялгыз гына чыгарга туры килде, Куҗакка без саботаж ясаганы өчен шелтә бирергә тиеш. Иптәшләр, сез шуңар ризамы?

Куҗак (*иң арттан, халык арасыннан кычкыра*). Иптәшләр, Аҗакның сүзенә, зинһар, ышанмагыз, ул ялган сөйли. Бер дә алай саботаж-мабатаж юк. Эш бары шунда гына: без һәрвакыт сәхнәгә аның белән бергә чыгабыз. Халык яратып кул чаба. Аҗак әйтә: «Алар мине яратып кул чабалар», – ди. Ә мин әйтәм: «Юк, мине яратып чабалар», – дим. (*Сәхнәгә һаман якын килә бара.*) Ул әйтә: «Мине!» – ди. Мин әйтәм: «Мине!» Ул әйтә: «Мине!» – ди. Мин әйтәм: «Бар алайса, чыгып кара, сиңа чабарлар микән, миңамы?» – дидем. Менә үзегез дә күрәсез, баядан бирле сәхнәдә тора, бер генә кул чабучы булмады. Ә менә, күрерсез, миңа чабарлар.

Аҗак. Җә, җә, кил инде, кил, сиңа чабалар икән.

Куҗак. Шул шул.

Аҗак. Җә, әйдә, берәр кызык нәрсә сөйләп алыйк әле, халык зарыкмасын.

Куҗак. Ярый, әйдә сөйли башла.

Аҗак. Юк, син башла!

Куҗак. Юк, син башла!

Аҗак. Җә, алайса, икәү бергә башлыйк.

Куҗак. Юк, мин икәү бергә сөйләргә яратмыйм.

Аҗак. Алайса, үзең генә сөйлә.

Куҗак. Ялгыз сөйләргә берни дә белмим.

Аҗак. Алай булгач сәхнәгә ник мендең?

Куҗак. Мин мендеммени? Үзең чакырып китердең ич.

Аҗак. Беләсеңме, менә нәрсә...

Куҗак. Юк, белмим.

Аҗак. Тыңлап тор.

Куҗак. Тыңлыйм ич.

Аҗак. Мин бит яңалифчә наданлык белән көрәшү җәмгыятенә член булып язылдым.

К у җ а к. Кит аннан! (*Курка.*)

А җ а к. Нигә гаҗәпләндең?

К у җ а к (*куркып, кире чигенә башлый*). Ярый, хуш, сау бул алайса!

А җ а к. Тукта әле, кайда качасың?

К у җ а к. Ныклап тамак туйдырып ашап килергә.

А җ а к. Соңыннан да өлгерерсең.

К у җ а к. Көрәшәм дисең ич, ашамаган, көчсез көенчә мин ничек көрәшим?

А җ а к. Көрәшсә бит, мин синең белән көрәшәм димим.

К у җ а к. Димәсәң дә, мин таякның кемгә тигәнен беләм лә. Мин дә бит яңалифчә белмим. Кара әле, зинһар, бу юлга калдыр әле.

А җ а к. Ул нинди сүз ул? Минем синең белән бераз сөйләшәсем бар.

К у җ а к. Миңа тимисеңме?

А җ а к. Нишләп тиим мин сиңа?

К у җ а к. Бу юлга гына калдыр инде алайса. Икенче тапкыр килгәндә, мин бик яхшылап яңалифне өйрәнеп килермен.

А җ а к. Ярый. Кара әле, Куҗак, син табышмак әйтә беләсеңме?

К у җ а к. Бераз беләм. Әбидән ишеткәләгәнем бар иде.

А җ а к. Хәзерге заман табышмакларын беләсеңме?

К у җ а к. Юк. Ничек соң ул?

А җ а к. Көн киттем, төн киттем, ярты аршын җир киттем, ул нәрсә?

К у җ а к. Улмы, ул Казанның канализациясе булырга кирәк.

А җ а к. Ни өчен?

К у җ а к. Ай китте, ел китте, Болактан[1] Яңа бистәгә[2] көчкә җитте.

А җ а к. Белмәдең.

К у җ а к. Соң, нәрсә?

А җ а к. Трамвай ул, 6 нчы номерлы трамвай.

К у җ а к. Ничек ул алай?

А җ а к. Шулай, ничә көн көттем, төн көттем. Трамвай Яңа бистәдән чыкканчы, мин Арча кырына[3] менеп җиттем.

К у җ а к. Кызык икән. Ә мин сиңа берне әйтим әле, син белерсеңме икән?

А җ а к. Җә!

К у җ а к. Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр. Төнгә кергәч, караңгыда япа-ялгыз калдырыр. Ул нәрсә?

А ж а к. Хатын.

К у җ а к. Ни өчен?

А җ а к. Хатыны төнге сменага фабрикка эшкә китә дә, ире ялгыз кала.

К у җ а к. Белмәдең.

А җ а к. Соң, нәрсә?

К у җ а к. Улмы, ул Казан электр заводы. Көне буена урамнарда да яна уты. Кичкә кергәч, шып сүнә. Урамда халык бәрелә бер-берсенә.

А җ а к. Инде хәзер миңа чират, карыйм әле мин синнән сорап. Әгәр җавабын таба алмасаң, мин акыллы булырмын, син – дурак.

К у җ а к. Җә, сора, хәзер табам. Туры сөйләп авызыңны ябам.

А җ а к. Катылыкка таштай каты. Ярата үзен адәм заты. Таралган дөньяга яманаты. Чыкканын белмәсәм дә мин кайдан, чыкмаганын беләм ләкин Кытайдан. Кооперативта юк, таба да алмассың базадан. Әгәр акчаң күп булса, һәр көн табарсың базардан. Ул нәрсә? Беләсеңме?

К у җ а к. Ә син үзең нәрсә икәнен, каян чыкканын беләсеңме?

А җ а к. Беләм.

К у җ а к. Белсәң, алайса әйдә киттек милициягә. (*Өстери.*)

А җ а к. Тукта, мин нишләп анда барыйм?

К у җ а к. Беләм дисең ич. Ә анда бөтен халык аның базарга кайдан чыкканын белми аптырап йөри.

А җ а к. Нәрсәнең?

К у җ а к. Беләм мин синең нәрсә турында сөйләгәнеңне. Син шикәр турында әйтәсең. Син анда ай көтәсең, ел көтәсең, кайчан гына шикәр бирерләр дип интегеп бетәсең. Ә син аны беләсең. Бездән авыз җырып көләсең. Әйдә әле, анда баргач, шикәрдән иткән файдаларны артыгы белән түләрсең.

Кереп китәләр.

## АҖАК БЕЛӘН КУҖАК (2)

Аҗак сәхнәдә, Куҗак көрәк күтәреп узып бара.

Аҗак. Көрәк күтәреп кая киттең, әллә берәр яшелчә бакчасына өмәгәме?

Куҗак. Юк, хәзер алай кеше өчен эшләп йөри торган заман түгел. Кеше өчен түгел әле ... фабрик конторындагы хезмәтчеләр уңышы үзләренә булачак яшелчә бакчасына да эшкә бармыйлар.

Аҗак. Соң, алай булгач, кая барасың?

Куҗак. Зиратка.

Аҗак. Нигә?

Куҗак. Бабайның каберен казырга.

Аҗак. Яхшы кеше иде бугай, бичара, үлдемени?

Куҗак. Аның үлгәненә инде дүрт ел булды.

Аҗак. Чудак. Соң, дүрт ел элек үлгән кешенең каберен быел казыйлармыни?

Куҗак. Казыйлар шул. Син әле бабайның нинди кеше булганын белмисең.

Аҗак. Белмим шул. Нинди кеше иде?

Куҗак. Бик үзсүзле, үз сүзендә үлә торган бер кеше иде.

Аҗак. Соң?

Куҗак. Шул. Мин аңар, гәзитләрдән укып, бишьеллык планда менә шулай булачак, болай булачак, бөтен Совет илләре гигант белән тулачак; менә синең әрбәлегең булган урыннарга зур фабриклар корылачак дип сөйләгәч, ышанмыйдыр иде. «Әгәр дә бу эшләрегез барып чыкса, кулымны кисәргә бирәм», – дидер иде.

Аҗак. Соң?

Куҗак. Шул, мин әйткәннәр булды, ә аның кулы киселмичә үлеп китте. Мин хәзер аның каберен казып, кулын кисәргә барам.

Аҗак. Юк артыннан йөрмә. Ул вакыттан бирле инде аның кулы гына түгел, бөтен сөякләре дә киселеп, таралып беткәндер. Кстати, синең кулыңда көрәк тә бар икән, аның урынына без үзебездәге фабрик-заводлардагы пычраклар, чүпләрне тазартып алыйк.

Куҗак. Була ул, әйдә, кайсы фабрикны, кемнәрне?

---

Әрбәлек – ындырда башак (сугылган) саклау урыны.

## ИКЕ ТУГАН АЛКОГОЛЬ, ПРОГУЛ

*Клоунада бер пәрдәдә*

УЙНАУЧЫЛАР:

Аҗак – клоун.
Куҗак – клоун.

Куплетларга катнашалар: ике кыз, бер егет.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Аҗак һәм Куҗак, сәхнәнең ике ягыннан чыгып, урталыкта очрашалар.

Куҗак. Һа! Көтмәгәндә очрашу! Исәнме, Аҗак!

Аҗак. Исән, исән, бик исән, үзең бик исән-сау торасыңмы? Беренче категория буенча икмәкне бик шәп итеп убасыңмы?

Куҗак. Зарарсыз. Нәкъ ударникларча. (*Муенына чиертеп күрсәтеп.*) Монда җибәрсәм, прогул ясасам да бик шәп торам. Үзең кайларга бардың, кайларда йөрдең, кайдан кайтып киләсең? Кыска гына әйтеп ал. Озын итеп гайбәтләрне кеше юк чакта сөйләрсең.

Аҗак. Нигә кирәк аны сорап торырга? Безгә кирәк биредә прогулчыларның колакларын борырга.

Куҗак көлә.

Көлмә, көлмә, минем тикмәгә йөрмәгәнне үзең дә бик яхшы беләсең.

Куҗак. Беләм, беләм, бик яхшы беләм, кирәк булганда син һәркемне дә кармакка бик нык эләсең. Килгәндә дә килә белеп киләсең, көлгәндә дә көлә белеп көләсең. Шуңар күрә дә синнән сорыйм да: миңа бераз сөйләп бир әле, дим, ...дәге җыртык-тишекләр турында.

Аҗак. Була ул, минем өчен анысы ерунда! Менә син, шәп егет булсаң, сөйләп бир әле бер закон турында.

Куҗак. Нинди статья, нинди закон? Тукта әле, әйтми

тор, үзем белә алмам микән син сорамас борын да? (*Башын кашып уйлый.*)

Аҗак. Юкка тузгытма башыңдагы тузан, чәчең, кереңне. Алай бик тиз генә белә алмассың яшерен серемне. Мин синнән сорыйм, син тик миңа җавап бир: закон буенча ике игез бертуган җыела алалармы бер цехта, бер урында?

Кужак. Алалар, алалар, андыйлар бик күп. Кыскача гына әйткәндә, ул эш ерунда! Алай дидем диюен дә, тукта әле, ялгыш булмасын, кем соң алар? Нинди туганнар? Кайсы цехта? Синең сүзең кемнәр турында?

Аҗак. Әйттем бит инде, бертуган ике агай-эне турында.

Кужак. Кемнәр алар?

Аҗак. Берсе – алкоголь, берсе – прогул.

Кужак. Һи! Исең киткән икән. Андый агай-энеләр бездә бик күп була ул. Җә, син миңа шуны сөйлә: эш нәрсәдә?

Аҗак. Шуны да аңламыйсыңмы, дурак! Әнә шул ике брат ... цехында яшәгәнгә, бик артып китте брак.

Кужак. Аңладым. Аңладым. Ул братларның тиздән дөньяга таратырбыз даннарын. Кара әле, иптәш Аҗак!

Аҗак. Әү, дустым, ни дисең, иптәш Кужак?

Кужак. Ул турыларда ничегрәк соң безнең бу җак?

Аҗак. Шәп түгел.

Кужак. Сабыр ит әле, безнең анда гәп түгел. Минем шул Алкоголь белән Прогулны күргәнем юк. Син миңа шуларны күрсәтерсең әле, җәме?

Аҗак. Ярар, ярар, тик куркам, уенның китеп бармасын, дим, тәме. Ярый алайса, карап карыйк, биредә микән үзләре? Андыйларның җә майланган, җә йомылган була күзләре. Сөйләгәндә һич аңланмый сүзләре. Биредә булсалар, күрсәтүе бик ансат. Андыйларны тиз табып була, яхшылап карасак. Әнә берсе! (*Халык арасына төртеп күрсәтә.*) Алкоголь агай бугай. Шул, шул, урындыкта йоклый сөялеп. Ә аның иптәше, Прогул агай, пивнойларда йөри торгандыр сөйрәлеп.

Икесе ике якка китеп, уртадан юл бирәләр. Сәхнәгә, марш атлап ике кыз, бер егет керәләр.* Краковяк көенә җырлыйлар.

Алкоголь белән Прогул кайсы цехта күп була,
Менә шундый цехлар, дуслар, браклар белән тула.

Тезелешеп биеп китәләр.
Аҗак белән Кужак та катнашып, барысы бергә.

---

* Состав зур булганда, күбрәк булса тагы да яхшы. – *Г.Камал искәр.*

Алкоголь, Прогул
Әнә шундый була ул!
Алкоголь, Прогул
Әнә шундый була ул!

А җ а к. Әйтәләрме, дускай?

К у җ а к. Әйтәләр.

А җ а к. Әйдә, без дә шулай әйтик.

К у җ а к. Юк, әйтсеннәр, тимә. Тик без дә кушылыйк шул көйгә.

К ы з л а р. Прогулчының белгән эше –
тик бушату бутылка,
Карап торырлык товарны
чыгарып ташлау утилгә.

Б а р ы с ы б е р г ә. Алкоголь, Прогул
Әнә шундый була ул!
Алкоголь, Прогул
Шундый, шундый була ул!

К ы з л а р. Алкогольдән, Прогулдан
Барлык семья таркала.
Дус, дошманнар арасында
Йөзләргә ягыла кара.

Б а р ы с ы б е р г ә. Алкоголь, Прогул
Әнә шундый була ул!
Совет илләре аерыла
Аклар белән карадан;
Алкогольчы, прогулчылар
Китсен безнең арадан. } (*2 тапкыр.*)

Алкоголь, Прогул,
Долой безнең арадан! } (*2 тапкыр.*)

## ПРОРЫВЛАР (1)

Прорывлар ник булганын мин сезгә тормыйм сөйләп,
Аларның нигә булганын әйтеп бирербез көйләп.

Сәхнәгә ике кыз, ике егет чыга.

Исәнмесез!
Фабриклардагы эшчеләр
Отпускыларга сызган.
Күбесе вактында кайтмаган,
Промфинпланны бозган.

Выдвиженецлар киткәннәр,
Урынына кеше калмаган.
Калганнарның да күбесе
«Мин эшлим» дип алдаган.

Фабрикларда эчүчеләр,
Прогульщиклар күбәйгән,
Әрәмтамак, ялкау халык
Ычкынып киткәннәр бәйдән.

Симулянтлар, ырвачлар
Өстенлекне алганнар.
Ялкаулыкны алга алып,
Койрыкны сыртка салганнар.

Райшник. Шулай булгач, егетләр, кызлар, иптәшләр, дуслар, безгә нишләргә?

Һәммәсе бергә. Бөтен Татарстан күләмендә прорывларны бетерү өчен, хөкүмәт кушканча вакытлы рәвештә отпускыларны туктатырга, производстводан җибәрелгән выдвиженецларны прорывларны ямар өчен станокларына кире кайтарырга. Курсларны да вакытлы рәвештә туктатып торырга. Алар киткәннән соң иркенләп алган эчүчеләр, прогулчылар, әрәмтамак, симулянтлар, ырвачларны боргычларга!

---

Райшник – конферансье, алып баручы.

Б а р ы с ы  б е р г ә. Тулы план үтәргә,
Куып арттан җитәргә,
Без чыгарабыз карар:
Арттырып узып китәргә.

Тик бер булсын сүзегез,
Ачык булсын күзегез;
Ырвачлардан, ялкаулардан
Өмитләрне өзегез.

Беләсез бит үзегез,
Тагы бераз түзегез.
Бөтен илнең каршысында
Яктырачак йөзегез.

Б е р г ә. Тутырыйк бергәләп промфинпланны,
Көлдермик үзебездән күрше-коланны,
Бергәләп күрсәтеп зур көчебезне,
Сытып таптыйк дошман – кара еланны!

## ПРОРЫВЛАР (2)

Мастерларга,
эшчеләргә,
көчлеләргә,
көчсезләргә,
олыларга,
кечеләргә –
барыгызга миннән сәлам!
Һәркайсыгызга уңышлар теләп калам.
Мин килмәдем сезгә бүген көлке сүзләр генә сөйләргә
йә булмаса уйнап-көлеп, биеп, төрле көйләр көйләргә.
Сөйләгән сүзләремә яхшы илтифат белән кара:
бөтен Татарстанда хәзер зур-зур прорывлар бара.
Хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән план Татарстанда
тулысынча үтәлми,
эшләгән эшләр күбесендә 60–70 проценттан үтә алмый.
Шуның белән бергә безнең мех фабрикларында да
прорывлар булуга күз сал;
эшләр болай барса, ахыры начар булуын исеңә ал.
Яхшылап карап карыйк, кай җирләрдә планнар ничек
үтәлгән?
Артка калучылар гыйбрәт алсыннар башкалардан,
бүтәннән.
Мисал өчен алып карыйк соңгы ике айны.
Шуларга яхшы карап, күзеңне ач, айны.
Эшләр һаман шулай барса, яхшылыклар көтмә, агай-эне!
2 нче фабрик заданиене июль аенда бары 47 процент,
август аенда 44 процент кына үтәгән,
шуның белән иң артта калган барлык бүтәннән.
Выдвиженецлар җибәрелгән урыннарыннан кайтмаганга,
станоклар буш ята,
шуның аркасында прорыв көннән-көн арта.
ОМКУЗ июль ае планын 61,2 процент, август планын
68,7 процент үтәгән.
Ул да шулай, прорыв ясап, башкалардан күп алга
китмәгән.
4 нче фабрик июль аенда 49,48 процент эшләгән,
август аенда барлык эше 53,28 проценттан артыкка
төшмәгән.

Сырьевой база июль аенда 113,96 процентка менгән,
ә август аенда 89,74 процентка төшеп, бәхете аннан
бераз көлгән.
Арада 5 нче фабрик июль аенда 125,3 процент үтәп, иң
зур югарылыкка менгән,
ә августта 95,4 процентка төшеп, бераз артка түнгән.

* * *

1. Әйдә җырлап карыйк әле, синме, минме уздырыр,
Минем тавыш трактор күк, чәчләреңне туздырыр.

2. Минем җырлар бик шәп, малай,
әчкелтем дә төчкелтем,
Әчкелтемле җырлар җырлап,
булмас микән төчкертеп.

3. Җәйгә чыккач, яратамын ала карга тавышын,
Чиратларга йөри-йөри тузды өч пар галушым.

4. Товарищ зав, хозрасчетны тормышка ашырамсың,
Промфинпланың тулмагач, корсагың кашынамсың.

5. Казанның Зур урамында бик күп столовойлар,
Коммерчески кесәң булса, шәп ашаталар алар.

6. Кичә обед кыярлы иде, бүген булган огурца,
Йөрәгеңә ятар иде, әзрәк мае да булса.

7. Җәйге айларда авырма, аурып больниска барма,
Профессорлар – домотдыхта, докторлар киткән ялга.

8. «Скорый помощь» чакырганнар, син кинәт
авырганда,
«Скорый помощь» килеп җитте, сине күмеп
кайтканда.

9. Кооператив кибетләре ярышалар үзара,
Һәрбер завның, приказчикның бармагы үзенә таба.

10. Промтоварга аптырамассың, дустың булса приказчик,
Җизнәң булса завмагазин, кодаң булса помощник.

11. Кооперативта ит юк, диләр, ул итләр кая киткән,
Кичә ат ите бар иде, бүген ансы да беткән.

## ҺИНДСТАН ФАКИРЕ

Башына бик озын бүрекле чалма, өстенә чапан киеп, билен бик киң бер кушак белән буып Факир сәхнәгә чыга. Урталыкка килеп, тәбәнәк бер эскәмия куеп, аның өстенә бик зур һәм калын бер китап куеп сүзгә керешә.

Факир. Исәнмесез, саумысыз, белгән-күргәннәр, борыннарын салындырып йөрүчеләр һәм авыз җырып көлгәннәр, өй тавыгы шикелле өйдә ятучылар, көне буе гайбәт сатучылар, урамнарда шухыр чыгарып, тәрәзә ватучылар, урам буе лач-лач сагыз чәйнәп, әрле-бирле йөрүчеләр, 40 градус эсседә калын шәл бөркәнүчеләр, яулыкны арттан бәйләп, яланаякка киез ката киеп, кооперативтан кооперативка йөгерүчеләр, алардан ни тапсалар шуны алып, базарларда спекуляция ясап йөрүчеләр, шуларга да карамастан, авызларын күтәреп, «Мин – чын пролетар, мин – ударник эшче» диючеләр, ханымнар, матур туташлар, ак, кара, сары, кызыл, киң һәм нечкә кашлар! Докторлар, врачлар, прогульщик, рвачлар! Мин сезгә килдем ерак Һиндстан иленнән, булуга да карамыйча сакалларым билемнән, кырык ел йөрдем инглиз капиталистларының җәбер-золымыннан качып, хәзер йөрим шәһәрләр саен фал ачып. Кырык ел өйрәндем нөҗүм гыйлемен тау тишекләрендә, мәгарәләрдә ятып, гәүдәләремне корт-кошлар, елан-чаяннарга ашатып! Килдем иркен Совет илләренә, сезне күңелем ошатып. Кешеләрнең бәхет, талигаләреннән хәбәр бирәм, үзегез дә торырсыз шаклар катып.

Җәгез, егетләр, ханымнар, туташлар, йөрмәгез читтә качып, якынрак килегез, бирим сезгә бик туры сөйләгән фаллар ачып. Тәбрик итәрсез мине кулларыгызны чабып чат та чот! Кайда барсам, анда миңа зур почет!

Бер кыз килә.

Кыз (*картның алдына акча салып*). Җә әле, бабай,

---

Факир – иллюзионист, күз буучы.
Нөҗүм – йолдызлар.
Талигъ – алда булачак бәхет (яхшы киләчәк).

миңа фал ачып кара әле, нәрсә әйтер икән? Бәхетләрем алга җә артка китәр микән?

Ф а л ч ы. Яхшы, кызым, яхшы, миннән сиңа зур теләк. Ударник булып яхшы эшләсәң, алырсың үзеңә зур бүләк. (*Карт, китабын ачып, эченнән бер кәгазь алып.*) Мә, кызым, укып кара, бәхетләрең алга бара. Кычкырып укы, бер дә курыкма, фалың начар чыкса, кайгыдан чәчләреңне йолыкма. Салган акчаларың аз булган, шулай да синең барлык бәхет, талигаләрең шунда язылган.

К ы з (*кычкырып укый*). «Җәгъфәр Садыйк боерыр, кем, и фал иясе, бу фал кем сиңа килде синең талигаң мех комбинатының сырьелар урманында череп ята торган чималлар шикелледер. Аның ОМКУЗ ишегалдында һәм шәһәрдәге складында көя ашап, череп, сасып, түгелеп ята торган чималлар күпдер, һичбер исәбе-хисабы юкдыр, администрациянең алар турысында кайгысы юкдыр. Синең бәхетең дә, мех комбинатының сырьелар склады шикелле, сөтле, симез, савым сыерга охшый. Комбинат идарәсе шулардан кирәгенчә файдалана белмәгән шикелле, син дә үз бәхетеңнән файдалана белмисең, теләгеңә якын килмисең. Алардан файдаланыр өчен, удар бригадаларын уятырга, ирек бирмәскә йоклап ятарга, башларга җыелган томаннарны таратырга, төрле кампанияләр уздырып, бураннар туздырып, тимер себерке белән себертеп, барлык караңгы почмакларны каратып, критика тимер тараклары белән таратып, ачык хисаплар белән санатып, яраклыларын эшкә яратып файдаланырга кирәк булган шикелле, сиңа да битләреңне юарга, җәмәгатьчелек кояшы яктысы алдына чыгарып, киптереп куярга гына кирәк. Бик бәхетле булгайсың, киявеңнән дә уңгайсың, морадларыңа иргәйсең, хөкүмәткә һәм производствога да бик күп файдалар биргәйсең».

Ф а л ч ы. Бәрәкалла, кызым, бәрәкалла! Бәхетләрең белән тәгәрә алга! Иптәшләреңнән артка калма. Мин сезгә килдем бик кыска вакытка. Столовойда өлгергәндер ботка, вакытны әрәм итмәгез юкка, критикалар китеп барганда ходка. Кайда, тагы кемнәр бәхет сынап фаллар ачтыра, минем столовойга барасым бар, анда күп вакыт вакытында ашлар өлгерми, эшчеләр тамагы ач тора. Ач булса, минем дә эчләр бора.

И к е н ч е  к ы з  керә.

И к е н ч е  к ы з. Җә әле, бабай, миңа да фал ач! (*Акча сала.*)

Ф а л ч ы. Җегетләр турындамы, кызым? Аларның күбесе кызлар турында палач булса да, тамаклары ач, өсләре ялангач, производствога керми йөриләр, тамаклары туя торгандыр шул, матур-чибәр кызлар тирәсендә ялангач.

И к е н ч е к ы з. Җә, бабай, тизрәк ач инде, акча салдым, әнә ал!

Ф а л ч ы (*акчаны алып*). Ачам, кызым, ачам, кесәләремне тутырып өлгерсәм, кооператив күселәредәй тиздән качам. (*Алып бирә.*) Мә, кызым, ал! Хәерле фал булсын, кызым, хәерле фал! Кооперативлар тулы мал, авызлар тулы май да бал. Получка акчаңны әрәм итмә, кызым, ни бирсәләр, шуны ал!

И к е н ч е к ы з (*укый*). «Җәгъфәр Садыйк боерыр, кем, и фал иясе, бу фал, кем, сиңа килде, синең бәхетең арыслан авызындагы сөяк шикелледер. Файдалана белмисең. Алардан файдалану өчен, удар бригадаларын уятырга, көя ашап ята торган сырьеларны тимер себеркеләр белән себертеп, тимер удар чыбыклары белән чыбыклатып, тузаннарын тузгытырга, критика тимер тараклары белән таратырга, шулай итеп эшкә яратырга кирәк булган шикелле, сиңа да битләреңне юып, сырьеларга нафталин сипкән шикелле пудралар сибеп, җәмәгатьчелек кояшы алдына чыгарып, элеп киптерергә генә кирәк. Бик бәхетле булгайсың, морадларыңа иргәйсең һәм хөкүмәткә дә бик күп файдалар биргәйсең».

Ф а л ч ы. Бәрәкалла, кызым, бәрәкалла! Талигаң яхшы булырга охшый. Шулай. Бәхетле бул, кызым. Күзләреңне шулай яхшылап кара, критика көзгесенә кара, фабриктагы җитешмәгән җирләрне тимер тарак белән тараган шикелле итеп, чәчләреңне майлап тара. Бәхетле булырсың. Мин сезнең алдыгызга берничә минутка гына килдем, кайда, тагы кемнәр фал ачтыра? Столовойда вакытында аш өлгермәсә, тамакларым ач тора.

Ө ч е н ч е к ы з керә.

Ө ч е н ч е к ы з. Бабай, миңа да фал ач әле. (*Акча сала.*)

Ф а л ч ы. Хәерле фал булсын, кызым, хәерле фал. Кооперативлар тулы мал, авызлар тулы май, бал. Получка акчаңны әрәм итмә, ни бирсәләр, шуны ал. (*Китабын ача, бер кәгазь алып бирә.*)

Ө ч е н ч е к ы з (*укый*). «И фал иясе, бу фал, кем, сиңа килде, синең бәхетең арыслан авызындагы сөяк шикелледер. Арыслан авызындагы сөякне алу никадәр кыен булса, синең бәхетеңне дә кулга төшерү шулкадәр кыен

булачак. Син ...дәге Закирова шикелле эшләмиче премия алырга, аны алгач та, койрыкны сыртка салырга, ...дәге Маркиева, Рәхимовалар шикелле буза чыгарып, контордан чыкмый ятарга телисең. Ләкин өстегездән карап торучы күзләр бик очлы булганлыктан, ул максудыңа ирешә алмагайсың. Ул яман ниятләреңне ташлап, урыныңда яхшы басып утыруың хәерле булган».

Бер егет керә.

Егет. Бабай, син сөйлисең дә сөйлисең, әмма минем турыда һич берни дә белмисең. Җә әле, миңа да фал ачып кара, ни диярсең? (*Акча бирә.*)*

Фалчы (*акчаны алып*). Була ул. Тик, егет, зинһар, дип әйтәм, 2 нче фабрик окунчнидәге[1] Зверев, сушилкадагы Галиев, сирийный стригальный цехындагы[2] Заһидуллина шикелле ясый күрмә прогул. Комсомол Таҗетдинов шикелле экспорт план сорвать итмә, администрация билгеләгән урында эшләми ташлап китмә. Уткузов шикелле бер көн йоклап, икенче прогулда һичбер нәрсә дә әйтергә белмичә аптырап калма. ОМКУЗдагы чимал склады фабкомы Саттаров шикелле, артистларга материал бирермен дип йөреп, материал алырга килгәч, качып калма. (*Кәгазь алып бирә.*) Мә, егет, укы. Егетләргә – егетчә. Егет эштә чыныксын. Яхшы, таза егетләргә яхшы фаллар да чыксын.

Егет (*укый*). «И фал иясе, бу фал, кем, синә килде. Синең талигаң тәвә кошы кебидер. Тәвә кошы да: «Йөк тарт!» дисәң, «Мин – кош!», «Оч!» дисәң, «Мин – тәвә» дип йөргән шикелле, син дә, 5 нче фабриктагы заводтан Ишмурзин шикелле, кешене критикага алырга бик оста булсаң да, үзең бернәрсә дә эшләмичә, «кайчан кайтырга вакыт җитәр икән» дип, сәгатькә күз салып торырга гына яратасың икән. Синең шикелле егетләргә мондый эшләр һич килешә торган эш түгел. [...] Заһидуллин белән Минһаҗетдинов дигән эшчеләр шикелле, «субботникка барабыз» дип, анда баручылар өчен пешерелгән ашны ашап, үзең эштән чыгып тайма. Эшчеләрнең һәркайсына да бертигез күз белән карарга өйрән. Иптәшләр суды председателе Евдокимов шикелле, 2 көн прогул ясаган бер мездрильщикка выговор биреп, аның үзе белән охотага чыккан иптәше Архипка, 3 көн прогул ясаса да, һичбер сүз дә әйтмичә яклап калган шикелле, эшчеләргә төрлечә

---

* Әсәр тәмамланмаган. Дәвамы икенче кульязмадан алынды.

карама. ОМКУЗда натуральный товарда эшләүче Сидорова шикелле – дүрт көн, Тизухин шикелле – бер көн, Михайлова шикелле – бер көн, Мөхәррәмова шикелле – өч көн, Юсупов шикелле – дүрт көн, Васильева шикелле – ике көн, Ключкова шикелле бер көн прогул ясап, үзеңнең дәрәҗәңне югалтма. 4 нче фабрикта яка цехындагы счетоводның августның беренче яртысы өчен жалованье бирергә дигән контрамаркаларны болгаткан шикелле болгатма, эшләреңне дөрес йөрт. Барлык цехларның счетоводлары да минем шикелле үк хисапларны болгатып йөртәләр дип, алардан үрнәк алма. Керүдән элек, чыгуыңны исәплә. Андагы эшчеләр шикелле, башта утынга язылып, акча ала башлагач, отказаться итмә. Бакчада үскән яшелчәләрне ашарга яратып, үз каравыгыздагы бакчада эшләргә дип чакыргач, контордагы хезмәтчеләр белән эшчеләр шикелле, эшкә бармый калма. 5 нче фабрикта эшләүче Шакирова шикелле субботникка бару өчен авансом премия сорама, шулай ук, контордагы Моркеева һәм Рәхимовалар шикелле, бөтенләй бармый да калма. Алар шикелле һушыңнан таеп обморокка да егылма. Торма җебеп, шулай булсаң, булырсың чын егет!»

Ф а л ч ы. Ярый, егет, мин дә тормыйм җебеп. Булсаң егет, тамакларыңны җебет. Сезнең яннан киткәнче өзелеп, әйдә бергә җырлап җибәрик тезелеп.

Тезеләләр, җырлыйлар.

## КОРФЕТДИН БЕЛӘН ТОРФЕТДИН

*

Корфетдин. Җә, әйт әле, иптәш, кайсы шәһәр зуррак: Мәскәүме, Казанмы?

Торфетдин. Син бигрәк акылсыз сүзләр сөйлисең. Аны җүләр кеше дә белер. Мәскәү Казаннан ун, егерме, утыз өлеш зур.

Корфетдин. Белмәдең шул, безнең Казан зуррак.

Торфетдин. Ул сүзне сөйләгән син – дурак!

Корфетдин. Бер дә түгел! Син үзең белмисең. Мәскәүнең бер башыннан икенче башына трамвай егерме минут йөри. Ә Казанның трамвае Яңа Бистәдән Арча кырына кайвакытларда икешәр сәгать менә.

Торфетдин. Ну?

Корфетдин. Ну! Шулай булгач, Казан Мәскәүдән зур була!

Торфетдин. Алай икән.

*

Корфетдин. Җә, менә тагы бер сүз сорыйм: ай яктысы яктыракмы, безнең Казан электригымы?

Торфетдин. Билгеле, ай яктысы яктырак. Ул бит кичләрдә бөтен дөньяны яктырта.

Корфетдин. Тагы белмәдең. Ай кичләрдә генә яктырта. Ә безнең электрик көпә-көндез бөтен шәһәрне яктырта.

*

Корфетдин. Инде иң актык мәртәбә сорыйм: водопровод күбрәк продукция бирәме, әллә «Кызыл Шәрекъ»мы?

Торфетдин. Билгеле, водопровод!

Корфетдин. Алай булса, син – чеп-чи дурак!

Торфетдин. Нишләп?

Корфетдин. Нишләп, имеш! Абыстайлар суны водопроводтан чиләк-көянтә белән ташып та өлгертә алалар, ә «Кызыл Шәрекъ» сырасын атлар бертуктаусыз кы-

рык чиләк керешле мичкәләр белән ташып та өлгертә алмыйлар.

Торфетдин. Җә инде, тагы бер генә сүз сора, аны да белмәсәм, аннан ары бер дә сорамассың.

Корфетдин. Ярый инде алайса, күңелең булсын: кош итләренең иң тәмле җирләре кай төше була?

Торфетдин. Белмим шул, минем кош итләре ашарга байлыгым юк шул. Җә, әйт, әйт әле, кай җире, ә?

Корфетдин. Тиресе!

Торфетдин. Җә, җә, әйт, тагы берәрне әйт. Бу юлы беләм.

Корфетдин. Тай итенең кай җире тәмле була?

Торфетдин. Алла, бигрәк инде син тагы, үзең хәзер генә әйтә торып та, шуны да белмәскә...

Корфетдин. Кай җире соң?

Торфетдин. Билгеле инде – тиресе!

*

Корфетдин. Ой, син үзең кайдагы буласың, шәһәрнекеме, авылныкымы?

Торфетдин. Авылныкы.

Корфетдин. Сездә яшелчә игәләрме?

Торфетдин. Игәләр.

Корфетдин. Күбрәк нәрсә игәләр?

Торфетдин. Кәбестә.

Корфетдин. Эре буламы?

Торфетдин. Электә мулла абзыйның чалмасы кадәрләре буладыр иде.

Корфетдин. Ә бу ел?

Торфетдин. Аны каян беләсең? Хәзер бит инде чалмасы түгел, мулласы да калмады.

Корфетдин. Тагы синнән шуны сорыйм әле: сатарга товарлары булмый торып, бу Татсоюз, тагы әллә ничә төрле союзлар, коры шүрлекләр саклап утырырга кешеләр яллап, нигә бертуктаусыз кибетләр ачалар?

Торфетдин. Анысын инде безнең шикелле надан халык кайдан белсен, бәлки, бик күп булгангадыр артык акчалар.

Корфетдин. Син шаярып сөйләшмә әле, син, киресенчә, бик күп нәрсә беләсең икән. Син миңа әйтеп бир әле: бу күн товары белән мануфактур товары кайчан күбәер?

Торфетдин. Анысы бик билгеле лә инде, анысын син үзең дә миннән яхшырак беләсең.

Корфетдин. Юк, белмим, әйт әле? Син нигә миннән көләсең?

Т о р ф е т д и н. Билгеле инде, һич кирәге булмаган кешеләр өчен күннән портфель, разный абыстайлар өчен ике кием батинка чыгарлык күннән сумка, төрле мануфактур-клеенкалардан зур-зур чемоданнар ясау азайгач.

К о р ф е т д и н. Һич кирәге булмый торып андый нәрсәләр күтәреп йөрүчеләр кайчан азаер?

Т о р ф е т д и н. Кайчан күбесенең кесә төпләре аязыр.

Кайда барсаң, кемне күрсәң, –
Йә портфель, йә чемодан;
Урамнардан үтеп булмый,
Узып китте чамадан.

И к е с е б е р г ә. Ничә миллионнар ясалыр
Әле тагы яңадан. } *(2 тапкыр.)*

Т о р ф е т д и н. Портфель белән эштән кайта,

Бик күбесе – мунчадан;
Күнең түгел, киндер түгел,
Һич тә төтмәс мунчалаң.

И к е с е б е р г ә. Күнең түгел, киндер түгел,
Һич тә төтмәс мунчалаң. } *(2 тапкыр.)*

*

К о р ф е т д и н. Нихәл, иптәш Торфетдин, эшләрең шәпме?

Т о р ф е т д и н. Зарарсыз гына. Бик шәп үк түгел түгелен дә, шулай да зарарсыз.

К о р ф е т д и н. Син продуктларны кайдан аласың?

Т о р ф е т д и н. ЗРК[1]дан. Ә син каян?

К о р ф е т д и н. СРК[2]дан. Әй, синнән шуны сорыйм дигән идем әле. Ул ЗРК белән СРК арасында нинди аерма бар соң?

Т о р ф е т д и н. Мин үзем синнән сорамакчы идем әле. Мин бернинди дә аерма таба алмыйм.

К о р ф е т д и н. Сездә нәрсәләр бирәләр соң?

Т о р ф е т д и н. Һичбер нәрсәдән дә отказ юк, егерме төрле кофи, теләгәнең кадәр ал.

К о р ф е т д и н. Ә чәй, шикәр, бал?

Т о р ф е т д и н. Акчаң күп булса, базарга чыгып теләгәнең кадәр ал.

К о р ф е т д и н. Ә соң он, ярма, май?

Т о р ф е т д и н. Син акылдан шаштыңмы әллә? Аларның кооперативта булмаганына инде әллә ничә ай.

К о р ф е т д и н. Ни өчен икән соң ул алай?

Т о р ф е т д и н. Мин үзем дә шуңар аптырыйм шул, малай.

К о р ф е т д и н. Колхоз ярминкәләре булды бит, алып булмый микәнни колхоздан?

Т о р ф е т д и н. Минемчә, булырга тиеш иде дә бит, алардан да шул әллә кая сызган.

К о р ф е т д и н. Соң бит базарларда абыстайлар, крәстиян хатыннары бик күп саталар майны!

Т о р ф е т д и н. Алары аның безнең өчен түгел, сыйлар өчен ул спекулянт белән байны. Һи, агай-эне, хәзерге вакытта аз-маз акчага кызыктыра алмассың крәстиян агайны!

К о р ф е т д и н. Ярый, анысы да булмасын, кайда киткән соң бу бәрәңге?

Т о р ф е т д и н. Кем белсен, бәлки, туйдыра торганнардыр кәҗә, сарык, сыер, бәрәнне.

*

К о р ф е т д и н. Торфетдин, әйт әле: паровоз тизрәк йөриме, машинистмы?

Т о р ф е т д и н. Билгеле, паровоз.

К о р ф е т д и н. Белмәдең. Машинист тизрәк йөри.

Т о р ф е т д и н. Ни юк сүзне сөйлисең, машина белән җәяүле кеше бер буламыни?

К о р ф е т д и н. Бөтен хикмәт тә шунда шул. Паровоз станциягә җиткәч туктап калды. Ә машинист аны узып, станциягә, буфетка чәй эчәргә кереп китте.

*

К о р ф е т д и н. Иптәш Торфетдин, син хисап беләсеңме?

Т о р ф е т д и н. Беләм.

К о р ф е т д и н. Белсәң әйт әле: ике бишең ничә була?

Т о р ф е т д и н. Ун!

К о р ф е т д и н. Белдең пычагым!

Т о р ф е т д и н. Ничә соң?

К о р ф е т д и н. Сигез.

Т о р ф е т д и н. Кит, җүләр!

К о р ф е т д и н. Бер дә җүләр түгел. Чынлап санасаң, сигезгә дә тулмас әле.

Т о р ф е т д и н. Ничек?

К о р ф е т д и н. Беренче пятилетканы игълан иттеләр, дүрт елга да тулды. Ә инде хәзер икенче пятилетка игълан ителде. Беренчесе дүрткә дә тулмаганны, икенчесе тулмый да тулмый инде. Тулса да, барыбер, ике бишең сигез булган була.

*

К о р ф е т д и н. Син, иптәш Торфетдин, көндезге ашны кайда ашыйсың? Өйдәме, столовойдамы?

Т о р ф е т д и н. Столовойда.

К о р ф е т д и н. Шәп ашаталармы?

Т о р ф е т д и н. Зарарсыз.

К о р ф е т д и н. Беренчегә нәрсә бирәләр?

Т о р ф е т д и н. Кайсы көнне – үрдәк шулпасы, кай көннәрдә – балык шулпасы.

К о р ф е т д и н. Ай-яй! Алай булгач, бик шәп сыйлыйлар икән!

Т о р ф е т д и н. Чибәр сыйлыйлар сыйлавын да, бары тик үрдәге белән балыгы гына әләкми.

К о р ф е т д и н. Нишләп?

Т о р ф е т д и н. Шулпа өчен дип су алырга барганда, үрдәге оча, ә балыгы су төбенә киткән була. Безгә бары коры шулпасы гына кала.

## ХАТИП БЕЛӘН ЛАТИП

И к е с е б е р г ә сәхнәгә чыгалар.
Берсе икенчесен халыкка таныштыралар.

Л а т и п. Иптәшләр, ханымнар, туташлар!
Ал бит, сөрмәле күз, нечкә итеп сызылган
кара кашлар!
Бу чибәр егет сезгә үзенең күргән-белгәннәрен
сөйли башлар.
Килешмәгән җирләрегезне әйтеп, тетеп
ташлар.
Танышып җибәрегез, арадан берәр матур яки
чибәрегез.
Бу чибәр иптәшнең исеме – Хатип.
Килә ул безнең җиргә шахталардан кайтып.
Сүз сөйләргә бик оста, әгәр тешләп тә җибәрсә,
утырырсың күзең акайтып.
Шәмдәй туры,
мәче ялагандай шоп-шома мыек чыга
торган урыны,
матур ук егет булып китәчәк,
аз гына курносрак булмаса борыны.
Һәрвакыт үзен тота эре,
сезгә куплетлар сөйләргә дип килгән бире.
Авызы кыек, сүзе сыек, күзе чепи булса да,
ямьсез түгел, чибәр үк төскә.
Егетнең кыяфәт шәп, күкрәк киң, биле нечкә.
Сезгә, безгә куплетлар сөйләмәкче бу кичтә.
Х а т и п (*үпкәләгәнрәк кыяфәт белән*).
Ә бу чибәр егет[нең] исеме була Латип.
Егетләр арасында бик булдыклы, бик чибәр,
бик матур тип.
Ул да шулай минем кук бире килгән,
сезнең алда куплетлар сөйләргә дип.
Чибәр егет, яшь әле, картайса да –
өйләнмәгән,
өйләнергә кыз белән эшләре көйләнмәгән.
Гайбәтләр, даннар белән дөнья тулды,
ул хакта калмады сүз сөйләнмәгән.

Өйләнергә егет күзли ударница,
«Өйләнәм», – ди, күңеленә ошап китсә.
Мәҗлесеннән сезне дә калдырмабыз,
әгәр дә туйлары булса-нитсә.
Егет шәп, кышын йөри ботинкадан сикереп,
биеп, җәйгә чыккач – киез итектән,
шома гына, башын иеп.
Сүзгә оста, сөйләгәндә телләре телгә йокмый,
сезгә килде: «Куплет, рассказ сөйлим», –
диеп.

Л а т и п. Җә, җитәр, күп торма ләчтит сатып!
Ни торасың сәхнәдә басып, катып?
Эш вакытын юкка, бушка уздырып торма,
Йә җырла, йә бие, бас тып та тып!

Х а т и п (*тамакларын кырып*).
Хәзер сөйлим, колак пружиналарын борыгыз!
Икмәк кибетендәге приказчиклар турында
сөйлим, яхшы тыңлап торыгыз!

Л а т и п (*Хатипның авызын каплап*).
Тукта, тукта, сабыр ит!
Үзем сөйлим, бар, син бер читкәрәк кит!
Яңлыш син минем таныш приказчик турысында сөйләмә,
җырласаң да, аның кенәгәсез икмәк сатуын көйләмә.
Кенәгәм булмаса да, ул миңа иртәгә:
«Бер буханка икмәк бирермен», – диде
өйләгә.

Х а т и п. Бүлдермә мине, җырларымны оныттырасың,
ходка киткән авыз машинамны кирегә борасың.

Җырлый.

Кирпеч икмәк җиде сум, кулга да тими,
давай!
Көн саен икмәк сатасың, кайдан аласың, бабай?

Л а т и п. Күңелемә ярамый, ташла инде шул икмәк
турындагы җырыңны!
Җырларга беткәнмени сиңа, тешлә башка
бер җитешмәгән урынны!
Җырла башка бер шүрлек авыз яки чөелгән
борынны!

Х а т и п. Ярый, бетте алайса, башка бер эш турында
җырлыйм.

Л а т и п. Нәрсә турында җырлыйсың?

Хатип. Минем нәрсә турында җырлавымның сиңа нигә кирәге бар? ... нче фабрик турында җырлыйм.

Латип. Син тагы андагы ...ның ... эше турында җырлый күрмә. Ул миңа күптән таныш кеше, кәефе китәр.

Хатип. Юк, мин ул фабриктагы ... цехы турында җырлыйм.

Латип. Алай булса, әйдә дуй! Мин дә катышам.

Җырлыйлар.

Конференция, собраньене соңга калып
ачалар,
Концертларга халык сыймый, җыелыш
дисәң – качалар.

Шул характердагы җырлар дәвам иттерелә.

## УДАРНИК ҺӘМ БЕЗДАРНИК

Сәхнәгә **ике пар кыз** белән **егет** чыгалар. Сәхнәнең ике ягында пар-пар булып торалар. Сәхнә алдына уенны **Алып баручы** чыга.

Алып баручы

Исәнмесез, эшче иптәшләр,
Без бирегә килдек, сез иптәшләрне
сагынып!
Болар нәрсә сөйләрләр икән дип,
Сез дә көтә торгансыздыр зарыгып!

Кайбер фабрикларга барып керсәң,
Анда тире илиләр;
Кайсына гына барсаң, анда
Ударник та бездарниклар турында
сөйлиләр.

Бездарный пар

«Эшлә» диләр, «эшлә» диләр,
Ничек итеп эшләргә?
Бүләкләрне дә бирмиләр
Безнең эше кешеләргә!

Шыштыр-пыштыр тик маташ,
Эшләрне бутап саташ!
Кайчан гына җитәр аш?
Бүген бик авырта баш!

Ударный пар

Бүген яхшы эшли баш!
Күкләрдән яуса да таш,
Көнлек планнар тулачак
Обедка кадәр, шабаш! } (*2 тапкыр.*)

Җырлап бииләр.

Тутыр, тутыр планны!
Арттыр, чыгарыйк данны!
Прогул, прорывка каршы
Ачыйк сугышлар канлы! } (*2 тапкыр.*)

Б е з д а р н ы й   п а р

Бирмиләр бит бүләк тә,
«Юк, – диләр, – сез үләткә!»
«Вон! Бар, чык, – диләр, –
фабриктан,
Йөрмә булып күләткә!» } (*2 тапкыр.*)

Җырлап бииләр.

Калдыкмыни көлкегә?
Керә алмабызмы рәткә?
Синең баш та эшләмиме?
Тырыш тизрәк, рәтлә! } (*2 тапкыр.*)

У д а р н ы й   п а р

Синең белән икебез
Үтик планны ике йөз;
Планнарны үтәү өчен
Барлык авырлыкка түз! } (*2 тапкыр.*)

Җырлап бииләр.

Китер кулың, бир миңа!
Бер булсын вәгъдәле сүз.
Ялкаулардан, бездарниктан
Эшләр чыкмас, өмет өз. } (*2 тапкыр.*)

Б е з д а р н ы й   п а р

Бирикме әллә без дә сүз
Калышмыйча эшләргә?
Эшләмәсәк, туры килер
Терсәкләрне тешләргә! } (*2 тапкыр.*)

Җырлап бииләр.

Эшләргәме, нишләргә?
Сүз бирикме эшләргә?
Сүз бирәбез ияргә
Ударник иптәшләргә! } (*2 тапкыр.*)

У д а р н ы й   п а р

Удар эшләр алып барып,
Көн-төн алга барабыз.
Буксиргә сезне алабыз,
Сез дә эшкә ярагыз!

Барысы бергә биеп китәләр.

Б е з д а р н ы й л а р. Ударник иптәшләргә!
У д а р н ы й л а р. Сүз бирәбез эшләргә! } (*2 тапкыр.*)

Б а р ы с ы   б е р г ә

Планнарны тутырырга,
Арттырып та эшләргә! } (*2 тапкыр.*)

## УДАРНИК

Катнашалар:
Кыз һәм Егет.

*Егет сәхнәгә ачуланып килеп керә.*

Егет. Үләм, туганнар, шартлыйм! Имеш, һәрбер надан кеше миннән көлсен, имеш, һәрбер надан кеше мине мыскыл итсен! Ел буенча акырдым, ел буена иптәшләрне ударник булып эшләргә чакырдым. Үзебезнең цехны башкалардан алга чыгарыйк дип тилмердем. Кычкыра-кычкыра тамакларымны бетердем. Хурлык бит, шулай да сине һаман «син ялган ударник» дип сүксеннәр, имеш! Бу бит, бу бит, шайтан белсен, әллә нәрсә бу! Кешегә премияләр бирсеннәр дә, ә син авыз күтәреп кал, имеш! Ә миңа соң? Юк, юк, мин бу хурлыкка түзә алмыйм. Болай булса, тотам да шартлыйм!

*Ачуланып йөри башлый. Сәхнәгә Кыз керә.*

Кыз

Нигә болай кәефең киткән, –
Әрле-бирле йөрисең?
Ударниклар премия ала,
Әллә шуны белмисең?

Егет

Китче әле, зинһар өчен,
Якын килмә яныма!
Мине сүгеп, хур иттең син
Бөтен халык алдында.

Кыз

Сүгәрлек тә бар сине,
Суганлап та борычлап;
Кеше эшләгән чагында,
Син йокладың тынычлап.

Е г е т

*(күкрәгенә сугып)*

Минме, минме эшләмәгән?
Мин бит чын, чын ударник!
Мин түгелме кычкыручы:
«Даешь темп, удар!» – дип.

К ы з

Шулмы булды файда итү
Совет төзелешенә;
Күпме премия алдың
Удар эш өлешенә?

Е г е т

*(аптыраган хәлдә)*

Эшләдем мин, күп эшләдем;
Никтер бик аз язганнар.
Күпме кычкырдым, акырдым,
Шулай да оныткannar.

К ы з

Синең акырынып йөрүең
Берәүгә дә кирәкми,
Эшеңдә ударник булып
Күрсәтмәгәч үрнәкне.

Е г е т

Нишлим соң инде мин хәзер,
Хур булдым бит, җаныем?
Нинди җаваплар бирим соң, –
Акча көтә әнием?

К ы з

Коры куык шартлатып
Мактануыңны ташла,
Безнең бригада күгүк
Ударный эшкә башла!

Б е р г ә

Дөрес, удар юлы белән эшкә башлыйк бергәләп,
Эш башыннан эш хакы алу – эш яхшыруга сәбәп.
Партия куша: бар эшне дөрес оештырырга!
Дөрес оештыру өчен тотынабыз укырга.
Партия безгә әйткәнчә, техниканы өйрәнеп,
Башлаганда удар эшкә, эшләр китәр көйләнеп.

# Шигырьләр

*1905 — 1910*

## АЗАТЛЫК

Әй, кардәшләр! Килеңез,
Күз яшьләрен силеңез,
Буган булсын билеңез,
    Эш мәзәкле кәлде – йә!

Иске коллык кадалсын,
Аның көлен җил алсын,
Азатлык ялгыз калсын,
    Пәк соңарып кәлде – йә!

Иске низам котырып
Җан бирә, нәгърә орып,
Шашадыр торып-торып,
    Каргалганын белде – йә!

Күп вәлиләр ярышты,
Манифестка карышты,
Корал-сары сарышты,
    Шәһидне күп кыйлды – йа!

Әрвахлары булсын шат.
Ил анларны кыйлсын яд,
Догалар кыйлып кат-кат,
    Азат анлар кыйлды – йа!

«Победонос»ның кулы[1]
Сынды, бикләнде юлы,
Очты мәкринең мулы,
    Биле бөглеп төшде – йә!

---

Силеңез – туктатыгыз.
Пәк – бик.
Низам – тәртип, режим.
Нәгъръә ору – каты кычкыру.
Шәһид кыйлу – корбан итү.
Әрвахлар – үлеләрнең рухлары.
Кыйлсын яд – искә алсын.

## ӨНДӘҮ

Әйдәгез, дустлар, бараек
Петербурга, мәсҗед салаек[1],
Бар икән кулда иркенлекләр,
Эшемезне эшләп калаек.
Дума җыеннары тиз җыелыр,
Һәрбер эшләр анда куелыр,
Күзен ачкан милләт алга китәр,
Күз ачмый йоклаган җуелыр!
Бер мондыз бардыр бу чакларда –
Аурупа аталган якларда,
Бу җирнең халкы да шулай уктыр,
Асияләрне изәр чакларда.
Аяк бөкләп, ашта утырып,
Көчләп-көчләп Коръән тутырып,
Искелекне йөри мактый-мактый,
«Яңылар – динсез», – дип котырып.
Торсак, безне Дума якламас,
Полициямез түгел бит, сакламас,
Аурупалык кыйлыр, басып изәр,
«Белмәү – яхшы эш», – дип хакламас.
Аллаһ разый булсын, кузгалыйк,
Без дә эшне юлга салыйк,
Югыйсә беттек, харап булдык!
Безне көтеп тормас халык...
«Казан мөхбире» дә басылды,
Җыелаек, юллар ачылды.
Шөкерләр кыйлам бер Ходайга:
Иске хөкем дарга асылды.
Уку белән – байлык табылыр,
Белмәгәндә – юлдан сабылыр.
Мәктәпләрдә укың! Уртак сатың! –
Соң киңәшем, дустлар, бу булыр.

---

Мондыз – ташкын, язгы ташу.
Аурупа – Европа.
Асия – Азия.

## РУСИЯДӘ МӨСЕЛМАННАР

### 1. Хөррияткә кадәр

Татарларны Русиядә бу көнгә чаклы
Тырыштылар җуялмый чаклый-чаклый.
Ә гәрчә бунлар аталды – «фанатик»,
«Дүнең!» – дигәнләрә күрсәттеләр җик.
Салабәттер бууларың тотдыгы юл,
Бу көнгәчә бел: бу юл иде кул.

### 2. Хөррияттән соң

Бу көннән соң азат булды татарлар,
Күзәт – бунтлар ничек адым атларлар!..
Һәммә мәктәп боларга ишек ачсын!
Фәләк дүнеп, боларга йинҗү сачсен!
Сәясәтчә морадлар булсын уртак,
Татар ничек егетлекләр кыйлыр, бак!
Тәрәкъкыйгә кыйлырлар яхшы коллык.
Шөкер! Бунларда гайрәт, көчкә муллык.

---

Чаклый-чаклый – чак-чак.
Дүнү – «ваз кичү» мәгънәсендә.
Җик – нәфрәт, азап.
Салабәт – каршылык, ныклык.
Кул – кулай.
Фәләк – фәрештә.
Йинҗү – энҗе.
Сәясәтчә морадлар – политик максатлар.
Тәрәкъкый – прогресс.

## БЕЗНЕҢ КИРӘК

Вакыт җитте, күземезне ачмак кирәк,
Җәһаләт, тәгассыбтан качмак кирәк;
Гел җәһаләт, тәгассыблә яшәү булмас,
Һөнәр, гыйлем орлыгы сачмәк кирәк.
Төрле-төрле гыйлем, һөнәр белмәк кирәк,
Һөнәр, гыйлем мәктәбенә кермәк кирәк;
Мич башына гыйлемлекләр килеп кермәс,
Гыйлем өчен аһ-ваһ итеп йөрмәк кирәк.
Үземезнең наданлыкны сизмәк кирәк,
Шул наданлык дошманыңы измәк кирәк.
Өйдә ятып эш тугъмады һәм тугъмайдыр,
Гыйлем өчен Аурупаны гизмәк кирәк;
Наданлыкны асрамаек! – Ташлау кирәк!
Милләт, диннең агачларын ашлау кирәк;
Наданлык – дөнья-ахирәт йөз карасы,
Ихлас илә гыйлемлеккә башлау кирәк;
Безне җиңгән япунга[1] күз салмак кирәк,
Күзне салып, шундыйн гыйбрәт алмак кирәк.
Анлар кебек булырга кирәк нәрсә:
Гыйлем, һөнәр юлларында калмак кирәк.
Бик карамыз, безгә бик тә гыйлем кирәк,
Һәм санаигъ, һәм мәгариф, каләм кирәк.
Барчамыз да төрле җиргә тузып беттек,
Үзара да берләшергә җилем кирәк.
Гыйлемлекне остаз итеп санлау кирәк,
Дин тамырын гыйлем илә җанлау кирәк.
Дин вә милләт җәһаләтлә үләчәкдер,
Белек илә милләт, динне җанлау кирәк,

---

Җәһаләт – наданлык.
Тәгассыб – караңгылык.
Санаигъ – һөнәр, промышленность.
Каләм (*кәлям*) – дин турында фән.

Гыйлем өчен төн-көн җиһад итмәк кирәк,
Аурупа, Америкага җитмәк кирәк.
Укымыйча харап улдык, беләсезме?
Укыр өчен төрле җиргә китмәк кирәк,
Һәр авылга олугъ мәктәп салмак кирәк,
Укытырга җанлы хәлфә алмак кирәк.
Ярты-йорты уку илә эш чыкмады,
Ихлас куеп дәресләрдә калмак кирәк.
Күңелемезне гыйлем илә нурлау кирәк,
Укыган адәмнәрне зурлау кирәк.
Галимнәрне күп хурладык – җитәр инде,
Суфи сыман наданнарны хурлау кирәк.
Кальбемезне белек илә пакьләү кирәк,
Фикеремезне, юлымызны хаклау кирәк.
Наданлык, каралыкләә череп беттек,
Гыйлем илә үземезне саклау кирәк.

---

Җиһад иту – сугышу, тартышу.
Амрика – Америка.
Кальб (*калеб*) – күңел.

* * *

И мөселман, йокламагыл,
Ачкыл инде күзеңе,
Агъзын ачкан аждаһалар
Йотмасыннар үзеңе.

Күпме еллар сурды, дустым,
Ач сөлекләр каныңы;
Каның илә туймас анлар,
Алачаклар җаныңы.

Аңга килгел, и мөселман,
Сизсә тизрәк хатаңы –
Гыйлем иткел имамыңы,
Зинһар, итмә – атаңы!

Һөнәр, гыйлем, мәгърифәтле
Нурлы кыйлгыл миеңе;
Әсарәтне өзәчәк ул,
Яхшы итәчәк сыеңы.

Һөнәр, гыйлем чырагыйлә
Якты иткел юлыңы;
Үз-үзеңне коткарырга
Дәхи үгрәт кулыңы.

Җәһаләткә бирмәгел баш,
Һәлак итәр үзеңе;
Дөньяда һәм ахирәттә
Кара кыйлыр йөзеңе.

---

Сурды – суырды.
Әсарәт – әсирлек.
Дәхи – янә, тагын.
Җәһаләт – наданлык.
Чырагыйлә (*чырагы илә*) – чырасы белән.

Мәгърифәтнең, зыясыйлә
Әйлә ачык уеңы,
Шул чагында ач бүреләр
Үлчәмәсләр буеңы.

Гыйлем иткел юлдашыңы,
Яхшы итәр ул хәлеңе,
Күп итәчәк дәүләтеңе,
Байлыкыңы, малыңы...

Бик югары дәрәҗәгә
Беңгезәчәк үзеңе...
Инглизнең сүзе кебек
Итәчәк һәм сүзеңе.

---

Беңгезәчәк – менгезәчәк.
Зыясыйлә (*зыясы илә*) – яктысы белән.

## МИЛЛӘТ КӨЙМӘСЕ

Милләтнең көймәләре астка баткан,
　　Өстенә биш колачлы боз да каткан.
Бозының очы-чиге һич күренми,
　　Өстенә тагы аю менеп яткан.
Иншаллаһ, бер заманда кояш чыгар,
　　Нуры илә аюларны бәреп егар.
Бозларыны эретеп, төрле якка –
　　Төньягына, Котыпларга илтеп тыгар.
Хак теләсә, шушы кояш тиздән калкыр.
　　Күрми калмас һичбер кеше, шундый балкыр:
Ярканат, озынборын, ябалаклар,
　　Нурына чыдый алмый, күзе ялкыр.
Болытсыз көн кояшыдай нурын сачер,
　　Ябалак, ярканатлар – бар да качыр,
Караңгылык, калын бозлар – бар да бетәр,
　　Көймәмезгә йөремгә юлны арчыр,
Һич калмый калын бозлар бары эрер,
　　Менә шунда көймә карап бар да йөрер.
Көймәмез төне-көне юллар алып,
　　Туңмый торган диңгезләргә барып керер.
Көн ягына бертуктамый юллар алыр,
　　Шундай алыр, бөтен адәм хәйран калыр.
Фортына булмас, өермә белмәс лиманнарга
　　Керсә керер, шунда гына тимур салыр.
Һич туктамый диңгезләрдә тулай йөзәр.
　　Көймәнең екетләре балык сөзәр,
Туктаганда, су төбенә чумучылар
　　Энҗе-мәрҗән сөзеп, җепкә тезәр;
Яхшы урын кайда булса, шунда гизәр.
　　Яхшылыкны бик ерактан күреп сизәр.

---

Лиман – култык, диңгез култыгы.
Тимур – якорь.

Борынгы төньягына мәңге кайтмас,
Кайтканда катачактан – шуңар бизәр.
Диңгездә йөзүендә балык булыр,
Ярдәмчесе ул көймәнең – халык булыр.
Кыйммәтле асылташлар атау булса,
Ул атауның барчасына малик булыр.
Ул көймәнең башлыклары зирәк булыр,
Андай зирәк дөньясында сирәк булыр.
Хәзерге кибәк башлар анда юктыр,
Гакыллылар ул көймәгә кирәк булыр.
Хәзерге ала карга анда булмас,
Кайда булу, машена да килеп кунмас.
Кунса да, мылтык илә атачаклар,
Димәк ки, каргаларның эше уңмас.
Капитаны ул көймәнең күзле булыр,
Кояш кебек нур сачүче йөзле булыр.
Көймәсе яхшы юлдан асла чыкмас,
Шундый гаҗәп тыңлаерди сүзли булыр.
Арттан җитеп, һәр көймәне узып китәр,
Һичбер көймә чыдый алмас дулкынына,
Дулкыннарга гаркъ булып, тузып китәр.
Көймәнең кыйбламәсе замин улыр,
Һәрбер җире шуңар күрә әман булыр,
Әмма башка көймәләрнең эче-тышы
Ул чагында кайгулы һәм ямин улыр.

---

Малик булу – ия, хуҗа булу.
Маш – мачта.
Гаркъ булу – суга бату.
Асла – бөтенләй.
Кыйбламә – компас.
Замин улу – ышанычлы, гарантияле булу.
Әман – куркынычсыз, тыныч.
Ямин – моңсу.

## ЙОКЫДА

Барча милләт китте алга,
Без һаман да ятамыз,
Динемезне, үземезне
Мәңгелеккә сатамыз.
Бар да торып алга киткән,
Без һаман да тормыймыз,
Һөнәр, гыйлем, мәгарифкә
Дүрт кул илә сармыймыз.
Һәммә милләт алга бара,
Илла безләр бармыймыз,
Мәгарифкә, санаигъкә
Иҗтиһадлә сармыймыз.
Аурупалар очты күккә,
Без чокырда ятамыз,
Җәһаләтлә, каралыклә
Җир төбинә батамыз.
Башка милләт дөнья гиздe,
Без һаман да гизмимез,
Кайда гизү булсын әле –
Җәһаләтне сизмимез.
Башка милләт дөнья били,
Әйтсә, без ни билимез?
Без биләгән – бер наданлык,
Менә шулай димимез.
Башка милләт көри алтын,
Без тиреслек көримез.
Анлар өсттә, безләр астта,
Һични белми йөримез.

Санаигъ – һөнәр.
Иҗтиһад – тырышлык.
Җәһаләт – наданлык.

Анлар алмас ватканында,
Без кара таш ватамыз,
Гыйльмемез юк, малымыз юк, –
Һаман астка батамыз.

Башка миллəт күрə рəхəт,
Без мəшəкъкать күрəмез,
Кайда байлык, кайда дəүлəт, –
Күпме рəхəт сөрəмез?
Китте дəүлəт кулымыздан,
Үксез улып йөримез,
Юк тəрəккъкый, юк химаять,
Язгы кардай эримез.

---

Химаять – яклау.

## ЕГЪЛАМАГАН БАЛАГА ИМЧӘК БИРМИЛӘР

Теләгәнен биру, – гадәт, – аңлаганга,
Мәкъсудына һиммәт бавын багълаганга.
　　Анасы имчәк бирә баласына –
　　Канлы яшьлә туктамыйча агълаганга.
Бирми булмый канлы күзлә караганга,
Кара кошди кирәкене араганга.
　　Хосусән биреләдер шул кешегә –
　　Каршы торып, киреленкә яраганга.
Өлеш бирми бүленмидер – даулашканга,
«Безгә дә бир» дәю каты шаулашканга.
　　Куянга вирелгәндер аюдан җөзьә
　　Урманнан бергәләшеп каулашканга.
Колакы салынадыр куча сүзгә –
Кучалыкның әсәрләре тәмам үзгә.
　　Әрмән, фин, поләкләрнең вакыйгасе
　　Кояш кеби ап-ачыктыр күрер күзгә.
Олугъ файда ирер, дустлар, берләшүдә,
Бер булып, юлын белеп гөрләшүдә,
　　Үзара сугышып һич файда юк,
　　Милләтнең тузуыдыр төрләшүдә.
Вакыт җитте тузышуны ташлашырга,
Кулны кулга биреп, эшне башлашырга.
　　Тәрәккъый, мәдәният, заман хален
　　Үз арада бик пөхтәләп кашлашырга,

---

Һиммәт – кайгырту, ярдәмләшү.
Яшьлә (*яшь илә*) – яшь белән.
Күзлә (*күз илә*) – күз белән.
Кошди – коштай.
Араганга – күзәткәнгә.
Хосусән – бигрәк тә.
Җөзьә – өлеш.
Куча – батыр, кыю, акыллы.
Әсәр – тәэсир.
Кашлашу – «бизәү», «матурлау» мәгънәсендә.

Фарыз булды ихтиляфны куюшырга,
Бу заманда хәрам карендәш суюшырга.
　　Милләт намен, диннең исмен җир йөзеннән
　　Үз кулың, көчең илә җуешырга.
Килешми хәзер, дустлар, талашырга,
Туган канын балдай итеп ялашырга.
　　Тугърысы – олугъ юлны куеп, дустлар,
　　Караңгы төн ягына адашырга.
Заман җитте күчәрләрне майлашырга,
Торыр өчен рәхәт урын җайлашырга.
　　Кешеләр кебек, үземезгә муафикъ җир
　　Бик исәпләп, фикер илә сайлашырга.
Кул вирик бер-беремези саклашырга,
Дошман тигән карендәшләри яклашырга.
　　Арага кереп калган тигәнәктән
　　Милләтнең күзләрене пакьләшергә.
Бу җиһанда оят милләт йоттырырга,
Үзәккә тигәннәрне оттырырга.
　　Әлхасыйль, ишкәләргә ирек куеп,
　　Куян булып, үз-үзеңи тоттырырга.

---

Ф а р ы з  б у л у – тиеш булу.
И х т и л я ф – ызгыш, талаш.
Н а м – исем.
М у а ф и к ъ – яраклы, килешле, урынлы.
П а к ь л ә ш ү – сафландыру.
Ә л х а с ы й л ь – җыеп әйткәндә, озын сүзнең кыскасы.
И ш к ә (*ищейка*) – «эзләүче эт» мәгънәсендә.

## ВАКЫТ ҖИТТЕ

Вакыт җитте урынымыздан кузгалырга,
Гыйлем, һөнәр коралларын кулга алырга,
Милләтемез адашып, катып бетмеш,
Инде кирәк адашканны юлга алырга.

Гыйлем, һөнәр юлларында узышырга,
Ярдәм өчен кулны кулга сузышырга,
Бинаның нигезене берлек итик!
Хәрам безгә борынгыча тузышырга.

Тәрәкъкый, мәгарифне каулашырга,
Үземезгә кирәкләрне аулашырга,
Үземезнең кисәкләрне ятка бирмик!
Гайрәт итик шушы чакта шаулашырга.

Туганнар, тырышаек котылырга,
Риза булмыйк һаман болай сытылырга,
Җитәр инде, күп чыдадык, сабыр иттек –
Читлектәге көртлек кебек тотылырга.

Вакыт җитте иҗтиһадлә тырышырга,
Нигезләрне бик нык итеп корышырга,
Әүвәлдә наданлыкка сырган кебек,
Ушбу чакта мәгарифкә сырышырга.

Гыйлем, һөнәр юлларында чабышырга,
Берлек җебен азу тешлә кабышырга,
Күзне ачып гайрәт илә, хәмиятлә
Бергә-бергә ни яхшыны табышырга.

---

Иҗтиһадлә (*иҗтиһад илә*) – тырышлык белән.
Азу тешлә (*азу теш илә*) – азу теш белән.
Хәмиятлә (*хәмият илә*) – яклау белән.

Вакыт җитте урынымызны җайлашырга,
Милләтнең күчәрләрен майлашырга,
Һаман болай астта калып черемәек,
Кирәк хәзер яхшы урыннар сайлашырга.

Заман хәзер мәгърифәткә атланырга,
Төрле фәннәр, гыйлемлекләр ядка алырга,
Чүбек чәйнәп май чыкмады, чыкмаячак,
Файдасы ни, нигә аңа шатланырга.

Серләрне үз арада аңлашырга,
Яндык, беттек, җитте вакыт агълашырга.
Тагын да әүвәлгечә тузышыйкмы?
Фарыз безгә кисек җепне баглашырга.

Кирәк инде кирәкләрне сагышларга,
Хыяләтне шайтаннарга багышларга,
Күзне ачып, туганнарым, карыйк әле! –
Дөньядагы куркынычлы агышларга.

Хәрам безгә юлымызны яздырырга,
Тугъры юлдан халкымызны аздырырга.
Гыйрәт илә тырышаек без шунарга:
Милләтне мәгърифәткә бастырырга.

Оят безгә наданлыкка катышырга,
Дин карендәшен чокырларга атышырга,
Каралыклә иләс-миләс, берни белми,
Динемезне кулымызлә сатышырга,
Дин карендәшен кулымызлә суюшырга,
Көлен күккә итеп куюшырга.
Гаме белем, гыйлем булып, диям дустлар:
Ислам нурын җир йөзеннән җуюшырга,
Ярамый мәгарифтән качышырга,
Тәрбияләп, наданлыкны чәчешергә*.
Тугърысы – наданлыклә, каралыклә
Бату, бетү юлларыны ачышырга.
Көлке хәзер әүвәлгечә адашырга,
Тугърылыкны артка ташлап, саташырга.
Аурупалар җирне кулга алган чакта,
Әбҗәт, иҗек, кәләмәнлә маташырга,

---

* Авторда: сачишурга.

Хыяләт – мәгънәсез хыяллар.

Әбҗәт, кәләмән – иске әлифба хәрефләрен атау сүзләре.

Тәманигъ, халь хак укышырга,
Ач этәчтәй күзне-битне чукышырга.
Курапаткин[1] – ау яманы, беләсезме?
Кирәк безгә шулар гыйльмен укышырга.
Артык оят үз арада егышырга,
Чүпле таяк күземезгә тыгышырга,
Бар файдасы – иттифакъны буташырга,
Котырган ач эт кебек косышырга.
Килешми шилә-шилә йотылырга,
Төрле капкын-тозакларга тотылырга,
Белек, һөнәр укыйк, фәннәр, мәгарифләр,
Шулай булса, ирешермез котүләргә.
Башны бирмик хәмиятсез яманнарга,
Гыйлем, халык гайрәтләре таманларга
Коръән, хәдис, гыйлемлеке амам итик!
Алданмыйк, газиз дустлар, шаманнарга,
Хак, батыйльне аермаган аңсызларга,
Үзен-үзе батыручы сансызларга,
Мие, гаклы, аңы, җаны черүчеләр –
Һични белми ашап яткан җансызларга.
Динен, үзен, милләтне сатучыга,
Наданлыкта череп, сасып ятучыга,
Газиз динен һәм милләтен сөйрәп барып,
Төбе юк сазамыкка атучыга.
Каралык шомлыгыйлә катучыга,
Наданлыкны акча белән сатучыга,
Дөнья, ахирәт, дине, үзе, милләтилә
Белмиенчә, кәефләнеп ятучыга,
Әлхасыйль, наданлыкны яшәткәнгә,
Һөнәр, гыйлем, мәгарифкә таш атканга,
Үзен олугълы санап, белмәенчә,
Милләт, динне дошманнарга ашатканга.
Бу сүз лязим идер инде аңлаганга, –
Арттальктан төне-көне агълаганга, –
Аурупа, Американы күр вә уйла, –
Һөнәр, гыйлем укуга бил багълаганга!

---

Тәманигъ – тиешсез нәрсә.
Халь хак – тиешле нәрсә.
Иттифакъ – берләшү, союз.
Хәмиятсез – «игелексез» мәгънәсендә.
Амам – максат, маяк.
Батыйль – ялган.
Лязим – тиеш, кирәкле.

## «ЯШЕН»[1] СУКМАСЫН ӨЧЕН

(*Муллалар ушбу доганы укырга тиеш*)

Буннан соң начар эшләр кылмас идем,
Надан угълымны урыныма куймас идем,
Мужикларның җилкәсен дә суймас идем,
И Раббем! Мине «Яшен» сукмасын ла!

Малымнан зәкят тими димәс идем,
Ятимнәрнең малына да тимәс идем,
Көне-төне бәлеш ашап йөрмәс идем,
И Раббем! Мине «Яшен» сукмасын ла!

Мәдрәсәгә дәрескә дә керер идем,
Намазга да биш вакытка йөрер идем,
Вәгазьләр дә сөйләп-сөйләп бирер идем,
И Раббем! Мине «Яшен» сукмасын ла!

Гыйлем-фәннең кирәклеген икърар итәм,
Акчам бик күп, бу ел ук хаҗга китәм;
«Уку – хәрам» диюдән тәүбә итәм,
И Раббем! Мине «Яшен» сукмасын ла!

Буннан соң бик суфи да булачакмын,
Әфьюн ашау, вак салуны куячакмын,
Җәдитләрне гайбәтләүдән туячакмын,
И Раббем! Мине «Яшен» сукмасын ла!

Ишан булып моннан соң кеше алдамам,
«Сөннәт»[2] диеп өч-дүрт хатын һич тә алмам,
Бохарилар мәҗлесенә[3] һич тә бармам,
И Раббем! Мине «Яшен» сукмасын ла!

---

Вак салу – «тел астына вак тәмәке салу» мәгънәсендә.

## ОРЕНБУР – КАЗАН

(*«Бакырган»*[1]*нан*)

Оренбур, Казан мактаныша,
Мактануда мәгънә бар;
Оренбур әйтә: «Мин баймын,
Миндә Рәмиев һаман бар».

Казан әйтә: «Юк синдә,
Барча байгура миндә.
Синдә Рәмиевләр[2] булса,
Помещиклар миндә бар».

Оренбур әйтә: «Мин баймын,
Куй мае миннән чыга;
Минем Мәхмүд байларым[3]
Барчасын бәреп җыга».

Казан әйтә: «Юк синдә,
Читек, кәләпүш миндә;
Синдә Мәхмүд байлар булса,
Юнусовлар[4] бар миндә».

Оренбур сүзен бирми,
Казанны бик нык тирги:
«Күрмисеңмени, миндә
«Вакыт»[5], «Чүкеч»[6] бар бит», – ди.

Казан әйтә: «Мактама
«Вакыт», «Чүкеч»ләреңне,
Минем «Йолдыз»[7], «Ислах»[8], «Яшен»[9]
Чәнчелдерер барыны».

Оренбур әйтә: «Сөйләмә,
Юк көйләрне көйләмә,
Минем «Шура»м[10] бар вакытта
Юл бирелмәс кемгә дә».

Казан әйтә: «Мактама,
Журналмыни ул «Шура», –
Иске төрек китапларын
Татарча итеп бора.

Ничә төрле җәмгыять,
Матбага һәм клублар,
Мәдрәсәләр, мәктәпләр,
Университетлар миндә бар.

Миндә ничә матбага,
Биш-алты көтебханә;
Оренбур, моны күрмичә,
Нәрсәсенә мактана».

Оренбур тәүбәгә килде,
Казанга гозер кыйлды;
Тәүбәгә килмәс иде –
«Яшен»челәр анда бар.

## МӘХБҮС ШАҺЗАДӘ

Ничә еллар бу бинада ялгыз ултыра башым,
    Бер савыт су, бер телем икмәк ирер бәнем ашым.
Күрмәде һич ике күзем якты дөнья йөзине,
    Төне-көне егълый-егълый бетте инде күз яшем.

Хәсрәт утының сөреме каплады күзләриме,
    Ут кабынган йөрәгемә, тышка да чыга аһы.
Аһ, насыйб булырмы миңа якты дөньяны күрү,
    Әллә бу зиндан эчендә чыгачак газиз җаным.
Кәтифә күк яшел улуб тора микән җир йөзе,
    Әллә яндырып бетердеме аны да күз яшем?
Бакчаларда сандугачлар сайрый микән әле дә,
    Әллә анларны да тоткын итте микән дошманым?
Кайда китте яшь вакытым, назлы үскән чакларым,
    Йөз мең алтын торыр иде бәнем атланган атым.
Чыга торган идем ауга башыма таҗлар киеп,
    Инде таҗ урнына калды бу озын кара сачем.
Алтын илә бизәгән иде бәнем тәхетләрем,
    Тәхетемдер инде хәзер шушы ултырган ташым.

---

Мәхбүс – тоткын.
Шаһзадә – патша улы.
Кәтифә – хәтфә.

## «ТӘКЫЙ ГАҖӘБ»[1]

Замана ахыры булса, ниләр булгай,
Дөньяга төрле-төрле качкын тулгай,
Ишаннар мужикларның тиресен суйгай,
Мондыйн артык тәкый гаҗәб
дыңларый вар.

Сорыкортлык, эшсезлек яхшы, уңгай,
Бәдәлчеләр[2], саилчеләр дөнья тулгай,
Эшсез йөрү нәфес өчен була уңгай,
Мондыйн артык тәкый гаҗәб
дыңларый вар.

Тугызынчы елда бер гаҗәб булгай:
Наданнарны мөфти ахунд итеп куйгай,
Чүәкчеләр мәдрәсәгә назыйр булгай,
Мондыйн артык тәкый гаҗәб
дыңларый вар.

Мондыйн соң дәхи дә нәләр булгай,
«Артист мин» диючеләр дөнья тулгай,
Җыен начар, фахишәләр артист булгай,
Мондыйн артык тәкый гаҗәб
дыңларый вар.

---

Дыңларый вар – тыңлыйсы, ишетәсе бар.
Назыйр – надзиратель.

## БӘЙРӘМ ХӘЗЕРЛЕКЛӘРЕ

### Байларда

Узып китте шәриф ай да,
Эш бик начар Шәриф байда,
«Бәйрәм яңалыгы кайда?
Китер!» – ди өч абыстай да.

Бере яңа жикет даулый,
Бере «калфак!» диеп шаулый,
Бере байны тәмам аулый,
Сорый бик күп ислемай да.

Шәриф байның башы каткан,
Яңа ярминкәдән кайткан,
Малын зарар итеп саткан,
Итә алмаган тиен файда.

Алып кайткан иде бүләк,
Ничә генә асыл күлмәк,
Төрле майлар ничә чүлмәк,
Канәгать юк бу тутайда.

Сорый һаман: «Яңалык», – ди,
«Яңа батинкә юк бит», – ди,
«Туганыма алдың бит, – ди, –
Миңа да бир, китер, кайда?»

Чара юк һич котылырга,
Нигә генә тотынырга,
Тәкъдир иткән отылырга,
Сала алмый эшне һич җайга.

---

Шәриф ай – мөселманнарда дини бәйрәм, рамазан ае.

**Фәкыйрьләрдә**

Күрең кадир кодрәтен,
Эшли, йөгрә көн дә төн,
Бәйрәмгә бар ике көн,
    Шатлык җитә, тидия[1].

Бәйрәм ашы салырга
Он, май кирәк алырга,
Акча кайдан табарга,
    Аптыраштыр, тидия.

Productивы

Кактырасы бар ишек,
Кәвеш төбе дә тишек,
Бишмәт алырмын ничек,
    Бик читен бит, тидия.

Кәләпүш тә бик тузган,
Бүрек тә хәттин узган,
Кесәдә тузан тузган,
    Харап эшләр, тидия.

Түлисе бар кергә дә,
Утын һәм күмергә дә,
Котылмам гомергә дә
    Бурычымнан, тидия.

Аласы бар чәй, шикәр,
Фытырга[2] күпме китәр,
Егерме тиен дә җитәр,
    Мин бай түгел, тидия.

---

Кадир – Алла.
Хәттин узу – чиктән ашу.

# Декламациялəр

*1918 — 1921*

## ЯҢА «ТƏКЫЙ ГАҖƏБ»[1]

Берзаманны Казанга чехлар килде,
«Большевиктан коткарабыз сезне», – диде.
Бу сүзгə байларның бик кəефе килде,
Бундыйн артык тəкый гаҗəб дыңларый бар.

Байлар бирде ярдəмнəрне меңлəп-меңлəп,
Кызыл маллар, ситсыларны иңлəп-иңлəп,
Чехлар да озатты аны иплəп төйнəп,
Бундыйн артык тəкый гаҗəб дыңларый бар.

Байларның ялчылары чатыр чаба,
Сугышырга солдатлар да эзлəп таба,
Озаталар бер-бер артлы Идел таба,
Бундыйн артык тəкый гаҗəб дыңларый бар.

Байлар ача амбарының йозакларын,
Кызганмыйлар маллар, акча һəм атларын,
Чехларга тоттыралар ни булганын,
Бундыйн артык тəкый гаҗəб дыңларый бар.

Муллалар да – бар да байлар яклы була,
«Аклар җиңсен иде» диеп дога кыйла,
Ул чагында кесə төшем белəн тула,
Бундыйн артык тəкый гаҗəб дыңларый бар.

Əфитсəрлəр погоннарын кия башлый,
Солдатлар «Смирно!» честь бирə башлый,
Байлар кызыл əлəмнəрне җыртып ташлый,
Бундыйн артык тəкый гаҗəб дыңларый бар.

Калдырмыймы солдат кием һəм чалбарын,
Озаттылар Самар таба казна амбарын,
Китəргə дə вакыт җитте, тулды карын,
Бундыйн артык тəкый гаҗəб дыңларый бар.

Җеназа мәйданында[2] мөселманнар
Лебедевның[3] сул ягына кысылганнар,
Кавалерия төзергә дә тотынганнар,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

Самарадан особыйлар[4] бик күп килмеш,
Аның берсе мөселман-мөэмин ирмеш,
«Милләт, динне сакларга килдем», – димеш,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

Бервакытны шактый гына чыкты гауга:
Большевиклар килеп җиткән Биектауга;
«Халыклар» бармый башлый шунда яуга,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

Эш рәтсезен сизәләр дә шыпырт кына
Әфитсәрләр китә башлый, посып кына,
«Яңа»ларга сугышырга кушып кына,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

Лебедев: «Казаннан һич чыкмыйбыз», – ди, –
Большевикны Казанга кертмибез», – ди.
Үзе тизрәк качып китәргә юл эзли,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

Снәрәтләр шәһәргә дә төшә башлый,
Штабтагы кешеләр дә кача башлый,
Большевиклар бетерерләр, диеп, башны,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

Шул көнне: «Чигәргә!» – дип фәрман була,
Чигүчеләр Лаеш юлларында тула.
Төнлә белән чехлардан җил искән була,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

Алар белән Казан байлары киткәннәр,
Бара-бара Лаеш шәһренә җиткәннәр;
«Бичара»ларны бигрәк тә рәнҗеткәннәр,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

Тиз заманда шундый эшләр узып китә,
Дөньяга төрле хәлләр булып китә;
Уйласаң, күңелләр дә тулып китә,
Бундыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

## ТАГЫ «ГАҖӘБ» КИТАБЫ

«Торговый дом Әүлия һәм компаниясе»
Фабрикасы сезгә һәр көн шигырь ясый;
Тәме юктыр, чөнки түгел ул манпасый,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле[1].

«Әүлия» күп, аларның берсе – Вәли[2],
Икенчесе аның тагы – ишан Гали[3].
Ишаннарга безнең халык ышангалый,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

Күп хәбәрләр китерәдер безгә халык,
Габдулла һәм Галиулла, Габделхалик,
Без аларны хәбәр итеп язып барыйк,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

«Байлар бик сусаганнар кызыл канга», –
Дип, ярлылар киләләр безнең янга,
Санамый, дип, байлар безне һичбер санга,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

Безгә килеп, борычлар да өшкертәләр,
Шуны иснәтеп, байларны төчкертәләр,
Ярлыларга шактый гына көч кертәләр,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

Инде бик күп байлар кайткан Казанга, ди,
Приказ булган «Әүлия»га язарга, ди,
Бу хәбәрне сөйләгәннәр базарда, ди,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

Соңгы көннәрдә байлар бик китте азып,
Алтын-көмешне күмәләр җиргә казып,
Бетереп булмый барын да бунда язып,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

Кайчан да булса әле без, тагы барып,
Барысын да чыгарырбыз бер актарып,
Тормасыннар «котылдык» дип бик шатланып,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

«Окоп казырга барудан баш тартканнар,
Андыйларны, имеш, йөзләбен атканнар», –
Шулай итеп базарда «суган сатканнар»,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

«Красныйлар талыйлар», – дип, ашлык килми,
Шуның өчен базарда ашлык кими,
Акчалы байлар бу эшкә каршы килми,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

Ситсы товар магазинда тәмам беткән.
Спекулянтлар кесәсе тәмам кипкән,
Шулай да берсе Мәскәүгә дип киткән,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле. (...)

Гәзит язган: «Яраплан очрабыз», – дип, –
Казанны вәйран хәлгә төшрәбез», – дип;
Халыклар да каушаганнар: «Күченәбез», – дип,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

Дөньяда ниләр барын без беләбез,
Әгәр көлке хәбәр булса, без көләбез,
«Әүлия»лар кармагына элдерәбез,
Бундыйн артык тагы гаҗәб булыр әле.

## «КЫЗЫЛ АЛМА» КИТАБЫ

Күрең кызыл кодрәтен,
Белсен, диеп, куәтен,
Совет җөмһүриятен
Нинди күрекле кыйлдыя.

Байлыкларның ни барын –
Урман, кыр һәм суларын,
Йорт-җирләрнең зурларын
Халык милке кыйлдыя.

Халыкларны кыйлды азат,
Буржуйлар китте назад,
Алпавыттан һичбер зат
Калдырмады, тидия.

Байга юк һичбер кадер,
Алдында аның – кабер,
Эшче дөньясы хәзер –
Хуҗа шулар, тидия.

Бай, алпавыт яки поп,
Аксөякләр хәзер юк;
Һәммә кеше бертигез –
Серый шинель кидия.

Солдатка элек ярлы
Кешеләр генә барды,
Байлар котылып калды
Оборонда, тидия.

Хәзер котыла азы.
Буржуй да окоп казый
(Ягъни сугышлар базы)
Тирән итеп, тидия.

Байлар бик күп йөрделәр,
Төрле рәхәт сөрделәр,
Бу көннән соң эшче йөрер
Дышлаларда, тидия.

Бай бик тәкәббер иде,
Карамады мужикка,
Инде ул килә ишеккә
Икмәк сорап, тидия.

Байның эше күңелсез:
Байлык булган гомерсез;
Бу көннән соң күрерсез
Нужаларны, тидия.

Ята алмассыз эшсезгә,
Без табарбыз эш сезгә,
Булмас җәбер көчсезгә
Бу көннән соң, тидия.

Ярлы – эшнең башында,
Буржуй аның кашында
Күтәрә алмый башын да –
Җиңелде шул, тидия.

---

Д ы ш л а (*дышло*) – бер тәртәле арба, фаэтон.

К а ш ы н д а – «каршында» сүзенең революциягәчә шундый язылышы да булган.

## «АК»КА ШӨКЕР» КИТАБЫ

«Ак»ка шөкер идәлем һәр ан,
Түгә алмады әле күп кан,
Кызыл гаскәр җиңү белән,
Исән калды ничә мең җан.

Әгәр җиңгән булса аклар,
Ярлыларны алар таптар
Иде; ярый әле рәт бар, –
Тыгыз иде безнең сафлар.

Тырышты күп ярлы халык,
Сугыш сафларына барып,
Тырыштылар көне-төне,
«Аксөяк» калды тапталып.

Җиңсә сафны алар безнең,
Кабырганы санар безнең,
Ләкин инде Самар – безнең,
Җиңеп бара кызыл һәр ан.

Сабак булсын бу халыкка,
Яшенә һәм дә картына,
Барыйк та һәммәбез бергә,
Төшик аларның артына.

Әйдә атлан атыңа, бергә
Кертик аларны кабергә,
«Аксөяк»ләр ятсын җиргә,
Әйләнсен кара күмергә.

Алар эш итә хәйләләп,
Сатып алып һәм алдалап,

---

Һәр ан – һәрвакыт.

Ул эшләр узды булгалап,
Бетереп булмыйдыр санап.

Сатылганнар французлар –
Акча коллары, комсызлар,
Кызыллар сизде серләрен,
Инде акларны тиз тозлар.

Кылычлар ялтырый безнең,
Пуляләр шалтырый безнең,
Дошманнар калтырый безнең,
Әсир төшә алар һәр ан.

Америка да һәр дәмдә
Икән акларга ярдәмдә,
Ләкин чыдап торсын алар
Безнең кызыллар баргәндә.

Әйдә, иптәш, бераз алга,
Көтә иптәш безне анда,
Чөнки Урал эшчеләре
Батып ята кызыл канга!

Әйдә киттек – күтәрелдек,
Аклар сафына бәрелдек.
Кызылларның тәмен белдек,
Берләшә эшчеләр һәр ан.

Бөтен дөньядагы эшче
Безнең файдабызга эшли,
Алар белән без бик көчле,
Алырбыз бер булып үчне.

Кызылларның рухы төшми,
Алар көне-төне эшли;
«Кызыл»ның җиңәсе мәгълүм, –
Алар төптән сизә эшне.

---

Һәр дәмдә – һәр минутта.

## ӨР-ЯҢА «КИСЕКБАШ» КИТАБЫ

Башлыйк әле сүзне демократ[1] белә,
Аннан ары китәрбез рәт-рәт белә.

Өстебездә серый шинель күрәлем,
Буржуй сугышы мәйданына ирәлем.

Йортларының биш-алты, ди, катлары,
Җил шикелле очалар, ди, атлары.

Градовойлар иде буржуй канатлары,
Пристефе, министере, «санат»лары.

Очкалыйлар иде алар күккә дә,
Төшкәлиләр иде шартлап төпкә дә.

Эчәләр иде алар эшче канын,
Чыгаралар иде сыгып аның җанын.

Хезмәт итә көн буе биш тиен өчен,
Түгә иде шуның өчен тирен, көчен.

Файда килсә, бар да алар байга иде –
Чумсын өчен алар бал-майга иде.

Байлар һаман комсызлыктан туймый иде,
Акча артыннан чабуын куймый иде.

Кайда күрсә дә, аны ала иде,
Тулмас төпсез кесәгә сала иде.

Дөнья малы барыбер кала иде,
Хатынын да бер яшь егет ала иде.

Беләсезме сез, бу ник алай иде?
Падишасы чөнки Николай иде.

Николайлар дөньядан китте хәзер,
Китәчәк буржуйга да кабер әзер.

Чөнки алар, бирмәс өчен хәрам малын,
Бирергә әзер тора газиз җанын.

Бетте инде хәзер байларга көн,
Очар бар байлыклары булып төтен.

Инде килер якты көннәр эшчегә,
Эшләде күп, инде бу көн рәхәт чигә.

Эшләгән кеше ахырдан бер җиңә,
Ат итеп дөньясына байны җигә.

Китте өстләрдән золым, караңгы төн,
Якты ирек кояшыннан яктырды көн.

Күренә алда эшчеләргә якты юл,
Ятма, иптәш, тизрәк алгы сафта бул!

Тиз тезел син дә кызыллар рәтенә,
Чап тизрәк, бар тиз, бүрек тә кимә.

Чап тизрәк, дошман каланы алмасын,
Дөньяда буржуй дигәннәр калмасын!

## «БАКЫРГАН» КИТАБЫ

Эшче, буржуй мактаныша,
Мактануда мәгънә бар.
Буржуй әйтә: «Мин баймын,
Амбар тулы маллар бар».

Эшче әйтә: «Мин баймын,
Бөтен көч, куәт миндә.
Әгәр дә мин эшләмәсәм,
Булмас иде мал синдә».

Буржуй әйтә: «Мин баймын,
Зур ташпулат миндә бар,
Син торасың алачыкта,
Буе – кыска, иңе – тар».

Эшче әйтә: «Мактанма,
Йортым зур дип шатланма, –
Зур йортлар, – бер көн килер, –
Булыр ләхеттән дә тар.

Алырбыз пулатыңны,
Җигәрбез туратыңны,
Инде хәзер йорт безнеке,
Буржуйга йорт сатылмый».

Буржуй әйтә: «Мин баймын,
Кесәм тулы алтын бар,
«Мин кем!» диеп мактанырлык
Яшь һәм матур хатын бар.

Минем хатыным симез,
Арка, җилкәсе тигез,
Шаккатып карап торырсың, –
Чучка белән нәкъ игез».

Эшче әйтә: «Мактанма,
Байлыкка хәйран калма,
Хәйран калырлык эшләр
Килер әле сезгә алда.

Җиңнәреңне сызганып,
Син дә бергә эшләрсең;
Эшләмәсәң, үкенүдән
Терсәгеңне тешләрсең.

Алдагы көн – якты көн,
Ак-каралар күренә,
Эшче халык менеп утыра
Һәрбер эшнең түренә.

Син үз-үзеңне белеш,
Буржуйга калмый бер эш,
Алыйм дисәң бер өлеш,
Эшләп табарга кереш.

Сорыкорт, буржуйларга
Калмады күп уйларга,
Буннан соң булмас инде
Эшче белән уйнарга».

Буржуй талаша килде,
Ахырдан ул җиңелде,
«Әүлия»га иптәшлеккә
Компанионы җигелде[1].

Алар икәүләп бергә
Тотындылар селкергә
Буржуйны якасыннан,
Ирек юк байга бер дә.

## ИСТИКЪБАЛЬ

Көннән-көн эшләр артка китеп өмидләр өзелгәндә,
Кайгылар, бәхетсезлек, мохтаҗлыклар күз алдына
тезелгәндә,
Шулардан йөрәкләрдә түзә алмаслык ачы җәрәхәт
сизелгәндә,
Күз алдына ак, якты көннәр килеп, шатлык,
рәхәт сизә бәндә.

Сизә күңел: баткаклыклар озак тормас,
кибәр бер көн,
Золым, җәбер, караңгылык – безнең өсттән
китәр бу төн,
Чыгар ирек кояшы җир йөзенә тиз көндә дә,
Шатлык, сәгадәт, бәхеткә ирешер дөнья бөтен.

---

Истикъбаль – якты киләчәк.

## «БӘДӘВАМ» КИТАБЫ

Беленңез Совет берлеген,
Күңелләрнең көрлеген,
Нык иттереп өрлеген,
Нигез кордык, бәдәвам.

Хәзер кадер малга юк,
Буржуага сан да юк,
Суга сусаган да юк,
Һәркем тигез, бәдәвам.

Буржуй Бәдигъ Җәмалы,
Эшченең Гөлҗәмалы, –
Барсының да чамалы
Өст-башлары, бәдәвам.

Түш киермәк байга юк,
Шикәр дә юк, май да юк;
Кара икмәккә һәркем тук
Бер чамада, бәдәвам.

Бездә түгел*, һәр җирдә
Эшче халыклар бергә
Тырыша көн күрергә
Рәхәтлектә, бәдәвам.

Рус, татары, болгары,
Немец, французлары –
Ярлы халыкның бары
Берләшүдә, бәдәвам.

Берләшә ярлы халык,
Бай бара астка калып,
Җыгылыр беркөн арып,
Бара торгач, бәдәвам.

---

* «Бездә генә түгел» мәгънәсендә.

Эш кемнәрнең кулында
Булса – барыр юлында
Булыр беренче урында.
Бара торгач, бәдәвам.

Менәр эшнең башына,
Ходка китәр машина,
Карамый тау-ташына,
Алга китәр, бәдәвам.

Бу көн «бай» дип мактанган,
Акча өстенә атланган.
Байыйм диеп шатланган
Хур булачак, бәдәвам.

Байлар керә гүренә,
Эшче утыра түренә, –
Һаман шулай күренә
Һәрбер эшләр, бәдәвам.

Бай акча өчен җылый,
Чөнки ул – акча колы:
«Калам бит инде коры
Кул белән», – ди, бәдәвам.

Көн-төн ул дога кыла,
Төрле планнар кора,
«Яхшы» булмакчы була.
Байлык торса, бәдәвам.

Ләкин аның догасы
Һич юк кабул буласы.
Гомер буе ул гасый
Булып килде, бәдәвам.

Җәберләнде күп кеше,
Талау иде бар эше,
Җылаганда ач кеше,
Көлеп торды, бәдәвам.

---

Гасый – гөнаһлы.

Эшче – алдында торса,
«Ачмын!» – диеп аһ орса,
Кылды аны мәсхәрә:
«Ялкау син!» – дип, бәдәвам.

Ярлыларга төкерде,
Белмәстәй булып йөрде,
Көне-төне йөгерде
Мал артыннан, бәдәвам.

Шампан шәрабын эчеп,
Аулакта кызлар кочып,
Яхшатлар белән очып,
Типтереп йөрде, бәдәвам.

Бирми бер тиен фәкыйрьгә,
Кермиләр трактирга,
Китәләр ерак җиргә
Шыпырт кына, бәдәвам.

Кеше алдында бик суфи,
Көн дә биш намаз укый;
«Бары тик тәмле йокы
Кыз катында», бәдәвам.

Хатыны булса да өч,
Җитә иде асрарга көч
Берничәне «болай гына»
Чит фатирда, бәдәвам.

Рәхәт гомер сөргәндә,
Җәннәтләрдә йөргәндә,
Мал файдасын күргәндә,
Эш таралды, бәдәвам.

Большевик килде чыгып,
Алды бар малны сыгып,
Үзен дә куйды тыгып
Чыкмас җиргә, бәдәвам.

Килеп җитте кыямәт,
Сизелде һәр хыянәт,
Инде ялган дианәт
Файда бирми, бәдәвам.

«Мин бай» диеп йөргәне,
Ярлылардан көлгәне
Үз башына булганы
Күрнә инде, бәдәвам.

Шәп сарайлар гүр булды,
Ишек каты түр булды,
Бай абзыйлар хур булды,
Ахры, бер көн, бәдәвам.

Байга үләргә генә,
Безгә көләргә генә,
Малын бүләргә генә
Калды инде, бәдәвам.

---

Дианәт – динлелек.

## МИН СӨЯМ

Мин сөямен халыкны, халыкны,
Хезмәт итәм ялыкмый, ялыкмый.

Мин сөямен ирекне, ирекне,
Хезмәт итәм ирекми, ирекми.

Иптәш, кызыкма данга һәм малга,
Атла аякны алга да алга.

Мин сөямен ярлыны, ярлыны,
Ярлыларның барыны, барыны.

Мин сөямен эшчене, эшчене,
Эш – тормышның иң чыны, иң чыны.

## ЯТЬ (Ѣ) ҺӘМ ИЯ (ІЯ)НЕ БЕТЕРҮ

(*Нәсер*)

Совет хөкүмәте бетерсә дә five ять (Ѣ)не,
Аның урынына бирде зур хөрриятне.
Әмма союзниклар бетерергә телиләр «ия» (ія)не,
Кол итәргә телиләр һәрбер ияне.
Бетерәләр алар Серб ия (Сербия)не,
Серби калса да, аның китә яме.
Калса да нимес халкы дөньяда,
Бетерергә тели алар Герман ия (Германия)не.
Булмаса да үзләренә һичбер зыяны,
Бетерергә тели алар Аз ия (Азия)не,
Шулай ук бетерәчәк алар Перс ия (Персия)не,
Калмас үзенә җиренең бер сөяме.
Калдырмый алар һәм дөньяда Бельг ия (Бельгия)не,
Ул җирләрдә калыр икән билгегә ни?
Бетерәчәк алар ахырдан Румын ия (Румыния)не,
Дөньяда бетерер нәрсә булыр микән бу манияне.
Бетерәчәк алар шулай һәм Төрк ия (Төркия)не,
Суеп ашапмы, яки тере көйгәме.
Бетсә бетсен, калмасын Британ ия (Британия)дә,
Ходаем, бетер аны да, яки бер ит аны да йә.
Ходаем догамны кабул кылсын гына,
Коткарып калдыра алмасын Вильсон[1] гына.

## БАЙ – КИБЕТЧЕ

Б а й

– Әй син, малай, Гайнетдин,
Чыгып йөрмә кибеттин.
Яхшы хезмәт итсәң генә,
Жалуньяңне киметмим.

К и б е т ч е

Хәзер андый ел түгел,
Мин дә сиңа кол түгел.
Син нинди рәхәт теләсәң,
Минем дә тели күңел.

Б а й

Ни сөйлисең син, малай,
Кем өйрәтте сине алай?
Күп сөйләнсәң, бар, чыгып кит,
Китер кенәгәңне, давай.

К и б е т ч е

Юк инде, алай куарга,
Бугазымнан буарга
Бирә алмам мин сиңа, абзый,
Һич сәбәп юк дуларга.

Б а й

Ник дуламыйм, мин бай бит,
Итсәң, яхшы хезмәт ит,
Риза булсаң – торасың,
Булмасаң – бар, чыгып кит!

Кибетче

Булмас, ансы өшкергән,
Инде безгә көч кергән,
Бик тиз генә бирешмәбез,
Без алырбыз көч белән.

Бай

Алай икән алайса,
Бераз арттырыйм яисә, –
Бик күңелле түгел икән,
Эшчеләр канат җәйсә.

## НИЛӘР БЕТТЕ, НИЛӘР КАЛДЫ?

(*Спекулянтлар мөсахәбәсе*)

– Исән-саумы, сәламәтме?
Ниләр бетте, ниләр рәтле?
Кичә генә кайткан идем,
Туздырганнар икән рәтне.

– Ниләр булсын, берни дә юк,
Мин үзем дә әле өйдә юк
Идем, кичә генә кайттым,
Шөкер әле, тамаклар тук.

– Бунда рәт юк, таралды ла,
Совет безгә кадалды ла,
«Вольный сәүдә»не иттерми,
Ябып куя караңгыга.

Базарны да тараттылар,
Берничәләрне аттылар.
Безнең сәүдәгәр халыкка
Корды каннары – каттылар.

Карап бактык союз ясап,
Булмасмы дип бераз ансат,
Хәйләбезне тиз сизделәр,
Булмады һич алай да ашап.

Читләрдә дә рәт калмаган,
Калмады җир мин бармаган,
Кайда барсам, анда тентү,
Булар күк булмас армаган.

---

Мөсахәбә – утырышу, сөйләшү.

– Бирмиләр һич файда итәргә,
Белә алмыйм һичкайда итәргә
Алган малларны да, әллә
Инде башны алып китәргә.

– Качсаң да булмый котылып,
Бөтен дөнья беткән тулып
Безнең ише качак белән,
Хур булырсың йә тотылып.

– Булмас, ахры, болай йөреп,
Булмас та төсле эш күреп,
Тамаклар яхшырак туяр,
Һич булмаса, чабата үреп.

– Мин дә шулай диеп торам,
Койрыгымны бераз борам,
Һич булмаса, тамак туяр –
Җалланып көрәсәм урам.

## СӨЙЛӘШҮ

– Нихәл, սездә эшләр шәпме?
– Һу, бик шәп.
– Карагруһлылар ни эшли?
– Ора гәп.
– Ә тормышлар ничек сездә?
– Шәп түгел.
– Ашау-эчү сайракмыни?
– Күп түгел.
– Уку эшләреңез ни эшли?
– Көйләнә.
[...]
– Халык сәясәткә ни ди?
– Өйрәнә.
– Байлар кайда, күренмиләр?
– Себердә.
– Алар нишлиләр соң анда?
– Себереләә.
– Театрлар ничек бара?
– Уйныйлар.
– Яңа әсәрләр чыкмыйммы?
– Уйлыйлар.
[...]
– Хатын-кызларыңыз ни эшли?
– Киенә.
– Башка нәрсә белмиләрме?
– Ие лә.
– Узган кышлар ничек килде?
– Бик суык.
– «Милләт эшләре» ни булды?[1]
– Гел куык.
– «Гыйльми һәйьәт» эше ничек?[2]
– Бик һәйбәт.
– Берни эшләмәгән диләр?
– Ансын әйт.

Һ ә й ь ә т – комиссия, коллегия.

## ЯҢА «БАШМАК» КӨЕ

Башмагымның башы башка,
Аерылды эләгеп ташка,
Киярлек түгел – чыгарып ташла.
Бирче яңа башмагымны.

Башмак башы тишек була,
Тишегеннән тузан тула,
Күн табылса, җамап була,
Төзәтеп бирче башмагымны.

Башмак башы каерылган,
Олтаны да аерылган,
Нишлим икән, Ходай орган!
Биреп торчы башмагыңны.

Үкчәсе дә булган агач,
Ике кидем микән алгач,
Тагы алсам, калам бит ач,
Нишләтим бу башмагымны?

Башмак башы чиккән була,
Тегелүе читтән була,
Шуңар күрә тиз җыртыла,
Бирче таза башмагыңны.

Бу эшкә хәйран калырлык,
Олтаны кәгазь калынлык,
Акча юк бит тагы алырлык.
Юкка кидем башмагымны.

Башмак башы күтәрелгән,
Ахрысы, нык бәрелгән,
Тишелеп чыккан төпләреннән,
Кызганам шул башмагымны.

Җыртыгыннан җилләр уйный,
Җыртылган бит буйдан-буйлый,
Дивана булам уйлый-уйлый,
Нишләргә бу башмагымны?

Башмак башы бик зур тишек,
Әйтерсең лә ачык ишек,
Кияргә инде буны ничек,
Мә, ал кире башмагыңны!

## МАЛЕНЬКИЕ НЕДОСТАТКИ МЕХАНИЗМА*

Булса суык,
Шиңә куык.
Булмый куып
Колак уып,
Билне буып,
Кулны уып
Утыру белән
Бетми суык.
Җылы юк өйдә,
Якмаган мичкә.
Булмый бит язып
Салкында һич тә.
Утын бирмиләр,
Әйтсәң, тиргиләр.
Безнең язмауны
«Саботаж» диләр.

* Механизмның вак-төяк җитешсезлекләре.

## ПӘРӘВЕЗ

Үрмәкүч корган иде пәрәвезен,
Күрсәтмәскә корган иде пәрдә үзен;
Яшренеп бер почмакка, качып ятып,
Ау килгәнне көтеп ята терәп күзен.

Үз гомрендә бик күп чебен ләктерде ул,
Хәзерләде ашарына ризыкны мул.
Комсыз нәфсе канәгатьне белмәгәннән,
Эзли иде күбрәк файда итәргә юл.

Аңсыздан бер көн каты җилләр исте,
Үрмәкүчнең пәрәвезен тетеп кисте,
Дөнья каплап, шаулап килеп
кызыл җилләр
Хәйран итте, китәрде бөтен исне.

Киң дөньялар тарайды үрмәкүчкә,
Качып кына котылды үзе көчкә;
Бар оясын, ауларын ташлап качты,
Чыдый алмый бөтен чебен алган үчкә.

Үрмәкүчләр сөйми ирек кояшларын,
Киптерә кояш аларның ашларын;
Үрмәкүчләр якты ireккә чыдый алмый,
Күрсәтмиләр алар яктыда башларын.

## ЯРЛЫНЫҢ ҖЫРУЫ

Язмыш безне тудырган,
Кочагыннан кудырган,
Суыкларда туңдырып,
Колак-кулны удырган.

Төрендек чүпрәккә,
Суык үтте йөрәккә,
Адәм күрмеше калмады,
Әйләндек без өрәккә.

Туган булсак ялангач,
Булды тамаклар да ач,
Иртә-кич бай тирәләрен
Тәваф итеп, кылдык хаҗ.

Ишетмәдек татлы сүз,
Бәхетсезлек булды үз,
Мал-нигъмәткә
кул җитмәде,
Кызып караса да күз.

---

Т ә в а ф – бер нәрсәнең тирә-ягын әйләнү.

## КАР КӨРӘГӘНДӘ

Дусткаем Гайниҗамал,
Безнең хәлләр бик яман,
Шулай урамнар көрәтеп
Эшләтерләрме һаман!

Бик начар минем хәлем,
Буяла мамык шәлем,
Битләрем дә бик туңа бит,
Онтылып калган вәлем.

Бик авыр ич бу көрәк,
Бер дә булмый ич көрәп,
Күтәреп алып салганга
Авырта ич күкерәк.

Кара әле теге марҗаны,
Хәбәрендә дә юк, җаный:
Бер дә калмый көрәп бара,
Авыртмый микән саны?

Карасана, аппагым,
Берсе кигән калфагын,
Кыйланып йөргән була бит
Әнә берсесе тагын.

Яхшы сагын да кигән,
Төп шикелле, нәкъ имән,
Кунакка да чыкмый иде,
Ат җигелмәсә өйдән.

---

Вәл (*вуаль*) – биткә төшеп торган үтә күренмәле материал.
Сак – хатын-кызларның киң, озын пальтосы.

Кара, теге хатынның
Пирчәткәсе тишелгән;
Кара, теге җуан бака
Чүмәлә күк ишелгән.

Абау Алла, Ходаем,
Тагы да ниләр кыйлаем,
Ничек итеп күрәргә соң,
Белеп булмый уңаен.

Кар күрәгәнем юк иде,
Ардыра икән беләкне;
Кары да бик начар икән,
Күрәп булмый эрәтле.

## ТАТАРГА

Юкка уздырма көнеңне юк кына гайбәт белән.
Кулда бар көч, эшлә дә тап, эшлә зур гайрәт белән.

Ташла кеше җилкәсе өстеннән ашауларыңы.
Бергәләп бар, калма артка, син дә алгы рәт белән.

Ташла ансат юл белән күп мал җыю уйларыңы.
Аша эшләп, юкка йөрмә, селкетеп буйларыңы.

Ал кулыңа эш коралын да, тырыш хезмәтеңә,
Ик иген, күрсәт һөнәр яки көт куйларыңы.

Уйлама, күп акча җыеп, салырым дип ташпулат,
Яки, бикә берлә утырып, җигеп йөрергә туры ат.

Тук булып, иркен тору һәм шулай авылдадыр:
Шунда тырыш, шунда эшләсәң, салырсың син зурат.

Тынма, эшлә, тынма, тырыш, булма, туган, аксөяк,
Эшләмиче тик ятучы селкетә алмас аяк.

---

З у р а т – озынча кибән.

## КЫЗЫЛ АРМИЯЛЕ ҺӘМ СПЕКУЛЯНТ

К ы з ы л   а р м и я л е

Безнең бары шунда эш тик:
Таза, нык булсын штык.
Сез үзеңез нинди囊штә?
Анысын сездән ишетик.

С п е к у л я н т

Безнеңме?
Безнең эшебез ике:
Берсесе – ашау ипи,
Аннан соң – ятып йоклау,
Менә булды бит ике.

К ы з ы л   а р м и я л е

Без йөрибез сугышта,
Ачы җил, суык кышта.
Шундый суык, чыдамаслык,
Өйдә дә түгел, тышта.
Ә сез нишләп ятасыз?
Ни сафсата сатасыз?
Йә, әйтеп, сөйләп бир әле,
Туры гына, хатасыз.

С п е к у л я н т

Безме?
Без сатулар итәбез,
Бар малны киметәбез.
Бу җирләрдә файда бетсә,
Читкә эзләп китәбез.

Эшләр бара зарарсыз,
Бер әле санап карарсыз.
Эш тагы да шәбәячәк,
Сатсак иҗбари карарсыз.

К ы з ы л  а р м и я л е

Әгәр Советлар җиңсә,
Тынычлык еллар килсә,
Мылтык җилкәдән төшеп,
Ял итәр иде иңсә.

С п е к у л я н т

Зарар юк,
Сугыш дәвам итсә дә,
Бер-ике губерна китсә дә,
Сату-алу яхшы булса,
Акча тулса кесәгә.

К ы з ы л  а р м и я л е

Европа корса тозак,
Сугышлар булса озак,
Файданы күп итә алмассың,
Салыныр кесәңә йозак.

---

И җ б а р и – мәҗбүри.

## БУРЖУЙ ЗАРЫ

Ябынып толып якасын
Мин дә беләм ятасын,
Ләкин тыныч йоклап булмый,
Җан тирләргә батасың.
  Йоклап булмый ничек тә,
  Бала җылый бишектә.
  Җитмәсә, берсе килгән, ди,
  Бурыч сорап ишеккә.
Җылама, бала, җылама,
Тирбәт шуны, апасы,
Авызына каптырсана:
Юкмы шунда манпаси?
  Аны да миңа бирмиләр,
  Сорап барсаң, тиргиләр:
  «Син буржуйга әнә сабын,
  Шуны ашый бир», – диләр.
Миңа – сабын, тоз гына,
Эчем тулы боз гына;
Дөньяда кызык калмады, –
Инде аякны суз гына.
  Икмәк тә чирек кадак, –
  Утыр өстенә карап...
  Бундый тормыш начар икән,
  Эшләрем булды харап.
Ник тормадым тик кенә.
Канәгать итеп кенә?
Акча җыясым килде шул,
Файда күп итеп кенә.
  Үз башыма афәт итеп
  Мал җыясым калмаган.
  Дөньяда бик аз булыр шул
  Байлыкка алданмаган.

## ЯҢА ТИПТА ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Байлар кия каракүл,
Ярлы киде эшләпә;
Бай аһ ора, ярлылар шат, –
Менә Совет нишләтә.

Байбикәләр бик күп йөрде,
Киеп каракүл саклар,
Икмәк үлчәүлегә калгач,
Шиңде бик күп корсаклар.

Заманында рәхәт чикте
Алпавытлар, түрәләр;
Инде дөнья рәхәтләрен
Эшче халык күрәләр.

Заманында зур корсаклы,
Тугыз потлы кешеләр
Өч чирек кара икмәкне
Тәүлек буе көйшиләр.

Кәеф корып яшәүчеләр,
Көн буе кырын ятып,
Көн итәләр талчукларда
Артык-портыкны сатып.

Алмый узып китүчеләр
Ярлы кеше сәламен,
Үзе башлап сәлам бирә, –
Шуңар хәйран каламын.

Алтын-көмеш байларда,
Байбикә абыстайларда,
Алтын-көмеш җыйган байлар
Йөри икән кайларда?

---

Сак – хатын-кызларның киң һәм озын пальтосы.
Көйшиләр – күшиләр.

## ИРЕК НУРЫ

Тәрәзә ачтык, гөлләр чәчтек
Кояш баеш ягына.
Тигезлек фикре урнашты
Эшче халык аңына.

Кичә тишелде берничә,
Бүген үсте тагы да.
Озак вакытлар калмады
Чын ирекнең таңына.

Бүген берәү, иртә – тагын –
Артып тора гел ише;
Берничә айдан өлгерер
Чын ирекнең җимеше.

Ярлы халык эш күрәләр
Аңлап, белеп, аң белән;
Халыкны алдый алмаслар,
Чебен күгүк, бал белән.

Тәрәзә ачтык, нурлар чәчтек,
Ирек нуры яктырта,
Якты дөньяда үрмәкүч
Алмас чебенне тота.

---

Күгүк – кебек.

## СЕЗ ҺӘМ БЕЗ

*(Нәсер)*

Беләм, мин беләм, мин түгел иш;
Сез – байгура, буржуй, мин түгел ич.
Сез – байлыкта, рәхәттә;
Мин – хезмәттә иртә-кич.

Сез итәсез йөз мең файда,
Миңа андый акчалар кайда?
Сезнең бер күлмәк табышны
Без таба алмыйбыз айда.

Мин беләм: мин сезгә пар түгел,
Дөньяңыз киң, ләкин тар күңел.
Безнең эш: тик авыр йөкне
Ял итми көн-төн тарту гел.

Мин бик яхшы беләм сезне;
Сезнең күңелләр тик эзли
Күп-күп файда, ләкин дөнья
Һәркайсыбызны тигезли.

Сезнең теләк: хуҗа булу,
Ярлылар тотып ябылу,
Бөтен дөньядагы эшләр
Байлар теләгәнчә булу.

## БУРЖУЙ ПЛАНЫ

Яшереп акча биш кадак,
Тора як-якка карап;
Кем ягыннан булышсам,
Булыр икән күп талап?

Кемгә ярдәм итим икән –
Советкамы, акларга?
Кем ягыннан тырышканда
Мөмкин байлык сакларга?

Буржуй миңа ишрәк,
Акчасы да ишлерәк,
Советтан миңа файда юк,
Ә тегендә – эш рәт.

Анда – иркен торырга,
Төрле план корырга;
Алар үзләре дә оста
Койрыкларын борырга.

Ирек сату итәргә,
Максудка да җитәргә,
Тыгызлыклар килә калса,
Мөмкин читкә китәргә.

Күбрәк булса акчасы,
Табылыр җәннәт бакчасы;
Мин сау калсам, башкаларның
Барсын, сынсын матчасы.

---

М а к с у д – максат.

Акча – миңа Алла ул,
Өелеп торса алда ул;
Табып бирә мал да ул,
Икмәк тә ул, бал да ул.

Китәм аклар ягына,
Акчаны алып яныма;
Акчага коллык кылулар
Сеңгән инде каныма.

## ЧАГЫШТЫРУ

Борын-борын заманда, патшалар аллалык дәгъва кылганда, министрлар – Газраил[1], палитсәләр зобани[2] булганда, җир йөзе золым белән тулганда, бар иде, ди, бер шагыйрь, ул яза иде, ди, шигырьләрен менә болай дип:

Падишаһлар һәм санатлар –
Барсы да алар канатлар;
Алар сүзен тоткан затлар
Җәннәткә адым атлар.

Үзгәреш булды, җәһәннәм залимнәр белән тулды. Халык боларның золымыннан котылды. Шул вакыт ирекле бер шагыйрь үзенең шигырен менә болай дип язарга тотынды:

Патшаларын, санатларын,
Сындырып ташла канатларын;
Җәһәннәм төбенә китсен,
Авызыңа алма атларын.

### Иске шагыйрь

Безнең байның кызы матур,
Аермасы юк айдан;
Шул кыз миңа булса иде дип,
Көн-төн сорыйм Ходайдан.

### Яңа шагыйрь

Кара минем гүзәлемне,
Тазарган ул эш белән;
Үзе теләп бармаганда,
Каушып булмый көч белән.

И с к е ш а г ы й р ь

Нинди матур бакчасы,
Кесә тулы акчасы;
Һәр җәһәттән матур булган
Бу кыз миңа баксачы.

Я ң а ш а г ы й р ь

Кирәкми миңа малы,
Атының озын җалы,
Бирмәсә кызын – ялынмыйм,
Белмим тәрилкә җалый.

## КОРСАК

Бай сагына корсагын.
Теләгәнеңчә сагын!
Ул корсакны тутырырга
Насыйп булмас бит тагын.

Ул корсак бик тук иде,
Буш җире һич юк иде;
Ләкин хәзер бушаталар –
Корсак көннән-көн кими.

Урын бик күп корсакта,
Ни генә тутырсак та –
Ашарга мул булсын иде,
Тик кенә утырсак та.

Кайгырмыйбыз эш юкка –
Ашарга булса ботка;
«Вольный сәүдә» ясасалар,
Эш китәр иде ходка.

Ашар идем киерелеп,
Ит тә булса аз гына,
Җылкы ите күбрәк булса,
Булсын димим каз гына.

Бирсәләр иде эчәргә,
Һич булмаса, пирәшне;
Чыраемны сытмас идем
Ашаган көн миләшне.

---

Пирәш – сыра, эчемлек.

Һич булмаса, китермиләр
Базарларга балык та.
Акчага нәрсә сатмыйлар, –
Оят бетте халыкта.

Нишләтим бу корсакны,
Алҗыдым саклый-саклый.
Туйдырганчы ашатырлык
Юкмы һичбер инсафлы?!

Корсак тәмам бушады,
Төште инде салынып.
Мә, ал акча, бир ашарга,
Сездән сорыйм җалынып.

Корсак булса, тук булсын,
Тук булмаса, юк булсын!
Карным туярлык булмагач,
Бөтен дөнья ут булсын!

Бай корсагы зарлана,
Киң булса да, тарлана,
Шундый аһлар, шундый зарлар
Көн саен тәкрарлана.

---

Тәкрарлау – кабатлау.

## БЕР, ИКЕ, ӨЧ

Союзниклар аһ ора,
Чәчләре үрә тора
Кычкырганга безнең гаскәр
Һәрбер мәйданда «ура!».

Союзниклар, байгура
Мал беткәнгә кайгыра,
Николайга киткән акча
Өчен «эчләре бора»:

«Без аңарга акча бирдек,
Безнең өчен сугыш, дип,
Синең халкың күбрәк үлсә,
Без алырбыз сулыш, дип.

Бездән акчаны алгач,
Аны кесәгә салгач,
Халыкларны ирек алып,
Калдырдылар безне ач.

Китеп барды бит Себер,
Анда алдандык – бусы бер;
Салкынлыкка чыдый алмый,
Үкчәң күтәреп йөгер.

Дөнья була безнеке
Дип торганда, китте көй,
Үз халкыбыз баш күтәрә,
Бер кайгылар булды ике.

Аласы килсә дә үч,
Җитә алмый бит безнең көч,
Һәр якта Советлар җиңәләр,
Буның белән булды өч».

## ИГЕНЧЕНЕҢ ЗАРЫ

Түбәсен япкан өйнең салам белән,
Шунда торам алты-җиде балам белән,
Барыбыз – ун кеше хатын белән,
Сиксән яшьлек сукыр карчык –
анам белән.

Күршедәге байгура берничә атлы,
Йорты да аның бик биек – ике катлы;
Ачлыктан икмәк сорап барган идем,
Түли алмаслыкны белеп, миңа сатмый.

Өч ел булды сатканыма актык атны,
Атсыз яшәү крәстиәнгә ансатмы?..
Нигә миңа Ходай бик күп бала биргән,
Һич булмаса, берәресе суга батмый.

Һич булмаса, уңмый бит ашлык кына,
Ничек уңсын, җирем гел ташлык кына;
Өлешемә шундый начар туры килде:
Актык сука тимере шартлап сына.

## ГАЛӘБӘ

Мактанырга да лаек:
Алынды инде Җаек;
Аклар исереп йөргәндә,
Кызыллар булды аек.

Караларның золымыннан
Коткардылар Уралны;
Ак-каралар гаскәрләре
Төрле яктан уралды.

Казак ташлый коралны –
Аклар каршы торалмый;
Совет гаскәрләре бара
Пыр туздырып буранны.

Коткарылды Оренбур,
Искечеләр булды хур,
Инде капкынга эләкте
Күп җир талап йөргән вор.

Нинди олугъ Төркстан
Айрылган иде дусттан,
Яңадан килеп кушылды,
Дөнья булды гөлбөстан.

---

Галәбә – җиңү.
Гөлбөстан – гөлбакча.

## АКТЫК ЙОМРЫК

Актык йомрык Волгада,
Төшер – кулыңны болга да,
Калмасын дөньяда Колчак –
Элеп киптер колгага.

Коткарырга Иделне!
Ныгыт, туган, билеңне!
Шул мәйданда җиңү белән
Коткарырсың илеңне.

Идел суы – яман су,
Ага бик шәп һәм ярсу;
Себереп түк дошманны, –
Җәй булмасын ямансу.

Идел суы бик тирән,
Яз җыела кар суы;
Дошман шунда себерелсә,
Басылыр йөрәк ярсуы.

Аклар белән каралар
Иделгә дип баралар;
Шунда аларны себреп түксәк,
Төзәләчәк яралар.

Борын заман фиргавене[1]
Үлгән күк Нилгә батып,
Яңа фиргавен – Колчакны
Ташлыйк без суга атып.

Борын заман һәлак булган
Хамнар[2], батып туфанга[3].
Колчакны Иделгә батыр,
Ирек таңы туганда.

---

Йомрык – йодрык.

## БАЙЛАР БИШЕГЕ

Баем, баем, бай кеше,
Җимрелеп бара һәр эше.
Ул да кара икмәк көйши,
Кимеп бара һәм ише.

Баем, баем, бай гына,
Инде кесә сай гына;
Ашый алмый май гына,
Җиккәне дә тай гына.

Баем, баем, бай агай,
Ник кайгырасың алай?
Яшь чагында син дә булган
Тюк бәйләүче бер малай.

Баем, баем, бай кисәк,
Синдә юкмыни исәп?
Бик тиз генә арада
Баеп киттең бит кисәк.

Баем, байның баласы,
Бик бай иде атасы;
Ярты Казан каласы
Бары да аңар каласы.

Баем, баем, Байбулат,
Әллә ничә ташпулат;
Җиккәне дә гел туры ат,
Чабып бара бик дулап.

Баем, баем, байгура,
Бай «бөләм» дип кайгыра;
Бай беткәнне ишеткәч,
Ярлы кычкыра: «ура»!

---

Көйшәү – күшәү.

Баем, баем, байбикә,
Бар дәүләтең дә китә;
Җиң сызганып эшләргә
Сиңа да вакыт җитә.

Баем, баем, бай угълы,
Кесәдә акча тулы;
Тик типтереп йөрергә
Калмый инде һич юлы.

Баем, баем, бай туташ,
Түп-түгәрәк, бертоташ;
Түшләреңне бизәргә
Калмады бит асылташ.

## ФЛОТ КИЛӘ

(*Буржуй авызыннан*)

Әнә килә, күрәмсең, флот килә,
Флот түгел, аклар өстенә ут килә;
Аклар, колчаклар өстенә кыздырылган
Ут яудырып тора торган болыт килә...

Беләсеңме, Коръәндә бар «Фил» сүрәсе,
Билгеле ул, һәркем белә, юк сөйләсе;
Бабил кошлары[1] күк аэроплан
Акларның өстләренә ут сибәсе.

Акларга һөҗүм булды күктән, җирдән,
Бу көннән соң һөжүм булыр тагы судан;
Эшләр болай чынга таба китеп баргач,
Аклар эше начарлана бугай, туган.

Шулай сугыш пароходы килеп тулса,
Акларны кысып алса тимер күлса,
«Безнең аклар» бик озакка чыдый алмас,
Бер-ике чыдарлар бик күп булса.

Яшергән идем күп мал кыш буенча,
Тулы амбар, келәт асты һәм дә мунча,
Ахры, чыгарып сатулар яхшы булыр,
Күп файда өмид итеп асраганчы.

Акчасы булса – әле мал табылыр,
Тик утыны булсын гына, балта булыр;

---

К ү л с а (*кольцо*) – боҗра.

Күпне өмид итеп, аздан коры калсаң,
Ул эш бик зур төзәлмәслек хата булыр.

Шулай ук аклар инде җиңмәсмени?
Байларны коткарырга килмәсмени?
Байларның йөрәгендә Колчак гыйшкы
Ялкынланып янганын күрмәсмени?

Өмид юк шул, эш көннән-көн бит чуала,
Бөтен дөнья «кызыл ут» белә чолгана.
Бунда сүнсә, Европада нык кабынып,
Капиталның күңелләрен борчу ала.

## НӘҮРҮЗ[1] МӨБАРӘК БАД!

Нәүрүз әйтә: без килдек
Ишегеңнең төбенә,
Бу дөньяда һич алданма
Малларыңның күбенә.

Без әйтәбез кат-кат:
Нәүрүз мөбарәк бад!
Безнең әйткән бу сүзләр
Тойла буржуйга бик ят.

Бүген эшче нәүрүзе,
Буржуйның яна күзе,
Үтә алмый һич сүзе...
Нәүрүз мөбарәк бад!

Бүген буржуй аһ ора,
Чәчләре үрә тора;
Эшче кычкыра ура,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Буржуй айрылган дусттан,
Бюрократ качып поскан –
Кирәк татар һәм рустан,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Буржуй, түрә, алпавыт
Йөрәгендә яна ут,
Аларга «страшный суд»,
Нәүрүз мөбарәк бад!

---

[1] Нәүрүз мөбарәк бад! – Яңа ел котлы булсын!

Бүген һәрбер демократ
Шатланалар меңәр кат –
Кирәк бала, кирәк карт,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Бүген рәхәт эшчегә,
Туймаса да «Эшче»гә[2],
Ирек рәхәтен чигә,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Карты, яше, баласы,
Булса да ул нарасый,
Тигезләнгән арасы,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Арада юк аерма –
Тигез эшче-байгура,
Тик соңгысы кайгыра,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Һәркемгә дә юл ачык,
Беркем дә йөрми качып,
Тик «кара»га юк почет,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Ярлылар да шатлана,
Ирекле, дип, мактана,
Шатлыгы мең катлана,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Мөбарәк булсын Яңа ел –
Тигезлеккә яңа юл.
Гомерлек иректә бул,
Нәүрүз мөбарәк бад!

## КЫЗЫЛ АРМИЯЛЕЛӘРНЕҢ БЕРЕНЧЕ МАЙ ҖЫРЛАРЫ

Якты кояш, күк йөзендә ялтырап,
Ничек җир йөзләрен яктырта,
Шулай ук бөек Май бәйрәмендә
Эшче халык уяна һәм ныгый.

Бу көнне узган ел шатлык белән
Бәйрәм иттек, йөзләр яктырды.
Хәзер безнең башка бәла килде,
Күтәрелде туфан[1] караңгы.

Күтәрелә тулкыннар биек булып,
Өсткә килә ярсып, котырып,
Пермьнән, Уфадан һәм мәшрикътән
Китерә Колчак гаскәр куып.

Патшаның ул һич рәхимсез
Канечкеч гаскәре белән
Без эшчеләр илләренә килә
Бетерергә бар хезмәт халкын.

Әмма кызыл сугышчылар безнең
Төшерер аңар тиешле йозрык;
Зур дошманга, кирәк вакытларда,
Каршы барырбыз без йөгереп.

Барыңыз, иптәшләр, нык батыраеп,
Кемдә батыр йөрәкләр булса,
Хаклык өчен һәм ныклап көрәшеп,
Сал Колчак муйнына нык күлса.

Яшәсен Беренче май көннәре!
Эшче-крәстиян берексен!
Сөялле кул белән күк күлмәкле
Яшь ирек көннәрен шат күрсен!

---

Мәшрикъ – көнчыгыш.
Күлса (*кольцо*) – боҗра, алка.

## НӘҮРҮЗ (ЯКИ НАУРУЗ)

Нәүрүз әйтә: мин килдем
Театрның түренә;
Нәүрүз бәете билгеле
Иптәшләрнең күбенә.

Без әйтәбез кат-кат:
Нәүрүз мөбарәк бад!
Байлар йөзтүбән киткәнгә
Эшче халыклар бик шат.

Бу ел эшче нәүрүзе,
Буржуйның яна күзе,
Ишетелми һич сүзе,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Буржуй хатыны бикә
Ничек итеп көн итә?
Актык көннәре җитә,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Буржуй җикте ничә ат,
Пулатлары ничә кат,
Инде хәзер бар нәрсәне
Талчукка чыгарып сат.

Байның угълы байбәтчә,
Ашау-эчү гадәтчә,
Бүген бөтенләй боеккан,
Бик шәп иде бит кичә.

Алар тели иртә-кич,
Тырышмыйчы гына һич,

Рәхәт кенә көн итәргә,
Юк әле, наузуфә бат!

Без яшәрбез эш белән,
Эшчедәге көч белән,
Эшләрбез чүкеч белән,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Тагын әйтәм мин сезгә:
Җәйгә булмаса, көзгә
Рәхәт булачак безгә,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Без иттек бик күп сабыр,
Тормышлар булды кабер,
Вакыт рәхәт булса бер,
Нәүрүз мөбарәк бад!

Акыр, буржуй, җыла хет,
Дөньялар сиңа ләхет
Булырга күптән вахыт (вакыт),
Нәүрүз мөбарәк бад!

---

Наузуфә (*навозга*) – тирескә.

## МИЛЛӘТЧЕЛӘР, ДИНЧЕЛӘР

«Безнең максуд – дин генә», –
Диючеләр «динги»гә
Кызыгалар, чабышалар
Бик җиңел – нәкъ җил генә.

«Мин тырышам, милләтем
Өчен генә һиммәтем», –
Диючеләр чабышалар
Акча артыннан көн вә төн.

«Минем максудым – халык,
Байлыгы булса, алып
Китәм кесәгә салып,
Шәрекъ ягына чабып».

Бу – безнең милләтчеләр
Эше. Бу гайбәтчеләр
Кесәләрне әрчиләр,
Ләкин үзләре «чибәр».

Егет алар: фасон шәп,
Төрле фәннән ора гәп.
Арчыйлар ачыгавыз
Байларны, матур сөйләп.

Әгәр дә ул чалмалы
Булса, бигүк алдамый.
Ләкин фраклылар алдар
Туры килсә Алланы.

---

Динги (*деньги*) – акча.

## ШАЙТАННАР БИЮЕ

(*Яссыдагы контрреволюционерлар киңәше мөнәсәбәте илә*)[1]

Англо-Франко һәм нифакъ
Биешәләр краковяк,
Румания дә, сыбызгы уйнап,
Була аларга аяк.

Җыен иске, җыен чүп
Сикрешәләр «һуп та һуп»!
Сикрә алмассыз инде күп,
Җыгылырсыз итеп «гуп»!

Николай да күп биеде,
Сикрә алмады бик алай,
Күп сикереп сындырмаңыз
Аягыңызны, малай.

Мисыр, Һиндстан да Фас,
Әйдә, син шул көйгә бас!
Җабир патша һәм ерткычлар
Калып бара инде аз.

Үтер, бетер искене,
Ваклагачтын тиз кими;
Ват та сындыр һәм яндыр:
Искене һичкем кими.

Тапта, сикер кушаяк,
Каптыр ачы мишаяк,

---

Нифакъ – икейөзлелек.
Румания – Румыния.
Җабир – җәберләүче.

Тазарып калсын һәммә як,
Аннан тик рәхәттә ят.

Англо-Франко һәм нифакъ
Ясаганнар иттифакъ.
Ни эшли икән безнең як?
Курыкма, алар да бик сак!

Мылтыкларны нык корсак,
Штыкны аларга борсак,
Безгә каршы тора алмас
Дөньяда җуан корсак.

---

Иттифакъ – союз.

## БУЛСА ДА БУЛЫР ШУЛ

Ишеттеңме син әле,
Яңа хәбәр сөйлиләр:
Франция гаскәре дә
Баш күтәргәннәр, диләр.
Булса да булыр шул,
Һәм шулай булыр ул.

Ишеттеңме син әле:
Безнең совет гаскәре
Эшчеләргә булышырга
Германиягә бара, ди.
Булса да булыр шул,
Һәм шулай булыр ул.

Чех-словак гаскәре дә
Сугышырга бармаган,
Хаклык безнең якта икәнне
Алар да һәм аңлаган.
Булса да булыр шул,
Һәм шулай булыр ул.

Америка гаскәре дә,
Сугышмыйбыз, диләр, ди.
Алар да җырлый башлаган
Инкыйлаби көйләрне.
Булса да булыр шул,
Һәм шулай булыр ул.

Бөтен дөнья эшчеләре
Байга каршы борылган,
Капиталга каршы бөтен
Мылтыклар да корылган.
Булса да булыр шул,
Һәм шулай булыр ул.

---

Инкыйлаби – революцион.

## КАРАЛАРГА

Әй син, дошман – явыз кара малай,
Идән асты ярыктан карама алай;
Без сине шаяртабыз җурамалай,
Көчсезлектән диеп син җурама алай.

Әгәр сез идән асты ярыктан карасаңыз,
Чәйнәтербез кургашын – кара сагыз,
Кычытса аркаңыз – без басарбыз,
Муйныңыз кычытса – без асарбыз.

Хәшәрәткә бирмәбез үрмәләргә,
Яшеренергә бирмәбез бөрмәләргә;
Ният кылсаң котыртып йөргәләргә,
Чертербез ябып куеп төрмәләргә.

Маташмаңыз үлән астыннан ут йөртеп,
Халык ирке нигезенә утлар төртеп,
Дошманыңыз капкасына дегет сөртеп...
Бетерербез хәшәрәтне «дару» бөркеп.

Маташмаңыз якты көнне караларга,
Дошманлык салырга дип араларга.
Маташмаңыз юкка көчләр әрәм итеп,
Булмас инде якты көннәр караларга!

## ВӘГАЗЬ-НӘСИХӘТЛӘР

Әй син, «дусткай» инглиз!
Гаклыңа кил инде тиз,
Әнә теге зур Һиндстан
«Айрылам» ди, син «дуст»тан.

Әй, «дустым» француз,
Бик исән-сау торамсыз?
Син дә бик күп җиргә кердең
Иясеннән сораусыз.

Әй син, леди Америка,
Тотма байга тәрилкә;
Эшче тукмаклары төшсә,
Авыртыр калын җилкә.

Әй сез, карсак япуннар,
Сезнең сүзне кем тыңлар!
Сезнең йозрыктан куркырга
Без түгел бит хатыннар.

Әй, мөселман Төркия,
Тик торсаң син бер көйгә:
Кичә – дошман, бу көн – дуст –
Инглиз булыр көя.

Кичә Мисырга төште,
Шамга төшәр иртәгә;
Байлыгыңны савып ята,
Бәйләп куеп киртәгә.

---

Ш а м – Сирия.

Әй син, жегет итальян,
Йоклап ятма, иртә уян,
Юк исә син дә булырсың
Аучылар өчен куян.

Әй дустым, син, Иран,
Гакылга бераз өйрән,
Инглизләр баз казыйлар
Синең алдыңда тирән.

Әй син, озын чәч Кытай,
Бер читкәрәк тизрәк тай,
Сине дә Европа йотачак,
Узса узар берничә ай.

Сиңа әйтмим инде, Фас,
Чөнки миең бик тупас,
Әйткәнең генә калыр, дим,
Барыбер мәгънә чыкмас.

---

Фас – Марокко.

## БЕР ЕЛ ЭЛЕК

Бер ел элек чистарттылар Болак артын,
Кашыдылар «милләтчеләр» колак артын;
Буржуйларның аһларына колак салып,
Ярдәм бирүче булмады һичбер яртын.

Әфитсәрләр, ашап йөреп байлар ашын,
Күз чыгарды – төзәтәбез диеп кашын,
«Сезгә без җөмһүрият бирәбез», – дип
Әйләндерде «милләт байлары»ның башын.

Урам чатларына өеп бүрәнәләр,
Сугышырга мылтык уйны өйрәнәләр;
«Җөмһүрият»не йотарга бирмәбез дип,
Түр башында, аш янында сөйләнәләр.

Уйлаганнар иде бугай хан куярга,
Яшел төскә һәрбер флагны буярга;
Сизеп алгач Совет аларның уйларын,
Бирмәде ирек бай малайларына уйнарга.

---

Яртын – җирдән, тарафтан.

## КЕМ КӨЧЛЕ?

Син көчлеме, мин көчлеме?
Әллә «Иттифакъмы өчле»?[1]
Күреп-сынап карарсыз,
Без алган чакта үчне.

Кем көчле, ди, Колчакмы?
Шул кабахәт алчакмы?
Озак вакыт көтәсе юк
Аны җиңәчәк чакны.

Кемдә көч күп, байдамы?
Апуш корсак, майдамы?
Ул тик бары кайгырта
Күп итүне файданы.

Кем көчле соң, морзамы?
Җиңәм дип борнын сузамы?
Безне җиңү уе белән
Бөтен гомре узамы?

Юк аларның көчләре,
Тик күбенгән эчләре,
Тик акчага алдау гына
Бөтен белгән эшләре.

Алар барсы да куык,
Шиңәләр, булса суык;
Тиз көннәрдән җибәрербез
Һәммәсен дә без куып.

Көч бары тик эшчедә,
Эшче – дөньяны җиңә;
Бергәләшеп тырышканда,
Капиталны да җигә.

---

Алчак – түбән, куркак, пычрак.

## ЕВРОПА ҖАНВАРЛАРЫ

Арыслан, юлбарыс, бүре
Тотканнар, ди, бик зур ау.
Бу ауны бүлү турында
Арада чыккан зур дау.

Арыслан әйтә: «Миңа – күп,
Чөнки мин бит зур патша», –
Ди. Ләкин юлбарыс та әйтә:
«Җитәр, чамалап аша».

Бүрегә һич сан да юк,
Куркуыннан җан да юк;
Аңар кайда ауны алу –
Кечкенә «арт сан» да юк.

Низагъ бары бүлүдә,
Өлеш бирми бүрегә;
Арада ул йөгреп йөри,
Һич юк аны күрү дә.

Арыслан да, юлбарыс та
Карыйлар тик баюны,
Үзара бүлешмәкчеләр
Ниндәен зур «аю»ны.

Арысланы – Америка,
Бүресе – Япония,
Юлбарысы – Англия,
Булмакчылар, ди, ия.

Ләкин «аю» үлмәгән,
Бары тик ул күрмәгән.

---

Низагъ – талаш, дау.

Яки күрсә дә килгәнне,
Үзе өчен дип белмәгән.

Эшләр зурая бара,
Бетми бик тиз ятышып.
Менә талашлар башлана,
Кара канга батышып.

Кара-каршы сугышканда,
Барсы да хәлдән тая;
Инде аларда җан кайгысы,
«Аю» кайгысы кая!

Кара-каршы көрәшкәндә
Җыгылалар абынып;
Үзләренең өннәренә
Утлар китә кабынып.

## «ИШАН ГАЛИ» СӘЯХӘТЕ

Йөреп кайттым әле мин дөнья гизеп,
Кайда хак, кайда нифакъ күреп, сизеп,
Кайда халык богавыннан ычкынган да,
Кайда аларны капитал тора изеп.

Сәяхәттә күрдем мин бик күп җирләр,
Күп нәрсәләр, күп гыйбрәтләр,
бик күп ирләр;
Кайда барсаң, анда эшчеләр кол икән,
Эшли мискин, маңлаеннан ага тирләр.

Эшче халык кайда булса да – кысылган,
Кирәк мәҗүс, китаби[1] һәм мөселман;
Кайда барсаң, анда ярлы халык иңри,
Тегесенең аермасы юк бусыннан.

Һәр җирдә дә ярлы халык күрә золым,
Кол итеп, бәйләгәннәр аның кулын,
Картларын җиккәннәр машинага,
Эшчеләргә каршы озатканнар
улын (угълын).

Ярлылардан ваттыралар таш-тауларны,
Чишү юк муеннардан богауларны;
Байлары талашалар җир, мал өчен,
Куя алмаслар тиз генә бу дауларны.

Һәр җирдә түбәлиләр җыгылганны,
Туганга каршы куйганнар туганны;
Күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде
Хәзерге күк кардәш кардәшне буганны.

---

Нифакъ – икейөзлелек.

Бар җирдә тигезсезлек чиктән ашкан,
Күп кешеләр туры юлыннан адашкан;
Мал, җир өчен мең-мең җаннар корбан була,
Шуны күреп гакыллар чыга баштан.

Күрдем мин Деникин, Колчагын да,
Шулар кук тагы ничә алчагын да,
Буннан соң Ходаем күрсәтмәсен
Йөзләрен, тәнемдә җан бар чагында.

Баштанаяк коллык дөньясы аларда,
Җан алалар, кол итәләр, саталар да.
Турылыкның һичбер кадере, кыйммәте юк,
Ялган белә көн күрү ансат аларда...

*

Карап-карап торам да: эш шәбәйде,
Бөтен дөнья эшчеләре чишә бәйне;
Капиталист-буржуалар калтыраганда,
Эшче халык изү чишеп итә җәйне.

---

Алчак – түбән, пычрак, куркак.

## КАПИТАЛ ИЯРЧЕННӘРЕНӘ

(*Нәзымлы сүзләр*)

Байлар, аклар, каралар – һәммәсе бергә,
Кулга-кул тотынып, киттеләр Себергә.
Анда чех-словаклар сугышты ялланып,
Безнең «зыялылар» да йөрде шунда җалманып.

Йөрде алар капитал койрыгына ялганып,
Ташлап вөҗданны, мөнафикълыкны алга алып.
Йөрисез сез хезмәт итәбез дип динегезгә,
Китәсез мөнафикълар белән диңгезгә.

Ерак киткән саен сез шәрекъ таба,
Фәкыйрь халык хөкүмәте шәрәф таба.
Капитал бит сезне дә җалмап каба,
Сез йөрисез ике арада, җалап таба.

Ялганлыйсыз, сезнең теләк соң динмени?
Сезнең мәкъсуд – күбрәк табу дингене*;
Шөһрәт, дөнья, акча – сезнең теләгеңез,
Сораныңыз, баеңыздан теләнеңез!

Беләбез без: килерсез әле бер кайтып,
Ачыккачтын, күзләреңезне акайтып.
Кызыктырган иде сезне байның ашы,
Юклыктан байлар хәзер башын кашый.

Ләгънәт укый сезгә халык, карты-яше,
Сезгә төште әнә шул ярлы күз яше.

---

* Динге (*деньги*) – акча.
Нәзымлы – көйле.
Мөнафикъ – икейөзле, хыянәтче.
Шәрекъ – көнчыгыш.
Шәрәф – дәрәҗә, дан.

## СПЕКУЛЯНТКА

Әтәч бетеп йөргән идең, күркәмени –
Кабарындың! «Эч майларың» төртәмени?
Бер көн килеп, йөз-меңнәр налог төшкәч,
Сыңар аяк тыраклатып йөртәмени?

Ничек соң, шулай ук бик иртәмени?
Халык көче борнына нык чиртәмени?
Ары чабып, бире килеп йөрү бетте,
Салдылар юлга аркылы киртәмени?

Ничек соң, булмыймыни мал табарга?
Кисәргә урман юкмы, балта бар да?
Тиз арада миллионер булу фикре
Көннән-көн чыкмас сазга бата бар да!

Бар иде бит шәп заманнар, иркен вакыт,
Йөри идең кабарынып, чыгарып кот,
Очып китте бәхет кошы башыңыздан,
Чап артыннан, ычкындырма, тиз барып тот!

---

Бетеп – «нәкъ» мәгънәсендә.

## ТӨШ ТӘГЪБИРЕ

(*«Тәгъбирнамә»*[1])

Төштә күрсәң матур кыз,
Йөрсә әйләнеп тыз да быз! –
Шөһрәт бетүгә галәмәт,
Ул шәһәрдән тизрәк сыз!

Әгәр күрсәң син табын,
Анда өләшсәләр сабын,
Юынсаң да бетерә алмассың
Мөртәтлегеңнең табын.

Әгәр күрсәң адвокат,
Сиңа әйтәм кат вә кат:
Дөньяда рәхәт күрү юк –
Маңлаеңа тот та ат.

Әгәр күрсәң милләтче
Яки бер-бер ширбәтче,
Халык йоклау галәмәте –
Син дә бишеген тирбәтче.

Әгәр күрсәң син көмеш,
Чыкмас аннан бик күп эш,
Иптәш милләтчеләреңнән
Ишетерсең син сүгеш.

Әгәр күрсәң син алтын,
Каранма ялтын-йолтын,
Шәһәрне ташлап сызарсың,
Калдырып атың, йортың.

Әгәр күрсәң сәүдәгәр,
Бунсы бик начар хәбәр:
Ашарга да табалмассың,
Бөлеп бетәр ул шәһәр.

Күрсәң спекулянтлар
Яки иске пулатлар,
Бунсы яхшыга галәмәт –
Җиңлеп бетәрләр аклар.

## ТАҢ

Төн бетте, яктырды таң,
Күк йөзе алтын нурга чумган,
Күңелләр кайгыдан котылган,
Күкрәкләр ирек һавасы белән тулган.

Рәхәтләндерә йөрәкне ирек җилләре,
Нинди нурлы безнең ирек илләре,
Турайды эшченең бөгелгән билләре,
Ни өчен бу сәгадәт буннан йөз ел элек
килмәде!

Уяндылар кырлар, урманнар,
Күтәрделәр башны йокыдан торганнар;
Һәммәсе дә йөзләрен яктылыкка борганнар,
Вакыт инде файдаланырга бу рәхәттән,
туганнар!

## ИРЕК АВЫРУЫ

(*Нәзым*)

Европада ирек мәразы,
Англиянең шуны бетерү фаразы;
Ләкин ишекне япсаң, тәрәзәдән керә
Бу «начар» социализм заразы.

Һәр җирдә ирек алу ялкыны
Чорный һәр мәмләкәт халкыны,
Баса алмый аны сибелгән
Империализм суының салкыны.

Агызалар гаскәрне су урнына,
Штык кадар өчен ирек борнына;
Бер җирдә бассалар ул «афәт»не,
Тишлеп чыга икенче җирдән, борный да.

Яндырып корытмакчы булалар тамрын,
Бөтен дөньяга таралмас борын,
Ләкин инде дөньяда һич калмагандыр
Ул «авыру» йокмаган урын.

Инкыйлаб булды капитал өчен чума,
Бөтен дөнья шул авыруга чума,
Көннән-көн һаман ул арта бара,
Никадәр генә син аны борчыма.

Бу авыру – байлар өчен зур куркыныч:
Булмый үткәреп аңар балта-корыч.
Авызны япсаң, бәреп күзгә керә,
Әйтерсең гүя тузан, борыч.

---

Мәраз – чир, эпидемия.
Инкыйлаб – революция.

## ЧЕГӘН БӘЕТЕ

Иптәшләр!

Сезнең күбеңезнең хәтерендәдер, борынрак заманнарда, без яшьрәк чакларда «Чегән бәете» дигән бер җыру җырлыйлар иде, ул җыру менә шушылай дип башланадыр иде:

«Чегән, чегән» диденез лә,
Чегән өчен үлдеңез лә,
Һи Аллам ла,
Чегән өчен үлдеңез лә.
Чегән белән бер кич кунгач,
«Тәүбә-тәүбә» диденез лә,
Һи Аллам ла,
«Тәүбә-тәүбә» диденез лә.

Хәзер инде ул заманнар үтте, иске дөньялар пыр туздыы, һәм ул җыруны да төрле кеше төрлечә итеп бозды. Хәзер аны бер буржуй, юрган астына гына яшеренеп, менә болай дип җырлый:

«Совет, Совет» диденез лә,
Совет өчен үлдеңез лә,
Һи Аллам ла,
Совет өчен үлдеңез лә.
Совет эш башына менгәч,
Безне җиргә күмдеңез лә,
Һи Аллам ла,
Безне җиргә күмдеңез лә.

Тора идем шәп йортларда,
Тыныч иде бик йокларга,
Һи Аллам ла,
Тыныч иде бик йокларга.
Хәзер, малны алалар дип,
Туры килә ут йотарга,
Һи Аллам ла,
Туры килә ут йотарга.

Явып торды элек алтын,
Доход килде төрле яртын,
Һи Аллам ла,
Доход килде төрле яртын.
Хәзер сату иттермиләр,
Кысалар бит яшен-картын,
Һи Аллам ла,
Кысалар бит яшен-картын.

Кушалар бит эш эшләргә,
Белмим инде һич нишләргә,
Һи Аллам ла,
Белмим инде һич нишләргә.
Эшләр һаман шулай барса,
Уйлыйм тиз кыяк тешләргә,
Һи Аллам ла,
Кыяк тешләми нишләргә.

Ә байның бикәсе, бер почмакка посып, менә болай дип моңая:

Күлмәкләрем асыл иде,
Бар морадлар хасил иде*,
Һи Аллам ла,
Бар морадлар хасил иде.
Дөньяда рәхәт калмады,
Инде тот та асыл инде,
Һи Аллам ла,
Инде тот та асыл инде.

Алтын-көмеш, җәүһәр-якут,
Кайда барсам – анда почет,
Һи Аллам ла,
Кайда барсам – анда почет
Иде, хәзер бар да бетте:
Ятам тик почмакта качып,
Һи Аллам ла,
Ятам тик почмакта качып.

---

* Бар морадлар хасил иде – бар теләкләр үтәлә иде.

## МИНЕМ ТЕЛӘК (1)

Булса бик ак сумса,
Кабарып алда торса,
Нинди хозур булыр иде –
Ашап корсагым тулса.

Тагы булса бераз
Симез күркә һәм каз,
Йөзеп йөрсәм майда –
Барсы да миңа файда.

Чебеш жаркуйлары,
Гүя бай туйлары!
Ашау, эчү, кәеф кору –
Һәркемнең уйлары.

Аппак атланмайлар!
Шулай, туганкайлар,
Минем күрмәгәнгә
Ничә, ничә айлар!

Кәнфит, шикаладлар,
Тәмле мармаладлар
Ашасы иде күп итеп –
Шул гына морадлар!

Бөртек-бөртек дөге,
Аппак энҗе күге –
Аз булса да ярар иде,
Кайда инде күбе!

---

Күге – кебеге.

Төштә күрдем җимеш,
Гүя ашыйм, имеш;
Өнемдә дә ашасам,
Шәп булачак бик эш.

Тормас әле шул көе,
Күмәч түгел – булкие;
Бары да булыр, хафаланма,
Сабыр ит бераз түлке.

Алар түгел, паштет та
(Һичкемгә дә фаш итмә)
Тиздән булачак, туганкай,
Ашамый ташлап китмә!

---

Түлке (*только*) – тик.

## БАЙ

Бай яшергән алтынын,
Саклый, чыгармый тынын;
Ачка үлгәндә дә бирмәс,
Сатса сатар хатынын.

Бай яшергән көмешне,
Эшләгән күк зур эшне;
Кабренә алып китмәкче
Үзе белән өлешне.

Бай яшергән энҗене:
Кагылган байлык җене!
Кем әйтсә: «Байга – ирек», – дип,
Бирәчәк сөенчене.

Байның дошманы – кызыл!
Гомере булса озын,
Бирәчәк түгел кияүгә
Кызыл кешегә кызын.

Бай дошманы – демократ,
Дошманлыгы меңәр кат;
Аклар аз гына җиңгәнне
Ишетсә ул – була шат.

Бай ярата акларны,
«Гәзитәләрдә бармы
Аклар җиңгән хәбәрләр?» – дип,
Калмый һәр көн актармый.

Бай ярата караны,
Әле тик бу араны
Җиңелгәннәрен ишеткәч,
Гәзитәне карамый.

Бай әйтә бик күп нәзер[1],
Аклар җиңсәләр хәзер,
Кызганмыйчы, егерме тиен
Чыгарып бирергә әзер.

## ҺАЙ ДӨНЬЯ!

(*«Һай Дунай» көенә*)

Дөньяда күп яшәдем,
Кеше хакын ашадым,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!
Күп матурга гыйшык тоттым,
Бик күбесен ташладым,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, рәхимсез дөнья!

Ничә хатыннар алдым,
Биш катлы йортлар салдым,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!
Хатын китте, йорт ычкынды –
Хатынсыз, йортсыз калдым,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, рәхимсез дөнья!

Дуст-ишләрем иде күп,
Бары да җуан, минем күк,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!
Корсак шиңде, байлар бөлде,
Сөрелделәр иблис күк,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, рәхимсез дөнья!

Акча, маллар күп иде,
Дөнья безгә чүп иде,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!
Бу дөньяның байлыклары
Мәңге торыр күк иде,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, рәхимсез дөнья!

Корсагым иде мичкә,
Күтәреп йөрдем көчкә,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!
Бөтен дөнья хәрам малы
Сыядыр иде эчкә,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, рәхимсез дөнья!

Кесәләрне тутыргач,
Барып кылдым ничә хаҗ,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!
Совет бар малны алгач,
Калдым хәзер ялангач,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, рәхимсез дөнья!

Ярлы халыкны яклап,
Кибетләрне йозаклап,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!
Өләштеләр бар малны,
Кирәк кешегә ваклап,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, рәхимсез дөнья!

Эчтә серемне саклап,
Советыңызны яклап,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!
Тормыйм бунда, ташлап китәм,
Аклар ягына атлап,
Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, рәхимсез дөнья!

Һай дөнья, вай дөнья,
Һай, вафасыз дөнья!

## «МАТУР ЯР, КЕНӘРИ» КӨЕНӘ[1]

Дөньяда син рәхәт сөрдең, рәхәт сөрдең,
Күп тәмлене ашадың, ашадың.
        Буржуем, байбәтчәм, бүген гаебеңне ачам.
Бик күп матур яшь кызларны, яшь кызларны
Харап итеп ташладың, ташладың.
        Буржуем, байбәтчәм, үзең булдың гайбәтчән.

Син кылмаган начарлыклар, начарлыклар
Бу дөньяда калмады, калмады.
        Буржуем, корсагың, гаебеңне ачам тагын.
Булдыра алсаң, син тырыштың, син тырыштың
Алдаларга Алланы, Алланы.
        Буржуем, майлы күз, үткен тешләремә түз.

Аллаң синең – акчаң иде, акчаң иде,
Динең булды мал гына, мал гына.
        Буржуем, ачкүзем, гыйбрәт белән ач күзең.
Фәкыйрь эшче халыкларны, халыкларны
Тезләндердең алдыңа, алдыңа.
        Корсагың – киң алап, көн күрдең син алдалап.

Ашау-эчү, кәеф кору, кәеф кору –
Байбикәнең уйлары, уйлары.
        Буржуем, байбикә, бар байлыкларың китә.
Бүген безнең очка килде, очка килде
Шатлык сабантуйлары, туйлары.
        Байбикә, бай туташ, серләреңез булды фаш.

## ЯҢА «ҖИЗНӘКӘЙ»

«Җизнәкәй» көен ишетмәгән, җырламаган кеше юктыр, шулай да әле сезнең яңа чыккан «Җизнәкәй» көен ишеткәнегез юктыр.

Ул менә болай җырлана:

Бу билләрең нигә нечкә, җизнәкәй?
Ашау такыр булганга, балдызым, ялгызым.
Йөзләрең дә бик каралган, җизнәкәй?
Сабын кыйммәт булганга, балдызым, ялгызым.

Муеннарың бик юкарган, җизнәкәй?
Байлык бетеп бөлгәнгә, балдызым, ялгызым.
Чырайларың да сытылган, җизнәкәй?
Яфрак чәе эчкәнгә, балдызым, ялгызым.

Корсакларың да калмаган, җизнәкәй?
Көн-төн җәяү йөргәнгә, балдызым, ялгызым.
Аркаларың ник бөкере, җизнәкәй?
Капчык ташып йөргәнгә, балдызым, ялгызым.

Аякларың ник кәкере, җизнәкәй?
Иске итек кигәнгә, балдызым, ялгызым.
Битләрең дә җыерчыклы, җизнәкәй?
Мае бетеп шиңгәнгә, балдызым, ялгызым.

Гәүдәләрең калтырана, җизнәкәй?
Салкын өйдә торганга, балдызым, ялгызым.
Ул күзләрең ник яшәргән, җизнәкәй?
Күңелләрем тулганга, балдызым, ялгызым.

Син бөтенләй ябыккансың, җизнәкәй?
Ачлы-туклы торганга, балдызым, ялгызым.
Ни өчен соң эшләмисең, җизнәкәй?
Ак сөякле булганга, балдызым, ялгызым.

* * *

Арыслан да сөяк ашый,
Карыннары ач булса,
Авыз тутрып ашар идем,
Ак кына күмәч булса.

Киеп чыгып йөри идем
Американ читеген,
Кияргә дә табып булмый
Инде солдат итеген.

Ашаганым күмәч иде,
Инде калды икмәккә;
Бу эшләрнең барысы да
Булыр бер-бер хикмәткә.

Йөгереп чыктым урамга –
Тәгәрәп килә бер алма,
Байны санамыйлар санга –
Кызыкмый һичкем малга.

Утырып йөрдем яхшы атка,
Түшләремне киереп;
Үтеп киттем саилчедән,
Бакыр бер тиен биреп.

Йөри идем мин «пух!» итеп
Төлке, янут толыптан,
Инде хәзер өтәләндем
Янып чыккан күк уттан.

Һәр көн күп-күп файда иткәндә
Бик шәп иде эшләрем,
Утын да юк ягарыма –
Шак-шак итә тешләрем.

Ары чабып, бире килеп
Йөри идем кунакта,
Актык атны да озаттым,
Калмагачтын улак та.

Күркә, чебеш, каз, үрдәк –
Иртә-кичке ашларым;
Инде хәзер берни дә юк –
Бәрәңге ашый башладым.

Ашаганым – кара икмәк, –
Җыртып төшә үңәчне,
Шатлыгымнан сикреп тордым,
Төштә күргәч күмәчне.

Складлар тулы иде
Төрле-төрле мал белән;
Чәйне дә эчә идем
Лимон, шикәр, бал белән.

Эчкәннәрем – куфи иде,
Ашаганым – кәләвә,
Инде каты икмәкләрне
Авызда тик әвәлә.

Чикмәннәрем драп иде,
Бүркем иде каракүл,
Исемә дә керми иде
Килер диеп кара көн.

Гаклым җитми, хәйран булам
Беткәненә бу байлык.
Юкка борным чөеп йөрдем –
Булган икән бер айлык.

Самаварны да куябыз
Шакмак белән күмерсез.
Бу хәсрәтләрне күргәнче,
Ник булмадым гомерсез!

## ИСЕМНӘР

Бик матур кыз бит Зәйнәп,
Йөрмәсә гайбәт чәйнәп,
Тузгыган чәчләрен куйса
Аз гына үреп, бәйләп.

Бик матур кыз, ди, Мәрьям,
Дөньяга да бирә ямь,
Гаклы бераз җиңгелерәк,
Тик шуңар янам, көям.

Бик матур кыз Мәрфуга,
Бик тиз ярсый ярсуга,
Аз гына бер сүз эндәшсәң,
Китереп яңакка суга.

Гакыллы кыз Әминә,
Юк-барга үпкәләми дә,
Бер дә үпкәләмәгәчтен,
Булмый икән яме дә.

Матур кыз икән Бәян,
Булмаса әгәр наян,
Тик менә шунсы ярамый,
Ансысы бераз шаян.

Матур булса да Әсма,
Ансының теле тасма,
Тасма теле сөйли бирсен,
Син аңар колак асма.

Анда бар тагы Камәр,
Ну усал икән, каһәр,

Һич тә якты көн күрсәтмәс,
Хатының булса әгәр.

Тагы бар бер Фатыйма,
Һич чакырмый катына,
Шулай да керер хәлем юк
Аның яманатына.

Аннан теге Рабига,
Бармады бит абыйга,
Яшь кешене яратам, ди,
Алсаң – барам, ди, миңа.

Тагы бар бер Маһыруй,
Анысы усал – уй, уй, уй!
Аны сөям дип тә йөрмә,
Ул уеңны тизрәк куй.

## БЕР РӘСЕМГӘ

(*Пародия*)

Ник матур булмасын ул, тутыргач энҗе, алтын башына;
Шундый ак һәм шундый матур – охшый кабер ташына.

Шуны әллә белмисеңме, бар, парикмахердан сораш,
Әйе, күрдем, охшый икән китек тегермән ташына.

Һич оялма, капла битең, битеңә чүпрәк әләм,
Затсызлыгың өчен бирер бәласен Алла сиңа.

Андыйлар миллион табылыр, уйлама син мең генә;
Кулы[ң] баткач аның селәгәй лайласына,

Бозланыр күңлең, җылыныр өчен кирәк булыр туның, –
Шундый салкын бер чырайлы – охшый Себер һавасына.

Нишләп азсын, андыйлар дөньяда аз-мазлармыни,
Утырып китәрләр иде, качып, тирес арбасына.

Ачысыннан җылар әлбәт, имеш, ирнен тешләсен,
Тузгыган башы охшый каргалар оясына.

Күрмәгәндер чәчләре мәңге һич тарау-үру,
Ант итәр иде гомергә янына бармасына.

Бөркәнеп киеп утыр утын чанасына туның,
Тәкать тотар хәл калмады бу карынның ачына.

## НӘРСӘ СӨЙЛӘРГӘ КИРӘК?

(*Бу кайдан?*)

Белмисеңме, иптәш, дару сөялгә?
Агып торган фонтан суын бөяргә?

Белмисезме: кыяр ничек тозлана соң?
Суык чакта су ничек бозлана соң?

Бу ел кояш ничек чыга иртәли соң?
Әллә аны диюләр йөртәме соң?

Кесәңдә булмаса синең әгәр рәт,
Револьверның дулосын маңлайга терәт.

Кабак, кишер табу бу ел асатмы?
Биш йөз сумнан кимгә һичкем дә сатмый!

Булсын синең яныңда калын җанчык.
Булмаганда – далуй тәннән, әйдә, җан, чык!

Туган, туйдырсалар – кайгырма бер дә,
Ашарбыз тик утырып бергә-бергә!

## БӘРӘҢГЕ

(*Пародия*)

Түп-түгәрәк, кып-кызыл бәрәңге күргән кеше
Пешереп табак тулы, алга куеп утырып көйши.

Ул бәрәңге итләч ул: ашап җибәрсәң син үзен,
Туя тамак, күбә корсак, майланып китә күзең.

Күрсәләр капчык тулы ире бәрәңге арбада,
Сырышалар төрле яктан, йөгрешәләр алмага.

Гашыйк булып бар халык бәрәңге – җир алмасына,
Тезелеп чират торалар сатучы арбасына.

Күрсәләр әгәр бәрәңге бер кешенең кулында,
Кайдан алганын сорыйлар – туктатып мең урында.

Һи бәрәңге! Җитми аңар, торса әгәр алда ул –
Күп ашала – туйган булып тик үзеңне алдау ул!

## ӘҮВӘЛГЕЧӘ ТҮГЕЛ

(*Пародия*)

Алманың вак төшләрен ыргытып, җалманып:
«Әмма дә тәмле икәнсең», – дип, алып ашадым кичә.

Мин аның йомшак итен, кызыл битен, алсу түгел
Сабакларын, үзен калдырмыйчы йоттым кичә.

Чи алманың агуын, холерын күңел бик сизсә дә,
Янды күзем, түзмәдем мин – алмадан агу эчтем кичә.

Ә бүген, аһ! Ул алмам – ул минем кызыл йөзем,
нурым –
Нишләде? Эчне борып тешләде, чакты бүген.

Ул, багалмам, алдады мин абжорны, нык алдады, –
Бозды эчне, тик биетә, аяк тиз-тиз атлый бүген.

Шулмы соң тәм! Ташла үзен, ат! Алманы ашау кая?
Ул бетерде эчне, күмде мине, якты бүген!

Йөз яме һәм алма тәме бер-берсенә башкалыгын,
Әрнетеп эчнең ярасын, алма аңлатты бүген.

## БАЙ СҮЗЕ

Яратам мин Советларны,
Син – буржуй димәсәләр;
Башкаларда һич эшем юк –
Үз малыма тимәсәләр.

Бәйләнәләр бит корсакка,
Ник алай җуан, диләр;
Кеше хакын ашаганга,
Ул шулай тулган, диләр.

Сөбханалла, бу нинди сүз,
Минме ашыйм кеше хакын?
Салмас өчен читкә күзне,
Алып куйдым кече хатын.

Чыгып булмый атка утырып:
Бары да карый күз тутырып;
Аңлый алмый бу эшләрне,
Хәйран булам торып-торып.

«Син бай!» – диләр. Бай булса соң?
Мин бит малны үзем тапкан:
Арзан бәһагә алган да
Яхшы файда итеп саткан...

Мал күп икән, ни булган соң?
Алдым аны үзем табып*;
Талап алган булсам иде,
Куярлар иде бит ябып**.

---

* Авторда: «тавып».
** Авторда: «явып».

Файда итсәм – иткәнмен осталыктан,
Осталыгымны мин яшермим халыктан;
Йә, әйтегез, кемнәр кулын селтәр иде
Кармагына килеп эләккән балыктан?

Яшерә алмыйм салып куйганны кармакны.
Караткканны үземә таба бармакны;
Булдыра алсаң, син дә бае, һич көнләшмим,
Сату-алу эше ул мең тармаклы.

Соң көннәрдә терәлде көймә комга,
Куркып карап йөрисең уңга-сулга:
Яшергән малларны табалар, дип,
Үземне ябалар, дип, «чиривкомга»[1]!

## МИНЕМ ТЕЛӘК (2)

Кеше гашыйк кара күзгә,
Минем теләкләрем үзгә.
Минем теләгәнем – мәгънә,
Кешеләр алдана сүзгә.

Кеше гашыйк кара кашка,
Минем теләкләрем башка:
Әйләндерергә мин телим
Дошманнарны тораташка.

Кеше өйрәнгән сөенергә,
Матур итеп киенергә;
Миннән булмый, мин тик телим
Бар халыктан сөелергә.

Халык белән шатланырга,
Бергәләшеп атланырга
Залимнәрнең муйнына да,
Каһарман дип адланырга*.

Минем теләк: ирек, бәхет,
Ярлы халык өчен тәхет;
Халыкны кол итүчеләр
Өчен – казу тирән ләхет.

* А д л а н у (*ад алу*) – ат (*исем*) алу.

## БИЮ КӨЕ

Бас, дустым Лойд Жорж[1],
Син басмасаң, мин басам,
Актык җиңү туебызда
Басып калыйк, ичмасам.

Видро Вильсон[2], син дә бас,
Мин дә шулай баскалыйм,
Син дә үз ягыңны кара,
Мин үз кесәмне карыйм.

Ашыкмаңыз, дустларым,
Бунда мин дә бар әле,
Минем дә басып калырлык
Бераз хәлем бар әле.

Син дә калма, Килмансу[3],
Синсез безгә ямансу;
Безгә кайчан насыйб булыр
Җиңел көйләргә басу.

Син дә бас, дустым Пишун[4],
Шулай бергәләп биш-ун
Мәмләкәтне кулга алсак,
Ярап торырлык эш ул.

Тагы шулай Арландо[5]
Болар белән парланды:
«Киңәйтә төшик байлыкны,
Йорт-җиребез тарланды».

Бу арада союзниклар
Шушы көйгә бииләр,
Тулмас, төпсез кесәләргә
Алтыннарны төйиләр.

Әйдә, биеп калсыннар,
«Теләгәнне» алсыннар,
Озакламый киертербез
Төпсез, җыртык кальсоннар.

* * *

Буржуйны без яратмыйбыз,
Яратмаслык урны бар:
Буржуй торды киң йортларда,
Безнең фатир булды тар.

Буржуй итте файданы,
Ә безгә соң кайда, ди;
Гомер буе тарткан ләмкә
Муенны күп кайрады.

Буржуй торды яктыда,
Ә без тордык шакшы өйдә,
Кара икмәкне кимердек,
Теш үтмәс каты көйгә.

Буржуй киде шәп кием:
Төлке, янут һәм тиен,
Ә безнең кигән киемнәр
Тормый иде бер тиен.

Буржуй ашый шикәр-бал,
Җыя акча, җыя мал,
Ә безгә тик көн-төн хезмәт
Итәргә, һәм һич юк җал.

Буржуй кия трико,
Гел рәхәттә көн итә,
Эшче халык, җәфа чигеп,
Дөньяны ташлап китә.

Буржуй көн-төн рәхәттә,
Хатыны – ике, өч хәтта,

Җәяү йөрү дә ярамый –
Чабып йөри гел атта.

Син эш хакын күп сорасаң,
Канәгатьсез буласың,
Ә буржуйда кесә төпсез,
Һич тә белми туласын.

Эшче һич тә тик ятмасын –
Көне-төне эшләсен,
Буржуй эчендә май кайный,
Һич тә белми нишләсен.

Буржуй тели яхшы һава –
Җәен чыга дачага,
Ә эшченең эш күплектән
Маңлай тирләре чыга.

Эшче китә дөньядан –
Билләре бөкрәйгән,
Ә буржуйның, рәхәт яшәп,
Күңелләре көрәйгән.

## БОЛЬШЕВИЗМ КӨРӘШЕ

(*Нәсер*)

Союзниклар большевизмны телиләр буарга,
Ләкин үзләренә туры килә эчләрен уарга.

Сүндерергә маташканда большевизмның утын,
Яңа утның кабынуы ала союзник котын.

Капчык һәр яктан тишелә, союзник алмый җамый.
Көн-төн ишетелеп тора яңа халык кыямы.

Янгын башта көчсез иде, кабынды тик Русия,
Бөтен Европа бу көндә шул ут эчендә көя.

Су дип сипкәннәре утка булып чыга кирасин,
Тиздән капитал рухына укылачактыр ясин.

Теләделәр большевизмны себереп түгәргә,
Көчләргә ният кылдылар* сугыш бурычын түләргә.

Санадылар бугай алар бар халыкны җүләргә,
Ләкин халык барысы хәзер ирек өчен үләргә!

---

* Көчләргә ният кылдылар – «антлар иттеләр» мәгънәсендә.
Кыям – кузгалыш.

## КЫЗЫЛ КАРА, КЫЗЫЛ-КАРА

Берзаман кызыл кара
Хөкем сөрде берара.
Шул заман, карап кара,
Хакимнәр иде кара.

Берзаман кызыл-кара
Сугыштылар үзара.
Кара җиңелеп бара,
Төзәлә инде яра.

Күп вакытта: кызыл кара –
Күп әсәрләр иде кара.
Инде хәзер, карап кара,
Эшләр кая таба бара?

Язу каралары кара,
Ләкин фикерләр агара;
Кара язу – кызыл фикер –
Сәгать саен артып бара.

Күп булганда кызыл кара,
Күп фикер булды чем-кара.
Әгәр булса кара кара,
Фикер кызыллыгын кара.

## БҮГЕН БӘЙРӘМ

(*Нәсер*)

Буннан нәкъ мең бер көн элек,
Булып берәү тере үлек,
Кергән иде мәгарәгә.
Бүген, чыккач терелеп,

Хәйран калды дөньяга:
Киң тоелды дөнья аңа;
Элекке корган бинадан
Ирек чишмәсе ага.

Өч ел буннан элгәре
Мужикларның билләре
Бөкрәйгән иде коллыктан,
Эштән чыккан илләре.

Көн-төн түләп имана,
Булган иде дивана;
Бөтен халык эчләреннән
Каһәр укып җуана

Иде. Ахырда бер көн
Китте өсттән кара төн,
Залим патша тәхетләре,
Янып, булдылар төтен.

Шатланды буңар халык,
Бетте диеп «патша»лык,
Бүген зынҗыр, богауларны
Ташладык, диеп, алып.

---

З ы н җ ы р – чылбыр.

Ләкин озак тормады,
Менә бер көн борнады
Байлар яклы бер хәйван
Да ирекне урлады.

Килеп чыкты Керенский,
Тәртип булды кире иске;
Капитал коллыгы кайтып,
Кысанлык җилләре исте.

«Ирек дәвере» дигән булып,
Күтәрделәр кара болыт.
«Дошманнарны куабыз» дип,
Кабыздылар тагы бер ут.

Тагын коеп эшче канын,
Сарыф итеп халык малын,
Чыгарырга теләделәр
«Бөек Русия»нең данын.

Бетереп эшчеләр көчен,
Үз малларын саклар өчен,
Тырыштылар сугышырга,
Алмакчы булдылар үчен.

Учредилканы да сайлап,
Эшләрен дә яхшы җайлап
Калу артыннан йөрделәр
Ничә көнләп, ничә айлап.

Сизеп эшче бу хәйләне,
Кулларын бик нык бәйләде.
Менә шул көн шәрәфенә
Бүген ителә бәйрәме.

Бүген чын халык бәйрәме!
Һәм аның шунда бар яме:
Ит бәйрәмеңне бергәләп!
Гафил утырмаңыз, яме!

---

Гафил утыру – белми, ишетми калу.

## ЗАР

(*Буржуй авызыннан*)

Йөргәндә йөри идем акрын гына,
Эш юк иде, ята идем кырын гына,
Сөйләшкәндә бары тик җырлый идем
Патшалар, алпавытлар җырын гына.

Дөньяда юк иде һич минем кайгы,
Ашаганым татлы иде һәм дә майлы,
Эшләрем барысы да иде уңайлы,
Тора торган урыным да иде җайлы.

«Начальства» миңа бик дустлар иде,
Дустларым шәп пагунлы руслар[1] иде.
Шулай иркен дөньяларда рәхәт яшәп,
Һичбер гамьсез торган чакларым бар иде.

Һич мохтаҗлык юк иде миндә акчага,
Чыгып күңел ача идем мин бакчада;
Кирәк булса, сатып алырга дөньяны
Җитәрлек иде бит минем чама.

Һәр рәхәт бар, кирәк түгел иде җәннәт,
Кәефем өчен тормый идем акча жәлләп.
Дуст-иш белән җыелышып аулакларда
Мактанганда килә иде безнең бик гәп.

Малларны өеп куеп йөкләп, киплəп,
Дөньяда яшәгәндә шулай иплəп,
Кайдан килеп чыктылар бу
«кызыллар» да,
Бөтен сату-алуларны куйды бикләп.

Кырылды тегермәннең кырык чөе,
Бөтен бар рәхәтнең китте көе.
Иттеләр бар нәрсәне Совет милке,
Калмады торырга да җүнле өе.

Көн күрергә кушалар бит хезмәт белән,
«Эш эшләгән ачтан үлмәгәнне» беләм.
Тик менә рәхәт үскән гәүдә белән
Кара хезмәт эшләү хурлыгыннан үләм.

Ишеткәнем бар иде кыяматне,
Белми идем ничек булачагын рәтле;
Ахыр бер көн, Совет хөкүмәте килеп,
Кыяматкә иман китерүне өйрәтте.

## ИКЕ ЕЛ

### I

Анда почмакта кысылган бер фәкыйрь утыра туңып,
Бунда бер бай бара чабып, киерелеп, киеп толып.

Анда бер бай тутыра корсак төрле тәмле аш белә,
Бунда ерак тар урамда ярлылар ачтан үлә.

Бунда эшче тамак өчен хезмәт итә төнката,
Бай тегендә – «шаһ би гамь», йомшак урында ята.

Ярлы анда көн буена җигелеп сабан сөрә,
Бунда байлар түш киерә, булган алар зур түрә.

Анда ачлык, анда суык, анда юк һичбер ни дә,
Бунда шатлык, бунда туклык, дөньяга төкерми дә.

Анда юк һич җан әсәре, кап-караңгы – нәкъ кабер,
Бунда сарай нурга чумган, яна кандил мең дә бер.

Анда юк кабарга телем, ачлык эчләрен бора,
Бунда юкка-барга исраф, эчү, кычкырып «ура!».

Анда ялангач балалар, киеме тездән генә,
Бунда бай кызы асылташ, алтынын тезгән генә.

Анда пычрак, анда пислек, анда суык, анда тар,
Бунда киңлек, бунда җәннәт, ни кирәкләр – бар да бар.

Анда шатлыклар тудыра, булса икмәк туклыгы,
Бунда кәефне җибәрә татлы канфит юклыгы.

---

Ш а һ  б и  г а м ь – кайгысыз шаһ.

Анда икмәкне табалар көч белән, дәрман белән,
Бунда һәрни, бар да хәзер акча һәм фәрман белән.

Анда аналар үлә, кан азлыгы белән кибеп,
Бунда көлә һәммә йөзләр, яшиләр дөнья тибеп...

## II

Килде көннәр, иste җилләр, нинди сулар акмады,
Якты ирек көне килде, дөнья йөзен пакьләде.

Башлады ирек җиле дөнья йөзен әйләндерә,
Ярлы йортка башлады якты ирек нуры керә.

Себереп үрмәкүчләрен, яктырттылар почмакларын,
Төзеделәр халык өчен дөньяның оҗмахларын.

Анда якты, анда ирек, анда кояш һәм дә нур,
Барча дошманнар җиңелде, һәммәсе дә булды хур.

Суга батты, утка янды капитал козгыннары;
Очты күккә бар капитал – көл, тузан һәм комнары.

Бар халык итә бу көннең якты шатлык бәйрәмен,
Барча дөнья ярлылары күрә бу бәйрәм ямен.

## ДЕНИКИННЫҢ ТӨШЕ

Арып-талып, Деникин
Качып бара, яткан да.
Йөзтүбән йокыга китте,
Актык таңы атканда.

Юк тынычлык йокысында,
Як-ягына әйләнә.
Куркуыннан таушы чыкмый,
Телләре дә бәйләнә.

Ул һаман да саташа,
Сугыш белән маташа;
Котылырга юллар эзли,
Сикреп чыгып ут аша.

Тирә-ягы караңгы,
Бер дә алга баралмый;
Әйләнеп карый: гаскәр юк,
Әллә кайда таралды.

Союзниклар да күренми –
Әллә кайда югалган;
Артына борлып караса,
Анда халык чуалган.

Күзе төшә пагунына –
Ул да ялкын, ут булган;
Кайда басса, анда бата,
Диңгез кан белән тулган.

Тирә-як – кан диңгезе,
Ялгыз Деникин үзе;

Атау эзли котылырга,
Канланган ике күзе.

Күз сала байрагына –
Ул да кызыл кан гына;
Ак, зәңгәр, кызыл әләмнән
Тик кызыл калган гына.

Кесәсен карый капшап –
Анда да җилләр исә;
Гаскәре дә бара какшап,
Кызыллар турый-кисә.

Як-ягына карана ул,
Канлы күзләрен ачып;
Кайда бакса, анда аклар
Гаскәре бара качып.

Тирә-якта бары калган
Бары тик ач эт кенә,
Кайда үләксә булыр, дип,
Ашарга көтеп кенә.

Ул ач этләр ике аяклы
Алпавыт, баяр икән;
Шундый этләр һәммәсе дә
Деникинга яр икән.

Тик аларның максуды
Ашау һәм талау икән,
Эшче фәкыйрь канын эчеп,
Тәрилкә ялау икән...

* * *

Солых булгач, тынычлангач дөньялар
(Белмим, күпме вакыт узар әле аңар),
Эшләргә дип вакыт көтеп ятучылар
Дөньяда ничә вә ничә меңнәр бар.

Керешмәкче аларның бары да эшкә,
Яки хезмәт итәргә берәр төшкә.
Эшләмәкче булган эшен бу кешеләр
Көндез уйлый, кичләрендә күрә төштә.

Кайберләре йөриләр шуны уйлап:
Юл ачылса, китәргә Идел буйлап,
Китерергә Әстерханнан бик күп балык,
Ашарга гәрчитсәләп һәм дә суйлап.

Берсе тели китерергә бодай оны,
Шуны тели искә төшереп Ходаены;
Бүген үк сәфәргә дә чыгар иде,
Тик таба алмый, җөдәп чыга, уңаены.

Берсе уйлый китәргә чит илләргә:
Германия, Австрия, Сиҗилиягә.
Анда барып, күп акчага күп мал алсаң,
Файдалар күпләп-күпләп тиз әләгә...

Шул уй белән болар бар да акча җыя,
Тоттырмакчы учлап акча бакчачыга;
Дөньяның хәлләреннән хәбәре юк,
Бөтен эшләр уйлаганнан башка чыга.

---

Суйлап – соуслап.
Сиҗилия – Сицилия.

Белми алар сугыш ниләр җимергәнен,
Бөтен халыкның сөяген кимергәнен,
Чит җирләрнең халыклары һәрнәрсәгә
Бездән артык мохтаҗ булып тилмергәнен.

Белми алар сугыш ниләр яндырганын,
Дөньяны ач-ялангач калдырганын;
Белмиләр һәр җирдә до комсыз байлар
Түктергәнен эшче халык газиз канын.

Кайда гына карасаң да – гел бөлгенлек,
Аның нидән булганын син тор белеп:
Байларның максудлары – һаман талау,
Талаган рәвешенчә буннан элек.

Дөнья алардан котылыр тик бер юл белән,
Китсә бөтен эшче халык бер юл белән;
Сөялле кул эшче халык бар җирдә дә
Хуҗа булса, дөнья төзәлүен беләм.

## БУРЖУЙ ТЕЛӘГЕ

(*«Сандугач, күгәрчен» көенә*)

Мин телимен сөтле чәйнең
Эченә шикәр катканын,
Сандугач, күгәрчен,
Тамагым ач, күрәмсең.
Өем-өем акчаларның
Өелешеп ятканын,
Сандугач, күгәрчен,
Күзем туймый, күрәмсең.

Эчәр идем бал булса, ди,
Йөрәгемә ял булса,
Сандугач, күгәрчен,
Ниләр телим, күрәмсең.
Балы өчен кайгырмыйбыз,
Кибет тулы мал булса,
Сандугач, күгәрчен,
Черсен шунда, күгәрсен.

Бадьян чәчтем – булмады ла,
Бодай чәчтем – уңмады,
Сандугач, күгәрчен,
Күзләрем ач, күрәмсең.
Мильюн-мильюн файда иттем,
Һаман нәфсем туймады,
Сандугач, күгәрчен,
Нәфсем усал, күрәмсең.

Безнең урам түбән таба,
Шуып бара бер чана,
Сандугач, күгәрчен,
Теләгем зур, беләмсең.

Инде мильярдлар табарга
Табасы иде бер чара,
Сандугач – бичара,
Таба алмыйм ни чара.

Акча, малга мин бик гашыйк,
Малны малга алмашыйк,
Сандугач – матур кош,
Файда иттем былтыр кыш.
Башкалар ачка үлсә дә,
Тик без тәмлене ашыйк,
Сандугач – канатлы,
Җигеп чабам пар атны.

Аппак симез каз итләрен
Мин турыйм да, син аша,
Сандугач, ябалак,
Тыгын, торма чамалап.
Кода-кодагыйлар белән
Белер идем сыйлаша,
Сандугач – кошмыни,
Бу чамадан тышмыни.

И Ходаем, муенымны
Җилкәм белән тигез ит,
Сандугач – ак түгел,
Минем күңлем шат түгел.
Авызымнан сулар килә,
Искә төшкәч симез ит,
Сандугач –сайрадың,
Мин тешемне кайрадым.

Башка теләкләрем бетте,
Тик бер генә телэгем,
Сандугач – бакчада,
Ул да булыр акчага.
Матур симез хатын салсын
Муенга ак беләген,
Сандугач – син түгел,
Шуларны тели күңел.

## НӘСЕР

Күк йөзе – бер барабан ул,
Әнә, яшен камчысы суккач, дөберти.
Дөнья сугышы – бары да карадан ул;
Барсы да өрде, үлгәч бер эте.

Кояш – дөнья күкрәгенә тагылган бер медаль,
Мактана шуның белән бөтен күк йөзе.
Кеше шулай ди, ә минемчә, кояш белән ай –
Караңгыда эзләнеп йөрүче мәче күзе.

Кояш бата, бөтен мәгъриб ялкынлана,
Бөтен дөнья кып-кызыл ут була.
Шул янгыннан чәчрәгән очкыннар белән
Төннәрдә бөтен күк йөзе тула.

Әнә ул очкыннар атылып төшәләр җиргә таба,
Җирме? Җир ул мич төбенә куелган чуен таба.

Кара әле син дөньядагы диңгезләрне,
Шуларны бит җүләр халыклар «су» диләр.
Һи диваналар, ышанмаңыз; дөньяда һичкем дә
Шуның эрегән кургашын икәнен белмиләр.

Караңыз әле теге матур кызның йөзенә,
Йөзләре аның кызыл гына, ал гына.
Юк сүз ул, кызыл да түгел, ал да түгел,
Тик ул аның битенә буялган кан гына.

---

Мәгъриб – көнбатыш.

Һа, караңыз әле, кара, дөньяда
Матурлар, гүзәлләр меңнәр ич!
Син ни юк сүзне сөйлисең, алар бар да
Асыл тыш тарткан мендәр ич.

Һи, караңыз әле, кара, дөньяда нинди байлык!
Бөтен халыкта чемоданнар тулы унар меңлек
кәгазь.
Кәгазь түгел, алтын да чын байлык түгел,
Ләкин аны дөньяда аңлаган кеше бик аз.

Дөньяда алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән,
Җәүһәр-якутны сөю булган гадәт.
Бетсен алтын, бетсен көмеш,
һәркем булсын бертигез!
Менә, туганнар, шунда инде бар сәгадәт.

---

Сәгадәт – бәхет.

## АКЛАР САФЫННАН

Кызыгып алтын-көмешкә,
Керештек без юк эшкә;
Союзникларга сатылып,
Утырдык без юешкә.

Төрлечә итеп алдап,
Иттеләр безне солдат;
Төрле матур сүзләр белән
Сугыштырдылар яллап.

Кызыктырып тәтигә,
Каршы илтteләр әтигә;
Ничә айлар, ничә еллар
Без сугыштык соң нигә?

Аңламыйча хәйләсен,
Саклап байлар файдасын,
Сугышып йөрдек ничә айлар,
Хода гафу әйләсен.

Без үзебез дә эшче,
Әткәй дә көн-төн эшли;
Эшчегә каршы сугыштык,
Аңламаганнан эшне.

Без үзебез ялангач,
Карыннарыбыз да ач;
Тук байларның файдасына
Булып йөрдек без палач.

Инде, иптәш, күзең ач,
Аклар сафыннан тиз кач!
Алар җиңсә, патша куеп,
Киертәчәк алтын таҗ.

Җиңсә – алыр җиреңне,
Солдат итәр иреңне,
Көн-төн хезмәт иттерерләр,
Бөкрәйтерләр билеңне.

## ИРЕК ТАҢЫ

(*Нәсер*)

Европаның капиталист байлары
Тырышалар безгә китереп патша куярга;
Әмма Европаның эшчеләре – түгел кую,
Хәзер торалар үз патшаларын суярга.

Европа байлары тырышалар
Иректе Русияне дүрткә бүләргә;
Үзләренең эшчеләре хәзер тора
Ирек өчен сугышып үләргә.

Европа байлары тырышалар
Кол итәргә безне боярга;
Әмма үзләренең эшчеләре тырыша
Үз байлары коллыгыннан таярга.

Көрәшләр бара һәр ике яктан,
Көн туган, кояш баткан саен кызып;
Бетәр тиз көннән – озакка бармас –
Бөтен дөнья капиталы пыр тузып.

Берләшер бөтен дөнья эшчеләре
Берлек, иттифакъ белән, аң белән.
Бөтен дөнья эшчеләре тәбрик итәр тиздән
Иптәшен иректе, якты таң белән.

---

Иттифакъ – союз.

## КАПИТАЛГА

И рәхимсез капиталым, синең өчен
Сарыф иттем бертуктамый бөтен көчем;
Ахыр бер көн ялгызлыкта ташлап киттең,
Кайгы-хәсрәт утында яна эчем.

Мал артыннан чабып йөрдем гомер буе,
Итәрмен дип ахыр бер көн бәхет туе;
Алдандым ялган көләч йөзләренә,
Мине ташлап китү булган икән уе.

Белгән булсам аның болай алдарыны,
Тутырмаган булыр идем амбарымы;
Нәфсемнең кәефләрен табар өчен,
Тараткан булыр идем малларымы.

Рәхәт яшәүне уйладым картайганчы,
Чаптым артыннан хәлләремнән тайганчы;
Мин аны дусттыр дип белгән идем,
Ул икән кяфер мәлгунь һәм ялганчы.

Алданмам байлыкларга буннан ары,
Алдау гына максуды булган бары;
Бүген миңа җылмайса фахишә күк,
Иртәгә башкаларга көлеп карый.

## ХАТАЛЫК

Туганкайлар, булган бик зур хаталык –
Акча җыеп булмады һич киез каталык.

Чыгарам дип үземнән бер яңа эш,
Сатып куйганмын искесен дә яңлыш.

Кияремә бар иде яхшы бишмәт,
Сатып куйдым аны да әллә нишләп.

Шулай ук бар иде бер иске тун да,
Акча кирәк булгач, саттым утынга.

Исән булса иде, ичмаса, толып,
Бу кышта йөрмәс идем, бәлки, туңып.

Яңасы була дип саттым итекне,
Өч ай инде, итекчесе дә текми.

Җәй җитә, алда бар бит тагы дәү эш.
Кайдан табып алырга инде кәвеш.

Шулай күрәм бу дөньяның газабын,
Тагын сөйләрмен калганын, азагын.

## БЕРЛӘШЕҢЕЗ, БӨТЕНДӨНЬЯ ЭШЧЕЛӘРЕ!

Көчле рух, таза кул, киң күкрәк –
Кайсы якта булса шундый хасият күбрәк,
Куркыта алмый ул якны һичбер давыл,
Килсә дә яшен яшьнәп һәм күкрәп.

Таза рухлар була тик таза тәндә,
Куркак була һәрбер начар рухлы бәндә.
Куркак җаннар артларда качып кала,
Башкалар алга таба йөгергәндә.

Безгә кирәк таза кул – эшче кулы,
Шул кулларга таяну – Совет юлы;
Халыкны шул юл гына коткара ала
Булудан бу дөньяда байлар колы.

Көч никадәр күп булса безнең якта,
Эшче халык хәл алып баса аякка;
Ярлы халык дөньяда куәт алса,
Ирек нуры таралыр төрле якка.

Киләчәктә якты тормышның чибәре –
Берләшкәндә бөтендөнья эшчеләре.
Телеңездә сезнең тәсбих булып йөрсен:
«Берләшеңез, бөтендөнья эшчеләре!»

## БЕЛӘ АЛМЫЙМ

Белә алмыйм, нигә гашыйк булалар кара кашка,
Шуннан матур юк микәнни һич тә башка?
Кара каштан нинди мәгънә чыгар икән,
Булмаса гакыл, мәгънә, фикер башта?

Ни өчендер бик мактаулы кызыл ирен.
Кызыл ирен гашыйк итә кызын, ирен.
Кызыл ирен булуда ни мәгънә бар,
Булмаганда макталырлык башка җирең?

Кызларда мактала кечкенә авыз,
Үзе була күп зур авызлыдан явыз.
Теләсә, булсын авызың алап кадәр,
Бул син аңлы, шуның белән башкадан уз.

Авызың ярар, кечкенә булса тамак,
«Бар китер!» дип тормасаң, ирең талап;
Бик киң булса тамагың әгәр синең,
Ул вакытта инде ирнең эше харап.

Мактаулы, имеш, тагы чәчнең озынлыгы,
Чәч кушалар озын итү өчен буны;
Әллә ул нык тотарга дилбегәме?
Хатыннар башлаганда бик нык дулый.

Мактаулы, ди, аяк булу бик кечкенә,
Калош номеры булсын, имеш, тик өч кенә.
Минемчә, хатыннарның матуры шул:
Җөдәтмиче булышса, иренә бирсә көч кенә.

## БЕТМӘДЕ ӘЛЕ

Бетмәде әле, ирләр дә бик шатланмасын,
«Бик шәп мин», – дип, муенга нык атланмасын,
Тикшерәбез бу урында аларның да
Җөгәннәрен, камытларын, ат-арбасын.

Ир дә шулай мактаулы – матур булса,
Гакыллы, фикерле, батыр булса,
Җил-яңгыр тиермәсә хатынына,
Аның өчен һәрвакытта чатыр булса.

Ни мәгънә бар булуда башың такыр,
Эчендә миең булса чокыр-чакыр?
Мәгънәсез баш никадәр зур булса да,
Уты-суы булмаган бер дала-кыр.

Белмәгәннәр хатыннарын иптәш диеп,
Теләүчеләр хатын торганны баш иеп,
Йөрмәсеннәр үзләрен ир хисаплап,
Йөрү белән башларына бүрек киеп.

Күп мәгънә юк үстерүдә сакал-мыек,
Башыңда булса әгәр акыл сыек;
Аякларың бик туры йөрсәләр дә,
Фикерләрең атласа кыек-мыек.

Ир дигәч тә, хатынга ул түрә түгел,
Дөрест сүз бу, гәрчә аять, сүрә түгел.
Кирәк түгел тел белән сөйләргә дә,
Бу сүзләрнең дөрестлеген күрә күңел.

## ХАЛЫК ҖЫРЫНЧА

Аклы шәлең аклырак,
Зәңгәр шәлең затлырак,
Шәлләр сайлап яткан була,
Шәл синнән кыйбатлырак.
    Йөз мең сум тора.

Мәдрәсә почмагында,
Ут яна учагында,
Үлсәм, шәһид китәр идем
Зур күмәч кочагында.
    Насыйб түгел, күрәсең.

Ак Иделне кичкәндә,
Ишкәк сынды ишкәндә,
Үзем җылыйм, үзем җырлыйм,
Акмай искә төшкәндә.
    Хәзер җылкы мае төшсә дә шулай.

Ак Иделдә алты басма,
Чыга алмадым берсеннән,
Махорка тартасы килә,
Чыгасы юк исемнән.
    Рассыпной булса да ярый.

Ятыйм микән, йоклыйм микән,
Кермәс микән төшемә,
Каймак ашасы бик килә,
Ник төшердем исемә.
    Каймак тагын, сөт, диген, ичмаса.

Сандугачлар су ташый,
Кайда икән су башы,
Тәмле аш белән сыйлаучының
Хозыр булсын юлдашы.
    Урыны җәннәттә булсын!

Тәрәзәңне ачып куй,
Кояш төшсен түтәлгә.
Күзем төшсә, күңлем төшми
Ак күмәчтән бүтәнгә.
    Шуны гына сөям.

Алтын тарак кулымда,
Озын чәчем тарыймын,
Ак күмәч искә төшкәндә,
Тулган айга карыймын.
    Күмәч айдан матур.

Алма төйнәгән ак яулык
Зур булса да, шәл түгел,
Кабарып торган сумса өчен
Ни бирсәң дә жәл түгел.
    Әнә алсыннар ничә йөзне.

Чын чынаяк өстендә
Шикәр микән, тоз микән,
Юкка гына нәфсем төште,
Катып калган боз икән.
    Ачуташ та түгел, ичмаса.

Батинкәләр кыйбат булгач,
Читек кидек каюлы,
Ашарга тәмле булмагач,
Матур йөз дә кайгылы.
    Борыны салынган.

Иртә торып битем югач,
Барып карыйм көзгегә,
Көзгеләрдә тик күренә
Шиңгән ябык йөз генә.
    Шәлперәеп төшкән.

Безнең урам киң урам,
Җидегә бүләрдәй булам,
Тәмле ашлар искә төшкәч,
Җыглып үләрдәй булам.
    Үлсәң дә читен, күмүе кыйбат.

Чәй эчәсез үзеңез,
Тәрәзәдә күзеңез,
Дошман беткәч, бар да булыр,
    Тик шуңарчы түзеңез!

## ТӘМЛЕ НИГЪМӘТЛӘР ӨСТӘЛЕ

(*«Матур яр» көенә*)

Дөньяда иң тәмле нәрсә, тәмле нәрсә –
Кытайски чәй белән, чәй белән
Шикәр, бал, манпаси –
шулар белән сезгә сый.

Бу бик тәмле түгел әле, түгел әле.
Аннан тәмлене беләм, мин беләм:
Кәләвә, шикалад –
шулар белән сыйлап бак.

Аннан тәмле нәрсә юкмы, нәрсә юкмы?!
Сөйләп торасың юкны, син юкны:
Кәнфит һәм мармалад –
суыр аузың боргалап.

Ашап караганың юктыр синең, юктыр
Кырымски кампутны, кампутны!
Бергамут, апилсин –
шуны искә төшер син.

Какау эчсәң сөт белән, сөт белән,
Эченә шикәр катып, һай, катып,
Манпаси, йөзе алсу –
авызымнан килә су.

Куе сөт белән кофи, һай, кофи!
Торырсың хәйран калып, шаккатып,
Син тәмле, һай, кофи –
ачылып китә йокы.

---

Бергамут (*бергамот*) – баллы сусыл груша.

Аппак оннан гөбәдия, гөбәдия!
Эче тулы һәм дөге, һәм дөге,
          Өстләре җимешле –
                    ашап җибәрсәң нишли.

Сөт өстендә кызыл кесәл, кызыл кесәл!
Нәкъ кызыл якут күге, һай, күге.
          Кесәле, кесәле,
                    кашык белән кис әле.

Аш артыннан китерелсә, китерелсә
Виноград, карбыз, кавын, һай, кавын!
          Туганкай, син тукта,
                    тәменнән телең йотма.

Шул кадәре җитеп торыр, җитеп торыр,
Ашадың соң беркавым, беркавым;
          Алмалар һәм дуле булмады инде
                    бу юлы!

* * *

Без кол идек бай кулында,
Богау, зынҗырлар – муенда;
Зинданнарда чери идек
Хак сүз, тугърылык юлында.

Халык өчен тырышканга
Батырдылар безне канга;
Астылар да, кистеләр дә,
Салдылар кара зинданга.

Без ишеттек халык моңын,
Без һәм күрдек хаклык югын;
Залим патша, залим түрә
Атты безгә ачу угын.

Үтерттеләр без ачларны
Яллап куеп палачларны;
Суыкларда җәфа чиктек,
Кора алмыйча салашларны.

Ашадык без хәсрәт уты,
Булмады һич татлы йокы;
Дөнья иде кайгы йорты,
Чүп идек без, тирес корты.

Ачлыктан ана шешенгән,
Гөл күк бала йөзе шиңгән;
Ач ананың сөтен имгән
Бөтен йөзләр кара көйгән...

---

Зынҗыр – чылбыр.

Килде көннәр, кипте күлләр,
Сарай бакчасында – гөлләр;
Китте халыкның өстеннән
Күңелсез кара төтеннәр.

Җимердек без тәхетләрен,
Казыдык без ләхетләрен;
Янды тәхет, китте төтен,
Туды бүгенге якты көн.

Эшче куллары сындырды
Тәхет һәм алтын таҗларны;
Кидерде һәм дә туйдырды
Фәкыйрь һәм дә мохтаҗларны.

Капиталның нигезләре
Черде, калмады эзләре;
Ләхет туфраклары белән
Туйсын инде ач күзләре.

## ВИЛЬҺЕЛМ ТӘХЕТЕННӘН ТӨШТЕ

«Башында – таҗ, астында тәхет
Иде, бүген сарай ләхет
Булды, очты башыңнан бәхет», –
Диде Вильһелмгә һөд-һөд[1].

Нигезе адәм сөягеннән,
Эшче кулы сөяленнән
Күккә күтәрелгән сарай
Янды – тузан күтәрелде көленнән.

Алтын таҗлар бер-бер артлы
Оча баштан, тәхет шартлый;
Бөтен дөнья эшчеләре
Алга зур адымнар атлый.

Богауларны киертергә,
Теләгәнчә биетергә
Уйлаган шаһлар
Киде үзләре коршаулар.

## КАПИТАЛ ТОЗАГЫНДА

Капитал дөньяны изде,
Кол итәргә тели безне;
Тешләрен ыржайта, безгә
Бәйләнергә юллар эзли.

Бетте Кырым, бетте Кавказ,
Бетте Җәзаир һәм дә Фас;
Бар җирне дә таладылар,
Кул тимәгән җир калды аз.

Бетте шулай Төркиясе,
Коллыкка төште иясе;
Белмәгәндер бар икәнен
Хурлык камытын киясе.

Гаҗәмстан да Һиндстан,
Шулай ук һәм Гарәбстан
Көеп бара, бетеп бара,
Элек иде бар да бөстан.

Капиталның тозаклары,
Дәхи коллык йозаклары
Харап итте бөтен җирне,
Калмады һич йөз аклары.

Килер бер көн, бетәр бу төн,
Капитал коллары бөтен;
Харап булыр байлыклары,
Очар бар да булып төтен.

---

Җ ә з а и р – Алжир.
Ф а с – Марокко.
Г а җ ә м с т а н – Иран.
Д ә х и – янә.

## ТУФАН

Кузгалырга тора бөтен дөнья эшчеләре
Сулдан искән җил белән;
Итәрбез төсле тора киләчәк бәйрәмнәрне
Бөтен дөнья, бөтен ил белән.

Кузгалыр шимальнең ачы җилләре тиздән,
Басып китәр дөньяны сил белән;
Бу җил, бу туфанны каршы алыр капитал
Иенке баш, бөгелгән бил белән.

Бөтен дөнья тәхетләрен какшатыр җил,
Китәр Африкага да Нил белән.
Басып китәр Американы да ул туфан,
Шулай булачагын мин беләм.

Күтәрелер Англиянең эшче халкы да,
Туктата алмаслар аларны дим белән.
Баш күтәрер Италиянең гаскәре дә,
Куркыта алмаслар аларны дин белән.

Аңлады инде хәзер һәрбер халык
Бу сугышның чыкканын дингидән.

---

Шималь – төньяк.
Сил – көчле су агымы, ташу.
Дим – үгет.
Динги (*деньги*) – акча.

## ӘСИР МОҢЫ

Тоткынлыкта күп йөрдек без,
Хурлыкларны күп күрдек без;
Ачлыклардан җәфа чиктек,
Күрә алмадык һич көләр йөз.

Авыр йөкләр тарттырдылар,
Салкын җирдә яткырдылар:
Аз гына шикаять итсәк,
Һич рәхимсез аттырдылар.

Мөмкин булмады яшәргә,
Бирмәделәр һич ашарга;
Ачлыктан үлмәс өчен дип,
Күп кеше ашады карга.

Ачлыктан күпләр шешенде.
Эшләп булмагач эшеңне,
«Ялкау сез, эшләмисез», – дип,
Аркага камчы төшерде.

Өст-башлар булды ялангач –
Тетелгәч кием, талангач;
Ашаган ашы туйдырмый,
Тамаклар һаман булды ач.

Ачлыктан билләр бөгелде,
Күзләрдә яшьләр түгелде;
Шундый михнәтләрне күргән
Иптәшеңез без түгелме?

---

Ш и к а я т ь – зар, жалоба.

Сез – илдә калган туганнар –
Бар да бәхетле булганнар;
Ирек алган, бәхет алган,
Залимнәрне дә куганнар.

Көне-төне без зар кылдык,
Кайтырга интизар булдык;
Һичбер хәбәр ала алмадык,
Туган илләрне сагындык.

Сугыш беткәч, бер көннәрне
Күрәбез, диеп, илләрне,
Шатланышып кайткан идек –
Дошман алган ул җирләрне.

Тагын калдык ят илләрдә,
Турая алмый билләр дә;
Тагын насыйб икән йөрү
Калтырап ачы җилләрдә!

## БЕЗНЕҢ ФАЙДА

Инкыйлаблар баш күтәрсә кайда гына –
Һәммәсе дә безнең өчен файда гына;
Бер елда да табылмаслык максудымыз
Хасил булыр, һичшиксез, айда гына.

Инкыйлабка чумар дөнья берничә айда, –
Франция, Италия һәм Кытай да;
Булмаса да иптәш кытлыгы болай да,
Яңа иптәш табылачак һәм Дунайда.

Бүген бездә баш күтәрсә, иртән – сездә,
Һәр җирдә дә кузгалыр, калмас көзгә.
Бу хәлләргә ничек итеп шатланмассың,
Дөньяда күбәя бит иптәш безгә!

Кайчан гына кузгалыр Һиндстан да,
Хәбәр көтәм, түзә алмыйча, сез дустан да.
Иркен сулап яшәргә һәркем тели
Ирекле, яхшы, якты, киң бөстанда.

Ау тотарга теләүче алтын кармак белән
Калып бара санарлык бармак белән;
Алар да җиңлеп бара бер-бер артлы
Сибириядә сугышканда ярмак белән.

---

Инкыйлаб – революция.
Ярмак – акча (капитал); яра торган нәрсә, кылыч булуы да ихтимал.

## НӘСЕР

Усал булсаң – асарлар,
Юаш булсаң – басарлар,
Уртача булсаң – хан ясарлар.
Уртача булып булмый,
Чөнки заманы түгел.
Әллә кайларга, гали күкләргә
Ашарга тели күңел.
Юаш та булып булмый,
Чөнки аяк астында
Тапталырга күңелем күнми.
Усал да булып булмый,
Анысына күңелем тулмый.
Инде мин нишлим?
«Нишлим?» дим дә, тик терсәгемне тешлим.
Ләкин ачысыннан яна йөрәк,
Котылырга нинди булса да бер юл кирәк.
Булдым ярлы, киендем юклы-барлы,
Ашарга да юк,
Булганым юк һич тук.
Тырыштым үлмәскә,
Кешедән ким көн күрмәскә.
Ләкин һаман да булмый бит җиңеп,
Капитал эшләтә мине көн-төн җигеп.
Тик йөрим хәсрәт чигеп,
Иям башны, тартам йөкне,
Дөнья һаман да канәгать кылмый,
Өстемә төягәннән төйи бара
Күтәрә алмаслык авыр йөкне.
Бу дөнья иде – капитал дөньясы,
Ул һәрбер җан иясен кол ясый,
Ул – бөтен каһәр һәм ләгънәтләр оясы...
Һи, барсын – кадалсын дөньясы!
Юкмыни миндә көч,
Ала алмаммыни үч,

---

Гали – бөек.

Һаман да шулай канымны эчәрмени
Ул рәхимсез үрмәкүч?
Мин шулай чебенмени?
Үземнең көчемне дә күрсәтә алмаслык җебенмени?
Тор аякка!
Кара як-якка!
Торма өркеп!
Ташла капитал тузаннарын өстеңнән селкеп!
Берзаман шундый уй белән
Эшче халык, берүзе генә түгел,
Бөтен мәмләкәт, бөтен өй белән,
Басты нык итеп аякка,
Селтәп ташлады бөтен капитал дөньясын як-якка.
Капитал дөньясы җимерелде, ялкынланды,
Бөтен дөньяны чолгап алды кызыл ут, төтен.
Ачылды, шартлады капитал казаннары,
Чыкты, күтәрелде бөтен дөнья йөзенә пар.
Эшче халык баш күтәрде, түзә алмады,
Кан эчүче капиталистлар өчен
Киң дөнья йөзләре булды тар.
Буннан нәкъ ... ел элек[1] иде,
Эшче халык үзенең тимер киемен киде
Дә баш күтәреп чыкты дөньяга:
Капитал эш каршында башын иде.
Җимерде капитал дөньясын,
Инде һәркем аңласын
Эшче халыкның дустын, –
Хозырын, Ильясын[2].
Ялтырады дөньяда кызыл байрак,
Саргайды да коелды
Капитал дигән сары яфрак.
Күкләрне күкрәтеп,
Җирләрне тетрәтеп
Һөҗүм итте эшче дөньясы.
Таралды, җимерелде каһәр төшкән
Капитал – коллык оясы.
Булды бөтен халык барысы да игез,
Һәммә халык барысы да тигез.
Күрәсеңме син, иптәш, бу көннең нурын,
Изелгән эшче халык бар богауларын ташлап,
... нче ел инде, тота беренче урын!

---

Җ е б е н – булдыксыз, җебегән.

## КЫЗЫЛ ФРОНТТА

Окопта качып ята,
Яткан җиреннән ата,
Ләкин белми ул бичара
Эше булганын хата.

Ул үзе дә безнең күк,
Бала-чагалары күп,
Бер крәстиән баласы,
Кол була бит үзе үк.

Ялланып комсыз байга,
Гөнаһлы булып Ходайга,
Безгә каршы килү белән
Төкерә якты айга.

Комсыз байларны яклап,
Алар байлыгын саклап,
Акча өчен үз кардәшен
Ята мискин тураклап.

Эшче килә эшчегә,
Бай үзе артка чигә;
Бай байлыгын саклар өчен
Каршы киләсең нигә?

Кардәшем, син күзең ач:
Йортта балаларың ач,
Йөрмә байның малын саклап,
Аклар ягыннан тиз кач.

Балаң ята тилмереп,
Син йөрисең тилереп,
Йөрмә аклар, байлар яклы –
Бетсен бар да тик эреп.

Хуҗа булсалар аклар,
Алар байларны яклар,
Байлар хакларын хаклар,
Сине эт итеп тураклар.

Тагын җигәр туратлар,
Салыр зур ташпулатлар,
Алар файдасына йөрсәк,
Без булырбыз дураклар.

Куяр үзеңне кол итеп
Йә хатыныңны тол итеп,
Җиңсә, түләүләр салырлар
Безнең өсткә мул итеп.

Бай тик ята, бел әле,
Авыртмый ак беләге,
Барыбызны да кол итү –
Союзниклар теләге.

Туган, шуны син аңла:
Атла аягың алга,
Аклар сафында йөрмә
Кызыгып канлы малга!

## БАРЫ ДА КАЧА

Нишләргә икән, акча белән дустлык китте,
Кесәмнең төпләре тәмам кипте?
Корсакның да ачыгуы тәмам җитте,
Болай барса, эшләр түгел минем ипле.

Кайдан гына табарга соң җиңел хезмәт?
Хәзрәт миннән күргән иде бик күп хөрмәт.
Киңәш сорап карыйм дип ничә бардым,
Насыйб булган юк әле йөзен күрмәк.

Киңәш сорап баргалыйм ишанга да,
Ул да шул, кесә төбе бушаганга,
Файдалы киңәшләрне бирә алмый,
Ахры, бик шәп түгелдер эш анда да.

Азайгандыр аның да төшемнәре,
Сәҗдәгә китәр төсле түшәмнәре;
Йортының эчләрен кара баскан,
Бәхтенең якты яна алмый шәмнәре.

Борынгыдан килгән якын дустларым да,
Күптәнге «знаком» бай русларым да
Танымаска салынганнар һәммәсе дә –
Барган идем бер көн әле постларында.

Барсына да дуст икән акча гына,
Ул булмагач, бары да яннан кача гына;
Электә абыстайлар кардәш иде,
Кара көндә алары да кодача гына.

---

Пост – христианнарда ураза вакыты.

## ТЕЛӘК

Бетсен шул инглизләр,
Калмасын сары йөзләр!
Бетсә алар хуҗалыгы,
Ирек эшләре тизләр.

Бетсен сары йөз – алтын,
Кол итеп дөнья халкын
Тормасын! Ул яшәгәндә
Ирек һич ала алмас тын.

Булмасын хуҗа акча,
Булсын җир йөзе бакча!
Булса дустлык һәм тигезлек,
Ул иблис аннан кача.

Бөтен дөнья бертигез
Булсын, корылсын нигез;
Ирек, кардәшлек юлында
Һәр кеше булсын игез!

Һәммәсе дә бер калеб-
тә яратылган халык,
Алда бармасын берсе дә,
Башкалар артта калып!

---

Калеб – күңел, йөрәк.

* * *

Яңгыратып әйтсә дә ирек азаны,
Булмады тыңлаучылар, ишеттеләр бик аз аны.
Буржуйларның шартлады сабыр казаны,
Ни өчен җибәрә, дип, безнең мазаны.
Шартласын, шартласын
Буржуйларның казаны,
Яңгыра, яңгыра
Дөньяга, ирек азаны!
Тик ишетте ул авазны ярлы халык,
Тыңладылар колак салып, хәйран калып;
Киңәйделәр күкрәкләр киң сулу алып,
Гүя киң диңгезгә чумган иректе балык.
Шартласын, шартласын,
Ул гына аңар аз әле,
Яңгыра, яңгыра
Дөньяга, ирек азаны!
Ачып күзләрен якты дөньяга,
Якты инкыйлаб утларын яга
Башлады халык. Ирек нурлары
Балкып дөньяга, башлый нур ага.
Яктырсын, яктырсын
Дөньяга ирек нурлары,
Яңгыра, яңгыра
Дөньяга, ирек җырлары!
Бөтен халыклар, яшь һәм карт ага –
Бары да, саф булып, дошманга таба
Китте сугышка, җаннарын куеп
Эшче ирке өчен барсын картага.
Атласын, атласын
Алга Совет гаскәре,
Яңгыра, яңгыра
Дөньяга, ирек җырлары!

---

Маза – тынычлык.

Җиңеп дошманны, түгеп күп канны,
Дошман өстенә кубарып туфанны,
Үзенә – ирлек, халкына – ирек,
Иленә шөһрәт, мәртәбә алды.
　　　　Кубарсын, кубарсын
　　　　Дошманга зур туфанны,
　　　　Кайтмасын, кайтмасын
　　　　Җиңмичә һич дошманны!
Түгеп күп көчен, үз халкы өчен,
Дошманнан алып халкының үчен,
Тырышып һаман да – иртәсен, кичен –
Җәннәт ясады мәмләкәт эчен.
　　　　Ясасын, ясасын,
　　　　Җәннәт итсен дөньяны,
　　　　Таралсын, таралсын
　　　　Бөтен дөньяга даны!
Куерып төтен, булгач дөнья төн,
Бар эшче халык һәммәсе бөтен,
Бергә тырышып, эшкә керешеп,
Тудыра безгә якты, нурлы көн.
　　　　Яктырсын, яктырсын,
　　　　Чәчсен ирек нурлары,
　　　　Яңгыра, яңгыра
　　　　Дөньяга, ирек җырлары!
Якты көн алда, җиңү – коралда,
Күрәсеңме, иптәш, бәхет тора алда.
Халык бәхте өчен коралны ал да,
Үз бәхтең өчен, әйдә, син алга!
　　　　Якты көн, якты көн,
　　　　Бәхетең тора алда,
　　　　Ireш бәхеткә,
　　　　Әйдә син алга!
Ничә йөз еллар коллыкта торган
Залим кулында без татар, туган;
Залим патша, кара йөрәк золымы белән
Ничә гасырлар ул безне буган.
　　　　Дошманын, патшасын –
　　　　Барсын кош-корт ашасын;
　　　　Яшәсен, яшәсен,
　　　　Безнең Совет яшәсен!

## ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Эш уңга барса,
Кылны унга ярса,
Файдалар итеп
Ташпулат салса –
Борын-борын заманнарда
Бу кешегә сокландылар.
Симерттеләр корсакларын,
Кеше өстеннән туклandылар.

Эш артка китсә,
Чишмәләр кипсә,
Ниндидер бәхетсезлек
Берәүгә килсә –
Борын-борын заманнарда
Бу кешедән һәркем качты,
Каршысыннан куар өчен
Байлар ишекләрен ачты.

Тик ятып, берәү
Рәхәттә йөзсә,
Хаҗларга барып,
Дөньялар гизсә –
Борын-борын заманнарда
Бу кеше – бик изгеләрдән,
Гомер буе суырса да
Адәм канын эшчеләрдән.

Тырышып берәү
Көннәр буена,
Кара икмәккә
Көчкә туена.

Борын-борын заманнарда
Бу кеше – зур ялкаулардан,
«Олугъ» дигән кешеләрнең
Һәркайсы качты аңардан.

Ә хәзер ничек? –
Эшләгән кеше
Туйганчы ашый;
Эшләмәгәннәр
Башларын кашый.
Борын-борын заманнарда
Игътибар булган акчага,
Әрәмтамак буржуйларны
Хәзер эләләр матчага.

## АЛГА!

Бер, ике, өч,
Җыеп зур көч,
Дошман башына
Төшер зур чүкеч!
Мылтыгың ал да,
Батыраеп, алга!
Дошман килмәсен,
Син йоклап калма!
Атлап нык адым,
Әйдә алга – «шагом»!
Бетер дошманны
Тормаслык тагын!
Нык булсын йөрәк,
Таралмасын рәт,
Кызыл гаскәрдә –
Безнең нык терәк!
Авыр булса да,
Көрәш һәм чыда;
Дошманнар булсын
Җаныңнан җода!
Булыр якты көн,
Дөньялар иркен,
Килер бәйрәмнәр
Безгә дә беркөн.
Кемгә кадерле
Яктылык, ирек,
Саклар ул аны
Күкрәк киереп.
Иптәш, әйдә алга!
Алгы мәйданга!
Безнең исемнәр
Китсеннәр данга!

---

Җаныңнан җода – «җаныңнан аерылсын» мәгънәсендә.

## ТАБЫШМАКЛАР

Мин сезгә табышмаклар әйтәм, сез шуларны табыңыз,
Ә таба алмаганнарыңыз, тик торып, аузыңызны ябыңыз.
Менә:
– Киң, үзе җыерылган, иске читек балтыры күк
сыерылган,
Ә электә мичкә күк җуан булган, йә, әйт әле,
бу ни булыр икән, туган?
Әйтмисезме? Әйтмәсәңез мин бик ялынмам тагы.
Ни булсын, ашарга азайганлыктан шиңгән бай корсагы.
Менә тагы:
– Ал иде, күк иде, кызыл иде, сары иде,
Яшел иде, зәңгәр иде, нәкъ фирәзә;
Бөтен иде, нык иде, ә хәзер –
Ачылган төрле якларыннан тәрәзә,
Йә, әйтеңез инде, бу нәрсә?
Әллә үзем әйтеп биримме яисә?
Билгеле инде, ни булсын, түгел солдат итеге.
Бәлки, абыстайларның электә матур каюлы булган
пол-озын читеге.
Башта булган башта, ялтыраган колакта,
Төрле төстә булган үзе – яшел дә, кызыл да, ак та.
Бер бездә, бер сездә генә түгел, һәр якта.
Күмгәннәр, яшергәннәр ул нәрсәләрне аулакка,
Бу ни булыр икән, туган, кем алай яшереп куйган?
Кем белә, бәлки, ул аны күммәгән, яшермәгән,
төшереп җуйган.
Юк, белмәдеңез, байбикә яшереп куйган энҗе, мәрҗән,
якутын,
Канфисковать итәбез дип Совет алганга котын.
[...]

---

П о л (*половина*) – ярым.

## КОРДЫ, БАЛАМ, БУ КАЛА

(*«Корсын, балам» көенә*)

Корды, балам, бу кала,
Эч ачлыктан бутала;
Рәхәт иде шул сала,
Кайтып җирең сукала.

Корсаклар иде кибән,
Шәп иде кием кигән;
Хәзер инде бар нәрсәм дә
Өтәләнгән һәм көйгән.

Йортларым иде биек,
Йөрмәдем башым иеп;
Хәзер йөрим тәмам көеп,
Солдат шинеле киеп.

Өст-баш иде ничә кат,
Күңелләрем иде шат;
Корсак киереп йөри идем,
Җигеп чыгып юрга ат.

Элек атны алдылар,
Кантрибутсия салдылар;
Шулай итеп безнең байлар
Кара җәяү калдылар.

Колак кактык кибеттән,
Калада рәтләр беткән;
Кайтам авылга, йөргәнче
Ярлы булып бире эттән.

---

Сала – авыл.

## АК БӨРКӘНЧЕК

(*Михайловтан*[1])

Хурлыклы үлемгә мәхкүм булып
Ята богау эчендә яшь җегет*;
Яшь гомерен ул уздырган иде
Кысылган халыкны коткару юлында йөреп.
Ул саный үзен коллардан да көчсез бер кол итеп,
Азатлык көрәшендә әсир төшкән,
Шуңар аның күңле китек.
Дошманнары хөкем иткәннәр аны асарга,
Ул әле бик яшь, тик килә егерменче яшенә җитеп.
Шул яшендә туры килә дөньяны мәңге ташларга.
Кем белә,
Ул никадәр кадерле җегет булгандыр
матур ук туташларга.
Үлү аның өчен куркыныч түгел,
ул аны батыр каршы алыр,
Тик кызганыч көрәшне ташлау –
өлгереп җитмәгән иде башларга.
Үлем берни түгел, тик начар аның хурлыгы,
Беленмәү халыкка аның хезмәтенең зурлыгы.
Аның яшь, ялкынлы йөрәге тели күрергә
Тишелеп чыкканын чәчкән ирек орлыгы.
Килде актык мәртәбә күрешергә газиз анасы,
Иртән халык алдында асылачагын белеп кадерле баласы.
Белсә дә халык ирке өчен үләчәген баласының,
Килә иде газиз баласын җуатып каласы.
Тели ана халык өчен шәһид булачак угълының
батырлыгын,
Актык сулуында да югалтырга теләми аның матурлыгын.
Батырлык белән бизәп, актык сулуларын тели ул
Арттырырга, тели угълының кадере зурлыгын.

---

* Авторда «җегет», «егет» дип ике төрле языла.
Мәхкүм – хөкем ителгән кеше.
Шәһид булу – изге эш өчен үлү.

Теләп угълының китүен дөньядан зур дан белән,
Үлемне шат каршы алдырырга тели ялган белән.
«Кайгырма, – ди, – угълым, мин сине кичертермен,
Гафу сорап барырмын иртәгә таң белән.
Син ышан, угълым, тик минем сүземә,
Сәясәт мәйданында күтәрелеп кара минем күземә.
Актык минутыңда гафу ителергә дип вәгъдә алсам,
Ак бөркәнчек ябып чыгармын йөземә».
Тынычланып җегет шундый вәгъдәләрдән,
Кайгыларын онытып, тыныч йоклады;
Тик беренче мәртәбә зиндан гомерендә
Кайгы, хәсрәт агуын йотмады.
Татлы йокы белән яшь җегетнең йөзе нурланды,
Өмидсезлек белән куркак булуга яшь җан күңле
хурланды,
Анасы үтенүе белән гафу ителәчәген уйлап,
Киләчәктә яшәү өмете зурланды.
Иртән кызыл кояш нурланган, кызулыгы битне пешерә,
Җегет килә сәясәт мәйданына, тирә-якка күзен төшерә.
Анасы килгән, ак бөркәнчекне башына япкан,
Ышана җегет яшәвенә, төндә күргән татлы төшенә.
Нурлана күзе, шатлана йөзе, арта яшәүгә иманы,
Матур чәчәкләр белән бизәлгән, якты итеп күрә дөньяны.
Алдана тормыш хыялына яшь җегет,
Дөньядан батыр китсен өчен, анасы алдый аны.
Җәллад бугазына киерткәндә дә богауны,
Җегет каушамый, илтифатсыз каршы ала аны,
Актык минутында да шундый шат булу белән
Җегет хәйран калдыра дөньяны.

Актык минут, актык сулу... хаким асарга кул изәде...
Каушамый җегет, анасына карап, алдана,
һаман шатлык сизә әле.
Бер секундта җегет гәүдәсе һавада тирбәнде,
Җылмайган йөзе белән үлемен бизәде.
Тегендә ана һуштан китте, булды дивана,
Бердәнбер угълын югалту нинди авыр хәсрәт аңа.
Шулай да халык өчен шат йөз белән үлемне каршы алу –
Угълы өчен зур шәрәф – хурлыкта китмәде дөньядан бала.

---

Сәясәт мәйданы – «җәза урыны» мәгънәсендә.
Җәллад – палач.
Шәрәф – дәрәҗә.

## КЫЗ БЕЛӘН ҖЕГЕТ

Җ е г е т

Җегет кызны сайласын,
Ялкау кызны алмасын.

К ы з

Ялкау, летун егетләргә
Кыз кияүгә бармасын.

И к е с е  б е р г ә

Кыз жегетне, җегет кызны
бик яхшылап сайласын. } (*2 тапкыр*)

Җ е г е т

Җегет сөя матур кызның
Бит уртасы алмасын.

К ы з

Кызлар сайлый җегетләрнең
Булдыклысын, алдасын.

И к е с е  б е р г ә

Ялкау җегет, ялкау кызлар
тик бер-берсен алдасын. } (*2 тапкыр*)

Җ е г е т

Кызлар кия калфагын,
Җегет кия балдагын.

К ы з

Кызлар сөя җегетләрнең
Алгы сафта барганын.

Икесе бергә

Булдыклы алыр алдасын,
Һичкем артка калмасын. } (*2 тапкыр*)

Җегет

Кызлар кия алканы,
Яхшы җегет мал таный.

Кыз

Булдыклы кыз, эшлекле кыз
Һичбер вакыт алдамый.

Икесе бергә

Алдаганнар-җулдаганнар
алмасын да бармасын. } (*2 тапкыр*)

Җегет

Кыз мактала эш белән,
Түгел энҗе теш белән.

Кыз

Җегетләр дә макталсыннар
Хезмәттә узыш белән.

Икесе бергә

Матурлыкка масайганнар
безгә күзен салмасын. } (*2 тапкыр*)

Җегет

Кыз икән ул – кыз булсын,
Хезмәткә җитез булсын.

Кыз

Уңмаган җегет кирәкми,
Тик күзләре тоз булсын.

Икесе бергә

Ялкау, уңмаган җегет-кыз
ашасын тик салмасын. } (*2 тапкыр*)

## 15 ЕЛ

Моннан унбиш ел элек,
Бүген барсын да булмый ачык белеп,
Тик беләм: эшче халык башын иеп йөри иде,
Ябыгып-җетеп, саргаеп, киптергән күгүк элеп.

Тумыштан ук булдык ярлы,
Киендек юклы-барлы,
Буржуйлар тыгына-тыгына ашаганда,
Без булмадык һаман да икмәккә тук.

Маңлай тирен түгеп тырыштык ач үлмәскә,
Көне-төне тырыштык кешедән ким көн күрмәскә;
Шулай да булмый иде ач тормышны җиңеп,
Капитал эшләтә иде, көн-төн җигеп.

Капиталның алдында эшче халык башын иеп:
«Шулайдыр язмышым, тәкъдирем», – дип,
Эшли бирде уңга-сулга карамыйчы,
Тик йөрде хәсрәт чигеп, янып-көеп.

Ул вакытлар идек башны, тарттык йөкне,
Аркаларда ташыдык уникешәр потлы тюкны;
Вакытсыз, яшьләтә җиргә күмдек
Безнең күк эшче иптәшләрдән күпне.

Туя алмады һаман да капитал – җуан корсак,
Ашый бирде, йота бирде, никадәр генә тутырсак;
Өстебезгә төягәннән-төйи барды
Адәм, хайван күтәрә алмаслык авыр йөкне.

Онтылмаган бу заманнар – ул иде капитал дөньясы,
Авыр заман – хәзер килми хәтта аларны уйласы.
Халыкның бар иде Аллага, байларга коллык кыласы,
Баш иде бар эшкә дә буржуазия классы.

Бөтен дөньясы иде аның каһәр, ләгънәтләр оясы!
Киләдер иде барысы[н] да берәм-берәм тотып буасы,
Һәммәсе[н] дә киләдер иде терелә тотып суясы!
Ләкин булмыйдыр иде, чөнки патшалар иде
аларның судьясы!

Бөтен эшче тормышы – эт тормышы иде,
Бөтен дөньясы да – капиталист этләр дөньясы!
Һи! Барсын, кадалсын барлык дөньясы!
Булмады бит шул бирән корсакларның туясы!

Юкмыни миндә көч?
Ала алмаммыни соң мин шулай үч?
Мәңге шулай канымны суырып яшәрмени
Шул канечкеч хәшәрәт үрмәкүч?

Чебенмени мин аңар эшче канын эчертеп торырга?
Миндә юкмыни көч дөньяның рычагын борырга?
Әйдә, иптәш, уян, тор аякка!
Селкеп ташла капитал тузанын, каранып торма як-якка!

Батыр бул! Атла нык басып алга, торма өркеп!
Ташла, ыргыт капитал йөкләрен өстән,
дөньяны дер селкет!
Ташла сындырып, ыргыт капитал богауларын аяктан!
Бер сафтан, бер аяктан һөҗүм итик капиталга –
һәр яктан!

Себер, тузгыт, юк ит капиталның пәрәвезен!
Полный ход җибәр алга революциянең көчле паровозын!
Бир сигнал эшче дөньясына!!! Бир гудок!!!
Юк ит бөтен капитал дөньясын бер сугудук!!!

Берзаман барлык эшче халык шундый уй белән,
Ялгыз түгел – барлык пролетариат, барлык ил белән,
Сикереп торып басты ныклап аякка,
Селтәп, таратып ташлады капитал дөньясын як-якка!

Җимерелде капитал дөньясы, бөтен тирә-ягын ут алды.
Тыпырчынды, тончыкты, куырылды,
Әрле-бирле сугылып бакты, буталды.
Үзе башлап кабызган ут эчендә мәңгегә кадалды да
калды!

Шартлады капитал казаннары, күкләргә күтәрелде
көчле пар.
Канечкеч капитал өчен киң дөнья булды ләхеттән дә тар!
Буннан нәкъ унбиш ел элек эшче халык, көчле тимер
йодрыгын йомарлап,

Үзенең барлык бетмәс-төкәнмәс көчен сынап, барлап,
Бердәм булып дөньяга чыгып, капиталга каршы
баш күтәрде
дә аны яңадан тора алмаслык итеп селтәп алып бәрде.

Ватты, җимерде, көл итте капитал дөньясын!
Барсын бөтендөнья эшче-пролетар халкы аңласын:
Эшче көче – революциянең җиңелмәс көчле ташкыны–
Капиталга ничек итеп таныткан алласын!

Һи! Радио! Тарат, бөтен Җир шарына хәбәрләрне яңгырат!
Ишетмәгән, аңламаган һичбер адәм баласы да калмасын.

Яңгырат бөтен дөнья, Җир шарын, фабрик-заводларын,
шахталарын, Донбассын.
Ишетсеннәр: унбиш ел моннан элек эшченең батыр кулы
Тетеп ташлаганын патшаларын, тәхетләрен,
капиталистларның бәхетләрен;
Казыганын динчеләрнең ләхетләрен, тетрәткәнен
аларның көчле дигән алласын!

Җилберди дөнья йөзендә баш имәс көчле
кызыл байрак ялтырап!
Җыгылды канлы капитал дөньясы эшче аяк астына
калтырап!
Күкләрне күкрәтеп, җирләрне тетрәтеп һөҗүм итте
эшче дөньясы!
Мәңгегә, мәңгегә җимерелде каһәр төшкән капитал –
коллык оясы!

Күрегез, бөтендөнья эшчеләре: бүген дөньяда
Нинди яктылык, нинди нур, нинди зур, якты бәйрәм!
Бөтендөнья эшчеләренә бу унбишенче бәйрәм
бирә шатлык, бирә зур ямь!

# Кушымта

## ХАФИЗӘЛӘМ ИРКӘМ (1)

[...]* Х ә м и д ә. Әбәү, монда беркем дә юк ич! Мин бая ук Шәмкиләргә кергән идем, Хөбби астай: «Безнең Әсма әллә кайчан ук инде киндер тукмаклаган җиргә китте», – диде. Әллә ул туры Сәрбиләргә китте микән, әллә кызлар шунда җыелдылар микән?

М ә р ф у г а. Юк, ул Гайниҗамалларга кергәндер. Гайниҗамал аның дусымы бит. Шуның белән бергә килә торганнардыр. Һи, бу кызларын да әйтер идем инде, үзләре киндер тукмаклыйбыз дип йөргән булалар, ничә көннәрдән бирле сөйләнеп йөриләр, ә үзләре таганнарын асып, әзерләп куймаганнар. Болар соң таганны кайда гына асмакчы булдылар икән, бер дә әзерләгән нәрсәләре күренми. (*Агачтагы бауларны күреп.*) Ә, менә икән, менә элгәкләре, монда әзерләгәннәр икән, асарга бүрәнәсе генә кирәк.

Х ә м и д ә. Менә ич, монда шомартылган бер бүрәнә кисәге бар, шулдыр инде. Шуны асмакчы булганнардыр. Бу бик кыска бит, монда ничә буй гына тукмакларлар икән?

М ә р ф у г а (*карап*). Шул бик җиткән инде. Алты тукмак белән тукмакларлык булгач, ярый. Көне бер бүген генә түгел әле, озаккарак барса, тагы да күңеллерәк булыр. Хәзер инде урак өсте дә, эш вакыты да түгел. Ашлык коела дип ашыгасы юк. Әнә кызлар да җыела башладылар. Кәримә белән Сәгадәт тә килә.

К ә р и м ә белән С ә г а д ә т керәләр.

Х ә м и д ә (*Сәгадәткә*). Гармуныгызны ник алып килмәдегез?

С ә г а д ә т. Минем гармун туганымнарда иде. Беркөн абызәти ачулангач, ватып якмасын дип куркып, аларга илтеп куйган идем. Әле тукмаклый башламаган икәнсез.

Х ә м и д ә. Без нәрсә тукмаклыйк? Безнең тукмак та, киндер дә юк. Без бүген бит Сәрвинең бирнәгә әзерләгән нечкә киндерләрен тукмакларга гына җыелдык.

---

* Кулъязманың (13 ф. 1 тасв. 4 сакл. б.) бер бите юк.

Сәгадәт. Әй, сез ишеттегезме әле, Хафиз белән аның иптәшләре Хафизәне мактап көй чыгарганнар. Көйләре дә, җырлары да бик матур. Хафизәне бөтенләй күккә күтәргәннәр. Бүген монда, кызлар җыелгач, шуны җырламакчы булалар, ди. Җырларын тыңларга түбән оч кызлары белән җегетләре дә җыелмакчы булалар икән. Җырларының берничәсен мин дә отып алдым. Көе бик матур. Мин инде ул көйне гармунда да уйный белә башладым.

Хәмидә. Син юкка гына гармуныңны алып килмәгәнсең, уйнап күрсәткән булыр идең.

Сәгадәт. Җегетләр килгәч уйнарлар әле, ишетербез. Мин алар шикеллүк матур итеп уйный белмим әле. Хафизның Хафизә белән йөргәненә камитит Сираҗи малае Кәримнең бик ачуы килә икән. «Мин нишләсәм дә эшләрмен, Хафизәне Хафиз кулыннан тартып алмый калмам. Әгәр дә шуны Хафиз кулыннан алмасам, бу дөньяда йөрмим дә», – дип әйтә икән, ди.

Хәмидә. Аның шул булыр инде. Фетнә. Байлыгына масайган була да, әллә кем булган булып, борынын чөеп йөргән була. Прсидәтел улы булгач та, үзен әллә кем дип исәпли. Сираҗиның байлыгы бер айлык. Җәгез, инде кызлар да килеп җитәр, без бу бүрәнәне рәтләп, күтәреп асып куя торыйк. Ә, әнә Сәрбиләр дә киләләр. Туганым да килә, әйдәгез, элик.

Нечкәрәк бүрәнәне, бергәләшеп күтәреп, җирдән ярты аршын биеклектә итеп, бауга эләләр. Бер төргәк киндер һәм тукмаклар күтәреп, Сәрби һәм берничә кыз керәләр.

Сәрби. Әле кызлар шулай гынамыни?

Сәгадәт. Тукмак тавышлары ишетелә башлагач җыелырлар әле. Кояш баер вакыт та җитеп килә. Тизрәк кызларга тавыш бирә башларга кирәк. Кайсыберсе әле, бәлки, безнең монда җыеласыбызны да белми торганнардыр.

Хәмидә. Әйдәгез алайса, эшкә башлыйк.

Сәрби. Әйдәгез.

Киндерләрне, җәеп, тукмакларга керешәләр.

Сәгадәт (*бераз тукмаклагач, туктаган арада*). Безнең монда киндерне гел бер генә төрле көй белән тукмаклыйлар. Аны әллә ничә төрле көй белән тукмаклый торган җирләр бар икән. Мин былтыр кодагыйларга әниләр белән кунакка барган җирдә ишетеп кайттым. Ничә тукмак белән тукмаклаганнардыр, анысын белмим. Авылның икенче башында тукмаклыйлар иде, барып карый

алмадым, әмма тавышы еraktan бик моң, бик матур булып ишетелде.

*Яңадан тукмаклый башлыйлар.*

Х ә м и д ә. Кара әле, туганым, кайбер якларда бөтенләй киндер сукмый торган җирләр дә бар икән. Безнең абый әйтә: «Без солдатта хезмәт иткән җирдә киндер бөтенләй юк, – ди, – һәммә кеше ситсә белән җоннан гына киенәләр», – ди.

С ә г а д ә т. Булмый ни, бардыр шул. Киндерне чуарлап суга торган җирләр дә бар икән. Аларның суккан киндерләрен минем күргәнем дә бар. Сарфинкә шикелле вак шакмаклы була. Аннан соң, минем дә базарда күргәнем бар. Әллә кайсы якның марҗалары шундый чуар нәрсә киеп килгәннәр иде. Нәкъ чуар ашъяулык шикелле.

*Ерактан «Хафизәләм» көен җырлаган тавышлар ишетелә, ләкин җырлары аңланмый.*

С ә р б и. Киләләр, киләләр. Теге яңа көйне – «Хафизә» көен җырлыйлар. Көе бик матур икән. Хафизә бу көйне ишетсә, урынында да басып тора алмас, үрле-кырлы сикерер.

С ә г а д ә т. Ишеткәндер инде, бер генә түгел, әллә ничә тапкыр ишеткәндер. Кичә җегетләр җыелышып өй түрләреннән дә җырлап узганнар. Анда әле, Хафизәдән дә бигрәк, Кәрим үрле-кырлы сикерә, ди, бөтенләй кая барып бәрелергә дә белми, ди. Кәрим инде берничә көннән бирле, кем очраса, шуны сыйлап, үзенә ишләр дә җыя башлаган, ди. Әйдәгез, тукмаклыйк әле, тавыш бирик.

*Тукмаклыйлар. Җыр тавышы якынайганнан-якыная бара һәм шушы түбәндәге җырлар ишетелә.*

Олы юлдан атлар чаба,
Ком буранын туздырып,
Хафизәләм иркәм,
аппагым ла,
Ком буранын туздырып.
Матур җегет пар кыз таба,
Йөрми гомер уздырып,
Хафизәләм иркәм,
аппагым ла,
Йөрми гомер уздырып.

Хафизәнең матурлыгы
Тирә-җүнгә дан булган,
Хафизәләм иркәм,
аппагым ла,
Тирә-җүнгә дан булган.
Хафизә кулга эләкмәгәч,
Кәрим күзе кан булган,
Хафизәләм иркәм,
аппагым ла,
Кәрим күзе кан булган.

---

С а р ф и н к ә – тукыма төре.

Хафиз җегет Хафизәне
Тулган айга охшата,
Хафизәләм иркәм,
аппагым ла,
Тулган айга охшата.
Кәрим йөрәк кайгыларын
Яшен түгеп бушата,
Хафизәләм иркәм,
аппагым ла,
Яшен түгеп бушата.

Хафизә озын чәченә
Чәчтәңкәләр тезә икән,
Хафизәләм иркәм,
аппагым ла,
Чәчтәңкәләр тезә икән.
Хафизәнең кайгысына
Кәрим ничек түзә икән?
Хафизәләм иркәм,
аппагым ла,
Кәрим ничек түзә икән?

Егетләр җырлап керәләр.

Хафизәнең ак яулыгын,
Чайкаганда, су алган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Чайкаганда, су алган.
Хафизә күзен салмагач,
Кәрим башы чуалган.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Кәрим башы чуалган.

Нигъмәт. Җәгез, кызларның асыллары, без килгәч кенә нишләп туктадыгыз? Бик матур итеп тыкырдатадыр идегез бит әле. Каравылчы Төхфи бабай шакылдавыгыннан бер дә ким түгел иде.

Хәмидә. Без түгел әле, сез туктадыгыз, Кәримнең борынына бер чиерттегез дә шуның белән эш беттемени?

Нигъмәт. Инеш елгасында су бетмәсә, бездә җыр бетмәс. (*Озын бер кәгазь күрсәтеп.*) Менә ул әле никадәр, ятлап та бетерә алырлык түгел.

Хәмидә. Җә әле, Нигъми абый, бик күңелле икән, тагы җырлагыз әле.

Нигъмәт. Әйдә, менә безгә сез дә кушылып җырлагыз, аннан соң җырлыйбыз.

Кызлар. Җырлагыз, җырла, кушылабыз.

Нигъмәт. Әйдәгез, җегетләр, чибәр кызларның сүзләре җирдә калмасын, җырлыйбызмы калганын?

Җегетләр. Җырлыйбыз, җырлыйбыз, актыгына кадәр. (*Җырлыйлар.*)

Хафизәнең баш яулыгы
Аллы-гөлле буйлы икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Аллы-гөлле буйлы икән.
Хафизә кулдан ычкынгачтын,
Кәрим ниләр уйлый икән?

Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Кәрим ниләр уйлый икән?

Кәрим ниләр уйлый икән,
Утырып үкереп җылый икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Утырып үкереп җылый икән.
Хафизә Хафиз кочагында,
Хафиз куены җылы икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Хафиз куены җылы икән.

Нигъмәт. Җә, күңелегез булдымы инде?

Хәмидә. Рәхмәт сезгә.

Нигъмәт. Без сезнең сүзне тыңладык, инде сез дә безнең сүзне тыңлагыз. Йә, инде матур гына итеп киндерне тукмаклап алыгыз!

Сәгадәт. Ярый, тыңлыйбыз.

Тукмаклый башлыйлар. Җегетләр кайсы чүгәләп, кайсы агачларга сөялеп карап торалар.

Әхми (*бераздан уң якны күрсәтеп*). Җегетләр, җегетләр, әнә Хафиз үзе дә килә. Әйдәгез, җегетләр, җырлап каршы алабыз!

Нигъмәт (*як-якка каранып*). Кая? Ә, менә бу яктан Хафизә дә килә. Әйдәгез, башлагыз!

Күмәк җыр.

Югары очтан берәү килә,
Хафизәнең атлавы.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Хафизәнең атлавы.
Матур җегет, матур кызны
Бик күңелле мактавы.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Бик күңелле мактавы.

Хафизә – кызлар янына, Хафиз җегетләр янына килеп туктыйлар. Хафиз белән Хафизә ымлашып исәнләшәләр.

Хафиз. Исәнмесез, иптәшләр! Сез ни өчен бездән көләсез?

Әхми. Безме? Алла сакласын, без нишләп сездән көлик? Бер дә көлмибез. Әнә анда Кәрим ялчылары бездән көләргә җыенып йөриләр, ди. Чишмә буенда мыскыл итеп такмак, бәет чыгарып яталар, ди. Сиби дә шунда, ди. Кәрим

аларны кичә төн буена бал эчертеп сыйлап чыккан. Без шуны ишеттек тә монда җыелып килдек. Киндер тукмаклаган җиргә алар да килми калмаслар. Әгәр андыймондый мыскыл итә калсалар, без дә аларга бирешмәбез.

Нигъмәт. Җәгез, кызлар, сез нишләп без килгәч кенә киндер тукмаклаудан туктадыгыз? Әйдә тыкырдатыгыз. Мин, сезнең тукмак көенә басып, биеп тә алырмын.

Кызлар җыелып киндер тукмаклый, җегетләр гармун уйный.

*(Ул, бии башлап.)*
Тыкыр, тыкыр, тыкыр, тыкыр,
Кызлар киндер тукмаклый.
Кызлар киндер тукмаганны
Без[нең] китап бик мактый.
*(Биюдә дәвам итеп.)*
Әйдә, кызлар, булышыгыз,
Бергә салыйк сукмакны.
Дуслар шатлыктан кул чаба,
Дошман көя, ух, ах, ди.

Сиби, кереп, яшеренеп тора.

Бие, бие, җегетләр,
Такырайт ындыр табагын,
Бии белмәгән – җырласын,
Кызганмасын тамагын.

Җегетләр белән кызлар бии башлыйлар. Хафиз Хафизә янына килеп, башы белән ымлап, Хафизәне бер читкә алып китә.

Хафиз. Хафизә, сиңа сөйлисе бик күп сүзләр бар. Бүген кич күрешеп сөйләшергә бераз вакыт таба алырсыңмы?

Сиби яшеренгән җиреннән күренмичә генә чыгып, боларның артына яшеренә. Сүзләрен тыңлап тора.

Хафизә. Бүгенгә син сабыр ит инде. Бүген моннан да соң кайтылыр, аның өстенә бүген әни минем монда килүемә дә борчылып калды. Кичә кемнәрдер урамнан безнең көйне җырлап уздылар. Ахрысы, әниләр шуны ишеткәннәрдер. Бүген көн буена миңа ачуланып карап йөрде. Син иртәгә мәзин абзый ясыйгъга азан әйткәч тә, безнең келәт янына кил, шул вакыт мин дә чыгармын, иркенләп сөйләшербез. Ләкин кара аны, сак бул, Кәримнәр сизә күрмәсеннәр, болай да әле ул ачуыннан тиресенә сыя алмыйча йөри. Ярый, бар, инде читкәрәк кит.

Хафиз. Ярый, хәзергә хуш. (*Җегетләр арасына китә.*)

Н и г ъ м ә т. Бии торгач, корсактагы икмәкләр коелып бетте. Тукмак көенә басу күңелле икән. Моннан соң инде бу көйне «Тукмак көе» дип әйтербез. Җәгез, әйдә, кызган юлы кызсын инде.

Еракта җыр һәм гармун тавышы.

Ә х м и. Аһа, җегетләр! Иптәшләр, теге оч җегетләре, ак чабата-ак оеклар, җырлап менеп киләләр. Әгәр безне тешләп җырласалар, карагыз аны, бирешмәгез. Бер урынына ун җавап кайтарырга тырышыгыз.

Н и г ъ м ә т. Тырышырбыз, бирешмәбез. Ачуны китерсәләр, мәми авызларның салма савытларына да менеп төшәрбез.

Җыр тавышы якыная бара.

Ә х м и. Аһа, җегетләр, араларында Кәрим дә бар. Ахры, сыйларга да өлгергәндер, бик болагайланып киләләр.

Н и г ъ м ә т. Болагайлансыннар. Алар болагайлансалар, без уңагайлап җибәрербез.

Ә х м и. Анысы шулаен шулай да, эш зурга китеп бармасын, исерекләр белән сугышып тору яхшы түгел. Әгәр бәйләнә башласалар, китәрбез.

Н и г ъ м ә т. Бер дә курыкмагыз, кара-каршы әйтешмичә китте-митте юк. Кирәк булса, бәргәләшеп тә алырбыз.

К ә р и м  п а р т и я с е (*җырлап кер*ә).

Хафиз киткән ил буена,
Илдән хәер сорарга.
Хафиз бүкән, апара корсак,
Илдән хәер сорарга.

Хафизә балчык эзләп йөри,
Ватык чүлмәк сыларга.
Хафизә бүкән, апара корсак,
Ватык чүлмәк сыларга.

Х ә м и д ә (*Хафизәгә*). Әйдә, Хафизә, без китик моннан тизрәк, күрәсең алар нинди исерекләр.

Х а ф и з ә. Сугыш-фәлән чыгарып, Хафизларны харап итмәсләр микән?

Х ә м и д ә. Син алар өчен кайгырма, Хафизның иптәшләре күп, алар бирешмәсләр. (*Китәргә җыенган кызларны күрсәтеп.*) Әнә, күрәсең, бар кызлар да китеп бетәләр.

Х а ф и з ә. Әйдә.

Китә башлыйлар.

С и б и (*чыгып, Кәримнәр партиясенә кушылып*). Туктагыз, кызлар, кайда качасыз, без аю түгел, ашамабыз.

Х ә м и д ә. Күзле бүкәннәр! Кыйланышлары, җирәнгечләр, бер тиенлек эчеп, егерме тиенлек исергәннәр.

Китәләр.

К ә р и м. Туктагыз әле, туктагыз.

К ә р и м партиясе (*җырлый*).

Хафизәләрнең капкасын
Калмаган, ди, ачасы.
Хафизә лә бүкән, ачык авыз,
Калмаган, ди, ачасы.

Ачык капкаларны күргәч,
Килә ташлап качасы.
Хафизә лә бүкән, ачык авыз,
Килә ташлап качасы.
(*Көләләр.*)

Х а ф и з партиясе (*җырлый*).

Аргы яктан болыт килә,
Яшен яшьни камчылап,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Яшен яшьни камчылап.

Бай баласы Кәрим җылый,
Яше ага тамчылап,
Хафизәбикә эләкмәгәч,
Яше ага тамчылап.

К ә р и м партиясе.

Аргы якның җегетләре,
Авызлары селәгәй.
Хафизә, сөрт авызларын,
Авызлары селәгәй.

Хафиз малай ач бетләре
Йөри булып күләгәй.
Хафизә, кара, күрмисеңме,
Йөри булып күләгәй.

Х а ф и з партиясе.

Кәрим, Кәрим кәрләләргә
Әллә ниләр кирәкми.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Әллә ниләр кирәкми.
Айдай матур Хафизәләр
Кәримнәргә эләкми.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Кәримнәргә эләкми.

Һ ә м м ә с е бердән. Ха-ха-ха!

К ә р и м. Авызыгызны җыеп сөйләгез, малайлар! Юк исә, тешләрегезне җирдән җыеп алырсыз.

Х а ф и з. Күрербез, анда ничек булыр. Әгәр без сезнекен җыйдырсак, үзегез дә хәйран калырсыз.

К ә р и м. Чамалап сөйлә, малай! Кем белән сөйләшкәнеңне белеп сөйләш. (*Иярченнәренә.*) Әйдәгез, урыгыз үзләрен!

Бәргәләш башлана. Д и с ә т н и к л ә р керә.

С о т с к и й. Һай, йөзегез каралар! Караңгы төн эчендә бу нинди тавыш бу! Тотыгыз үзләрен!

Аеклар кача, исерекләр җыгылып кала.
Сотский һәм дисәтник куа китәләр.

С и б и (*кире кайтып*). Кәрим! Кәрим!

К ә р и м (*кире килеп*). Нәрсә, нәрсә бар?

С и б и. Бая мин Хафиз белән Хафизәнең сөйләшкәнен ишеттем. Иртәгә келәтләре артына Хафизга килергә кушты. Үзләрен шунда эләктерербез. [...]*

Х а ф и з (*акрын тавыш белән*).

Тәрәзәнең бусагасы
Бик киң микән, тар микән.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Бик киң микән, тар микән.

Хафизә күк матур ярлар
Бу дөньяда бар микән.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Бу дөньяда бар микән.

Тәрәзәдә ут сүнә дә яңадан яктыра.

Әһә, булды, Хафизә икән. (*Барып тәрәзәне чиертә.*)

Х а ф и з ә (*тәрәзәдән*). Хәзер чыгам. (*Утны кыса. Сакланып кына калиткәдән чыгып.*) Кеше-кара юкмы?

Х а ф и з (*тирә-якны барып карап килеп*). Юк, беркем дә күренми. (*Килә. Хафизәне коча.*)

Х а ф и з ә. Чү, тукта әле. Кичәге көннән бирле бер дә җаным урынында түгел. Кичә без киткәч ниләр булганын бер дә белә алмадым. Кешедән сорашырга да яхшысынмадым. Без китеп, Гобәйләр чатын борылуга, аннан, сезнең яктан, ындыр артыннан, әллә нинди тавыш-гаугалар ишетелде. Әллә нинди сугыш-фәләннәр булмагандыр бит?

Х а ф и з. Юк, әллә ни зур эшләр булмады. Шулай да, әгәр дисәтникләр килеп чыккан булмаса, шактый гына

---

* Бу урында кулъязманың берничә бите төшкән.

зур бәрелешләр дә булып алган булыр иде. Кәримнең иярченнәре, үзең дә күргәнсеңдер, барысы да исерекләр иде. Кәрим, тавыш чыгартыр өчен, аларны юри сыйлаган. Моннан соң инде алар безне тыныч тотмаслар. Безгә ничек тә сак булырга кирәк.

Х а ф и з ә. Ие шул, мин дә шулай дип әйтмәкче идем. Бераз, тавыш-тыннар басылганчы, күрешмирәк, сакланыбрак торсак, ничек булыр иде икән, дим.

Х а ф и з. Анысы шулай. Мин дә шулай уйлыйм. Ләкин без һаман да шушы көйгә генә торсак, Кәрим безгә тынычлык бирмәс.

Х а ф и з ә. Син нишләмәкче буласың соң?

Х а ф и з. Әгәр дә мин җаучы җибәреп карасам, ничек булыр?

Х а ф и з ә. Сынап кара. Ә соң әгәр дә этиләр риза булмасалар, нишләрбез?

Х а ф и з. Ул вакытта да җае табылыр. Моннан качып китәрбез дә икенче бер авылга барып никах укытырбыз. Аннан соң калага барып, бераз вакытка кадәр калада торырбыз. Соңыннан, тавыш-тын басылгач, этиләрең белән килешеп, яңадан авылга кайтып тора башларбыз. Аңарчы, бәлки, күз алдыннан югалып торгач, Кәримнең дә өмиде өзелер.

Х а ф и з ә. Мин алай китәргә куркам шул. Әгәр этиләр рәнҗесәләр, нишләрбез? Йә булмаса, качып киттеләр дип, тоттырсалар, ни итәрбез?

Тирә-якта шәүләләр.

Х а ф и з. Алай иттермәсләр. Без бит никах укытырбыз. Никах укыткач, алай качып киттеләр дип тоттыра алмаслар. (*Як-ягына каранып.*) Минем күземә тегендә, читән буйларында, кемнәрдер йөргән шикелле күренде. Безне сагалап йөрүчеләр-фәләннәр булмасыннар тагы. (*Акрын гына шыпаеп карый.*) Юктыр, ахры, курыкканга куш күренә, диләр.

Х а ф и з ә. Шулай да бит бу бик читен эш. Баштарак, берәр төрле эшкә урнашканчы, көн күрүләре авыр булыр бит? Без бер дә шәһәргә ияләнгән кешеләр дә түгел. Анда барып ничек итеп урнашып тора башларбыз?

Х а ф и з. Анысы шулаен шулай да, ләкин бит шәһәр җирендә бер кеше дә ачтан үлми. Ходайга шөкер әле, минем тазалыгым бар. Мин кулымнан эш килмәслек җегет түгел. Мин бит, бик оста булмасам да, балта эшләрен дә беләм. Анда берәр балта остасына җалланып эшләрмен, һич булмый икән, көнлекче булып, утын ярып

йөрсәм дә, тамагыбызны туйдырырбыз. Шәһәр җирендә эшләгән кешегә эш табыла. Бары тик...

Х а ф и з ә. Кара әле, тегендә минем күземә дә кешеләр үрмәләп йөргән шикелле күренә башлады.

Х а ф и з. Юк, бая миңа да шулай шикелле тоелган иде дә, ахрысы, кеше түгелдер. Киртәнең теге ягында кемнең булса да бозаулары йөри торгандыр.

Х а ф и з ә. Юк, мин әллә нигә бик шикләнәм. Сагалап торучы кешеләр-фәләннәр була күрмәсен. Яхшы вакытта мин кереп китим. Йә мине югалтып, артымнан эзләргә чыга башларлар. Әни әле болай да бик борчылып йөри. Озак торырга туры килмәс. Хәзергә хуш. Иртәгә тагы шушы вакытларда монда килерсең. Шунда иркенләбрәк сөйләшербез.

Х а ф и з. Ярый, алай булса, хәзергә хуш, җаным! (*Җырлый.*)

Бакча ишеген ачып куй,
Кояш төшсен түтәлгә.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Кояш төшсен түтәлгә.

Күзең, күңлеңне төшермә
Хафизыңнан бүтәнгә.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Хафизыңнан бүтәнгә.

Х а ф и з ә. Хуш! (*Җырлый.*)
Кызу кояш кыздырса ла
Бакчадагы түтәлне,
Хафизым иркәм, аппагым ла,
Бакчадагы түтәлне.
Хафизәң тик сине сөя,
Сөйми синнән бүтәнне,
Хафизым иркәм, аппагым ла,
Сөйми синнән бүтәнне.

Хафизәңнең бар уе – син,
Уйнаса да, көлсә дә.
Хафизым иркәм, аппагым ла,
Уйнаса да, көлсә дә.
Хафизәң сине һич онытмас,
Үлсә, гүргә керсә дә,
Хафизым иркәм, аппагым ла,
Үлсә, гүргә керсә дә.

Хуш!

Х а ф и з. Хуш, җаным!

Кочаклашып үбешәләр. Хафизә кереп китә.

Үзем дә белмим, ни өчендер шул Хафизә миңа авылдагы бөтен кызлардан да матуррак күренә. Үзен күргән саен күрәсе килә. Ә күргәннән соң, йөрәкләрем тибә башлый да сөйлисе сүзләремне дә онытып бетерәм. Берни дә сөйли алмый калам. Ах, тагын бер бик кирәкле сүземне әйтәсем калган икән. Тукта әле, үзенә әйтим әле. (*Тәрәзәдән үреләп.*) Хафизә! Хафизә! Ишетми. Әллә өйгә кереп китте микән? Хафизә, Хафизә!

Кәрим, Сиби һәм башка берничә җегет төрлесе төрле яктан йөгерешеп киләләр.

Кәрим. Тотыгыз, тот!

Сиби. Келәт басалар!

Җегетләр (*бердән*). Тотыгыз, тот! Сибегез! Кайда сез? Келәтегезне басалар! Карак бар, карак!

Хафиз качмакчы була. Аны тотып алалар.

Кәрим һәм иптәшләре (*капканы ачып*). Чыгыгыз! Чыгыгыз! Келәтегезне басалар!

Вахид, Хөбби калиткәдән чыгалар. Тирә-яктан берән-сәрән кешеләр җыела башлый.

Вахид. Нәрсә, ни бар?

Сиби. Келәтегезне бастылар.

Хөбби. Ярабби Ходаем, җыеп саклап килгән бодай оным бар иде, харап булдык!

Вахид. Кайда, кем? Кая таба китте?

Җегетләр. Менә тоттык. Кем икәнен белеп булмый. Башын яшерә.

Вахид. Кая дисәтник? Кая староста? Җегетләр, зинһар, җибәрмәгез. Камититкә алып барыйк.

Фазылҗан. Кабыргаларын яхшылап санагыз!

Җегетләр йодрыкларын йомарлап киләләр. Суккалыйлар.

Кәрим. Юк, җегетләр, монда тимәгез. Без, кыйнап, гаепле булмыйк, суд үзе тикшерер.

Вахид. Ие, ие, җегетләр, зинһар, сез булышыгыз. Әйдә, камититкә алып барыйк үзен. Чү, бу Хафиз түгелме соң бу? Һи, яхшыдан яман туган нәрсә!

Хафиз. Валлаһи, Вахид абзый, һичбер гаебем юк. Алар бары тик дошманлык белән генә...

Кәрим. Әйдәгез, әйдә, җегетләр, сөйләтмәгез үзен. Анда баргач, тикшерерләр.

Хафиз. Кара аны, Кәрим! Онытма! Бу эш сиңа бик кыйбатка төшәр!

Кәрим. Күрербез.

Җегетләр Хафизны алып китәләр.

Сиби (*Кәримне читкә тартып*). Шаулама, иптәш, эш пеште! Кыз синеке. Сыеңны гына кызганма.

Кәрим. Аннан эш калмас!

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Тәбәнәк кенә, начар гына, иске генә өй. Түрдә киң сәке. Зур мич. Ике янда тар гына ян сәкеләр. Сәке белән ян сәке алдында өстәл. Өстәл өстендә чынаяклар. Карчык – «әби» самавыр әзерли. Старший белән иптәшләре, капчыкларыннан икмәк чыгарып, ашарга әзерләнәләр.

Старший. Нихәл, әби, тормышлар ничек? Бик авыр түгелме?

Әби. Ходайга шөкер әле, бер көе гомерем итеп киләм. Бер башым да бер үзем. Авыш-төеш китергәләп торам әле шунда.

Старший. Беркемең дә юкмыни?

Әби. Балаларым бар иде дә, барысы да яшьләтә үлеп беттеләр. Соңгы елларга кадәр карт белән икәү генә, менә шулай, калага баручылар, каладан кайтучыларга самаварлар куеп, двор төшереп, көн итеп килгән идек. Узган ел, Алланың рәхмәтендә булсын, картым да вафат булып китте. Берьялгызым калдым. Шулай да Алла рәхмәтеннән ташламый әле. Электән аш-су күргән дуст-ишләр, килгәндә-барганда һаман безгә төшеп, аз-маз ризыклык биреп китәләр. Әллә ни артык эшләр булмаса да, көн уздырырлык булгач, канәгать инде. Самавыр да кайнап чыкты. Билләрем бик авырта, көчем бер дә калмаган. Самавырны үзегез генә өстәлгә алып куймассыз микән?

Старший. Ярар, ярар, әби, мәшәкатьләнмәгез, үзебез алырбыз. Барыгыз әле, самавырны алып китереп куегыз.

Красноармеецларның берсе самавырны өстәлгә куя. Чәй салып, эчәргә керешәләр.

Әйдә, әби, сез дә утырыгыз, чәй эчегез.

Әби. Юк, рәхмәт, сез үзегез генә иркенләп эчегез. Мин, шунда сездән калса, соңыннан берәрне генә эчәрмен. Чәй күп эчү безнең шикелле карчык кешегә бик файдалы түгел. Сез соң нинди чәй эчәсез? Яфрак чәйме?

С т а р ш и й. Юк, әби, яфрак түгел. Төрле җиләкләрдән киптереп ясаган чәй.

Ә б и. Алай булса, берәрне эчеп җибәрим әле.

С т а р ш и й. Әйдә, кил, утыр.

Ә б и. Тукта инде, алай булгач, минем монда бераз сөтем дә бар иде бугай, сөтләп эчегез.

С т а р ш и й. Алай булса, сез безне сөт белән сыйласагыз, без сезне шикәр белән сыйлыйк. (*Бер шакмак шикәр бирә.*)

Ә б и. Без инде шикәрне күптән онытып бетердек. Рәхмәт. (*Ала, ян сәкегә барып утырып, чәй эчә башлый.*) Улларым, сез соң ничек, салдаттан кайтып киләсезмени?

С т а р ш и й. Юк, без эш белән йөрибез.

Ә б и. Нинди эш, әллә иген җыярга чыктыгызмы?

С т а р ш и й. Курыкма, әби, иген җыярга түгел. Башка эш белән.

Ә б и. Юк, курыкмыйм. Мин бит иген игә торган кеше түгел.

С т а р ш и й. Алай икән.

Урамда гармун һәм «Хафизә» көен җырлаган тавышлар.

Болар кемнәр болай җырлап йөриләр? Әллә солдатка китүче яшьләрме?

К а р ч ы к. Юк, тегеләй генә, яшьләр үзара җырлап кына йөриләр.

С т а р ш и й. Ахры, бу яңа көйдер. Минем моңарчы мондый көйне ишеткәнем бер дә хәтеремдә юк.

К а р ч ы к. Яңа көй ул. Монда, безнең авылда, бер Хафизә дигән матур кыз бар. Җегетләрнең, яшь-җилбәзәкләрнең, беләсең инде аларның, бар белгәннәре кыз гына. Аларның дөньяның авырлыкларына бер дә исләре китми. Шул Хафизә дигән кызны ике җегет сөеп йөриләр. Яшьләр шуңар бәет чыгарганнар. Әле менә бер-ике көн элек кенә шул Хафиз дигән җегетне келәт баскан өчен тотып яптылар. Иртәгә суды булачак.

С т а р ш и й. Нинди Хафиз дигән җегетне?

К а р ч ы к. Шул инде, кызны сөеп йөргән җегетне.

С т а р ш и й. Ул шулай начар куллы җегетмени?

К а р ч ы к. Болай үзе бик чибәр, бик акыллы җегет төсле. Тышкы ягыннан карап кына аны кайдан беләсең инде. Бәлки, ярлылыктан аптырагач, шәйтан җилкеткәндер инде.

С т а р ш и й. Ничек соң ул, он-фәлән, ашлык-фәлән урлаганмыни?

К а р ч ы к. Юк, алай аның янында оны-фәләне булма-

ган. Бары тик келәт тәрәзәсеннән керергә теләгәндә генә тотканнар.

Старший. Нинди келәт тәрәзәсеннән?

Карчык. Бая әйттем ич әле, Хафизә дигән матур кыз бар дип, шуларның келәт тәрәзәсеннән.

Старший. Кем белә, бәлки, ул анда урлар өчен килмәгәндер, кыз янына килгәндер?

Карчык. Кем белә, бәлки, шулайдыр. Анысы безгә караңгы. Иртәгә судлары булачак, шунда беленер әле, ләкин тотучылары: «Келәт басарга кергән иде», – диләр икән.

Старший. Аны соң кемнәр тоткан?

Карчык. Шул инде, бая әйткән идем ич әле, икенче бер сөйгән җегете бар дип, шулар тоттырган. Әле бүген кич шул җегет монда безгә иптәшләрен җыеп сыйларга килмәкче булып киткән иде, бәлки, килеп тә җитәрләр инде. Миңа ашарга да әзерләп куярга кушып китте. Ике каз да пешертте. Кайдандыр ике чиләк бал да алып килделәр. Базга төшереп куйдым. Озакламаслар, бәлки, килеп тә җитәрләр инде.

Старший. Алай икән! Әби, син каз дигәч искә төште, синдә бераз ашарлык берәр нәрсә юкмы? Без синә бәясен түләрбез. Үзеңдә булмаса, башка кешедән булса да табып алып кил әле. Маймы, йомыркамы – кайсы булса да ярый. Ит булса, бигрәк яхшы. Мә, менә акчасын да ала кит. Камисар кайткач, аңар да ашарга нәрсә кирәк булыр.

Карчык. Ярый, ярый, күрше-коланнан эзләп карыйм алайса, бәлки, табылыр. Сез соң үзегез генә чыгып алып кермәссез микән?

Старший. Курыкма, әби, без синең әйберләреңә тия торган кеше түгел. Әгәр үзең генә курыксаң, менә бу иптәш тә синең белән барсын. Без бит солдат кеше. Авыл халкының күзенә күренеп, әйбер сорый башласаң, бушлай алмагайлары дип курка башлыйлар. Шуның өчен генә сезгә кушам.

Карчык. Ярый, алай булса, әйдә, күршеләрдән берәрсенә барып карыйк.

Старший. Бар, син, Шакир иптәш, әби белән син бар. Тиз кайтыгыз.

Шакир.<br>Карчык. } Ярар, ярар. (*Чыгалар.*)

Старший. Бу әбинең сөйләгән экиятләре мине гаҗәпләндерә башлады әле. Бу эштә нинди булса да берәр төрле сер булырга кирәк. Минем шул эшне аңлыйсым килә. Мин монда мич башына менеп яшеренеп ятам, ә сез, әби кайткач, берәр сылтау тапкан булып, чыгып китегез. Соңыннан, җегетләр киткәч, кайтып ятарсыз. Җә

булмаса туп-туры ишегалдына, арбага ятарсыз. Бүген көн җылы. Әби кайткач мине сораса: «Йөреп керәм дип чыгып китте», – диярсез. Аның ул җегетләрне сыйлавының нинди булса да берәр мәгънәсе булырга тиеш, ул аларны бушка гына сыйламый торгандыр. Аңладыгызмы, иптәшләр? Әгәр андый-мондый зуррак эш чыкса, камисар кайткач, аңар да белдерербез.

Красноармеецлар. Аңладык.

Старший. Ярый. Әйдәгез эшкә! (*Мич башына менеп ята.*)

Бер красноармеец. Чыннан да, моннан берәр төрле эш чыгуы ихтимал бит, ә?! Кем белә, бәлки, алар арасында дизиртирлар да бардыр.

Карчык, солдат керәләр.

Карчык. Ну, җегетләр, мин бер дә уйламаган идем, бәхетегез бар икән. Сез сораганнарның барысы да табылды.

Красноармеец. Ярый, булса, хәзергә җыеп куй әле. Иптәш кайткач, үзебез сорап алырбыз. Бәлки, тиздән инде камисар да кайтыр.

Карчык. Иптәшегез кайда соң?

Красноармеец. Ул: «Бераз йөреп керәм», – дип чыгып китте. Камисар эш белән киткән иде. Алар, бәлки, бик тиз кайтмаслар әле. Әйдә, Шакир иптәш, без дә арбага чыгып бераз ятып торыйк. (*Ишарә кыла.*)

Чыгалар.

Карчык (*ялгыз*). Җүнле генә җегетләргә охшыйлар. Шулай да үземдә алар сораган нәрсәләрнең һәммәсе дә бар икәнен әйтергә курыктым. Кем белә бит, очраган бер кешегә ышанып бетереп булмый.

Гармун, җыр тавышлары ишетелә.

Киләләр бугай. Ярый, бик яхшы, бик вакытлы киләләр. Салдатлар бар вакытта килүләрен күңелем бер дә тартмаган иде. Ярый инде, чыгып киттеләр.

Кәрим керә.

Кәрим (*сулап*). Әби өйдәме?!

Карчык. Өйдә, өйдә, әйдә, рәхим итегез. (*Ишекне ачып.*) Әйдәгез, җегетләр!

Алты-җиде җегет керә. Кайсы исерек, кайсы кызмача.

Ә у х ә д и. Ха-ха-ха! Шәп эш. Сыйланабыз диген, ә! Кәрим ярый ул, аның өчен, ичмасам, нишләсәң дә стоит! Ә ул Хафиз нәрсә? Ул бит ач бет. Аның үзенә дә юк, кешегә дә.

К ә р и м (*кызмача*). Ну, җегетләр, әйдәгез сәке түреннән.

Утыралар.

Әйдә тарт гармунны!

Г а р м у н ч ы. Була ул. «Хафизә» көенме?

К ә р и м. Юк, аны түгел, бүгенгә башканы.

Ф а з ы л. «Хафизә» көен аны Кәрим Хафизәне алган вакытта туйда әйттерербез, шул вакытта.

К ә р и м. Әби, кая баягы казлар белән балны китер әле.

Ә б и. Ярый, хәзер китерәм. Мин аларны, бик әчеп, тәмсезләнеп бетмәсеннәр дип, базга төшереп куйган идем. Хәзер алып менәм.

К ә р и м. Бар алайса, тизрәк алып мен.

Ә б и. Ярый. (*Чыга.*)

К ә р и м. Җәгез, әйдә, әйттерә башлагыз, тарт гармунның колагын!

Гармун уйный. Җегетләр җырлыйлар.
Бу урында берәр төрле авыл көе җырлана.

Ф а з ы л. Шуны беләсе иде, тегендә Хафиз нишләп ята икән, Хафиз? Кандалалар белән борчалар үзен үрле-кырлы сикертәләр бугай!

Ә у х ә д и. Әле аның сикерәсе көннәре алда. Аны судта тагы да яхшырак сикертерләр. Ну, малай, Кәрим, үзеңдә дә баш бар икән соң! Кайдан табып, уйлап чыгарган бит! Келәт басарга кергән, имеш! Ха-ха-ха! Келәт басарга диген, ә? Ие, келәт басарга! Тычкан кимерерлек бер сынык каткан икмәге дә булмаган буш келәтне басарга! Ха-ха-ха!

К ә р и м. Җә, җитәр инде, авызыңны бик артык җырма. Беләсең икән, бик яхшы, эчеңнән генә тын. Җә әби килеп керер.

Ә у х ә д и. Мин бит болай гына, болай гына, үземнең исем киткәнлектән генә әйтәм. Келәт баскан диген, ә! Ну соң үзеңдә баш та бар икән! Һаман әле көләсем килә. Ха-ха-ха! Хафиз келәт баскан!

Ф а з ы л. Җә, әйтәләр бит инде сиңа тик утыр дип! Бу кадәр тотнаксыз авыз булырсың икән.

Ә у х ә д и. Юк, юк, мин болай гына. Әйдә, уйна гармунны, мин биим.

Гармун озын көй уйный. Ә Әүхәди алпан-тилпән биеп маташа. Әби бер култык астына каз кыстырып, ике кулына ике чиләк белән бал күтәреп керә.

Д а у т. Менә, ичмасам, әбине мактасаң да ярый. Әби дисәң, әбинең дә менә дигәне! Җан теләгән нәрсәне алып килгән.

Ә б и. Караңгыда базга чүт кенә җыгылып төшмәдем. Җегетләре яхшы, жегетләре! Җегетләр хөрмәтенә генә төштем. Юк исә, караңгы төн уртасында җен оясы базга һичбер аягымны да атлап төшмәс идем. Төнлә базга күп төшеп йөрергә ярамый, җен сирпелүе бар.

К ә р и м. Рәхмәт сиңа, әби, рәхмәт! Синең яхшылыгыңны онытмабыз. Менә эшләр генә бетсен, мин сине буш итмәм, әби. Беләсең бит әле, эшләр бар. Менә кайчан Хафизә минеке булыр, шул вакытта мин сине түр башына менгереп утыртып, баш кодача итеп сыйлармын.

Ә б и. Бик яхшы, бик яхшы. Алла морадыңны гына бирсен. Чибәр җегетләргә чибәр кызлар килешә. (*Читкә.*) Атаң үлсә ни миңа, анаң үлсә ни миңа, биш сум акчаң бир миңа.

Ә ү х ә д и. Торам, торам да, һаман да минем исем китә. Хафиз тегендә, ябылган җирендә, ниләр генә исәпләп ята икән, «чыннан да, мин әллә келәт басарга кереп барадыр идем микән» ди микән? Ха-ха-ха!

Д а у т. Фу, билләһи! Тәмам туйдырдың инде син дә. Әйдә, тот кулыңа да эч! Эчеп исерерсең дә кайтып йокларсың.

Ә ү х ә д и. Юк әле, тора тор! Мин бер дә исерек түгел! Ха-ха-ха! Минем бары тик көләсем генә килә: Хафиз җегет келәт баскан. Аның дала, кыр шикелле такыр идәненә сөртенеп җыгылып, башын ярган! Хи-ха-ха!

Д а у т. Булса соң, сиңа нәрсә, син үзеңнең эчүеңне генә бел. Сез дә шул, нигә кирәк шул бортак авызны ияртеп йөрергә?

Ә ү х ә д и. Исерек, исерек, бер дә исерек түгел. Әйдә, уйна бию көен, мин биим. (*Торып, биемәкче була, ләкин абынып егыла.*)

Д а у т. Җә, тор инде, нәрсә ауныйсың?

К ә р и м. Җә, тимәгез аңар, аның булуы җиткән инде. Әйдәгез, җегетләр, ашагыз, эчегез, уйнагыз, көлегез, биегез – бүген минем туй!

Ә ү х ә д и (*яткан җирдән*). Юк әле... Туй түгел... Туй алда... Әй... Кәрим... Мине туйдан калдырма... (*Йокыга китә.*)

Д а у т. Җәгез, тагы бераз җиңел көй әйттереп җибәрегез.

Эчәләр. Җиңел көй уйныйлар, җырлыйлар, бииләр, исерәләр.

К э р и м. Җә, иптәшләр, күңелегез булдымы инде?

Җ е г е т л ә р. Бик шәп! Маладис, Кәрим, маладис!

Д а у т. Туктагыз әле, җегетләр, монда бал бик күп бит әле. Әйдәгез эчәбез.

Ә б и. Җегетләр, бераз саграк булыгыз, бик тавышланмагыз. Монда фатирга төшкән каладан килгән салдатлар бар. Араларында берсе зуррак, башлыклары булырга кирәк, алар ишетә күрмәсеннәр.

Җ е г е т л ә р. Нәрсә? Салдатлар? Кайда? Нинди салдатлар?

Ә б и. Ниндиләр икәнен белмим, берсе башлыклары, йөрергә чыгып китте, андан да зуррагы, «камисар» дигәне, вулыска кантурга киткән бугай. Башкалары ишегалдында, арбада йоклыйлар.

Җ е г е т л ә р (*аерым-аерым*). Ват тибә на! Менә сиңа кирәк булса!

Ф а з ы л. Менә сиңа пәрәмәч!

Д а у т. Бетте баш, алай булса! Әйдә, үкчәң күтәр, сыз тизрәк!

К ә р и м. Син нишләп соң аны элегрәк әйтмәдең?

Ә б и. Әйтәм бит, арбада йоклыйлар дип. Бик тавышланмасагыз, бер дә зарары юк.

К ә р и м. Юк инде, алай булгач, булмады, әйдә, җегетләр, китик моннан.

Д а у т. Тукта әле, эчеп бетермәгән бит.

К ә р и м. Юк, ярамый, әйдә, бер чиләген үзегез белән алыгыз, калганын иртәгә яңадан килеп эчәрбез.

Д а у т. Ну, әйдәгез алайса!

Кузгалалар. Алпан-тилпән чыгалар. Әүхәдине, уятып, җитәкләп алып чыгалар. Урамда җыр, гармун тавышлары, Әби өстәлне җыештыра.

Ә б и. Ахры, башка җирдә дә эчкәннәрдер. Бер чиләкне дә эчеп бетерә алмадылар.

С о л д а т л а р керә.

Ш а к и р. Тышта шактый салкынча икән, өрә башлады. Инде кунаклар киткәч, керергә ярый торгандыр?

Ә б и. Ярый, ярый, бик ярый. Әйдә, менә бераз каз итләреннән, балдан да рәхим итегез. (*Каз итен алларына куя. Берәр полоскательный белән бал салып бирә.*) Монысын базга төшереп куйыйм әле, иртәгә килеп баш төзәтергә дип сорарлар әле. (*Чыга.*)

С т а р ш и й (*мич башыннан төшеп*). Безгә монда эшләргә әле шактый эшләр бар икән. Камисар кайткач, мин эшне аңар далажит итәрмен. Ул аларга күрмәгәннәрен күрсәтер.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Волость башкармасы ишегалды. Крыльцо алдына өстәлләр, урындыклар, язу әсбаблары куелган. Судның хөкемен карар өчен, Хафиз яклы җегетләр дә, Кәрим яклы җегетләр дә җыелганнар. Арада сакаллы кешеләр дә, бер читтәрәк карчык-корылар, хатын-кызлар, бала-чагалар да бар. Дисәтникләр халыкны артка чигенергә кушалар.

Дисәтник (*бала-чагаларга*). Барыгыз, китегез моннан, сезгә монда ни калган! Марш моннан! Барыгыз да китегез. Барыгыз, әнә анда урамга чыгып уйнагыз! (*Хатын-кызларга.*) Сезгә дә монда берни дә калмаган. Бәрәкәт китәреп, ир-ат арасына килеп йөрмәсәгез ярамыймыни? Хатыннар ирләр эшенә килеп катышып йөри башладылар. Шуның аркасында явымнар да булмый башлады.

Беренче хатын. Нәрсәгә ул кадәр җикеренгән буласың соң! Дисәтник булган, имеш тә, әллә кем булган. Бездә синең эшең булмасын, үз хатының белән үз кызларың янында җикеренерсең.

Дисәтник. Күп сөйләнсәгез, менә шушы таяк белән барыгызны да кыздырып җибәрермен.

Икенче хатын. Кулың кыскарак булыр. Хәзер инде аның заманы андый түгел.

Әүхәди (*иптәшләренә*). Гуаһлыкка безнең яктан язылган кешеләрнең барысы да килгәннәрме?

Фазылҗан. Килүен килгәннәр, ләкин макмыр баш белән әллә ниләр бутап бетермәсәләр ярар иде.

Даут. Бетермәсләр. Барысы да эшнең ничек икәнен беләләр бит инде.

Фазылҗан. Белүен беләләр дә, ә менә мин инде бер көн җавап алганда ниләр сөйләгәнемне онытып та бетердем инде...*

Комиссар. Кичә син эчтеңме?

Даут. Нишләп эчмәскә, эчтем. Сыйлагач, нигә эчмәскә.

Комиссар. Кем эчертте?

Даут. Кем булсын, әнә... әй, юк икән, Кәрим, бая алып киттеләр ич әле.

Комиссар. Тагы ниләр эшләдегез?

Даут. Биедек.

Комиссар. Бии беләсеңмени?

Даут. Беләм. (*Ике бөеренә таянып биергә керешә.)*

Халык көлә.

---

* Бу урында кулъязманың 8 бите төшкән.

Комиссар. Җә, ярар, соңыннан биерсең.

Даут туктый.

Син җегетләр белән мунча янына килдеңме?

Даут. Килдем.

Комиссар. Үзең генәме?

Даут. Юк, иптәш җегетләр белән бергә.

Комиссар. Нигә килдең?

Даут. Чакыргач, килдем.

Комиссар. Сине кем чакырды?

Даут. Әнә әйттем ич инде, Кәрим чакырды.

Комиссар. Хафизның тәрәзәдән кергәнен күрдеңме?

Даут. Нинди тәрәзәдән?

Комиссар. Келәт тәрәзәсеннән.

Даут. Юк, аннан ничек Хафиз сыйсын?! Ул бит төнлек юлы шикелле генә.

Комиссар. Ә соң син аның Хафизә белән сөйләшкәнен күрдеңме?

Даут. Күрдем. Хафизның җырлаганын да ишеттем. Хафизә кереп киткәндә, пхыйә! Үбештеләр дә.

Комиссар. Хафизны син дә кыйнадыңмы?

Даут. Әй, юк, билләһи, абзый, кыйнамадым. Бер суктым сугуын. Аның да Хафизга тигәнен белмим. Берәүгә тиде инде шунда. Тик торганда мин нишләп кыйныйм. Хафизның миңа бер зыяны да тигәне юк. Мин Хафизны да, Хафизәне дә, Кәримне дә яратам.

Комиссар. Ярый, бар кит.

Даут. Әүхәдиләр янынамы?

Комиссар. Теләсәң, шулар янына.

Даут сикергәләп китә.

Әүхәди Камали угылын китерегез!

Китерәләр.

Йә, сез бу турыда ни беләсез?

Әүхәди. Мин артык берни дә белмим. Иптәшләр: «Кызлар киндер тукмаклый торган җиргә барыйк», – дигәч, бардым, «кайтыйк» дигәч, кайттым.

Комиссар. Әби йортында булдыңмы?

Әүхәди. Булдым.

Комиссар. Нишләдегез?

Әүхәди. Нишлик, эчтек, уйнадык, көлдек, биедек.

Комиссар. Син мунча янына килгән идеңме?

Әүхәди. Килгән идем.

Комиссар. Хафизның тәрәзәдән керергә йөргәнен күрдеңме?

Әүхәди. Тәрәзә янында торганын күрдем, кергәнен күрмәдем.

Комиссар. Сиңа мунча янына килергә кем кушты?

Әүхәди. Миңа иптәшләр әйттеләр, мин килдем.

Комиссар. Синеңчә, Хафиз шулай начар җегетмени?

Әүхәди. Начарлыгын күргәнем юк.

Комиссар. Бу турыда тагы ниләр беләсең?

Әүхәди. Артык берни дә белмим.

Комиссар (*Дисәтникләргә*). Ярый, бар, алып китегез. Кәрим Сираҗетдин угылын монда китерегез.

Китерәләр.

Туры сөйләвегезгә сүз бирәсезме?

Кәрим. Минем ялган сөйләгәнем юк.

Комиссар. Син Хафизә дигән кызны сөядер идеңме?

Кәрим. Электә сөядер идем, хәзер сөймим. Хәтта җирәнәм.

Комиссар. Сәбәп?

Кәрим. Ул Хафизны сөя.

Комиссар. Син Хафизны кыйнаган өчен әбинең өенә җегетләрне җыеп, аларны бал эчертеп сыйладыңмы?

Кәрим. Барыбер, мин әйтсәм әйтмәсәм дә, барысын да беләсез инде, сыйладым.

Комиссар. Хафизны ни өчен кыйнаттың?

Кәрим. Мин яраткан кызны сөйгән өчен, көнләштем дә кыйнаттым.

Комиссар. Алай булгач, сүз озайтып торырга да хаҗәт юк икән, сез үзегезнең гаебегезне икърар итәсез.

Кәрим. Ул кадәр кеше әйтеп торгач, яшерүнең файдасы юк. Мин Хафизәне сөйдем...*

---

* Кулъязма шушы урында өзелә.

## ӨЧ ТОРМЫШ (1)

[...] юк, иртәгә килерсез», – дип куып чыгарды.

Балалар. Әни, ашарга бир инде!

Хатын. Әнә, бар, пычак аша.

Хәйри. Сүзгә мавыгып, мин тагы онытып җибәргәнмен. Мә, туганым, бир әле үзләренә, ашасыннар. (*Бирә.*) Аларның да, мескеннәрнең, ашасылары килә торгандыр шул. Безнеке инде карт йөрәк, ашамый торсаң бик тиз өзелә.

Хатын. Өзелмәгән кая инде ул, Хәйри астай. Үзеңә булмаса да, аларны ач тотасы килми шул. (*Икмәкне алып, кисеп.*) Мәгез, ашагыз! (*Кечкенә генә, юка гына итеп кисеп алып, үзе дә ашый башлый.*) Җәй көне, җылы вакыт булса тагы да бер хәл иде. Урамга куып чыгарыр идең дә бераз колагың тынып торыр иде. Бу суык вакытта аларны кая куып чыгарасың, өст-башларына да юк.

Хәйри. Шулай инде, туганым, шулай, ни дисәң дә аптыраш. Үзебездә дә шундый ук хәл. Ичмаса, ягарына утыны булса тагы бер хәл булыр иде әле. Өең җылы булса, тагы бераз ярар иде әле шунда. Утын алырлык та көч юк бит. Әле менә үзем дә, тиреслек башыннан, аннан-моннан йомычкалар җыеп алып кереп, көчкә генә ягып, бераз гына җылыткан шикелле булдым шунда.

Хатын. Анысы инде, Хәйри астай, йомычкасын табып булса, бик ягасың инде аны. Әле бит аның йомычкасын да табар хәл юк. Иртә белән Габдрахман байларның теге амбарлар эшләтә торган җирләренә барып, бер кочак йомычка җыйган идем, чыгып барганда двурниклары күрде дә: «Байның рөхсәте юк», – дип, җыйган йомычкаларымны кире ташлаттырды.

Хәйри. Юк инде, юк, туганым, байларда рәхим-шәфкать дигән нәрсә һич юк.

Хатын. Бай, үзе дә түгел бит әле. Үзе булса тагы бер хәер иде. Двурнигы бит әле. Үзе дә бит безнең шикелле бер хәерче бит. Безнең хәлне бераз белергә кирәк инде. Хәлебез булса, без соң йөзебезне җыртып, әрсезләнеп, аларның алларына барып йөрер идекмени?

Хәйри. Аларга да берни дә әйтер хәл юк инде, туганым. Аларның да шул байлары кушканны эшләми хәлләре юк. Һәркемгә дә үз җаны кадерле. Ярлылар яклы

булсалар, байлары аларны да куып чыгаралар шул. Юк инде, юк, туганым, байларда мәрхәмәт дигән нәрсә юк инде. Алар тиреңне тунарга гына торалар. Алар шул ярлылар хакын ашый-ашый шулай баеганнар да шул.

Хатын. Шулай инде, Хәйри апа, шулай. Менә ничә атна булды бит инде, бай безнекенең хезмәт иткән акчасын ничә атнадан бирле бирмиче йөртә бит әле. Безнеке шунда, каядыр бер җыелышта, иптәшләре арасында, байларның кысулары турысында сөйләп, бераз телләнгән икән, шуны кайсыдыр бер эте байга җитештергән. Бай шуңар ачуланып, ике атнадан бирле хезмәт хакын бирмиче йөртә.

Тыштан тавыш. Сәдакадан ярдәм итсәгез лә, бәбкәем!

Хатын. Тамагыңа пычак кадалсын! Ачны хәерче кыстар, ди. (*Кычкырып.*) Гаеп итмә!

Хәйри. Шул инде, шул. Алар да шул, безнең янга килмиче, кайда барсыннар? Байлар бит алар хәерчегә бер телем икмәген бирергә кызгансалар да, хәерчегә өрә торган эткә ашатырга кызганмыйлар. Беркөннәрне Гали байның хатыны киерелеп, ясанып, теге сыгылмалы, резинке көпчәкле, исемен дә әйтә белмим инде, атына утырып кайтып килә. Илаһи! Ни күзем белән күрим! Аяк астына, нәкъ ике пот булыр, атныкымы, сыерныкымы, әйбәт, симез үпкә-бавырлар төяп алып кайтып килә. «Кара, мин әйтәм, байлар да үпкә-бавыр ашыйлар икән», – дигән идем, узып баручы берәү әйтә: «Беләсең икән пычагым, алар бит аны этләре белән хезмәтчеләренә ашатырга алып кайталар», – ди.

Хатын. Шулай инде, шулай, Хәйри апа, эткә сан бар, байлар кашында эшчегә сан юк.

Хәйри. Җә, ярый, икмәк алып кайткач самавыр куйган булган идем, самавырым ташымасын тагы. Ярый, хуш. Үзең ипи алгач кертерсең, бик озаклатма.

Хатын. Ярый, ярый, бик рәхмәт инде сиңа. Озаклатмам, үзе акча алып кайткач та, алып кайтып түләрмен. Ярый, хуш!

Хәйри чыга.

(*Икмәкне, кисеп алып, йотыга-йотыга ашый башлый.*) И җаным, чикләвек төше тәмнәре килә.

3 нче бала. Әни, әллә аны чикләвек төшеннән пешергәннәрме?

Хатын. Чикләвек төшеннән сары май белән пешергәннәр.

3 нче бала. Әйтәм бик тәмле!

2 нче бала. Бервакытны әти перәннек алып кайткан иде. Ул да шулай бик тәмле иде бит, әйеме?

Х а т ы н. Әйе, әйе, ашасың килгәндә ипи дә перәннек шикелле тәмле була ул.

Э ш ч е керә дә, хәлсезләнеп, ишек янындагы табуреткага утыра.

Тагы булмагандыр, ахры. Нихәл, әллә бүген дә бирмәделәрме?

Э ш ч е. Биру түгел, бүген бөтенләй кибетенә дә төшмәде. «Бай бүген кунак уздыра. Бигәнәй ишан хәзрәт килгән», – диделәр. (*Балаларының ашаганын күреп.*) Ипи кайдан алдыгыз?

Х а т ы н. Балалар «ашарга» дип бик җөдәткәч, син кайткач кертеп бирербез дип, Хәйри ападан алып тордым.

Э ш ч е. Мин алып кайткач! Алырсың шәйтаннан иман!

Х а т ы н. Соң бүген нишләрбез икән инде?

Э ш ч е. Белмим. Бөтенләй башларым катты инде. Бер байның өенә барып карыйм микән дигән идем дә, йөрәгем җитмәде. Җә бөтенләй кудырып чыгарыр дип курыктым. Аларның этләре дә безнең шикелле ярлыларга дошман бит.

Х а т ы н. Һи Раббым! Нишләргә инде?

Э ш ч е. Әллә булмаса, син барып сорап карыйсыңмы?! Хатын кеше булгач, бераз кызганып, биреп җибәрмәсме?

Х а т ы н. Сораныргa калган баш инде, бармыйчы булмас шул. Ни хәл итәсең. Барсаң да теләнүең генә калыр, барыбер бирмәс. Сиңа да бер дә кирәк түгел иде теләнергә. Аларны без генә җиңә алабызмыни? Синең шул телләнүеңнең ачуын ала инде ул.

Э ш ч е. Телләнсә бит, мин аны атап әйтмәдем, упщий гына әйттем.

Х а т ы н. Ничек әйтсәң дә, алар таякның башы кемгә тигәнен бик яхшы беләләр. Шулай да ачтан үләр хәл юк, бармыйчы булмас. Син инде мин кайтканчы балаларны карап торырсың бит.

Э ш ч е. Торырмын, тик син бар гына.

Х а т ы н. Барып карыйм инде алайса. (*Өстенә сәләмә киемнәр киеп, чыга башлый.*)

Э ш ч е. Кара әле, сиңа әйтәм, бик ашасы килә бит, шул Хәйридән алган икмәгеңнән миңа да бераз өлеш калмадымы?

Х а т ы н. Әнә шунда бераз калдырган идем. Ал. Балаларга да беразын калдыр. Барып карыйм инде, ни булыр. Ләкин ни өчендер бер дә күңелем ышанмый. (*Чыгып китә.*)

Э ш ч е (*балалар өстенә төбәп карап тора да*). Их, тормыш, тормыш! Бу бала дигән нәрсәләр дә безнең шикелле ярлылар белән этләрдә генә шулай күп булалар бит! Этләрнең дә яхширак сортының балалары ул кадәр күп булмый. Бары тик урам көчекләре генә күп булалар. Байга

да минем сөйләгән сүзләрне шундый тәлинкә ялаучы урам көчекләре ирештергәннәр булырга кирәк. Аларның эшләре бик күп бит.

Городовой керә.

Бу газраил нишләп йөри тагын?

Городовой. Әхмәди Мөхетдинов син буласыңмы?

Эшче. Әйе, мин булам, нишкә?

Городовой. Нишкә икәнен анда баргач күрсәтерләр. Нишкә булсын, билгеле инде, кунакка түгел. Үзеңнең нишләгәнеңне үзең беләторгансыңдыр.

Эшче. Минем гаепле булырлык бернәрсә дә эшләгәнем юк.

Городовой. Шулайдыр шул, берни дә эшләгәнең юктыр. Соңгы вакытларда телгә бигрәк остарып киттегез. Авызыгызга телегез сыймый башлады. Бигрәк белемле булып киттегез. Кешегә эш югында эш чыгарып йөрисез.

Эшче. Сезгә чурт кушканмыни? Йөрмәгез! Йөрсәгез, бушка йөрмисез бит, жалуния аласыз.

Городовой. Ну, әйдә, телеңә салынып торма, әйдә, өстеңә киен, сине эзләп йөреп обедка да соңга калдым.

Эшче. Өсткә киенергә минем сезнеке шикелле казенный киемнәрем юк.

Городовой. Киемнәрең булмаса, анда казенный киемнәр табылыр. Арестанский халатлар чахавыз тулы.

Эшче. Бераз сабыр ит, хатын кайтсын. Мин бу балаларны кемгә калдырыйм? Карарга кеше юк бит.

Городовой. Синнән башка да торырлар әле. Көчекләр белән урам тулы. Этләргә көтүче ялламыйлар.

Эшче (*барып, балаларын кочаклап*). Һи, балалар, балалар, сезне ятим калдырырга туры килә бит!

Балалар. Әти, син кая барасың?

Эшче. Җәһәннәмгә, балалар, җәһәннәмгә!

3 нче бала. Анда ипи бирәләрме?

Эшче. Бирәләр, балам, бирәләр. Монда бирмәсәләр дә, анда бирәләр.

3 нче бала. Безгә дә алып кайт, җәме?

Эшче (*күзләре яшәреп*). Ярар.

Чыгып китәләр.

2 нче бала. Абый, алар кая киттеләр?

3 нче бала. Ипи алырга ди ич.

Пәрдә.

---

Чахавыз (*цейхгауз*) – кием-салым склады.

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Байның ишегалды. Караңгы. Сәхнәгә тәрәзәләрдән төшкән электр яктылары яктылык бирә. Пәрдә күтәрелер алдыннан Алып баручы сәхнә алдына чыга.

Алып баручы. Менә шулай, иптәшләр, электә эшчеләр тормышында шулай бардылар эшләр. Инде хәзер карап торыгыз, эшченең хуҗасы – җуан бай, буржуй нишләр?

Кереп китә. Пәрдә ачыла.
Хатын каранып, куркып кына ишегалдына керә. Читтән эт өргән тавыш ишетелә.

Хатын. Ярабби Ходаем, этләре дә өрә. Ачуланмасалар гына ярар иде. И Раббым! Читен дә соң кеше каршына соранып баруы! Әҗәл белән бер. Ачуланып, сүгеп кенә кайтармасалар ярар иде.

Дворник керә.

Дворник. Әй, кем бар анда? Эт өрдереп, кеше көлдереп, караңгыда кем йөри? Билгеле инде, җүнле кеше түгелдер. Җүнле кешене эт тә таный. (*Хатынны күреп.*) Әйтәм бит, җүнле кеше түгелдер дип. Һәй, син кем? Нәрсә монда, караңгыда, сораусыз-нисез ишегалдына кереп йөрисең? Әйберләр чәлдерергә кердеңмени? Йомычка урларга кергәндер әле. Бар, чык. Югал күземнән! Сезнең аркада монда байдан орыш алырга туры килә.

Хатын. Мин ул, мин, Миңлебай абзый. Байга йомыш белән килгән идем.

Дворник. Ә, Хәерниса, синмени? Мин хәерче кергәнме әллә дип торадыр идем. Төнлә белән караңгыда ни эшләп йөрисең? Байның өйдә йомыш белән килгән кешеләрне кабул итмәгәнен белмисеңмени?

Хатын. Һи, Миңлебай абзый, белмисең! Үз ихтыярымда булса, бер дә аягымны да атлап килмәс идем. Мохтаҗлык китерә, мохтаҗлык! Ачлыктан гаҗиз булгач кына килдем. Ашарга юк, ягарга юк. Өйдә салкынга чыдар хәл юк. Бай тиешле эш хакын да ике атнадан бирле бирми йөртә. Бүген дә үзе көн буе байның кибет ишеге төбен саклап кайтты. «Бүген ул аш уздыра, кибеткә төшмәс», – дигәч, ачлыктан аптырап, булмаса, син барып кара әле дип, мине җибәрде.

Дворник. Ай-һай, белмим, Хәерниса, бай бирер микән! Байның аңар бик кәефе киткән. Беркөнне мине дә: «Син дә, Әхмәди шикелле, байга каршы өрә башладыңмыни?» – дип тетеп сүкте. Әхмәдигә дә нигә кирәк иде инде алай телләнеп йөрергә! Байларны аларны җиңәргә

безнең кулдан киләмени! Патшасыннан башлап бутишнекләренә кадәр – барысы да алар яклы бит.

Хатын. Шулай инде, шулай, Миңлебай абзый. Телләнмәгән булса, бик яхшы булган булыр иде дә бит, нишләтәсең бит, күрәчәгенә каршы, сөйләп җибәргән инде.

Дворник. Ялгыш иткән, кызым, ялгыш иткән. Хәерле булсын инде.

Хатын. Бай янына керсәм, күрә алмам микәнни?

Дворник. Бер дә белмим шул. Бераз гына сабыр ит инде, ашап бетерделәр инде. Хәзер чәй генә эчәләр, кунаклары таралырлар да инде. Ишан хәзрәтне дә баюк икенче җирдән алмага килделәр, атлары көтеп тора.

Парадный ишегендә электр яна.

Әнә утны да яндырдылар. Чыга торганнардыр. Син читкәрәк китеп тор.

Бай белән Ишан парадныйдан чыгалар.

Бай. Миңлебай! Бар әйт, Ишан хәзрәткә ат китерсеннәр.

Дворник. Хәзер. (*Чыгып китә.*) Әүхәди!

Бай. Тәкъсир, инде сезне яхшылап сыйлап та булмады, бик ашыктырдылар. Тиз китмәсәгез, икенче бер вакыт иркенләп сохбәт итеп утырырга рәхим итегез. Алдан берәр кеше җибәреп әйттерсәгез, хәзерләнеп торырбыз. Әле сәфәрегез тиз түгелдер бит?

Ишан. Үземнең тиз китәргә ният иде дә, әһле яраннар: «Китмә әле, хәзрәт», – дип бик үтенәләр. Ватанны да сагынган идем дә, сезнең шикелле сахибе хәйрат байлар: «Китмәгез әле, абыстайны да ат җибәреп алдырабыз», – дип, аны алырга ат җибәрделәр.

Бай. Шулай, шулай, хәзрәт, китмәгез әле. Сез булган вакытта шәһәребезгә бәрәкәт иңә. Әле теге яка чыккан әхтәм абил дигән нәрсәне алырга да ният бар иде дә, җитешә генә алмыйм. Бәлки, сез киткәнче аны да алып утыртып йөртербез.

Ишан. Андый рәсүлулла саллаллаһе галәйһи вә сәлләм заманында, гасри сәгадәттә булмаган бидгать нәрсәләрне[1] алуың бик мәгъкуль булып бетмәс. Кадим-кадим-

---

Тәкъсир – хөрмәтлем.
Сохбәт – сөйләшеп утыру.
Әһле яраннар – дус-ишләр.
Сахибе хәйрат – изге эшияләре.
Әхтәм абил – автомобиль.
Мәгъкуль – урынлы.

гедән килгән ат белән канәгатьләнеп торуыгыз мәгъкульрәк булыр.

Б а й. Ләббәйкә, тәкъсир, ләббәйкә! Алай булса, бетте, тәкъсир, алмыйм. Әстәгъфируллаһе тәүбә!

Чыгалар.

Хуш, тәкъсир, хуш!

Ат аягы тавышы. Б а й керә.

Х а т ы н (*алгарак кереп*). Бай!

Б а й (*танымаганга салышып*). Миңлебай! Нишләп ишегалдына төнлә белән хәерчеләр кертеп йөртәсең? Капканы яхшы карамыйсың?

Д в о р н и к. Хәерче түгел бит ул, Әхмәди хатыны. Сезне күрергә дип килгән.

Б а й. Төнлә белән ни калган аңар?

Х а т ы н. Хаҗи абзый, зинһар, мәрхәмәтегездән ташламагыз инде. Балаларым ач утыралар, өебезгә ягарга бер агач утыныбыз юк. Балаларыбыз ялангач, өебез суык.

Б а й (*үзалдына*). Мин әле Әхмәдине чыгарту турысында ялынырга килгән микән дип уйлаган идем. Әле алып китмәгәннәр, күрәсең. (*Ишеттереп.*) Ач булса, эшләрсез. Тамагыгыз туяр. Анда сезне бушка туйдырып асрарга миндә Әндри казнасы юк. Бик яхшы, теленә салынып, рабучилар арасында митинге ясап йөрергә белгән бит, рабучилары туйдырмаганнармыни?

Х а т ы н. Үзенең күрәсенә каршы булган инде, хаҗи абзый. Мин дә әллә ничә тапкыр әйттем инде үзенә.

Б а й. Ярый, ашарыгызга булмаса, Миңлебай биреп җибәрер. Иртәгә кибеткә төшәрсең. Акчаңны да биреп җибәрермен, ләкин Әхмәдиең төшмәсен, аңар күзенә кырып салырга сукыр бер тиен дә бирмәм. Моннан соң эшне дә шул дуст рабучилары табып бирерләр. Миңлебай, бар әнә, теге этләргә дип алып кайткан үпкә-бавырдан бер ашлык итеп кисеп бирсеннәр, хатыныңа әйт. Шунда ишегалдындагы йомычкалардан да бер кочак, берәр ягарлык йомычка бир.

Х а т ы н. Рәхмәт инде, хаҗи абзый, балаларны шатландырган өчен Алла әҗерен бирсен.

Б а й (*үзалдына*). Пристефенең дә ужуы җитмәгән икән әле. Алары да шул тыгынырга гына яраталар. (*Кереп китә. Утны сүндерә.*)

Д в о р н и к. Син торып тор, хәзер үзем чыгарып бирермен. (*Почмактан китеп югала.*)

---

У ж у ы (*уже*) – «вакытында эшләү» мәгънәсендә.

Хатын (*үзалдына*). Инде кая барырбыз? Урыннан да колак кактык. (*Бераз торып.*) Хәер лә әле. Моңарчы бай туйдырмаган. Башы исән булса, эше табылыр.

Дворник (*килеп*). Менә, ал. Бик симез булгач, эткә ашатуларына җаным әрнегән иде, сиңа насыйп ризык икән. Әйдә, тегеннән йомычкалар да бирермен.

Хатын. Бик рәхмәт, Миңлебай абзый. Эшче кеше эшченең хәлен ничек тә аңлый.

Кереп китәләр.
Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

Эшченең яңа квартиры. Тәрәзәләр зур, якты, яңа стильдә эшләнгән ике бүлмәле йорт. Мебельләр дә яхшырган.

Хатын (*ишектән, зур сумка белән әйбер күтәреп кереп, кече якка чыгып китә. Анда сумкасын калдырып керә*). Шушы ял көне җитсә, гел эш туа да тора. Көннең узганын сизми дә каласың, капиратифта бер дә баш тыгарлык түгел. Чират көтеп тәмам арып беттем. Фабриктан палучка алган көнне бераз сыйланып каласы да килә. Тик менә үзенеке белән минем ял көне икесе бер көн туры килмәве генә бераз уңайсызрак. Бүген, заем кәгазьләренә отыш чыкмаган микән дип, фабкомнан тикшертеп карармын дигән идем дә, өлгерә алмадым инде. Балалар мәктәптән кайтып җиткәнче, ашны булдырырга кирәк. Аннан соң кичен кинога барып кайтырмын. Тукта әле, бүген ни көн соң әле? Бу биш көнлек эш атнасына күчкәннән бирле көн исемнәрен дә онытып бетердем инде. Бары тик числа гына хәтердә кала. Ә, бүген, тиатрга барырга дип, билет биргәннәр иде бугай әле. (*Кесәсеннән билетын алып карап.*) Ә, бүгенгә түгел икән әле. Башта, яңалиф укытабыз дигәч, беләалмам дип курыккан идем. Укый торгач, белдем тагы.

Хәйри керә.

Хатын. Һу! Әйдүк, Хәйри апа! Исән-сау, сәламәт йөрисеңме! Бер дә килүең-китүең юк.

Хәйри. Дөнья мәшәкате, туганым, дөнья мәшәкате. Һич бушар хәл юк. Үзегез бик исән-сау торасызмы соң? Әхмәди бик исән йөриме?

Хатын. Шөкер әле, бик исән йөри. Бары тик ударник булып эшләгәнгә күрә, бер дә бушый алмый. Үзен бу ел Октябрь бәйрәмендә бүләкләделәр. Эш башыннан эшләгәнгә күрә, акчаны да яхшы таба. Балалар зурайгач, алар

да яхшы булыша башладылар. Олы улым, ФЗУны бетереп, яхшы гына урынга урнашты. Жалуниясе дә яхшы. Уртанчысы рабфакка керде. Кечесен көн техникумына бирдек.

Хәйри. Бик яхшы, бик яхшы. Син дә бик ачылып киттең. Минем ул исемнәрне әйтергә телем дә күнми.

Хатын. Элек мин дә белмидер идем. Фабрикка кереп эшли башлагач, кичке курсларга йөреп кенә ачылдым.

Хәйри. Бик яхшы булды инде, туганым, бик яхшы. Аның каравы электә бик зур җәфалар чиктегез бит.

Хатын. Сөйләмә дә инде. Ул вакытлар искә төшкәч, әле булса һаман йөрәкләрем жу итеп китә. Әйтергә генә асат бит: ике ел ярым төрмәдә череттеләр бит! Ривалютсия булмаса, кем белә, тагы да әллә никадәр яткан булыр иде әле.

Хәйри. Шулай, шулай, ул вакыттагы көннәрне дустыңа түгел, дошманыңа да күрсәтмәсен. Кара әле, туганым, син әйткәч, исемә төште әле. Шул сезнең баегыз хаҗины бер көннәрне урамда күрдем. Ябыккан, җөнчелгән, битләре салынып, җыерчыкланып беткән, корсаклары тәмам шиңгән. Көчкә генә таныдым. Үзе танып эндәшмәсә, гомеремдә дә таный алырлык түгел. Ул өс-башының һичбер элә-танагы юк. Электәге корсагын киереп йөргән чакларының исе дә калмаган.

Хатын. Октябрь бәйрәмендә амнистия булгач, кайткан икән дип ишеткән идем, үзен күргәнем юк. Ишан хәзрәтенең фатихалары файда бирмәгәнмени?

Хәйри. Ишаннарның догалары кабул була торган булса, алар иң элек үзләрен коткарырлар иде. Йөргәннәр шунда безнең шикелле надан халыкларны алдалап. Барысы да безнең шикелле халыкларны кулларына эләктерер өчен тозак кына булган.

Хатын. Ишаннарыннан, муллаларыннан башка да бик яхшы торабыз әле. Әхмәдине ябарга алып киткән көннән бирле, үзләренең төсләрен дә күрәсем килми. Бәддога дип авыз күтәреп йөргән булдылар. Нигә төшми хәзер каммунисларга бәддогалары? Ә ярлылар каргышы аларның үзләренә төште.

Хәйри. Шулай, шулай, туганым. Ярый, кайтыйм инде, үзең дә безнең якларга барып чык.

Хатын. Куй юк сүзләреңне. Авызыңны да ачма. Самавырым да булган. Әллә нигә бер килеп чәй дә эчми китәргә! Авызыңның бәхете бар икән әле, ударный паек алган көнгә туры килдең. Менә хәзер аш та салып җибәрәм, аш ашап китәрсең.

Хәйри. Оят булыр ич алай.

Х а т ы н. Юк, юк, ояты-фәләне дә юк. Үз кеше бит син, ояты булырга.

Әхмәди керә.

Ә х м ә д и. Һу! Кадерле кунак бар икән. Исәнме, Хәйри! Исән-сау йөрисеңме?

Х ә й р и. Шөкер әле, бертөрле генә йөреп торам. Безнеке инде, Нөркинеке бер көе дигәндәй, һаман да бер көе инде. Менә сезнеке ул бик шәбәйгән. Фатирыгыз да бик якты, бик иркен икән.

Ә х м ә д и. Зарарсыз. Хәзер бит власть үзебезнеке. Түлке ударный бригада башында торгач, бер дә эштән бушап булмый. Бригаданы артта калдырасы килми. Тырышасың.

Х а т ы н. Әле соң син бүген ничек иртә кайттың? Минем аш та салынмаган. Капиратифта чират бик күп булды, аш салырга өлгерә алмадым. Хәзергә чәй генә эчә торырсыз инде.

Ә х м ә д и. Чәй булгач, ярый. Кайда, чәеңне китер дә, эчеп китәргә кирәк. Канфиринсиягә барасы бар. Делегат итеп сайладылар. Ашны кайткач ашармын.

Х а т ы н. Ярый алай булгач. Менә эчә торыгыз алайса.

Ә х м ә д и. Сезнең тирәгә бер дә бара алган юк. Сабир ни эшләр бетереп йөри. Бер дә ул тирәләргә барып чыга алган юк.

Х ә й р и. Безнеке инде шул, Нөркинеке бер көе дигән шикелле, йөреп тора шунда.

Ә х м ә д и. Ярый. Менә хәзер безнең яңа фабрик өлгерде. Әгәр дә керергә теләсә, аңарга да урын табылыр. Хәзергә көндә бит эшчеләр кадерле.

Х ә й р и. Әйе шул. Чыннан да яхшы булыр иде. Болай гына торып, бер дә рәтле эш чыгарып булмый. Эшләгәне ашарына да җитми.

Б а й (*ишек шакылдатып, тыштан*). Әхмәди шушында торамы?

Ә х м ә д и. Кем бар анда? Ишек ачык, керегез.

Бай керә.

Нихәл, бабай, ни йомыш?

Б а й. Мин бигрәк картаеп киттем, өс-башлар да начарланып китте, таный алмассыз да шул. Мин хаҗи абзагыз булам. Сөргендә йөреп, шул хәлгә калдым.

Ә х м ә д и. Чыннан да, һич таный алмаслык булгансыз. Әйдә, түрдән узыгыз.

Б а й. Ярар, шушында ишек төбендә генә утырсак та. Мин сиңа бик зур бер йомыш белән килгән идем.

Ә х м ә д и. Нинди йомыш?

Б а й. Үзеңә мәгълүм, безнең инде йорт-җир, мал-мөлкәт калмады. Шәйтаннан да ялангач калдырдылар.

Ә х м ә д и. Ишаннарыгыз кәраматләре белән булышлык итә алмадылармыни?

Б а й. Ул үзе дә безнең шикелле сөргендә йөреп, чыдый алмыйчы үлеп калды.

Ә х м ә д и. Кызганыч, охранкыларыгыз да ярдәм итә алмаганнар икән.

Б а й. Ул иске эшләрне искә төшермәгез инде, Әхмәди.

Ә х м ә д и. Ике ел ярым төрмә бик тиз генә онытырлык түгел ул. Әле ярый ривалютсия килеп коткарды. Ул булмаса, һаман да утырган булыр идек әле.

Б а й. Шулай инде, сөргендә йөрү безнең өчен дә бик асат булмады.

Ә х м ә д и. Эш нәрсәдә соң? Минем эшем ашыгыч, йомышыгызны сөйләгез.

Б а й. Ачтан үләсе килми. Сату итәргә сума юк. Берәр урынга каравылчылыкка керермен дигән идем. Ышанычлы берәр эшчедән кул куйдырып язу китерсәң, алырбыз, диләр. Шул. Иске эшләрне онытып, син миңа берәр язу бирә алмассың микән дигән идем. Синең һәр җирдә дә сүзең үтә, диделәр.

Ә х м ә д и. Бик мөмкин. «Ахранкага өстемнән данус ясап, ике ел ярым төрмәдә утырттыручы кеше шул булган иде» дип язып бирсәм, ярый торгандыр бит?

Б а й. Юк инде, Әхмәди, алай итмә инде син, шәйтан вәсвәсәсе белән булган эшне алай йөзгә бәрмә инде. Болай да җәзасын җитәрлек чиктек инде.

Ә х м ә д и. Ярый, без – эшче халыклар, дошманнарыбызны җиңә белгән шикелле, аларны кичерә дә беләбез. Иртәгә фабрикка барып, мине сорарсың. Фабкомнан заверять иттереп, язып бирермен. Хәзер эшем ашыгыч. (*Портфелен алып, өстенә киеп, чыгып китә.*)

Х а т ы н. Әйдә, хаҗи абзый, утыр, чәй эч. Без алай эткә дип алган үпкә-бавырлар белән сыйламабыз. Менә, килегез, атланмайлардан, шикаладлардан да җитешегез.

Б а й. Юк, рәхмәт, Хәерниса, рәхмәт. Үз эшем көчле. Тамагымнан аш үтәрлек түгел әле. Ах, дөньялар, дөньялар! Бер битен, бер артын күрсәтә! Хушыгыз. (*Чыга.*)

Х ә й р и. Дөньялар шулайрак була икән шул. Бабайлар «дөнья – калюса» дип белеп әйткәннәр. Бу көннәрне, бу хәлләрне күргәч, эчләрем киңәеп китте. Әйдә, яса, Хәерниса, тагы бер чынаяк!

П ә р д ә.

## КҮЗСЕЗ МАСТЕРЛАР (1)

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гариф (*эшләп бетергән бер пар щеткасын шакылдатып*). Менә, Гайнеттин, бу щетканы үзләрен күзле дип йөри торган мастерларның борын асларына китереп төртеп күрсәтәсе иде, нәрсә диярләр иде икән? Һәрбер тишегенә ничә бөртек щитина, ничә бөртек кыл кергәнен белә алырлар идеме икән?

Гайнеттин. Берәмләп санап карасалар, беләрләр. Син дә инде бигрәк артык мактанып җибәргән буласың. Безгәме соң күзлеләр белән тиңләшергә!

Гариф. Күзле дигәч тә, исең киткән икән күзлеләргә! Нигә аларга ис китәргә дә, нигә алар белән тиңләшмәскә? Кулдан эш килгәч мактанырсың да шул. Минем әле күзле мастерларны үзем белән ярышка чакырырга да ният бар. (*Залга төртеп күрсәтеп.*) Син менә монда, залда утыра торган күзле халыклардан сорап кара әле, алар дөньяны ничек дип таныйлар икән? Алар дөньяны безнең кармалап караган кадәр, кармалап таныган кадәр таный алалармы икән?

Сабит. Аларгамы соң таныруга?! Безнең мех фабригында сортировкада эшләүче әллә никадәр күзлеләр бар, шуларның күбесе безнең шикелле яхшы итеп сортовать итә белмиләр. Без сортовать иткәннәрнең өне өнгә, жоны җонга тигез булып килеп кенә тора. Мастерлар без сортовать иткән нәрсәләрне бик яраталар, ә күзлеләр сортовать иткән нәрсәләрне кайвакыт, бракка чыгарып, кире кайтаралар.

Гайнеттин. Күзлеләр алар мактанырга гына беләләр. Мин, матрасны капшап карау белән үк, аны күзле кешеме, сукыр кешеме эшләгән икәнен беләм. Сукырлар эшләгән матраслар мамык шикелле йомшак, ә күзлеләр эшләгән матраслар, Гарифның эшләгән щеткалары шикелле, тырпаеп торалар.

Гариф. Минем щетка шикелле түгел, Әндринең кырма сакалы шикелле диген, шадра пәри. Минем белән тиңләштереп маташкан буласың тагы. Үзеңнең борчакка егылган шикелле шадра битләреңне генә бел.

Г а й н е т т и н. Шадра, шадра, шадра, шадра йөрәк яндыра, ди. Дарым шадра булсын, шадра булса да, Гайнеттинне аны кызлар ярата, артыннан калмыйчы ияреп йөриләр, аны култыклап кына йөртәләр.

С а б и т. Син дә мактанган буласың инде шунда. Сиңа кем иярә соң? Әллә шул көйгән тире шикелле җыерчыклы битле Җәмиләң белән мактанган буласыңмы?

Г а й н е т т и н. Һи, кабак баш! Син дә кеше булган булып сөйләп утырасың шунда. Җәмиләнең бите җыерчыклы икәнен син каян беләсең? Әллә аны капшап карадыңмы?

С а б и т. Беркөн коридорда үзе килеп бәрелде дә, әллә минем Зөбәйдәмме икән дип, битен сыйпап караган идем, шунда белдем.

Г а й н е т т и н. Миңа килгәндә ул тутырган тавык шикелле иде, суңыннан бала тапканга гына шулай йөнчелеп китте.

Г а р и ф. Хәзер йөнчелсә дә гаеп итеп булмый, заманалар авыраебрак китте, ашау җитми. Моннан бер-ике ел элек баскычтан менгән вакытларда аяк астында баскычлар шыгырдап торадыр иде, ә хәзер баскычның тыны да чыкмый.

Г а й н е т т и н. Ашаулар такыраебрак китте шул. Кыйбатчылыкның артыннан һич тә куып җитәр хәл юк. Ял көннәрендә дә ял итмиче сдельни эшләргә туры килә. Ял бер дә юк, шул ябыктыра. Зарар юк, икенче бишьеллыкны яхшы гына башкарып чыксак, иркенәербез әле. Мин элек, Герман сугышына кадәрле, типсәм тимер өзәрлек, кып-кызыл, нарат яркасы шикелле яныл торган бер җегет идем, Герман сугышында гына газ белән агуланып, шулай сукыраеп, какшап калдым.

С а б и т. Ие, шул патшаларның бүләкләре безгә бик кыйбатка төште.

Г а й н е т т и н. Кыйбатка төшсә төште, аның каравы безнең эшләр дә яхшы пеште. Революция аркасында патшалары чәнчелеп, кадалып китеп, җәһәннәмнәренең төбенә барып төште. Совет хөкүмәте төзелмәгән булса, без әле һаман да күпер төпләрендә теләнеп утырган булыр идек. Хәзер бары тик безнең илдә генә сукырларны кешегә саныйлар. Капиталистлар илләрендә этләргә сан бар, сукырларга һичбер сан юк.

С а б и т. Сукырларга дисең син, сукырларга түгел, аларда күзле, таза эшчеләргә дә сан юк. Дөньяның иң алга киткән мәмләкәтләреннән саналган Америкада да ничә миллионнар, общий алганда барлык капитал илләрендә илле миллион кадәр эшчеләр эшсез калып ачыгалар, ә безнең Советлар илендә, кайда кара[саң] анда, кирәк производ-

ствода булсын, кирәк төзү эшләрендә булсын, эшче куллар җитми.

Гариф. Син дә үз гомереңдә бер дөрес сүз сөйли белерсең икән.

Гайнеттин. Әле беркөннәрдә генә гәзиттә укыдылар: бездә эшче куллар җитмәгәнгә күрә, барлык инвалидларны да, сукырларны да, кулларыннан нинди генә эш килсә дә, шундый эшкә кушып, алардан файдаланырга, һөнәрләре булмаганнарны нинди булса да кулларыннан килерлек берәр төрле хезмәткә урнаштырырга кушылган.

Сабит. Ә кызылармиеслар турында нигә бер сүз дә әйтмисең? Электә, патша заманында, солдатлар әрәмтамак булып, ашап кына яталар иде. Ә хәзерге заманда кызылармиеслар төрле производстволарда – урман хәзерләү, корткычлар белән көрәшү эшләрендә алгы сафларда эшләп, илебезнең алга китүенә булышлык итәләр.

Гайнеттин. Әле алар беренче бишьеллыкта гына шулай, икенче бишьеллык тулганда, Совет илен бөтенләй танымаслык булыр әле. Ул чагында сукырларны таный да алмассың әле. Хәзерге көндә дә әле сукырлар күп эшләрдә күзлеләрдән калышмыйлар. Әнә Мәскәүдә электр кирәкләре эшли торган фабрикларда, магнит катушкалары чорнау эшләрендә, безнең сукырлар иң беренче, алдынгы мастерлардан саналалар.

Гариф. Икенче биш ел тулганда, совет медицинасы аркасында сукырларны көндез кулыңа шәм яндырып эзләсәң дә таба алмаслык булыр әле. Ул вакытларда безне: «Сукырлар менә шундый була ул», – дип, күргәзмәләргә куеп күрсәтеп йөртерләр әле.

Гайнеттин. Сукырлар күргәзмәсе ясап, сине күргәзмәгә куйсалар, мин үземнең малайны сине карарга җибәрермен. (*Пауза.*) Менә матрас та эшләнеп бетте. Их, йомшаклыгы да йомшаклыгы! Мамык түшәгең бер якта торсын, сатарга да кызганырлык! Әллә булмаса, Җәмилә апагыз белән йокларга үземә алып каласы инде?!

Гариф. Бик йомшак, җылы булгач, Җәмиләң эреп акмасын.

Гайнеттин. Бер дә акмас.

Тышта гармун уйнаган тавыш ишетелә.

Әһә! Минем эш бетүгә, Әхмәди дә килеп җитте. Радионың хәбәрен салды. Бик шәпләп әйттереп тә алабыз икән.

Әхмәди керә.

Әхмәди. Исәнмесез, жегетләрнең асыллары! Сәлам бирдем бит, нигә алмадыгыз?

Г а р и ф. Кайчан бирдең?

Ә х м ә д и. Нигә, гармунны кычкырттым бит, ишетмәдегезмени? Без бит хәзер сүзне авыз белән сөйләмибез, гармун белән генә әйттерәбез.

Г а й н е т т и н. Әйдә, бик вакытлы килдең. Син килүгә ударник Гайнеттин абзаң эшен дә бетереп куйды. Күңелләр боегып торадыр иде, бераз ачылып китәр.

Ә х м ә д и. Минем күзләр шикеллеме?

Г а р и ф. Синең күзләр ачыкмыни?

Ә х м ә д и. Ачык булмый ни, ачык шул. Безнең шикелле профессор кешегә: «Ачык күзле кеше», – диләр бит.

С а б и т. Нәрсә профессоры?

Г а р и ф. Нәрсә профессоры булсын, билгеле инде, икмәк черетү профессорыдыр.

Ә х м ә д и. Бер дә алай түгел әле, гармун профессоры. Абзаң әле ул, бүген монда килгәнче, шул гармуны белән бер-ике червонесны эшләп алды әле ул. Бүген общий ял көне булганга, халык күбрәк җыелып тыңлап тора. Ике червонес ярап тора ул, ул акчаны бит ни җитте профессорлар да таба алмыйлар.

Г а й н е т т и н. Алай булса, әйдә, менә бирегә, минем янга кил. Профессор кешегә урын бирергә кирәк. Профессор булгач, даруыңны алып килдеңме соң?

Ә х м ә д и. Ансыз ярыймы соң. Син дусның авыруына да дару тапмагач, ул аннан ары профессор буламыни? (*Кесәсеннән ярты литрны чыгарып.*) Мә, менә, тот, менә дигән кырык градыслысы, ышанмасаң, әнә язуын да укып кара, өстенә ретсибе дә ябыштырылган. (*Икенче кесәсеннән кәгазьгә төргән закускалар чыгарып.*) Ә менә булары дару артыннан кабарга – пилүлиләр.

Г а р и ф. Гармун уйнауларыгыз, җырлауларыгыз – алары бик күңелле эш, тик шул агуны эчүегез белән генә эшне изәсез.

Г а й н е т т и н. Һи, сафсата нәрсә! «Суфи суган сөймәс, күрсә – кабыгын да куймас» ди. Үзеңнең ташлаганыңа күптәнме соң әле?

Г а р и ф. Шулай дип әйтерләр әле, дигән идем аны. Гомереңдә бер генә тапкыр ялгышсаң да, хәзер йөзеңә бәрергә генә торалар.

С а б и т. Эчсәгез эчәрсез, җегетләр, анысыннан тыярга минем кулымнан килми, тик бик күп эчеп, исереп, беркөнге Степаннар шикелле, тавыш кына чыгара күрмәгез, яхшы түгел.

Г а й н е т т и н. Алар бит хатыннарыннан көнләшеп кенә шулай тавыш чыгардылар. Ни чыкмаса, алар аркасында чыга. Безнең монда хатын-кызлар юк әле.

Ә х м ә д и. Күпер төбендә көне буена гармун уйнап утырып, туңып, катып беттем. Аз гына ул, тамак чылатырлык, кул җылытырлык кына.

С а б и т. Алай булса гына ярый.

Г а й н е т т и н. Җә, ярый, ул ишанның сүзенә карама. (*Шешәнең төбенә сугып ачып, стаканны алып.*) Мин бүлимме, үзең бүләсеңме?

Ә х м ә д и. Сине, мине юк инде, тот та бүл инде шунда. Син спикүләнт түгелсеңдер бит, алдамассың. Спикүләнтләр генә бит алар: «Сукыр белмәс әле», – дип алдаларга маташалар. Беркөнне берсе шулай базарда күлмәк алганда: «Беренче сорт сатин», – дип, бәздән теккән күлмәкне теттереп алдап ята. «Сатинмы?» – мин әйтәм. «Сатин», – ди. «Сатинмы?» – мин әйтәм. «Сатин», – ди. «Сатин булса, мин синең үзеңне сатыйм!» – дигән идем, спикүләнтең шып булды!

Г а й н е т т и н. Үзенең дә күзләре шар булгандыр. (*Аракыны стаканга бераз сала да, шешәне колак төбенә китереп, селкеп карап.*) Мә, тот, нәкъ яртысы булган.

Ә х м ә д и. Кая әле, шешәңне бир әле, дөрес әйтәсеңме икән? (*Шешәне алып, колак төбенә китереп, селкеп карап.*) Молодец! Колагың нәкъ минеке чаклы ук күрә икән. Җә, әйдә, исәнлеккә-саулыкка! (*Эчә, закускасын каба.*) Туптуры табан астына кадәр төшеп китте.

Г а й н е т т и н. Җә, инде мин дә тәмен татып карыйм. Тәме үзгәрмәгәнме икән? (*Салып эчә.*) Юк икән, үзгәрмәгән икән, нәкъ әрем әчесе шикелле.

Ә х м ә д и. Шуңар күрә дә аны бер вакытларны «Русская горькая» дип йөриләр иде.

Г а й н е т т и н. Инде өстеннән казылык белән томалап та куйыйк, тыны чыкмасын. (*Казылык ашый.*) Чыннан да бик шәп булып китте бу, малай! Җә, инде хәзер гармуныңны да тартып җибәр.

Ә х м ә д и. Анысыннан эш калмас. Син үзең дә мәгънәсен әйтә бар.

Г а й н е т т и н. Була ул.

Әхмәди бер кат уйнап чыга.

(*Җиңелрәк авыл көенә җырлый.*)
Күзле, күзле, күзле кеше,
Күзлеләр дә сөртенә.
Көзге каршысына басып,
Иннек, кершән сөртенә.

Без, күзсезләр, килеп чыктык
Бүген сезнең каршыга.

Мин сиңа җыр җырлап бирим,
Син кул чабып каршыла.

Күзең ачык, күзең ачык,
Китмә сукырдан качып.
Сукыр мастерлар хәленә
Карагыз күзне ачып.

Өйрәнмәсәк без һөнәр,
Тавык, чебеш тә көләр.
Дөньябызны төзәтмәсәк,
Калырбыз булып җүләр.

Галия, Сәкинә, Әхмәт кереп тыңлап торалар.

Эшлә, укы һәм тырыш,
Язу танымый калма;
Надан калып, теләнеп йөреп,
Китә алмабыз алга!

Җә, нихәл, шулай ярыймы? Чиерттерәме Гайнеттин абзагыз борыныгызга?

Галия.
Сәкинә. } Браво, браво, браво! Маладис!
Әхмәт.

Әхмәт. Маладис, Гайнеттин абзый! Бик шәп, искиткеч шәп!

Гайнеттин. Шәп диген, ә? Шәп булмаска, Гайнеттин абзыең үзе чыгарган җырлар ла алар.

Галия. Шулаймыни? Син шулай шигырьләр дә чыгара беләсеңмени?

Гайнеттин. Мин сезнең шикелле шигырь-мигырьләр чыгара белмәсәм дә, бераз шулай бәетләр язгалый беләм. Яшь вакытта, сезнең шикелле кызларга хат язган чакларда, хатка бәетләрне үземнән чыгарып язадыр идем. Соңыннан, күз күрми башлагач кына, тукталып калган идем, хәзер инде, татарлар өчен сукырлар әлифбасы чыгарылгач, тагы яза башладым.

Сәкинә. Маладис, Гайнеттин абзый, маладис! Җә, тагы җырлагыз әле, без дә ишетик.

Гайнеттин. Ярар, җырларбыз. Нәрсәгә анда ишек төбендә генә басып торасыз, утырыгыз!

Утыралар.

Туташлар сорагач, җырламый булмас инде, Әхмәди, уйнап җибәрерсең инде, җырламый ярамас, тик бер шартым бар: мин җырлаганнан соң, сез дә җырларсыз. Мин кызлар җырлаганны бик яратам, яшь вакытлар искә төшә.

Г а л и я. Җырларбыз, җырларбыз. Сәкинәнең дә үзе чыгарган җырлары бар, ул да җырлап күрсәтер.

С ә к и н ә. Әй, минеке җыр түгел лә ул, әллә нинди мөнәҗәт шикелле булып чыкты.

С а б и т. Булсын, мөнәҗәт шикелле булсын. Без яшь чакта, авылда шәкертләр мөнәҗәтләр укып, наврузлар әйтеп йөриләр иде, бик күңелле буладыр иде, хәтта карчык-корылар кызганып җылыйлар иде.

Г а р и ф. Анысы ул кадәресен без җылый алмабыз ла инде.

С а б и т. Алай димә син. «Чынлап, чынлап җылагач, сукыр күздән дә яшь чыга», – диләр. Мин кешенең җылаганын-җыламаганын белмим, әмма мин үзем җылыйм.

Г а й н е т т и н. Җә, әйдә алайса, Әхмәди, уйнап җибәр, тик карагыз аны, соңыннан үзегез дә җырларлык булсагыз гына җырлыйм.

Г а л и я.<br>С ә к и н ә. } Җырлыйбыз, җырлыйбыз.

Г а й н е т т и н. Әйдә, Әхмәди, уйна алайса.

Ә х м ә д и. Була ул. (*Уйный.*)

Г а й н е т т и н (*җырлый*).

Без барасы юлларның
ике чите канаулы,
Дөньяда безгә якты юк –
күзләребез ямаулы.

Безнең урам тар урам,
чокыр-чакыр юл гына,
Без ашыйбыз да эчәбез –
безгә рәхәт шул гына.

Ә х м ә т. Менә монысы бер дә ярамый инде, Гайнеттин абзый. (*Иснәп.*) Чыннан да, монда сезнең аракы исе килә. Ул эшегез бер дә ярамый инде.

Г а й н е т т и н. Юк, ул болай гына, аз гына, эшләп арыгач, бераз сөяк-санакны йомшатып җибәрер өчен генә. Бердән, ардыра, икенчедән, бүген – ял көне. Аның каравы без бүген ял итмәдек.

Г а р и ф. Мин дә әйткән идем, ярамый, килешми, дип, Әхмәди алып килгән бит.

Ә х м ә т. Әхмәди абзый, ул эшең бер дә ярамый инде. Үзең эчү дә бер дә килешми, кешене эчертүең бигрәк тә. Син бит инде олыгайган, картайган, әллә ничә бала-чага атасы булган. Анда, өеңдә, бала-чагаларың ач утыра торганнардыр.

Ә х м ә д и. Дөрес әйтәсең, Әхмәт, сүзләрең дөрес, тик менә йөрәк яна. Иптәшләрнең барысы да эштә, рәхәтләнеп

көн күрәләр, кулларыннан эш килә, барысы да укый-яза беләләр, һөнәрләре бар, ә минем нәрсә рәхәтем бар да, нәрсә куанычым бар? Элекке заманнарда, патшалар вакытында, безне укытмаганнар, укытсалар да, урысларны гына укытканнар, богадилнәгә дә без татарларны алмыйлар, бары тик урысларны гына алалар иде. Безгә шул күпер төпләрендә соранып утырудан башка эш калмады. Көне буена йөзеңне җыртып, соранып утырасың-утырасың да, үзеңнең бәхетсезлегеңне исәпләп, эчләр поша башлый, эчеңә кайгы-хәсрәтләр урнаша, шуннан соң шул эчү белән генә бераз кайгы-хәсрәтләрне җуйган, күкрәгеңә урнашкан катуларыңны бераз йомшарткан шикелле буласың.

Ә х м ә т. Нигә кирәк алай өметсезләнергә? Нигә кирәк алай борчылырга? Менә без дә бит барыбыз да синең шикелле үк күзсезләр, шулай булса да, бер дә алай синең шикелле өметсезләнмибез, киләчәккә зур өметләр белән карыйбыз.

Ә х м ә д и. Сезнең – шулай, һәм шулай булырга тиеш тә. Сез бит яшьләр, сез укыйсыз, сезнең эшләрегез алга бара. Киләчәктә сезне зур бәхетләр, рәхәтләр көтә. Сез укып бетерерсез, зур кеше дә булырсыз, рәхәт гомер дә күрерсез, ә мин нәрсә, мин бит дөм сукыр, укый-яза да белмим, башка күзсез иптәшләрнеке шикелле, минем кулымнан бер эш тә килми, шул гармун уйнап, теләнеп тамак туйдырудан башка минем һичбер төрле һөнәрем дә юк. Мин соң шуннан башка нәрсәгә генә ярыйм? Мин бит чүплек башына чыгарып ташланган, һичбер төрле дә эшкә ярамый торган бер чүп кенә.

Ә х м ә т. Юк, Әхмәди абзый, син ялгышасың. Син чүп тә түгел, утиль дә түгел. Хәзерге көндә һәртөрле утильләрне дә эшкә яраталар. Син тот та, ул күпер төпләрендә соранып, теләнеп утыруларыңны бер якка ташлап, безнең арага кил. Безнең арада сиңа яраклы эшләр табылыр. Картайган булсаң да, әле син бөтенләй кулыңнан бер эш тә килә алмаслык кеше түгел. Эшкә тотынгач, өметсезләнүләрең дә бетәр, күңелләрең дә күтәрелер. Күңелең тыныч булгач, кайгы-хәсрәтләрең дә басылыр.

Ә х м ә д и. Алай булса бик яхшы булыр иде кана, мин шул бер дә башка төрле эш белмим. Яшь чагында да мин бит җәен көтү көтеп, кышын байларның ат абзарларын көрәп гомер иткән кеше. Бернәрсә дә белмим.

Ә х м ә т. Нигә белмәскә, бик шәп беләсең. Ничек тә синең көтү көткәндә чабата ясаганың, чыбыркы, киндерә үргәнең бардыр?

Ә х м ә д и. Анысы бар. Чабата ясарга яхшук оста идем, мин ясаган чабаталарны яраталар да иде, ләкин, күзем сукырайганнан бирле, бер дә ул эшләрне тотканым булмаганга күрә, онытылып беткәндер инде.

Ә х м ә т. Әнә барсын, син дигәнчә дә булсын, анысы да онытылган булсын, сиңа аннан башка да эш табылыр. Менә безнең бу мастерскойда матраслар эшләнә.

Г а й н е т т и н. Ие шул, менә әле күптән түгел генә бик шәп йомшак матрас эшләп бетереп куйдым, нәкъ мамык шикелле.

Ә х м ә т. Шулай. Гайнеттин абзыйлар матрас өчен мунчаланы үзләре тетеп, йомшартып утырып, әллә никадәр вакытларын әрәм итәләр. Ә мунчала тетәргә генә синең кулдан килә. Чабата эшләгән кеше булгач, күзләрең күрмәсә дә, син шул эшләрне булдыра аласың. Син, мунчала тетеп, аларга булышсаң, эш тизрәк барып, мастерскойның эш чыгаруы да артыр, шуның аркасында синең дә тамагың тук, өстең бөтен булыр, хатының, балаларың да ач, ялангач булмаслар, өеңдә хатыныңның да сиңа күз караулары үзгәрер, тыныч яшәрсең, шуның аркасында эчүләрең дә ташланыр, күпер өстендә суыкта катып, туңып та утырмассың. Үзеңне укырга-язарга да өйрәтербез, китаплар укый башлагач, күңелләрең дә ачылыр. Җә, шул мунчала тетәргә риза буласыңмы?

Ә х м ә д и. Анысы мунчала тетү генә кулдан килер, тик менә укырга өйрәнүе генә кулдан килерме икән?

Ә х м ә т. Һич тә хафаланма, килер. Ике-өч ай эчендә сине укый-яза белә торган кеше итәргә үзем өстемә алам. Менә, бәлки, Сәкинә туташ белән Галия туташлар да миңа булышырга сүз бирерләр. Җә, туташлар, сез ни дисез, сүз бирәсезме?

Г а л и я. Бик шатланып.

С ә к и н ә. Һичбер сүзсез!

Ә х м ә д и. Рәхмәт, алайса, сезгә, сеңелләрем, энекәшләрем! Алай булса, мин дә сезгә сүз бирәм: бүгеннән соң эчү дә юк, теләнү дә юк! Күпер төпләре күзле ялкауларга калсын. Күңелне күтәреп җибәрдегез, кайтам да хатыннан сөенче алам, ул да шатланып җибәрсен. Шатлыктан бер уйнап та җибәрим әле.

Ә х м ә т. Билгеле, шулай кирәк. Әйдә, Сәкинә иптәш, син дә үзеңнең чыгарган җырларыңны җырлап җибәр. Сезнең ишеткәнегез юктыр әле, Сәкинә иптәш бик шәп итеп үз тормышыбыздан җырлар язган.

Г а р и ф. Минем дә күңелне җилкетеп җибәрдегез, мин дә җырлыйм әле.

С а б и т. Чүегез, алай булгач, булган-булган, ботка булсын дигәндәй, әйдә, барыбыз да бергә кушылып җырлап җибәрик?!

С ә к и н ә. Алай булса, менә нәрсә, мин җырның башын

җырлыйм, ә сез барыгыз да ахырына кушылыгыз. Менә мин шушылай дип башлыйм:

Ике суның уртасында
Безнең Казан каласы.
Уку белән кеше була
Барлык адәм баласы.

Сез, шуңар кушылып:

Ие шул, шулай шул,
Барлык адәм баласы, –

дип, ике кат җырларсыз. Аннан соңгы җырларда тагы шулай – җырның ахыргы бүлеген икешәр тапкыр бергә кушылып җырларсыз.

Г а й н е т т и н. Булды гына! Әйдә, башла, Әхмәди, тарт гармуныңны!

Ә х м ә д и. Була ул!

**Тон биреп, бер кат уйнап чыга. Нинди көйгә җырлау – анысы катнашучыларның үзләренең сайлауларына калдырыла.**

С ә к и н ә. Ике суның уртасында
Безнең Казан каласы.
Уку белән кеше була
Барлык адәм баласы.

Х о р. Ие шул, шулай шул,
Барлык адәм баласы. } (*2 тапкыр.*)

С ә к и н ә. Казан каласы таш кала,
Күп калага баш кала.
Менә дигән көн итәбез
Ике күздән башка да.

Х о р. Ие шул, шулай шул,
Ике күздән башка да. } (*2 тапкыр.*)

# БЕРЕНЧЕ ТЕАТР

*Оперетта өч пәрдәдә*

(Шул ук исемдәге бер пәрдәлек комедиядән үзгәртеп язылды.)

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘДӘ УЕНГА КАТНАШУЧЫЛАР:

Хәмзә бай – иске фикерле Казан бае, Печән базары сәүдәгәре; башында ак бүрек, бүрек астыннан кырые күренеп тора торган яшел хәтфә кәләпүш, өстендә читенә кама тоткан дарчин төсендәге озын «намаз туны», аның эченнән яшел төстә җалаулы бикасап бишмәт, аның эченнән җиңе ярты беләккә төшеп тора торган яшел бикасап камзол, аның эченнән итәге тез башына җиткән ак күлмәк кигән. Чалбары тубыктан югары, аның балагын җыеп ак тасма белән бәйләгән, аягында кустарь эше зур ак киез итек; агара башлаган кәҗә сакаллы, кырт кискән чал мыеклы, ач яңаклы, саваплы булу өчен күзенә сөрмә тартып йөри торган 60 яшәрлек бер кеше.

Сәләхи – Хәмзә байның нәкъ үз тибында, шундый ук иске печемдә кама якалы, соры төстә пустау тышлы тун, аягына шулай ук ак киез итек, башына кама читле тәвәккәл бүрек кигән, билен пута белән буган карт приказчигы. 40 яшьләр чамасында, коңгыр, кечкенәрәк сакаллы кибетчесе.

1 нче Низами хаҗи – нәкъ Хәмзә бай тибында; бар нәрсәсен Хәмзә бай кибетеннән алып, аның белән берочтан киенә торган (нәкъ Хәмзә бай тибында, аермасы бары өстендәге зәңгәр постау тышлы, каплаулы якалы билле туны белән башындагы зур каракүл бүрегендә генә) мануфактурачы бай; Хәмзә байның аерылмас дусы һәм сердәше; Хәмзә бай яшьләрендә.

Кара савыт Таҗи – шкафчы, бүрекче карт.

2 нче Низами хаҗи – шулар тибында ук; билен пута белән буып, өстенә камалы тун, башына зур каракүл бүрек кигән; кырт кискән мыеклы, сирәк сакаллы, бер кулына бүрек, икенче кулына пачас себерке тотып, бертуктаусыз бүреген себереп йөри торган 30 яшьләр чамасындагы, Хәмзә бай һәм аның дусларына ихлас багълаган бүрекче.

Алып Шаһи – нәкъ шулар тибында, ләкин өстенә төлке якалы төлке толып кигән; күпләп сатучы мануфактурачы, Хәмзә бай кордашы, кечкенә сакаллы, йомыграк күзле кеше. Хәмзә байның чәйдәше.

Хафиз – Хәмзә бай кибетенә каршы чатта, мәчет астында, шкаф-

---

Дарчин – тропикада үсә торган лавр сыман агач.

Бикасап – Шәрекътагы ярымефәк тукыма.

Иске печемдә – искечә киселгән.

Пачас (*рус. подчёс*) – чүбек.

та төрле төймәләр, тәсбихләр, кәләпүшләр, гатыршаһ, дарчин майлары, тубалаклар, әфиун һәм башка москатил нәрсәләре белән сату итүче, дөньяда охшашы килмәгән иске фикерле, ләкин бик мәзахчән, Коръәнне күңелennән бикләгән, кайбер аятьләрнең мәгънәләрен дә белә торган, җыен фанатик татарларны үз янына җыеп, бертуктаусыз яңача укучыларны сүгеп яши торган бер шкафчы.

Гайфетдин хаҗи – кәләпүш һәм калфаклар эшләтеп, шулар белән күпләп сәүдә итүче, шәһәрдә ике җирдә зур таш пулатлы бай.

Садыйк бай Хәйруллин – читекче сәүдәгәр.

Шакир хаҗи – читек-кәвешче, тәбәнәк гәүдәле, чиктән тыш юан корсаклы, второй гилди купец.

Дуду Шакир – Печән базары байларына гәзит укып, мәгъҗунләп көненә кырыгар чынаяк чәй эчеп, пәрәмәч ашап тамак туйдырып, семьясын гәзит укыганын тыңлап утыручы Печән базары халкыннан, язу танымый торган Печән базары сәүдәгәрләреннән җыйналган акчалар белән туйдырып яшәүче, байлар тәрилкәсен ялаучы, кибетчеләр арасында шымчылык итеп, алар өстеннән байларга донос ясап йөрүче, кыска буйлы, гадәттән тыш зур башлы, Гарәбстаннан килгән бәдәлче гарәпләргә тылмачлык һәм маклерлык итеп яшәүче, киң якалы драп чикмән киеп, бөрешеп йөрүче гайбәтче, әләкче бер кеше.

Иргали хаҗи – башын шарф белән урап, аның өстеннән фәс киеп йөри торган аксак аяклы бер хаҗи.

Җамали унтер – күкрәгенә алтын һәм көмеш медальләр таккан, Казан байлары белән бик әшнә һәм дус булып аларгаерактан ук күкрәгенә кулын куеп сәламнәр биреп, мәчеткә намазларга кереп, байларга мәҗлесләргә йөреп, бәйрәмнәрдә аларда бәйрәм чәйләре эчеп, бәйрәм чәйлекләре җыеп, ул вакытның «шөбһәле» яшьләре өстеннән «начальство»га донослар ясап йөрүче, 3 төймәле унтер градовой.

Гыйльман хаҗи – мануфактурачы, ак сакал.

Галәү – аның доверенные, сары сакаллы, камалы туннан, фанатик.

Толпа – кулдан йөртеп сатучы кәләпүшче, бүрекче, мехчы, читекче, кәвешче, лимончылар, мәчет чатында бәдәлче гарәпләр, шәһәр һәм авыл халыклары.

Сәхнә: Казан шәһәренең Печән базары уртасы. Тамашачылар ягыннан караганда, сул якта беренче планда – Печән базары мәчетенең алды; аннан үткәч – кибет аллары, бөтен тротуар өсте капланган зонт сузылып китә. Зонт өстендә әллә никадәр алтын-көмеш медальләр рәсеме төшерелеп һәм кәләпүш, калфак рәсемнәре төшерелеп эшләнгән, озын булып сузылып киткән Гайфетдин хаҗи Сәгыйтов вывескасы. Эчтә кибет ишекләре күренә. Уңда – Кара савыт Таҗиның шкафы, аннан ары «Гыйльман Кәбиров» дип, аннан ары «Хәмзә Хәйруллин» дип, аннан ары тагы шуңа охшашлы вывескалар. Еракта, уң якта, ак мәчет манарасы күренә. Кыш көне, вакыт иртә, сәгать уннар чамасы. Базар кызып җитмәгән, мәчет алдында гарәпләр һәм сәдакачылар. Хәмзә бай кибете алдында – Гыйльман хаҗи, 1 нче Низами хаҗи, Алып Шаһи; Шкафчы Хафиз алдында – Дуду Шакир, Иргали хаҗи прилавкага сөялеп, сөйләшеп торалар.

---

Гатыршаһ – ислемай, хушбуй.

Тубалак – күз тимәсен дип балаларга тагыла торган агач төймә.

Москатил – вак товар.

Мәзахчән – мәзәкчән.

Мәгъҗун – мәк орлыгы, әфьюн катнаштырылган наркотик әйбер.

Бәдәлче – ялланып хаҗга баручы.

Унтер градовой (*городовой*) – полиция кече офицеры.

Х ә м з ә. Шаһиның бая сез килгәнче минем Хәбибрахманга әйткән бер сүзенә бик кәефем килде әле.

1 н ч е  Н и з а м и  х а җ и. Шаһи хаҗи сүзгә булдыра ул, безнең шикелле күчән авыз түгел ул, сүзне бик ераклардан алып, бик вәземләп сөйли ул. Нәрсә ди, нәрсә ди?

Х ә м з ә. Хәбибрахманны янына чакырып китерде дә аның кай җирен килештермәгәндер: «Энем, Хәбибрахман, – ди, – Шаһиның улы Шаһи кадәр булса, җитә, артык булуы кирәкми. Шулай ук Хәмзәнең улы Хәбибрахман да Хәмзә кадәр булса, җитә, – ди, – артык булуы кирәкми»,– ди.

1 н ч е  Н и з а м и  х а җ и. Әйтәм бит, ул әйтер ул дип.

Ш а һ и. Аны шуннан китереп әйттем аны, бая мин кибеткә төшкәч тә, улым Гаптелгаллям: «Күрше Сибгатулла хаҗиның уллары яңа чыга башлаган «Казан мөхбире»[1] гәзитен яздырып ала башлаганнар, без дә алдырасы иде», – ди. Шуңар бик ачуым килде. Гәзит укып зур эш кырдылар инде, мин әйтәм; күкрәкләрен киереп, ике кесәләренә кулларын тыгып йөрүдән артык эшләре күренми әле, мин әйтәм. Киявенә тел тиергәч, бәлки, хаҗи яратмас инде яратмавын.

Г ы й л ь м а н. Нишләп яратмаска, туры сүзгә җан корбан, ди. Менә Хәмзә хаҗи кызын шәкерткә биреп уңды, ичмасам. Үзе укыган, гыйлем егет, дамелланың пишкадәме булып хәтме көтеб кылган кеше.

Х ә м з ә. Ул ягыннан яман түгел түгелен дә, ләкин бер дә Хафиз белән килешә алмыйлар, узган-барганда гел чәкәләшеп кенә торалар. Хафиз аның теге, ни атлы әле соң, мөселман телендә чыгарыла торган гәзит тирәсендә чуалуын бер дә яратмый. «Ул эшнең ахыры бер дә яхшылыкка барып чыкмас, мишәр Минһаҗ улы шикелле, нәчәлства каршында күздән төшүе ихтимал», – ди.

Ш а һ и. Хафиз бик дөрес сүз әйтә. Теге Ямашев Минһаҗ улын әйтә торгансыңдыр бит? Атасының байлыкларына илтифат итмичә, бай улы була торып, канлы ыштан балаклары күтәреп йөрүче азган-тузган эшчеләр артыннан ияреп йөрү бер дә ярый торган эш түгел.

Г ы й л ь м а н. Малайның бәхете бар икән әле, атасын дус күрү аркасында Җамали унтер, эшне алдан сизенеп, эшне атасына акрын гына тишкән. Атасы да үткен кеше

---

В ә з е м л ә п – җиренә җиткереп, көйләп-бизәп.

Д а м е л л а н ы ң  п и ш к а д ә м е – мулланың олы шәкерте.

Х ә т м е  к ө т е б  к ы л у – мәктәп (*мәдрәсә*) тәмамлау.

К а н л ы  ы ш т а н  б а л а к л а р ы – кызыл әләмнәрне мыскыллап әйтүе.

бит, улы ни атлы соң әле, Чистай мишәре кияве, ә, Хөсәен атлы бугай, базарга чыгартып, чирмештән бер алап күмер алдырган да, күмерне бушаттырып, Хөсәенне алапка салып, өстенә салам каплап, тиз генә малайны шылдырганнар. Тайный политсә артыннан ук килеп җитсә дә, малайдан җилләр искән.

Хәмзә. Җамали унтерның андый яхшылыклары бар аның. Ничә әйтсәң дә, үз кеше, мөселман кеше!

Шаһи. Мөселманлыкка Сафа унтер да мөселман кеше дә бит, бер дә алай түгел.

Гыйльман. Ул кая да, бу кая! Шуңа күрә дә ул мөселман агай-эне арасына бик сыя алмый.

Хафиз (*үз янына җыелган төркемгә*). Шулай, хаҗи, изге-мөбарәк илләрдән килгән хаҗилар, үзебездәге мөбарәк ишан хәзрәтләр, карт хәзрәтләр, галим-голәмаләрнең хәер-догалары бәрәкәтендә генә бераз кеше шикелле булып яшәп киләбез, юк исә ул каһәр төшкән ысул язит галәйһиннәгъләчеләр белән имансыз-динсез, госелсез студиннәр, тар балак, камфурка бүрекле шкулникләр, яннарыннан тәрәткана исе аңкып тора торган рабучиләр кулына калсаң, Алла сакласын, дөньяда торуыңнан тормавың мең өлеш артык. Зарар юк, падишаһе әгъзам хәзрәтләре күп шаяртмас, койрыкларына тиз басар. «Бу дураклар нәрсәгә җилкенәләр икән?» – дип сынап кына тора торгандыр әле.

Иргали хаҗи. Шулай, шулай, хәлифәи руи зәмин, солтан әгъзам Габделхәмид[2] хан хәзрәтләре...

Гарәпләр. Зыйллуллаһи фил галәмин...

Иргали хаҗи. Кяфир, зиндикъ «Кәнеҗ төрекләренә»[3] берәм-берәм тоттырып, аякларына таш бәйләп, Мәрмәрә диңгезенә тончыктырды. Шуннан соң, син күр дә мин күр, барысы да койрыкларын кыстырдылар.

2 нче Низами хаҗи. Монда да шулай булыр әле, боерган булса.

---

Чирмеш – мари.
Алап – кабыктан эшләнгән зур савыт, әрҗә.
Мөбарәк – хөрмәтле.
Ысул язит галәйһиннәгъләчеләр – ләгънәтле җәдитчеләр.
Госелсез – коенмаган, пакьләнмәгән.
Падишаһе әгъзам хәзрәтләре – бөек патша.
Хәлифәи руи зәмин – Җир йөзенең патшасы.
Зыйллуллаһи фил галәмин – Галәмдә Алланың күләгәсе.
Кяфир – Алланы бер дип танымаучы.
Зиндикъ – динсез.
«Кәнеҗ төрекләре» – «Яшь төрекләр».
Мәрмәрә диңгезе – Мәрмәр диңгезе.

Д у д у  Ш а к и р. Шулай буласы билгеле. Питербур, Мәскәү гәзитләренең язуларыннан шундыйрак исләр килгәне сизелә.

Х а ф и з. Бүгенге гәзитләрдә ниләр бар икән, укымадыңмы әле?

Д у д у  Ш а к и р. Укырга әле чәйгә кергән юк бит.

Х а ф и з. Чыннан да, чәйгә керергә вакыт җиткәндер инде. (*Сәгатен карап.*) У-һу! Унберенче ярты булып килә, керергә кирәк.

Д у д у  Ш а к и р (*әле берсенә, әле берсенә*). Тәфаддел йа хәбиби нәшер Иборай.

Г а р ә п л ә р. Билгайни вәррәес. Әлкәрамәте ля тәрәддө[4].

2 н ч е  Н и з а м и  х а җ и. Нәрсә терәтте диләр алар?

Д у д у  Ш а к и р. Үзең хаҗи кеше, үзең шуны да белмисең, сине әйтәләр: «Кәкре каен терәтте, – диләр, – бер дә ашка чакырып сыйлаганы юк», – диләр...

---

Б и л г а й н и  в ә р р ә е с – баш өсте, бик теләп.
Ә л к ә р а м ә т е  л я  т ә р ә д д ө – могҗизага каршы килеп булмый.

## ХАТЫННАР ТЕГҮЧЕСЕ

*Комедия бер пәрдәдә*

ӘШХАС:

Циля Фонк – кафе-шантанда җырлаучы кыз.
Фред – банкада хезмәт итүче.
Штром*.

Вакыйга Парижда хәзерге заманда.
Циля Фонкның бик шәп җыештырылган будуары. Көзгеләр, этажерка, анда төрле вак-төяк нәрсәләр. Зур туалет өстәле. Киемнәр тутырган зур кием шкафы, һәр җирдә тәртипсез таратылып ташланган туалет нәрсәләре. Бик зур хатыннар эшләпәсе өстендә корсет, өстәл өстендә ирләр эшләпәсе һәм таяк. Ике якта ишекләр. Уң яктагысы – йокы бүлмәсенә, сул яктагысы коридорга чыга. Вакыт кич, сәгать 6 тирәсе. Бүлмә яктыртылган. Пәрдә күтәрелгәндә, Циля туалет өстәле алдында чәчен төзәтеп тора. Спальныйдан җиңел оперетта көе җырлый торган бер ир тавышы ишетелә.

Циля (*сигаретка тартып, сәгатькә карый да спальныйга карап сөйли*). Җә, сөеклем, син тиз буласыңмы?

Фред (*спальныйда җырлый*). Хәзер, сөекле мәхлук...

Циля. Син биш минуттан китәргә тиеш.

Фред (*спальныйда җырлый*). Һу, нинди куркыныч... (*Сөйли.*) Циличка, миңа сигаретка бир әле?

Циля. Ярый, ләкин тизрәк.

Фред (*спальныйдан*). Кабызып бир, минем шырпым бетте.

Циля. Шулаймыни? Ярый, кабызып бирәм, ләкин тизрәк кит! (*Фред өчен сигарета кабыза да ишеккә бара.*)

Фреднең башы күренә.

(*Циля сигаретканы авызына каптырып.*) Мә...

Фред (*яңагын куеп*). Үп!..

Циля (*акрын гына яңагына сугып*). Мә, ал...

Фред югала.

---

* Штром пьесада «карт, типичный буржуй» дип характерлана.

Ф р е д (*спальныйдан җырлый*).

Матурларның йөрәге хыянәткә бирелә...

Ц и л я. Җә, син инде җырлаудан туктыйсыңмы?

Ф р е д (*спальныйдан, кәефе китеп*). Нәрсә? Бәлки, син әле мине начар җырлыйсың ди торгансыңдыр?

Ц и л я. Билгеле, нәкъ тиреслек башындагы әтәч шикелле.

Ф р е д (*ишектән сюртуксыз, манжетсыз күренеп, галстугын бәйли-бәйли, трагически*). Гүзәл хатын, сүзегезне кире алуыгызны үтенәм!

Ц и л я. Моннан тизрәк китүеңне үтенәм, ишетәсеңме?

Фред югала.

Чынлап әйткәндә, син ни уйлыйсың? Кайчанга кадәр синнән үтенергә кушасың? (*Спальныйга бара да Фредне галстугыннан өстерәп чыгара да, спальныйдан сюртугын ыргытып ташлап, спальныйны бикләп ала.*) Сиңа аз гына булса да саграк булырга кирәк иде.

Ф р е д (*киенә-киенә*). Җә, җә, хәзер.

Ц и л я. Мин сине сөйгәнлек өчен миңа шулай рәхмәт әйтүеңмени? Әгәр хәзер ул килеп, сине монда очратса, ул вакытта ни булыр? Минем фатирым өчен син түләмәссең бит?

Ф р е д. Һу! Юк...

Ц и л я. Син минем атларым өчен, минем туалетым өчен түләрсеңмени?

Ф р е д. Һу! Юк, юк...

Ц и л я (*елап*). Әллә, бәлки, син минем шул жалованьема карап кына торуымны тели торгансыңдыр?

Ф р е д (*юатып*). Алай дип кем уйлый алсын?

Ц и л я. Әйе, әйе, мине бер дә сөйми торган кеше белән миңа ничек итеп очрашырга кирәк?

Ф р е д. Йә, Циличка, кайдан тагы шундый уйлар башыңа килә? Мин инде киендем, мин китәм...

Циля елый.

Йә, тукта инде, мин сине бит бик сөям. (*Үбә.*) Мин сине чиксез сөям...

Ц и л я (*яшь аркылы елмаеп*). Дөресме?

Ф р е д. Менә инде минем синең белән танышуыма өч атна булды; шул көннән бирле мин бөтенләй икенче кеше булып киттем. Хәзер инде мин театрларга да йөрмим, китаплар да укымыйм. Хезмәтемә барудан да туктадым. Миңа безнең шеф күптән түгел генә әйтте, әгәр дә син болай йөрсәң, урыныңнан да очарсың, диде.

Ц и л я (*аны кочып*). Ах син!..

Ф р е д (*эсәрләнгән булып кыйланып*). Мин газап чиксәм дә, бары тик сиңа үземнең сине сөюемне күрсәтә алмаганым өчен генә газапланам. Мин ничек итеп кенә сиңа шатлык китерә алыйм? Синең һәрнәрсәң дә бар... Штром әфәнде сиңа ни теләсәң, шуны бирә... Кыйммәтле асылташлар, атлар, туалетлар... Һәрнәрсә... Һәрнәрсә... Коточкыч кеше!

Ц и л я. Син миңа аннан да артыгракны – үзеңнең мәхәббәтеңне бирәсең. (*Аны кочаклый.*)

Ф р е д. Минем сөекле күгәрченем.

Ц и л я. Минем кадерле песием.

Озак үбешү.

Ф р е д (*мөлаем гына аерылып*). Яңадан кайчан килим?

Ц и л я. Берни дә әйтә алмыйм әле... Мин язу җибәрермен...

Ф р е д. Бик яхшы. Ә хәзергә хуш... (*Чыкмакчы була.*)

Ц и л я (*аны туктатып*). Сабыр ит әле... (*Мөлаем гына.*) Мин сиңа бер-ике сүз сөйләмәкче булам.

Ф р е д. Әле шулай вакыт бармыни? Син бит мине бик ашыктырып куган идең...

Ц и л я. Тагы бераз гына мөмкин... Ул яртысыз килми.

Ф р е д. Җә, алай булса, тизрәк сөйлә.

Ц и л я. Мин, мин... Син һичбер ни дә уйламаска тиеш... Син ачуланмаска тиеш...

Ф р е д. Алай сузмыйча гына... Тизрәк сөйлә...

Ц и л я. Минем синнән үтенечем бар.

Ф р е д. Үтенеч?

Ц и л я. Син бая әйткән идең. «Синең өчен бик авыр, мин синең өчен һичбер ни дә эшли алмыйм» дигән идең...

Ф р е д (*ачуланып*). Әлбәттә, әлбәттә... Ләкин хәзер соң инде... Әгәр карт килеп җитсә... Без бу турыда... икенче бервакыт сөйләшербез әле... (*Чыкмакчы була.*)

Ц и л я (*пальтосының җиңеннән тотып*). Юк, юк, әле бераз вакыт бар... (*Мөлаем гына.*) Фред, Фредем, син миңа зур гына бер илтифат күрсәтергә тиеш.

Ф р е д (*ачуланып*). Йә, соң эш нәрсәдә?

Ц и л я. Эш бер хисап кәгазе турысында... Аз гына бер нәрсә... Юк кына бер акча турысында... Бары тик 720 франк турысында гына. Мин аны иртәгәдән дә соңга калмыйчы түләргә тиеш. Ә минем акчам юк.

Ф р е д. Эш нәрсәдә соң? Син аны картка әйт. Шуны да түләрлек булмагач, ул бу дөньяда нигә дип тора?

Ц и л я. Мөмкин түгел. Син аның нинди кеше икәнен белмисең. Ул миңа билгеле бер үлчәүдә генә акча бирә.

Мин шул акчаны җиткерергә тиеш. Аның белән акча турысында артык сөйләшмәскә тиеш. Аның шарты шулай.

Ф р е д. Менә бүкән! Аның өчен башка кешеләр түләргә тиеш булсын, имеш!

Ц и л я (*хисап кәгазен биреп*). Менә... Минем хакым өчен син бу эшне эшлә инде... Син түләрсең бит? (*Хисапны кулына тоттыра.*)

Ф р е д. Минем кыйммәтле хәзинәм, синең өчен бер дә кызганыч түгел иде, ләкин мин ул кадәр акчаны кайдан алыйм? Юк бит, чынлап юк.

Ц и л я. Ә, шулаймыни? Син минем өчен шундый юк кына бер эшне эшләргә дә теләмисең икән. (*Елап.*) Минем бердәнбер бушлай сөйгән бер кешем, шул булып шул бер генә мәртәбә булса да минем өчен аз гына бер нәрсәне – 720 франкны да түли алмасын, имеш... Бу инде бик артык...

Ф р е д. Билгеле, шулай. Мин дә шулай дим бит, бу бик артык күп, дим... 720 франк... Шулкадәр акча... Минем бөтен банкының да ул кадәр акчасы юк...

Ц и л я. Син бит минем өчен ач калырга да риза дигән идең...

Ф р е д. Әлбәттә... Хәтта берничә сәгатьләргә кадәр...

Ц и л я. Яхшы, яхшы, алай булса, бар кит... Мин сине моннан соң күрәсем дә килми... Моннан соң минем күземә дә күренәсе булма.

Ф р е д (*аны тынычландырырга теләп*). Җә, бераз акыллырак бул әле, ул, шаять, сиңа бирер.

Ц и л я. Мин аннан алырга теләмим... Мин бу киемне кигәндә аның синеке булганын күрәсем килә. Аның өчен син түләгән идең дип әйтәсем килә.

Ф р е д. Мин үз костюмымны кигән вакытларда да, бервакытта да андый уйларга бирелгәнем юк.

Ц и л я. Яхшы, яхшы, бар кит...

**Фред хисап кәгазен кулына тоткан көйгә, аны һич нишләтергә дә белмичә, аптырап карап тора.**

(*Аның муенына асылынып.*) Түләрсең бит? Шулай бит, ә? (*Колагына.*) Түләсәң, сиңа иртәгә тагы килергә мөмкин.

Ф р е д. Иртәгәме? Ни вакытта?

**Звонок тавышы ишетелә.**

Ц и л я (*куркып*). Алла хакы өчен... Ул...

Ф р е д. Якында кайда гына утырып таярга аэроплан бар икән? (*Машина белән хәрәкәт иткән шикелле, тиз генә хисапны яшерә дә спальныйга качмакчы була.*)

Ц и л я (*аны туктатып*). Син әллә акылыңнан шаштыңмы?

Ф р е д. Дөрес әйтәсең... Ул иң элек анда керер. (*Шкафны ачмакчы була.*)

Ц и л я. Син әллә җүләрләндеңме, бу һич мөмкин түгел!..

Ф р е д (*бүлмә буена йөгереп*). Нишләргә соң? Нишләргә?

Ц и л я (*кинәт*). Тукта... Мин юлын таптым... (*Шкафтан бер костюмны алып, Фреднең кулына тоттыра да.*) Шулай гына тор, кузгалма! (*Тиз генә җилкәсенә киң, җиңел кием сала да коридорга чыга.*)

Ф р е д (*итагать белән торып*). Хәзер инде минем борыныма боҗра да тез башларына ямаулар гына кирәк.

Яңадан звонок.

Ц и л я (*коридордан*). Җитәр инде! Берәр секунд кына сабыр итәргә ярый торгандыр.

Ш т р о м (*коридорда*). Ә, җанкай, мин тагы ни дип уйлаган идем...

Ц и л я (*тышта*). Туктасагыз ла... Никадәр борчу, никадәр күңелсезлекләр... (*Ишекне ачу белән яба, керә.)*

Артыннан Ш т р о м керә. Карт, типичный буржуй.

Ш т р о м (*беркатлылык белән*). Ни булды ул кадәр?

Ц и л я. Ни булды дисеңме? (*Фредне күрсәтеп.*) Менә шул ишәккә кара...

Фред нәрсәдер әйтмәкче була.

Шул бүкәнгә, шул ишәккә кара! Син аңар тау кадәр акча түлисең, ә ул бары тик бозарга гына белә.

Ф р е д. Ләкин...

Ц и л я. Нәрсә? Сез үзегезне оста тегүче димәкче буласызмы? Сез – эрәмтамак сез, тегүче түгел! Сезгә җиде кат җир астына чәнчелеп китәргә генә кирәк иде.

Ш т р о м. Ләкин, чибәрем...

Ц и л я. Син тик кенә тор... (*Фреднең кулыннан киемне тартып алып, аяк астына ташлап.*) Менә сезнең хәзинәгез... Миңа расходларымны кайтарыгыз. Сез моңарчы шул базардагы сату итеп йөри торган хатыннарга гына кием теккәнсездер...

Ф р е д (*җәберсенеп*). Зинһар...

Ц и л я. Сез әле тагын сүз әйтергә дә батырчылык итмәкче буласызмы? Менә сезгә!..

Өстәлдән кечкенә бер статуяны алып, Фредкә ыргыта, Фред башын бөгеп кала. Статуя Штромның башына тия.

Штром. Саграк бул, күгәрченкәем...

Циля. Ә... Син әле сөйли дә башладыңмы?.. (*Аягы белән тибенгәләп.*) Мин моңар ирек бирмәм, бу чиктән тыш күп...

Штром (*аның янына килеп*). Кара әле, тыңла әле...

Циля. Тимә миңа... Башым... Йөрәгем... Бу мине кабергә кертер... (*Елап, спальныйга таба йөгерә.*)

Фред (*читкә*). Менә бу актриса дисәң дә актриса! Нинди яхшы уйный. Моның уенына бары тик Дүзә[1] генә тиң килә алыр.

Штром. Тыныч булыгыз, егет, ул шулай бераз кабынып китүчәнрәк, болай ул үзе вакыйгъдә яхшы кеше...

Фред. Юк, мин аның ул эшен кичерә алмыйм, ул мине, ишәк, аңгыра, идиот, диде... Мин аны болай гына калдырмыйм, мин аның өстеннән судка бирермен.

Штром. Юк эш... Миңа ул андый сүзләрне көн саен әйтә.

Фред. Анысы сез, башка эш...

Штром. Ягъни мәсәлән, ничек алай башка?

Фред. Ул бит сезнең белән якыннан таныш, ә мин аны кемгә бирермен?

Штром. Куегыз, юк өчен генә тавыш чыгармагыз... Киемнәрегезне монда калдырыгыз... Ул тынычланыр... Хисабыгыз яныгыздамы?

Фред. Нәрсә?

Штром. Хисабыгыз яныгыздамы, дим?

Фред. Хисап дисезме? (*Кинәттән башына бер фикер төшеп.*) Ә, ие, әлбәттә, янымда. Менә, рәхим итегез. (*Хисапны бирә.*)

Штром. 720 франк. Бу бераз күбрәк икән.

Фред (*туп-туры гына*). Әйе, күбрәк шул. (*Тиз генә төшенеп алып.*) Актрисалар аннан арзан түләмиләр.

Штром. Менә сезгә 750 франк.

Фред. Гафу итегез, минем кайтарырга вак акчам юк.

Штром. Кирәкми... Калганы сезгә... (*Фреднең иңбашына сугып.*) Ишәк өчен, идиот өчен, аңлыйсызмы?

Фред. Ә, рәхмәт сезгә.

Штром. Алганлыгыгызга кул куегыз.

Фред (*хисапның артына язып*). 720 франкны вәкаләт буенча алдым. (*Авыз эченнән мыгырдый.*)

---

Вакыйгъдә – чынлыкта.

Ш т р о м (*мөлаем*). Шулай итеп, сез ачуланмагыз, ул бераз кызурак... Иртәгә яңадан барысы да яхшыланыр.

Ф р е д. Мин дә шулай дип өмет итәм. Сез, зинһар, аңар әйтегез, мин һәммәсен дә тәртипкә куярмын, һәм иртәгүк сәгать биштә килеп яңадан үлчәрмен... һәм, гомумән...

Ш т р о м. Яхшы, яхшы, мин үзенә әйтермен.

Фред баш иеп чыга. Штром Циляның ишеген кага.

Җанкай, җанаш...

Ц и л я (*чыгып*). Теге ишәк киттеме?

Ш т р о м. Син аның белән бигрәк мәрхәмәтсез кыйландың?

Ц и л я. Ах, җитәр инде...

Ш т р о м. Әйе, җанкай... Беләсеңме, мин нинди җегет кеше. Мин аңар хисап буенча түләп җибәрдем.

Ц и л я (*гаҗәпләнеп*). Нәрсә?

Ш т р о м. Әйе, әлбәттә... (*Хисапны сузып.*) Һәм ул иртәгә сәгать биштә яңадан килер. Син, зинһар, аның белән яхшырак мөгамәлә кыл... (*Йомшаклык белән.*) Җә, балакай, вәгъдә бирәсеңме?

Ц и л я. Яхшы, ярый, бары тик синең өчен генә, сиңа күңеллелек китерер өчен генә.

П ә р д ә.

## ИСКӘРМӘ ҺӘМ АҢЛАТМАЛАР

2 нче том Г.Камалның совет чоры әсәрләрен (пьесаларын, декламацияләрен, эстрада әсәрләрен һәм бер тәрҗемәсен) үз эченә ала. Дөрес, язучының бөтен тезмә әсәрләрен бергә туплау максаты белән, монда Г.Камалның Октябрьгә кадәр язылган шигырьләре дә кертелде. 1905 ел революциясе яңгырашы буларак туган бу шигырьләр – Гражданнар сугышы елларында яңарып кабынган Г.Камал революцион шигъри публицистикасының үзенчәлекле бер этабы. Шуңа күрә дә алар әлеге декламацияләр белән бергә шушы томда урын алдылар.

Татар әдәбияты тарихында Г.Камал шигъри мирасының аеруча икенче өлеше – совет чоры декламацияләре күренекле урын тота. Әдипнең яңа дәвер совет чоры шартларында иҗат ителгән агитацион-публицистик юнәлештәге, оптимистик пафослы, сатирик ялкынлы шигырьләре, Октябрь революциясе һәм Гражданнар сугышы елларының актуаль-политик эчтәлекле татар революцион поэзиясе үрнәкләре буларак характерланалар.

Г.Тукай белән бергәләп «Яшен» сатирик журналын чыгарган, 1905–1909 елларда ук сатирик поэзиягә мөрәҗәгать иткән Г.Камал Гражданнар сугышы көннәрендә яңадан шул ук сугышчан жанрга әйләнеп кайта һәм аның сәбәбен үзе болай дип аңлата: «Гражданнар сугышының кызган чоры. Деникин, Колчак һәм башка ак бандалар яшь Совет иленә төрле яктан һөҗүм итәләр. Шуңа күрә дә мин кыска әсәрләр (шигырьләр) язып, көннең кадагына сугып барырга тиеш идем. Ул вакытларда мин, икешәр көн өйгә кайтмыйча, редакциядә кунып эшли идем»*.

Октябрь революциясе җиңүен Г.Камал иҗади активлык белән каршылый, аны хезмәт халкының күптән көткән вакыйгасы итеп кабул итә.

Бу елларда ул Мөселман социалистлары комитетының «Кызыл байрак» газетасында һәм Көнчыгыш фронтның нәшрият бүлегендә тәрҗемәче булып эшли, «Эш», «Безнең байрак», «Эшче», «Кызыл көрәшче» газеталарында үзенең әлеге революцион эчтәлекле шигъри әсәрләрен бастыра.

Г.Камалның бу еллардагы шигырьләре татар революцион поэзиясенең үрнәкләре буларак та, халык массаларына социалистик революция идеяләрен оператив һәм үтемле формада җиткерүдә көрәш коралы буларак та гаять әһәмиятле.

Сәнгатьчә формасы ягыннан Г.Камал шигырьләре халык авыз иҗатының поэтик жанрларына якын. Яңа дәвер әдәбиятының форма мәсьәләләре хәл ителмәгән чорда туган халыкчан табигатьле, демократик рухлы мондый реалистик әсәрләр хезмәт ияләренең күңеленә туры юл табалар, үзләренең революцион политик агитация вазифаларын уңышлы үтиләр.

Мәгълүм булганча, Г.Камал үсмер чакта ук иптәшләре белән бергә-

---

* К а м а л Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татгосиздат, 1938. 4 б.

ләп «юка кәгазь астына копировка кәгазьләре куеп, мәдрәсәдәге хәлфәләрнең җитешмәгән якларыннан көлеп «Телескоп», «Мәнзарател галәм» исемле кулъязма газеталар чыгарып, төнлә белән җәмәгать сәкеләренә» дә шул сатирик ялкынны ташлаган шәкерт*. Шәкертләр арасында мәдрәсәләрдә күптәннән яшәп килгән бунтарьлык традициясен үстереп, дини-мифик сюжетларга, реакцион хәлфәләргә пародияләр чыгару, иске әдәби формаларга яңа сатирик эчтәлек салу тәҗрибәсен яңа көрәш максатларына юнәлтеп тә Г.Камал татар революцион сатирасын тудыруга зур өлеш кертте һәм В.Маяковский, Д.Бедныйларга тартым политик сатира үрнәкләре бирде.

Г.Камалның шигъри әсәрләре халыкка таныш элекке үлчәү, ритмнарны, иске әдәби форма калыбын яңа максатларга хезмәт иттерү иде.

Берзаманны Казанга чехлар килде,
«Большевиктан коткарабыз сезне», – диде.
Бу сүзгә байларның бик кәефе килде,
Мондыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

(*«Яңа тәкый гаҗәб»*, *1918*)

Әдипнең политик сатирасы көчле ирония белән сугарылган. Революциягә кадәр үк йөзләгән карикатуралар эшләү дә Г.Камалның сатирик көлү осталыгын үстергән. Үзе «декламацияләр» дип атаган бу шигырьләрдә әкият формасы да, риваять детальләре дә, дастан алымнары да еш очрый. Әлбәттә, болар барысы да биредә көлү чарасы буларак күбрәк сатирик гиперболаларда урын алалар.

Алар белән Казан байлары киткәннәр,
Бара-бара Лаеш шәһренә җиткәннәр;
«Бичара»ларны бигрәк тә рәнҗеткәннәр,
Мондыйн артык тәкый гаҗәб дыңларый бар.

(*«Яңа тәкый гаҗәб»*, *1918*)

Әдипнең шигъри сатирасы тематик яктан гаять киң. Бу шигырьләрдә Антанта министрлары да каләм очына алына, милли буржуазиянең вак-төяк иярченнәренә дә урын табыла. Бер үк вакытта бөтендөнья пролетариатының сыйнфый көрәш, интернациональ бердәмлек темасы да чагыла. Бу бердәмлек – Г.Камал иҗатындагы оптимизм, ачы көлү таянычы, җиңүгә чиксез ышану чыганагы.

Г.Камалның шигъри иҗаты турында Г.Ибраһимов, мәсәлән, шул чорда ук болай дип язган иде: «Татар драма әдәбиятының атасы, татар сәхнәсе өчен аның башлап тууыннан 16 нчы елларгача үзенең әсәрләре белән байлык бирә килгән, «Бүләк өчен», «Беренче театр» кебек комедияләре белән татар әдәбияты тарихында мәңгелек урын алган Галиәсгар Камал иптәшнең көйләп язарга куәте барлыгы күптән мәгълүм иде... Менә шул карт язучы, революция керү белән, үзенең аңарчы комедияләрендә ялтыраган һөҗүви көчен вак-вак көйле шигырьләр язу ягына борды; «Эш»тә, «Эшче»дә төрле имза астында көйле һөҗүләр яза килде. Менә хәзер шуларны җыеп бастырган. Язучы боларны «декламация» дип атый. Ләкин бунын исеме «Революция бәетләре» булыр иде... Бу мәҗмуга ярлы авылга, кызыл казармага нык таралырга тиеш. «Кәҗә бәетләре», «Чәй бәетләре», «Чукынган мулла», «Мәзлум килен», «Үги кыз», «Чегән бәетләре» халыкның иң караңгы почмакларында ничек үз булса, бу «Революция бәетләре» дә ярлы татар дөньясы-

* К а м а л Г. Яза башлавым тарихы // Г.Камал Әсәрләр. 2 томда. Казан: Татгосиздат, 1951. 2 т. 266 б.

ның иң караңгы подвалларына төшәргә, таралырга тиешле. Мәгънәнең гадилеге, теленең җиңеллеге, вакыйганың һәркемгә мәгълүмлеге, көйнең халыктан алынуы – буны тәэмин итәләр...»*

Г.Камал үзенең сатирасында элекке традицияләргә таяна, дидек. Әйтик, аның Беренче рус революциясе елларында язган сатирик шигырьләренең диалог-пародия формасы Гражданнар сугышы елларында иҗат ителгән шигырьләрендә дә, шуннан соңгы драматургиясендә дә, аеруча парлы конферанс һәм агитпьесаларында киң кулланыла. Бу традиция исә бүгенге агитбригадалар репертуарында яши һәм яңара. Мисал өчен Г.Камалның берничә әсәрен алыйк. Иске «Бакырган» китабында җәннәт һәм тәмуг сөйләшүе формасындагы диалог бар. Г.Камал, шушы формадан файдаланып, 1908 елда ук әле «Яшен» журналында иронияле пародия – «Оренбур – Казан» шигырен бастырып чыгара.

Оренбур әйтә: «Мин баймын,
Миндә Рәмиев һаман бар».
Казан әйтә: «Юк синдә,
Барча байгура миндә».

1918 елда «Эш» газетасында басылган «Бакырган китабы» шигырендә исә без аның мондый юлларын укыйбыз:

Буржуй әйтә: «Мин баймын,
Зур таш пулат миндә бар,
Син торасың алачыкта,
Буе кыска, иңе тар».

Эшче әйтә: «Мактанма,
Зур йортлар – бер көн килер –
Булыр ләхеттән дә тар».

Г.Тукайдан ук килә торган бу парлы мактанышу формасындагы сатирик ялангачландыру алымын Г.Камалның егерменче-утызынчы елларда язылган, үз вакытында төрле кимчелекләрне камчылап, үткен эстрада сүзе булып яңгыраган сәхнә әсәрләрендә дә («Аҗак белән Куҗак», «Корфетдин белән Торфетдин», «Хатип белән Латип», «Ударник һәм бездарник» бәхәсләрендә) күрәбез.

Г.Камал көлүе Г.Тукай сатирасына бик якын. Шәхси дуслык, дөньяга караш берлеге, тема-проблемалар уртаклыгы бу ике талантның иҗатында бик нык сизелә. Моны драматургның Г.Тукай шигырьләрен иҗади файдаланып сәхнәләштерү дә раслап тора. Әйтик, аның «Өйләнәм... Ник өйләндем?» комедиясе Г.Тукайның «Өйләнү – түгел сөйләнү» шигыре нигезендә иҗат ителә. «Ысулы кадимче» комедиясендә исә әдип турыдан-туры Г.Тукай шигырен эпиграф итеп файдалана, «сәхнә алдында утырган тәфсирче вакыйганың мәгънәсен Тукаев шигыре буенча тәфсир итә бара» дип, махсус искәрмә язып куя. Кадимчелеккә каршы көрәш Г.Камал иҗатының буеннан-буена сузыла. Революциягә кадәр «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Безнең шәһәрнең серләре» кебек комедияләрдә камчыланган искелек калдыклары Октябрьдән соң иҗат ителгән пьесаларда да утка тотыла. «Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман» (1929), «Могҗиза» (1933), «Өч тормыш» (1933) пьесаларында бу традицион мотив аеруча көчле яңгырый. Г.Камал үткән тарихка, шул исәптән дини-схоластик караңгылыкка, патриархаль урта гасыр тәр-

---

* Ибраһимов Г. Яңа әсәрләр. Татарстан хәбәрләре. 1922. 17 гыйнв.

типләренә яңа дәвер казанышлары югарылыгыннан карый һәм «Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман» пьесасының апофеозын болай итеп сурәтли: «Интернационал» уйный, артта пәрдә ачыла, артта ялтыраган якты кызыл йолдыз, бөтен тирә-якта индустрия төзелеше, уртада төрле милләт пролетариатының кардәшлеге картинасы күренә».

Г.Камалның Совет власте елларында язылган пьесалары аның сатирик шигырьләрендәге форма һәм эчтәлек үзенчәлекләрен нык хәтерләтә. Алар да – нигездә агитацион политик сатира үрнәкләре. Биредә дә әдип – сыйнфый принципиаль, социаль тенденциоз, революцион оптимист. Ул яңа заман үзгәрешләренә соклана, үткәнгә ачы көлеп карый, Совет иленең һәртөрле дошманнарын үтергеч сатира объекты итеп ала. Аның шундый әсәрләреннән берсе – «Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман».

Ике бүлектән торган бу сатирик комедияне «элек һәм хәзер» дигән принципта иҗат ителгән дияргә мөмкин. Шунысы үзенчәлекле: ул принцип Г.Камалның «Өч тормыш» пьесасындагы кебек традицион «элек нинди идек, хәзер нинди булдык» рәвешендә түгел. Драматург биредә «монысы – элекке каралык, монысы – хәзерге кимчелек» дигән принципта яза.

Драматургик конфликт ягыннан «Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман» пьесасы персонажлаштырылмаган конфликтлы сатирик комедияләр төркеменә керә – Н.В.Гогольнең «Ревизор»ыча, көлке типлар дөньясын сурәтли. Биредә барлык персонажлар да «тискәреләр» рәтендә торалар. Аларның тормышчанлыгы турында, әсәрнең беренче бүлеген ассызыклап, Г. Нигъмәти: «Типлар – реаль типлар, вакыйгалар да реаль тормыштан алынганнар», – дип бик хаклы яза*.

Беренче карашка, пьесаның ике бүлеге ике әсәрдәй. Чынлыкта исә ике бүлек бер эчке бөтенлеккә ия. Бу бөтенлек әсәрнең яңгырашын бермә-бер арттыра. Уртак тема, идея, форма әсәрне бербөтен итә. Г.Нигъмәти сүзләре белән әйткәндә, әсәр «шарж-обозрение» төсендәрәк.

Драматург үткән заман реакция көчләрен яңа заман реакция көчләре белән бер сафка куя, замана хәлләрен бәяләгәндә үткәндәге елларга экскурс ясый. «Өч тормыш» (1933) пьесасындагы шундый ук алымны искә төшерсәк, моның үзенә бер закончалык икәне ачыклана: Г.Камалның бу чор драматургиясендә чынбарлыкны, тарихны бер үк әсәрдә аерым заманнарга бүлеп, конкрет чагылдыру формасы аеруча көчәеп китә. Октябрь революциясенең дөньяга тарихи яңалык, борылыш алып килүен халык массаларына аңлаешлы рәвештә җиткерү зарурияте әдипне әнә шундый әдәби алымнарга да мөрәҗәгать иттергән.

Пьесаның беренче бүлеге мулла, мөрит, мәзин, карый, бай, фәхешханә тотучы фахишәләрнең бозыклыкларын фаш итә. Вәгазь укып, изге булып йөргән кешеләрнең, «дәрәҗәле» зыялыларның һәм аларга ияручеләрнең түбәнлекләре, көлке хәле, оят эшләре, икейөзлелекләре фәхешханә күренешендә ачыла.

Драматург һәр ике бүлектә персонажларның күбесенә ялгызлык исеме бирми. Катнашучыларны беренче бүлектә мулла, мужик, гармунчы, юан бай, мөрит һ.б. дип кенә атый. Икенче бүлектә, мулла, мөрит, раввин, кәшиш, ишан, поп, инженер, генерал, шагыйрь, адвокат, интеллигент, буржуй һ.б. дип, яңа тормышка каршы типларны сәхнәгә чыгара. Бу да пьесаның уртак форма сыйфаты. Дөрес, ике бүлектә ике вакыйга-сюжет. Шуңа да карамастан башка художество компонентлары, шул исәптән стиль берлеге дә бу бүлекләрне үзара берләштерә.

---

* Нигъмәти Г. Тәкый гаҗәб... // Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивындагы кулъязма (1929 елның 30 ноябрендә язылган эчке рецензия). 13 ф. 1 тасв. 9 сакл.б.

«Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман»га Г.Камалның «Могҗиза» (1933) исемле комедиясе дә күпмедер якын тора. Монысында драматург яңа заман «могҗизаларын» олылый, искедән калган гореф-гадәтләрдән, дини ышанулардан ачы көлә.

Әлеге пьесалар, Г.Камалның күп кенә башка әсәрләре кебек, хәзерге заман «могҗиза»ларына, сыйнфый көрәшләргә аваздаш. Г.Камал драматургиясе, гомумән, ил тарихы, ил проблемалары белән тыгыз бәйләнештә үсә бара.

Мәгълүм булганча, татар революцион демократларының бер вәкиле буларак, Г.Камал бөтендөнья прогрессив культура казанышларын үзләштерергә яшьтән үк җаны-тәне белән омтылган әдип. Алга киткән Европа илләренең мәдәният җимешләрен ул үз халкына да авыз иттерергә тели һәм бу юлда шактый зур эш күрсәтә. Яңа гына дөньяга килгән татар театрын үз пьесалары белән шатландыруы өстенә Г.Камал дистәләгән драматургларның бик күп пьесаларын татарчага тәрҗемә итә. Алар арасында Н.Гогольнең «Ревизор»ы, А.Островскийның «Яшенле яңгыр»ы, М.Горькийның «Тормыш төбендә»се кебек рус классик әсәрләре дә бар. Татарларның шул заман мәгърифәтчел карашларына, революцион-демократик теләкләренә, гомумкешелек гуманистик идеяләренә үз булган француз, итальян, төрек язучыларының күп кенә пьесалары аның каләме аша татар сәхнәсенә menәләр.

Г.Камалның тәрҗемәләре арасында, мәсәлән, Италия драматургы Джакометти Паолоның (1816–1882) «Җинаятьче гаиләсе» (1862) исемле драмасы да бар. «Христофор Колумб», «Микеланджело Буонаротти» кебек тарихи драмалар, «Ана һәм кыз», «Сөрелгән кеше хатыны», «Икенче никахтагы хатын» кебек комедияләр язган талантлы каләм иясенең әлеге драмасы, демократик рухлы, хөр фикерле булуы белән, татар театр эшлеклеләренә кадәр рус әдипләрен дә җәлеп иткән. Италиядә зур уңыш казанган, анда «Гражданская смерть» исеме белән билгеле булган бу әсәр 1870 елда А.Н.Островский тарафыннан русчага тәрҗемә ителә («Семья преступника») һәм рус сәхнәләрендә уйнала.

Джакометти Паоло бу драмасында руханиларны нәфрәтләнеп гаепли, алар яклаган дини тәртипләрнең мәрхәмәтсезлеген, кешеләрнең табигый теләкләрен буып торуын фаш итә. Тере кешене граждан буларак мәет иткән шундый богауларның берсе – никах ирексезлеге, католиклар чиркәвенең аерылышуларны каттый тыюы. Драматург аерылышуга законлы хокук бирелүен таләп итә. Бу теләкләр Россиядә яшәгән халыкларга, әлбәттә, бик якын һәм аңлаешлы була. А.Н.Островскийның «Яшенле яңгыр» драмасында, Г.Камалның «Уйнаш», «Өч бәдбәхет» һәм башка пьесаларында хатын-кыз азатлыгы, мәхәббәттә тигезлек, талак мәсьәләләренең кискен куелуы, Катерина – Сәрбиҗамал – Сәрвиҗамал кебек героиняларның уртак уйлары, фаҗигале язмышлары моны раслап тора.

Кайбер мәгълүматларга караганда, Г.Камалның йөздән артык тәрҗемәсе булуы ихтимал. Аларның күбесе сәхнәдә уйналган, әмма басылмый калган. Әдипнең зур күләмле тәрҗемә пьесалары арасында «Хатыннар тегүчесе» кебек кечкенә водевильләр дә бар. Беренче карашка җиңелчә әсәр булып күренгән бу пьесада капитал тозагына эләккән хатын-кызларның фаҗигале хәле ачык чагыла.

Г.Камалның совет чоры драматургиясе сыйнфый принципиаль, социаль эчтәлекле булуы белән, халыкчан, реалистик табигате белән үзенчәлекле. «Хафизәләм иркәм», «Өч тормыш» кебек пьесалар нәкъ менә шул яклары белән аерылып торалар. Бу әсәрләр – илдә кискен социаль үзгәрешләр барган елларда татар совет драматургиясенең яңалык өчен көрәшеп, тормыш белән тыгыз бәйләнештә алга атлавының ачык дәлилләре.

«Хафизәләм иркәм» комедиясе – Г.Камалның Октябрь революциясеннән соң хезмәт ияләре тормышындагы тирән үзгәрешләрне чагылдырып язган беренче зур пьесасы. Әсәр драматургик эшләнеше ягыннан күпмедер дәрәҗәдә М.Фәйзинең атаклы «Галиябану» драмасын хәтерләтә. «Хафизәләм иркәм» дә, «Галиябану» кебек үк, тормышчан, үтәдән-үтә музыкаль әсәр. Шул ук вакытта Г.Камал комедиясенең яңачалыгы да күзгә бәрелеп тора.

Пьесада яңа шартлардагы бәхетле мәхәббәт тарихы ачыла. Авыл халкының табигый тормыш агышы, яшьләрнең мәхәббәте, заманның сыйнфый каршылыклары тыгыз үрелештә бирелү – аның идея-эстетик кыйммәтен күтәрә. Пьеса элек изелгәннәрнең җиңү пафосы белән сугарылган. Галиябану белән Хәлил хыялында яшәгән якты көнне Хафизә белән Хафиз үз язмышларында күрәләр. Дөрес, аларга да гаделлекне көрәшеп табарга туры килә. Исмәгыйльчә эш итүче Кәрим корган тозакларны аларның җимереп үтүе комедиянең төп сюжет сызыгын тәшкил итә.

Г.Камалның революциядән соңгы иҗаты татар совет әдәбияты дөньясындагы башлангычларның башы буларак күз алдына килә. Аның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеген югары бәяләп, 1923 елда Г.Ибраһимов хаклы рәвештә болай дип язды: «Февраль, Октябрь килеп, Совет тарафыннан матбугат тугач, хәзерге көндә Совет автономияләренә кул суза башлаган зыялылар, язучыларыбыз, саботаж ясап, совет матбугатыннан җирәнеп йөргәндә, Г.Камал бөтен көче белән хезмәт кыйлды. Безнең гәзитәләрдә картлардан беренче башлап эшләүче ул булды. Чех, Колчак вакытларында да акларга качмады. Шул заманнан бирле өзлексез пролетариат әдәбиятында хезмәт кыйлды; революция дошманнарыннан көлеп, декламация мәҗмугалары чыгарды. Кыскасы, әдәбият тарихында урыны зур булган кебек, революция матбугатында да аның ихлас хезмәте бар»*.

Әлбәттә, художество эшләнешләре ягыннан томдагы әсәрләр бер үк дәрәҗәдә түгел. Әйтик, агитпьесаларның, эстрада өчен язылган шигъри әсәрләрнең кайберләре көннең кадагына сугып ашыгыч язылганнар, соңыннан да эшкәртелми калганнар. Әмма драматургның иҗат эволюциясен күз алдына китерү өчен алар да игътибарга лаек тарихи материал, кыйммәтле хәзинә булып торалар.

Г.Камалның Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәрге демократик матбугат, әдәбият тарату, драматургия һәм театр өлкәсендәге хезмәтләре җитди тарихи әһәмияткә ия булган кебек, Совет власте елларындагы иҗаты да татар культурасы тарихында тирән эз калдырды.

*Назыйм Ханзафаров*

## Пьесалар

7 бит

**Хафизәләм иркәм.** 1921–1922 елларда язылган. 1929 елда аерым китап булып чыккан (К а м а л Г. Хафизәләм иркәм. Казан: Татиздат. Татарстан сәяси аң-белем баш комитеты).

Драматургның сайланма әсәрләре томнарында күп мәртәбәләр басылган: К а м а л Г. Әсәрләр / кереш сүз авт. Ф.Сәйфи-Казанлы**. Казан: Яңалиф, 1930. 2 т.; К а м а л Г. Әсәрләр / кереш сүз авт. Г.Нигъмәти***; төз. И.Рәми. Казан: Таттосиздат, 1935; К а м а л Г. Сайланма

* И б р а һ и м Г. Әдип Г.Камалның хәле авыр. Татарстан. 1923. 2 окт.

** Моннан ары «Әсәрләр» (1930) дип кенә күрсәтеләчәк.

*** Моннан ары «Әсәрләр» (1935) дип кенә күрсәтеләчәк.

әсәрләр / кереш сүз авт. Х.Җәмил. Казан: Таттосиздат, 1938*; Камал Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Таткнигоиздат, 1942; Камал Г. Әсәрләр. 2 томда. / кереш сүз авт. М.Гайнуллин; төз. М.Гали. Казан: Таттосиздат, 1950. 1 т.**; Камал Г. Драма һәм комедияләр / төз. Ә.Камал. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969; Камал Г. Әсәрләр / төз. Н.Ханзафаров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.

Сәхнәгә беренче мәртәбә Казанның «Зур театр»*** бинасында К.Тинчурин җитәкчелегендәге «Беренче мәркәз драмтруппасы» тарафыннан 1922 елның 7 апрелендә куела. Премьерада артистлардан И.Кугушев, М.Вәлишин, Х.Колмәмәт һам башкалар катнашалар (Кәрам Г. Хафизәләм иркәм. Татарстан. 1922. 11 апр. (№ 83).

1949 елның 25 гыйнварында Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры аның яңа премьерасын куя. Халык театрлары һәм үзешчән театр коллективлары да бу әсәрне төрле елларда күп мәртәбәләр куялар. Татарстаннан читтә Әстерхан татар театрындагы премьерасы 1948 елның 22 маенда була. Режиссеры – И.А.Кугушев****. Әстерхан татар театрында бу әсәр 1922 елда да куелган (Сәерче. Әстерхан сәхнәсе тирәсендә. Кызыл ил. 1922. 27 июль).

«Хафизәләм иркәм»нең бүгенге көндә тулы булмаган ике кульязмасы бар. Беренчесе 1921–1922 елгы, икенчесе 1929 елгы дип фараз ителә. Әдипнең үз кулы белән язылган бу нөсхәләр Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында*****  сакла期налар (13 ф. 1 тасв. 4 һәм 5, 6 сакл. б.). Беренче кульязманың (4 сакл. б.) тексты томның «Кушымта»сында бирелде.

[1] *Ясигъ* – кояш баеп, шәфәкъ яктысы беткәч укыла торган бишенче намаз.

[2] *Ясту* – бишенче намаз (шул ук ясигъ).

43 бит.

**Өч тормыш.** 1929–1930 еллар тирәсендә язылган дип уйланыла. 1933 елда «Күзсез мастерлар» пьесасы белән бергә аерым китап булып басылган (Камал Г. Өч тормыш. Казан: Таттосиздат, 1933). Титул битендә: «Клуб сәхнәләре өчен пьеса» дип тәкъдим ителгән.

Моннан соң «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1950), «Әсәрләр» (1979) томнарына, «Яктылык җиңә» дигән әдәби җыентыкка (Казан: Таткнигоиздат, 1955 / төз.: З.Мәҗитов, З.Мансур) кертелгән. Гарәп графикасында язылган кульязмасы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 15 сакл. б.). Кульязма 1933 елгы басмадан шактый аерылып тора, ул шушы томның «Кушымта»сында бирелә.

[1] *Яңалиф* – латин язуы нигезендәге алфавит һәм орфография. 1927 елның 3 июлендә Татарстан республикасы Халык Комиссарлары Со-

---

* Моннан ары «Сайланма әсәрләр» (1938) дип кенә күрсәтеләчәк.

** Моннан ары 1 нче том – «Әсәрләр» (1950), ә 2 нче том «Әсәрләр» (1951) дип кенә күрсәтеләчәк.

*** Хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасы.

**** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивы. 49 ф., И.Кугушев тапшырган «1929–1958 еллар театр программалары, афишалар, фотоальбом, хатлар».

***** Моннан ары «Г.Ибраһимов исем. институт» дип кенә күрсәтеләчәк.

веты латин алфавитын татар теленең рәсми алфавиты дип игълан итә. Бу алфавит 1940 елга кадәр, рус алфавиты нигезендәге хәзерге алфавитка күчкәнче, гамәлдә була.

62 бит.

**Ысулы кадимче.** Язылу вакыты төгәл билгеле түгел. Г.Тукайның шул исемдәге әсәренә ияреп язылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр» (1979) кертелгән. Гарәп графикасындагы кульязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 26 сакл. б.).

[1] Мәгълүм булганча, Г.Тукайның «Ысулы кадимче» әсәре дини эчтәлекле «Мөхәммәдия» (XV гасырның беренче яртысында яшәгән төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләби Язычы әсәре) китабындагы бер шигырьгә пародия итеп язылган. Г.Тукай шигырендә вакыйга беренче заттан – кадимче авызыннан сөйләнелә. Г.Камалның тәфсирчесе ул сүзләрне читтән күзәтүче буларак сөйли. Шуңа текстта кайбер аермалыклар бар.

[2] *Әмре трахтир* – «Мөхәммәдия»дәге «әмре тәкъдир» дигән сүзләргә Г. Тукай пародиясе.

[3] Строфа Г. Тукайдагыча алынды*.

[4] *Тәваб (тәваф)* – изге нәрсә, изге урын. Г.Тукайда «сәвап» дип алынган.

[5] *Хатыннарында качу* – ислам дине кушканча ирләрдән йөз яшерү, качу.

79 бит.

**Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман**. Беренче мәртәбә «Әсәрләр»дә (1935) басылган. Аңарчы «Ахыры заман» дигән бер пәрдәсе «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты» (1920–1930) дигән җыентыкка (Казан: Татиздат, 1930 / төз.: К.Нәҗми, Г.Нигъмәти, Г.Гали) кертелгән. Яңалифчә кульязмасы Г. Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 9 сакл. б.). Кульязманың соңгы битләрендә Г.Нигъмәтинең 1929 ел, 30 ноябрьдә, А.Шамовның 1931 ел, 24 майда язган кыска гына рецензияләре бар. Димәк, 1929 елга кадәр язылган.

[1] *«Сөлләм казый»* – «Дөреслекне эзләү баскычлары» дигән иске схоластик китап. Бу логика китабы мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылган.

[2] *Кышкар* – хәзерге Арча районына керә торган Кышкар авылындагы мәдрәсә. Дини догмаларны белү, яклау буенча Кышкар шәкертләре ул елларда оештырылган дискуссияләрдә осталык күрсәткәннәр.

[3] *Әшратый сәгать* – соңгы сәгать; дини мифология буенча дөнья бетү, кыямәт килү сәгате.

[4] *Хәдис* – Мөхәммәд пигамбәрниләр эшләгәнлеге, ниләр сөйләгәнлеге турында хикәя.

[5] *Ясин* – Коръәннең 36 нчы сүрәсе; үлем түшәгендәге кешенең баш очында укыла.

[6] *Фидия* – үлгән кешенең гөнаһысын йолып алу өчен бирелә торган мал, сәдака.

[7] *Тамак толып* – төлке тамагы мехыннан тегелгән яхшы толып.

[8] *Бер «әби»не...* – әби патша (Екатерина II) рәсеме төшерелгән йөз сумлык акча күздә тотыла.

[9] *«Мохтәсар»* – ислам диненең юридик законнары турындагы китап. Кадим мәдрәсәләрдә дәреслек булып йөргән.

---

* Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 1 т. 391 б.

[10] *Бохараи шәриф күргән кеше...* – «Бохара мәдрәсәләрендә укып кайткан кеше» мәгънәсендә.

[11] *Зәкят* – ислам дине буенча сәүдәгәрләргә еллык керемнең кырыктан бере күләмендә салынган налог.

[12] *Гошер* – уңышның уннан бере күләмендәге дини налог.

[13] *Зөфаф кичәсе* – кыз янына кияү булып керү киче.

[14] *Фатиха* – Коръәннең беренче сүрәсе, ризалык биреп, уңышлар теләп укыла.

[15] *Мәһәр* – никах вакытында кияү тарафыннан кыз ягына бирелә торган мал, акча, калым.

[16] Икенче пәрдәдә катнашучылар исемлеге юк.

[17] *Дәҗҗал* – дини-фантастик алдакчы, мәкерле зат; үзенә ияргәннәрне оҗмахка дип тәмугка кертә, имеш.

[18] *Мәһди* – кыямәт җиткәч җир йөзенә килеп, кешеләрне туры юлга төшерүче зат.

[19] Бу строфа «Тәкый гаҗәб» китабыннан алынган. Г.Камал шуңа пародия рәвешендә пьесаның икенче пәрдәсен язган.

[20] *Ифтар* – уразада авыз ачтыру, сыйлау.

[21] *Фитра (фытыр)* – авыз ачу сәдакасы.

[22] *Корбан* – дини йола буенча савап өчен хайван чалып, итен өләшү. Аллага бүләк китерү, аның рәхим-шәфкатен казану.

[23] *Иблис* – дин буенча Аллага каршы баш күтәргән, мәңгегә ләгънәтләнгән, шайтанга әверелгән мифик зат.

[24] *Тәүбә капкалары* – дини өйрәтүләр буенча замана ахырында, кыямәт көнне, тәүбә капкалары ябылачак. Тәүбә итсәң дә, кабул булмаячак, димәк.

[25] *Аять* – Коръән сүрәләрендә аерым җөмләләр, бәетләр.

[26] *Нәзер-нияз* – дини караш буенча адарыну, кемнең дә булса үзе өстенә үзе алган эш, шартлы вәгъдә һәм илаһи көчләрдән үтенү, ялвару йоласы.

[27] *Яәҗүҗ-мәәҗүҗ* – дини риваятьләрдәге ике халык исеме.

[28] *Дөббәтел арыз* – дини мифология буенча кыямәт көнне барлык туфракны ашап бетереп килүче хайван.

[29] *Туран* – иранлылар тарафыннан төрки халыклар яшәгән урыннарга бирелгән исем. Монда Г.Камал «Бөек Туран» дәүләте оештыру турындагы хыяллардан көлә.

107 бит.

**Могҗиза**. 1930 елда язылган дип уйланыла. Беренче тапкыр «Әсәрләр»дә (1935) басылган. Яңалифчә кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 13 сакл. б.).

[1] *Шәмаил* – зур хәрефләр белән язылган, төрлечә бизәп эшләнгән Коръән сүрәләре, догалар. Имеш, аларны өеңдә тотсаң, йортка тынычлык килә, җен-пәриләр кача.

[2] *Икенде* – кояш баер алдыннан укыла торган өченче намаз вакыты.

[3] *Акшам* (*ахшам*) – кояш баегач ук укыла торган дүртенче намаз вакыты.

[4] *Кадер кичәсе* – искечә рамазан аеның 26 нчы көнендә була торган бәйрәм. Бу төнне күк капкасы (күк капугы) ачыла дип ышанганнар. Аны күргән кешеләр гөнаһсыз булалар дигәннәр. Бу кичне зурлап мондый мөнәҗәтләр әйткәннәр:

Бу Кадер кич – җылда бер кич –
Барча кичләр изгесе.
Пакьләнер ул, сафланыр ул –
Мөэмин мөселман көзгесе.

[5] *Җәбраил галәйһиссәлам* – дини өйрәтүләр буенча иң бөек дүрт фәрештәнең беренчесе (христианнарда – Гавриил), Алланың җирдәге вәкиле. Имеш, ул баскан туфракны җансыз нәрсәгә салсаң, ул җанлана. Аның икенче исеме – Рухулла – Алланың рухы.

[6] *Ак пыраклар* – дини риваятьләр буенча җәннәттәге канатлы ак атлар.

[7] *Җиде газизләр* – пигамбәр дәрәҗәсендәге мөселман изгеләре. Имам Әгъзам (Ногъман бине Сабит), Мәхмүд Газнави, Хуҗа Баһаветдин-Нәкышбәнди, Әхмәт Ясәви кебек ислам динен таратуга, ныгытуга зур өлеш керткән шәхесләр. Заманга, ил-җир аермалыкларына, хакимнәр политикасына карап, дини аермалыклар буенча төзелгән «җиде газизләр» исемлеге тарихта үзгәреп торган.

[8] «*Сөбател-гаҗизин*» («*Аллага ялваруда ныклык*») – суфи Аллаһиярның (1624–1713) мөселманнар арасында киң таралган китабы.

[9] *Нәфел корбаны чалу* – дин тарафыннан мәҗбүри кушылмаган, савап өчен ирекле эшләнә торган корбан.

[10] *Хуҗа Баһаветдин* – Идел буе һәм Себер мөселманнары суфилыгының нигезен салучы, алар арасында изге булып танылган кеше. 1389 елда үлгән, Бохарадан җиде чакрым ераклыкта күмелгән.

[11] *Хозер галәйһиссәлам* (*Хозер һәм Ильяс*) – дөнья беткәнче үлмичә кешеләргә яхшылык эшләп йөрергә алынган изгеләр.

[12] *Мәсихле читек* – дини кагыйдәләр буенча һәр намаз алдыннан аяк юып тулы тәһарәтләнмәстән, читекне юеш кул белән сыйпап шартлы аруланудан соң читек мәсихле була дип карала.

122 бит.

**Күзсез мастерлар**. Г. Камал, персональ пенсионер булгач, 1931–1932 елларда сукырлар арасында җәмәгать эшләре алып бара. Ул Наркомсобес клубында сукырлар өчен драмтүгәрәк оештыра. Аның репертуары өчен махсус пьеса яза, режиссер буларак сәхнәгә куя. Пьесаның берничә кулъязма варианты булган. Яңалифчә язылган бер кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 10 сакл. б.), анысы бу томның «Кушымта»сында бирелә. Икенче бер варианты 1933 елда «Өч тормыш» пьесасы белән бергә басылган (Г. К а м а л. Өч тормыш. Казан: Таттосиздат, 1933). «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938) китапларына да кертелгән.

129 бит.

**Бозау**. Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 3 сакл. б.). Кулъязманың титул битендә «Подлежит к выпуску и постановке. Препятствие со стороны худ. отдела не встречается. За завед. худ. отд.» дигән резолюция, имзалар һәм «17. XI – 1922 г., 27.XI – 1922 г.» даталары бар. Әмма әсәрнең төгәл кайчан язылуы ачык билгеле түгел.

142 бит.

**Җантаһир белән Җанзөһрә**. 1924–1925 еллар тирәсендә язылган дип уйланыла. Беренче тапкыр «Әсәрләр» (1935) җыентыгында басылган. «Сайланма әсәрләр»гә (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән. Бу ике басмада әсәр исеме астына «Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә»сенә пародия» дип искәрмә бирелгән.

Мулла кызы белән мәзин улын легендар Таһир, Зөһрә урынына куеп, ирония белән язылган бу әсәрендә Г.Камал Ф.Бурнашта файдаланылган күптәнге романтик сюжетны сыйнфый ноктадан карап һәм романтизмны шул замандагыча үги күреп, сатирик юнәлештә җирләштерә. Шул ук максат белән пьесаның шигъри ягын да «канатсыз» итә. Романтик әдәбият геройларының зур мәхәббәте, саф хисләре белән ча-

гыштырганда, Җантаһир белән Җанзөһрә мәхәббәте, морале, уй-хисләре көлке, түбән. Аларның эти-әниләре – мулла, мәзин, абыстайлар да шундый хәлгә куелган. Бу яктан әсәрнең соңгы строфасы бик характерлы. Анда әлеге ике гашыйк «шыр тиле» дип бәяләнә. Замандашлары хәтерләвенчә, бу пьеса сәхнәдә куелганда, Ф. Бурнаш аны бик кызыксынып карый торган булган.

### Эстрада әсәрләре

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңеп, илдә яңа тормыш төзү өчен көрәш барган елларда, Г.Камал, завод-фабрикаларда булып, андагы эшләр белән якыннан танышып, көннең актуаль мәсьәләләренә караган яңа агитацион әсәрләр иҗат итә. 1931 елдан башлап Казан мех фабрикасында аеруча еш булып, шундагы конкрет материалга таянып, эстрада өчен җыйнак пьесалар, скетчлар яза. Заманы өчен яңа жанр булган һәм бик җанлы кабул ителгән әлеге әсәрләр бүген инде «күк күлмәкләр» тарихының бер сәхифәсе булып күренсәләр дә, шул көннәрнең көрәш рухын, татар совет эстрада сәнгатенең сугышчан үткән елларын чагылдырулары белән әһәмиятле мирас булып торалар.

159 бит.

**Контроль будкасы.** 1930 елда язылган булуы ихтимал. Яңалифчә кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 21 сакл. б.).

[1] *Мездрильщик* – тиренең эчке ягын эшкәртүче, калдык ит, май катламнарыннан арындыручы эшче.

[2] *Җуеш скабачы (скобарь)* – «скоба» сүзеннән. Юеш тирене скоба («П» хәрефедәй агач тоткалы тимер кыргыч) белән кырып эшкәртүче – юеш скабачы.

[3] *Җуеш* – «юеш» сүзен бозып әйтү. Ике мәгънәдә аңлашыла: русча «жуешь» (ашарга, чәйнәргә), татарча «җуеш» (югалтыш, урлаш).

[4] *Профессор Визе Төньяк боз диңгезендә яңа бер атау эзләп тапкан...* – Визе Владимир Юльевич (1886–1954), Арктиканы өйрәнүче совет галиме, СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты. Аның фәнни җитәкчелегендә оештырылган «Георгий Седов» пароходы фәнни экспедициясе 1930 елда Карский диңгезендә яңа утрау ача. Аңа «Визе утравы» дип исем бирелә. В.Ю.Визе ул утрауның булуын, теоретик рәвештә нигезләп, 1924 елда ук әйткән була.

[5] *Троцкийчы. Троцкизм* – социалистик революциянең күренекле вәкиле Л.Д.Троцкий (Бронштейн, 1879–1940) исеме белән аталган агым. Советларга каршы эш алып бара дип, Троцкий 1929 елда СССРдан сөрелә, ә 1932 елда совет гражданлыгыннан мәхрүм ителә.

174 бит.

**Җанлы кино**. Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 19 сакл. б.).

[1] *Сирийный (сырейный) цех җуыш скабасында* – чимал цехының юу-кыру бүлегендә.

178 бит.

**Казаннан хатлар**. Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 20 сакл. б.).

[1] *ОМКУЗ* (*Овчинно-мерлушечно-каракулевая фабрика и утильзавод*) – Сарык, яшь бәрән-каракүл тиреләрен эшкәртү һәм шуның калдыкларыннан әйбер эшләү заводы.

182 бит.

**Аҗак белән Кужак (1).** Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 20 сакл. б.).

[1] *Болак* – Казандагы Уң Болак һәм Сул Болак урамнары буйлап үткән канал-елга.

[2] *Яңа бистә* – хәзерге Казанның Идел буе районына кергән бер өлеше.

[3] *Арча кыры* – хәзерге Казанның Н.Ершов кыры дип аталган урыны.

185 бит.

**Аҗак белән Кужак (2).** Тәмамланмаган. Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 20 сакл. б.).

186 бит.

**Ике туган Алкоголь, Прогул.** Кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 18 сакл. б.).

189 бит.

**Прорывлар (1).** Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 20 сакл. б.).

191 бит.

**Прорывлар (2).** Кулъязмасы Г. Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 20 сакл. б.). Ахырына кушымта рәвешендә чәнечкеле җырлар бирелгән.

[1] *ОМКУЗ* – 452 биттәге искәрмәне карагыз.

193 бит.

**Һиндстан факире.** Ике варианты бар; бер вариантының ахыры юк. Гарәп графикасындагы кулъязмалары Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 28 сакл. б.).

[1] *...окунчнидәге (окунуть)...* – чимал цехында тирене суга батырып җебетү бүлегендәге.

[2] *...сириный (сырейный) стригальный цехындагы* – чималның (тиренең) йонын тигезләп кыскарту цехындагы.

198 бит.

**Корфетдин белән Торфетдин.** Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 22 сакл. б.).

[1] *ЗРК (Закрытый рабочий кооператив)* – завод-фабрика эшчеләрен оешкан төстә азык-төлек һәм башка көнкүреш нәрсәләре белән тәэмин итү өчен төзелгән. 1932 елдан ОРС (Отдел рабочего снабжения) итеп үзгәртелгән. ЗРКның һәр предприятиедә кибетләре, лареклары булган, анда карточка һәм ордерлар белән кирәкле нәрсәләр сатылган.

[2] *СРК (ЦРК)* – КЦРК (Казанский центральный рабочий кооператив)ның үзгәртеп әйтелеше. КЦРКның кибетләре, ашханәләре шәһәрдә булган. Икмәк сату да шушы оешма карамагында башкарылган. КЦРКның идарәсе Казанның, хәзерге Бутлеров һәм Маяковский урамнары чатындагы йортта, элекке «Вузовец» кинотеатры бинасында урнашкан булган.

203 бит.

**Хатип белән Латип.** Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 23 сакл. б.).

206 бит.

**Ударник һәм бездарник.** Гарәп графикасындагы төп кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 24 сакл. б.). Шунда ук әсәрнең беркадәр үзгәртелгән икенче бер варианты да бар.

208 бит.

**Ударник.** Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г. Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 25 сакл. б.).

### Шигырьләр

*(1905–1910)*

1905–1910 елларда Галиәсгар Камал «Казан мөхбире», «Азат», «Азат халык» кебек газеталарда һәм «Яшен» журналы битләрендә шигырьләрен дә бастыра. Буржуаз-демократик революция иллюзияләре тәэсирендә язылган бу шигырьләрдә әдип «милләт кирәген» кайгырта: мәгърифәт, һөнәр, фән, культурага өнди, бердәмлек, дуслык фикерләрен куәтли, искелеккә, кадимчелеккә каршы көрәшә. Алар шул чор татар әдәбиятының характерлы мисалы, Г.Камал иҗат эволюциясенең үзенчәлекле бер этабы буларак кыйммәтлеләр.

210 бит.

**Азатлык.** «Казан мөхбире» газетасының 1905 ел, 28 ноябрь (8) санында «Саип» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

*«Казан мөхбире»* – 1905–1911 елларда Казанда чыккан газета.

[1] *«Победонос»ның кулы...* – Победоносцев, 1890–1917 елларда Россиядәге православие чиркәүләренең башлыгы, Эчке эшләр министрлыгында реакционер чиновник.

211 бит.

**Өндәү.** «Казан мөхбире»нең 1905 ел, 14 ноябрь (5) санында «Саип» имзасы белән басылган.

[1] *Петербурга, мәсҗед салаек...* – 1905 ел революциясе биргән кайбер иркенлекләр белән рухланып, Г.Камал вакытлыча конституцион иллюзияләргә дә бирелеп ала. Аң-белем, һөнәр, фәнне олылау белән бергә, ул динне яхшыртуны да алга сөрә. Динне яхшырту турындагы фикерләрнең 1906 елгы шигырьләрендә куерып китүенең җитди бер сәбәбе бар. 1906 елның беренче февраленнән башлап, Казан мулласы Габдулла Апанаев белән бергәләшеп, Г.Камал «Азат» газетасын чыгара башлый. Ләкин газета чыгаруга рөхсәт алу һәм материаль мөмкинлек булдыру нияте белән туган бу «бердәмлек» озакка бармый, Габдулла мулла газетаны динчеләр, милләт яклылар органы итәргә, Г.Камалның да шул юнәлештә генә язуын тели. Г.Камал исә газетаның искелеккә каршы көрәшүче, демократик фикерләр таратучы орган булуын тели. «Азат»ның 56 нчы саны чыккач, Габдулла мулла газетаны ташлап китә. Революцион рухтагы мәкаләләр дә басылсын, патша хөкүмәте газетаны ябмасын, материаль мөмкинлек булсын дип тә язылган чуар фикерле кайбер шигырьләр әнә шундый шартларда туганнар. Г.Камалның төп фикерләре «Азат халык» газетасы битләрендә ачыграк чагыла.

212 бит.

**Русиядә мөселманнар.** «Казан мөхбире»нең 1905 ел, 19 декабрь (14) санында «Саип» имзасы белән басылган.

213 бит.

**Безнең кирәк**. «Азат» газетасының 1906 ел, 9 февраль (4) санында «Һади» псевдонимы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

*«Азат»* – 1906 елның 1 февраленнән 1906 елның 24 маена кадәр (барлыгы 56 сан) чыккан газета. Нашире – Г.Апанаев, фактик редакторы – Г.Камал.

[1] *Безне җиңгән япунга...* – 1904–1905 еллардагы рус-япон сугышында патша армиясенең хурлыклы җиңелүенә ишарә.

215 бит.

**«И мөселман, йокламагыл...»** «Азат»ның 1906 ел, 12 февраль (5) санында «Һади» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

217 бит.

**Милләт көймәсе**. «Азат»ның 1906 ел, 3 март (12) санында «Һади» имзасы белән басылган.

219 бит.

**Йокыда**. «Азат»ның 1906 ел, 7 март (13) санында «Һади» имзасы белән басылган.

221 бит.

**Егъламаган балага имчәк бирмиләр**. «Азат»ның 1906 ел, 7 май (45) санында «Һади» имзасы белән басылган.

223 бит.

**Вакыт җитте**. «Азат халык» газетасының 1906 ел, 12 сентябрь (15) санында «Һади» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

*«Азат халык»* – 1906 елның 4 июненнән 12 сентябренә кадәр (барлыгы 15 сан) Казанда Г.Камал наширлегендә һәм редакторлыгында чыккан демократик юнәлештәге газета.

[1] *Курапаткин...*– Куропаткин А.Н. (1848–1925) – патша генералы. 1898–1904 елларда Россиянең хәрби министры. Рус-япон сугышында булдыксызлыгы белән таныла.

226 бит.

**«Яшен» сукмасын өчен**. Догалык китапларына пародия рәвешендә язылган. «Яшен» журналының 1908 елгы 1 нче (3 август) санында «Мәҗмәгыйддәгъват»тан күчереп язучы «Сагыйка» («Яшенче») имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *«Яшен»* – 1908 елның августыннан 1909 елның июненә кадәр (барлыгы 10 сан) Казанда Г.Камал редакторлыгында, Г.Тукайның якыннан катнашы белән чыккан демократик юнәлештәге рәсемле сатирик журнал.

[2] *«Сөннәт»...* – Мөхәммәт пигамбәр турындагы риваятьләргә, Коръәнгә өстәмәләр, аңлатмалар. Сөннәтне таныган мөселманнар, андагы өстәмәләр бик мәҗбүри булмасалар да, шуларны да үтәргә тырышканнар. Өч-дүрт хатын алу да әнә шундый мәҗбүри булмаган нәрсә.

[3] *...Бохарилар мәҗлесенә...* – Бохарада укыган муллалар мәҗлесенә. Дөньяга, ислам догмаларына карашлар аермалыгы күз алдында тотыла.

227 бит.

**Оренбур – Казан.** «Яшен»нең 1908 елгы 5 нче (17 декабрь) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *«Бакырган»* – революциягә кадәр татарлар арасында киң таралган шигырьләр җыентыгы. 1846 елда Казанда басылып чыккан. Урта Азиянең суфи шагыйре Сөләйман Бакыргани (1186 елда үлгән) шигыре белән ачыла.

[2] *Рәмиевләр* – Урал якларында алтын приискалары тоткан Закир (1859–1921) һәм Шакир (1857–1912) Рәмиевләр. Алар «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы хуҗалары да булганнар.

[3] *Мәхмүд бай* – Мәхмүд Хөсәенев (1840–1912), Оренбургның миллионер сәүдәгәре.

[4] *Юнусовлар* – Казанда яшәгән консерватив карашлы алпавытлар.

[5] *«Вакыт»* – 1906 елның 21 февраленнән 1918 елның 26 гыйнварына кадәр Оренбургта Фатих Кәрими (1870–1937) редакторлыгында чыккан либераль-буржуаз газета.

[6] *«Чүкеч»* – Оренбургта 1906–1910 елларда чыккан рәсемле көлке журналы.

[7] *«Йолдыз»* – 1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр Казанда Әхмәтһади Максуди (1868–1941) наширлегендә һәм редакторлыгында чыккан газета.

[8] *«Ислах»* – 1907–1909 елларда Казанда чыккан демократик юнәлештәге «Әлислах» газетасы.

[9] *«Яшен»* – 455 биттәге искәрмәне карагыз.

[10] *«Шура»* – 1908 елның 10 гыйнварыннан 1918 елның гыйнварына кадәр Риза Фәхретдинов (1858–1936) редакторлыгында чыккан әдәби-фәнни журнал.

229 бит.

**Мәхбүс шаһзадә**. Халык авыз иҗатына таянып, бәет стилендә язылган бу шигырь беренче мәртәбә 1908 елда Казанда «Шигырьләр» мәҗмугасыннан «беренче китап»та «Г.Камал» имзасы белән басылып чыга. Заманында шигырь бик зур популярлык казана. Бу хакта, мәсәлән, Г.Ибраһимов үзенең «Яңа әсәрләр» исемле мәкаләсендә (Татарстан хәбәрләре. 1921. 6 май) болай дип искә алып үтә: «Аның (Г.Камалның. – *Н.Х.*) «Мәхбүс» атлы бер мәнзумәсе бөтен татар яшьләре тарафыннан ятланган, унбиш еллар буенча телдән, сәхнәдән төшми йөргән бер нәрсә иде».

230 бит.

**«Тәкый гаҗәб»**. «Яшен» журналының 1909 елгы 6 нчы (31 гыйнвар) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *«Тәкый гаҗәб»* – тезмә белән язылган дини китап, революциягә кадәр схоластик мәктәпләрдә дәреслек буларак кулланылган. Аның һәр бәете: «Андин артык тәкый гаҗәб дыңларый вар» («аннан артык тагы да гаҗәбрәк хәлләр ишетерсез әле») дип тәмамлана.

[2] *Бәдәлчеләр* – акчага ялланып, кеше өчен хаҗга баручылар.

231 бит.

**Бәйрәм хәзерлекләре**. «Йолдыз»ның 1910 елгы 589 нчы санында «Яшенче» псевдонимы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] Шигырьнең икенче өлеше, элек схоластик мәктәпләрдә укытылган «Кызыл алма» китабындагы әсәр формасын файдаланып, «тидия» сүзе кабатлап язылган.

[2] *Фытыр...* – Ураза бәйрәме хөрмәтенә бирелә торган сәдака – авыз ачу сәдакасы.

---

Мәнзумә – дастан.

## Декламацияләр

*(1918–1921)*

1918–1919 елларның канлы көрәш көннәрендә Г.Камал яңадан үзенең сыналган оператив жанрына – шигъри публицистикага мөрәҗәгать итә: «Эш» (1918–1920 елларда Казанда чыккан газета, хәзерге «Социалистик Татарстан»ның элгәресе), «Эшче» (1920 елларда Казанда, Мәскәүдә чыгып килгән газета), «Кызыл көрәшче» (1918–1919 елларда Казанда чыккан гаскәри газета) битләрендә көн саен диярлек үткен сатирик шигырьләрен бастырып килә. Соңыннан, 1921 елда, бу шигырьләр барысы бергә тупланып һәм яңалары да өстәлеп, «Декламацияләр» исеме астында аерым китап булып басылып чыгалар (К а м а л Г. Декламацияләр. Казан: Шәрекъ коммунистлары мәркәз бюросының нәшере, 1921).

Г.Ибраһимов тарафыннан югары бәяләнеп, «революция бәетләре» дип аталган бу шигырьләр томга әлеге «Декламацияләр» китабындагы басма текст һәм тәртип буенча урнаштырылды.

233 бит.

**Яңа «Тәкый гаҗәб».** «Эш» газетасының 1918 ел, 13 сентябрь (61) санында басылган*. «Октябрь революциясенең бер еллык бәйрәме бүләге» (1918) дип исемләнгән шигырьләр җыентыгына, «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар поэзиясе антологиясе»** китапларына да кертелгән. Шигырьнең исеме астына «Әүлия һәм компаниясе»нең дип язылган. Әсәр шул заманның актив журналистларыннан берсе Вәли Шәфигуллин (1894–1939) белән бергәләп иҗат ителгәнгә, Г.Камал шул искәрмәне куллана. Мондый искәрмә сигез шигырьдә очрый. Әүлия – В. Шәфигуллинның псевдонимы.

[1] *«Тәкый гаҗәб»* – 456 биттәге искәрмәне карагыз.

[2] *Җеназа мәйданы...* – Казанның Г.Тукай исемендәге кинотеатры каршындагы бакча урынындагы мәйдан элек шулай аталган.

[3] *Лебедев* – 1918 елда Казанга кергән контрреволюцион ак чехларның гаскәр башлыгы. Татар буржуазиясе аңа зур ышаныч багълый, материаль ярдәм күрсәтә.

[4] *...особыйлар...* – ак чехларның Самарадагы штабыннан Казанга җибәрелгән махсус вәкилләр. Алар арасында Ильяс Алкин да була. Г.Камал: «Аның берсе – «мөселман»-мөэмин, ирмеш», – дип шуңа ишарәли.

235 бит.

**Тагы «Гаҗәб» китабы**. «Эш»нең 1918 ел, 17 сентябрь (64) санында басылган. Кабат «Октябрь революциясенең бер еллык бәйрәме бүләге» (1918) җыентыгына, «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) дә кертелгән. «Әүлия һәм компаниясе» дигән искәрмәсе бар.

[1] Монда да иске «Тәкый гаҗәб» формасына пародия.

[2] *Вәли* – Вәли Шәфигуллин. Г.Камал кайбер декламацияләрен аның белән бергәләп язган, шуңа ишарә.

[3] *Ишан Гали* – Г.Камалның псевдонимы. «Эш» газетасында шушы псевдоним белән бик күп шигырьләрен бастырган.

---

* Алга таба даталар яңа стиль буенча күрсәтеләчәк.

** Татар поэзиясе антологиясе / төз.: М.Гайнуллин, Х.Госман, Ә.Исхак һ.б. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Моннан ары «Татар поэзиясе антологиясе» (1956) дип кенә күрсәтеләчәк.

237 бит.

**«Кызыл алма» китабы**. «Эш»нең 1918 ел, 23 сентябрь (69) санында «Әүлия һәм компаниясе»нең имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән. Стилендә иске схоластик мәктәпләрдә укытылган «Кызыл алма» яки «Ярым алма» әсәренең формасы файдаланылган.

239 бит.

**«Ак»ка шөкер» китабы**. «Эш»нең 1918 ел, 20 сентябрь (67) санында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсирләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Көрәш еллары» (1958)* китапларына кертелгән. Бу шигырендә Г.Камал иске схоластик мәктәпләрдә укытылган «Хакка шөкер» исемле көйле дини әсәрнең формасын файдалана. Шигырьнең исеме астында «Әүлия һәм компаниясе»нең дигән искәрмәсе бар.

241 бит.

**Өр-яңа «Кисекбаш» китабы**. «Эш»нең 1918 ел, 19 сентябрь (66) санында «Әүлия һәм компаниясе»нең дигән имза белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр» (1951) китапларына кертелгән. Иске «Кисекбаш» китабына пародия рәвешендә язылган. Г.Тукайның да шул әсәргә пародиясе «Яңа Кисекбаш» поэмасы булуын искә алып, Г.Камал үз әсәрен «Өр-яңа «Кисекбаш» китабы» дип атый.

[1] *...демократ...* – сүздә халык өчен дигән булып, чынлыкта үз байлыгы өчен тырышучыларга ишарә. Г.Тукай Карәхмәттән көлгән алымны файдалана.

243 бит.

**«Бакырган» китабы**. «Эш»нең 1918 ел, 21 сентябрь (68) санында басылган. Исеме астында «Әүлия һәм компаниясе»нең дигән искәрмә бар. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951) китапларына да кертелгән. «Бакырган» – Октябрь революциясенә кадәр татарлар арасында киң таралган «Бакырган китабы»на төрле шагыйрьләрнең әсәрләре тупланган була. Урта Азия суфи шагыйре Сөләйман Бакыргани (1186 елда үлгән) шигыре белән ачылган бу китапта җәннәт белән тәмуг сөйләшүе формасындагы диалог бар. Г.Камал, шул форманы файдаланып, 1908 елда «Яшен» журналында «Оренбур – Казан» исемле пародия шигырен бастырып чыгара, ә Гражданнар сугышы елларында, шул ук форманы кулланып, «Бакырган китабы» пародиясен иҗат итә.

[1] *«Әүлия»га иптәшлеккә компанионы җигелде...* – Г.Камалның журналист Вәли Шәфигуллин белән бергә «Эш» газетасында эшли башлавына ишарә.

245 бит.

**Истикъбаль**. «Эш»нең 1919 ел, 3 декабрь (360) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган.

246 бит.

**«Бәдәвам» китабы**. «Эш»нең 1918 ел, 8 октябрь (70) санында «Әүлия һәм компаниясе»нең дигән имза белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956) китапларына да кертелгән. Г.Камал бу шигырен

---

* Көрәш еллары (Совет Армиясенең 40 еллыгына багышлап чыгарылган әдәби җыентык) / төз.: М.Садри, С.Мортазин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. Моннан ары «Көрәш еллары» (1958) дип күрсәтеләчәк.

Болгар дәүләте чорында язылган, авторы билгесез көйле әсәр – «Бәдәвам» калыбын файдаланып иҗат итә. «Бәдәвам» беренче тапкыр Казан университеты типографиясендә 1846 елда басыла, аннан соң күп тапкырлар кабат чыгарыла.

250 бит.

**Мин сөям.** «Эш»нең 1918 ел, 30 сентябрь (74) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. Шул ук елны «Октябрь революциясенең бер еллык бәйрәме бүләге», соңыннан «Декламацияләр» (1954)*, «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952)**, «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

251 бит.

**Ять (Ѣ) һәм ия (ія)не бетерү.** «Эш»нең 1918 ел, 24 декабрь (128) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

1918 елның 10 октябрендә Совнарком «Яңа орфография кертү турында» декрет чыгара. Шул декрет буенча, иске рус орфографиясендәге кайбер артыклыклар, уңайсызлыклар бетерелә. Г.Камал, шуларның икесен сүз уйнату рәвешендә телгә алып, шигырендә империалистларның яулап алу политикасын фаш итүдә файдалана.

[1] *Вильсон* – Вудро Вильсон (1856–1924), 1912–1921 елларда АКШ президенты.

252 бит.

**Бай – кибетче.** «Эш»нең 1919 ел, 10 февраль (165) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Яңа декламатор» (1925)***. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

254 бит.

**Ниләр бетте, ниләр калды?** «Эш»нең 1919 ел, 12 февраль (167) санында «Ишан Гали» псевдонимы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

256 бит.

**Сөйләшү.** «Эш»нең 1919 ел, 14 февраль (169) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *«Милләт эшләре» ни булды?* – күп кенә оештыру мәсьәләләре каралып, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелгәнче язылган әлеге шигырьнең бу юлларында милли мәсьәләләрне тулысынча хәл итүне ашыктыру теләге белдерелә.

[2] *«Гыйльми һәйьәт» эше ничек?* – 1918 елның 23–31 маенда Казанда Бөтенроссия мөселман укытучылар съезды эшли. Съезд мөсел-

---

* 1954 елда Г.Камалның уналты декламациясе аерым китап булып кабат басылган (К а м а л Г. Декламацияләр. Казан: Таттосиздат, 1954). Алга таба бу басма «Декламацияләр» (1954) дип кенә күрсәтеләчәк.

** Татар совет поэзиясе / төз. С.Хәким, А.Гомәров. Казан: Таттосиздат, 1952. Моннан ары «Татар совет поэзиясе» (1952) дип кенә күрсәтеләчәк.

*** Яңа декламатор / төз. Мөкәррәм Мәһдиев. Мәскәү: «Нәшрият», 1925. Моннан ары «Яңа декламатор» (1925) дип кенә күрсәтеләчәк.

маннар арасында гыйльми эшләрне, аерым алганда, мәктәпләр өчен дәреслекләр әзерләүне һәм бастыруны юлга салу өчен Гыйльми һәйәт (коллегия) төзи. Соңрак ул Үзәк мөселман комиссариаты карамагына күчә. Яңа оештырылган бу Үзәк тиз генә арада әллә ни зур эш күрсәтеп өлгерә алмый. Биредә шуңа ризасызлык белдерелә.

257 бит.

**Яңа «Башмак» көе**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) дә басылган. Татар халык җыры «Башмагым»а пародия.

259 бит.

**Маленькие недостатки механизма**. «Эш»нең 1919 ел, 28 гыйнвар (154) санында имзасыз басылган. «1918 ел кыш көне «Эш»тә басылды» дигән искәрмәсе бар. Димәк, «1918» ел – ялгыш, дөресе – «1919» ел. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

260 бит.

**Пәрәвез**. «Эш»нең 1919 ел, 30 гыйнвар (156) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

261 бит.

**Ярлының җыруы**. «Эш»нең 1919 ел, 7 февраль (163) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

262 бит.

**Кар көрәгәндә**. «Эш»нең 1919 ел, 9 февраль (164) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

264 бит.

**Татарга**. «Эш»нең 1919 ел, 19 февраль (173) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган.

265 бит.

**Кызыл армияле һәм спекулянт**. «Эш»нең 1919 ел, 4 март (183) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган.

267 бит.

**Буржуй зары**. «Эш»нең 1918 ел, 13 декабрь (120) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

268 бит.

**Яңа типта халык җырлары**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» дә (1921) басылган, соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

269 бит.

**Ирек нуры**. «Эш»нең 1919 ел, 19 май (228) санында «Кызыл» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

270 бит.

**Сез һәм без**. «Эш»нең 1919 ел, 20 май (229) санында «Кызыл» имзасы белән басылган.

271 бит.

**Буржуй планы**. «Эш»нең 1919 ел, 13 гыйнвар (142) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951) кертелгән.

273 бит.

**Чагыштыру**. «Эш»нең 1919 ел, 15 гыйнвар (144) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Яңа декламатор» (1925), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *Газраил* – дини өйрәтүләр буенча кешеләрнең җанын алучы фәрештә.

[2] *Зобани* – тәмуг палачы.

275 бит.

**Корсак**. «Эш»нең 1919 ел, 19 гыйнвар (147) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

277 бит.

**Бер, ике, өч**. «Эш»нең 1919 ел, 26 гыйнвар (152) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

278 бит.

**Игенченең зары**. «Эш»нең 1919 ел, 27 гыйнвар (153) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

279 бит.

**Галәбә**. «Эш»нең 1919 ел, 28 гыйнвар (154) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

280 бит.

**Актык йомрык**. «Эш»нең 1919 ел, 22 апрель (222) санында «Кызыл» имзасы белән басылган. Колчак гаскәрләренең Идел һәм Кама буйларыннан куылуы уңае белән язылган. Исеме астында җәяләр эчендә «1919 ел, 22 апрельдә язылган» дигән искәрмәсе бар. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *Фиргавен (фараон)* – борынгы Египет патшаларының титулы. Үзен җирдәге Алла дип санап, Муса пигамбәр кешеләрен куа барганда Нилгә батып үлгән патшага ишарә.

[2] *Хамнар* – дини мифология буенча Нух пигамбәр балаларының берсе (Хам) этисеннән мыскыллап көлгән. Шуның өчен иң изге нәрсәләрне мыскыллаган кешеләрне «хам» диләр. Хамның токымы хамнарга да шул яман сыйфат хас, имеш.

[3] *Туфан* – бөтен дөньяны су басу.

281 бит.

**Байлар бишеге**. «Эш»нең 1918 ел, 4 октябрь (77) санында имзасыз басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

283 бит.

**Флот килә.** «Эш»нең 1919 ел, 25 апрель (224) санында «Кызыл» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән. Бу шигырь Камада Колчакка каршы флот төзелү уңае белән язылган. «1919 ел, 25 апрельдә язылган» дигән искәрмәсе бар.

[1] *Бабил кошлары...* – Коръәннең «Фил» сүрәсендә гадәттән тыш зур Һабабил кошларының мөселманнарга ярдәмгә очып килеп, ислам дине дошманнарын кырып ташлаулары турында сөйләнә. Биредә шул кошлар образы файдаланыла.

285 бит.

**Нәүрүз мөбарәк бад!** «Эш»нең 1918 ел, 7 ноябрь (93) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *Нәүрүз* – төрки халыкларда бик борынгыдан килгән Яңа ел бәйрәме. Элек яңа елны табигать уянган вакыттан – март башыннан хисаплаганнар. Шул бәйрәм уңае белән, йорттан йортка кереп, «Нәүрүз бәете» әйтеп котлап йөргәннәр. Бәетнең эчтәлеге яңарса да, төп формасы сакланып калган, «Нәүрүз мөбарәк бад!» («Яңа ел котлы булсын!») дигән сүзләре һәр строфада кабатланган. Шушы бәетне файдаланып, Г.Камал революцион эчтәлекле яңа әсәр язган.

[2] *«Эшче»* – 1918 елның 27 сентябреннән чыга башлаган газета. Мөселман коммунистларының мәркәз һәм Казан комитетлары органы. Соңрак Мәскәүгә күчә, «Коммунист» исеме астында 1934 елга кадәр чыга.

287 бит.

**Кызыл армиялеләрнең Беренче май җырлары.** «Кызыл көрәшче» газетасының 1919 елгы 1 нче санында (1 май) имзасыз басылган. Исеме астына «1 май, 1919 ел» дип дата куелган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *Туфан* – шушы биттәге искәрмәне карагыз.

288 бит.

**Нәүрүз (яки Науруз).** Беренче тапкыр «Декламацияләр»дә (1921) басылган. Соңыннан «Әсәрләр»гә (1951) кертелгән. Г.Камалның «Нәүрүз бәете» формасын файдаланып язган икенче шигыре. Беренчесе «Нәүрүз мөбарәк бад!» дип атала.

290 бит.

**Милләтчеләр, динчеләр.** «Эш»нең 1918 ел, 15 ноябрь (98) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Дингә каршы» (1939)*, «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

291 бит.

**Шайтаннар биюе.** Беренче тапкыр «Декламацияләр»дә (1921) басылып чыккан. Соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *Яссыдагы контрреволюционерлар киңәше мөнәсәбәте илә...* – 1917 елның 1–10 ноябрендә Яссы шәһәрендә Антанта вәкилләренең яшерен киңәшмәсе була. Анда чехословаклар корпусын Совет властена каршы көрәштә файдалану мәсьәләсе тикшерелә.

---

* Дингә каршы: әдәби җыентык / төз. Р.Ильяс. Казан: Татгосиздат, 1939.

293 бит.

**Булса да булыр шул**. «Эш»нең 1918 ел, 24 ноябрь (105) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

294 бит

**Караларга**. «Эш»нең 1918 ел, 4 декабрь (113) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

295 бит.

**Вәгазь-нәсихәтләр**. «Эш»нең 1918 ел, 22 ноябрь (104) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

297 бит.

**Бер ел элек**. Беренче тапкыр «Декламацияләр»дә (1921) басылган. «Казанда Болак арты җөмһүрияте бетерелү мөнәсәбәте белән язылган иде» дигән искәрмәсе бар. Соңыннан «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

298 бит.

**Кем көчле?** «Эш»нең 1919 ел, 21 апрель (220) санында «Кызыл» имзасы белән басылган. «1919 ел, 21 апрельдә язылган» дигән искәрмәсе бар. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *«Иттифакъ өчле»* – Россия, Англия, Франция хәрби союзы күздә тотыла.

299 бит.

**Европа җанварлары**. «Эш»нең 1918 ел, 22 декабрь (126) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

301 бит.

**«Ишан Гали» сәяхәте**. «Эш»нең 1919 ел, 4 ноябрь (340) санында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *Китаби...* – христиан яки яһүди динендәге (ягъни мөселман булмаса да, изге китапны – Тәүратны таныган) кеше. Буддистлар һ.б. китабиларга карамый, мәҗүсиләр булып исәпләнә.

303 бит.

**Капитал иярченнәренә**. «Эш»нең 1918 ел, 9 декабрь (116) санында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

304 бит.

**Спекулянтка**. «Эш»нең 1918 ел, 10 декабрь (117) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

305 бит.

**Төш тәгъбире**. «Эш»нең 1918 ел, 11 декабрь (118) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *«Тәгъбирнамә»* – элекке заманнарда киң таралган төш юрау китапчыгы. Шигырь шуңа пародия рәвешендә язылган.

307 бит.

**Таң**. «Эш»нең 1918 ел, 12 декабрь (119) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Эстрада» (1957)*, «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

308 бит.

**Ирек авыруы**. «Эш»нең 1918 ел, 15 декабрь (121) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

309 бит.

**Чегән бәете**. Беренче тапкыр «Декламацияләр»дә (1921) урнаштырылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

311 бит.

**Минем теләк (1).** Г.Камалның шушы исемдә ике шигыре бар. Икесе дә «Декламацияләр» (1921) китабында басылган. Монысы «Булса бик ак сумса...» дип башлана.

313 бит.

**Бай**. «Эш»нең 1919 ел, 5 март (184) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *Нәзер* – теләкләре тормышка ашса, әйбер корбан итәргә сүз бирү, дини вәгъдә.

314 бит.

**Һай дөнья!** Беренче тапкыр «Декламацияләр»дә (1921) басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

316 бит.

**«Матур яр, кенәри» көенә**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *«Матур яр, кенәри» көенә* – «Декламацияләр» (1921) җыентыгында «Матур янар кәнәри» көенә дип язылган. Бу сүзләр «Матур янар шахтер лампасы» дигән мәгънәдә булу ихтимал. Кән – шахта дигән сүз.

317 бит.

**Яңа «Җизнәкәй»**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

318 бит.

**«Арыслан да сөяк ашый...»** Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

---

* Эстрада: үзешчән сәнгать коллективлары өчен репертуар җыентыгы / төз. М.Садри. Казан: Таткнигоиздат, 1957. 3 кит.

320 бит.

**Исемнәр**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

322 бит.

**Бер рәсемгә**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән. Бу шигырь Г.Тукайның шул исемдәге шигыренә дусларча назыйрә-пародия рәвешендә язылган. «Декламацияләр» (1921) китабында икесе янәшә урнаштырылган.

**Бер рәсемгә***

(*Г.Тукай*)

Бик матур бит, бакчы бу кызның күзенә, кашына;
Мең вә мильюн афәрин бу сурәтен нәкъкашына.

Бу озын сачны каян алган икән соң бу кояш?
Күр Ходайның кодрәтене, – бер күзең сал башына.

И кояш! ямьсезлегеңнән син оялырсың, беләм,
Гәр чагыштырсаң йөзеңне син бу бит алмасына.

Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсмен генә,
Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә үз Ләйләсенә[1].

Булсыйде оҗмах түрендә әүвәл үк рәсме моның,
Илтифат итмәс иде Адәм дә үз Хаувасына[2].

Күрсә Һарут берлә Марут[3], юлдан азмаслар иде,
Бәлки, бакмаслар иде шәйтаннары игъвасына.

Татлы ирнен үпсә бер мән, кәүсәреңне[4] нишләсен?
Пар килер ул дөньяның үлмәс Хозер, Ильясына[5].

Күрсийде Иблис ләгыйнь[6] дә, кайда баш тартып йөрү!
Баш иярди сәҗдәгә, кайтып тагын Алласына.

Булмаса сайраулары мәдхе сәнасында моның,
Кит! пычак керсен җиһанның барча сандугачына!

[1] *Ләйлә, Мәҗнүн* – Азәрбайҗан әдәбияты классигы Низами Ганҗәвинең (XII йөз) «Ләйлә вә Мәҗнүн» исемле поэмасы геройлары.

[2] *Адәм, Хаува* – дини мифология буенча җир йөзендәге беренче кешеләр. Алар элек оҗмахта яшәгәннәр, имеш.

[3] *Һарут берлә Марут* – фәрештәләр, кешеләрнең бозыклык эшләүләренә ачынып, шуны бетерү өчен җиргә төшәләр дә, озак та үтми, үзләре дә «юлдан язалар».

---

* Шигырьнең тексты Г.Тукай әсәрләренең соңгы басмасы буенча алынды: Тукай Г. Сайланма әсәрләр. 2 томда. Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. 1 т. 110 б.

Нәкъкаш – художник, рәссам.

Игъва – коткы, вәсвәсә.

Мән – кеше.

Иярди – ияр иде.

Мәдхе сәнасында – мактавында.

[4] *Кәүсәр* – җәннәттәге татлы сулы елга исеме.
[5] *Хозер, Ильяс* – 451 биттәге искәрмәне карагыз.
[6] *Иблис ләгыйнь* – 450 биттәге искәрмәне карагыз.

223 бит.

**Нәрсә сөйләргә кирәк?** Г. Тукайның «Кемне сөяргә кирәк?» исемле шигыренә дусларча назыйрә-пародия рәвешендә язылган һәм «Декламацияләр» (1921) җыентыгында оригиналы белән янәшә басылган. Оригиналның соңгы алты юлы җыентыкта төшереп калдырылган.

**Кемне сөяргә кирәк?**

(*Г.Тукай*)

Белү мөшкил – кирәк кемне сөяргә?
Үзең аусаң да, аудармый сөяргә?

Син үлсәң (бет!), сине кем кызгана соң?
Синең зәхмеңгә кемнәр сызлана соң?

Бу дөньяда сине кем иркәли соң?
Бәлаләрдән сине кем киртәли соң?

Синең соң хәсрәтең кемнәргә хәсрәт?
Гамеңнең кәсрәте кемнәргә кәсрәт?*

Кеше сатмас кеше тапмак асатмы?
Сине соң кайсы дуст дошманга сатмый?

Синең якты көнең кемнәргә тансык?
Кирәксә, яшь җиренә кара кан сык!

Сине кемнәр генә туйдырмый бер дә?
Күңелсез хәлгә кем куйдырмый бер дә?

Г.Тукай бу шигырен А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» романындагы 4 нче бүлекнең XXII строфасын файдаланып язган**.

324 бит.

**Бәрәңге.** Авторы билгесез «Алма» шигыренә назыйрә-пародия рәвешендә язылып, «Декламацияләр» (1921) җыентыгында бер-беренә янәшә урнаштырылган.

**Алма**

Түп-түгәрәк, кып-кызыл алма тәмен белгән кеше
Җан бирердәй гашыйк була, онтыла һәммә эше.

Алма бит ул! Охшаталар аңар хурлар йөзен!
Шомырт төсле матур диләр туташның кара күзен.

---

Мөшкил – читен.
Зәхмеңгә – җәрәхәтеңә, авыруыңа.
*Гамеңнең кәсрәте кемнәргә кәсрәт – кайгыңның күплеге кемнәргә күп булып күренә.
** Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр.,1975. 1 т. 44, 363 б.

«Шул матурны насыйб ит!» – дип ялваралар Аллага,
Кем кызыкмас дөньясында шундый кызыл алмага.

Алданып Адәм, Хаува да оҗмах кызыл алмасына,
Гасый булган, ди, тарихта бөтен галәм Алласына.

Алма бит ул – тәмле бит ул һәр матурның кулында,
Алма ташучы тезелгән бөтен Усия юлында*.

Алма бит ул тәмле, матур: ул кызыл ул, ал да ул,
Вак-вак итеп тешләп аша – шикәр дә ул, бал да ул.

325 бит.

**Әүвәлгечә түгел.** «Декламацияләр» (1921) җыентыгында С.Сүнчәләйнең «Кичә, бүген» дигән шигыре белән янәшә урнаштырылган, шуңа назыйрә-пародия рәвешендә язылган.

**Кичә, бүген**

(*С.Сүнчәләй шигыре*)

Дөньяның вак тормышын бер якка ташлап, ялбарып:
«Син минем кәгъбәм!» – диеп алдында тез чүктем кичә.

Мин аның ак кулларын, ямьле йөзен, диңгез кебек
Күзләрен, авызын, телен, керфекләрен үптем кичә.

Сөешүнең агуын күңел бик сизсә дә, бик янса да,
Түзмәдем мин! – ул фәрештәмнән агу эчтем кичә.

Ә бүген, аһ! ул җыланым, ул! минем «изге хурым»
Нишләде! Бәгъремне үткен тешләде, чакты бүген!

Ул фәрештәм алдады, мискин шагыйрьне алдады.
Бозды антын! Ташлады утка мине, атты бүген.

Шулмы соң ямь! Шулмы изге ант! Сөю, вәгъдә кая?
Ул үтерде, хурлады, күмде мине, якты бүген!

Йөз яме һәм җан яме бер-берсенә башкалыгын,
Әрнетеп күңлем ярасын, Алла аңлатты бүген!

326 бит.

**Бай сүзе**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр» (1979) гә кертелгән.

[1] ...*«чиривкомга!»* (Чрезвычайная комиссия) – Совет властеның беренче елларында контрреволюцион элементларга каршы көрәшү өчен төзелгән комиссия.

328 бит.

**Минем теләк (2).** «Эш»нең 1919 ел, 6 февраль (162) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр»

* Усия (Устье) юлы – Казанның хәзерге Киров районындагы элекке пристань юлы шулай аталган.

Гасый булу – буйсынмау.

(1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

329 бит.

**Бию көе**. «Эш»нең 1919 ел, 6 февраль (162) санында басылган. «Әүлия һәм компаниясе» дип күрсәтелгән. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *Лойд Жорж* – Ллойд Джордж (1863–1945), 1916–1922 елларда Англиянең премьер-министры.

[2] *Видро Вильсон...* – Вудро Вильсон (519 биттәге искәрмәне карагыз).

[3] *Килмансу* – Жорж Клемансо (1841–1929), 1917–1920 елларда Франциянең премьер-министры.

[4] *Пишун* – Пишон (1857–1933), Франциянең тышкы эшләр министры булган кеше.

[5] *Арландо* – Орландо Витторио Эмануэле (1860–1952), 1917–1919 елларда Италиянең хөкүмәт башлыгы.

Исемнәре аталган бу чит ил дәүләт эшлеклеләре – яшь Совет илендәге революцион үзгәрешләргә каршы политика алып барулары белән танылган шәхесләр, интервенция оештыручылар.

330 бит.

***** Буржуйны без яратмыйбыз...** «Эш»нең 1919 ел, 28 март (202) санында «Эшче» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938) китапларына да кертелгән. «Декламацияләр» (1921) китабында «Әүлия һәм компаниясе» дип искәрмә бирелгән.

332 бит.

**Большевизм көрәше**. «Эш»нең 1919 ел, 6 апрель (208) санында «И. Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

333 бит.

**Кызыл кара, кызыл-кара**. «Эш»нең 1918 ел, 13 ноябрь (96) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган.

334 бит.

**Бүген бәйрәм**. «Эш»нең 1919 ел, 12 март (190) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

336 бит.

**Зар**. «Эш»нең 1919 ел, 23 май (232) санында «Кызыл» имзасы белән басылган.

[1] *Дустларым шәп пагунлы руслар...* – сүз патшага турылыклы полиция һәм хәрбиләр турында бара.

338 бит.

**Ике ел**. Октябрь революциясенең ике еллык бәйрәме уңае белән язылган; «Эш»нең 1919 ел, 5 ноябрь (341) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган.

340 бит.

**Деникинның төше**. «Эш»нең 1919 ел, 28 ноябрь (356) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәр-

ләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Керәш еллары» (1958), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

342 бит.

**«Солых булгач...»** Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

344 бит.

**Буржуй теләге**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

346 бит.

**Нәсер (Күк йөзе — бер барабан ул...)** Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган.

348 бит.

**Аклар сафыннан**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Солдат сөйләве рәвешендә язылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

349 бит.

**Ирек таңы**. «Эш»нең 1919 ел, 2 февраль (158) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

350 бит.

**Капиталга**. «Эш»нең 1919 ел, 3 февраль (159) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган.

351 бит.

**Хаталык**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган.

352 бит.

**Берләшегез, бөтен дөнья эшчеләре!** «Эш»нең 1919 ел, 10 декабрь (364) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

353 бит.

**Белә алмыйм**. «Бетмәде әле» дигән шигырьнең беренче өлеше буларак язылган. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Соңыннан «Яңа декламатор» (1925), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

354 бит.

**Бетмәде әле**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

355 бит.

**Халык җырынча**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Аннары «Әсәрләр» (1935), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

357 бит.

**Тәмле нигъмәтләр өстәле**. Беренче тапкыр «Декламацияләр (1921) җыентыгында басылган.

359 бит.

**«Без кол идек бай кулында...»** «Эш»нең 1918 ел, 4 ноябрь (91) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

361 бит.

**Вильһелм тәхетеннән төште**. «Эш»нең 1918 ел, 13 ноябрь (96) санында имзасыз басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән. Германиянең соңгы императоры Вильһелмнең тәхеттән төшерелүе көннәрендә язылган.

[1] *Һөд-һөд* – күкедән зуррак чуар кош. Шәрекъта, ул кошның очып килүенә карап, Нил елгасының ташуын белгәннәр. Легендаларда, төрле халыкларда бу кош хәбәр китерүче буларак танылган.

362 бит.

**Капитал тозагында**. «Эш»нең 1918 ел, 16 декабрь (122) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

363 бит.

**Туфан**. «Эш»нең 1918 ел, 19 декабрь (124) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

364 бит.

**Әсир моңы**. «Эш»нең 1919 ел, 5 гыйнвар (136) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган.

366 бит.

**Безнең файда**. «Эш»нең 1919 ел, 10 гыйнвар (140) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

367 бит.

**Нәсер (Усал булсаң – асарлар...)**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

[1] *...ел элек...* – шигырьнең төрле елларда укылачагын искә алып, автор конкрет елны күрсәтмәгән, өч нокта куйган.
[2] *Хозер, Ильяс* – 451 биттәге искәрмәне карагыз.

369 бит

**Кызыл фронтта**. «Эш»нең 1919 ел, 21 гыйнвар (149) санында «Ишан Гали» имзасы белән, ә 1919 ел, 24 март (198) санында «Кызыл» имзасы белән басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

371 бит.

**Бары да кача**. «Эш»нең 1919 ел, 22 гыйнвар (150) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган.

372 бит.

**Теләк**. «Эш»нең 1919 ел, 16 гыйнвар (145) санында «Ишан Гали» имзасы белән басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

373 бит.

**«Яңгыратып әйтсә дә ирек азаны...»** Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

375 бит.

**Элек һәм хәзер**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Кабат «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1951), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

377 бит.

**Алга!** «Эш»нең 1919 ел, 22 май (231) санында «Әдип»* имзасы белән басылган. «Декламацияләр» (1954), «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр» (1951), «Татар совет поэзиясе» (1952), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

378 бит.

**Табышмаклар**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган. Соңыннан «Әсәрләр» (1935), «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән.

379 бит.

**Корды, балам, бу кала**. Беренче тапкыр «Декламацияләр» (1921) җыентыгында басылган.

Г.Камалның «Корсын, балам, бу кала» дигән сәхнә әсәре шушы шигырьне үстереп язылган.

### Төрле елларда язылган шигырьләрдән

380 бит.

**Ак бөркәнчек**. 1921 елда язылган тәрҗемә шигырь. Беренче тапкыр «Сайланма әсәрләр» (1938), «Әсәрләр»гә (1979) кертелгән. Соңыннан «Әсәрләр» (1951) томына кертелгән. «Михайловтан алынды» дигән искәрмәсе бар. Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 2 сакл. б.).

[1] Бу әсәрнең төп авторы чех революцион шагыйре Һартман Моритс (1821–1872). Аның бу шигырен русчага М.Л.Михайлов тәрҗемә итеп бастырган.

*Михайлов* – Михайлов Михаил Ларионович (Илларионович, 1829–1865), рус революционеры, язучы һәм публицист. 1852 елдан башлап «Современник» журналында демократик рухлы шигырьләрен, тәрҗемәләрен, мәкаләләрен бастырган. 1861 елда кулга алынган, 1865 елда сөргендә һәлак булган.

382 бит.

**Кыз белән җегет**. 1931 елда язылган. Беренче тапкыр «Әсәрләр» (1951) дә басылган. Кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 17 сакл б.).

Бу исемдә Г.Камалның тагын бер әсәре бар. Анысы «Мин яратам ударникны» дип башлана.

384 бит.

**15 ел**. Беренче тапкыр «Әсәрләр» (1951) томында басылган. Бөек Октябрь социалистик революциясенең 15 еллык бәйрәме уңае белән язылган. «Нәсер» исемле элекке шигыре файдаланылган. Кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 16 сакл. б.).

---

* Имзаның язылышы буталчык. Якынча «Әдип» һәм «Совдеп» дип укыла.

## Кушымта

387 бит.

**Хафизәләм иркәм (1).** Пьесаның 1921–1922 елларда язылган беренче варианты. 1922 елның 7 апрелендә премьерасы булган (447 биттәге искәрмәне карагыз). Кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 4 сакл. б.).

409 бит.

**Өч тормыш (1).** Шул исемдәге мәгълүм әсәрнең беренче варианты. 1929–1930 еллар тирәсендә язылган дип уйланыла. Томдагы төп текстган шактый нык аерылып тора. Кулъязмасы Г. Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 15 сакл. б.).

[1] *Рәсулулла саллалаһе галәйһи вә сәллам заманында, гасрый сәгадәттә булмаган бидгать нәрсәләр...* – ислам дине өйрәтүләре буенча Алланың илчесе дип танылган Мөхәммәд пигамбәр белән якын мөнәсәбәттә булып эш иткән кешеләр һәм ислам диненең дөньяга таралган «бәхет гасыры»нда булмаган, ислам диненең төп кануннарында каралмаган нәрсәләр...

420 бит.

**Күзсез мастерлар (1).** 451 биттәге искәрмәне карагыз. Шушы исемдә томга кертелгән пьесаның бер варианты. Сукырлар тормышы турындагы бу әсәрнең яңалифчә кулъязмасы Г. Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 10 сакл. б.).

430 бит.

**Беренче театр (оперетта).** «Совет әдәбияты» журналының 1935 ел, 6 июнь санында басылган. Соңыннан «Әсәрләр»гә (1951) кертелгән. Автор «Беренче театр» комедиясен 3 пәрдәле оперетта итеп яза башлаган. Әмма ул тәмамланмый калган. Журналда кулъязманың гади дәфтәрдә яңалифчә язылуы әйтелсә дә, кайда саклануы күрсәтелмәгән. Әлегә ул кулъязма табылмады.

[1] *Яңа чыга башлаган «Казан мөхбире»...* – «Казан мөхбире» – 1905 елның 29 октябреннән 1911 елга кадәр (барысы – 416 сан) чыккан либераль-буржуаз газета.

[2] *Габделхәмид* (1842–1918) – 1876–1909 елларда Төркия солтаны. 1878 елда Төркиянең дәүләт мәҗлесен (парламентын) тарата, илдә деспотизм урнаштыра.

[3] *Кәнеҗ төрекләре* (*«Яшь төрекләр»*) – Төркиядә буржуаз революция ясау нияте белән төзелгән партия. 1908 елда дәүләт башына килә, ләкин ахырга таба бөтен демократик вәгъдәләреннән ваз кичә, буржуаз милләтчелек сукмагы белән китә.

[4] Бу өзек аңлашылып җитми. Биредә Дуду Шакир, гарәпләр алдында мактанып, дусларына напирләр дип эндәшә булса кирәк. Гарәпләр бу хәлне могҗиза дип бәялиләр.

435 бит.

**Хатыннар тегүчесе**. Тәрҗемә. Француз язучысы М.Вит әсәре. Кулъязманың титул битендә «Мөтәрҗиме Галиәсгар Камал, 15 май, 1923» дип күрсәтелгән. Гарәп графикасындагы кулъязмасы Г.Ибраһимов исем. институт архивында саклана (13 ф. 1 тасв. 27 сакл. б.).

[1] *Дузэ* – Элеонора Дузэ (1858–1924), итальян актрисасы. 1890–1892 һәм 1908 елларда Россия сәхнәләрендә дә уйный.

## ИКЕНЧЕ ТОМДАГЫ ӘСӘРЛӘРНЕҢ АЛФАВИТ ТӘРТИБЕНДӘГЕ ИСЕМЛЕГЕ


| | Текст | Искәрмә |
|---|---|---|
| **А** | | |
| Аҗак белән Кужак (1) | 182 | 453 |
| Аҗак белән Кужак (2) | 185 | 453 |
| Азатлык | 210 | 454 |
| Ак бөркәнчек | 380 | 471 |
| «Ак»ка шөкер» китабы | 239 | 458 |
| Аклар сафыннан | 348 | 469 |
| Актык йомрык | 280 | 461 |
| Алга! | 377 | 471 |
| «Арыслан да сөяк ашый...» | 318 | 464 |
| **Ә** | | |
| Әсир моңы | 364 | 470 |
| Әүвәлгечә түгел | 325 | 467 |
| **Б** | | |
| Бай | 313 | 464 |
| Бай – кибетче | 252 | 459 |
| Байлар бишеге | 281 | 461 |
| Бай сүзе | 326 | 467 |
| «Бакырган» китабы | 243 | 458 |
| Бары да кача | 371 | 470 |
| «Бәдәвам» китабы | 246 | 458 |
| Бәйрәм хәзерлекләре | 231 | 456 |
| Бәрәңге | 324 | 466 |
| «Без кол идек...» | 359 | 470 |
| Безнең кирәк | 213 | 455 |
| Безнең файда | 366 | 470 |
| Белә алмыйм | 353 | 469 |
| Бер ел элек | 297 | 463 |
| Беренче театр | 430 | 472 |
| Бер, ике, өч | 277 | 461 |
| Берләшегез, бөтен дөнья эшчеләре! | 352 | 469 |
| Бер рәсемгә | 322 | 465 |
| Бетмәде әле | 354 | 469 |
| Бию көе | 329 | 468 |
| Бозау | 129 | 451 |
| Большевизм көрәше | 332 | 468 |
| Булса да булыр шул | 293 | 463 |
| Буржуй зары | 267 | 460 |
| «Буржуйны без яратмыйбыз...» | 330 | 468 |
| Буржуй теләге | 344 | 469 |
| Буржуй планы | 271 | 461 |
| Бүген бәйрәм | 334 | 468 |

| | Текст | Искәрмә |
|---|---|---|
| **В** | | |
| Вакыт җитте | 223 | 455 |
| Вильһелм тәхетеннән төште | 361 | 470 |
| Вәгазь-нәсихәтләр | 295 | 463 |
| **Г** | | |
| Галәбә | 279 | 461 |
| **Д** | | |
| Деникинның төше | 340 | 468 |
| **Е** | | |
| Европа җанварлары | 299 | 463 |
| Егъламаган балага имчәк бирмиләр | 221 | 455 |
| **Җ** | | |
| Җанлы кино | 174 | 452 |
| Җантаһир белән Җанзөһрә | 142 | 451 |
| **З** | | |
| Зар | 336 | 468 |
| **И** | | |
| Игенченең зары | 278 | 461 |
| Ике ел | 338 | 468 |
| Ике туган Алкоголь, Прогул | 186 | 453 |
| «И мөселман, йокламагыл...» | 215 | 455 |
| Ирек авыруы | 308 | 464 |
| Ирек нуры | 269 | 460 |
| Ирек таңы | 349 | 469 |
| Исемнәр | 320 | 465 |
| Истикъбаль | 245 | 458 |
| «Ишан Гали» сәяхәте | 301 | 463 |
| **Й** | | |
| Йокыда | 219 | 455 |
| **К** | | |
| Казаннан хатлар | 178 | 452 |
| Капиталга | 350 | 469 |
| Капитал иярченнәренә | 303 | 463 |
| Капитал тозагында | 362 | 470 |
| Каралларга | 294 | 463 |
| Кар күрәгәндә | 262 | 460 |
| Кем көчле? | 298 | 463 |
| Контроль будкасы | 159 | 452 |
| Корды, балам, бу кала | 379 | 472 |
| Корсак | 275 | 461 |
| Корфетдин белән Торфетдин | 198 | 453 |
| Кыз белән җегет | 382 | 472 |
| «Кызыл алма» китабы | 237 | 458 |
| Кызыл армияләрнең Беренче май җырлары | 287 | 462 |
| Кызыл армияле һәм спекулянт | 265 | 460 |
| Кызыл кара, кызыл-кара | 333 | 468 |
| Кызыл фронтта | 369 | 470 |

| | Текст | Искәрмә |
|---|---|---|
| Күзсез мастерлар | 122 | 451 |
| Күзсез мастерлар (1) | 420 | 473 |
| **М** | | |
| Маленькие недостатки механизма | 259 | 460 |
| «Матур яр, кенәри» көенә | 316 | 465 |
| Мәхбүс шаһзадә | 229 | 456 |
| Милләт көймәсе | 217 | 455 |
| Милләтчеләр, динчеләр | 290 | 462 |
| Минем теләк (1) | 311 | 464 |
| Минем теләк (2) | 328 | 467 |
| Мин сөям | 250 | 459 |
| Могҗиза | 107 | 450 |
| **Н** | | |
| Ниләр бетте, ниләр калды? | 254 | 459 |
| Нәрсә сөйләргә кирәк? | 323 | 466 |
| Нәсер («Күк йөзе – бер барабан ул...») | 346 | 469 |
| Нәсер («Усал булсаң – асарлар...») | 367 | 470 |
| Нәүрүз мөбарәк бад! | 285 | 462 |
| Нәүрүз (яки Науруз) | 288 | 463 |
| **О** | | |
| Оренбур–Казан | 227 | 455 |
| **Ө** | | |
| Өндәү | 211 | 454 |
| Өр-яңа «Кисекбаш» китабы | 241 | 458 |
| Өч тормыш | 43 | 448 |
| Өч тормыш (1) | 409 | 472 |
| **П** | | |
| Пәрәвез | 260 | 460 |
| Прорывлар (1) | 189 | 453 |
| Прорывлар (2) | 191 | 453 |
| **Р** | | |
| Русиядә мөселманнар | 212 | 454 |
| **С** | | |
| Сез һәм без | 270 | 460 |
| «Солых булгач...» | 342 | 469 |
| Спекулянтка | 304 | 464 |
| Сөйләшү | 256 | 459 |
| **Т** | | |
| Табышмаклар | 378 | 472 |
| Тагы «Гаҗәб» китабы | 235 | 457 |
| Таң | 307 | 464 |
| Татарга | 264 | 460 |
| «Тәкый гаҗәб» | 230 | 456 |
| Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман | 79 | 449 |
| Тәмле нигъмәтләр өстәле | 357 | 469 |
| Теләк | 372 | 470 |
| Төш тәгъбире | 305 | 463 |
| Туфан | 363 | 470 |

| | Текст | Искәрмә |
|---|---|---|
| **У** | | |
| Ударник | 208 | 454 |
| Ударник һәм бездарник | 206 | 454 |
| 15 ел | 384 | 471 |
| **Ф** | | |
| Флот килә | 283 | 462 |
| **Х** | | |
| Халык җырынча | 355 | 469 |
| Хаталык | 351 | 469 |
| Хатип белән Латип | 203 | 453 |
| Хатыннар тегүчесе | 435 | 472 |
| Хафизәләм иркәм | 7 | 447 |
| Хафизәләм иркәм (1) | 387 | 472 |
| **Һ** | | |
| Һай дөнья! | 314 | 464 |
| Һиндстан факире | 193 | 453 |
| **Ч** | | |
| Чагыштыру | 273 | 461 |
| Чегән бәете | 309 | 464 |
| **Ш** | | |
| Шайтаннар биюе | 291 | 462 |
| **Ы** | | |
| Ысулы кадимче | 62 | 449 |
| **Э** | | |
| Элек һәм хәзер | 375 | 471 |
| **Я** | | |
| Яңа типта халык җырлары | 268 | 460 |
| Яңа «Тәкый гаҗәб» | 233 | 457 |
| Яңа «Җизнәкәй» | 317 | 465 |
| «Яңгыратып әйтсә дә ирек азаны...» | 373 | 471 |
| Ярлының җыруы | 261 | 460 |
| Ять (Ѣ) һәм ия (іа)не бетерү | 251 | 459 |
| «Яшен» сукмасын өчен | 226 | 455 |
| Яңа «Башмак» көе | 257 | 460 |

## ЭЧТӘЛЕК

### Пьесалар


Хафизәләм иркәм ........ 7
Өч тормыш ........ 43
Ысулы кадимче ........ 62
Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман ........ 79
Могҗиза ........ 107
Күзсез мастерлар ........ 122
Бозау ........ 129
Җантаһир белән Җанзөһрә ........ 142


### Эстрада әсәрләре


Контроль будкасы ........ 159
Җанлы кино ........ 174
Казаннан хатлар ........ 178
Аҗак белән Куҗак (1) ........ 182
Ажак белән Куҗак (2) ........ 185
Ике туган Алкоголь, Прогул ........ 186
Прорывлар (1) ........ 189
Прорывлар (2) ........ 191
Һиндстан факире ........ 193
Корфетдин белән Торфетдин ........ 198
Хатип белән Латип ........ 203
Ударник һәм бездарник ........ 206
Ударник ........ 208


### Шигырьләр
*(1905–1910)*


Азатлык ........ 210
Өндәү ........ 211
Русиядә мөселманнар ........ 212
Безнең кирәк ........ 213
«И мөселман, йокламагыл...» ........ 215
Милләт көймәсе ........ 217
Йокыда ........ 219
Егъламаган балага имчәк бирмиләр ........ 221
Вакыт җитте ........ 223
«Яшен» сукмасын өчен ........ 226
Оренбур – Казан ........ 227
Мәхбүс шаһзадә ........ 229
«Тәкый гаҗәб» ........ 230
Бәйрәм хәзерлекләре ........ 231


### Декламацияләр
*(1918–1921)*


Яңа «Тәкый гаҗәб» ........ 233
Тагы «Гаҗәб» китабы ........ 235
«Кызыл алма» китабы ........ 237

«Ак»ка шөкер» китабы ........ 239
Өр-яңа «Кисекбаш» китабы ........ 241
«Бакырган» китабы ........ 243
Истикъбаль ........ 245
«Бәдәвам» китабы ........ 246
Мин сөям ........ 250
Ять (Ѣ) һәм ия (ія)не бетерү ........ 251
Бай – кибетче ........ 252
Ниләр бетте, ниләр калды? ........ 254
Сөйләшү ........ 256
Яңа «Башмак» көе ........ 257
Маленькие недостатки механизма ........ 259
Пәрәвез ........ 260
Ярлының җыруы ........ 261
Кар күргәндә ........ 262
Татарга ........ 264
Кызыл армияле һәм спекулянт ........ 265
Буржуй зары ........ 267
Яңа типта халык җырлары ........ 268
Ирек нуры ........ 269
Сез һәм без ........ 270
Буржуй планы ........ 271
Чагыштыру ........ 273
Корсак ........ 275
Бер, ике, өч ........ 277
Игенченең зары ........ 278
Галәбә ........ 279
Актык йомрык ........ 280
Байлар бишеге ........ 281
Флот килә ........ 283
Нәүрүз мөбарәк бад! ........ 285
Кызыл армиялеләрнең Беренче май җырлары ........ 287
Нәүрүз (яки Науруз) ........ 288
Милләтчеләр, динчеләр ........ 290
Шайтаннар биюе ........ 291
Булса да булыр шул ........ 293
Караларга ........ 294
Вәгазь-нәсихәтләр ........ 295
Бер ел элек ........ 297
Кем көчле? ........ 298
Европа җанварлары ........ 299
«Ишан Гали» сәяхәте ........ 301
Капитал иярченнәренә ........ 303
Спекулянтка ........ 304
Төш тәгъбире ........ 305
Таң ........ 307
Ирек авыруы ........ 308
Чегән бәете ........ 309
Минем теләк (1) ........ 311
Бай ........ 313
Һай дөнья! ........ 314
«Матур яр, кенәри» көенә ........ 316
Яңа «Җизнәкәй» ........ 317
«Арыслан да сөяк ашый...» ........ 318
Исемнәр ........ 320
Бер рәсемгә ........ 322

Нәрсә сөйләргә кирәк? ........ 323
Бәрәңге ........ 324
Әүвәлгечә түгел ........ 325
Бай сүзе ........ 326
Минем теләк (2) ........ 328
Бию көе ........ 329
«Буржуйны без яратмыйбыз...» ........ 330
Большевизм көрәше ........ 332
Кызыл кара, кызыл-кара ........ 333
Бүген бәйрәм ........ 334
Зар ........ 336
Ике ел ........ 338
Деникинның төше ........ 340
«Солых булгач...» ........ 342
Буржуй теләге ........ 344
Нәсер («Күк йөзе – бер барабан ул...») ........ 346
Аклар сафыннан ........ 348
Ирек таңы ........ 349
Капиталга ........ 350
Хаталык ........ 351
Берләшеңез, бөтен дөнья эшчеләре! ........ 352
Белә алмыйм ........ 353
Бетмәде әле ........ 354
Халык җырынча ........ 355
Тәмле нигъмәтләр өстәле ........ 357
«Без кол идек...» ........ 359
Вильһелм тәхетеннән төште ........ 361
Капитал тозагында ........ 362
Туфан ........ 363
Әсир моңы ........ 364
Безнең файда ........ 366
Нәсер («Усал булсаң – асарлар...») ........ 367
Кызыл фронтта ........ 369
Бары да кача ........ 371
Теләк ........ 372
«Яңгыратып әйтсә дә ирек азаны...» ........ 373
Элек һәм хәзер ........ 375
Алга! ........ 377
Табышмаклар ........ 378
Корды, балам, бу кала ........ 379

**Төрле елларда язылган шигырьләрдән**

Ак бөркәнчек ........ 380
Кыз белән җегет ........ 382
15 ел ........ 384

**Кушымта**

Хафизәләм иркәм (1) ........ 387
Өч тормыш (1) ........ 409
Күзсез мастерлар (1) ........ 420
Беренче театр ........ 430
Хатыннар тегүчесе ........ 435

Искәрмә һәм аңлатмалар ........ 442
Икенче томдагы әсәрләрнең алфавит тәртибендәге исемлеге ........ 473

Литературно-художественное издание

**Камал** Галиасгар
(**Камалетдинов** Галиасгар Галиакберович)

**СОЧИНЕНИЯ**

Издание второе, исправленное и дополненное

В трех томах

Том 2

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Камал** Галиәсгар
(**Камалетдинов** Галиәсгар Галиәкбәр улы)

**ӘСӘРЛӘР**

Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма

Өч томда

2 том

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Л.Р.Галимова, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.06.2010.
Форматы 84´108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 25,20.
Тиражы 2100 д. Заказ О-703.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.